# КАЗАН УТЛАРЫ

9. 1991



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:
ТАТАРСТАН ССРның ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**9**

**1991**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ

**Ф. ЯРУЛЛИН.** Коткарыгыз. *Поэма-монолог* ........ 3
**Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.** Күкеле паровозлар. *Шигырьләр* ........ 7
**Ф. ГАБДРӘХИМ.** И горур зат!.. *Шигырьләр* ........ 116
**Р. ИДИЯТУЛЛИН.** Ачлык баскан елда... *Шигырьләр* ........ 117
**С. РӘХМӘТУЛЛА.** Очрашулар... *Шигырьләр* ........ 118
**Р. ГАТАУЛЛИН.** Үз чорыңны ничек танырга... *Шигырьләр* ........ 118
**М. НӘЗИРОВ.** Бу дөньяда бар шул әле... *Шигырьләр* ........ 119
**Н. ӘМИНЕВА.** Диңгездән түгел, йолдыздан... *Шигырьләр* ........ 120
**Ф. СУФИЯРОВ.** Ир итте. *Шигырь* ........ 120
**В. МУСИНА.** Әй... *Шигырьләр* ........ 121
**К. ШӘФИКОВА.** Тел бозылды... *Шигырьләр* ........ 121

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**БАТУЛЛА.** Сөембикә кыйссасы. *Роман* ........ 9
**Ф. ГЫЙЛЬМИ.** Зәйтүнәкәй, акчарлагым. *Хикәя* ........ 108

ПУБЛИЦИСТИКА

**М. ЗАРИПОВ.** Бал нигә кыйммәт? ........ 122

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ә. СӘХАПОВ.** Заманга җавап бирәбезме? ........ 136

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. ӘМИРХАН.** Җилгә карап кыйбланы үзгәртмик ........ 141

Яңа әсәр укыгач ........ 147

СӘНГАТЬ

**Ф. ЯРУЛЛИН.** Авылның җиденче чишмәсе ........ 151

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

**Р. ФӘХРЕТДИНОВ.** Татар углы татармын ........ 157

*Баш мөхәррир*

**РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН**

*Редколлегия*

**ГАРИФ АХУНОВ**
**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ФЛҮС ЛАТЫЙФИ**
*(җаваплы сәркәтип)*
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**МАРАТ МӨЛЕКОВ**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
**РАШАТ НИЗАМИЕВ**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**ГӘРӘЙ РӘХИМ**
**КОЯШ ТИМБИКОВА**
*(бүлек мөхәррире)*
**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ**
**ТӘУФИКЪ ӘЙДИ**
*(бүлек мөхәррире)*
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

Коръән сүрәләре ........ 167

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

**Ф. ИБРАҺИМОВ.** Иж-Буби шәкерте ........ 178

Укучы сүзе ........ 184

Котлыйбыз! ........ 177, 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190
Тышлыктагы сурәтләр ........ 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: окончание романа Р. БАТУЛЛЫ «Сказание о Сююмбике», рассказ Ф. ГЫЙЛЬМИ «Зайтуна моя любимая»; поэма-монолог Ф. ЯРУЛЛИНА, стихи Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Ф. ГАБДРАХИМА, Р. ИДИЯТУЛЛИНА, С. РАХМАТУЛЛЫ, Р. ГАТАУЛЛИНА, М. НАЗИРОВА, Н. АМИНОВОЙ, Ф. СУФИЯРОВА, В. МУСИНОЙ, К. ШАФИКОВОЙ.
«Публицистика»: М. ЗАРИПОВ. «Почему мед очень дорог?»
«Литературная критика»: А. САХАПОВ. «Отвечаем ли мы зову времени?»
«Книжное обозрение»: Р. АМИРХАН рецензирует четырехтомник Ф. Амирхана.
«Искусство»: Ф. ЯРУЛЛИН. «Седьмой родник деревни».
«Из истории нашего народа»: Р. ФАХРУТДИНОВ. «Я татарин — сын татара».
Суры из Корана.
«История культуры»: Ф. ИБРАГИМОВ. «Шакирд из медреси Иж-Буби».
Слово читателя.
Поздравляем юбиляров.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Золотой узор на коже»; известный писатель и драматург Ш. Хусаинов.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 17.07.1991 ел. Басарга кул куелды 18.09.1991 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 38377. Заказ И-343. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

# Фәнис Яруллин

## Коткарыгыз

### РӘНЖЕТЕЛГӘН КЕШЕ МОНОЛОГЫ

1

Орден сатам, орден сатам!
Кемгә кирәк? Йә, алыгыз.
Түшегезгә орден таккач,
Үсеп китәчәк данызгыз...

Орден сатам! Шәп орден бу,
Ришвәт биреп алынмаган.
Өр-яңа ул, чөнки түшкә
Бер тапкыр да тагылмаган.

Үз хуҗасы кулына тотып
Карамаган аны бер дә...

Иярен эзләп йөргән
Даннар күпме әле җирдә.

...Кырык бишнең шаулы язы!
Җиңүчеләр өйгә кайта,
Солдат кайткан һәрбер йортта
Кочак булып ачыла капка.

Менә безнең капканы да
Яңа хәбәр килеп какты:
Әтиебез кайтмаса да,
Даны кайтты — орден кайтты.

2

Ул елларны бәйнә-бәйнә
Язар идем, кәгазь янар.
Ялкыннары өр-яңадан
Йөрәгемә килеп кабар.

Әле һаман төшләремә
Керә шушы авыр еллар:
Йөзләр тулы сары сагыш,
Күзләр тулы эремәс моңнар.

Иреннәрдә елмаю юк,
Хәсрәт изгән карт аналар...
Туу белән тормыш баскан
Җыерчыклы карт балалар...

Бер кабымлык ипи эзләп,
Балачакны югалттык без.
Барыбер бер табарбыз дип,
Күңелләрне юаттык без.

Еласак та яшебезне
Сөртте бары җилләр генә.
Ә кычкырсак, тавышыбызны
Йотты кара төннәр генә.

Өметләрне учак итеп
Шул төннәргә яккан чакта,
Нәфрәтләрне, уклар итеп,
Шул төннәргә аткан чакта —

Орден кайтты. Әйтерсең лә
Кысыр сыер бозаулады:
Ачылып китте күңелләрнең
Авыр тимер богаулары.

Әй, сөендек, әй, сөендек!
Шатлык күргән бармы безнең?!
Инде авыр болытлары
Таралыр, шәт, күгебезнең.

---

Фәнис ЯРУЛЛИН *(1938) — танылган шагыйрь, әдип, драматург; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы шигырь, проза китаплары авторы, М. Җәлил бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Качар өйдән хәерчелек —
Бәхетебез йөрер алдан.
Бу орденны әткәбез бит
Үз гомерен бирсп алган.

Кем керсә дә күрсәтәбез,
Мактанырга хакыбыз бар.

Әйтерсең лә кулыбызда
Орден түгел, атыбыз бар...

Кем уйлаган ул орденның
Безгә ниләр китерәсен:
Тереклек сулары биргән
Чишмәбезне киптерәсен!

3

Истә әле, кичкә таба
Килеп керде ике кеше.
(Хәлне язып аңлатырга
Җитәр микән каләм көче.)

Әни, мескен, кабаланып
Нидер куйды, нидер алды.
Ә аннары, исенә төшеп,
Самавырга күмер салды.

Кем керсә дә чәен куя —
Шундый инде безнең халык:
Дошманымы, дустымы ул —
Сыйлый соңгы сыен салып.

Безгә кергән бәндәләрнең
Карашлары чалыш иде.
Кулларында кара сумка,
Шунда безнең язмыш иде.

Түләнмәгән налогларның
Кыштырдауга кәгазьләре,
Әни кинәт чүгеп куйды,
Кәгазьдәй булды йөзләре.

Һәм тезләнде безнең әни
Бу бәндәләр каршысында.
Ялварды ул, бәргәләнеп,
Туймый күз яшь ачысын да:

«Коткарыгыз, зинһар өчен,
Бу налоглар җәбереннән.
Үлгәч тә рәхмәт укырмын
Торып-торып каберемнән.

Коткарыгыз, коткар, зинһар,
Шушы балам хакы өчен.
Иремнең иленә кайткан
Батыр дигән аты өчен.

Күрәсез бит, һичнәрсәм юк,—
Карап торган бер сыерым.
Ул да быел бозау салды,
Килсә килә бит ул кырын...»

Әни озак өзгәләнде
Түбәнсетеп горурлыгын.
Юкса, күреп торды инде
Боларда һич шәфкать югын.

Намусларын бу бәндәләр
Күптән сатып эчкән инде.
Вөҗданнары — ишелеп торган
Корсак булып үскән инде.

Сине сыту, изү, таптау
Аларга тик ләззәт кенә.
Ашый алар үз корбанын
Әкрен генә, тәмләп кенә.

Заманы шул: куркак җаннар
Җанын сатып батырлана.
Һәм яманлык ил буенча
Миллионнарга тапкырлана.

Алыйм дисәң куркакларның
Соңгы тамчы кешелеген —
Кулларына власть тоттыр,
Власть яшерер мескенлеген.

Әнә алар бау салалар
Сыерыбыз муенына.
Сыер, мөгрәп, безгә карый:
«Яклагызчы, кыен миңа.

Сукаларга җиккәндә дә
Карышмадым — тарттым, сөрдем,
Җаныгызны асрарлык
Һәр көн саен сөтен бирдем.

Заем, налог ишеләрне
Түләргә дә кирәк булдым.
Мин бит сезгә ничә еллар
Иң-иң ныклы терәк булдым!».

Тыпырчына мескен сыер,
Мөлдерәтеп карый күзен.
Хайван түгел, кешеләр дә
Яклый алмый кайчак үзен.

Түзмим, барып ябышам бауга,
Тешләшәм һәм тарткалашам.
Бауның башы сыртка төшә,
Ә мин ярсыйм, ә мин шашам.

Мине бәйләп ыргыталар,
Биттән сөртеп булмый канны.
Ишетелә әни тавышы,
Сискәндереп бөтен җанны.

Аңламыйча тордым берни,
Башым бик нык чатный иде.
Күзем ачсам, әни, ярсып,
Шул орденны таптый иде:

«Ил өчен дип бирдең җаның —
Менә сиңа, менә сиңа!
Җан урынына кайтты даның —
Менә сиңа, менә сиңа!

Җан сатканнар майда йөзә —
Менә сиңа, менә сиңа!
Көчсезләрне бар да изә —
Менә сиңа, менә сиңа!

Ләгънәтле ил бүләге —
Менә сиңа, менә сиңа!
Кимсетелгән ир йөрәге —
Менә сиңа, менә сиңа!

Ипи булсаң, ашар идек —
Менә сиңа, менә сиңа!

Утын булсаң, ягар идек —
Менә сиңа, менә сиңа!

Ямауга да ярамыйсың —
Менә сиңа, менә сиңа!
Җанны гына яралыйсың —
Менә сиңа, менә сиңа!»

Әни арып туктап калды
Һәм елады ятып җиргә...
Әнкәм яше тамган җирләр
Яшәрмәде кабат бер дә.

4

Күз алдымда шәүлә йөри,
Бу нинди котсыз шәүлә?
Балачагым өрәк булып
Әйләнеп кайткан мәллә?

Юл тузанына күмелеп,
Бәргәләнеп кем елый? —
Рәнҗетелгән бер сабый да...
Аңа кушылып гөл елый.

Иелә башы, түгелә яше,
Сүнеп бара кояшы.
Кулларында бер чыбыркы —
Тик шул аның юлдашы.

Орденны хурлаган өчен
Утырткannар әнкәсен.
Әнкәсеннән мәхрүм итеп
Җәзалыйлар бәбкәсен.

Агыла болыт, агыла болыт,
Агыла болыт ишелеп;
Бу кадәрле хаксызлыкны
Ник күрмисең, Кешелек!

Тибелә кеше, сүгелә кеше,
Чайкала уңга-сулга;
Бу кадәрле хурлауларга
Ничек түзәсең, Дөнья?

Кимсетелә гүзәл җаннар,
Тезләнә горур ирләр;
Бу кадәрле күз яшьләрен
Ничек күтәрә җирләр?!

Уф, түзә алмыйм, тавыш килә,
Чыңлый хәтта колаклар:
Ыңгырашып ята бугай
Мең корбанлы зиратлар.

Су бирегез, су бирегез —
Кирәк миңа Иделләр.
Җир йөзендә миллион әле
Яраланган күңелләр.

Йә, кайсыгыз тылсым белә?
Дәвалагыз шуларны.

Әллә инде ялварыймы,
Күккә сузып кулларны?

Инде кабат җир йөзендә
Булмас микән ГУЛАГлар?
Кара төндә ыңгырашып
Ятмас микән зиратлар?

Җаным кайный, каным кайный,
Уйлар мине тилертә.
Йөрәгемә әллә кемнәр
Һаман йөгән кигертә.

Чаң бирегез, чаң бирегез,
Чаң бирегез сез миңа;
Доң-доң иткән чаң тавышын
Ишетсен әле дөнья.

Чукраклар да ишетсеннәр
Бу тавышны җирдәге.
Аң уянсын, җан уянсын,
Сүз уянсын телдәге.

Ут бирегез, ут бирегез —
Бушады шәмдәлләрем:
Яктыртыйм әле йөзләрен
Мин явыз бәндәләрнең.

Күрсен дөнья, белсен дөнья
Кемнең кем икәнлеген:
Беркем яшереп калалмасын
Үзенең түбәнлеген.

Ут бирегез, ут бирегез,
Ут бирегез, ут кирәк:
Кара төннәрне яндырып,
Җирне яктыртыйм тизрәк.

Шул яктылык сукырларның
Күзен ачып җибәрсен.
Күрсен кеше үзен-үзе,
Әйтсен: — Ә без кемнәр соң?

Ут бирегез, ут бирегез,
Ут бирегез кулларга:
Маяк тезеп чыгыйм әле
Әнкәм кайтыр юлларга...

## 5

Хатлар язып торды әни
Миңа ерак-еракган:
«Монда да шул ук эш икән,
Шул ук көн дә, шул ук таң.

Без инде күптәннән бирле
«Төрмәдә икәнбез» бит,
Тик шуны үзебез генә
Белмәгән икәнбез бит:

Сыртыбызда уйнап торды
Бригадирның камчысы.
Анда ашалган икән бит
Икмәкнең иң ачысы...

Туды авыл кешеләре
Тик налог түләр өчен.
Гомре буе налог түләп,
Бурычлы үләр өчен.

Әй изелдек, әй изелдек!
Көлчә булып изелдек.
Гомер буе изелүгә
Ничек җитсен түземлек?

Әй тапталдык, әй тапталдык,
Тузан булып тапталдык.
Калмады һичбер көчебез
Үзебезне якларлык.

Әй кысылдык, әй кысылдык,
Кысылып та карадык!
Кысыла торгач, такта булдык
Тик табутка ярарлык.

Мин кайчак уйлап та куям,
Дөрес, ми сыек минем:
Коммунизм дигәннәре
Әллә шушымы, димен.

Беркемнең бер нәрсәсе юк —
Бар да шәрә, бар да ач:
Эшләр өчен куллар бар да...
Иелер өчен — мескен баш.

Без, улым, изелүләргә
Тәмам күнегеп беттек.
Әз генә изми торсалар,
Торабыз шуны көтеп.

Гүя «тиешле норманың»ны
Алмый калсаң ярамый.
Менә шушы нәрсә бигрәк
Йөрәкләрне яралый.

Түбәнгә төшү бер нәрсә —
Ансы бары бер яман.
Түбәнлеккә күнегеп китү —
Ансы инде мең яман.

Өч нәрсәдән саклан, балам,
Киңәшемне ташлама:
Беренчесе — бер кабым да
Хәрам ризык ашама.

Икенчесе — күңелеңә
Оялмасын ялган.
Ялган бар җирдә хаклык юк.
Шуны онытма, балам.

Өченчесе — иң мөһиме —
Шәфкатьсез була күрмә.
Шәфкатьсез кеше—тиран ул.
Шәфкатьсез дөнья—төрмә».

## 6

Әниемнең бу хатлары
Беткән инде, сакланмаган.
Хәер, алар хәтерләрдән
Җуелырлык ятланмаган!

Ул хатларны укыр өчен
Күпме чыра яндырдым мин.
Әниемне көтә-көтә
Күпме күзләр талдырдым мин.

Ул кайтмады, төрмә йотты,
Төрмәгә бит кирәк корбан.
Төрмә — җиде башлы Дию —
Кеше канын суыра торган.

Калтыранып уянамын
Һаман кара төннәрдә мин:
Хәер сорап йөрим, имеш,
Әллә кайсы җирләрдә мин.

Кулда капчык—киндер капчык,
Әнкәемнең соңгы төсе.
Ачлардан икмәк сорарга
Күзләремнең җитми көче.

Борылам да китеп барам,
Тотынмыйча ишекләргә.
Суык җилләр керә эчкә
Күлмәктәге тишекләрдән.

Һәр авылда, һәр урамда
Өреп кала явыз этләр...
Хәтер җебем нык тартылды,
Йә өзелер, туктыйм, җитәр!

...Орден сатам, орден сатам!
Шәп металлдан коелган ул.
Ә аннары ничә еллар
Күз яшь белән юылган ул.

Анда күпме өметләрнең
Кабынмаган чаткысы бар.
Анда әткәм гомеренең
Сүнеп калган яктысы бар.

Анда күпме хыялларның
Калкып торган кабере бар.
Анда каһәрле заманның
Һич онытылмас җәбере бар.

Орден сатам, орден сатам,—
Хакы тик шул — хәтерлә син:
Орден белән бирәчәкмен
Ул елларның хатирәсен...

*1990*

# Флера Гыйззәтуллина

## Күкеле паровозлар

Сезнең дә күкрәгегездә
Сызлаулы ярагыз бар,
Яшьлектә авыр йөк тарткан
Күкеле паровозлар[1].

Сезне дә безнең яшьлекнең
Дәрманы чорнап алган:
Ургылган утлы гудоклар
Ялкынлы торбалардан.

Уф! Уф! дип авыр сулауның
Бездә дә дәвамы бар:
Кешегә сансызлар безне
Күкегә санадылар.

Әнә шул «күке»леккә дә
Төшермәс өчен таплар,
Булды бит, булды:
—Кәк-күк!—дип,
Үксеп кычкырган чаклар.

***

Юк, үзем өчен оялып
Башымны имәм түбән:
Эшелоннарга йөк төяп,
Күкләргә тиде түбәм.

Төягән, сөйрәгән саен
Йөгебез авырланды,
Суырып үзенә һаман
Үзәкле тамырларны.

Котыртып, «акыллы баш»лар
Йөрделәр тирәбездә:
—Ташлагыз файдасыз йөкне—
Тамырын төйнәгез дә...
«Булмый ул, булмый, димәгез,
Тел белән этлек корып».

Күп вакыт «күке» ялгызы,
Этлекнең эте кырык.
Кырыгы бердәм тотынса
Һау-һаулап чабышырга...
Ишетелми башлый колакка
Гудоклар тавышы да.

Ялкыны сүнгән торбадан
Күңелгә корым сара,
Нык сызлый корым астында
Ачылмый калган яра.

«Күке»гә хезмәт халкыннан
Булса да хөрмәт олы,—
Сыйдырмый башлый, йончыгач,
Локомотивлар юлы.

***

Җитәм бит инде, җитәм мин
Гомерем чикләренә...
Үкенмим ләкин йөгемне
Калдырып китмәвемә.
Күрсәм дә бүген күпләрнең
Читләргә таралганын,—
Бу юлдан үзәк-тамырым
Куптарып алалмамын.

Эшлексез, илне кызганып,
Салам да сузмаганда,
Җанымны кырыкка ярып,
Мең ярам сызлаганда,—
Артка чигеним, бөлимме,
Үлимме «җайлы гына»?!

Әверелде минем бу эшем
Тарихи байлыгыма.
...Талатмас өчен тарихым
Торгынлык «эт»ләреннән,
Ярамны тотып капланам
Төялгән йөкләремә:
Хезмәт «күке»сен җанымда
Өйрәтеп кышлатырга,
Тереләм әле,—торам мин
Йөгемне бушатырга.
Хәтер гудогым янәдән
Очкынын чәчкән мәлдә:
—Кәк-күк!—дип җавап бирермен
«Күке!» дип дәшкәннәргә.

---

[1] Күкеле паровозлар—сугыш елларында тимер юл эшчеләрен эшкә йөрткән иске, кечкенә паровозлар. *Автор*.

## Мин — боз кошы

Тормыш итү—боз өстендә бию!—
Биим, шуам—кылам тамаша...
Акыл әйтә:
— Туктал кыланудан,—
Яшь гомерең узган лабаса!—
Күпме өметләрең җимерелгән,
Күңелеңдә калган боз катып.
Ничә бала табып үстергәнсең,
Үзәгеңне бозда сызлатып...

...Ә мин туктый алмыйм: тормыш куам.
Күзгесендә биеп хәтернең...
«Йөзең нигә алсу?» дигәннәргә
«Җаным ярсу!» диеп әйтермен...
Ниятләсәң, үз йөзеңне җуймый,
Җан тынычлыгына ашарга,
Тырыш Тормыш кагыйдәсендәге
Һәр ноктага туры басарга!
Аяк баскан урынында ялгыш
Ярылса боз, китсә убылып,
Имгәнмәсме рухи иминлегең —
Төшмәссеңме шунда егылып?..

Тормышыңда әгәр көч тапмасаң
Боз өсләрен көзге итәрлек —
Язмыш уттан аралаган парың
Бозларга да бәрә күтәреп.

Эзләремә карап, тормыштагы
Урынымны тарих билгеләр:
Эзләр коям боздан,
Көзге коям,
Уям тирән-тирән өлгеләр.

...Яндырган да, туңдырган да сөю:
Кара эзне—эзгә ялганмый!..
Мине парсыз, сөйгән ярсыз калу
Куркынычы мәллә сагалый?

Яз җылысы көткән «тамаша»чы
«Парлы бию» чакырып кул чаба.
... Боз шуудан мин туктала алмам,
Алкышлардан күңелем тулса да.

Ачы җилдән, давыллардан саклап,
Иңен куяр миңа кем элек?..
Мин — боз кошы!
Очам яз каршына,
Моңлы музыкага күмелеп.

Боздан утка ашкан ихтыярым
Төп халәтен җуймас хәтернең:
«Җаның нигә ярсу?» дигәннәргә,
«Сөеп ярсыдым!» дип әйтермен.

## Явызлык юк ярсу җаннарда

Ярсый дәрья,
Ярсый—дулкыннарын
Кагып мин сөялгән талларга.
Кем үчегә, күкрәк читлегемдә
Дәрьяга тиң ярсу җан барга!?
...Менә тагын, ничә дәрья кичкәч,
Авырлыклар кага — елларга,
Һуштан язмас өчен, бер җанымны
Яргалыймын кырык кылларга.
Уйлыйм, фикер йөртәм, бер төенгә
Төйнәп бөтен зиһен, акылым...
Табып, үз җанымда беркеткәндә
Замананың ярсу һәр кылын.
Кырык кылга бер юлысы чиртсәм,
«Уел» уем яшен яшьнәтер.

Гасыр күз яшенә тиңдәш итеп
Милләтемнең ачы хәсрәтен.

... Хәсрәт, нәфрәт ярдан ташкан саен,
Куркып үзе кылган хатадан,—
Ничә гасыр минем нәселемнең
Тамырларын җәллад таптаган!
Мөлкәтемне талап, туфрагыма
Басып кергән һәрбер «имгәк» бит
Моңлы йөрәк кылларына сугып
Интектергән минем милләтне.
Милләтемнең зур түземлелеге
Ярдәм итте шуны аңларга:
Явызлыкка каршы торыр көч бар!
Явызлык—юк, ярсу — җаннарда.

## Чәчмә әсәрләр

**Батулла**

# СӨЕМБИКӘ КЫЙССАСЫ

Атасына ул, тиз кайтам, диеп чынын әйтсә дә, вәгъдәсендә тора алмады. Чүл алачыгына килеп җиткәнче үк алар күрде: ваһа агачлыгы янында бер-ике дөя тора, еракта-еракта тагын берничә кучкыл күзгә чалына. Көтү таркау.

Аблак баба үлем ястыгында ята иде. Ахирәтләрне күргәч, бик куанды.

— Балаларым ... — диде дә өнсез калды.

Эш башланды. Таралган көтүне җыярга биш-алты кыз чыгып чапты, бер-ике кыз савылмаган дөяләрне саварга кереште. Калганнары тиз-тиз генә коедан су чыгара башлады. Шалтыр-шолтыр табак-савыт, казан юып, учак тергезеп җибәрделәр. Бабаның тагын бер сүзе булды:

— Чәй! — диде.

Аның куллары йөрми, аяклары да укмашып каткан, картның башын чак кына күтәреп, кашыклап чәй эчерделәр.

Аблак баба, бераз хәл алгач, әйтте:

— Аллаһ тәгалә... авызыма су тигезеп торыр өчен... җибәргән фәрештәләрдер сез ... — диде.

Ике-өч көн узгач, чүл карты күзгә күренеп тернәкләнә башлады. Сөйләшүе кыен булса да, кирәген әйтеп өлгерә иде:

— Фалиҗ сукты... башлап бу якны... Елдан артык... кырын-кырын йөрдем... Янә бу якка китереп орды... Өч тәүлек... Мендем ятакка... Җиденче көн ятам... Шушлай җан тартырга әзерләнеп беткән идем... Аллаһның рәхмәте...

Ахирәтләр утын-кизәк җыеп, абзарга кайтарып өйделәр. Корык, тура киптерделәр. Мал суеп, тутырма, казылык элделәр. Шулай итеп, айдан артык гомер узды. Аблак баба янында дүрт кызны калдырып, Сөен тутай атасы йортына кайтып китте.

Язда Аблак баба вафат итеп, дүрт кыз чүл эченнән чыкты.

Сөен тутай белән ахирәтләр бу гомер эчендә атасының китапханәсен тәртип итеп, алып кайткан кульязмаларны коры урынга тезеп, һәр китапның кайсы бүлмәдә, кайсы теземдә, кайсы киштәдә, кайсы турда икәнен бик тиз табар өчен аерым җәдвәл төзеп куйды. Дала да онытылды, ияр-кылыч та тузан җыя. Ахирәтләрнең чабышкылары да симереп, үшәнләнде. Кыз-ахирәтләрнең шулай өйтәшләмәс булып яшәүләре сарай халкы өчен бик тә куаныч. Комбар ата гына ара-тирә зарлангалый:

— Әрәм иттеләр елкыларны! Аша да ое, ое да аша, шулмы айгыр эше?

---

Ахыры. Башы журналның 8 санында.

Аптырагач, Комбар ата, Сөен тутайдан рөхсәт сорап, ахирәтләрнең юртакларына яшь мирзаларны, оланнарны атландырып, үзе дә Бүзтарланны иярләп, даладан әйләнгәләп кайта. Акбәкәл дә, Бүзтарлан да сабырланган; хәер, Комбар атаның үзенә дә иярдән төшәргә күптән вакыт.

Сөен тутайны баштарак сарайда, калада тотып булмый иде, хәзер кусаң да китапханәдән чыкмас, чатлап ябышкан. Аның серен китапларны тәртипкә тезүче ахирәтләре дә сизми, белми иде. Белсә дә, иң якыннары гына беләдер: Татлыбик, Сауфия, Нәргәтай. Сөен тутай китап яза — «Сәяхәтнамә». Ул бөтен күргәннәрен, уй-фикерләрен, сәфәр мажараларын кәгазьгә терки, язганын яшерә, һичкемгә күрсәтми. «Сәяхәтнамә» язылып, өч данә күчерелеп, өч явыздан — янгырдан, янгыннан, яудан саклар өчен төрле җиргә яшереп куелырга тиеш иде. Китап язылып бетте, шөкер. Өч каләм белән күчерә башларга кирәк... Сөен тутай, Сарайчык китапханәсен тәртип итеп бетергәч, ахирәтләре белән бергә сирәк кулъязмаларны берничә нөсхәгә күчерә башлады. Аның бу эшенә төрле кеше төрлечә бәя бирә килде. Берәүләре: кияүгә чыгып, бала үрчетәсе урында китап тузаны эчеп, сула бара дисә, сарай хәттатларының башлыгы Мостафа бахшы, Сөен тутайның китапка мәхәббәтен күреп, куана, җае чыккан саен тутайны хуплый, аңа сокланып карый. Сөен тутай гарәпчә язылган китапларны гына түгел, уйгыр, чин-кытай язуларын да укый-күчерә. Сөен тутай хәзер сирәк көлә, ат бәйгеләренә чыкмый, кәгазь өстенә иелеп, көннәр буе утыра, укый, яза.

Китапханә эчендәге салкынча тынлык, серлелеккә, салмак тормышка күнегеп җиткәндә генә Сөен тутай-бәгимнең күңеленә шом иңде. Бу билгесез шомның фаҗига көтү икәнен аңлады ул. Төшенәме керде бу шомлы хәтәр шикләнү галәмәте, әллә өнендә булдымы? Ярым караңгы, салкынча китапханәнең иң аулак почмагында ул гадәттәгечә язып утыра иде, аның янында таныш түгел бер дәрвиш пәйда булды. Сәлам бирмәде, сәлам алмады сәер карт, тутайга карамыйча гына, коңгырт тавышы белән:

— Койрыклы йолдыз килә-ә,— диде.— Синең күңелең шуңа тыныч түгел.

— Син кем, монда ничек индең?— дип сорады тутай.

Сәер карт аның сүзен ишетмәде дә:

— Якыная-а койрыклы йолдыз... Койрыклы йолдыз баш өстеннән узганда дөньяга ике афәт килер... Миһербан вә гүзәллек иясе вафат кыйлыр... Шул төндә ук мәкер вә Дәҗҗал углы дөньяга килер...

Шулай диде дә, серле карт дәрвиш юкка чыкты. Тутай-бәгим, нишләргә белмәенчә, аптырашта утырды. «Кем үлә, кем туачак?»— дип сораганчы, әлеге дәрвиштән җилләр искән. Күпме генә сорашса да, китапханәгә кем кергәнен берәү дә әйтә алмады. Бу сәер вакыйга турында ул төрлечә уйлап бакты. Төшенә кергәнне өн дип бутыймы? Ул көнне Сөен тутай, һич кузгалмыйча, эңгер төшкәнче укып утырды. Арган ми галәмәтләре булып, эңгерменгердә юк нәрсәнең дә күзгә күренүе ихтимал. Шул көннән соң аның йокысы качты. Урык-сурык йоклаганда күргән төшләре өндәге вакыйгалар белән бутала башлады. Ул китапханәгә йөрмәс булды. Көннәр, айлар ялгызы утырып, еш-еш өнендә дә, төшендә дә Хозыр Ильяска охшаш серле дәрвишне күреп, гел ханәкәсеннән чыкмаска эверелде. Табипларны да, имтомчыларны да күрергә теләмичә, ахирәтләре алып килгән китапларны укып, нидер язып, ашавын да ханәкәдә генә ашап яши башлады... Чыннан да, бер Сөен тутай гына сәер халәттә түгел иде, бик күпләрнең күңеленә билгесез шом иңде. Эч пошулар, сәбәпсезгә елаулар артты. Сылтаусыз, карымтасыз гына кеше үтерүләр ишәйде. Хәтта мал-туарлар да, ашаудан аерылып, шомраеп нидер тыңлый, нindидер билгесез куркыныч көтә сыман. Җир тетрәү алдыннан шулай була торган иде... Койрыклы йолдыз якынайганны бөтен узгынчылар, кәрванчы-сәүдәгәрләр бик еш сөйләп, ваба-мур киләсен дә әйтәләр. Шом өстенә шом өстәп, сихерчеләр, шаманнар да коточкыч гарасат булачагын сөйләп уза... Ул төнне Сөен тутай-бәгим бик яхшы хәтерли. Юлъязма дәфтәренә төгәл көнен дә теркәгән иде.

«Һиҗрәтдин соңра туккыз йөз дә утыз алтыда, Юлбарыс Елында җомадә әл-ахирә аеның унынчы төнендә таң беленгәч, куркып уйгандым.

Янә мин төшемдә Ирәмбагта пәйда булып, Шәддад падишаһ белән кочаклашырга дип якынайганда, Каракош заһир кыйлып, Шәддад падишаһны чукып-талап үлтермеш. Аннан соңра Каракош мине чукый-тырный башлады. Күземне чукыганда уйганып, котылмышмын».

Шул төнне Койрыклы йолдызның, дала өстеннән очып, Көнбаеш ягына киткәнлеген әйттеләр. Узгынчылар Хаҗитархан, Кырым вә Юнан-Фрәнк илләрендә бик каты җир тетрәгәнлеге турында хәбәр итте. Мур үләте чыгып, аяклы мал кырылулар, Казан ягындагы мөселманнарның күпләп кырылуы да булды ул елны... Әкренләп, Койрыклы йолдыз онытылды. Әмма әлеге сәер дәрвиш Сөен тутай күзенә тагын күренде. Тагын шулай әңгер чак иде. Тавышсыз гына ханәкәгә кереп, тутайны куркытты. Тутай ялангач иде: ул, кычкырып, өстенә идән келәмен каплап өлгерде, ләкин дәрвиш аңа дикъкать итмәде, диварга сөйләнгәндәй, тутайга бакмастан, сөйләнә башлады:

— Койрыклы йолды-ыз искәртеп китте-е... Мөселманга зыян эшләп китте-е... Койрыклы йолдыз тагын җитмеш алты елдан киләчә-әк. Һиҗрәтдин соң бер мең дә ундүрт сәнә узгач, Елан Елында яңадан пәйда булы-ыр... Ул вакытта мөслимнең бу як дәүләтләрен җир йоткан булы-ыр... Әүвәл Казан юк булыр, аннан Нугай-Хаҗитархан китә-әр...

Сөен тутай ни өчендер чыгу ишегенә ыргылган иде, дәрвиш юк булды.

Бу төнне ул иптәшкә Нәргәтай, Татлыбикне чакырып китергәч кенә йокларга ятты. Беренчесендә дә сәер карт дөресен әйткән, дип уйлады тутай, йолдыз киләсен ул алдан әйтте, сүзе рас килде. Шул төнне ике фаҗига булачагын: изге бер адәмнең дөнья куячагын һәм дә шул ук вакыт бер мордарның туачагын әйткән. Сөен тутай бу турыда олуг илче булып Мәскәүгә бөек кенәз Василийга баручы Хуҗа Хөсәен мирзадан ишетте ки, туккыз йөз дә утыз алтынчы сәнәдә Юлбарыс Елы тарихында җөмадә әл ахирәнең унынчы төнендә Заһретдин Мөхәммәт Бабур падишаһ вафат булган.

Сәер дәрвиш менә кем турында әйткән булып чыга. Икълимне чәчәкле бакчага күмгән шагыйрь-рәссам Бабур падишаһ дөнья куйган төнне ул куркыныч төш күреп уянган. Мәлгунь Каракош менә кемне чукып үтергән. Сәер мосафирның әйткәннәреннән икесенең раст килүе — Койрыклы йолдыз килүе белән Бабурның үлеме тутайны тетрәндерде. Бәс, өченчесе дә: мөселман халыклары өчен җәллад мәлгуньның тууы да дәрвиш әйткәнчә раст киләчәк. Кем туды ул төндә дөньяга? Кайсы патшалыкта үсә ул дөньяга кырылыш вә мәкер китерәчәк Дәҗҗал углы Дәҗҗал?

Бу хакыйкатьне үз җилкәсендә татыгач кына, нәкъ төшендәге коточыргыч Каракош кебек, колак-борыннары өзелеп, малы таланып, нәселе кырылып беткәч кенә, ул дәрвиш юраганнарның өчесе дә раст килгәнен аңлар...

Шундый авыр уйлар мохитеннән аерылыр көн дә килеп җитте. Койрыклы йолдыз күренгәннән соң өч-дүрт ел узгач, бәрәбаннар дөпелдәтеп, быргылар кычкыртып, шактый ук олыдан кубып, зур даудан җиңеп кайткандагыдай, Йосыф бәк йөз егете белән ажгырып Казаннан Сарайчыкка кайтып төште.

Олуг бәк Йосыф түрәнең сазап калган сөекле кызы Сөен тутай Казан ханы Җан Галигә кияүгә чыга икән, дигән хәбәр тиз таралды. Бу хәбәрнең ил өчен куанычлы яклары байтак иде. Дала кануннары кушканча, кукрәгә тулган һәр кыз — һич соңламый кияүгә чыгарга тиеш. Хәтта өлгереп җитмәгән кызның да булачак иренең йортына төшүе язык саналмый. Киленчәк булып өлгергәнче, яшь кыз иренең олы хатыннары тәрбиясендә үсә, киләчәктә ничек ир хатыны булып яшәргә кирәклеген өйрәнә, сабак ала. Өлгергәч кенә никах укыла. Шуннан соң гына ул ире куенына керә ала. Унсигез яшьлек Сөен тутай яшьтәшләренең өчәр-дүртәр баласы бар... Ханзадәләр, абруйлы мирзалар башта тутайга яучы җибәреп, арып бетте. Соңра Йосыф бәкнең киребеткән шашкын карт кызына яучыларның юлы өзелде. Сөен тутай Чыңгыз хан токымы булган шаһзадәләрдән килгән яучыларны да кире бора торгач, китапханәсендә утырып калды. Әнә шул утырып калган

унсигез яшьлек кызга тагын яучылар килгән. Кемнән диген әле син? Казан тикле мәшһүр Казан йортының япь-яшь ханы Җан Галидән — Чыңгыз токымыннан!.. Бәс. Сөен тутай-бәгим көткәненә иреште. Ул ханбикә булачак, Казан мәмләкәтенең беренче бикәсе булуны аңа Аллаһ Тәгалә үзе насыйп иткән!

## Җан Гали хан

Гәүһәршад бикә белән Булат бәк, Сафа Гәрәй ханны үтертә алмаганга яисә бәйләп Мәскәүгә сата алмаганга бик көенсәләр дә, асылда ханның качып китүенә куанып, бәйрәм ясап, тиз арада Мәскәүгә илчеләр юлладылар. Бөтен олы бәкләр, угланнар, сәет вә мирзалар, Казан йорты исеменнән язылган хатны илчеләр Колчура белән Фирүззат бәкләр алып китте: синең кандошманың Сафа Гәрәй ханны кудык, күп кырым ирләрен, нугайларны суйдык. Казан тәхетенә Шәех Әүлияр углы Җан Галине багышла, без сиңа мәңге тугры булырбыз...

Василий, бу хатны алгач, сөенә-сөенә, биш куллап ризалык бирде.һәм Яков Морозов белән Афанасий Куритскийга, Җан Галине саклап алып барып, Казан тәхетенә утыртырга боерды. Зур гаскәр белән Казанга килеп, алар Җан Галине Казан тәхетенә утырттылар.

Бу хәл тугыз йөз дә утыз тугызынчы ел тарихында (1532), җәй аеның егерме тугызынчы көнендә булды. Ул сәнә Аждаһа Елы иде.

Тәхеткә утыруының беренче эше итеп, Җан Гали хан Мәскәүнең олы кенәзе Василийга тугры булырга ант хаты язды. Василий да үз ягыннан ант кәгазе юллады.

— Идел йортын күз карасыдай саклаячакмын. Сине, Җан Гали ханны, үз углым кебек сөячәкмен! Амин!

Җан Гали хан идарәсе башлануга, Казанда әллә нинди сәер бер мохит барлыкка килде. Казанның олылары Булат бәк белән Гәүһәршад бикә, теләгәнне кылып, Сафаны хан иткән иде, шулар ук Сафаны тәхеттән куды; шулар ук Җан Галине сорап алды. Мәскәү белән Казан дуслыгы өчен ике яктан да ант эчтеләр. Әмма Казан һаман тыныч түгел. Һичнинди үзгәреш күренми, тормыш яхшырмый, дәүләт артып, мәмләкәтнең куәтләнүе сизелми. Җан Галине тәхеткә утыртырга килгән гаскәр казнаның яртысын талап китте. Казанда яшәеш төссез, күңелсез вә шом мохитендә иде.

Җан Галине сорап алган ачык авызлар хаталарын тиз аңлады. Күп тә узмастан, Василий Җан Гали ханга шундый шартнамә юллады:

— Өч ел элек булган орышларда вә дәхи аннан элеккеге орышларда ганимәт маллары буларак Казанда калган тупларны, утчагар мылтыкларны, мәетләрдән салдырылган сугыш киемнәрен, ярakларны, әсирлектәге бөтен христиан адәмнәрен Мәскәүгә кайтар!

Яхшы булырга ничек кенә ант итсә дә, Мәскәүнең Казанга булган дошманый мөнәсәбәте һичкайчан үзгәрмәячәген ачык авыз бәкләрнең зиһенлерәкләре, ниһаять, аңлады кебек. Казан тәхетендә Гали ханмы, Вәли ханмы — кем утыруы Мәскәү өчен барыбер; Гали белән Вәлинең ничек утыруы Мәскәү өчен әһәмиятле. Ике олы сугышта таланган Казанның фәкыйрь казнасын да Җан Гали күз йоммыйча Мәскәүгә озатты. Василийның соңгы шартнамәсен үтәү бу эшлексез хан өчен чүп тә тормый иде. Казанның олылары бер сүзгә килде һәм Василийга хат яздылар:

«И олы кенәз Иван углы Уасили хәзрәтләре! Без Аллаһ тәгалә коллары вә синең колларың, сиңа озын гомер, вә сагълык эстәймез. Бердәнбер варисың вә углың Ибанның сагъ үсүен, сиңа раст падишаһ булуын теләймез. Без синең белән вә углың Ибан белән гомер бакый дустанә яшәячәкмез. Әмма, Аллаһка ялваргандай ялварамыз, зинһар, Аллаһ тәгалә хакыйна ганимәт тупларыйн вә мылтыкларны алмаң. Безем тәхетемездин сөрелгән ханнар бар. Аларның вә дәхи бүтән дошманнарның йортымызны забет кыйлмакча эстәкләри кимемәс. Безем йортымыз иминлеге — синең йортыңның иминлеге. Казанның хәрби куәте кимемәсен. Ганимәтне, зинһар, сорама!»

Шушы хатны тотып, Агиш бәк рәһбәрлегендәге илчелек Мәскәүгә йөрде. Агиш бәк бу эшне бик оста башкарып, үз теленнән дә яхшылап аңлатып, ганимәт-үлҗә малын кайтармаска Василийны күндереп кайтты. Василийның бу «юмартлыгын» ни белән аңлатырга була соң? Казан белән Нугай арасында туганлык бәгъләры бар, Нугай белән Хаҗитархан арасы да дуслыкта булсын дипме, Василий Нугайның иң шөһрәтле бәге Шәйдакны Мәскәүгә чакырды. Шәйдак бәк белән бергә Нугайның җитмеш куәтле мирзасы да Мәскәүгә барды. Алар белән бергә дала малы алып, дүрт мең җиде йөз сәүдәгәр йөреп, Мәскәүдә сатар өчен илле мең иәселле елкы китерелде. Кырым ханы Сәгадәт Гәрәй дә, Хаҗитархан ханы Касыйм да Василийга олы бүләкләр, кызыл мал, елкы белән илчеләр юллады. Бөек кенәз Василийның шөһрәте артканнан-арта барып, күрше-тирә патшалыкларга гына түгел, Һиндстан падишаһы Бабур углы Хумаюнга да барып иреште. Хумаюн падишаһ бөек Мәскәүнең бөек кенәзе Василий белән дуст яшәргә, илче-килче, базаркән-уртак алмашып яшәргә теләк белдереп, бик мул бүләкләр белән үзенең илчесе Хуҗа Хөсәенне ерак сәфәргә озатты. Мәскәү көчәя, Мәскәүнең даны арта. Ул күп кенә күрше мәмләкәтләргә үз ихтыярын ирексезләп тага алырдай куәтле дәүләткә әйләнеп бара иде.

Казан олылары да Җан Гали ханны гелән искәртә торып, әйттеләр:

— Мәскәү илә дуслыгың бар, шөкер, әмма күрше-күләннәр илә дә дуслыкны ныгытырга кирәк,— диделәр.

Җан Гали хан ничек итеп күрше илләр белән дуслыкны ныгытырга белми, белергә дә теләми иде, шуңа күрә ул олылар сүзен тыңламый, тыңласа да тотмый, чөнки аның аркаланыр кешесе бар: Василий аңа ни боерса, ул шуны башкарачак, Мәскәүдән боерык көтеп яшәү аның өчен рәхәтрәк. Мәскәү барысын белә, бөтенесен күрә, нигә уйлап мәшәкатьләнергә? Шул сәбәпле Җан Гали хан хафаланмый. Якын тирәдә Мәскәүгә каршы торырдай куәтле ил юк.

Уналты яшенә җиткән булса да, Җан Гали сабый иде әле, сабыйлыгы да мәгънәсез сабыйлык булып, дәүләт эшләрендә комачау итә, соң өлгерә торган зиһенле бу бәндәчек ил белән идарә итү түгел, үзен дә җыеп йөртә белмәс бер мәхлук иде; Мәскәү ихтыяры аны тәмам бичара ясаган, шуңа күрә бу курчак хан тәхеттә утырса да, бары тик ике нәрсә белән мәшгуль иде: ат менеп куян куу, аннан соң тәхеттә йокымсырап утыру. Иртүк торса да, соң гына ятса да, кирәге булса да, кирәге булмаса да — ул, тәхетханәгә кермичә калмый, кергәч тәхеткә утырып, ханәдә кеше булмаса да, булмаган адәмнәргә өстән карап:

— Мин Шәех Әүлияр углы, Чыңгыз токымы Җан Гали хан, сүзем!— дип тәкърар артыннан тәкърарлап, әллә нинди фәрманнар чыгарып, кемнәрнедер үлем җәзасына тартып, хыялый рәвештә ил-ватан белән идарә иткән була. Чынлыкта исә бу идарә түгел, ә бәлки өлгермәгән үсмернең уены иде.

Шулай да, олы бәкләр җыйналып, Җан Галигә эшләрне төшендереп карарга булдылар. Сүзне Булат бәк Ширин башлады:

— Мәскәү белән дустанә яшәү бик мөһим сәясәт, хан, әмма күршеләремез Нугайлар илә араны ныгыту—иң олы фәгалиятләрнең берсе...

Җан Гали хан Булат бәк сүзенең өстенә менде:

— Ныгытыйк соң!— диде ул.— Ныгытыгыз! Нугай белән дә, Хаҗитархан белән дә ныгытыгыз. Сез бит карачылар. Син үзең бәйләрбәй — Булат Ширин... Кем каршы соң бу дустлыкка? Әмма ул дустлану Мәскәү мәнфәгатьләренә аркылы ятмасын: шул.

Булат бәк, ачуы эчтән кайнаса да, сабырлык илә сүзен дәвам итте:

— Хан!— диде ул.— Дустлашу сүзендә башка бер мәгънә дә бар әле.

— Нинди мәгънә?

— Дустлашу — туганлашу аша, кодалашу аша булса, ныграк булыр иде,— дип уйлаштык без олылар илә.

— Ягъни?

— Ягъни, хан-солтан, сиңа бер куәтле нәселнең кызына өйләнмәк лаземдер.

Ике сүзгә урын калдырмас өчен, бөтен бәкләр дә берьюлы:

— Дөрест-дөрест,—дип кабатлады.—Сиңа өйләнү бик тә вакытлы вә савaплы эштер, хан!

Җан Гали хан бу сүзләрдән соң тәхетендә кымырҗып куйды. Ул куанычын яшерә алмый һәм ни әйтергә белми кыбырсый иде:

— Ягъни?

Булат бәк туры ярып әйтте:

— Хәзер килен сайлау лаземдер!—диде.—Нугай бәкләре арасында иң куәтлесе, иң күп маллысы—берьюлы ике йөз мең атлы гаскәр яуга җыйный ала торган Йосыф булыр. Йосыф әмирнең угыллары да бай — гайрәтле, бөтен даланы дер селкетеп, бөтен кәрван юлларын үз кулында тота. Йосыф бәкнең угыллары Юныс белән Гали мирзалар үзләре дә падишаһ хисабында. Менә шул Йосыф әмирнең бик гүзәл вә мәшһүр кызы бар. Сөен тутайның гүзәллеге, зирәклеге, укымышлылыгы турында риваятьләр бөтен дөньяга таралган.

Булат бәк туктады. Җан Гали Сөен тутай хакында ишеткәләгән иде, шул мәшһүрә тутайны аның үзенә димлиләр түгелме соң? Ханның авызы үзенә буйсынмыйча ерылып китте. Ул хыялында гүзәлләр гүзәле Сөен тутайның сурәтен күрә башлады бугай, хан түземсезлек белән Булат бәккә дәште:

— Җә, җә, нигә туктап калдың, бәйләрбәй, сөйләң!—диде.

Булат бәк шуны гына көтә иде, ул сүзгә саранланмады. Мәдхия тәмамланганчы ук, хан:

— Мин риза!—диде.

Ризасын ризадыр да, әмма риза дигән белән генә бикәчең куенында булмый шул. Бичара Җан Гали хан ни теләсә, шуны эшли ала, хан ни боерса, баш өсте, ләббәйкә, дип буйсынарлары фәрманны үтәргә атлыгып тора, дип бик хәтәр ялгыша. Ханнарның андый заманнары да бар иде: Чыңгыз, Батый, Үзбәкләр идарәсендә. Олы Мөхәммәт, Мәхмүт, Ибраһим ханнар янына килеп, чит ил патшалары буй сындырып, җир биләү өчен ярлык сорап, тәхеткә агамны түгел, мине күндерсәнә, дип ялварган Мәскәү кенәзләрен дә тарих яхшы хәтерли. Әмма Касыйм-Ханкирмән ханнары гомер-гомергә Мәскәү кулындагы җепле курчак булды. Хан дип аталып та, алар Мәскәүнең иң кече баярының да гозерен үтәргә алгысап яшәүче йомышчы малай була килде. Җан Гали хан Касыйм каласында да уенчык ханчык иде, Казанда да ул уенчык кына икәнен өнenә ала алмый иде. Казан тикле Казанның җәүһәр, энҗе асылташлары белән бизәлгән тәхетендә алтын таҗ киеп утырса да, ул һаман җепле курчак булудан ары китә алмый. Ул өйләнүне дә үзе хәл итә алмас дәрәҗәдә иде. Йомшак агачны корт баса, чирле адәмне мәрт баса, дигәндәй, Җан Гали хан Мәскәү курчагы гына түгел, Казан бәкләренең дә уенчык ханчыгы була калды. Җан Гали ханны өйләндерү мәсьәләсен Гәүһәршад бикә уйлады, бу уйны ул Булат бәккә әйтте. Җан Галине Сөен тутайга өйләндерүне дә Гәүһәршад уйлап тапты. Бу эш Сафа Гәрәй ханга аркылы төшү иде. Сафа Гәрәй хан Шәехмамай кияве, кайчан да булса, агасы Сәгадәт Гәрәй ханнан һәм кайнатасы ягыннан күп санлы атлы гаскәр алып, Казанга яу чабачак, бу яуга Йосыф әмир дә катнашачак. Әгәр дә Җан Гали хан Йосыф кызы Сөен тутайга өйләнсә, Йосыф әмир Сафага гаскәр бирмәс, хәтта Шәехмамайныкылар да бу яуга катнашмас. Шуңа күрә Булат бәк, бөтен бәкләрнең гаҗәбенә каршы, Җан Гали ханга Сөен тутайны димләде. Шулай итеп, ханны кемгә өйләндерү мәсьәләсе дә хәл ителде. Ләкин әле бу эш бары тик теләк кенә. Иң беренче бу никахка Сөен тутайның атасы олуг әмир Йосыфның ризалыгын алыш кирәк. Аннан соң Сөен тутай ул—чыгымчы тай кебек, кире холыклы: чыкмыйм мин ул бозау Җан Галиегезгә дисә, ни кылырсың? Хуш, Сөен тутай биш куллап риза да булсын, ди. Ә Мәскәү, Мәскәү ни әйтер? Бу никах мөнәсәбәте илә бөек кенәз Василий, баярлар, митрополит Даниил нинди фикер әйтер? Мәскәү бу эшне, һичшиксез, олы җыенында уртага салачак. Хуш, баярлар рөхсәт бирде ди: Сөен тутай Казанга китсә, Казан белән Нугай йорты бер булып көчәергә мөмкинлек табачак. Җан Гали ханны Сөен тутайга өйләндереп, Нугай далаларындагы бихисап елкыларга, бихисап куйларга, бихисап дөяләргә хуҗа була алырмы Казан? Гәүһәршад бикә гозере илә Бу-

лат бәк, диван бәкләрен җыйнап, бер карарга килделәр һәм икенче көнне үк ике якка ике илчелек Казаннан чыкты. Берсе Мәскәү юлына төште, икенчесе Нугайга Сарайчык каласына таба йөреп китте. Мәскәүгә киткән илчелек башында Булат бәк Ширин үзе, Апай углан, Кадыш бәк, Яутәк бахшы иде. Йосыф әмиргә юнәлгән илчелек башында мәшһүр яучы Агиш бәк тора иде.

Шундый абруйлы бәкләр илче булып вак эш белән йөрмәс, дип, Василий Казан илчеләрен үзе генә түгел, олы баярлары һәм митрополит белән бергә кабул итте. Булат бәк гозернамәне тапшыргач, сүз белән дә эшнең асылын сөйләгәч, баярлар белән митрополит үзара карашып алды; бөек кенәз дә, бер сүз әйтмәстән, бер кавым тын утырды. Баярлар да, митрополит та, бөек кенәз дә бер уй уйлый иде: Булат бәк белән Гәүһәршад бикә һәрвакыт Мәскәүгә таянды; әмма алар, ничарадан бичара булганга гына, Мәскәүгә аркалана килде. Җае чыгып, алар кулындагы Казан куәтләнә калса, ике утырып, бер уйламыйча, алар Василийның дошманына әвереләчәк. Андый мөмкинлек бар: Нугай белән Казанны чынлап берләштерү. Нугайның йөзләгән мирзалары берләшсә, Казан ягыннан йөз мең атлы кушылып, алты йөз мең ат берьюлы, Мәскәүгә йөрсә, Кырымлылар йөз, йөз илле мең кылычны кыныдан чыгарса, Мәскәүнең тетмәсен тетәчәк.

Василий, Казан илчеләрен кунак мәҗлесенә чакырып, мәсьәләне бар яклап уйларга кирәклеген әйтеп, баярларын таратты. Казан илчеләре, кунактан-кунакка йөреп, куян-төлкегә, хәтта аюга ау оештырып, атна-ун көн үтеп китте. Алар онытылып сыйланганда Василий якыннары белән озак киңәште. Анысы шулай, Нугай Казан белән чынлап туганлашса, эшләр хәтәрәячәк. Сөен тутайның атасы әмир Йосыфка тәэсире барлыгын бөтен дөнья белә. Татарлар йодрык булып берләшсә, Литва белән Польша да тик ятмас.

— Ләкин,— диде митрополит.— Тарих дәлиллегендә уйласак, эш болайрак тора. Сафа Гәрәй хан да Нугайдан атаклы Шәехмамай бәктән кыз алды. Әмма Казан кайнаганда Сафаның кайнатасы нибары утыз мең атлы бирде. Хисаплый китсәң, ул йөз меңлек гаскәр юллый ала иде. Исмәгыйль мирза агасының кияве Сафага сыңар ат та, сыңар кылыч та бирмәде, шул ук Йосыф бәк агасының кияве шул ук Сафага бер генә яугир дә җибәрмәде. Хаҗитархан, Мәскәү белән араны бозмас өчен, Казанны яклау җәһәтеннән кыл да кыймылдатмады. Сафа Гәрәйне Казанда ныгытыр өчен Сәгадәт Гәрәй хан ни эшләде? Чынлыкта исә Сафа Гәрәй хан бер уч Кырымлы егетләре белән Булат бәккә каршы тора алмады, качып котылды. Әлбәттә, кайнатасы йөз мең кылыч җибәргән булса, Сафа Гәрәй хан Мәскәү гаскәрен дә, Булат бәк фиркасен дә туздырган булыр иде. Бәс, хөрмәтле баярлар, Җан Гали ханның Йосыф әмир кызы Сөен тутайга өйләнүе, фикри яктан Мәскәвиягә кулай булмаса да, тәҗрибәи яктан мөмкин, хәтта бик мөһим эш дип саныйм.

Баярлар берьюлы сөйләшә башлады. Митрополитның соңгы җөмләсе өстенрәк уйларга күнеккәннәр өчен имәнгеч булып тоелды. Василий бер якка да катышмады: баярлар аерым сүз алмыйча гына бәхәсләшеп аргач, ул әйтте:

— Алгы сүзләрендә хакыйкать ята, әмма «мөһим» дигәнеңдә ни мәгънә бар, Даниил атакай?

Митрополит Даниил бу сорауны күптән көтә иде. Ул бәхәсчеләр ни әйткәнне тыныч тыңлады. Кайсы баярның нәрсә әйтәсен ул алдан белеп тора, ахмак сүз әйткәннәргә ул игътибар салмый, аның җавабы күптән әзер һәм ул җавап бөек кенәзгә дә, тәпләрәк баярларга да ошаячак.

Митрополит куәтле, сабыр тавыш белән әйтте:

— Сизәмсез,— диде,— Җан Гали хан Казанның ватанпәрвәрләренә генә түгел, хәтта Мәскәүгә йөз тотканнар күңеленә дә ятыша алмый. Абзасы Шаһ Гали хан кебек. Җан Гали ханның да сөйкемсез сояге бар. Аларның икесен дә сөймиләр. Мәскәү ягы да, Казан ягы да. Касыймныкылар да аларны сөйми. Хәтта аталары Шәех Әүлияр белән аналары Шаһсолтан бикә дә бу мәхлукларга битараф булды. Ничек әйтергә... бу ике бәндәне ана карынында ук Аллалары каргаган. Алар белән ни татар, ни рус чын дус була ал-

мый, киракка гена дус булып йөри. Кирәк өчен генә дус кору — ул мәкерле дуслык.
Бу сүзләрне митрополиттан башка бер генә бояр да әйтә алмас иде, чөнки бу сүзләр туп-туры Василийның үзенә кагыла. Шаһ Гали белән Җан Гали — аның дусты. Шаһ Галине бер — хан ясап, бер зинданга ябып тотуы, Җан Галине «үз улым кебек күрермен» дип шартнамә язып бирүе дә, ханны сөйгәннән түгел, үзенә хезмәт иттерергә теләүдән икәнен һәркем белә. Василий дәшмәде.
— Бәс, — диде митрополит, — Җан Гали ханның Казанда чын дусты юк. Аның тәхете какшау, таҗы кыек, буыны сыек. Җае чыгу белән, шул ук Булат бәк аны куачак яки үтерәчәк. Әгәр дә бу никахка фатыйха бирмәсәң, Василий Иваныч, бу эшне тизләтәчәксең генә. Һәм Казан тәхетенә, белмим, кем менеп утырачак, Сәхип Гәрәйме, Сафа Гәрәйме? Үзегезгә мәгълүм ки, икесенең берсе утырса да — Мәскәү тыныч йоклап, тыныч ашый алмаячак! Сүзем тәмам!
Бәярлар тын утыра калды. Акыллылар уйлый. Уйсызлары бөек кенәз сүзен көтә. Василийга бар да ачык иде, күптән ачык иде — митрополит хаклы. Өстән уйлаучылар каршы килгәндә дә Василий үз сүзен каты әйтәчәк: бу никахка фатыйха бирергә кирәк! Һәм бу туйга Мәскәүнең иң атаклы кенәзләре вә бояр егетләре олы бүләкләр белән барырга тиеш!
Булат бәк Ширин, никахка рөхсәт белән бергә, мул бүләкләр төяп, Казанга кайтты.
Дала уртасында Агиш бәк белән Йосыф әмир очрашты. Җаек җәйләвендәге бу очрашу бәйрәм төсендә узды, туйдан ким түгел иде бу ярәшү мәҗлесе. Әлбәттә, әмир Йосыф өчен бу бәхет мәҗлесе булды. Йосыф бәк Сарайчыкка атылып кайтты да Сөен тутай ханәкәсенә үзе керде. Сөен тутай бу хәбәрне йөзенә, кыяфәтенә үзгәреш чыгармыйча гына тыңлады. Сөен тутай Җан Галинең ир-егет буларак гайрәтсез икәнен дә, хонса йөзле икәнен дә ишетә белә иде. Әмма ул Казан ханбикәсе булачагына сөенә. Әмир Йосыф, Сөен бикәчнең ризалыгын Агиш бәккә белгертер өчен язу язып, Җаек җәйләвенә чапкын җибәрде.

## Сөембикә

Хакыйкатән, Җан Гали хан белән Сөембикәнең туен берничә ил берьюлы, күп чыгым ясап, бергә уздырды: Мәскәү, Касыйм ханлыгы, Нугай урдасы, Шәһәри Казанның барча олылары туйга байтак бүләк, мал, акча салды.
Туй берьюлы өч зур мәйданда оештырылды: Кунак Атавында, Ханболында, Арча Кырында. Затлы тирмәләрне түгәрәк буйлап, урам-урам ясап, зур күчәләр калдырып кордылар. Түгәрәк мәркәзендә ап-ак киездән эшләнгән атау-йорт тора. Ак атау-йорт — кияү белән кәләшкә. Өч мәйданда берьюлы яшьләр уен башлап җибәрде.
Җан Гали хан белән Сөембикә туе вакытында күрше илләр, яу эшләрен туктатып, барымта чабу, кан үче-карымта кайтаруларны чигереп торды. Чакырулы ил агалары — бүләк төяп, чакырылмаганнары — бәйгеләрдә катнашу өчен — Казанга юнәлде.
Һәр өч мәйданда да көрәш, атлы уеннар, ук ату, аркан тарту кебек ярышлар башланды. Батыр калганнар, алга чыкканнар, соңгы ярышка Ханболын мәйданына җыйналып, хәлиткеч көрәш-узышлар шунда булачак иде. Аңынчы Җан Гали хан белән Сөембикә, иң башта Кунак Атавындагы җыенга барып, халык белән бергә өч көн бәйрәм итте; аннан соң, аларны ап-ак атлар җигелгән туй арбасына утыртып, Арча Кырындагы атау-йортка төшерделәр, монда да алар өч тәүлек уеннарда катнашып, куәтле көрәшчеләр һәм мәргәннәр бәйгесен тамаша кылып, истирахәт кичерде. Туй уеннарының иң кайнары Ханболында башланды. Кораеш, Утыч мәчетләреннән алып Иделгә чаклы арадагы киң җәйләү — Ханболынның матурлыгын күреп, Казанга бе-

ренче тапкыр килгән кунаклар тел шартлатып, аһ-ваһ итеп, хәйран-вәйран булып сокландылар, мактадылар.

Җан Гали хан белән Сөембикә Ханболынга уеннар башланыр-башланмаста гына төште. Алар икесе ап-ак атта иде. Акбүз атлар сыртында тирлек җәймә урынына затлы-зәңгәр келәм җәелгән, келәм өстенә ияр салынган, иярдә ап-ак кием кигән хан белән ханбикә. Мәйданга алар килеп кергәч, барча мотрибчы бергә уйный башлады. Хан белән ханбикә мәйдан түгәрәге буйлый атларын биетеп-атлатып кына йөреп китте. Халык аларны алкышлый, алар да халыкка сәлам юллый.

Сөембикәнең кыяфәтенә карап сокланмаган кеше калмады. Аның иярдә йөргәндәге мәгърурлыгы, аты тайпылганда да иярендә төз калуы; горурлыктан вәкарьлеккә күчмәенчә халыкны сәламләве, тезгенне кирәк чакта чәнчә бармагы белән генә тартып, атын теләгән якка йөртүе дә гаҗәеп бер осталык, матур тамаша, мәһабәтият күргәзмәсе иде. Бөкшәебрәк утыручы Җан Гали ханга игътибар итмәделәр дә кебек, бөтен күз Сөембикәгә текәлгән. Халык яңа ханбикәгә үлеп гашыйк иде.

Хан сандалие янында кунаклар өчен көрсиләр куелган, ул көрсиләрдә кәттә кодалар, әмир Йосыф утыра. Икенче якта — Җан Гали ханның якыннары, олы бәкләр. Булат бәк белән Гәүһәршад бикә ханның уң кул ягында иде. Сөембикәнең атта йөрүен, атны туктатып, иярдән җиңел, оста, матур итеп төшүен карап, Гәүһәршад бикә һич риясыз елмайды. Булат бәкнең күзләре соклану катыш бер үзгә очкыннар белән яна иде. Ул да елмайган, авызы ерылган. Гәүһәршад бикә чын күңелдән канәгать. Беренче күргәч тә үк, ул Сөембикәне бик ошаткан иде, бүген ошату сөюгә әверелде кебек. Бу гүзәллекне, бу камиллекне сөймәү мөмкин түгелдер. Гүзәллек, мәгърурлык сирәк галәмәт түгел, бар ул гүзәл хатыннар, әмма Сөембикәнең гүзәллеге үзгә, аның гүзәллегендә эчтәлек-мәгънә бар кебек. Чибәр генә түгел, зиһенле дә, әнә шул зиһен гүзәллек өстенә бәреп чыгамы, әллә Сөембикә үзе кешеләргә ошау серен беләме — ханбикәгә бөтен нәрсә килешә, ашавы да, кымыздан авыз итүе дә, соалыгә җавап бирүе дә ягымлы, төпле, аңгәмәдәшчене үзенә тарта. Голәмә Сөембикәнең бәхетле икәнен күрде. Ул сизелер-сизелмәс елмая. Хәрәкәтләре салмак, алак-ялак каранмый, әйләнә-тирәне ул күбесенчә күңел күзе, күз кырые белән барлый, күзәтә иде. Аттан төшкәндә, бәтчәләр килеп, берсе атның тезгенен тотты, икенчесе Сөембикәгә кулын сузды. Сөембикә, бер үсмер кулына таянып, җиңел генә җәяүләнде. Кияү белән кәләш, аттан төшеп, өсте каплаулы сандалиларга утырды. Тамашачылар, кунаклар хан белән ханбикәне аягөсте алкышлады. Алар сандалига утырганда, Гәүһәршад бикә белән ханбикәнең карашы очрашты. Ике караш та мизгел эчендә аерылды, әмма Гәүһәршад бикә Сөембикәнең күз карашын, күз алмасын, керфекләрен, караштагы әз генә тарсыну, бәхет чаткылары белән янәшә кырыслык та барын шәйләде. Сөембикә бер мәлдә күреп калган Гәүһәршад бикәнең карашындагы усаллык, мәкерне күңеленә йотты.

Ханболындагы бәйрәмнең беренче көне көрәш карап узды. Батыр калган өч егеткә олы бүләкләр бирделәр. Бөтен халыкны, кунак-илчеләрне биһуш ясап, Сөембикә өч башбатырга өч бүләк тапшырды — килен бүләге. Батырлар һәр бүләкне мәйдан әйләнә халыкка күрсәтеп йөрде, халык Сөембикәгә икенче кат гашыйк булды.

Икенче көнне бәйрәм кыз куыш уены белән башланды. Уенның иң кызган чагында гына Сөембикә Җан Гали ханга нидер әйтте, тегесе янәшәдә торучы аталыкка ишарә ясады, аталык кемгәдер ым какты, ике бәтчә ике ак атны җитәкләп, хан белән ханбикә янына алып килде. Сөембикә, җәһәт кенә ияргә менеп, аякларын өзәңгегә терәде дә атына чөңгерде. Алгысаган ат — туры айгыр — дагалары белән чирәм учмаларын тамашачылар битенә сибеп, алга ыргылды. Мәйдан үкереп, сызгырып куйды:

— Һай, ханбикә-ә! Һай-ди, Сөембикә-ә! — дип кычкыра. — Һай, Җан Гали ха-ан, куып җит Сөембикәне-е!

Хан атланганчы, Сөембикә болын түренә, Идел ягасына җиткән иде инде. Җан Гали ияргә утырыр-утырмаста, ат алга ыргылды, хан чак кына егыл-

мады. Ярсыган ат алга ымсынса да, хан тезгенне бушатмый... Сөембикә, болын түреннән яр буйлый чабып, агачлар арасына кереп югалды. Бераздан Җан Гали хан да шул тарафка кереп китте. Куыш уйнаучылар мәйданга кайтып бетте. Кемдер кызын куып торкан. Куып тота алмаган егетне кызы, камчылап, мәйданга алып кайга. Халык шашардай булып үкерә, алкышлый, эче катып көлә.

Сөембикә дә, аны куа киткән хан да озак күренмәде... Сөембикә, урман юлы белән бераз юырткач, аңлады: Җан Гали хан аны куып җитә алмаячак. Бикә тезгенен тарта төште; ат, авызлыгын чәйнәп, акрынайды. Шулчак куаклар артыннан Җан Гали чабып чыкты; аны күргәч, Сөембикә атын икенче юлга чыгарып, кайтырга таба борылды. Ире белән ара ерагайгач, янә тезгенне тартты. Җан Гали якынайгач, янә тезгенне бушатты. Аның артыннан ук Җан Гали дә урман авызына килеп чыкты. Сөембикә атын тагын тыйды. Җан Гали аны болын уртасында куып житте дә, кочаклап, башындагы яулыгын тартып алды. Һай, халыкка рәхәт булды инде, кызык булды. Атналар, айлар буе сөйләрлек бер ярыш-вакыйга булды бу. Бар да канәгать иде. Бу ярыштан бары тик бераү генә ризасыз калды: Сөембикә үзе. Иренең шулай җебеки булуына ачыныпмы, күрәләтә үзен алдап, халыкны алдап, җиңәсе урында җиңелергә мәҗбүр булганынамы, ул йокы алдыннан, аулак урын табып, бер елады. Казан йортына килен булып төшкәч, Сөембикәнең беренче елавы, беренче күз яшьләре иде бу. Әмма соңгысы түгел иде. Иң әчесе, иң канлы күз яшьләре әле алда, кара көннәрдә булачак.

Туй уеннары азагында соңгы чабышлар булырга тиеш иде. Кичтән озак елаганын яшерер өчен, Сөембикә иртән иртүк торып юынды, бизәнде дә Җан Галигә сүз катты:

— Хан — диде, — Син, бәйгедә катнашып, беренче килергә тиешсең!

Җан Гали хан аңламады, зиһененә барып җиткәч, гаҗәпсенеп:

— Ни өчен? Нигә? — диде.

— Син хан гына түгел, син — ир-ат! Хәтәр яугир икәнеңне бөтен илгә күрсәтергә тиеш!

Хан әйтте:

— Өч бәйгедә җиңгән өчәр ат — тугыз, тугызы да баш биргесез айгырлар. Аларны узардай елкы тумаган!

Сөембикә әйтте:

— Туган! — диде. — Туган! Бар андый йөрге ат!

— Кайда? — диде хан.

— Бүген карышкыңны күтәреп, гавамга әйткел: туебызны озайтыр өчен, соңгы бәйгене ун көнгә чигерәм, диң. Ун көннән соң үзем дә бәйгедә катнашачагым, диң. Мин беренчегә менә нәрсә әзерләдем...

Сөембикә сандыгыннан чигелгән ябынча чыгарды, ябынча гына түгел, могҗиза иде ул. Юка туланы һиндстан ефәге белән тышлаган, каюлары алтын ука белән чигелгән, бәйләмәсе саф алтын зынҗыр, төймәләренә энҗе-мәрҗән береккән, яка бавының ике башында ике алмаз тагылган ике бөҗра, эче ап-ак, тышы күк-зәңгәр бу ябынчыга бәһа куярлык түгел иде. Ни гамьсез Җан Гали хан да, ябынчаны күргәч, авызын ачып, артына утырды. Үпкәсенә кайнар һава кергәндәй, тыны капланып торды.

Сөембикә янә кабатлады:

— Бу ябынчаны бәйгедә узып, син алырга тиеш! — диде.

— Ничек? — диде хан.

— Мине тыңласаң — булыр,— диде бикә. — Бәйгене ун көнгә күчер. Узышачак атны бөтен халык алдында елкы көтүеннән үзең сайлап алырсың.

— Мин ат танымыйм, — диде хан.

— Ат сайлаганда миңа бак, ярамас булса, мин сул кулым белән маңгаемны сыпырырмын, ярашлык ат булса — уңы булыр...

Ханның туй уеннарын озайтып, соңгы бәйгене ун көнгә күчерүе, узышта үзенең катнашачагын игълан итүе сарай агаларын гаҗәпкә салды. Бәйрәм озайганга чаптар хуҗалары куанды. Ханның үзе сайлаган йөргедә беренче килергә теләгәнен ишеткәч, Булат бәк ирен кырыйлары белән генә елмайды. Беренче килгәнгә бирeләчәк могҗиза ябынчасын күргәч, олылар

да, халык та телсез калды. Булат бәк хатынына бакты. Гәүһәршад бикәнең күзе канәгать елмая. Бу зиннәтле ябынча аларга булачак. Аларның албирмәс чабышкые Зәррәтай җиңәчәк. Димәк, бәйге хәтәр булачак. Гәүһәршад бикә Сөембикәгә янә сокланып бакты: бу дала кызы, гүзәллек өстенә, зиһен иясе дә икән, кара... Бәйгене ун көнгә күчерү Җан Гали мокытның башына килә торган фикер түгел. Бәйгене күчерү — болай да ярсыган кунаклар, тамашачыларны тагын да кыздыру, алгысату; бәс, ярыш хәтәрдән дә хәтәр булачак. Сөембикәнең даны дөньяга таралачак.

Якын далага чыгып, хан елкы көтүеннән тайны үзе сайларга тиеш иде. Ханның елкы сайлаганын карар өчен бик күп зыялылар далага чыкты. Бөтен мәйдан халкы диярлек җәйләүдә иде. Ат сайлау өчен араталар белән тыкрык ясап, елкыларны берәм-берәм шул аралыктан уздырганда Җан Гали хан — аратаның бу ягында, Сөембикә аңа каршы якта тора иде. Тыкрык буйлатып беренче елкылар чабып узды.

Тамашачылар, елкы осталары дәррәү кычкыра:

— Кукчуарны ал! Җирәнкашка узачак!

Тегесен сайла, монысын ал, дип өйрәтүчеләрнең иге-чиге юк иде. Чыннан да, сайларлык мал күп: күзең оясыннан чыгар, билләһи! Нәзек муенлы, кечкенә башлы, күкрәк кагып, биеп узучы яхшы тайларга карап сокланмый мөмкин түгел иде. Халык тел шартлата, гүли, әфарин, машалла кычкыра. Халык гүли башлауга, Җан Гали хатынына карый. Ләкин Сөембикә сул кулын маңгаеннан алмый да. Елкы өере узып бетте дигәндә генә, ниһаять, Сөембикә сул кулын төшерде, уң кулындагы кулъяулык белән маңгаена кагылды, ике арадан зур корсаклы, ябагатай узып бара иде.

Җан Гали хан:

— Менә шушы! — дип кычкырды.

Янәшәдә генә торучы елкычылар, хан күрсәткән тайның арт торыгына уткызган тимер басып, тамга салды. Араталарга ябырылып, яңа гына тамгаланган ябагага карап, халык аптырады. Хан шаяртамы соң?

— Шул тайга атланып, мин соңгы бәйгегә барачагым! — диде хан, Сөембикәнең хуплаулы карашыннан аерыла алмаенча.

Шаркылдап көлүен тыяр өчен, күп кеше, учы белән авызын томалап, читкә борылды. Олы бәкләр сабыр гына елмайды. Ханга, бәкләргә ераграк торганнар пырых-пырх көләргә тотынды.

Хан сүзе-сүз, атка тамга орылган. Зур корсаклы ябагатайны аерып, башына нукта кигезеп, далага җибәрделәр. Бу көн шушы эш белән тәмамланды. Димәк, өч бәйгедә беренче өч урынны алган тугыз ат, унынчысы халык телендә Капкорсак дип аталган ябагатай ун көннән соң ярышачак. Халык таралгач, ханбикә белән хан үз тирмәсенә иңде. Сөембикә канәгать иде. Хан, үпкәләгән бала кебек, турсайган.

— Бүген үк, — диде Сөембикә. — Хәзер үк, көймәгә төялеп, Капкорсакны алып, Ослан ягына, Идел аръягына китәчәкбез...

Сөембикә барысын да алдан ук әзерләткән булып чыкты. Сарай халкына алар: «Истирахәт өчен Осланга чыгамыз, бәйгегә кайтырмыз», — дип, ун көнлек сәяхәткә китте.

Аръякка чыккач, карачуралар дүрт олы тирмә ясатты. Хан өчен — бер тирмә, ханбикәгә — аерым тирмә, ахирәтләр өчен — тагын бер тирмә, җансакчылар өчен һәм бавырчылар, елкычылар өчен махсус тирмәләр корып, хәйран гына зур бер авыл хасил иттеләр. Сөембикәне танырлык түгел иде. Ул, ханбикә киемнәрен салып, җайдакча амузын кызлар киеме киде. Җан Галине дә җайдакча киендерделәр. Сөембикә биш-алты куй суярга кушты; яңа туналган тиреләрдән, чи ягын эчтә калдырып, Капкорсакка тун тектерде. Шул тунны ябага атка кигезеп-бәйләп куйгач, Сөембикә ат сыртына сикереп менде дә, Капкорсакны камчылап, үкчәләре белән ат корсагына тибә-тибә, Ослан тавына, үргә каршы чаптырып минеп китте. Берничә тапкыр ул атны бер аска, бер үргә куып, мышнатып, күбеккә батырып ташлады. Бераз хәл алгач, атка Нәргәтай, аннан Сауфия, аннан соң Җан Гали хан менеп куакладды. Атның танау тишекләре кып-кызыл итенә чаклы ачылып киерелде, авызыннан сыек күбек ага, күзләрен кан баскан, ул тормышының кинәт

үзгәрүен аңлап бетерми, аптырый сыман, ни гаебем бар дигәндәй, керфек шапылдата. Кич җиткәч, сарык тунын салдырып, Капкорсакны далага җибәрделәр... Шулай көн саен Капкорсакны үргә кудылар. Ат көннән-көн азрак тирли, үргә җиңелрәк менә, танау тишекләре тарая бара, күзендә дә шашкынлык кими, корсагы күзгә күренеп бетә иде. Тугызынчы көнне Капкорсак танымаслык булып җиңеләйде, нечкә торыклы, эчсез, тыгыз, җитез бер чабышкыга охшап калды. Тигез юлдан чапканда Капкорсак җайдакны сизми дә кебек. Бавырчылар да, елкычылар да ачык сизде: Капкорсакны сайлап, хан ялгышмаган икән. Җан Гали хан елкы малын осталардан да яхшырак таный белә икән дигән хәбәр таралып, ханның абруе кинәт үсеп китте. Булат бәк белән Гәүһәршад бикәнең генә ханга булган карашы үзгәрмәде. Елкыны хан түгел, ханбикә сайлаганлыгын алар сизде.

Соңгы бәйге башланыр вакытта дөнья шаулый иде инде. Капкорсакка бармак төртеп берәү дә ыржаеп көлми: халык могҗиза көтә. Алгы ярышларда беренчегә чыккан бәйгирләр дә пошаманда, аларга көндәш арткан. Хан чатыры янындагы колгага могҗиза ябынчасы эленгән. Беренче килгән ат хуҗасына нәселле сигез айгыр, бер дөя биреләчәк, болары язылмаган кагыйдә буенча шулай тиеш. Шуның өстенә — Сөембикә чиккән ябынча. Ун көн буена хәтәр ярыш көтеп, кешеләр дә, атлар да ярсып бетте. Хәзер бушаныш, нәтиҗә кирәк. Бушаныш булмаса, киренке сеңерләр өзелер, түземсез йөрәкләр шартлап ярылыр сыман. Узышачак атларның түземсезлеге халыкка күчкәнме, халыкның бәйге-нәтиҗә көтеп ярсыган йөрәкләреннән атларга дулкын күчәме — гасабилану, җанату гомум гүләүгә әверелә, бөтен мәйдан, барча җан иясе тынгысыз-алгысу халәтендә иде.

Шулчак мәйданга Капкорсакка атланган Җан Гали хан чыкты. Атның дүрт бәкәленә дә корыч силә куйганнармыни, ат адымы сикәлтәле, әйтерсең лә, ниндидер бер билгесез көч аның аякларын өскә этеп-этеп җибәрә. Уң торыгы өстендәге тамга булмаса, атны алыштырганнар, Капкорсак — ябага урынына дөнья бәһасе торган башка чабышкы куйганнар дип әйтергә булыр иде; әмма елкычылар-шаһитләр бик яхшы белә — бу хан үзе сайлаган ябагатай. Ун көн эчендә ничек шулай үзгәргән, шунысы гаҗәп, моның серен ханның, ханбикәнең якыннары гына белә иде.

Ат бәйгесендә хәрәмләш булмасын өчен, һәр борылмага, һәр юл кырына бактаннар куелды. Чаптарларны узган чаптарлар узышын, бәйге батырларының бу соңгы бәйгесен караганда адәми зат бүтән һични турында уйлый алмый. Үз аты, якын кардәше өчен җан атучылар гына түгел, ат хуҗаларына битараф тамашачылар да атларның йөрешен, ыргымлап чабышын караганда үзе сайлаган ат өчен өзгәләнә, кычкыра, сызгыра, йодрыклары белән тез башларын кыйный, шаша.

Ире Җан Галигә кырыкмаса кырык әйткәне булса да, Сөембикә бәйге башланыр алдыннан тагын кабатлады:

— Ярты юлгача тезгенеңне тартыбрак тот, — диде. — Кайтыр юлга борылгач, җибәр. Тезгенеңне ияргә бәйлә дә, ябыш. Егылма гына, калганын малкай үзе белер.

Атларны тигезләп, уенбашы хәбәр салды: соңгы бәйге башланды. Айгырлар җир селкетеп алга ыргылды. Капкорсак та, бераз соңгарак калып, җан көче белән томырылды, ләкин Җан Гали хан тезгенне тарта төште, ат арттарак калды.

Сөембикә уйлаганча булды: Капкорсак өстендә Җан Гали беренче килде! Дөнья хәйран-вәйран булып шаулады. Җиңүче хөрмәтенә быргылар да уйналды, кубыз-сорнай да чалынды. Җан Гали ханга сигез елкы, бер дөя бүләк иттеләр. Сөембикә, үзе чиккән ябынчаның бавын чишеп, баганадан бүләкне үзе төшерде дә, үз кулы белән Җан Гали ханның иңенә салды.

Гәүһәршад бикә Сөембикә карашында җиңү шатлыгы күрде.

— Үзе беренче килдемени? — диде Булат бәк хатынына.

— Үзе! — диде бикә. — Бу — Сөембикәнең җиңүе.

Булат бәк, хатыны әйткәннәрне аңлапмы, әллә болай гына карадымы Сөембикәгә — аның зиһененнән шул мәлдә үк бер уй сызылып узды: мәхлук Җан Галигә әрәм бу хатын. Дөнья бәһасенә торгы бу гүзәл, хыялның үзе

булып. Булат бәкнең күңел түренә менде. Картлык вәсвәсәсеме бу? Шайтан котыртыгымы, әмма бәкләри бәк ачык аңлады: Сөембикә-ханбикә аның бөтен уйларыннан өстә тора иде.

Гәүһәршад бикәнең сизгер күңеле, очлы карашыннан Булат бәктәге кинәт үзгәреш читтә калмады: Булат бәк хыялы белән Сөембикәне чишендереп азаплана иде. Картлык ягына чыккан хөкемдар хатынны мондый чакта нинди хис биләсә, Гәүһәршад бикә дә шул халәттә иде. Гүзәл, яшь Сөембикәгә нәфрәт, аңа кара язмыш теләү, чибәр йөзенә агу сибәргә теләү иде бу. Ләкин Гәүһәршад бикә бер мизгелгә генә калкынган бу хисләрне шундук кире куды: Булат бәккә яшь хатын алу күптән кирәк иде инде. Әмма Сөембикә тол түгел, хан никахында.

Җан Гали хан, бикәсе бүләк иткән ябынчасын бөркәнеп, Капкорсагына атланып, тантана түгәрәгә буйлап йөргәндә могҗизалы ябынчаның җилдә уйнавы үзенә күрә бер тамаша вә җиңү кебек булды.

Бу төнне өч кешенең күзенә чытлым да йокы кермәде: Гәүһәршад бикә, Булат бәк вә аларның углы Татлыбай йоклый алмады. Ничәмә-ничә бәйгедә баш бирмәгән Татлыбай бу юлы икенче килде. Затлы ябынча да, сигез ат белән бер дөя дә аңа тәтемәде. Булат бәк Ширин өчен дә углының җиңелүе олы кайгы иде, әмма Сөембикәгә күңеле төшү бу кайгыны кысырыклап чыгарган иде инде. Булат бәк татлы хыял эчендә йөзә. Гәүһәршад бикәнең үз уйлары: бу гүзәл ханбикә гүзәл генә түгел, акыллы да, сер бирмәс тешләк тә икән, шул җебеки Шәех Әүлиярның төксез бәтчәсен үзенә тиң ясамак теләр. Ләкин Гәүһәршад бикә бер мизгелгә генә калкынган бу хисләрне шундук ли; янәсе, ул — чын ир хатыны. Димәк, Сөембикә ханча Казан эшләрен үз кулына алмак эсти...

Бу төнне тагын бер кеше йоклый алмады: бу — Сөембикә үзе иде. Ул үз теләгенә ирешә, сайлаган ат та хыянәт итмәде, Җан Гали хан да иярдән төшеп калмады, шөкер. Гомере буе чиккән ябынча да ятка китмәде...

Никахтан соң ничәмә-ничә төн узды, Җан Гали ханның әле кәләш куенына кергәне юк. Хан тикле ханга ул: «Нигә син минем янга ятмыйсың, нигә мине үз ястыгыңа алмыйсың?» — дип әйтә алмый бит инде...

Беренче кичне үк, ак атау-йортта төн уздырганда, Нәргәтай белән Сауфия, Кабулда ишеткәнчә, китап-дәфтәрдән укыганнарынча, җиңги-әбиләр өйрәткәнчә, Сөембикәне кияү каршыларга әзерләделәр.

Картлар яткач, ай калыккач, нөкәрләре белән кияү-хан зөфаф тирмәсенә килергә тиеш иде; ләкин, ни сәбәптер, кияү күренмәде. төн эчендә ат пошкырганы да, ерактагы җыр да ишетелә, әмма Җан Гали ханның тамак кырганы гына ишетелми дә ишетелми. Гадәттә кияү кеше никахка чаклы ук атау-йорт тирәсендә бөтерелә торган иде. Бүләкләр биреп, бикәчне каравыллаучыларның кулын «майлап-җайлап», атауга уза иде; Җан Гали хан исә кыз куенына керәсе төнне дә әллә кайда йөри... Бик соң килде кияү, таң атар-атмаста — ханны китерделәр. Ишек бавы тотучы җиңгәчәйләргә, Нәргәтайга да, Сауфиягә дә ишек хакын кияү үзе бирерлек түгел иде. Нөкәрләр, акча чәчкән булдылар да, китеп бардылар. Атау-йортта кияү белән кәләш кенә калды. Кияү әллә арган, әллә сәрхүш иде, күзен ачар-ачмастан, Сөембикәне кочаклагандай итте дә, нидер мыгырданып, йоклап та китте. Сөембикә атау-тирмәдә ялгыз башы таң аттырды.

Еламады Сөембикә. Бик авыр уйлар кичте аның башыннан. Аллаһ тәгалә аңа ир насыйп итмәгән икән. Абзасы Шаһ Гали кебек, бусы да күсә, хонса бер бәндә, ягъни ирлексез-гайрәтсез нәмәстәкәй булып чыкты. Ләкин серне ятларга сиздермәскә иде. Сөембикә, үзен белә башлаганнан бирле, иреннән яшертен генә зарланган килениәрне җене сөймәс булды. Ирен башкаларга өзлексез мактаганнарны да ул өнәми иде. Ире яманнарны көнләштерә андый мактанулар. Көнчеләр ир белән хатын арасын бозарга да күп сорамый. Ирен хурлаганнар — аларыннан да кабахәтрәк. Ирен бер хурлаган — үзен мең хурлар. Андый сертотмас хатыннар, үзләре дә сизмәенчә, көнчел хатыннарга да, ире яман хатыннарга да сөенеч ташый. Көнчелләр аларның яратышмаганнары өчен сөенә, иреннән уңмаганнар: «Һи, без генә бәхетсез түгел икән әле, әнә ул да иреннән уңмаган», — дип шатлана. Өлешеңә тигән көмешең, башыңа төшкәч — ир итеп тор, зарланма!

Казан җиңгиләре белән Җан Гали хан ягындагы хатыннар иртүк атауга атылып керәчәк. Урын-ятак — ястык-мендәр җыя башлаячаклар. Ястык мендәр асларына мул итеп акча, затлы бүләкләр салырга кирәк. Сөембикәнең кулсандыгы атау-йортта түгел иде. Ул, Җан Галине тиз генә чишендереп, кесәләреннән, кошагыннан акча алып, мендәр асларына, ястыкка, юрган өстенә сипте. Монысы булды, рәнҗемәсләр. Ә зөфаф хакын кем бирер? Кияү ягыннан хатыннар киленнең инсафлыгын тикшерергә керәчәк. Энеләренең җебегәнлеге башларына да килмәс, киленнән гаеп эзләрләр. Түшәк җәймәсенең зөфаф төненнән соң ап-ак калганын күреп, дөнья шаулатачаклар. Гәүһәршад бикә, һичшиксез, җәймәнең ак булуын көтә.

Җәйләү уяна башлады. Хатыннар бия сава, хайваннары белән юри кычкырып сөйләшкән булалар, янәсе, озак йоклый килен белән кияү; тизрәк уянсалар, җиңгиләр атауга ятак җыйнарга керәчәк.

Сөембикә Җан Галине уятып карады, хан уянмады. Хәер, уянса да ул нишләр иде икән дә, ни киңәш бирер иде икән! Аллаһ тәгалә ярдәм итте, шөкер. Сөембикә ике бармагы белән борынын кысып тотты да, колак пәрдәләре ертылырдай итеп, күзе атылып чыгардай итеп көчәнде, аның борыныннан кайнар кан китте. Сөембикә, Җан Гали гәүдәсен бераз читкәрәк тәгәрәтеп, борын канын җәймәгә тамызды. Аннан соң, башын артка ташлап, канын туктатты. Ишек катында җиз төпсә белән җиз комган тора иде. Сөембикә борынын, битен-кулын юып, Җан Гали янына барып ятты. Бераздан хатыннарның җыр әйткәне ишетелде:

— Ишек бавы йөз алтын, безнең килен мең алтын...

— Кияүкәй — ханкай! Һәй, ханбикәчкәй, ач ишегең! — дип кычкырдылар тышта. — Ач ишегең, без керәек, урыныгызны без җыйнаек...

Сөембикә дәшмәде.

— Каты йоклыйлар, — диде берсе.

— Төне каты булгандыр, — диде икенчесе.

Сөембикә, яңа гына уянгандай, киерелгән булды, сузылган булды да:

— Ә-ә, җиңгиләр, сезме-е? — дигән булды.

Хатыннар ургылып атауга керде. Кайсысы мендәрләргә барып тотынды, кайсы — ястыкка; кемдер, Җан Гали ханны түшәктән тәгәрәтеп, өстенә юрган ташлап, җәймәне алды.

Җан Гали ханның егетлек даны, Сөембикәнең кызлык шөһрәте бер тында җәйләүгә җәелде, аннан Казанга таралды, атна эчендә кәрванчылар аша күрше-тирә илләргә дә барып иреште. Бөтен Нугай йорты өчен, бигрәк тә Казанлылар өчен, аерата Касыйм ханкирмәне өчен, ягъни Җан Гали хан якыннары өчен сөенеч иде бу. Әмма очлы күз Гәүһәршад бикә игътибарыннан бер нәрсәне дә яшереп булмый иде шул...

Сөен тутай турында телдәш-диндәш мәмләкәтләрдә төрле сүз йөрде. Аның кияүгә чыгарга теләмәгәнен дә, кызлар гаскәре амузын явы оештырып, барымта ясаулары да, һиндстанга-Кабулга сәяхәт кылганы да төрле авыздан төрлечә сөйләнде. Себер ханыннан килгән кода-яучыларны оятка калдырып кире боруы да, ул яучы-ябагай чәчкән гайбәт тә, адәм әйтеп, адәм ышанмаслык купаеп, Казанга, Булат бәк Ширин белән Гәүһәршад бикәгә килеп ирешкән иде инде. Имеш, Сөен тутайның унсигезгә җитеп тә утырып калуына сәбәпләр берничәү икән: Сөен тутай ирдәүкә икән; имеш, ул кыз-хатыннарга ныграк тартыла, аңа егет тә, ир дә хаҗәт түгел икән; имештер, ерак сәфәрләрдә йөргәндә ул хәрамиләргә, ягъни юлбасар-талаучыларга эләгеп, озак кына хәрамиләр башлыгының хәрам хатыны булып торган икән.

Булат бәк Ширин боларның барысына да чын күңелдән ышана, хәтта үзе сөйләгәндә арттырып та җибәрә. Әйтик, имеш, Сөен тутай, теге хәрами атаманыннан соң, юлбасардан юлбасарга күчеп, кулдан-кулга йөргән, дигән сүз Ширин иҗатының бер җимеше иде... Гәүһәршад бикә — кайда гайбәт, кайда хаклык — кайсысы Булат бәкнең, һәр юлбасар урынына үзен күзаллап, истирахәт кичергәнен бик яхшы аңлый. Бу яман сүзләр генә Сөембикәнең илаһи камиллеген кимetә алмаганын да белә Гәүһәршад бикә.

Ул гайбәтләр Сөембикәнең үзен күрүгә үк чәчелде дә онытылды. Бу хатынга гайбәт-пычрак — бөһтан ябышмый, коела да төшә икән. Гайбәтавызлар үзләреннән-үзләре ябылды, томаланды. Булат бәк кенә иске сүзләрне кабатлаудан туймый. Әмма Гәүһәршад бикә белә: Булат бәк, яман сөйләгән саен, Сөембикәгә гашыйк була бара.

— Кара син, атай,— диде Булат бәк чираттагы гайбәттән соң.— Әллә кайларда себерелеп йөргән, димәссең... Шул сәрхүш күсә Җан Галигәме шул хә... хәрами калдыгы?

Булат бәкнең «хәзинә» дип әйтә язганын, соңра «хәрами» сүзе белән котылганын бикә бик тиз аңлады, ләкин сүз әйтмәде, әмма болай уйлап куйды: Сөембикәне төшеңдә күрәсең, карт качыр, Сөембикәне сөясең килә синең. Кулдан-кулга йөреп себерелгән булса да, яламаган җирен калдырмас идең дә... Сөембикә синең өчен ерак йолдыз... Сөембикә әле саф кыз, мокыт үгез Булат бәк! Ә кем бәхетенә эләгер ул хәзинә? Билгесез. Әгәр дә бу дивана-тастаракай Булат, хакыйкатьне сизсә, һичшиксез, теләсә нинди яман юл белән булса да, әлеге эшкә алыначак. Җан Гали ханны буып булса да, ул Сөембикәне алачак... Гәүһәршад бикә янә иренә бакты да, янә үзалдына әйтте: ю-ук, бу карт качыр, астан эш йөртү остасы булса да, бер ялгызы гына бу эшне майтара алмас. Дала кызы, ирләр авызлыклый алмаган айгырларны буйсындырган Сөембикә бу шома бәккә җене белән каршы торачак, барыбер бирешмәячәк.

Җан Гали хан зөфаф кичендә кыз-бикәч куенына кергәнен халык теленнән генә белде: нөкәрләре аны олылап тәбрикләде. Халык әйтсә, хак әйтәдер, дип, сәрхүшлектә хәтерләмим, дип, Җан Гали хан үзен ир санап, һушкүңел илә яши иде. Ханның аталык остазы Хуҗәмәт бәй эшнең чынлыкта ничек булганын чамалый иде. Өйләнү турында сүз кузгалгач та, аталык Хуҗәмәт Галине өйрәтә башлады. Кыз куенына кергәндә алай-болай булсабулмаса, ничек итеп, зөфаф тамгасы салырга икәнне әйтеп куйган иде.

Аталык Хуҗәмәт Шәех Әүлияр ханның Шаһсолтан бикәдән туган балаларының гел үлә баруы, буынсыз булып туулары, исән калган Шаһ Гали белән Җан Галинең дә, сигез яшьләрдә генә телләре ачылып, бик соң тәпи йөри башлауларын искә төшереп, уйланып утырды. Шәех Әүлияр да, Шаһсолтан бикә дә бу ике сабыйны һичкемгә күрсәтмичә үстерделәр. Икесен дә сөннәтче бабага бирмичә, аталык Хуҗәмәткә тапшырды Әүлияр хан. Хуҗәмәттән сер чыкмый. Хуҗәмәт Шаһ Галине — җидедә, Җан Галине биш яшьтә сөннәтләде. Хуҗәмәттән сер чыкмады, әмма илнең күзе сукыр түгел, очлы күзле хатыннар да, ил агалары да сизенде: Шәех Әүлияр ханның балалары Шаһ Гали дә, Җан Гали дә башка мирза балалары белән су коенмый, мунча керми.

Сөембикә иренә сүз катмаенча гына киенде. Җан Гали хан да, мунчага барып, юынып, киенеп чыкты. Сөембикә, һични булмагандай, көләч, хәтта артык көләч, читтән караганнарга ул чиктән ашкан бәхетле булып күренгәндер...

Туйлар узгач, туй күлмәген салып өлгермәс борын, Сөембикә ханша, җиң сызганып, йортны тәртипләргә кереште. Сарай агалары ханбикәгә Хансарайдагы иң яхшы бүлмәләрне тәкъдим итте. Әмма Сөембикә Хансарайда калырга теләмәде: ул ире Җан Гали ханга үзе өчен аерым йорт салырга кушты. Йорт өчен урынны Сөембикә үзе сайлады. Бу урын Мунча Күле буенда, Ханкүчә белән Мунча урамы кисешкән төштә, почмак йорт булачак иде. Бакчасы Мунча Күленә барып тоташачак. Җан Гали хан да, түшәкче би дә моңа каршы килә алмады, чөнки Сөембикә үз теләген сабыр гына, әмма икеләнергә урын калдырмаслык итеп әйтте. Төрлечә юрадылар Сөембикә ханшаның Хансарайдан читтә, хәтта төп кальгадан тыш яшәргә теләвен. Аталык Хуҗәмәт ханга: җаны теләгән җылан ите ашаган, дип, Сөембикә теләгеи үтәргә киңәш бирде. Гәүһәршад бикә бу эшне ханбикәнең иркенлек сөюе, дип аңлатты. Булат бәк Ширин ханбикәнең иркенлектә яшәячәген,

аерым йортта торырга теләвен бик хуплады. Сарай бикәләре дә бу хакта сүз кузгатып караган иде. Сөембикә кыска һәм үтәрлек итеп:
— Ханның гозере шул!—диде.
Ә хан үзе нәүбәтендә, Сөембикә өйрәткәнчә:
—Хансарай ул—хан өчен, гаурәтләр өчен түгел,—дигән булды.—Минем әле тагын өч тапкыр өйләнәсем бар. Һәр мөэмин мөселман һәр хәләле өчен аерым йорт салдырып кергезергә бурычлы. Хатынымның йортына кайчан телим, шул чак барачагым.
Җавап кискен вә төгәл иде. Гәүһәршад бикә Җан Гали хан авызы әйткән бу сүзләрнең Сөембикәдән чыкканын бик яхшы аңлады. Сөембикә, эшне үзе йөртсә дә, ире Җан Гали хан теләге итеп-күрсәтергә тырыша, ирен халык алдында күтәрергә омтыла, үзе дә абруйлы ханның абруйлы хатыны булып яшәргә тели. Моннан соң Гәүһәршад бикәнең Сөембикәгә булган соклануы тагын да артты: мәрхәбә, Сөембикә! Әфарин, Сөембикә! Син чын ханбикә булып дөньяга килгәнсең!
Сөембикә өчен ике йорт салдылар. Төп нигез таштан корылды. Кып-кызыл янган кирпечтән. Кабулдагы падишаһ сараеның күчермәсе иде бу бина. Икенче йорт шытырдап торган нараттан салынды. Йорт эшләренә, бакча мәшәкатьләренә Сөембикә турыдан-туры үзе рәһбәрлек кылды. Кай җиргә арык ясап су агызырга, кай урынга су атып торучы көпшәләр куярга, кайда җимеш агачлары, кайда чәчәк түтәлләре казырга, кайсы урында ямь-яшел чирәм генә калдырырга, тавис, тутый, сайрар кошлар җибәрергә икәнен телдән әйтеп кенә түгел, мөһәндисләр, мәгъмурларга сызып, сурәтләр ясатып, йортларны, бакчаны шул сурәт-сызымнарга төгәл туры китереп төзеттерде...
Казан йортына Нугайдан да, Хаҗитарханнан да, Себер вә Кырымнан да ханбикә-килен булып төшкәннәр бик күп булды. Әмма дә болай да матур йортлар салдырып, шундый да гүзәл истирахәт бакчасы корган бикә моңарчы булмады. Казан ханы ихатасында туып та, Казанның иң мәшһүр, бай нәселе Шириннәрнең Булат бәгенә кияүгә чыгып та, Казан шәһәрен матурлау, гүзәл бакча үстерү, матур биналар салдыру Гәүһәршад бикәнең башына да килмәгән. Сөембикә майтарган эшләрне күргәч, Гәүһәршад бикә кара каршы ике хис уртасында калды. Гүзәллекне күреп, ул башта сөенде, ханбикәне мактады, хәтта бер мәҗлестә ул Сөембикәнең фәгалиятен хуплап алкыш күтәрде. Әмма Гәүһәршад бикәнең күңеленә кортлы бер фикер кереп оялады: ни өчен соң ул, Гәүһәршад бикә, тамырларында Чыңгыз каны ага торган, Олуг Мөхәммәт ханның туруны була торып, Ибраһим ханның кызы була торып, Мөхәммәт Әмин ханның сеңлесе була торып, үз ватанын, үз Казанын шундыен да матур бакча ясамаган? Шәһәрсез үскән дала кызы, елкы дөя өстеннән төшмәгән кыргый мирза кызы Сөембикә шушы эшләрне бик оста башкарып ташлады. Сөембикәгә алкыш күтәргәндә Гәүһәршад бикәнең елмаюында көнчелек кортының шәүләсе дә бар иде.
Тормыш корып җибәргәч, Сөембикә янә дә гүзәл бер бакча төзергә алынды. Урта Кабан күле буенда моңарчы дөньяда күренмәгән бер бакча, шау чәчәккә күмелеп, сайрар кошларның тавышына чумып утырырга тиеш иде. Сөембикәнең гомер хыялы булган Ирәмбагка, үз күзләре белән күргән дөнья җәннәте, Баги Вафага тиң булырга тиеш иде ул истирахәт бакчасы, ватан агачлары белән бергә анда һиндстан, Кытай, Мәвәрәәннәһердән кайтарткан җимеш агачлары да үсәргә тиеш иде. Сөембаг дип аталачак бу бакча, хан өчен, бәкләр, кунаклар өчен генә түгел, теләгән һәр кеше кереп, хәл алырлык, кош сайравын тыңлап хозурланырлык иркен вә зур мәйданлы булачак иде.
Урта Кабан белән Ерак Кабан арасында бакча эшләре башланды.
Вакыт уза торгач, Сөембикә бу язмышына иялəнеп өлгерде, чыннан да ул яртылаш кына булса да бәхетле иде шикелле. Дөресрәге, максатлы иде ул. Бөтен кайнар дәртен ул китапханә белән Сөенбагка багышлады. Ханның килешүчән булуы, Сөембикә сүзеннән чыкмавы ил өчен бик тә кулай иде. Буынсыз хан исеменнән Сөембикә Казан йорты, тәхет өчен күп эшләр майтара алачагына сөенә иде.

Шулай ел үтте, янә җәй җитте. Туйдан соң тугыз ай узар-узмастан сүзләр йөри башлады: ханбикәдә үзгәреш юк; Сөембикә кысыр икән; юк, ханда икән гаеп, Җан Галинең баласы булмый икән; икесендә дә бардыр, дип сөйлиләр... Эшнең асылын ике-өч кеше генә белә иде: Хуҗәмәт аталык, Гәүһәршад бикә дә, Сөембикә үзе.

Көннәрдән бер көнне Сөембикә ирен җайдак йөрешкә, Идел арьягына чыгарга күндерде. Үзе белән бер генә ят кеше дә алдырмады. Сөембикәнең җанахирәтләре Нәргәтай белән Сауфия дә хезмәтче коллар гына иде.

— Курыкма!—диде бикә иренә.—Тәхәтеңне урламаслар. Тәхеттә озак утырган түрәнең күте җәелә икән, син шуны беләсеңме, ханҗаным? Артык җәелеп, йомшакка изләшеп китмәсеңгә, иярге менәргә, каты күнгә утырыш лазем, ханкай-җанкай! Сакчыларыңны да калдыр. Минем ике ахирәтем бар, әнә, Нәргәтай белән Сауфия—аларның берсе ун сакчыңа тора, билләһи. Җәң, ахирәткәйләрем, ханыгызга һөнәрегезне күрсәтеп бирең...

Алдан сөйләшенгәннәрдер, шул сүзне генә көтеп торгандай, Нәргәтай белән Сауфия тезгеннәрен тартып бушаттылар да чөңгереп, бер сызгырдылар:

— Һәйдә-ә, малка-ай!—дип кычкырдылар.

Ике айгыр, җиңел гәүдәле кызларны алып, томырылып чабып китте. Дала түреннән борылып, алар узыша-узыша хан янына килеп җитте, кызлар икесе берьюлы җен кебек ыргып чабучы ат сыртына аягүрә басты. Егылып төштеләр дигәндә генә, ахирәтләр, ияр җәясенә тотынып, ат корсагы астына керде, хан яныннан ахирәтләр шулай чабып узды. Җан Гали ханның исе акылы киткән, аның өчен бу шаккатыргыч тамаша иде. Ахирәтләр ат корсагы астыннан үтеп, иярнең икенче ягына үрмәләп, янә иярге менеп утырды, атлар янә борылды, аҗгырып чабып, туп-туры хан белән хинбикәгә килә башлады. Атлар менә-менә Җан Гали белән ханбикәне таптап узар кебек туры килә, өскә килә. Хан Сөембикәгә бакты, бикәнең йөзендә курку түгел, соклану-елмаю күргәч, хан качып китмәде, шулай да Сөембикәгә сыена төште. Ике хезмәтче, ике сөңге тотып, атлар белән ике арага йөгереп чыкты да, сөңгеләрне ташлап, читкә тайпылды. Атлар сөңгеләр турына җитәрәк, кызлар бер куллары белән ияргә тотынып, икенчесе белән сөңгеләрне эләктереп, иярләрендә тураеп, хан белән ханбикәгә тияр-тимәс пыраннап чабып узды. Атлар узуга, әлеге ике кол сөңгеләр ташланган урынга ике карачкы-мәрә кадап куйды. Чапкын кызлар, барган шәпкә атларын борып, чинап-кычкырып, өзәңгеләре белән атларына тибә-тибә, атларын җендәй дулатып, карачкыларга туры килә. Алар шулай өермә куптарып хан яныннан узды. Ике карачкы да күкрәкләренә ике сөңге алып, авып калды. Кирегә борылып, Сауфия атын янә хан белән бикә өстенә җибәрде. Җан Гали читкә тартылды. Сөембикә баскан урынында төз калды. Сауфия, бер-ике адым ара калдырып, атын шып туктатты. Ат чинап-кешнәп арткы куш аягын җиргә терәп, койрыгы белән туфракка тиеп үзен тыйды. Сауфия җиргә төште. Хезмәтчеләр атны йөртергә алып китте. Нәргәтай арттарак калган иде. Ул ыстанга җитәрәк, атын куалый башлады, ат соң чик тизлек белән ыстан турыннан узганда Нәргәтай әче аваз белән чинап-кычкырып, ияреннән очып чыкты да, янга сикерде. Җан Гали хан авызыннан: «Йа-а, Хода-а!»—дигән өн чыкты. Нәргәтай башта аякка төште, егылып, ике кулын җиргә каты терәп, башы аркылы тәкмәрләп китте, биш-алты тапкыр тәгәрәгәннән соң, аякка басты.

— Мең яшә! Машалла!— дип кычкырды Сөембикә.

Җан Гали хан агарынган, хәлсез иде. Ул әллә куркуыннан, әллә Нәргәтайның исән калуына ишарә итте:

— Әстәгыйфирулла! Сөбханаллаһ-машаллаһ!—дип кабатлаудан һич туктый алмый иде.

Ни өчен аны, якыннарыннан аерып, үзен генә сәхрәгә алып чыкканнарын Җан Гали хан аңламый иде әле. Шаян-тиктормас хатыны Сөембикә аны ат тамашасы күрсәтергә, тирмә күләгәсендә янга ятып, калкаеп кымыз чөмерергә чакырды, дип уйлый иде хан. Чыннан да, ат кәмитеннән соң, Сөембикә аны үз тирмәсенә чакырды. Дала уртасындагы ялгыз тирмәгә

ахирәтләр дә, коллар да, сакчылар да мең адым арадан якынаерга тиеш түгел иде. Тирмә салкынына кереп, бераз кымыз эчкәч, аннан соң «куып тотам»лы уйнагач, Сөембикә, тирмәдән чыгып, әйләнә-тирәне карапгыргалап керде: берәрсе якын тормыймы, янәсе. Ул кинәт җитдиләнде һәм йомшак, үгетле тавыш белән ирена дәште:

— Ханкай, җанкай,— диде.— Син беләсең — Казанның казнасында хәзинә юк. Ни өчен Казанның казнасында хәзинә юк? Әйт, хан! Ни өчен гөлбакча корырга, матур йортлар бина кылырга мая юк? Әйт?

Истирахәт урынына казна малы турында сөйләшү башлангач, Җан Гали ханның сөмсере коелды. Җитмәсә, хатыны кыса: әйт, вәссәлам! Җавап таләп итә. Җан Гали хан, аклангандай, сүз башлады:

— Сың... Булат бәк Шырын әйтте бит инде... Әүвәлге яуда урыслар ганимәт алып китте...

— Элеккеге яу беләсеңме кайчан булды?.. Аждаһа елында. Хәзер нинди ел, ханкай?.. Бичин елы, ягъни Маймун елы... Шул еллар эчендә казнага күпме мал туплап була иде? Кая ул маллар? Кая ул хәзинә? Син хан булганга да ике ел узган бит. Кая китә харажс малы, кая китә калан җыемы? Кайда ул хәзинә? Кайда кичү-чатлардан алынган салым? Моржа башыннан җыелганнар маясы кайда? Елкы башыннан, куй башыннан алынган ясакны кая куйдың, хан? Кая куйдырдың, хан? Тугыз үгездән — бер үгез, тугыз елкыдан — бер елкы, ун куйдан бер куй — сана! Базарда торганнардан өч өлеш сәүдә керемен куш. Кайда ул дәүләт байлыгы? Ел саен өч йөз меңләп елкы, шул ук санда сыгыр малы, кызыл мал җыйналган. Яртысы карак бәкләр казнасына хәзинә булып урнашкан. Калганы Мәскәүгә озатылган. Җәйли җыйган маяны урыс җыя, урыстан калганны ата күселәр ашап бетерә...

Җан Гали хан кымырҗып әйтә куйды:

— Хансарайда да, казна-пулатта да күселәр юк.

Сөембикә ачынып көлде:

— Һай, Аллам-Ходайкаем ла! Мин амбар күселәрен әйтмимен, ханыкай, тирәңдәге күселәрне әйтәм: Булат бәк күсе, Боерган сәет күселәрне әйтәм... Син тагын мәҗлестә: ханбикә сезне сарай күселәре, дип атады дип кычкыра күрмә... Ханнар килә дә китә. Шул сарай күселәре кала. Казна тагын бушый. Сине өч яклап талыйлар, ханкаем-җанкаем. Мәскәү — Казанның кан тамырына кадалган талпаннарның иң комсызы, иң олысы. Касыйм ханкирмән дә — Казан имчәгенә аслынган имгәк. Шуннан соң бичара Казан ничек мантысын?

Бу сөйләшү ханга бик авыр тәэсир итте. Рәхәт иде элек. Касыйм ханкирмәнендә чакта ул һичбер мондай эшләргә тыкшынмый иде. Бәкләр-мирзалар, Мәскәү баярлары белән үзара сөйләшеп, кәгазь яза иде дә, Җан Гали ястыкта чактамы, балыкта чактамы, килеп кул куйдырталар, мөһер суктыралар иде дә, кабат борчучы булмый иде. Василий аны Казан тәхетенә куябыз дигәч тә, ул шатланып разый булды. Казан тәхетендә утыруы да шулай ук мәшәкатьсез булыр, диделәр аңа. Ә монда яшәве бик рәхәт түгел икән шул. Кемдер аның астыннан тәхетне тартып алырга уйлый, кемдер аны куарга йөри кебек. Ниндидер күселәр казнаны талый, аның үз өлешен урлый икән. Сөембикәгә өйләнгәч, эшләр тагын да читенләште. Корылтайда, дивани мәҗлесләрдә аны бер төрле бәкләр бу якка каера, икенчеләре тегe якка аударырга маташа. Өйгә кайткач, Сөембикә үзенчә тирги. Хан булмаганың мең өлеш артык икән лә ул. Гомере буе Мәскәү сүзеннән чыкмаска ул теле белән дә, шартнамә белән дә ант бирде... Бичара хан, күз яше белән елыйелый, хатынына шуларны сөйләде.

— Хәзер мин ни кылаем инде? — диде хан.— Сине тыңласам — син дөрест. Алар әйтсә — алар хаклы.

Сөембикә иң мөһим сүзне әйтергә вакыт җиткәнлеген сизде: ул Җан Гали ханның юеш битен кулъяулыгы белән корытты, такыясын салдырып, Җан Галинең тирләгән башын сөртте. Бикә әйтте:

— Ханкай, җанкай Гали,— диде.— Син мине сөясеңме?

— Син мине сөяр булсаң, сөям! — диде хан.

Сөембикә көлде. Сабый да — сабый, ике тәхет биләгән хан да — сабый.

— Мине тыңласаң,— диде бикәч,— мине син сөйгәннән дә ныграк сөячәкмен: син Мәскәүдән аерыл!

— Уасили белән Булаттан куркам!— диде хан.

— Миннән курыкмыйсыңмыни?— диде бикә.

— Куркам,— диде хан.— Син әллә нинди... Бер баксам — син анам, бер баксам — апам, бер баксам — җен кебек усал пәри син.

«Дөрес әйтәсең,— дип уйлады бикәч.— Мин сиңа ана да, апа да, усал казый да, тик — хатын гына түгел».

— Ханыкай-җаныкай,— диде ханбикәч.— Син яхшы хан булып яшәр идеңме?

Җан Галигә җан керде, ул хыялый елмаеп:

— Һе, ничек кенә але,— диде.

— Яхшы айгырда мин чиккән ябынчаны иңеңә салып, ян кырыңа йөргек атка атланган мәгърүрә ханбикәңне куеп, бәйрәмнәрдә, базар көннәрендә, илчеләр-кунаклар алдында Казан мәмләкәтенең бөек падишаһы Шаех Әүлияр углы Җан Гали хан булып йөрер өчен, казнаны баетырга кирәк. Башка илләргә яу чапмаенча, үз илеңә яу чакырмаенча яшәрлек куәтең булса, синең бөтен нәрсәң җитеш булыр, хан. Мин сиңа тугры хатын булырмын! Мин сине әнә шундый хан буларак сөярмен, син мине...

— Мин сине хәзер дә сөямен,— диде хан, бикәчнең итәгенә башын куеп.

— Сөйсәң — шул, Җан Гали хан!— диде Сөембикә.— Без синең белән икәү Булат күсе белән Боерган кумакны да, Мәскәүнең бөек кенәзе Уасилины да Казанның канын имүдән туктатырга тиеш. Без икәү. Бу эшне башка берәү дә майтарырга алынмас. Минем — зиһен-акыл, синең тәхет хакың ярымкол Казанның зынҗырларын чишәргә алынсын!

Шушы сөйләшүдән соң, Җан Гали хан бик нык үзгәрде. Хатынына да, сарай олыларына да, Мәскәү илчеләренә дә ул җентекләбрәк, турырак карый башлады. Аның күз карашында мәгънә чаткылары чагыла, сүзләрендә дә читтән кергән ихтыяр түгел, үз уеннан чыккан фикерләр сизелә. Бу үзгәреш Сөембикәне чиксез куандырды. Әмма әлеге үзгәреш Булат бәкне хафага салды. Ханның яңа фәрманнары хакыйкый мөмкинлекләрдән ерак түгел иде. Ул фәрманнар астыртын эш йөртүчеләр мәнфәгатенә суга, Мәскәүнең өметләренә аркылы ята иде.

Сөембикә бик күп файдалы-күрекле эшләр майтарды. Ханболында, Арча Кырында да, Кунак Атауда да сәүдә гөрли. Нугайлы бәкләр, мирзалар, сәүдәгәр-базаркәннәр, Казанга ил булып килеп, җәй буе сату итә: елкы, куй, дөя китерәләр. Бу туганлык, дуслык сәүдәсе ике илне дә бик ныгыта-баета иде. Себердән эрбет чикләвеге, кеш, бүре, төлке тиреләре, нарат сагызы, чәер алып киләләр. Хаҗитарханнан балык җилеме, балык мае, каклаган балык килә. Кырымнан йөзем, алма ташыйлар. Гөрли базар, гөрли туганлык: Казан мөселманның шимали кыйбласына әверелә бара. Татар-нугай арасындагы бу кардәшлек, үзара кораю, ярдәмләшү Мәскәү өчен бик тә кирәкмәгән бер фәгалият булып, баярларны да, дин әһелләрен дә, олы кенәз Василийны да бик зур хафага ташлады. Илчеләр аша, телдән дә, шартнамә-хатлар язып та, Василий Җан Гали ханның йөрәгенә курку салырга тырыша башлады. Яу белән килеп, ханны әсир алып, Белозеро зинданына ябып җәзалап үтерәчәген Василий илчеләр теле аша әйтә торды. Икенче яктан Булат бәк өере аңа көн күрсәтми, өченче яктан сөекле хатыны Сөембикә ханны битәрли. Шуларга чыдый алмыйча, хан хәмер эчә башлады.

— Һәй, ханкай, куй бу яман гадәтеңне!— диде бикәсе.

— Эчүмени бу, бикәм!?— диде хан.— Касыймда яшәгәндә урыс баярлары миңа болай түгел, менә шушлай салып бирә торган ие,— дип, Җан Гали көрәгәсен тотырып, тагын хәмер эчте.

— Баярлар синдәйләрне бик яхшы һөнәргә өйрәтәләр шул,— диде бикә.— Алар сине чукынырга да өйрәткәннәрдер әле?

— Өйрәттеләр шул!— диде хан һәм чукына да башлады.

— Кәйт, нәҗес!— дип кычкырды Сөембикә.— Чукынмыш татар булгансың син!

Җан Гали хан көлә дә көлә.

— Тәмуг кисәве!—дип, Сөембикә, Иблистән качкандай, Җан Гали хан янынннан читкә атылды. Хан Сөембикәгә якынаймакчы иде: бикә, кулларын болгап, ирен читкә кугандай итеп, икенче бүлмәгә чыгып китте.

Сөембикә ни әйтергә, ни уйларга да белмичә аптырады. Ходаем, әллә Касыймда чакта урыслар Җан Галине чынлап чукындырдыларммы икән? Һич курыкмаенча төртенә бит, нәҗес.

Бүлмәгә Җан Гали хан керде.

— Кит, мөртәт!—дип кычкырды Сөембикә.—Якын килмә, кяфер!

Бикәнең чынлап үпкәләгәнен күреп, гаепле бала сыман, Җан Гали кыюсыз гына ишек катына барып чүгәләде. Аннан бикә янына елышмак булып торган иде, Сөембикә аны кискен кул хәрәкәте белән туктатты:

— Якын килмә, мордар!—диде.

— Мин уйнап кына,—диде хан.

— Бар,—диде бикә.—Мунчага барып, кулларыңны, маңгаеңны кырык кат ю! Тәүбә ит! Шунсыз миңа йогынасы булма!

Хан юынып кайтты. Ул мәлҗери башлаган иде инде, мунчадан соң чүлмәге белән күтәреп, хәмер эчте дә:

—Их, Сөембикә, ханбикә,—дип, күкрәгенә суга-суга елый башлады.—Мәскәүгә биргән антым булмаса... мин синең сүздән чыкмас идем...

Сөембикә дәшмәде. Хан, сөйләнеп-мышкылдап утыра торгач, йоклап китте. Бикә, аның өске киемнәрен салдырып, түшәккә яткырды. Үзе төн ката йокламады.

«Менә дигән кияүләрдән килгән яучыларны борып сайлана торгач, сайлап алган бәхетең шушы инде, Сөембикә, ханбикә»,—диде ул сабыр гына. Ярымсабый, ярымдивана, ярымхан, ярымир, гамьсез мышнап, рәхәт йоклый... Кыйсмәтендә әлләниләр булса да, ул хурланмас иде. Сөембикәнең кысырлыгы хакында сүзләр, куера-куера, үзенә килеп җитсә дә, ул кимсенми. Вариссыз гаиләләр аз түгел. Әнә, Мәскәүнең иң бөек кенәзе Уасилинең хатыны да бала тапмый, дип бөтен дөнья сөйли. Уасили шул хатынын аерып, яшь хатын алды. Дүрт ел тордылар—балалары булмады. Гаеп хатыннарында түгел, Уасилинең үзендә, ул үзе хонса ир икән, диләр. Төрле хәлләр була җиһанда. Уасилинең кысыр икәненә тәмам ышанып җиткәндә, яшь кенәзбикә Барыс Елында бала китерде. Уасилинең бу хатыны Елена турындагы гайбәт Казанга да килеп иреште. Имеш, кенәзбикә бу ир баланы хәрам юлдан тапкан икән, диләр. Гайбәттер, ихтимал. Әмма кенәзбикә Елена түзә бит. Сөембикә дә гайбәттән егылып үләрдәй зәгыйфь түгел. Әмма, ире каты куллы хөкемдар булса, төкерер иде ул гайбәтләргә. Эшләр исерек Җан Гали әйткәнчә генә гади түгел шул. Ямани затлар астыртын эшләр майтара. Җан Галине тәхеткә сорап йөргән бәкләр дә, Булат бәк белән Гәүһәршад бикә дә ханга каршы нидер кора, кайнаштыра. Бу кайнаштыру Сөембикә тарафынамы, әллә Җан Гали ханга гына юнәлтелгәнме, әллә икесенә берьюлы риялымы алар? Җан Гали хан, Мәскәү кушканны эшләсә дә, аларга ярамады. Сөембикә теләгәнне тота башлагач та, алар риза түгел. Ни тели бу фирка? Билгесез...

Шушы заманда Кырым вилаятендә кинәт үзгәрешләр булып алды. Бөек солтан Сөләйман Кануни, Бакчасарай тәхетеннән Сәгадәт Гәрәй ханны алып, аның урынына Сәхип Гәрәйне тәгаенләде. Кырым белән Мәскәү арасы янә яу-сугыш мохитенә килеп керде. Мәскәүнең кан вә җан дошманы Сәхип Гәрәй хан, Бакчасарай тәхетенә менүгә үк, Мәскәү өстенә яу чыкты. Бөек кенәз Василий, Коломна шәһәрендәге бөтен казнаны, затлы-кыйбатлы нәрсәләрне Мәскәүгә ташыттырып, гаскәрен Коломнага китерде.

Кырым гаскәре, һич тоткарлыксыз, Рязань каласына килеп җитте. Бу чигенү гадәти бер алдавыч хәрәкәт булып, бераз чигенгәч, кинәт борылып, Мәскәү явы кырымлылар өстенә ябырылды. Инде Кырым гаскәре кача башлый, урыслар качып баручы татарлар артыннан бастырып куа китә. Татарлар, бераз качкач, кырт борылып, дошман өстенә ыргылып һөҗүм итә, урыс гаскәре тәмам кырылып бетә. Бу яу белән җитәкчелек итүче баһадир—Ка-

занның элекке ханы Сафа Гәрәй иде. Казаннан куылуының төп сәбәпчесе Василийга Сафаның бөек үче булганлыктан, бу яуны башлап йөрүче дә Сафа Гәрәй үзе иде һәм ул орышның иң кайнаган урынында йөрде. Ул бик күп дошман баһадирларын үз кулы белән чабып һәлак итте, турады. Бу кырылыштан соң калган Мәскәү гаскәре таралып-чәчелеп беткәч, Сафа Гәрәй яу кырыннан бөек кенәз Василийга хат язды:

«Казанда хан булып торганымда һичвакыт синең җиргә баскынлык кылмадым. Һичбер вакыт усаллык итмәдем. Бәлкем, син үзең һәрвакыт миңа золым итеп тордың вә һәрвакыт өстемә гаскәр җибәрә тордың. Кара халыкка иген икмәк, мал үрчетмәк өчен форсат калдырмадың, яу артын яу юллап, канымызны корыттың. Ханлыкны ташлап чыгарга мине мәҗбүр иттең. Миңа фәкать Аллаһ тәгалә куәт бирде вә синең өстеңнән интикамымны алдым, гаскәреңне ватып, зыран кыйлдым, шөкер. Боның илә генә эш бетмәс, моннан соң да сиңа гадел тормасам кирәк!»

Сафа Гәрәй бу хатны тоткын урыслар аша Мәскәүгә, Василийга юллады. Әлеге хатны алганда кенәз Василий үлем якасында, түшәктә ята иде. Сәхип Гәрәй хан белән Сафа Гәрәй баһадирның Мәскәү гаскәрен пыран-заран туздырганын ишетүгә, бөек кенәз аяктан калып, хаста булды. Шулай ятканда аңа Сафа Гәрәй баһадирның хатын тоттырдылар. Мәскәүнең бөек кенәзе, егерме сигез ел тәхеттә утырганнан соң, илле дүрт яшендә, шулай җиңелүне кичерә алмыйча җан тартты.

Хакыйкый ки, Иван углы Василий бөек хаким иде. Урысның вак вә эре кенәзләрен җиңеп, бөек Московия мәмләкәте корып, аны Казан вә Кырымның куркыныч күршесенә әверелдерүче ул — кенәз Василий. Казан җиренә басып кереп, мәмләкәт ара солых вә язылмаган әхлак кануннарын җимереп, Сура елгасы тамагына рөхсәтсез рәвештә шәһәр корып куйган йортбасар да ул — Иван углы Василий кенәз булды. Әсир алынган Казан ханы Габдел Латыйфның вакытсыз үлемендә дә, бөек хан-шагыйрь Мөхәммәт Әминнең агулануында да Иван углы Василий кенәзнең кулы уйнамагандыр, дип бер генә тарихчы да кистереп әйтә алмас. Казан йортының нигезләрен әнә шулай астыртын эшләре, яулары белән какшатып, җимерелер хәлгә җиткезүдә бөек кенәз Василийның кулы кылган эшләр санап бетергесездер.

Казан тәхете әтрафында кайнашучы олы вә кече бәкләр өчен бөек кенәз Василийның вафаты шөпшә оясына чыбык тыгып болгаткандай булды. Сөембикә Кырым белән Мәскәү сугышы башлангач, бераз иркен сулаган иде. Сәхип Гәрәй ханның Сафа Гәрәй баһадир рәһбәрлегендәге куәтле гаскәре Мәскәүгә йөри башлаганын ишеткәч, Казан сараенда тынычлык урнашты. Мәскәү тарафдарлы астыртын бәкләр тынып калды. Казан яклы ватансөяр мирзалар төз атлап йөри башлады. Бу тынычлыкның вакытлыча гына, шомлы бер тын алу гына булуын Сөембикә бик тиз аңлады. Еланнар, күселәр форсат көтә. Әмма дивани мәҗлесләрдә элек Мәскәү эте булган бәкләрнең дә, Сафа Гәрәй ханны суярга төнлә баш күтәргәннәрнең дә:

— Мәскәүгә яу чабарга кирәк! Сәхип Гәрәй хан белән Сафа Гәрәй баһадирга ярдәм булыр! — дип Җан Гали колагына оялаганнарын уйлап, Сөембикә пошаманда яши башлады.

Сафа Гәрәй баһадир өчен бу, әлбәттә, бик зур ярдәм булыр иде. Казан явы Коломнага йөреп, Мәскәү явының артына, янына китереп орса, алар тагын да бөек җиңүгә ирешер иде. Әмма буш казна белән соңгы яугирләрне олы яуга озату бик зур ахмаклык булыр иде. Сөембикә бөтен көче белән яуга алгысыган угланнарны, бәкләрне бу эштән тыйды. Шулай итеп, ул хәтта үзенә дустанә булганнарны да дошман ясады. Мондый мохиттә дус — дошманга, дошман дуска әверелү ихтималы тагын да артты. Кузгалыш булуы бик мөмкин, әмма бу кузгалыш кай тарафка юнәлер — хәл аңлап булмас дәрәҗәдә буталчык иде.

Сөембикә Җан Гали ханның үзен генә калдырырга да, үзе генә ялгыз кунарга да курка. Хансарайда Җан Гали хан йортында кунганда да ул шикләнә, үз өендә икесе бергә булса да курка. Кемдер йөри сыман. Сакчы

лар йоклаган булса, аларны йоклаткан булсалар? Җан Галигә иярә килгән Касыйм Хан кирмән бәкләре дә сәер сәясәтле кебек тоела, алар да хәзер ханны кистереп якламый кебек. Алар да, Василий кенәз үлгәч, Җан Гали ханга каршымы? Шулай шомлы төннәр, борчулы көннәр үтә торганда, Мәскәүдән чапкыннар кайтып төште.

— Тәхеттә мәрхүм Уасилинең дүрт яшәр углы Ибан калды,— диделәр.

Бу хәбәрне ишеткәч, берничә кеше берьюлы бер сүз әйтте:

— Бәс, иске шартнамәләр, антлар бозылачак!

Шул атнаны ук Мәскәүдән яңа кенәздән илчеләр дә килеп җитте. Кенәз Иван Васильевич илчеләре иске шартнамәләрне яңарту максаты белән Җан Гали ханның йортына узып, зур бүләкләр биреп, иске шартнамә көчендә кала, дип имза алып, алтын нишанлы мөһерне бастырып, кайтып та киттеләр. Моны белгәч, бәкләр хәйран калып, бот чабып, тел шартлатып аптырашта калды. Аннан соң, бәкләрнең олысы-кечесе, акырып-бакырып, Җан Гали хан өенә басып кереп, бик олы гауга куптарды. Бу хәлләрне ишеткәч, Сөембикә егылып китә язды, ханны сүкте.

Җан Галинең мыгырдана-мыгырдана аклануын да тыңлар дәрәҗәдә түгел иде Сөембикә.

— Алар бит: «Ел саен ясак түләсәң, һичбер вакытта Мәскәү гаскәре Казан өстенә йөрмәс»,— диде... — Яуга караганда ясак түләү хушрак!

Сөембикә чәчен йолкый-йолкый илерде.

Булат бәк өере, икенче көнне диван мәҗлесе туплап, Җан Гали ханны шунда чакырды. Хан мәҗлескә җан сакчылары белән килде. Сөембикә аңа шулай кушкан иде. Ярсыган бәкләр хайванга әйтмәстәй сүзләр белән ханны битәрләде, битәрләп кенә калмаслар иде, ботарларлар иде — ярый әле, хан сакчылар уртасында булды.

Үткән эшкә салават, илчеләрне кайтарып булмый. Шуннан соң Җан Гали хан тагын да мескенләнде, бетереште. Казан тәхетендә рәхәт ял итәргә өметләнеп килгән үсмер ханны ун елга картайттылар. Элек аны Мәскәүгә файдалы эш кылса хуплыйлар иде, шул ук кешеләр хәзер аны элекке шартнамәне яңартканы өчен чак үтермәде.

Ханны үтерү ихтималияте бар. Шуңа күрә хан Сөембикә йортыннан чыкмаска тырыша. Сөембикә дә эшне төптән аңлады: ханның эшләре бик мөшкел. Чынлыкта, хан үз сакчылары урап алган төрмәдә утырырга дучар иде. Сөембикә: Җан Гали хан авыру, дип игълан ясады. Шулай атналар, айлар узды. Диван мәҗлесләре ханнан башка гына уза, мәҗлескә Булат бәк хуҗа.

Тора-бара Казан бераз тынычланды кебек. Шом узып китте. Җан Гали хан ныклы сак янында Хансарайга йөри башлады.

— Хан җәнаблары савыккан икән, шөкер! — диде Булат бәк.— Сәхрәгә чыгыш кирәк, сәхрәгә.

— Чынлап,— диде Атабай бәк.— Бүген минем углымның мөшәл елы тулган көн: унике яшь! Шул сәбәп илә мин диван мәҗлесен вә хан хәзрәтләрен куян авына дәшәм!

Җан Гали ханга җан керде. Бу тәкъдимне барча олылар күтәреп алды.

— Күптән ауга чыккан юк,— диештеләр.

Хан риза булды. Ауны олылап, шау-шулап, Казанда торган чит ил сәүдәгәрләрен, илче-килчеләрне дә чакырып, Казан елгасының аръягындагы сазламык янындагы болынга алып киттеләр. Ук-җәя аскан, яхшы атка атланган Җан Гали хан ышанычлы сакчылары янында йөрде.

Сөембикә сизде, күңеле белән сизде, ләкин:

— Барма, зинһар, сунарга барма, ханкай-җанкай! — дип әйтергә теле әйләнмәде.

Ау өч көнгә сузылды. Сөембикә җанын кая куярга белмәде. Күзенә йокы кермәде. Урык-сурык йоклаганда да саташып-бастырылып, куркыныч төшләр күреп, ватылып уяна иде. Өченче көн азагында чапкыннар хәбәр китерде: Җан Гали хан ауда һәлак булган. Хәбәр артыннан хәбәр таралды: ханны үтергәннәр, имеш. Аны Булат бәк чәнечкән икән, дип әйтүчеләр дә булды. Имеш, аны Камай мирза бавырына кадап үтергән икән, дигән сүз дә

кайтты. Ау вакытында мылтык ядрәсеннән дә, ук тиеп үлүчеләр дә булгалый, әмма Җан Гали хан уктан да түгел, ядрәдән дә түгел, хәнҗәр җәрәхәтеннән үлгән иде. Төрле сүзләр йөрде, бутап бетерделәр, буталып беттеләр. Сөембикә ауда катнашкан тугры адәмнәреннән сорашты, берәү дә төгәл әйтә алмады: күрмәгәннәр, белмиләр, алар ыстанга кайтканда хан җан тарткан булган инде. Ни өчендер ыстан янында ханның якыннары булмаган. Алары кайда йөргән? Билгесез. Мәетне беренче күрүчеләр әйтә: имеш, ыстанга чабып кайтканда ханның аты абынган да, хан иярдән егылып, үз хәнҗәре аның эченә кергән. Сөембикә сөйләүчеләрнең күзеннән күрде: барысы да ялган сөйли.

Бу фаҗига тарих туккыз йөздә кырык икенче сәнәдә, Куй Елында (1535) булды. Сөембикә ханбикә, ел ярым ир белән яшәп, кыз килеш тол калды. Ирен җирләгәннән соң, ул бик сәер халәттә яши башлады. Күп уйлады ул мәрхүм турында. Бер көрештә үк Җан Гали хан аңа ошамаган иде. Ханның җебекилеген күргәч, ошамау урынына җанбизү килде. Нишләмәк кирәк соң? Кияү миңа ошамый, дип, атаң өенә кайтып китәргә соң иде инде. Анасы Сайгөле бикә, шаярыпмы, чынлапмы, кәефе килгән чакларда җырлый торган иде:

— Кыштыр-кыштыр туныңный
Кыштырдатып киярсең;
Бәхетеңәй туры килгәч,
Карт булса да сөярсең.

Сөембикә дә, шул рәвешле, тәкъдиренә буйсынып, сабый холыклы иргә хатын булып яшәргә ниятләде. Тора-бара ул бичара Җан Гали ханчыкны баласы кебек, энесе кебек кызгана, карый башлады, аның ахмаклык дәрәҗәсендәге беркатлы кылмышларына күнегеп китте. Бигрәк ярдәмсез иде шул, мәрхүм. Сөембикә дә аңа нәфрәтле булса, кем ул сабыйны яклар, юатыр иде икән? Гомере озын булып, Сөембикә тәрбиясендә бергә яшәгәндә, ихтимал, Җан Гали хан булып та, ир булып та өлгерер иде. Әмма аның хан булып, ир булып өлгерүе берәүгә дә кирәк түгел иде шул.

Сөембикә-толбикә, йола буенча, иренең өчесен, җидесен, кырыгын үткәрде, мул итеп сәдака-хәер өләште. Иренең ел ашы узмаенча капкадан түгел, ишегеннән дә чыкмады. Елы узгач та ишегалдына, бакчага гына чыгып керә, урамда, күчәдә күренми. Хансарай китапханәсеннән, Кабан Күле буендагы Сөенбаг эшләреннән аны читләштерделәр. Шулай итеп, бу олы ике эш ярты юлда туктап калды. Сөембикә бикләнеп тыныч яши, ә Казан каласы астан кайный иде. Ниндидер эшләр эшләнә, ни кылынганын берәү дә белми, кемнәрдер төнлә чатыр чабып урамнардан уза, өере-өере белән атлылар, шомлы чабып, Сөембикә йорты алдыннан йөри. Сөембикә белән Җан Гали хан яклыларны суеш башлана икән, дигән шомлы чышын-пышыннар купкач, Сөембикә якыннары белән атасы йортына — Нугайга, Сарайчык каласына кайтып китте...

Атасы Йосыф әмир Казан хәлләреннән хәбәрле иде, кызы кайтып кергәч, дәшмәде.

Сөембикә, атасы йортында артык булмаса да, бик үк көтеп алынган да түгел икәнен аңлап, сөйләшмәс булды. Чакырулы мәҗлесләргә дә ул йөрмәде. Ахирәтләре белән көннәр буе китапханәдә утырып, ханәкәсенә йоклар өчен генә кайта... Сөембикәнең качып киткәндәй төнлә юлга чыгуы турындагы хәбәр яклаучысыз калганнар өчен бик зур шом булды. Җан Гали хан белән Ханкирмәннән, Мәскәүдән иярә килгән йөздән артык якыннары да тиз генә Казаннан чыгып качты. Алар, Булат бәк өеренең суыюннан куркып, Касыйм Ханкирмәненә дә туктамыйча, туп-туры Мәскәүгә чапты. Юкасты Итәк бәк, Шаһбаз бәк, Кармыш бәк, Яулыш бәкләр җитәкләгән бу өер Мәскәүгә Иван Васильевичка барып сыенды... Чуртаннан сибелеп качкан балык көтүедәй, Себердән, Нугайдан, Хаҗитарханнан килгән бәкләр дә төрлесе төрле якка чәчелеп бетте.

Булат бәк белән Гәүһәршад бикә, Сафа Гәрәйнең Мәскәү гаскәрен туздырганын вә бөек кенәз Василийның вафатын ишеткәч, аптырап калмады, аларга ничек булса да бер кебек иде, әмма бикә, ниһаять, каты сүзен әйтте:

— Сафа Гәрәйне тәхеткә чакырт!—диде.—Бик тиз генә ышанычлы адәмнәр Кырымга, Бакчасарайга йөрсен. Сәхип Гәрәй хан безгә Сафаны хан тәгаенләсен!

Булат бәк, бөтен Казан халкы исеменнән хат язып, Сәхип Гәрәй ханга илчеләр җибәрде.

Сөембикә киткәч, Казан ятим калды. Аның яклылар боекты. Аннан көнләшүчеләр баш калкытты. Казанның күренмәс хуҗасы Гәүһәршад бикә булса, урам-күчәләрдә, Хансарайда Булат бәк Ширин баш иде. Ул хаким, ул хөкем чыгара, ул ярлыкый, ул ясак-салым җыя. Хәзер инде маяны Мәскәүгә бирми, башкаларга да таратмый, казнага да күчерми, үзенә ала. Халык Булат бәккә нәфрәтле; әмма, нәфрәте ничаклы көчле булса, куркуы да шулкадәр булып, дәшми. Шундый шомлы халәттә яшәгәндә халыкка бер-бер вакыйга кирәк, олы фаҗигаме, зур шатлыкмы, җир тетрәүме, койрыклы йолдыз килүеме—ни дә булса кирәк, юкса, тиле бер кузгалыш, баш калкытыш булуы ихтимал... Нәкъ шул көннәрдә сүз таралды: имеш, Кырымнан Казан тәхетенә Сафа Гәрәй баһадир хан булып килә икән. Бу хәбәрне ишеткәч, Казан халкы кырык эшен кырга ташлап, Кырым юлына чыкты. Урам-күчә тулып халык агыла; олы бәкләр, яхшы дирбияле атларга атланып, затлы киемнәрен киеп, хан каршына чыккан. Бәкләр башында Булат бәк Ширин белән Сәет Боерган тора. Манарадан бактан:

— Киләлә-әр!—дип кычкыргач, җәяүле халык юлга төшеп, хан каршына йөгерә башлады.

Ләкин Сафа Гәрәй ханның җан сакчылары халыкка каршы төште. Кечкенә айбалта тоткан җәяүле сакчылар халыкны ханга якын җибәрмәскә тырыша. Халык сүрелә төште, әмма Сафа Гәрәй ханны алкышлау кимемәде.

— Мәр-хәбә-ә, Сафа хан! Машалла-а, ха-ан!—дип гүли халык.

Сафа Гәрәй хан мәһабәт иде. Кырымнан ни ара җир килеп тә, арыган кебек түгел. Ул бераз олыгайган, гәүдәгә дә калынайган. Киң җилкәле, иярдә шәм кебек төз утыра, кыйммәтле бәйрәм киеме кигән-ясанган. Елгыр атын уйнатып, хан килә! Килә түгел, кайта. Елгыр атын уйнатып, Сафа Гәрәй хан Казанга кайта! Баһадир хан кайта. Мәскәү гаскәрен тар-мар кылган батыр кайта. Гаскәр башында, ханның уң кулында икенче баһадир Кошчык углан йөри. Сафа Гәрәй хан шушы Казаннан кара төндә, кара суеш төнендә качып киткән иде. Бүген аны сөекле хан сыйфатында алкышлыйлар. Сафа Гәрәй хан чиксез горур, йөзендә—шатлык нуры. Казан бәкләре, иярдән төшеп, хан атының тезгенен тотарга тиеш булсалар да, өзәңгегә ябышып, хан ябынчасының итәген үбәргә тиеш булсалар да, бу йоланы үтәргә халык җай бирмәде—ханны урап алып, атыннан төшереп, янә кул очына күтәрделәр, бераздан Кошчак углан да халык кулында, өстә иде. Кулдан төшермичә, хан белән баш угланны урамнар буйлап Хансарайга күтәреп кайттылар. Каравыл да, айбалталы усал сакчылар да берни эшли алмады.

— Бу синең үз тәхетең, Сафа Гәрәй!—диде халык.—Йөз яшә, Сафа хан! Тәхетең дә, бәхетең дә шушында булсын!

Сафа Гәрәй хан Кошчак ишетерлек итеп кенә әйтте:

— Тәхетең дә, бәхетең дә, ләхетең дә шушы булсын, дип әйтүеме халыкның? Бәхет яулаган—тәхетле, тәхет яулаган ләхетле була. Бу ханнарның кара тәкъдире-кыйсмәте!

Сафа Гәрәй хан эргәсендә иң нык бөтерелгәне Булат бәк Ширин булды.

— Элеккеге еланлыкларын юарга тырыша!—диде Кошчак углан.

— Юк,—диде хан.—Мине тәхеткә чакырып илчеләр җибәргәненә бүләк өмет итә.

Хансарай ишеге янында җыен сыман нәрсә булып алды. Сафа Гәрәй хан Казан халкына сәлам бирде, халык аны янә гүләп алкышлады. Соңра Булат бәк ханга карап әйтте:

— Юл тузанын кагып, мунча кереп, чәйләп алгач, хан күтәрмәк мәҗлес булыр, и хан...

Сафа Гәрәй төксе генә бәкләрибәкне бүлдерде:

— Мине хан итеп бер күтәрдегез бит инде!— диде.— Үз теләгем илә тәхет ташламадым. Телем белән дә, кулым белән дә мин ханлыктан ваз кичмәдем. Сез дә мине, корылтай җыеп, бертавыштан шартнамә язып тәхеттән төшермәдегез. Бәс, элеккеге корылтайның карары куәтендә кала... Хәзер, бәкләрибәк Булат Ширин, корылтай вә ханкүтәрмәк булмас, әмма дивани мәҗлес булыр! Тиешлеләрне син, Булат бәк, өйләдән соң диванга тупла!

— Ләббәй, хан! Башым өсте!— диде бәкләрибәк.

Кырымнан килгәннәрнең барчасын да Казан бәкләре, мирзалары, бистә халкы мунчага алдырды. Сафа Гәрәй хан белән Кошчак угланны Таһир мунчасына алып киттеләр.

— Кабихҗан,— диде Сафа хан ләүкәдә утырганда.— Булат бәкне әйтәм... Кунак Атавында да мине шушы күсе каршы алды. Палитский кылычыннан чаптырырга, урыс мылтыгыннан аттырырга, Мәскәү кулы белән мине үтерергә көтеп, сөенеп каршылады. Бүген дә алай башында шушы сасык көзән. Бу юлы үзе чакырды, ни уе бар аның? Бу юлы кем кулы белән аткармакчы? Әллә соң мин дөньяда ике кабат яшимме? Бу хәлләр бер булды бит инде. Сәетләр сәете дә кочак җәеп каршы алды, кочак җәеп каршы алып, бәйләп, Мәскәүгә озатмак эстәгән иде. Бүген дә сәет алкышлый, исеме генә башка: Боерган!

— Хан!— диде Кошчак.— Булат бәк белән Боерган сәет ни өчен сине чакыртып алганын беләсеңме?.. Мәскәүне җиңгәч, Уасили үлгәч, Сафа Гәрәй ханның Казанга йөриячәге көн кебек ачык иде. Казанны көч белән алачагы да билгеле иде. Син көч белән алсаң, алар дарда җилфердәп торачак иде. Булат бәктә баш бар.

— Гәүһәршадта!— диде хан.

Сафа Гәрәй ханның уйлары хакыйкатькә якын иде. Икенче тапкыр ханлык идарәсендә дә ул, Сафа Гәрәй хан, бу ике адәмнән, Булат бәк белән Боерган сәеттән әшәкелек күрәчәген дә, күп кан коелачагын да сиземли иде. Әмма тәдбирле, куәтле, зиһенле баһадир Сафа Гәрәй хан алда карадан-кара көннәр булачагын аңламый иде әле. Казан казнасының бушавы әле төп фаҗига түгел; үзара талаш, мал бүлеш, астыртын эшләр диван бәкләрен төп максаттан, илне ныгыту сәясәтеннән аера. Илнең икътисади куәтеннән башка бер генә мәмләкәт тә хәрби куәт туплый алмый. Илнең матди байлыгын күбәйтү өчен җир биләүчеләрнең, җәйләү, урман хуҗаларының кара халыкка булган мөнәсәбәте-мөгамәләсен үзгәртеш кирәклеге турында бер генә хан да, бер генә олы бәк тә уйламады. Хан алышынган саен, харәҗ салымы арта барып, икмәк үстерүчеләр ашау хакына гына эшләүче кара колга әверелеп бара иде. Кара халыкны шәрә калдырып талау казнаны баетырга тиеш иде кебек. Әмма, салым-ясак арткан саен, дәүләт казнасы бушый бара. Дала мирзалары да, күршесенең җәйләвенә барымтага йөреп, мал куып кына дәүләт арттырып була дип, нык хаталана иде. Чыңгыз, Батый заманасындагы идарә ысуллары инде искергәнен, яраксыз бер эшкә әйләнгәнен ил агаларының күбесе аңларга теләми иде.

Борынгы ата-баба данын үзенеке санап, «безләр Чыңгыз каныннан» дип шапырынучы буынсыз ханнар, эшлексез бәкләр дошман илләрнең үз борыннары төбендә үк тимер вә утлы кораллы гаскәр тәрбия кылып, калын таш диварлы кальгалар салып, икмәк-тәгамны күп елларга җитәрлек саклап, куәтләнә барганын күрмәс дәрәҗәдә сукыр иде.

Сафа Гәрәй хан, Казанның соңгы ханнарыннан иң тәдбирлесе, әнә шушы хәлләрне аңлаучы бер бөек адәм иде. Казанның иң куркыныч дошманы — Мәскәү, дип күпләр әйтә.

— Юк,— ди Сафа Гәрәй хан.— Казанның иң куркыныч дошманы Мәскәү түгел. Казанның иң коточкыч дошманы — үзара талашып, кырышып яшәүче олы бәкләр, буынсыз ханнар. Илебез тыныч булмаганга, туганнар үзара тату булмаганга, Мәскәү безнең өскә менә. Казан өстенә кара яулар-

ны яман татарлар үзләре чакыра. Дөрес! Казан Мәскәү белән дус яшәргә тиеш. Мәскәү Казанны хөрмәт итсә генә, ике арада дуслык булыр. Мәскәү Казанны хөрмәт итсен өчен, Казан йорты икътисади яктан да, яу куәте белән дә Мәскәүгә тиң булырга лазем. Юашны басалар, усалны асалар! Мәскәү илә дус яшәп, йортыбызны ныгытырга Аллаһ тәгалә үзе куша. Без күршегә яу булмабыз, күрше безгә яу булса, кул кушырып тормабыз!

Дивани мәҗлестән таралганда олылар, бик канәгать гәп корып, эш дәрте илә өйләренә кайтты. Сафа Гәрәй хан тәхетендә калды, ул үз янына Атабай бәкне чакырды:

— Боерың, и хан!—диде Атабай бәк.

Сафа хан бу кешенең астыртын эш йөртүче, мал сөюче, кыек ятканны үз ягына аударучы бәкләрнең берсе икәнен бик яхшы белә. Мәскәүгә хан илчесе сыйфатында барып, ханга каршы өер туплаучы, чынлыкта Сафаны Василийга сатучы бәндәнең Атабай бәк икәне бөтен Казанга мәгълүм. Хан аның үзенә генә Хансарайда калырга кушкач, Атабай бәкнең коты табанына төште: хан үч алачак икән, дигән уй аның йөрәген көйдереп алды.

— Атабай бәк,—диде хан,—эшләр бихисаптыр... Әмма минем гаиләм Нугайда, кайнатам йортындадыр. Аларны монда кайтармак лаземдер. Үз егетләрең белән бу эшне син майтарсаң, шат булырмын!

Атабай бәк моны һич көтмәгән иде. Мәскәүдәге хыянәте өчен хан бүген аны астыра ала иде. Сафа Гәрәй хан Кырымнан көчле гаскәр белән килде. Бөтен капкаларда, һәр кичүдә, һәр ишек төбендә, Хансарайның һәр борылмасында күпләп-күпләп сакчы тора. Башыңны кисәм, дип әйтәсе урында, олы йомыш кушкач, Атабай тагын да ныграк каушады. Хан гозерен ишеткәч, сүзсез торды, үз урынындамы дигәндәй, башын сыйпап карады.

— Кайчан сәфәр?—диде ул.

— Хәзер үк!—диде хан.

Шулай итеп, Атабай бәк, ханның беренче хатынын, баласын вә хезмәтче колларын Казанга алып кайтырга дип, юлга чыкты... Ханның: «Үз егетләрең белән бу эшне син майтарсаң, шат булырмын»,—дигән сүзен Атабай бәк башкачарак аңлаган, ахрысы; икенче көнне Сафа Гәрәй ханга Кошчак углан әйтте:

— Атабай хатыннарын, балаларын, тагын иң якын ахирәт дусларын Котлулсын бәкне, Кадыш бәкне, бахшы Яутәкне дә чирүе белән алып киткән,—диде.

Хан әйтте:

— Димәк ки, Атабай бәкнең качуы шушы. Үзләренең кабахәтлекләрен үзләре белән алып китсеннәр.

Ханның юравы юш килде. Атабай бәкнең үз өере белән Мәскәү юлына, Иван кенәзгә сыенырга китканлеге беленде. Ханның гаиләсен әмир Йосыфның олы углы Юныс мирза Казанга илтергә алынды...

Казанга китәсе кәрван әзерләнеп беткәч, Сөембикә яңа ахирәте Мәһлекә солтанны бер җир буе озата барды.

— Бәхетле син, ахирәт,—диде Сөембикә.

— Кара бәхетле,—диде Мәһликә.

— Авызыңнан җил алсын, тефү әстәгыйфируллаһ,—диде Сөембикә.

— Хан хатыны бәхетле буламыни!—диде Мәһликә.

Сөембикә дәшмәде. Бу сүз аның үзенә аталган сыман тоелды: хан хатыны бәхетле буламыни, дип ул, бәлки, үз кыйсмәтен уйлап әйткәндер, ни уйласа да—аларның язмышы уртак иде.

Кәрванбаш олы юлга борылырга хәбәр салды; Сөембикә ахирәтләре белән, атларын туктатып, китеп баручыларга яулык болгады.

— Юныс абыкаем!—дип кычкырды Сөембикә.—Казаныма сәлам әйт. Мөхәммәдъяр остазга әманәтем җиткер!

Сафа Гәрәй ханның тәкъдир дәфтәренә шулай язылганмы... Ихтимал, шулайдыр. Узганында, сабый хан өстенә зур кара яу белән бөек Василий баскынлык ясап, күп каннар агызып, күп җаннар чыгуга сәбәп булган иде; бу юлы да, Казан йортын тәртип итәм, дип торганда гына, тәхеткә утырып,

Сафаның тән җылысы тәхет бәрхетенә сеңә башламаган көе, Мәскәү гаскәренең Казанга яу чыкканлыгы беленде. Ни кылсын яңа хан? Дошман явының Казанга килеп, камап алуын, талап китүен көтеп ятсынмы? Сафа Гәрәй хан җәһәт кенә карар кылды.

— Тиз арада яу гаскәре туплап, дошманга каршы чыгарга, Казанга якын җибәрмәскә!—дигән фәрман халыкны изге яуга күтәрде.

Бу яуны Сафа Гәрәй хан белән Кошчак углан икәвесе алып китте. Түбән Новгородка җиткәч, ике гаскәр башка-баш очрашып, каты орыш булды. Семен Гундарев белән Василий Заменский кенәзләр рәһбәрлегендәге Мәскәү гаскәре, җиңелеп, Түбән Новгород кальгасына кереп качты. Казанлыларның батырлыгы чиксез булса да, шәһәр алырлык түгел иде. Дивар, капка вату өчен тарамнар, бүрәнә дөмбеләрнең булмавы яртылаш кына җиңү китерә иде. Капкага кереп өлгермәгән урыс яугирләрен әсир итеп, Түбән Новгород тирәсендәге авылларны талап, яндырып, Сафа Гәрәй хан Казанга кайтты...

Шул орыштан соң, Мәскәү белән Казан арасында кыска сугышлар булгалады. Шуннан соң ике арада ике еллык тынычлык урнашты.

Хатынын, беренче улын Казанга кайтаргач, Сафа Гәрәй хан тагын да яныбрак эшли башлады. Өч ел күрмәгән хатыны, өч ел күрмәгән улы үз янында булгангадыр, ахрысы, ханның кәефе һәйбәт. Олы бәкләр дә, мирзалар да, Булат бәк белән Боерган сәет тә үзләре майтарган эшләрен һәм ханга, һәм халыкка күрсәтергә тырыша; боерыкларны үтәргә әзер торганлыкларын сиздерәләр. Сафа Гәрәй хан да аларның элеккеге этлекләрен онытканга салыша. Әгәренки, алар яңадан да Казан йортына хыянәт кылмасалар, ихтимал, чынлап оныткан да булыр иде: беркем дә хатадан хали түгел. Шуңа күрә, хан ул мәсьәләне кабат куертмады... Казна сандыклары такыр булса да, Сафа Гәрәй хан Сөенбагны төзү өчен күп кенә акча бүлеп бирергә булды: үз хәзинәсеннән. Казанның хәле мөшкел булса да, хан Сөембикә башлаган китапханә эшен диван мәҗлесенә китереп, кистереп куйды:

— Без, мөселманнар, сугышып кына, барымта алып кына, баскынлык хисабына гына тереклек итмибез. Без мәдәният вә истирахәт әтрафында яшәдек вә яшәргә ниятебез. Китапларын, ярлыкларын, шартнамәләрен кадерләп сакламаган халык кол булырга мәхкүм, андый халыкның тарихы көл булырга дучар. Ягъни халкың кол булса, тарихың көл булыр! Һәр бәк, һәр мирза үз җирендә гәлбакча ясарга тиеш. Үзе өчен. Һәр бәндә үз йортын гөлгә ураса, бөтен ил гөлбакча булачак...

Хуш! Тормыш шулай барса, Казан ханлыгы моңарчы күрелмәгән шөһрәткә ия булачак иде дә...

Мәскәүнең бик күп гаскәр тәртип итеп, Казан өстенә җыенганын белгәч, Сафа Гәрәй хан бәгыре өзелердәй итеп бер төкергән иде:

— Токымыңны ораен! Бу ни хәл соң, ә? Кара йөрәк! Сулыш алырга ирек бирсә икән!

Илне саклау өчен Казанның үз куәте генә җитмәячәген Мәскәү дә, башка тугандаш-канкардәш мәмләкәтләр дә бик яхшы белә. Шундый олы яуга каршы чыгарга куәтең булмагач, дошманың капка төбенә килеп, туп ата башлаганын көтеп, тәсбих тартып утырырга гына кала. Сафа Гәрәй бу чишелмәс мәсьәләнең чишелешен бер генә юл белән тапмак булды: һәр күрше дәүләт белән туганлашу, ягъни һәр күрше мәмләкәттән кыз алу. Теге кара елда Казаннан Бакчасарайга кайткач, ул Кырымның иң олы бәкләренең берсе Аргын нәселе булган Тәүран бәк кызы Латифә тутайга өйләнгән иде; Хаҗитарханның Касай углы Сабыр мирза кызы Хуркизә дә Сафа ханга өченче хатын булды, Себер ягы Шәйбани хан токымы Дәүләтъярның балдызы Җидегән бәгим дә Сафа ханга кияүгә чыкты; урыслар белән дә кодалык-туганлык форсаты чыгып, ул Рәзән каласының иң олы баяры Семен Казиевның кызын үзенә ризалаштырды. Хуш! Димәк, хәзер Казан иле гел кодалар, туганнар, дуслар белән уратылган бер бәхетле, тыныч атау булырга тиеш иде кебек. Чыннан да, Сафа ханның каенаталары аңа бик ярдәмчел булды, узган ханлык чорында Шәехмамай бәк аңа бик яхшы атлы гаскәр биргән иде. Бу юлы да ул Себердәге каенатасы Дәүләтъярдан да, Рәзән баярлары

ягыннан да, агасы Сәхип Гәрәй ханнан да, каенатасы Тәүран бидән дә гаскәр сорар һәм шул куәт илә Казан җиренә басып кергән кара яуны җиңәр, һич югында, яуны кире борылырга мәҗбүр итәр.

Шушы сәясәт вә туй, туй вә сәясәт мәшәкатьләре берлә Сафа Гәрәй вакыт узганын сизми дә калды. Вакыт узган саен, Мәскәүнең яу чыгарга дәрте арта барганын да онытып җибәргән иде. Хәбәрләргә караганда, Мәскәүнең кара яу белән Казан өстенә озакламый чыгачагы шиксез иде. Сафа Гәрәй хан әле яңа гына туйдан кайтып киткән кодаларына, каенаталарына, гаскәр сорап, чапкыннар күндерде. Хатка җавап итеп, иң әүвәл Дәүләтъяр каенатасы ун меңлек атлысын Казанга юллады. Аннан Нугайлар килеп җитте, Хаҗитарханнан да бераз атлы булды. Рәзәннән Семен Казиев кенә дәшмәде. Бакчасарай ханы Сәхип Гәрәй үзенчә гамәл кылды: ул гаскәр, корал юллый алмады, әмма Мәскәүнең яшь кенәзе Иван Васильевичка тозлап-борычлап хат язды:

«Мин, Кырым вилаятенең түрәсе Сәхип Гәрәй хан, сүзем: әгәр дә кисин минем ир туганым — Казан ханы Сафа Гәрәй илә килешеп-барышып яшәсәң, Казан аталган минем йортымны хөрмәт итсәң, вә дәхи син Казан йортыннан ясак алмасаң, халкына золым-зәхмәт кыйлмасаң, мин синең берлә дустлыкта вә үзара хөрмәттә вә сөешеп яшәргә разыймын. Әгәр дә ки, син Казан өстенә баскынлык итсәң, илчеләреңне Бакчасараемда күзем күрмәсен, чапкыннарың җиремә аяк басмасын — без синең белән кан дошман. Шулай була калса, синең атаң Уасилига зилзилә япкан кеби, Сафа Гәрәй хан белән җиреңә басып кереп, тагын туздырачакбыз».

Бу ярлыкны Дүртенче Иванга Сәхип Гәрәй ханның илчесе Дәрвиш Гали илтә китте. Бу сүзләр тәэсир иттеме, әллә башка хәтәр мәсьәләләр килеп чыктымы, Мәскәү гаскәре бу юлы Казан өстенә йөрүдән тыелып калды.

Күп тә узмастан, Мәскәү янә Казанга яу әзерли башлады. Сәхип Гәрәй хан бу юлы Баем бәк атлы илчесе аша Иванга, Казан өстенә бармавын үтенеп, янә хат юллады. Үз җәһәтендә Дүртенче Иван имзасы илә язылган хат Сәхип Гәрәй ханга килеп иреште. Бу хатында Иван Казан җиренә яу белән бармаска ант иткән иде. Шулай итеп, Сафа Гәрәй хан белән Сәхип Гәрәй ханның тырышлыгы аркасында, илче-килче, кунак-төшем алмашып, биш еллап гомер тынычлыкта узды... Шушы тыныч еллар эчендә Казанда сәүдә гөрләде, йорт ныгыды, казна тулыланды. Тәхет-Хансарай әтрафындагы гаугалар бетте, астыртын эш йөртүчеләр дә, койрыкларын кысып, шымып калды. Менә шул чакта Сафа Гәрәй ханның урыс ягыннан алган хатыны үлеп китте. Хан өчен тагын бер хатын алырга форсат ачылды. Дүртенче хатынлыкка, Сафа Гәрәй ханның үз теләге белән, тол Сөембикәне димләделәр. Яучылап барган кодалар әмир Йосыфтан да, Сөембикә ягыннан да ризасызлык күрмәде: Сөембикә өчен бу бик зур дәрәҗә-шатлык иде. Сафа Гәрәй хан өчен дә, Казан өчен дә бу никах бик кулай эш, берьюлы ике йөз мең кылычлы яу туплый алырлык әмир Йосыф кебек каенатаң булу бәләкәй эш түгел. Йосыф бәк өчен мәшһүр Казанның олы кодасы булу, китапханә эчендә әрәм булып ятучы сөекле кызының янә дә мәһабәт баһадир Сафа Гәрәй ханга яшь хатын булуы Аллаһ биргән бәхет иде. Мәскәү өчен бу никах бик тә күңелсез хәбәр булып, Казанның куәтләнеп китүен баярлар һич тә теләми иде. Бу никахка җавап итеп, Мәскәү янә яу әзерли башлады. Сафа Гәрәй хан утыз меңлек гаскәре белән Муромга йөреп китте. Шаһ Гали рәһбәрлегендәге Касыйм татарлары вә Иван юллаган урыс яугирләре белән Сафа Гәрәй гаскәре очрашты. Каты орыштан соң Сафа Гәрәй хан чигенергә мәҗбүр булды. Сафа Гәрәйнең бу җиңелүе астыртыннар өчен бик зур куаныч булып, Булат бәк, Боерган сәет баш калкытты. Мәскәүгә йөз тоткан фирка яңадан оешты һәм, яшерен хат алып, ышанычлы шымчылар Мәскәүгә, Иванга чапты. Хатта мондый сүзләр язылган иде:

«Ибраһим хан кызы Гәүһәршад бикә, Булат бәк Ширин Мәскәү тарафдарыдыр. Шаһ Гали Мәскәүдән хан сыйфатында Казанга җибәрелсә, без аны кабул кылырбыз вә Сафа Гәрәй ханны, кул-аягын богаулап, Мәскәүгә озатырбыз. Казан Мәскәү идарәсенә табигъ булыр!»

Бу астыртын эшләрнең башлануына Мәскәүдәге качкын Атабай бәк сәбәпче иде. Казанның бөтен серен, андагы фиркаләрнең мәсләген ул баярларга бәян итеп, Мәскәүгә ярап рәхәт яшәп ята иде. Атабай бәк, Гәүһәршад бикә белән Булат бәккә яшертен кеше җибәреп, Иванга хат язарга кушкан иде. Бары тик ике кеше ихтыяры белән генә язылган, рәсми булмаган бу кәгазьне, Казан халкы исеменнән дигән булып, зур гаскәр тәртип итеп, Иван Казанга озатты. Сафа Гәрәй хан үз гаскәре илә яуга каршы яу булды. Бу орышта ике яктан да күп кан акты, бихисап күп кеше кырылды. Урыслар, бик күп татарларны әсир алып, Мәскәүгә алып кайтып, мәркәзи мәйданда башларын чаптылар. Моңа үч итеп, Сәхип Гәрәй хан Мәскәүгә һөҗүм итте. Ошбу газават сугышында Сәхип Гәрәй хан Мәскәү гаскәрләрен җиңеп, күп мал алып, Бакчасарайга кайтты. Ләкин, Казан эчендә Мәскәү шымчылары артканнан-арта барып, астан гына Сафа Гәрәй ханга каршы хәтәр эш йөртү башланды. Гәүһәршад бикә фиркасе тагын Мәскәүгә хат җибәрде. Хатны Гәүһәршад бикә үзе язып, тиз генә Мәскәүгә күндерде.

«И бөекләр бөеге, Мәскәү кенәзе, дустыбыз мәрхүм Уасили углы Дүртенче Иван,— диелгән иде бу хатта.— Аллаһ тәгалә боерып, бөек Мәскәү Казанны үз химаясына алыр. Мәскәү, Казанны алгач, тагын да бөекләнер, иншалла-машалла, бирсен Ходай!»

Шуннан соң Мәскәү белән Казан арасы тәмам бозылып, алмаш-тилмәш яу чабулар күбәеп китте. Әле Мәскәүләр килеп, татар авылларын яндырып, талап китә; әле Казаннар урыс җирләрен айкап кайта. Дошманлык артканнан-арта бара. Мәскәүгә сыенган хаин татарлар да, Казандагы сатлыклар да, тәхет әтрафындагы шымчылар да бу дошманлыкны көчәйтеп, Казанны астан кайната башлады. Шул талашны күреп, Мәскәү Казанга янә һөҗүм итте.

Бу каһәрле сугыш Нократ ягыннан да, Мәскәү тарафыннан да ике гаскәр берьюлы искәртмәстән һөҗүм итү белән башланды. Казан камалышта калды. Юл өстендәге каравыллар, су кичүләрендәге сакчылар, тау башларындагы бактаннар, шымчылар кулы белән суелып, Казан дошманның ике яклап килүен сизми, күрми калды. Дошман явы капка төбенә килеп җиткәч кенә Сафа Гәрәй хан аңлады: Казанның язмышы кыл өстендә, бу яуга каршы чыгып орышырга Сафа Гәрәй хан әзер түгел. Мәскәү гаскәре Казанның агач диварларына, биналарга ут салып, Казанда коточкыч янгын чыкты. Картлар, балалар, хаста булып түшәктә ятучылар янып үлде. Утарларда атлар, маллар янды, янгыннан соң коточкыч талау, сую, коллыкка алу башланды. Мәскәү гаскәре бик күп байлык, коллар алып, кайтып китте. Хурлыклы җиңелү иде бу... Дошман явы ераклашкач, янгынны тәмам сүндергәч, мәетләрне, кисәү арасындагы янган сөякләрне барлап җирләгәч, өчесен, җидесен узгаргач, Сафа Гәрәй хан сатлыклар, хаиннар фиркасен фаш итәргә кереште. Бу эшне башкарырга ул үзе тотынды. Дошман явын Казанга уздырганны, вакытында хәбәр салмаганнарны тиз таптылар. Аларга хөкем каты булды. Бик күп мирзалар, шымчылар, каравыл башлары җәзаланды, маллары казнага күчерелде, гаиләләре Казаннан куылды. Бу эш башлануга, Боерган сәет төнлә Нугайга качты. Яман сабан җир бозар, яман мулла дин бозар дигәндәй, Боерган сәет Нугай даласында да тик ятмый. Нугайның күренекле бәкләрен Габдулла, Илзаман, Хөсрәүләрне Сафа Гәрәй ханга яу чабарга котырта. Бу бәкләрне ул, Иванга җибәреп, бергәләп Казанны яуларга өнди. Хөкемнән качып котылган Кадыш бәк, Чура бәкләр Мәскәүгә качты. Ләкин алар, качкын сыйфатында түгел, ә бәлки Мәскәүгә илче кыяфәтендә килеп, Иван янына кереп, Сафа Гәрәй ханны тотып, Иванга бирәчәкләрен әйтеп ант эчәләр. Боларның антын алганнан соң, Иван Казандагы шымчыларына һәм Гәүһәршад бикәгә яшерен хат язды. Сафаны богауларга куштыз: әгәр дә ханны богауларга курыксагыз, мин зур гаскәр юллыйм, шуның ярдәмендә ханны миңа багышларсыз, диде.

Казанда астыртын, шомлы, рәхимсез көрәш башланды. Кайный Казан каласы, кайнаталар Казанны. Казан астына учак ягылган, утны сүндерүче юк, учакка коры утын, каен тузы өстәп, май сибүчеләр бихисап.

Сөембикәнең Казанга икенче тапкыр килен булып төшүе Сафа Гәрәйнең икенче тапкыр Казан тәхетенә утыру бәйрәме белән бер дәрәҗәдә тантаналы булды. Бикәне дә Казан халкы каршы чыгып алды. Хансарайгача озата барды. Никахтан соң алар беренче тапкыр очрашты, беренче төнне бергә уздырды. Сөер төн иде бу аларның икесе өчен дә. Сафа Гәрәй — олпат ир, күп яуларда катнашкан, күп җиңү яулаган бөек баһадир, мәһабәт хан. Эш башласа — җене белән эшләр, кылыч алса — җене белән орышыр, күңел ачса — чыны белән бәйрәм ясар. Гашыйк булса — колагыннан гашыйк булып, үлеп сөя торган куәтле шәхес иде Сафа Гәрәй. Китапларга, тарихка кереп калырлык каһарман булса да, Казанны ныгытуда бихисап куәт сарыф итсә дә, мәхәббәттә ул гел сагышлы булды, эшүңмас булды. Беренче тапкырында колиһәсе Фрәнгизне үлеп сөйде, гомере буе аны оныта алмады. Сөймәде түгел Сафа, беренче хәләле Мәһликәне дә, икенчесе Латифәне дә, Хуркизәне дә, Җидегәнне дә, Мәрьям атлы урыс кызын да чит-ят итмәде ул. Шәригать кушканча, һәр никахлы хатынын тигез күрде, берсен дә рәнҗетмәде. Җәйләүгә чыкса, һәрберсенә аерым тирмә куеп, аерым коллар, сакчылар биреп, калада торганда аерым йорт салып, мул яшәтте. Яудан кайтканда да, ярминкә базарыннан, чит илләрдән кайтканда да ул хатыннарына тигез бүләк алып кайта, һәрберсенең күңелен тигез күрә; монысы аеруча сөекле хатыным, дип, калганнарын кимсетми... Ихтимал, аталык Талышбай аны шулай тәрбия кылгандыр. Фрәнгизе булмаган булса, бәлки, ул берәр хатынын артыграк күрер иде, чын мәхәббәте Фрәнгиздә киткәч, ул хатыннарына тигез карый. Соңрак Фрәнгизен мәңге оныта алмасына һәм аңа тиң башка яр таба алмасына инанган иде ул. Бәс, өйләнергә, хатыннарны рәнҗетмәскә, ирлек вазифаларын тигез үтәргә ул нык карар кылды. Хак, ул шулай яшәде дә. Һәр хатыны яшертен генә: хан мине генә сөя, дип уйлый иде. Бәлки, шул сәбәпледер — Сафаның дүрт хатыны да бәхетле, эчләрендә нур һәм җылылык балкый, барысы да мөлаем, якты чәһрәле. Бичара Мәрьям генә мәрхүмә булды. Менә, хәзер ул урын да буш түгел.

Сафа Гәрәй Сөембикәне Мәрьям өенә алып кайткан иде. Әмма Сөембикә ханга иплән кенә әйтте:

— Хан-солтан, үз йортыма урынлаштырчы, зинһар, — диде. — Мәрхүмә Мәрьямнең рухы рәнеж булмасын!

Сафа Гәрәй хан эчтән генә уфтанып куйды: Сөембикәнең үз йорты, үзе корган бакчасы барын ничек башыннан чыгарган ул? Туры шунда төшерергә иде.

Сөембикә шул көнне үк үз йортына күченде. Дүрт ел күрмәгән өе, дүрт ел күрмәгән бакчасы хуҗабикәсен түземсезлек белән көткән икән. Сафа хан, Сөембикәнең өе әзер булгач, коллар өйне элеккеге хәленә китергәч кенә килде... Биш-алты ел чамасы элек тә Сөембикә никахлы ирен куенына алырга дип шушылай тәфсилләп әзерләнгән иде. Әзерләнүе артыграк булгандыр шул, Аллаһ аны ул чакта хатын булудан мәхрүм итте...

Сафа хан озак көттермәде. Берничә никахта булган ир тол хатынга өйләнгәндә шау-шулы туй уеннары озакка сузылмый, кыз куйнына керү йолалары да булмый. Туй уеннарын Сафа хан, бәлки, озаккарак та сузган булыр иде, әмма Мәскәү яу артыннан яу җибәреп торганда, бәйрәмнәр ясап, көч-куәт сарыф итүне кирәксенмәде. Ярый, хуш, анысын барысы да аңлар. Ә менә ишек бавына килеп тотынгач, Сафа хан аптырап калды. Ул сак кына тамак кырды, җавап булмады. Катырак тамак кырды, ишек ачылмады. Ул ишекне тартты, бифайда, ишек эчтән бикле иде. Бу юлы эчтән мут, шаян тавыш ишетелде:

— Кем бар анда, кем килгән?

Сафа Гәрәй хан үзе дә сизмәстән әйтеп салды:

— Тилгән чебеш алырга килгән!

Эчтә берничә хатын-кыз берьюлы көлде. Әкрен генә ишек ачылды.

— Чебешегез тавык шул, — диде ишек ачыгындагы авыз. — Бәһасе дә авыр шул.

Хан-солтанга башка чара калмады; ул, янчыгында, кесәсендә булган бөтен акчасын, билхәнҗәрен кызга биреп, ишекне киңрәк ачтырды. Ишек

бавы тотучылар юк булды. Хан эчкәригә узды. Кемдер ишеккә кәлә төшерде. Алар Сөембикә белән икәүдән-икәү генә калды...

Сафа хан сәер бер сихри дөньяга килеп эләккәнен тойды. Нинди генә сер бар бу йортта? Хыялдагы җиһанмы бу, әллә саташумы? Бүлмәдә хуш ис. Сөембикә, ефәккә төренеп, идән уртасындагы келәмгә тезләнгән сурәттә, башын иеп утыра. Калку җирдә, сандык өстендә бугай, бердәнбер чыракъ яна. Икенче якта — киң чаршаулы әзер ятак. Эчкәридә, әллә кайда, ишетелер-ишетелмәс кенә кыл кубыз уйный. Кемдер сүзләре аңлашылмый торган җыру җырлый. Җыру түгел бу, елау, кызлар елавына охшаш моң. Сөембикә дә елый иде бугай. Сафага шулай тоелды. Ник елый бу бикәч? Унөчтәге кыз түгел, егерме икедәге тол хатын... Йола кушуынча, кияү-кәләш икәүдән-икәү генә калгач, килен никахлы ирен үзе чишендерергә тиеш. Әмма Сөембикә кузгалмады. Ул Сафа ханның эчкәригә кергәнен сизми-белми кебек. Ерак эчкәридәге җыр, кубыз авазы көчәя башлады. Сафа хан, кошагын чишеп, күлмәкчән калды. Ул Сөембикә янына чүгәләде, аннан тезләнде, бикәчнең йөзен ачты, әкрен генә үтә күренмәле ефәкне салдырды. Сөембикә башын калкытты. Ул туп-туры Сафа Гәрәйнең күз алмасына бакты. Алар шулай, тын гына, күзгә-күз берекkән килеш торды. Сөембикәнең уйлары шул иде: Ирәмбаг падишасы Шәддадмы бу, әллә Бабур падишаһмы? Хыялый Шәддад, хәяти Бабур чалымнары бар бу кешедә, ләкин бу Шәддад та, Бабур да, Хумаюн солтан да түгел, бу — алардан да мәһабәт Сафа Гәрәй хан. Менә шушы икән бит аның беренче һәм соңгы мәхәббәте — Сафа Гәрәй хан!.. Моңлы көй тагын көчәеп алды. Сафа хан Сөембикә күзенә карап шуны аңлады: менә кем Фрәңгизне алыштырыр. Юк, Сөембикә аны алыштырып кына калмас, бу хатын Фрәңгизне оныттырыр да. Сафа Гәрәй хан бәдәненә тыгыз гайрәт тулганын тойды. Әмма ул ашыкмады, кузгалмады. Бу өйдә бикәчнең үз кануннары барын Сафа хан тоемлаган иде инде. Шуңа күрә, Сафа хан шул кануннарга, шул мохиткә буйсынырга, күндәм булырга разый иде. Ярымкараңгылыкмы, ерактагы серле көйме, гаҗәеп бер илаһи тәмле исме шулай эчке теләккә моң өсти, кабаланмаска куша. Сөембикә, чыннан да, елый иде, Сафа хан ялгышмады; ләкин елау тавышы юк, мышкылдау да юк, Сөембикәнең йөзе тыныч, сабыр, ә күз бәбәкләренә мөлдерәмә яшь тулган. Болай да чем-кара керфекләре, болай да чем-кара күз алмалары ялгыз чыракъ яктысында тагын да кара булып, ук каурыедай кара булып күренә. Күз яшьләре тәгәрәп төшмәсен дип, керфек кагарга да курка бугай ул. Ләкин күз йоммау гына ярдәм итмәячәк, ул ике яшь тамчысы дөньяга чыккан инде, алар кире кереп китә алмаячак, яшьләр барыбер тамачак. Сафа хан шулай уйлаган гына иде, Сөембикәнең керфекләре кош канатыдай бер талпынды, энҗедәй түп-түгәрәк күз яше аска тәгәрәде. Ни булды Сафа ханга: ул, үзе дә сизмәстән, аң белән уйламастан, ике кулын сузды, ике күз яше дә ханның кылыч, гөрзи тотып, имәнгә әйләнгән учына тамды, уң кулының уч төбендә яшь бөртекләре кавышты, олы бер тамчы хасил булды. Терекөмеш ядрәседәй тамчы, ханның уч сызыклары буйлап ары тәгәрәде, бире тәгәрәде дә, уртада туктады. Сафа Гәрәй хан үзен тыеп тора алмас дәрәҗәгә җитте һәм ике тән буйлап баягы кайнар күз яше йөгереп китте. Сафа Гәрәй ханның кулы бармактан беләккә, беләктән күкрәккә күчкәндә Сөембикә җиңелчә генә аякланып, ефәкне биленә урады. Шәм янындагы төпсәгә куелган ике касә кымызны алып, янә хан алдына тезләнде. Сөембикә дә, Сафа да үз касәсеннән берәр йотым кымыз эчте, касәләр алмашынды, икесе дә кымызны эчеп бетерде. Шул мәлне үк кубыз тавышы да, җыручы да тынды. Кап-караңгы бүлмәдә кып-кызыл күмергә әйләнгән шәм пилтәсе тырпаеп калды. Пилтә дә тәмам сүнде. Йортны дөм караңгы басты. Сафа хан караңгыда да Сөембикәне күрә иде. Сөембикәнең кыяфәте күзгә эленеп калганмы, әллә Сафа хан сихри бер халәттәме, ни булса да булгандыр, ул Сөембикәне ап-ачык күрә иде. Ике янак бер-беренә якын килде, Сөембикәнең тәненнән җофар исе килә иде... Гомере буе юксынып эзләгән хатын менә шушы икән — Сөембикә...

Иртән алар икесе дә уяна алмады. Сафа Гәрәй ханның гомергә бер мәртәбә дә кояш чыкканчы йоклап ятканы булмады. Хатыннары янында

кунганда да ул һәрвакыт таң белән торып китә иде. Сафа Гәрәй ханның яшь хатыны янында беренче төн уздырганы, көтүләр чыгып, диван-биләр, сарай агалары күптән Хансарайда эш башлап та, ханның Сөембикә куеныннан чыга алмый ятуы турындагы хәбәр бик тиз таралды һәм җае чыккан саен сөйләнә торган бер вакыйгага әверелде. Сөембикәнең җан ахирәтләре — үзләре ир куенында йоклаганмыни — бәхетле иде. Ханны уятырга кирәклеген белсәләр дә, бу бәхетне озаккарак сузу өчен, алар ханәкәгә кермәде... Иң беренче булып хан уянды, ул кыймылдауга ханбикә дә баш калкытты. Алар тагын бер тән, ике җан булып байтак ятты. Кичтән ишек бавы хакына дөнья бәһасе хәнҗәрен түләп кергән хан үкенми. Сөембикә янына узганнан бирле ике арада бер кәлимә сүз әйтелмәгән: мин сине сөям, дип пышылдау булмаган, әмма бөтен нәрсә аңлашыла ки: Сафа Гәрәй хан Сөембикәне бөтенләе белән сөя; Сөембикә өчен Сафа Гәрәй хан — бердәнбер сөекле адәми зат... Казанның очлы күзле, без колаклы гайбәтчеләре эшнең асылын белмәде. Ике ел ир белән торып, биш ел тол яшәп, икенче тапкыр ир белән беренче төн уздыргач, түшәк җаймәсе җыяр-га җиңгиләр дә, тутайлар да кермәде, кергән булсалар бүләкне күп итеп ал-ган булырлар иде.

Хансарайга барганда олы бәкләрнең елмаеп сәлам биргәннәрен Са-фа Гәрәй хан үзенчә аңлады: әссәламе галәйкүм, хан-ата, диләр; ә тел төбендә, зәфаф төннәре хәерле уздымы, яшь хатын ничегрәк, татлы-дыр шул, татлы булмаса, болай озак йокламас идең, кебек төрттерү ята... Ханның кәефе шулкадәр яхшы иде ки, ул андый төрттерүләрне генә киче-рерлек киң күңелле иде. Ул тәнендә, теләгендә, зиһенендә уңлата куәт арт-канны сизде...

Кайный торган Казан астына каен тузы, нарат чыралары ташлаучылар күбәйде. Менә шул көннәрдә Мәскәү кенәзе Иван Казанның качкын сәете Боерган исеменә ярлык җибәрде. Сафа Гәрәй кылычыннан качып, далада ятучы бу хаинга язылган ярлыкта Илзаман, Хөсрәү, Габдулла бәкләргә дә мөрәҗәгать бар иде. Әгәр алар, бергә оешып, Казанга, Сафа Гәрәй хан өстенә гаскәр илә барса, ул, ягъни Иван, Мәскәү ягыннан йөреп, Казанны бергәләшеп җимереп, Сафа Гәрәй ханны әсир алып, Белозеро зинданына ябып куяр иде. Бу эштә Мәскәүгә сыенган Казан бәкләре Атабай, Хуҗабир-де углан, Тукыл, Бәйтулла, Үтәй, Мамай, Конырчы, Мәмәш Хафиз, Колчура, Бикчура, Борнаш, Терекугыл, Кәбәк мирзалар, Чапкын, Ислам Әбәкче, Хан-килде, Шаһчура, Колыш вә Галикәй, Агишлар да Мәскәү ягыннан Казан өстенә йөрергә атлыгып тора икән.

Казанның үз эчендә дә андый бәдбәхетләрнең аз түгеллеген Сафа Гәрәй хан белә, ләкин койрыкларын гына тота алмый. Казан эчендә Кадыш мирза белән Чура Нарык — иң хәтәрләре, алар белән идарә итүче, аларны котырту-чы Гәүһәршад бикә белән Булат бәк Ширин икәнлеге дә мәгълүм.

Казан өстенә як-яклап та, Мәскәүдән дә, эчке дошманнар да берьюлы һөҗүм итәргә карар кылынып, илнең эшләре бик мөшкел чакта Сафа Гәрәй хан өчен дә, Казанның яхшы кешеләре өчен дә зур куаныч килде: Сөембикә ир бала тапты. Олы мәхәббәтнең уртак җимеше — ир оланның тууы могҗиза белән бер бәхет иде. Сөембикә бәхет эчендә ята. Сафа хан да бәхетен һич яшерә алмый. Хатыннары аңа угыллар табып бирде. Ул ата горурлыгы ки-чергән ир, шөкер. Ләкин Сафа хан беренче угыллары туганда болай ук сөенмәгән иде: гадәтендә булмаганны, Сафа Гәрәй бу юлы яңа туган сабый-ны күрергә теләде. Ихтимал, сабыен күрергә теләве сылтау гына булгандыр, ул сөеклесен, Сөембикәне күрергә алгысый... Сөембикә сабыен имезә иде. Дөньяга килгәненә тәүлек тә юк, олан анасының имчәгенә чат ябышкан. Сөембикә, ирен күрүгә, бәбәйдән яхшы котылуын әйтергә теләгәндәй, чак кына калкынды да, сагышлы елмаеп кире ятты. Аннан баласына бакты, ан-нан янә иренә карады: күр, атасы, менә шундый тере-тырыш оланың бар! Сафа хан хатынына елмайды. Карчыклар чырае сыман җыерчык йөзле, кып-кызыл җан иясенә хан сөеп карады. Юкса, ханнар, бәкләр түгел, кара халык-та да ата кеше яңа туган баланы күрергә атлыгып тормый. Сафа хан бүген хатыныннан да, баласыннан да аерыла алмый.

Сафа Гәрәй исем кушу туе узгармак булды. Шомлы мохиттә булды ул туй. Сөембикәсенең котылу куанычы, углының сау-сәламәт тууы аркасында Сафа Гәрәй хан күп нәрсәне сизми калды, күрми калды. Туй башланырга ике сәгать кала ышанычлы кешеләре аңа җиткерде: туйга Булат бәй өеренең кешеләре җиңнәренә пычак тыгып килеп, сабыйны да, Сафаныкыларны да суярга булалар икән. Боерган сәет, каһәр, күп атлы гаскәр белән — дала яктан, Мәскәүдән — Шаһ Гали, Атабай рәһбәрлегендә качкын татарлар вә олы урыс гаскәре йөриячәклеге беленде... Мәскәү гаскәре ун-унбиш көндә килеп җитәчәк, вакыт бар әле, шуңа күрә хан туйны күчермәскә булды. Мәҗлескә күбрәк ышанычлы кешеләрне чакырып, бу өерне җиңеп, дошман явына каршы чыгарлык гаскәр тәртип итәргә була әле.

Казанның атаклы мулласы Колшәриф остаз Сафа хан углына Үтәмеш дип исем кушты: Үтәмеш Гәрәй солтан аның тулы аты булды. Алдан килешенгәнчә, Колшәриф өченче тапкыр сабый колагына «Үтәмеш» дип әйткәч тә, Сафаның ышанычлы кешеләре, корал чыгарып, сатлыкларга ташланырга, Сафа Гәрәй хан баланы алып тозактан ычкынырга тиеш иде. Әмма дошман хәйләлерәк булып чыкты; «Үтәмеш» дип беренче әйтүгә үк, мәҗлес бозылды. Яман кешеләр — фетнәбиләр, җиңнәреннән хәнҗәр чыгарып, Сафа кешеләрен суя башлады. Ул арада Кошчак угланның чаршау артына постырып куелган иллеләп егете, кулларына икешәр кылыч тотып, табын ягына чыкты. Кылычлар яшендәй тизлек илә фетнәчеләрне чаба-турый башлады. Сафа Гәрәй хан, баласын күтәреп, үзен саклаучылар белән Сөембикә йортына йөгерде.

Үтәмеш Гәрәй солтанның исем туенда, кымыз, бал, буза урынына, гөрләп мөселман каны акты. Колшәриф мулла, ике кулын сузып, суешучыларга карап илерә-кычкыра, ялвара иде:

— Мөселманна-ар! Мөселманна-ар! Аллаһтан куркыгыз! Туктагыз, Ходай хакы өчен туктагыз! Мөселман канын мөселман агызыш харам! — дип елый-елый йөгереп йөрде.

Аны берәү дә ишетми, берәү дә тыңламый иде, хәтта Аллаһ исеме дә суешучыларга тәэсир итмәде. Бу канлы туйда Кырым, Нугай егетләренең бик азы исән калды. Исәннәре дә авыр җәрәхәтле — кайсының күзе чабык, кайсының кулы киселгән. Суеш башланута, Булат бәк юк булды. Ул нәҗеснең өере дә шактый кырылды. Ихтимал, чыгып качмаса, Булат бәк үзе дә исән калмас иде. Суеш тына төшкәч, исән калган егетләре белән Кошчак ат аранкарына чапты. Сафа ханны саклаучылар Кырым — Нугай гаиләләренә хәбәр салган иде. Хатыннар, иң кирәк нәрсәләрне аннан-моннан алгалап, балаларны уятып, урамга чыкты. Атларны туй башлангачы ук иярләгәннәр иде. Сафа Гәрәй, хатыннарын, балаларын якыннарын алып, арттан куа килүчеләр белән орыша-орыша, Болгар капкасыннан чыгып качты. Кемдер Сафаны тагын Булат бәккә сатты, дошманнар алданрак кузгалды. Шул ике мизгел дошман файдасына булды... Язмыш-тәкъдир дулкыннары Сөембикәне, Сафа ханны икенче тапкыр Казан каласыннан куды. Арттан куа-гаскәр чыгачагына шик юк иде, дошманнар ат иярли. Шуңа күрә, Кошчак углан элекке юлдан китмәде, бичаралар алаен ул, әйләнеч булса да, Лаеш кичүенә борды. Лаеш кичүендә ышанычлы каравыл-нугайлар тора иде. Кичү каравылчылары качакларга кушылды. Лаеш кичүен чыгып, соң көчкә байтак чапкач кына, алар кунышка туктады. Күп чатыр корырга ярамый, куа-гаскәр килеп чыкса, сүтеп-җыярга вакыт булмаячак, хан өчен бер тирмә, балалар-хатыннар өчен икенче тирмә кордылар да, калганнар сакта калып, учак янына утырып таң аттырды.

— Ханыкаем, — диде Сөембикә. — Иң яхшысы шул булыр, атам йортына кайтсак... Бу яктан Нугайга юл туры...

Дөрес әйтә ул Сөембикә. Сарайчыкка барып, кайнатасы әмир Йосыфка ялвару: гаскәрең бир, мин Казанны кайтарыйм, дияр. Тик Боерган сәет гаскәренә тап булса, котылыш юк, бу аз кешеләр белән яуга каршы торып булмас. Бәс, алга кат-кат сакчылар куярга.

Таң беленгәндә кечкенә кәрван юлда иде инде.

Сафа Гәрәй хан китеп котылгач, Казанда фетнәнең олысы купты: таң атар-атмаста Булат бәк, качкын ханны куып җитеп, тереләй яки үләләй алып, балаларын, хатыннарын, бигрәк тә Сөембикәне качырмаска боерды. Ул җибәргән куа-гаскәр, ике тәүлек йөреп, әлсерәп, буш кул белән кайтып егылды. Булат бәк үз ялгышын шунда аңлады: качкыннар аннан акыллырак булып чыкты, алар кире якка — Лаешка киткәннәр икән. Таң аткач, кача алмый калган Нугайдан, Кырымнан, Себердән килгән угланнарны, мирзаларны суеп йөрделәр. Бичаралар, башта ялварып карадылар:

— Безнең ни гаебебез бар? Без Казан йортын саклар өчен килдек, сез чакырганга килдек, нигә безне кырасыз, ичмасам, хатыннарыбыз, гөнаһсыз сабыйларыбызны калдырыгыз,— диделәр. Юк, Булат бәкнең күзендә миһербан күренмәде:

— Чабарга!— диде бәкләрибәк.

Канлы туй махмырыннан соң Булат бәк белән Боерган сәет, дивани мәҗлесне туплап, бөтен халык исеменнән Иван Васильевичка шартнамә яздырды, шартнамәне олы бәкләрдән генә торган илчеләр белән Мәскәүгә юлладылар.

Ул шартнамәдә:

«И бөек кенәз, бөтен Русиянең олуг падишасы Дүртенче Иван галиҗанәпләре, синнән Шаһ Гали ханны Казан тәхетенә насыйб итүеңне ялварып сорыймыз!» — дип язылган иде.

Сафа Гәрәй ханның Казаннан куылуы Мәскәү өчен олы шатлык булса, Казан олыларының Шаһ Галине сораулары тагын да олырак куаныч иде. Бу ике сөенечне бәйрәм итеп, Иван Шаһ Галине Казан тәхетенә утыртып кайту өчен зур яу гаскәре җибәрде.

Бу яу һиҗрәтдин соң туккыз йөз дә илле өченче ел тарихында, җәй аенда Казанга җитте. Шаһ Гали һич каршылыксыз Казанга узды, аны Булат бәк, Боерган сәет кочак җәеп каршы алды. Шаһ Галине хан күтәргәч, Мәскәү гаскәре күп мал, хәзинә төяп, кайтып китте. Бу эш Казанның, сугышсыз гына, бик каты җиңелүе иде.

Шаһ Гали, башына күсәк белән сукканнан соң айный алмаган бәндәдәй, миңгерәү халәттә иде. Василий кенәз аны еллар буе Белозеро зинданында черетеп яткырганда, кинәт үлеп, кечек Иван аны төрмәдән азат кылып, Казан тәхетенә тәгаенләп, бу эш барып чыкмаенча, Казанга хан итеп Җан Гали куелды. Менә, гел көтмәстән, хәзер Шах Галине хан ясадылар. Шаһ Гали нәҗестән чыгып, кәүсәр суына чумды, кәүсәрдән соң янә нәҗес-тизәккә батып яшәүдән һич арына алмау сәбәпле, бөтенләй ихтыярсыз калган бер мәхлук булганлыктан, үзенең хәлен күпвакыт аңлап та бетерә алмый иде. Мескен Шаһ Гали бу үзгәрешләр кулында курчак кына икәнен сизми, әмма үзенең башкаларга охшамаганын чамалый, җәфалана, тагын да боега, мескенләнә бара. Бу юлы да — ай күрде, кояш алды дигәндәй — Мәскәү явы ярдәмендә икенче кат Казанга хан булып килгәч тә озак утыра алмады ул. Бигрәкләр дә мәхлук булып яратылган икән шул: мәхлуклар алар, ичмасам, бәхетле була, һич югында алар үзләренең бәхетсез икәнен, мәхлук икәнен аңламый, бу бәхетсез үзенең мәхлук икәнен белә. Бәхет сөенеченнәнме, әллә Казан олыларының күңелен күрер өченме, Шаһ Гали хан олы бәйрәм ясарга кушты. Бөтен Казан халкын Ханболынга алып чыгып, бер өлешен Кунак Атавына чакырып, Арча Кырына да күп чатырлар кордырып, голәмәнең күңелен үз ягына каратмак булды. Мәскәү талап киткән фәкыйрь казна хисабына уздырылган, озакка сузылган бу туйның яме-тәме булмады. Ашаучылар тәмләп ашамады, эчүчеләре дә рәхәт эчмәде, көлүчеләр дә ихластан көлмәде. Бәкләр дә иркенәеп, таралып бәйрәмләмәде сыман. Хәтта Булат бәк белән Боерган сәет тә сөенми иде кебек: алар икесе дә, өч көннән соң, мәҗлесләргә йөрүдән туктады. Мәҗлестәге бәкләр дә, бәйрәм ясаудан битәр, анда оешып, монда өчәүләп чышын-пышын килеп, алак-ялак карангалап гомер уздырды. Төннәрен бу чышыннар тагын да көчәя, кемдер атка ат-

ланып, артык ашыгып, атын куа, каядыр чабалар, каяндыр кайталар. Шаһ Гали белән очрашканда күпләре күзен читкә ала, кайсылары ханга сәерсенеп карый. Бичара хан, үзенекеләрен яшерен җыйнап, сорарга мәҗбүр булды:

— Ни булды кешеләргә? Бәйрәм азагында табын ташлап киттеләр...

Шаһ Гали ханның якыннары да үзенә охшаган иде шул: алар һични әйтә алмады, әмма мәсьәлә бик хәтәр вә катлаулы иде.

Сафа Гәрәй хан Нугай, Хаҗитархан, Кырым җирләреннән кочле гаскәр туплаган, тиз көндә Казанны камаячак икән, Шаһ Гали ханны бөтен якыннары белән астырачак икән, дигән хәбәр алынгач, аумакай бәкләр хафага төшеп, аш-суны онытып, киңәшә башлады: Сафа Гәрәй ханга каршы чыгаргамы, әллә Шаһ Гали ханны куаргамы? Төннәрен җыелып сөйләшә торгач, астыртыннар, ниһаять, уртак фикергә килде: Шаһ Гали ханны тоткын итәргә. Сафа Гәрәй хан килеп җитүгә үк, капкаларны ачарга, тәхеткә аны утыртырга, Шаһ Гали ханны бәйләп, аның кулына тапшырырга!

Бу эш нәкъ шулай башкарылды да. Шаһ Гали ханны бәйрәм табынында ук әсир кылып, үз өенә бикләп, каравыл куйдылар. Хан янына теләсә кем керә ала, әмма хан бер җиргә дә чыга алмый. Шаһ Гали хан янына кергәндә, сарай тәртипләренчә, һәр кеше кылычын, сөңгесен, ук җәясен, мылтыгын ишек янындагы сакка тапшырып калдырырга тиеш. Әмма Шаһ Гали хан өенә һәр юеш танау мирзачыклар да кылыч-хәнҗәр, кыска көпшәле утчагар асып кергән була. Мескен Шаһ Гали хан һични эшли алмый утыра...

Хатыны Фатыйма солтан кушуы белән, Шаһ Гали хан Булат бәкне чакыртып алды. Ике-өч хат язганнан соң гына бәкләрибәк килде, ләкин ул бик ашыга иде, Шаһ Гали хан сүзләренә игътибарсыз калды. Бичара хан үзе әйтә алмагач, хатыны чаршау артыннан чыкты:

— Булат бәк!—диде Фатыйма солтан.—Үзегез ялварып, сорап алдыгыз ханны. Һич ярдәмегез юк. Ханны тоткын иттегез, бу ни эшегез! Бу кылмышыгызга бөек кенәз мәрхабә димәс!

Булат бәк бу сүзгә җавап кайтаруны кирәксенмәде, ашыгып чыгып китте. Фатыйма солтан Булат бәктән соң йомыш белән кергән Казан мирзаларына өзелеп әйтте:

— Оятыгыз кайда сезнең!? Сез бит абруйлы бәк балалары! Каршыгызда Казан тәхетенең ханы утыра. Нә тәгъзим юк, нә сәлам юк. Муллагызмы шулай надан-әдәпсез иде? Хан дәрәҗәсен хөрмәткә санамасагыз, яшәгән яшен олылагыз, алдыгызда кырыкны узган мөслим торыр!—диде.

Яшь угланнар да хатынның сүзенә җавапланмады. Бу сакчылар ниндидер әмер көтә...

Чынлап та, төн урталарында урамнар, күчәләр тулып атлылар, җәяүлеләр йөри башлады. Димәк, капкаларны Сафа Гәрәйгә ачканнар. Шул ыгы-зыгы арасында Шаһ Гали хан йорты әйләнәсендәге сакчылар каядыр киттеме, әллә аларны үтерделәрме, тыны капланган Чура мирза килеп керде:

— Тиз җыеныгыз! Качарга уңай чак!

Ханбикә төенчеген алдан ук әзерләгән иде. Чура мирза Шаһ Галине әйдәкләп алып чыкты. Урам-күчәдәге ташкынга кушылып, алар Нургали капкасына җитте, анда да капка ачык иде, алар Казан елгасына таба йөгерде. Аларны көймәчеләр көтеп тора иде.

## Кызыл касә

Шулай итеп, Сафа Гәрәй хан өченче кат үз урынына, Казан тәхетенә кайтты. Бу гает киче иде. Авыз ачып, сәхәр ашап, мунчада чайканып чыккач, төн уртасында бар җиргә сак куйдырып, диван мәҗлесен чакырды.

Сафа Гәрәй кече яшьтән үк миһербанлы булып үсте. Рәхимсез, кансыз хакимнәрне сөймәде. Риваятьләр тыңлап, тарих китаплары укып, ул гаҗәпкә кала иде: кеше мәетләре өстенә корылган һәр мәмләкәт үлемгә дучар. Ни өчен түрәләр, хакимнәр шуны аңламый, һаман тарих хаталарын кабатлый. Мәгънәсезгә кан кою, кардәш башын кардәш чаптыру, диндәшне сәбәпсезгә үтерү татар тарихында аз түгел.

Яхшы булырга тырышкан түрәләрнең хәле дә мактанырлык түгел: андыйларның үзләрен, болгап-болгап, тәхеттән чөйгәннәр. Бәс, ничек-нинди ысул белән идарә кылырга? Беренче карачы Булат бәк нинди генә мәкерле эшләр йөретмәде, ил өчен нинди генә зарар кылмады; Атабай бәкнең Сафа ханга гына түгел, Казан халкына, илгә никадәр зыян-зәхмәт ташыганын хисапка алырлык түгел; Боерган сәетнең илгә, илгә генә түгел, бөтен әһле Исламга китергән зыяны өчен аны асарга, кисәргә, мәетен этләргә ташларга иде дә... Шаһ Гали мокыт ничә тапкыр кулга төште, ас-кис, токымын корыт... Илне, казнаны сатучы шушы хаиннәрне ничек җир күтәрә дә, ни өчен алар җәзасыз кала, ни өчен халык дәшми? Югыйсә, беләләр бит, күрәләр бит кем илне, кем динне тарката. Теге юлы, киң күңелле булам дип, Сафа хан Шаһ Гали мөртәтне һич җәзасыз иреккә җибәрде. Атабай мордарны дарга элеп куясы урында, олы эш йөкләп, Нугайга юллап, Мәскәүгә качырды. Сафа хан алар кулына төшсә, ни кылырлар иде икән? Җибәрерләр иде микән? Каршы торса, шундук үтерерләр, карусыз булса, бәйләп Мәскәүгә озатырлар иде. Мәскәү аны нишләтер иде? Кулына төшкән ханнарны ни кыйлса — шуны ук кыйлыр иде. Чукынганнарны исән калдырып, чукынырга теләмәгәннәрне Мәскәүнең Мәркәзи Мәйданында, бәйрәм ясап, халык җыеп, тамаша ясап, башларын чаптыра Мәскәү. Илһам ханны төрмәдә черетеләр-черетеләр дә үтерделәр. Габдел Латыйф ханны зинданда черетеп, ирекка чыгарган булып, ауда үтерделәр. Мәскәүнең кулы озын, Казанга да җитә. Мәскәүдән торып, ничә ханны теге дөньяга озатты ул куллар. Шымчылар, җасуслар, сатлыкҗаннар тарафыннан Мәскәүгә баш орырга теләмәгән ханнар үтерелде. Олы Мөхәммәт ханның үлеме Бөкере кенәз Василийга баглы. Мәхмүт ханның кинәт вафаты да сәер һәм очраклы гына түгел. Мөхәммәт Әмин ханны үзенекеләр агуламагандыр бит инде! Әҗем ханның көндәше дә, туганы да, тәхеткә күз елтыратучы ир баласы да юк иде. Аның ашына зәһәрне Мәскәүгә хезмәт итүче хаиннар салганы сабыйга да мәгълүм... Бәс, диде Сафа Гәрәй хан, җебемәскә кирәк, хаиннарга кансыз булыш лазем, дусларга миһербан сакларга бурычлымын.

Сафа Гәрәй Казаннан качып китүгә, бөтен мөселман илләре Казаннан йөз чөергән иде: кунакка йөрешмәс, базарга сәүдәгәрләр җибәрмәс булып, Казанның эшләре яманнан да яманракка әйләнде. Халык үз малын кирәкяракка, тимергә алыштыра алмый, сәүдә тукталган, базардан керем юк. Кичүләр, күперләрдән файда юк — кәрваннар йөрми. Казан ханлыгы бичара икътисади аблукада, ягъни хәерчелек, керемсезлек камалышында калган иде. Шуңа күрә хан бөтен сәясәт эшләрен — шәһәрне ныгыту, гаскәр тоту мәшәкатьләрен үз өстенә алды. Астыртын эш йөртүчеләрне фаш итү фәгалиятен Кошчак угланга тапшырды. Шәһәрне матурлау, гөлбакча ясау вә китапханә эшләрен сөекле хатыны Сөембикәгә йөкләде. Дөресрәге, Сөембикә бу эшләрне үзе сорап алды.

Сөембикәнең иң бәхетле көннәре иде бу. Аның күңел күгендә Каракош түгел, Хумай кошы — бәхет бөркете очып йөри: ул — ханбикә, аның үз Шәддады — Сафа Гәрәй бар, ул хыялындагы Ирәмбагны үзе төзи. Казан халкы ул бакчаны күптән «Сөенбаг» дип йөртә икән. Ләкин Сөембикә ул бакчага «Баги Сафа», ягъни «Сафа бакчасы» дип исем кушты. Хансарай китапханәсен дә «Сөембикә көтепханәсе» дип исемләгәннәр.

Карванчыларга, Һиндстанга, Кытайга йөрүчеләргә ул күп итеп тутый кошлар алып кайтырга, сайрар кошлар сатып алырга кушты. Шулай итеп, Сөенбаг эчендә моңарчы бу якларда күренмәгән сәер-матур кошлар пәйда булды. Сөенбаг чирәмнәрендә таҗлы торналар, ап-ак челәннәр, салават күпере кебек аллы-гөлле койрыклы тавислар мәгърур атлап йөри, йөз төрле тутый кошлар агач ботакларында кукраеп утыра. Арыкларда әллә ничә төрле алтын балыклар йөзә, бихисап матур кошлар сайрый. Сөенбагның даны тиз таралды. Гүзәл бакчаны карарга дип Казан халкы гына түгел, авыл халкы да килә. Еракттан йөргән кәрванчылар да, илчеләр дә, Сөенбагны багар өчен генә юлга чыккан мосафирлар да анда тулып ята. Бакчага керү шартлары язып капкага кадакланган: Сөенбагта сөйләшмәскә, яман уй уйламаска, чәчәкләр, гөлләрне өзмәскә, кош-кортларны куркытмаска, сукмаклар

буйлап йөгермәскә, арык-кулләргә чүп ташламаска киңәшебез. Колаклары-гыз кош сайравыннан, күзләрегез чәчәк вә кош матурлыгыннан, борыныгыз хуш ислардән тыныч ләззәт алсын, тәнегезгә сихәт булып ятсын! Амин!

Бакча үстерергә каршы булган, казнадан акча бирмәскә кыр талашкан бәкләр дә бөтен гаиләсен, туган-тумачасын ияртеп, һәр җомга, өйләдән соң Сөенбагка килә. Ханбикә андыйларга: әһә, сез менә шушы бакчаны булдыр-маска тырыштыгыз, үзегез истирахәт кылырга гелән шушы бакчага йөрисез, дип әйтмәде, онытканга са.ышты; ул килгәннәрнең бөтенесен дә ачык йөз илә каршы ала, бакчага алып керә, пышылдап кына кайсы гөлнең, кайсы кошның кайсы илдән кайтартылганын сөйли.

Беркөнне Сафа Гәрәй хан Сөембикәгә әйтте:

— Карыйчыгым,— диде.— Сөенбагта рәһбәрлек кылу ханбикә эше түгелдер... Кайсы гөлнең кайдан кайтканлыгы хакында ахирәтләрең сөйләсен...

Сөембикә иренә чәй ясый иде, касәне биргәндә ул ханга бакты, хан күзендә усаллык юк иде, димәк, бу сүзләрне ул тыяр өчен түгел, киңәш бу-ларак әйткән. Бикә, сизелер-сизелмәс кенә баш иеп, иренә касәне тапшыр-ды да әйтте:

— Син — тәхетеңдә хаким, мин — бакчамда!

Шуннан соң матур җәй көннәрендә чит ил кунакларын алар бакчада икәүләп кабул итә башлады. Гаҗәеп гүзәл мизгелләр иде ул көннәр: Сөен-багтан канәгатьсез чыккан адәм булмады.

Еллар авыр килде Казан халкына. Сугыш артыннан сугыш чыгып тал-кынса да, халык сугыш тынган арада һаман бөкрәеп җир сөрә, мал үрчетә. Сафа Гәрәй хан казнаны ныгытырга тырыша. Җан Гали, Шаһ Гали ханнар заманасында салымнар икеләтә артып, алынган харәҗнең иң күп өлеше Мәскәүгә озатыла торган. Сафа Гәрәй хан тәхеткә килде дә, салымнарны киметте, дип булмый. Әмма, Сафа хан килгәч, харәҗ малын сарай күселәре үз өннәренә ташудан туктады: барысы да дәүләт казнасына туплана. Җыел-ган ашлык, сәрмая булып, ачлык-мур-яу вакыты өчен амбарларга, келәтләргә салына. Бәкләрнең, мирзаларның керемнәре кысылды, чыгымна-ры артты. Акыллыраклар бу мәҗбүриятне аңлый, ризасыз түгел, бик теләп булмаса да, мәмләкәт куәтен арттырырга үз чамасы белән өлеш кертә. Го-мер буе халыкны, казнаны талап яшәгән бәкләр Сафа ханның бу эшләренә «ярхәмәкалла» дип тормый, аяк чала, буынсызракларны ханга каршы котыр-та, баз казый. Иң олы бәк Булат Ширин белән дин әһеле сәет Боерганнар шулай комсыз булгач, үз үче өчен илсатар булгач, Казан мәмләкәте кая бар-сын? Эче тулы хаин бәкләр белән илне карадошманнардан, диндошманнар-дан яклап буламы? Халык каһарманнарын үз куллары белән чапкан шушы мордарлардан нинди миһербан, нинди фидакарьлек көтәсең. Казанның яхшы кешеләре белән чагыштырганда, хаиннар саны күп түгел, әмма алар өстә, хакимият шул сатлыклар кулында, алар мәкер иясе, алар астыртын эш йөртә, шуңа күрә алар хуҗа халыкка.

Кошчак углан үз эшен коры тотты. Электә гаепләре билгеле булган сат-лык бәкләрне ул, берәм-берәм фаш итеп, зинданга яба башлады. Кулга алынган Бәһү бәк, Кадыш бәк, Чуракай бәкләргә үлем җәзасы чыгарылып, аларны таңда асарга, дип торганда Чуракай бөтен нәселе, ыруы белән Мәскәүгә качып киткән. Чуранлыкылар белән ата хаиннар, бер тимер алка кулмәккә — бөтен илне, бер утчагарга бөтен әһле Исламны сатып җибәрергә әзер бәкләр, йорт ташлап, тамыры белән Мәскәү ягына киткән. Кулга алы-насы шул төндә Боерган сәет тагын далага качкан. Шулай итеп, ике меңнән артык җан, Казанны ташлап, дошман ягына күчте.

Тотылган хаиннарга хөкем кырыс булды:

— Йортны саткан мөртәтләр, динне саткан денсезләр, малны озаткан җаһилләргә үлем җәзасы!

Зинданнардан алып чыгып, җинаятьчеләрне халык алдында асып, бәгъзеләренең башларын чабып, хәрам белән җыйналган мал-мөлкәтләрен дәүләт казнасына алдылар. Бу канлы фәгалиять башкаларга сабак булсын, дигән максаттан эшләнде һәм тәэсире бик каты иде.

Әмма хуҗасы кулыннан сөяк көткән эт өере кебек яшәүче качкын татарлар Мәскәүдә Казан өчен корткыч эшләр башкара. Мәскәү баярларына Казанның бөтен серен сата, башкаларны да Сафа Гәрәй ханга каршы котырта, фетнә әзерли иде. Каргап каргыш төшмәстәй, янап нәфрәт төкәнмәстәй бу хаиннар, әхлакның аргы ягына чыгып, адәми зат, мөслим икәннәрен онытырдай сәрхүшкә әверелгән бәндәләр өере иде. Бу өер башында Атабай бәк. Борнашлар торып, рәһбәрлек кыла. Шушы өер Тау ягы чирмешләренә илчелек булып йөреп, Иваннан олы бүләкләр алып барып:

— Иван патша, Казанны җиңсә, сездән мөстәкыйль дәүләт ясаячак. Әгәр дә сез Мәскәү ягыннан Казанга каршы орышсагыз, Иван сезне алтынга күмәчәк. Риза булмасагыз, Мәскәү гаскәре Казанга түгел, сезгә йөрер. Аерылыгыз Сафа Гәрәйдән, аерылсагыз, Иван сездән ясак алмаячак!— дип котырталар һәм Тау ягы чирмешләре Мәскәү ягыннан Казанга яу булып барырга ант итә.

Чирмеш гаскәре белән бергә йөргәндә Казанны тәмам җимерәчәгенә Иван бик нык инанган иде; бу турыда ул хәтта боярлары алдында кычкырып әйтте.

Шулай итеп, Иван Дүртенче янә Казанга баскынлык явына чыкты... Ләкин Аллаһ Иванга түгел, Сафа Гәрәй ханга рәхимле булды, шөкер. Аллаһ тәгалә кодрәте илә, мөселманнарның җанын-тәнен саклар өчендер, бу җәй бик коры килде. Сулыклар кибеп бетте, елгаларда су кимеде. Яуга чыккан көймәләр елга төбенә утырды. Кояш кыздырып, көймәләр кибеп, кайсылары ярылып бетте. Бик күп җәзалар, үлемнәр вә югалтулар илә Мәскәү-чирмеш гаскәре чигенергә мәҗбүр булды. Сугышсыз гына җиңелеп, Иван Мәскәүгә кайтып егылды... Бу мәсхәрәдән соң Иван патша суынырга, уйланырга тиеш иде, һич югында бер-ике ел хәл алырга кирәк иде, әмма Иванның кире холкы алай эшли алмаячак иде шул. Тешләргә теләсә, тешләп үч алырга өйрәнеп үскән усал Иван иде ул: тешләсә өзәргә өйрәнгән Иван иде; тешли алмаса, җиңә алмаса, үз бармагын чәйнәп елый торган Иван, көче җитмәсә дә тырнаша торган Иван, үзенекен итмәсә, астан үч ала торган Иван иде ул. Сайга утырып хур булганына ул, әллә кемнәрне гаепләп, үлем җәзасы бирде. Әйтерсең лә яңгыр яумаганга алар — көймәчеләр гаепле. Ярты ел узар-узмастан, Иван кыш уртасында гаскәр тупларга боерды. Аңа әйтеп карадылар: кыш өсте яу өчен яраксыз, диделәр, язны көтик, диделәр. Юк, холыксыз Иван үзенекен итте.

Һиҗрәтдин соң туккыз йөз дә илле биштә (1548), Мәймүн елында Иван тагын да күбрәк гаскәр, бик күп туплар вә утчагар мылтыклар илә Казанга баскынлык явы белән кузгалып китте.

Элек Казан юлы өстендә чирмеш җәячеләре торып, урыс явына бик күп зыян эшли, урман эченнән чыгып, ук атып, туп тартучы атларны, сугышчыларны үтереп, Мәскәү гаскәренә бик күп комачау кыла иде. Бу юлы чирмешләр, урыска кушылып, Казанга яу булып йөри. Шул сәбәпле Мәскәү гаскәре тоткарлыксыз бик тиз Казанга җитте. Ләкин, Иделне кичкәндә кинәт көн сындырып, җепшек кар ява башлады. Җепшек кар яңгырга әйләнеп, кыш уртасында коеп яңгыр яварга тотынды. Боз өстенә су чыгып, яңгыр коеп, боз түшәк кебек көпшәкләнде. Иванга яки чигенергә, яки, Иделне кичмичә генә, көн суытканны көтәргә кирәк иде. Аңа шулай киңәш иттеләр дә, ләкин кире Иван боз өстендәге су аша Иделне кичәргә боерды. Гаскәрнең бер башы Идел уртасына җиткәч боз шартлап ярылды да, күз алдында бик күп туплар, атлар, кешеләр боз астына китте. Яр башында, боз өстендә исән калган атларның каешлары, туп тарттыра торган баулары җебеп, озаеп, камыт баулары, тәртә баулары өзелеп, гаскәр эчендә каушау, өметсезлек таралды. Киез итекләр, чабата кигәннәр, бил тиңентен бозлы суда йөреп, үпкәләре шешеп чирли башлады. Иделне кичү турында уйларга да мөмкин түгел иде. Иван чарасыз калды; ул бармакларын чәйни-чәйни, үзен-үзе кыйный-кыйный үкереп елый, гаепле санаганнарны шундук аттыра иде.

Мәскәү явының Идел кичәчәген белгәч, Сафа Гәрәй гаскәр җибәрде. Ул гаскәр Иванның Идел кичкәнен сагалап торды. Боз ярылганчы чыгып

калганнарны әсир алып, Сафа Гәрәй Казанга юллады. Иван, гаскәрен алып, кирегә борылды. Чигенеп кайтканда да ул бик күп сугышчысын югалтты. Мең бәлаләр белән эшунмас патша Түбән Новгородка кайтып егылды.

Иван икенче тапкыр мәсхәрәле җиңелде, сугышсыз-орышсыз җиңелүне кичерә алмыйча, үкереп төннәр узгарды. Казанны алу, татарларны изү теләге аның күзен дә, аңын да томалаган иде. Ул һичкемнең киңәшен тыңламый, тыңласа да ишетми:

— Туплар! Атлар! Гаскәр! — дип бертуктаусыз тәкърарлый. — Бер ай эчендә йөз меңлек гаскәр, җитәрлек дары, мылтык, ике йөз туп әзер булсын!

Шашкан патша Иванга бирәү дә каршы килмәде: баярлар тавышсыз гына яңа яу әзерли башлады. Бер ай булды дигәндә гаскәр әзер иде. Бу юлы Иван, үзе Казанга йөрмичә, гаскәрен Дмитрий Бельский, Шаһ Гали рәһбәрлегенә тапшырып, Мәскәүдә калды.

Шулай итеп, шул ук елның кышкы чиләсендә Мәскәүдән Казанга бик зур кара яу китте. Яу якынайганын белгәч, дошманны Казанга якын җибәрмәү нияте илә, Сафа Гәрәй хан үз гаскәре белән кара яуга каршы чыкты. Казан явын күргәч, Бельский белән Шаһ Гали, куркып, Мәскәүгә кайтып китте. Бу җиңелү дә Иванны ярсытты, ул җиңелгән саен усаллана гына бара иде. Акыллы баярлар, динчеләр Иванны Казан өстенә йөрмәскә үгетләп карадылар. Шуннан соң Иван бераз сабырлана төшкән кебек булды. Ләкин ул Казанны җимерү, мөселманнарны тәмам кырып бетерү уеннан кайтмады. Бу максатка ирешү өчен мондый яулар гына җитмәсен ул, ниһаять, аңлады. Иван башка юл сайлады. Әгәр дә Шаһ Гали кебек күндәм бәндә Казан ханы булса, бар да бик һәйбәт килеп чыгар иде: Шаһ Гали үз исәнлеге, үз рәхәте өчен Казан илен генә түгел, мөмкинлек чыкса, бөтен Ислам мәмләкәтләрен кычкыртып аңа сатар иде. Сафа Гәрәй хан тәхеттә булганда Казан беркайчан да Мәскәүгә буйсынмаячак. Сафа — Казанның соңгы ханнары арасында иң усалы, иң батыры, каты рухлысы. Сафа хан барында Казанны алып булмасын Иван уйлый-уйлый төшенде.

Сафа Гәрәй хан үзенә-үзе гаҗәпләнә: үзгәрде ул Сөембикәгә өйләнгәч, аның кырыслыгы кимеде. Сөембикә угыл тапкач, ханның күңеле нечкәрде сыман. Угыллары Мөбарәк белән Бүләкне ул чит күрмәде, үз итте, сирәк кенә булса да, тезенә утыртып сөйгәләде. Шуны ул «балаларымны сөям», дип уйлый иде. Матур-батыр булып үсеп килүче оланнарына карап, ул куана да: алмаш үсә, тәхет варислары өлгерә. Мөбарәк, анасыннан ятим калгангамы, юашрак үсә, Бүләк углы чая, үткен, хөкемдар булырга ярата. Мөбарәкне юашлыгына күрә, Бүләкне чаялыгы өчен сөя бугай ул. Әмма Үтәмеш углына булган мөнәсәбәт бөтенләй үзгә шул. Туган көненнән алып, ул Үтәмешне үтә якын күрде.

...Ул төнне Булат бәк Ширин йортына әллә нинди шикле мосафирлар килде; алар, Булат бәк янында озак тормыйча, килгәндәге кебек, ашыгып китеп тә барды. Кемнәр булды ул шомлы шәүләләр: читтәнме, Казан кешеләреме? Читтән булса, ничек итеп алар каравыллы-бикле капкалар аша үтеп керә алган? Казан кешеләре булса, ни өчен алар бик шикле, алак-ялак каранды, үзләрен танытмаска теләгәндәй тоелды.

Сафа Гәрәй ханның Зөннар атлы колы бар иде. Шушы Зөннар тарих туккыз йөз дә утыз алтыда (1530), Юлбарыс Елында булган Казан сугышында әсир төшкән урыс егете булып, җәрәхәтле бу егетне Сафа Гәрәй хан исән калдырган иде. Таза-елгыр бу егетнең җәрәхәте тирән түгел, ә таза куллар, яшь коллар Казанга бик тә кирәк булганлыктан, әсирнең ярасына май сөртеп бәйләделәр. Ярасын бәйләгәндә егет татарчалап:

— Мин тырыш... Мин Ислам сүәмән... — диде.

Егет сәламәт кулы белән муенындагы тимер тәрене өзеп, җиргә ташлады.

— Тефү, хач! — диде әсир.

Аның янында утыручы башка тоткын урыслар, үзләренчә сүгенеп, егеткә усал карап:

— Креста на тобе нету! Холоп татарвинский! — диделәр.

Бер-ике урыс, йодрык төйнәп, әлеге торкын егеткә ташланган иде; татар сакчылары, аларның башына гөрзи белән төртеп, урыннарына утырттылар.

Колшәриф мулла әсир егеткә Зөннар дип ат кушты. Зөннар үз аягы белән бабачыга барып, үзен сөннәтләтте. Ул тулысы белән Ислам кабул итеп, мөселманча яши башлады. Әллә ничек, ягымлы иде ул әсир егет Зөннар. Игътибарны гел үзенә тартып тора. Эштә дә бик җитез, урыс димәссең, теле дә йөгерек, көн саен тәһарәт алып, мәсҗеткә намаз укырга йөри. Гаҗәеп ярашлык кол булып чыкты ул. Мөселман мөселманга кол булмас дип, рас Зөннар Исламга күчкән икән, кол булудан туктый, дип, Зөннар өстеннән «кол» кушаматын да алдылар. Ата-анасы ачлыктан үлеп, ятим үскән бала икән бичара... Яшәве кайда да бер. Каравылда йоклап киткән өчен аны үлемгә хөкем иткәннәр, бу гаебен юар өчен ул орышта батырлык илә сугышырга тиеш булган, әмма тагын аның гаебе аркасында ике кенәз-воеводаны татарлар арттан килеп үтергән, бу мужиклар да аның аркасында әсир төшкән. Урыс ыстанына кире кайтса, аны ике тапкыр асачаклар. Бәс, ул бик рәхәтләнеп Исламны кабул итә дә, бик куанып, Казанга хезмәт кыла.

Тора-бара бу чая егет Сафа Гәрәй ханның хезмәтчесе булып китте. Зөннар башта араннар тирәсендә уралды. Ат караучылар ни кушса, шуларны үтәп, ышаныч казанды. Ара-тирә Зөннарга олырак эшләр дә йөкли башладылар: аны Ханмәсҗетнең капкачысы итеп куйдылар. Бу эшне дә ул җиренә җиткезеп эшләде. Колшәриф остаз Зөннарны Ханмәсҗет йомышчысы итте. Ата-анадан мөселман туган шәкертләрнең укуы зарланырлык түгел: зиһенле балалар, әмма урыстан мөслим булган Зөннар искитәрлек һәвәслек илә Коръән ятлый, мәгънәсенә төшенмичә, гаҗәеп матур-моңлы мәкам илә сүрәләр укырга өйрәнде. Колшәриф остаз тагын бер нәрсә сизде: Зөннар башкалар кебек мие тинтерәгәнче Коръән ятламый, аятьләр, сүрәләрнең мәгънәсен эзли, остазын аптырашта калдырып, кайбер гыйбарәләрне үзенчә шәрехләргә маташа, башка мәгънә таба иде.

Сафа Гәрәй бу әсир егетнең үсешен күзәтә, әледән-әле тикшерә торды, һәм ул, Зөннарның кыюлыгын орышта күрер өчен, аны Муром явына алды. Зөннар Сафа Гәрәй ханның уң кулында орышты. Мәскәү ягыннан орышучы Шаһ Гали гаскәренә каршы җен урынына сугышучы кешеләрнең берсе Зөннар булды. Тоткан кылычы Зөннарның үз кулына берегеп үскән кебек елгыр һәм туры чаба икән. Байтак дошманны кырып, Зөннар үзе җәрәхәтсез калды. Хан Зөннардан бик канәгать иде. Бу җәсүрлеге өчен Сафа хан аңа үз кылычларының берсен бүләк итте. Кяфердән мөселман булган бу әсир урта кальга эчендә, Хансарайга якын хөҗрәләрнең берсендә яши башлады... Дөньялар болганып, Сафа Гәрәй Казанны ташлап качканда, Зөннәр бар булган мөлкәтен төйнәп тугры кылычын тотып, хан янына килде:

— Ханкай!— диде ул.— Мин синнән калмыйм!

— Без рәхәт сәфәренә чыкмыйбыз!— диде хан.— Һиҗрәт юлына дучарбыз...

Зөннар әйтте:

— Монда калсам, мине үтерәчәкләр. Шаһ Гали ханга яки Иванга бәйләп озатачаклар. Ал мине үзең белән, тугры колың булырмын!— дип, хан аягына егылды.

Зөннарга йөгерек ат бирделәр, алар ашыгыч качып китте. Шул көннән соң Зөннарның ханыннан аерылганы булмады, чынында ул Сафага гомере буе тугры кол булды. Кырымнан Мәскәү өстенә яу булып барганда да Сафа Гәрәй хан Зөннарны үзеннән калдырмады. Ханның җан сакчысы Кошчак углан булса, тән сакчысы Зөннар иде. Хан нинди кыен күрсә, Зөннар да шуны карусыз күтәрде. Юл йөргәндә олылар ни сөйләсә, ни маҗарага тап булсалар, Зөннар шуны яза йөрде. Ул Сафа ханның елъязмачысына әверелде. Казан тәхетеннән икенче тапкыр куылганда да Зөннар ханнан аерылмады. Һиҗрәт сәфәренең бөтен әчесен-төчесен алар бергә татыды. Инде менә өченче кат тәхет яулагач, Казанда тәртип урнашкач, Сафа Гәрәй хан Зөннарны «мирза» дип атый башлады. Зөннар мирзага аерым йорт бирделәр. Инде Зөннарга өйләнергә дә рөхсәт ителде. Аңа ятимә кызны димләделәр. Кыз-

ның атасы Сәях мирза кяфер кулыннан шәһит китеп, анасы үз йортында янып үлгән иде. Зөннар мирза Сәях мирза кызы Җәмлиханы алып таза тормыш корып җибәрде. Дөнья түгәрәкләнде. Зөннар үзенең сөекле хезмәтенә тотынды, ул Сафа Гәрәй ханга атап «Тәхетнамә» дигән китап яза башлады.

Сафа Гәрәй хан, Мәскәү гаскәрен куып җибәргәннән соң, Казанга кайтып, яу киемнәрен салып, гадәтенчә, мунчага китте. Аның уйлары еракта иде. Иншаллаһ, мунча кереп, йоклап алгач, иртәгә иртүк диван җыйнармын, дип уйлады ул. Диван бәкләре алдында: Казан тирәли янә бер диван-кальга корыш лазем. Бу дивар Ханболынны, Арча кырын, ике Кабан күлен уртада калдырып, Казан елгасы һәм Идел ярына тоташып, Кавал җирен эчкә алып узарга тиеш, дигән мәсьәлә куелачак. Ул дивар-кальганы корыргамы, юкмы?—дип сорамаячак хан, шул кальганы корыр өчен чыгымнар кирәк!—дип, мәсьәләне кабыргасы белән куячак.

Сафа хан, тыныч чакта, һәр атнаны хатыннарының берсе белән мунчага йөри торган иде. Яудан кайткач, ул һәрчак яугирләр белән мунчага бара. Бу юлы да уң кул вә сул кул батырлары белән мунчага китте. Зөннар мирза да мунчага чакырулы иде. Хан Таһир мунчасында юынганда Казан Елгасы яры буйлый, Нургали капкасына, манараларга икеләтә каты сак куела. Каравылда ышанычлы сакчылар торганын ныклап барлап, өсте-өстенә кисәтмәләр биргәч кенә, Кошчак углан мунчага кереп китте. Барысы да җыелган, Зөннар мирза гына юк иде.

Зөннар мирзаны Булат бәк тоткарлады. Дөресрәге, Зөннар мирза Булат бәкне көтеп соңга калды. Ниһаять, алар сазлык чаукалыгында очрашты. Аларның сүзе кыска булды: шул бер-ике сүз арасында Булат бәк Зөннарның учына нидер салды.

— Ялгышма, кызыл касәгә сал!—диде бәк.

Зөннар мирза Таһир мунчасына килеп кергәндә хан да, бәкләр дә, угланнар да ләүкәдә ята иде, кайсылары ләүкә баскычында утырып тора.

— Зөннар мирза, бикәсе куеныннан чыгып, госел тәһарәте алырга килде!—диде кемдер.

Кызык булды, дәррәү көлделәр.

— Кымыз урынына хәтәр буза алып йөрдем бузачыдан,—диде Зөннар мирза.—Чабынып чыккач, сыйлармын үзегезне.

Зөннар мирза ләүкәгә утырды. Керләнгән, арган тәннәр рәхәт чигә. Уңышлы яудан соң якыннарың белән мунча керү, буза-кымыз эчүдән дә рәхәт нәрсә юктыр, дип уйлый һәрберсе.

— Нугайда да бар мунча, Кырымда да бар мунча,—диде Кошчак углан.—Әмма дә Казан мунчасына җитми, яудашлар...

Тагын чабынып, тагын коенып алгач, Зөннар мирза аларны салкынча бүлмәгә, сусын басарга чакырды.

— Ихтыярыгыз, олуг яугирләр!—диде Зөннар мирза.—Бу тулыкта кымыз—яңа туган. Бу турсыкта тагын кымыз—сазаганы. Бу тәпәндә бал булыр—әчегәне. Бу тырыста бузадыр—татырлысы. Кайсысын татырсыз?

— Барысын да!—диде Кошчак углан.

— Салкын булса, миңа—бал!—диде хан.

Яугирләр, теләгәнен татып, ак җәймәгә кырын ятты.

Хан бушаган кызыл касәсен Зөннарга сузды:

— Балы тәмле!—диде.

— Куәтле дә,—диде Зөннар һәм тагын бер касә каплап куйды. Шул ук тәпәннән шул ук кызыл касәгә бал коеп, ханга сузды.—Алың, ханым!—диде.

Хан балны эчеп, мыегын сөртте дә, касәне Зөннарга бирде:

— Тагын эссе сал, колак пешәрдәй булсын!—диде.

Ханның шау эссегә иң алдан керә торган гадәте булганга, яугирләр кырын ята калды, хан эчкә үтте. Зөннар янә ике касәгә бал агызып:

— Монысы ләүкәдә эчәргә!—дип, хан янына керде.

Яугирләр эссе бүлмәгә кергәндә Сафа Гәрәй, бик каты чабынганнан соң, ләүкәгә утырган килеш, кызыл касәдән бал эчеп утыра иде. Соңгы йотымнан соң ул буш касәне Зөннар мирзага сузды. Зөннар, касә төбендә

калган бал тамчыларын авызына коеп, буш касәләр белән су алып ташка сипте дә, салкын бүлмәгә чыкты. Чыгу белән, авызындагы балны төкереп, тиз генә кымыз белән авызын чайкады, янә күп итеп кымыз эчте, кабалана-кабалана, кесәсеннән ношгыя алып йотты. Үзе Казан елгасына йөгерде, килә-килешли яр башыннан суга сикерде. Ул, пошкыра-пошкыра йөзеп, елга уртасына җитте. Бераздан, чабына-чабына кызарып беткән яугирләр чыгып, берәм-берәм суга чумды. Елга уртасында Кошчак углан белән борынга-борын очрашкач, Зөннар әйтте:

— Хан нигә коенмый?—диде.

— Ләүкәдә ятып тора!—диде Кошчак.—Хәзер төшәр...

Ләкин хан су коенырга төшмәде. Тирләп ятканнан соң, ихтимал, кымыз, буза эчәдер, дип уйлады Кошчак углан... һәм күңеленә ниндидер, сәбәпсез шом иңеп, ул ашыгып ярга борылды... Кошчак су буеннан менгәндә хан чәй бүлмәсендә түгел иде; углан, ашкынып, эссе ишеген ачты. Хан мәрмәр идәндә уңайсыз хәлдә йөзтүбән ята иде. Кошчак үз гомерендә мәетләрне күп күргән кеше, тиз аңлады: Сафа Гәрәй хан җансыз иде. Кошчак, борылмыйча гына, үкчәсе белән ишеккә каты типте, ишек ачылды:

— Ха-а-ан!—дип кычкырды углан.—Ха-а-ан үлгә-ән!

Яугирләр өерелеп ишеккә капланды.

— Эссе суккан,—диде Зөннар.—Ис тигән! Салкын су кирәк!

Ул бер ләгән салкын суны өстенә койды, мәетне әйләндереп, корсагына, күкрәгенә басып, сулыш алдырырга маташып карады. Тагын салкын су сиптеләр. Салкын су да, сулыш алдыру да, шар ачык ишектән ургылып кергән саф һава да ханга җан өрмәде. Бөтен яугирләр ханның уң чигәсендә күгәреп кабарган урын күрде. Ихтимал, ләүкәдән егылып, ул чигәсе белән мәрмәр ырмавына төшкәндер.

— Диванны җыярга, хәбәр итәргә кирәк,—диде Кошчак углан.

Мунча эчен шом басты. Мирзаларның берсе, сумы, кымызмы эчәргә дип, табын янына килде, Кошчак углан җене белән акырды:

— Кагылма-а!

Мирза сискәнде, касәсе дәстәрханга төшеп китте.

Кошчак янә әйтте:

— Кагылмагыз! Бөтен нәрсә шулай калсын. Бирегә дивани бәкләрдән башка беркем дә керергә тиеш түгел. Үзем саклыйм... Барыгыз, карачыларны алып килегез. Беркемгә бер сүз әйтмәгез...

Карачыларны чакырырга Зөннар мирза алынды. Яугирләр, салкын бүлмәдә киенеп, утыра калды. Тиз арада карачы бәкләр килеп җитте... Булат бәк кенә әзрәк соңлады: ашка киләмени, ул ашыкмый, ах-ух килми. Тәфсилчеләр дә килеп җитте. Карачылар вә яугирләр алдында тәфсилчеләр, бөтен эчемлекләрне иснәп, ханның тәнен, күгәргән урыннарын карап, ләгәннәрне, касәләрне җентекләп тикшерделәр. Бернинди агу-зәһәр галәмәте тапмадылар. Кымыз-балны, тел тигезеп, тәмләп караучылар да булды, хәтта атаклы тәфсилче Мөрадбәй эчемлекләрне берәр йотым эчеп карады. Аңа һич яман тәэсир булмады. Кемнең алдан, кемнең арттан чыкканнарын, хан мәетен иң беренче кем күргәнен тәфсилләп сорашып, язып, һәр шаһиттән имза куйдырып, тамга салдырып, бер карарга килделәр:

— Сафа Гәрәй, башы әйләнеп, ялгыш таеп, ләүкә биеклегеннән сырлы мәрмәргә чигәсе белән егылып җан тарткан...

Иренең кинәт вафаты турындагы хәбәр Сөембикәгә башта бөтенләй дә тәэсир итмәде. Ул ни әйткәннәрен аңламады. Кабатлап әйткәч, үзе сорады:

— Кем дидең? Кем вафат булган?

— Ханым-бикә,—диде Нәргәтай.—Ирең Сафа Гәрәй хан егылган... вафат иткән...

Сөембикә җандусты-ахирәтенә бакты да елмайды:

— Алай каты бәгырьле булма, Нәргәтай,—диде.—Сәхип Гәрәй хан ни сәбәпле үлсен икән?

Нәргәтай бөтен гәүдәсе белән калтырый башлады һәм:

— Сәхип Гәрәй түгел, бикәм,—диде.—Хәләлең Сафа Гәрәй хан мунча идәненә башы белән егылып...

Нәргәтай, ике учы белән, тастар очы белән чыраен каплады да, тезенә егылып, башын идәнгә орды; ул иләмсез үкереп елый иде. Сөембикә Нәргәтайга бакты, ниһаять, ул ни булганын аңлады. Гомергә бер дә әдәп кагыйдәләрен бозмаган Сөембикә, өстендә ни булган — шул килеш өеннән чыгып чапты. Ул ат иярләгәннәрен көтеп тормады, Ханкапкага таба йөгерде. Ябынчасын, Сөембикәнең җиләнен күтәреп, Нәргәтай белән Сауфия бер-бер артлы ханбикә артыннан йөгерә...

Мәсҗет ишегалдына куелган табут япмасын ачкач, ул Сафасын күрде. Ире йоклаган кебек тыныч ята, әмма йөзе үзенеке түгел.

— Үтергәннәр! — дип кычкырды бикә. — Ханны үтергәннәр!..

Сөембикә чәчбаусыз иде, ике кулы белән чәчен туздырып, йөзен тырный-тырный илаулый башлады, үзе һаман:

— Сафамны үтергәннәр, — дип кабатлый. — Ханны агулаганнар. Күрмисезмени аның йөзен? Аңа агу эчергәннә-әр!.. Кем үтерде минем иремне? Баламның атасын, Казанның башын кем агулады?!

Шулчак аның карашы Кошчак угланга төште:

— Син табарга тиеш, Кошчак, табарга тиеш ул җәлладны!

Бик авыр мохит иде бу. Казан мөселманнарында мәет янында кычкырып елау тыелган. Елау түгел, сөйләшергә дә ярамый. Колшәриф мулла Сөембикә янына килеп, аның терсәгенә сак кына кагылды:

— Ханәш бикә, сабыр булыш кирәк, сабыр бул! — диде.

Сөембикә тагын да катырак еларга тотынды. Сауфия аңа җиләнен кигездe, Нәргәтай ябынча бөркәде. Ахирәтләр, икәүләп, Сөембикәгә кушылып илаулый башлады. Ханмәсҗеткә генә түгел, бөтен калага кайгылы елау өне таралды. Аларга кушылып, бөтен халык елый иде...

Казан йортының тарихында бу иң зур фаҗига — Сафа Гәрәй ханның вакытсыз үлеме булгандыр, мөгаен. Бердәнбер мөстәкыйль хан, куәтле каһарман, халык мәхәббәтен казанган түрә гүргә иңдерелде. Аны Хансарай бинасы белән Дивани сарай бинасы арасындагы ханнар зиратына җирләделәр.

Сөембикәнең ярым һушсыз гәүдәсен өенә алып кайттылар. Ул ут алмыйча, ашамыйча-эчмичә, өч көн, өч төн бер сүз сөйләшмичә, йокламыйча, ыңгырашып өйдә утырды; урамнан, күчәдән үткән-сүткәннәрнең дә, бу кайгы ыңгырашуын ишетеп, бәгыре өзгәләнә иде.

Бу фаҗига туккыз йөз илле алты тарихында (1549) Тавык Елында булды.

## Үтәмеш Гәрәй хан

Сафа Гәрәй ханның кырыгын уздыргач, Сөембикә васыятьләр сандыгын ачарга рөхсәт бирде. Сандыкны ачканда олы бәкләр вә Сафа Гәрәй ханның дүрт хатыны да бар иде. Сандыктан котыйчык табылды; котыйчыктан алтын нишанлы васыятьнамә килеп чыкты. Сафа ханның мөһер тамгасы вә балдак тамгасы басылып, кулы куелган иде.

«Сафа Гәрәй хан, сүзем. Аллаһ Тәгалә кушуы илә җиһад юлында вафат итсәм, хасталанып үлсәм, миннән калган бар күк мөлкәтеми хәләл хатыннарым Мәһликә бикә, Латифә бикә, Хуркизә бикә, Җидегән бикә вә Сөембикәләргә тигез итеп, шәригатьчә бүләргә гозер итәм. Һәркем үз өлешен алып, тели икән, ошбу җирдә калырга һәм дә, тели икән, атасы йортына кайтып китәргә ирекледер. Балигъ булган ир оланнарыма аерым өлеш чыгарып, алар да кайда яшәргә икәнен үз ихтыярлары илә йөретсен. Аллаһ Тәгалә ихтыяр биреп, фани дөньядан күчсәм, тәхеткә төпчек углым Үтәмеш Гәрәй солтанны хан насыйб әйләсен. Бу васыятьнамә битилде туккыз йөз илле алты тарихында (1549), Тавык Елында. Мөхәррәм аеның унынчы көнендә».

Кошчак углан, васыятьнамәне карачылар вә бикәләр алдына куеп, һәр оланга, һәр бикәгә үз өлешләрен бүлеп бирү хакында шартнамә яздыртты. Тәхеткә өч яшьлек Үтәмеш Гәрәй солтан хан күтәрелде. Бу йола

мәҗлесләреннән соң, мәрхүм Сафа Гәрәй ханның бер хатыны Җидегән бикә — Себергә, туган туфрагына, Хуркизә бикә — Хаҗитарханына, атасы йортына, Латифә бикә — Кырымга, Мәһликә бикә Нугайга кайтып китте. Сөембикә углы Үтәмеш хан белән үз өендә, Казанда калды. Бүләк Гәрәй сабый анасы белән Бакчасарайга юл алды.

Сафа Гәрәй хан һәлакәтеннән соң, аның васыятьнамәсе игълан ителеп, мәрхүмнең амәнәте тормышка ашырылгач та, ханның марҗадан туган иң олы балигъ углы, егерме яшьлек Мөбарәк Гәрәй солтан һичбер каршы сүз әйтмәде:

— Атам ихтыяры — тәңрем ихтыяры! — диде.

Булат бәк өере Мөбарәк Гәрәйгә төрлечә басым ясап карады: пышылдадылар, язып та бирделәр, ачыктан-ачык та котыртып карадылар, тәхет сиңа тиеш, дип теңкәсенә тиеп беттеләр. Сөембикә турында Мөбарәккә ниләр генә сөйләмәделәр.

— Синең анаң урыс канлы иде, шуңа күрә атаң сине варис итмәгән, димәк, ул сине углы санамаган. Ә син — мөселман. Синең тәхеткә хакың зуррак! — дип, бичара солтанчыкның колагына да, күзенә дә керә тордылар. Мөбарәк солтан, бу юха еланнарны тыңласа да, һич кенә дә алар ягына аумады:

— Атам ихтыяры — Аллаһ ихтыяры! Үтәмеш Гәрәй хан — минем канкардәшем, Сөембикә ханша миңа анам белән бер! — дип кырт кисә торды.

Мәскәү илче-шымчылары да, Мөбарәк солтанны үзләренә аудармакчы булып, бүләк-санак биреп, хатлар язып:

— Синдә урыс каны, син Мәскәүгә кушылырга тиеш! — дип, вәсвәсәгә салырга нык тырышты.

— Мин — мөселман, мин — атам баласы, Казан йорты өчен җаным фида! — диде Мөбарәк солтан.

Ул үги анасы Сөембикәне үз анасыдай якын күрде. Әллә ана назы күрмәгәнгә, ул ун яшендә чакта Сөембикә белән беренче очрашуында ук ханбикәгә сыенды. Озак еллар баласы булмагангамы, Мөбарәк солтанның Сафа Гәрәй ханга бик тә охшаганы сәбәплеме, Сөембикә дә үсмер Мөбарәкне үз баласыдай сөйде. Үги ана белән үги бала бер-берсенә тартыла, рыялык кылу түгел, ярдәмләшү аларның теләге. Астыртыннар аларның арасын боза алмады. Яшь солтанны астыртын эшкә бәйләргә тырышучылар, максатка ирешә алмагач, нык холыклы бу мәһабәт егетне хәтта дошманнары да хөрмәт итә башлады. Мөбарәк Гәрәй солтанны чын ир-егет, атасы Сафа Гәрәй хан кебек затлы шәхес буларак үрнәккә куя иделәр.

Шулай итеп, тол Сөембикәнең иң якын ике терәге булып Кошчак углан белән Мөбарәк Гәрәй солтан калды.

Сафа ханны җирләгәч, астыртын эшләр өскә чыкты, мәкер җәтмәләре тыгыз үрелә, Казан тагын да хәтәррәк кайный башлады. Бәгъзе бәкләр, Үтәмеш Гәрәй ханны санга сукмыйча — янәсе, ул — сабый,— Мәскәүдән хан соратырга йөри.

Кайберләре Сафа Гәрәй ханның Кырымдагы углы Бүләк Гәрәйне тәхеткә соратыйк, ди.

Аларга икенче фирка каршы төшә:

— Бер сабыйны алып, икенче сабыйны хан итүдән ни фәтүә?

Бу талашларны ишетеп-белеп торган Мәскәү патшасы Иван сабыр гына көтә иде. Аның үз кешесе бар: Казан тәхетендә Шаһ Гали утырырга тиеш!

Бу талашларны ишетеп-белеп торган Кырым ханы Сәхип Гәрәйнең дә күз тоткан кешесе бар: Дәүләт Гәрәй солтан.

Казанның олы бәкләре дә, ниһаять, бер фикергә килеп, тәхеткә Дәүләт Гәрәй солтанны чакырырга булды. Тиз генә үтенеч хаты язып, бөек солтан Сөләйман Канунига илчеләр юлланды. Дәүләт Гәрәй солтан бу вакытта Истамбулда бөек солтан Сөләйман сараенда хезмәттә тора иде. Төрек солтаны янында тәрбия алган Дәүләт Гәрәй солтан Казан тәхетенә утырса, Кырым ханы Сәхип Гәрәй өчен дә, Казан йорты өчен дә бик кулай булып, Мәскәү сәясәте өчен һич тә файдалы булмас иде. Дүртенче Иван бу эшләргә комачау кылу өчен бөтен сәяси-хәйлә куәтен куйды. Казан-

нан — Кырымга. Кырымнан Казанга салынган юлларга нык сак-каравыл, гаскәр вә шымчылар көндерде. Бу шымчылар вә гаскәр, урыс адәмнәре түгел, ә бәлки тулысы белән чукынмыш татарлар һәм, Мәскәүгә хезмәт итеп, үз халкын кырып тамак туйдыручы вак мирза балалары, качкын бәкләр-кацаклар-казаклардан торган яллаулы аламан гаскәр иде. Менә шушы шымчылар гаскәре башында телен, динен, оятын саткан бәндә, хаин татар-нугай Урак мордар иде.

Казан олылары язган хатны алгач, бөек солтан Сөләйман Кануни, якыннарын җыеп, Казан тәхетенә хан көндерү хакында уртага салып сөйләшмәк булды... Дөресен әйткәндә, солтан Сөләйман Казан белән Мәскәү эшләреннән тәфсилле хәбәрдар түгел иде. Якын-тирә илләр белән булган олы мәшәкатьләре аны Шималдагы, ягъни Идел буендагы, Себерия вә Җидесу арасындагы төрки-мөселман урдаларыннан игътибарын ерагайта иде. Ата-бабасыннан калган гадәт тә, бәлки, аны арка ягындагы ханлыкларга дикъкатьсез калдыргандыр. Янәсе, төрки дәүләтләр борынгыдан куәтле булган, аларны христианнар ала алмас. Әмма уң кул Шимал да ут арасында калган, хәле мөшкел бер мәмләкәтнең көннәре санаулы гына икәнен солтан Сөләйман һич тә башына китерә алмады. Казан киткәч — Хаҗитархан, ул киткәч — Нугай, аннан соң Кырым-Кавказның китәчәген аңласа, һичшиксез, ул Шималга табан йөзе белән борылыр иде. Кара тәкъдир васвасәсе илә, нәкъ киресен кылып, гомумислам, гомумтөрки дөньясына хәтәр зыян салганын бөек солтан Сөләйман гомеренең соңгы сәгатьләрендә генә аңлар. Сөләйман Кануни, үз бөеклегенә — шөһрәтенә күмелеп, җиңелмәс Сөләйман булып, «вак» нәрсәләрне күрмәс дәрәҗәдәге хаким иде. Аның бу сыйфатын белеп, Мәскәүнең бөек кенәзе Василий да, Сөләйманны Казан ханнарына каршы котыртып, күп файда күргән иде. Мәскәүнең рәхимсез кара явына каршы орышыр өчен гаскәр сорап, Казан ханы Сәхип Гәрәй солтан Сөләйманга тезләнеп ялварган иде, әмма бу ялваруларны Сөләйман колагына да элмәде. Мәскәү шымчылары Казан, Нугай, Хаҗитарханда гына түгел, бөек солтан Сөләйман йортында да мыжлап тора иде. Мөселман кыяфәтенә кергән кяфер шымчылары да, илче булып килгәннәре дә солтан Сөләйман әтрафындагы патшалар, шаһзадә-солтанчыклар, муллалар аша Сөләйманны Мәскәү файдасына Казанга каршы өстерә торды. Атасы Василийдан алган бу гадәт Дүртенче Иванда куәтлерәк, тирәнрәк иде.

Янә дә килеп, шушы болганчык эшләр өстенә шаһзадә Дәүләт Гәрәй һәм олуг солтан Сөләйман вә пашалар арасында да астыртын эшләр кайный торды. Дәүләт Гәрәй — солтан Сөләйман Кануниның иң сөекле якыны, бөек солтан аңа сөеп карый һәм бөек солтан кече солтанның бөтен теләген үтәргә әзер тора, аңа олы бүләкләр бирә. Күп кенә шаһзадәләр, пашалар Дәүләт Гәрәйдән көнләшә, бәгъзе бер олы пашалар аңа нәфрәтле, көчләреннән килсә, алар Дәүләт Гәрәйне чәйнәп ташлар иде, җае гына чыкмый. Дәүләт Гәрәй шаһзадә үзе дә, нәфрәткә сәбәпче булып, тиңдәшләре илә мөгамәләдә дорфа, хәтта рәхимсез дә булгалый. Дәүләт Гәрәйнең хыялы — бөрәр бушаган тәхеткә хан булып утыру, ил белән идарә итәргә ул үзен өлгергән саный һәм бу турыда солтан Сөләйманның колагына гелән төшерә тора. Бөек солтан да аны бушаган тәхеткә тәгаенләргә разый. Әмма шундый форсатның күренгәне булмады. Ниһаять, менә форсат чыкты кебек. Дәүләт Гәрәй шаһзадәне Казанга хан итеп юлласалар, пашалар, шаһзадәләр иң хәтәр көндәштән котыла.

Бөтен Аурупаны дер селкетеп, бөтен христиан мәмләкәтләрен үз химаясендә тотучы, газават каһарманы бөек солтан Сөләйман Кануниның алтын сараенда бөек диван мәҗлесе җыйналды. Диван пашалары, шаһзадәләр үзара сөйләшкәннән соң, солтанга болай диделәр ки:

— И бөек вә җиңелмәс солтан! Иң әүвәл бу фекеремезне тыңлап бак. Сәхип Гәрәй хан ошбу кыйлмышлары илә Шимал мәмләкәтләрен берләштереп, һәм Кырымны, һәм Казанны синнән алып, үзбаш булып яшәмәк эстәер. Үзенә баш хан читкә баш бирмәс. Дошманың булмаса да, дустың да булмастыр. Кулың сузсаң, җитәрлек арадагы Кырым вә Бакчасарай — ул безнең ви-

лаятебездер... Сәхип Гәрәй ханның авызлык тешләп чабарга хирыс икәнен син үзең беләсең, и бөек солтан. Әгәр дә ки ул Казан илә берексә, авызлыкны чәйнәп өзәр...

Киңәшүчеләр исеменнән сөйләүче башпаша юри тынып калды: солтан бу фикерне ныклап тикшерсен. Сөләйман Кануни Сәхип Гәрәй ханның бөтен узганын уйлый һәм башпаша сүзләренә дәлил эзли иде: Сәхип Гәрәй ханның Казан тәхетен ташлап качуы аның Бакчасарай тәхетенә утырасы килгәннән булмадымы икән? Бакчасарайда хан булуы аның Госманлы сараена тәмгысын сузуы түгелме икән?

— Я, хуш,— диде солтан. Башпаша шуны гына көтә иде.

— Бәс,— диде ул.— Сәхип Гәрәй ханны бөтен токымы берлә Аллаһ ихтыярына тапшырырга да, аның урынына Бакчасарай тәхетенә сәүгелегез Дәүләт Гәрәй шаһзадәне багышларга лаземдер, ихтимал.

Бөек солтан тагын уйга чумды. Тәсбихен тартып туктагач, әйтте:

— Хуш!— диде.

Ризалык сүзе идеме бу, сүзеңне дәвам ит дип әйтүе булдымы?

Диванны таратып, солтан ялгызы гына калды.

Раст углы Юлбарыс, Мөхәммәт углы Даниян рәһбәрлегендәге утыз илче Казаннан Кырымга, Сәхип Гәрәй ханга китте. Алар Сәхип Гәрәй ханнан Казан тәхетенә хан сорарга тиеш иде. Ләкин бу илчелек Иван шымчылары кулына эләкте. Урак мордар гаскәре Казан илчеләрен Тын елгасына коючы Аю Ермагы кичүендә кырып салды. Хан сорап язылган хатны Урак мордар ашыгыч рәвештә Мәскәүгә озатты. Казан илчеләренең барысы да, Сәхип Гәрәй ханга барып җитә алмыйча, юлда һәлак булды. Илчеләрнең хәбәрсез югалганлыгы беленгәч, Бакчасарайга икенче илчеләр китте. Болары мең бәлаләр илә Кырымга барып җитте; ләкин, ихтимал, Солтан Сөләйман ягыннан җәбер күрә башлагангадыр, Сәхип Гәрәй хан Казан илчеләрен кабул итә алмады. Анда Казан кайгысы түгел, үз кайгысы кайгы булгандыр.

Сөләйман солтанның Сәхип Гәрәй хан астына чокыр казый башлавы да, Дәүләт Гәрәйне Казанга җибәрмәве дә, Казан илчеләренең кырылып бетүе дә, яшерен хатның Кырымга түгел, Мәскәүгә китүе дә, Сәхип Гәрәйнең Казан илчеләренә илтифатсызлыгы да — һәммәсе Иван патша өчен бик уңай булды. Шулар өстенә, Казан белән Нугай арасы нык түгел, хәтта иң олы әмир Йосыфның үз кызы Сөембикәгә ныклап ярдәмләшмәве — барысы да Мәскәү өчен мәгъкуль эш иде. Нугайның иң олы әмире Йосыф, абзасы Шәехмамай бәк вафатыннан соң тәхетне үз кулына алса да, илендәге таркау мирзаларны берләштерә алмады. Шул сәбәпле Исмәгыйль мирза, Касай мирза, Канбай мирза, Бибәй мирзалар һәм Шәехмамайның үз балалары — барысы да Казанның кан дошманы, Мәскәүнең җандуслары иде.

Тарих туккыз йөз дә илле алтыда, Тавык Елында, җәй башында (1549), Нугай йортыннан Мәскәүгә зур илчелек китте. Нугай илендә һәр мирза үз җәйләвендә падишаһ нисбәтендә булганга, һәр мирза Мәскәүгә үз илчесен юллады. Бу — әмир Йосыфка баш бирмәскә тырышу, син үзеңә әмир, без үзебезгә әмир, дигән сүз иде.

Иван Васильевич патша Нугай мирзаларының илчеләрен бик хуплап каршы алды. Аларны ныклап, сыйлап-сыйпап, олы бүләкләр төяп, җавап хатлары язып, хөрмәтләп, үзе озатып җибәрде. Касай мирзага Иванның җавап хаты менә шундый сүзләр белән тәгәлләнә иде:

«Син безнең өчен Кырым вә Казан илә орыштың, бу эшең безгә хуш килде. Сораган нәрсәләреңне: ике табанча, бер төлке тун юллыйм. Тагын да безнең яктан Казан вә Кырым илә хәтәррәк орышсаң, тагын да шундый бүләкләр җибәреп торырмын».

Шундый рәвештә Казан тирәсендә мәкерле җәтмә урелгән чакта, Казанга, бичара Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәй ханга әмир Йосыф хәрби куәте илә ярдәм итәргә тиеш кебек иде, әмма ул бүтән сәясәт тотмакчы булды. Мәскәү белән дә араны бозасы килмичә, Казанга да ярдәм итмичә, бу кыен

хәлдән ул Сөембикәне Шаһ Галигә кияүгә биреп котылмак булды. Янәсе, урыс яклы Шаһ Гали белән Казан ханбикәсе кушылгач та, Мәскәү белән Казан җандус булып китәчәк. Шулай уйлады да әмир Йосыф, хат язып, Мәскәүгә илчеләрен юллады:

— И олуг падишаһ вә бөтенруссиянең бөек кенәзе Дүртенче Иван Васильевич! Сәүгеле кызымның хәләле Сафа Гәрәй хан дөнья куюы сәбәпле, Сөембикә бер сабые илә тол калды. Казан хәзер хансыз гына гомер кичерә. Синең туплы, мылтыклы гаскәрең берлә минем атлы гаскәрем бергәләп Казанны бик тиз мохарәбә кыйлыр идек. Синең дустың Шаһ Галигә минем сәүгеле кызым Сөембикәне багышлап, без дә синең илә дустлашып гомер кичерер идек... Бәс, мин үтенәмен ки, син әсир төшкән адәмнәремне азат кыйл вә миңа тун җибәр!

Иван бу хатка җавабын әйтте:

— Казанга Шаһ Галине куячагым. Кырым юлларына, яңа хан киләсе булса, каравыл-гаскәр куйдым. Казанга илтүче барча юлларны, кичүләрне сакка алдым,— диде.

Иваннан бүләк-санак алгач, Нугай мирзалары җыелып, Мәскәүгә хат-хәбәр күндерде:

— Без, Исмәгыйль мирза, Белүк Булат, Арслан мирза, Касай мирзалар әйтәбез ки: бөек падиша вә бөтенруссиянең олуг кенәзе Иван Васильевич Казанны мохарәбә итәр өчен олы яу белән йөрсә, үз ягыбыздан күп атлы гаскәр белән Казанны мохарәбә кылыр өчен яу чабачакбыз...

Шулай итеп, Нугайның куәтле мирзалары тун, алтынлы кылыч, ияр өчен, үз туганнары Үтәмеш Гәрәй хан белән Сөембикәне тар-мар китереп, Казанны Мәскәүгә баш-аягы белән сатып җибәрергә алгысап, ярыша-ярыша гаскәр туплый башлады.

Сөембикәнең агасы Исмәгыйль мирзаның гомеренә бер мәртәбә дә туганнарына игелек кылганы булмады; хәзер генә, Казан бичара хәлгә калгач кына, ул инде Үтәмеш Гәрәй ханга ярдәм итмәс. Әмма Сөембикәнең бертуган абыйсы Юныс мирзаның Иванга язган хатын укыгач, күпме хаиннәрне белгән, сатлык татарлардан күпме файда алган баярлар да, Иван үзе дә шаккатты:

— Була,— диде Иван падиша,— була сатлыклар, әмма татар арасында да мондый хаинлек бик сирәктер,— дип сөйләнә-сөйләнә, көлә-көлә, Юныс мирзаның хатын кычкырып укырга кушты:

— Бүре бүрек белән төлке тун, бер утчагар белән ун атарлык дары җибәрсәң, Казан өстенә алтмыш мең кылыч илә яу чабачагым!

Әлеге хат баярларның күңелен күтәрде, алар яхшы кәеф белән таралды.

Гәүһәршад бикә белән Булат бәк тәмаммысы азау ярды. Алар, өстән шаулап-кычкырып, астан гына нидер кыла, тагын фетнә әзерли кебек. Казан бәкләре, каты куллы хан булмау сәбәпле, бик күп төркемнәргә, өерләргә, фиркаләргә бүленеп бетте, аларның кем яклы икәнен аерып булмый. Булат бәккә шул гына кирәк тә. Әгәр дә ки Мәскәү гаскәре хәзер килеп чыкса, Казанны ялангач кул белән дә яулап алачак.

Сөембикә әнә шушындый тәбегә-тозакка килеп капты. Ни кылырга белмәгәч, ул Үтәмеш Гәрәй хан исеменнән Иванга Бахшанды атлы илчесен җибәрде. Бахшанды бәк Мәскәү белән Казан арасындагы яу киеренкелеген киметергә, дус яшәргә теләк белдереп, солых төзеп кайтырга тиеш иде. Сөембикә, Бахшанды бәк рәһбәрлегендәге илчеләрне озатуга ук, Нугай йортына, атасы әмир Йосыфка һәм бертуган абыйлары Юныс вә Гали мирзаларга, тагын башка туганнарына, ялварулы хатлар тоттырып, илчеләр тәгаенләде: Аллаһ хакы өчен, зинһар, Иванны Казанга йөрүдән тыегыз, ул сезнең дустыгыз, ул сезне тыңлар; коткарыгыз углым Үтәмеш Гәрәй ханны, коткарыгыз мине. Болай хуп күрмәсәгез, йортымны, Казанымны сакламак өчен күп гаскәр җибәрегез.

Кызының күз яшьләре тамган бу хатны алгач, әмир Йосыф, Казанга яу йөрмәвен үтенеп, Иванга илчеләр күндерде. Ләкин Казан илчесе Бахшанды бәк һәм Йосыф әмир кешеләре Мәскәүгә җиткәндә Иван, яуга әзерләнеп, гаскәр туплап бетергән иде инде. Тыны капланган илчеләргә ул:

— Шулкадәр чыгымнар белән туплаган гаскәрне таратып буямый бит инде, нигә алданрак килмәдегез, мин гаскәр җыймаган булыр идем. Казан йортына орыш илә бармаган булыр идем,— дип җаваплаңды.

Шушы ук елны, ягъни Тавык елында, кышкы зәмһәрирдә бөек кенәз, олуг падишаһ Иван Дүртенче кара явы белән Казанга йөри башлады.

Бу яуны каршы алырга ныклы әзерлек булмаса да, татарлар Иван гаскәре белән бик каты сугышты, дошманга Казанны бирмәде, шөкер. Иван Казанны ала алмасына инангач кына, бик озак тоткан камалышны алып, чигенде, Мәскәүгә юл алды. Сөембикә белән Кошчак углан һәм Мөбарәк Гәрәй солтан булмаса, һичшиксез, урыс гаскәре Казанны харап итә иде. Кошчак баһадирлары вә Мөбарәк Гәрәй солтан әйдәгән аз санлы батыр сугышчылар, Иванның яхшы коралланган кара явына каршы аяусыз сугышып, Казанны бирмәде.

Ни сәбәптән шулай булгандыр, бәлки, Сөембикәне коткару өчендер, Нугай мирзалары Арслан, Атай, Тайлаклар кинәт кенә, баштагы сәясәтләрен үзгәртеп, Иванга биргән вәгъдәләрен бозып, урыска каршы сугыш башладылар: Иван Казаннан чигенгән чакта, илле меңлек атлы гаскәр белән, урыс шәһәрләренә яу чаптылар; бик тиз йөреп, Мишчәр, Иске Рәзән җирләренә һөҗүм иттеләр. Ләкин бу төптән уйланган яу булмады, ашык-пошык кына, алдын-артын карамыйча, коры егетлеккә генә корылган бер уңышсыз һөҗүм булды. Мишчәр, Рәзәннәр берләшеп, нугайларга каты дарбә ясады, нугай атлылары кырылып бетте. Бу хәтәр орыш Елатма дигән урында булды. Бу орышта мәшһүр Тайлак мирза һәлак булды. Исән калган нугай-татарлар качып китәргә мәҗбүр иде, ләкин алар Елатмадан ерак китә алмады, тирән кар капланган юлсыз җиргә кереп, атлары күкрәктән көрткә батты. Урысларның кугын гаскәре татарларны кырып салды. Бу тозактан меңгә якын кеше генә качып котылды. Идел бозына җиткәндә тагын куып җитеп, казаклар аларны да тәмам турап бетерде. Шулай итеп, илле мең кешедән Арслан мирза, Атай мирза белән илле ике нугай — алары да яраланган, хәлсез, ач-кышлауга кайтып егылды. Мәгънәсез, акылсыз бу яу сәфәре шулай тәмам булды.

Икенче елны, ягъни туккыз йөз дә илле җидедә, Эт Елында (1550) Мәскәүдән элеккесеннән дә куәтлерәк гаскәр Казан өстенә яу булып килде. Ятим калган йортны Иван тәмам изәргә уйлый иде. Бу яуга каршы торырлык куәтне Казан әзерләп өлгерә алмады. Мөселман-тугандаш илләр арасында низаг арты низаг чыгып, үзара сугышып, Казан язмышына алар гамьсез калды. Мәскәү ягы тәмам ныгый барды, куәтләнде; Иван олыгая барган саен, Мәскәүнең матди куәте дә, хәрби көче дә, кенәз-баярларның көчле бер байрак янына — дини сәясәткә берләшүе дә көннән-көн арта иде.

Кошчак углан белән Мөбарәк Гәрәй солтан вә Сөембикә тырышлыгы илә Казан эчендә бар булган гаскәри көч тупланды.

Бу юлы Мәскәү гаскәре, килә-килешкә үк шәһәрне камап, куәтле һөҗүмгә ташланды. Казан теше-тырнагы белән хәтәргә каршы хәтәр сугышты. Ике яктан да бихисап күп адәм кырылды, санап бетергесез батырлар кяфер кулыннан шәһит китте, шулар арасында мәрхүм Сафа Гәрәй ханның олы углы Мөбарәк Гәрәй дә җансыз иде. Көн саен, сәгать саен мәетләр артканнан-арта барып, аларны олылап, йола белән җир куенына тапшырырга да вакыт җитмәде. Иванның дистәләгән туплары, учтагар мылтыклары бертуктаусыз атып, дивар өстендәге татарларны һәм каладан чыккан атлыларны рәхимсез кырып сала торды. Кыю татарлар, ук-җәя, сөңге, кылыч тотып, атларга атланып, шул тимер гаскәргә каршы аяусыз каты орышты, кырылды, әмма Изге йортын — Казанны дошманга бирмәде. Кансыз Иван, меңләгән мәетләр калдырып, һич нәтиҗәсез Мәскәүгә кайтып китәргә мәҗбүр булды.

Бу яудан кайтуга ук, Кансыз Иван Казан өстенә яңа яу әзерләргә тотынды. Көз буе, кыш буе салым җыеп, икмәк, печән, солы туплап, туплар, мылтыклар койдырып, алны-ялны белмәенчә, кешеләрне җикте, баярларны йөгертте; үзе дә, төнгә төнне тоташтырып, гаскәр туплау белән мәшгуль булды.

Мәскәүнең Казан өстенә шундый хәтәр кара яу әзерләгәне бөтен мәмләкәтләргә дә мәгълүм иде, ләкин нә Төрек, нә Кырымнан, нә Хаҗитар-ханнан, нә бүтән ханлыклардан ярдәмгә килүче булмады. Ничарадан бичара, Үтәмеш Гәрәй хан исеменнән Сөембикә Мәскәүгә Дәүләт-яр атлы илчесен юллады. Шулай итеп, Сөембикә солых сорап, афәтне булдырмаска тырышты. Ханбикә, атасы әмир Йосыфка да хат язып, аның аша Иванны Казанга йөрмәскә өндәп карады. Әмир Йосыф, чыннан да, кызының гозерен Иванга җиткезде. Әмма Иван аңа бик тәкәббер сүз илә хат язды:

«Минем белән дус яшисе килсә, Сөембикә ханша илче итеп миңа яхшы кешесен җибәрсен... Әйтик: Нургали бәкне, аның өч угланын, тагын дүрт олысын юлласын. Шул чагында мин нәрсә теләгәнемне әйтермен. Минем өчен яман кешеләрен җибәрмәсен, яман кешеләрен җибәрсә, мин аларны зинданга ташлармын, үзем Казанга йөриячәкмен!»

Бу, әлбәттә, сүз уйнату гына иде: Сөембикә яхшысынмы, яманынмы — кемне генә җибәрсә дә, Кансыз Иван барыбер Казан җиренә басып керәчәк иде. Йосыф әмир вә Сөембикә илчеләре кайтып китүгә үк, Иван баярларын җыйнап алды, Казанга бару-бармау мәсьәләсен куйды. Иванның ашкынып Казанны яуласы килгәнен бөтенесе дә белә, аңа каршы чыгу үлем белән бер иде. Баярлар сугыш ягында иде.

— Казанны бөтенләй тар-мар кылып, яулап алу өчен, Казаннан ерак түгел кальга салырга. Ул кальга Шүкәколый елгасы белән Зөя арасында мәгъкуль булыр иде,— диделәр.— Бу шәһәрне тиз салу өчен, булачак кирмән диварларын, йортларны, чиркәүләрне чирмеш җирендә, урман эчендә бурап, көймәләргә төяп, берьюлы Зөягә илтеп бушатырга, шунда ук мүкләп күтәрергә. Осталар дивар йортларны күтәргәндә, татарлар комачауламасын өчен, Иван Выродкиг рәһбәрлегендә зур гаскәр Угличта сакта торырга тиеш!

Иван өчен җил гел уңайдан гына исә башлаган иде инде. Аңа күп яклап ярдәмгә алынучылар байтак табылды. Казанның җандуслары — оста җәячеләр, чирмеш, чуаш олылары — Иван ягыннан сугышырга булды. Сөембикәгә канкардәш мирзалар, хәтта бертуган абый-агалары да, Иванга куштанлык хатлары язып, дус булырга, бергәләп Казанны мохарәбә итәргә риза булып, илчеләр җибәрде.

Әмир Йосыфның Иванга язган ялварулы хатлары да, Сәхип Гәрәй ханның Иванга язган янаулы ярлыклары да Кансыз Иванга тәэсир итә алмады. Мәскәүнең бөек кенәзе, бөтенрусиянең олуг падишасы Кансыз Иванны үҗәт максаты — Казан каласын җимереп, татарларны тар-мар китереп, мөстәкыйль дәүләтне тамырдан корыту, юк итү теләгеннән бернәрсә дә туктата алмый иде инде.

Бу вакытта Зөя елгасының Түгәрәктау дип аталган урынында урыслар яңа кала салып куйганнар иде инде. Бу каланы салуда Шаһ Гали бик тырышлык белән дан казанырга уйлады. Кала бер айда салынып беткәч, урыс поплары татар туфрагына изге суларын сибеп, гыйбадәт кылып, агач чиркәү күтәртеп куйдылар. Чиркәү эченә кереп, янә гыйбадәт кылып, Казанны алу, татарларны кырып бетерү өчен, үз Аллаларына инәлеп, Литургия дигән йолаларын башкардылар. Татар туфрагына рөхсәтсез басып кереп салынган бу гыйбадәтханәгә «Атаклы Сергей чиркәве» дип исем куштылар. Шуннан соң, кальганың диварларын салып, яшәү өчен йортларны күтәрделәр. Тау ягында шундый нык урыс каласы салынып беткәнен күргәч, шул калага бик күп Мәскәү гаскәре кереп тулганын белгәч, Тау ягы халкы бу яңа калага — Зөягә, Шаһ Гали каршына килеп баш орды:

— Безне кырмагыз, без Мәскәүгә хезмәт итәрбез, татарларга каршы орышырбыз,— диделәр.

Шаһ Гали аларга әйтте ки:

— Бөек кенәз, бөтенрусиянең олуг падишасы Дүртенче Иван Васильевичка мәңге тугры булырга авызыгыз илә һәм язуыгыз-тамгаларыгыз илә ант эчегез, үз коралларыгыз, үз атларыгыз илә Казанга каршы орышсагыз, Иван Васильевич сезнең һәрбер катнашучыгызның токымын өч елга ясактан азат итәчәк!— диде.

Тау ягы олылары Шаһ Гали кушканча эшләделәр. Алар, ант беркетеп, алты йөз кеше санындагы гаскәр башлыклары урыс ягына чыкты. Шулай итеп, Казан ханлыгының иң күп керем бирә торган вилаяте; икмәк, бал, урман, кыйммәтле җәнлек тиреләре чыганагы булган мул як Казаннан аерылды. Хәзер ул як Казанның дошманы булды... Тау ягының куәтле гаскәре: төз атучы чирмешләр, Тарлаш, Ташлы Кичүләрдән Идел аша чыгып, Казаннан утыз чакрымда туктап, Иван әмерен көтә калды. Ул арада Мәскәү гаскәре Казанны камады. Мәскәү явы эчендә татарларга каршы бик теләп орышучылар — Казаннан качкан бәкләр, мирзалар — Борнаш, Костров, Чапкыннар белән биш йөз кеше, Шаһ Гали рәһбәрлегендә Касыйм ханлыгыннан килгән татарлар да бар иде. Иван әмере илә Тау ягы чирмешләре дә Казанга якын ук килде. Чирмеш җәяүчеләре килеп җитүгә үк, Мәскәү явы кинәт һөҗүм башлады: Казанның атлы гаскәре дошманга каршы чыкты. Казан кирмәне диварларыннан, каравыл манараларыннан — бар булган утчагар мылтыктан, дүрт туптан урыс гаскәренә төбәп аталар. Беренче калкыныш бик тиз кире кайтарылды: дошман чикте. Чигенүчеләрне бераз куып баргач, татарлар калага кайтты. Атыш туктады. Яу кырында мәетләр, авыр җәрәхәтләнгәннәр, кача алмас дәрәҗәдә имгәнгәннәр генә калды. Татарлар бу юлы берән-сәрән генә үлде. Кыр тулы, күпер өсләре тулы кяфер мәетләре... Һөҗүм арты һөҗүм кайтара торгач, казанлылар әлсерәп, атлар яраланып, йончылып, дошман гаскәренең дә кикриге шиңде. Казан каты торачак, бирешергә уйламый. Бусы хак. Баягы орышлар шулай уйланырга мәҗбүр итә. Кошчак углан гаскәрләрне яуга үзе әзерли, үзе өнди, үзе әйди, үзе иң башта йөри, каты-оста орыша һәм һәрвакыт җиңә, суештан исән кайта иде. Әмма кылыч тотардай яугирләр азайганнан-азая, көчләр, атлар кими бара.

Дошман ягында эшләр башкачарак. Орыштан исән кайтканнарны Иванның воеводалары хәл алырга арткы тирмәләргә җибәрә; яраланганнарны тагын да ераграк урнаштырып, җәрәхәтләрен бәйлиләр. Иван яңадан-яңа гаскәрен һөҗүмгә әзерләп тора. Татарлар, бичаралар, ял итү түгел, ашап-эчеп алырга да өлгерми, алар ат алмаштырырга гына җитешә. Манарадагы бактаннар:

— Я-ау килә-ә! — дип кычкыруга, әле яңа гына орыштан кайткannар, янә ияргә менеп, кулга кылыч-гөрзи, сөңге алып, ачык капкага томырыла.

Сугышка озатырга кеше җитмәү сәбәпле, үсмерләрне, балигъ булмаган оланнарны да ияргә кундырып, кулларына кылыч тоттырып, баскынчыларга каршы җибәрә башладылар. Ике яктан да кырылыш күп булып, юллар, күперләр мәетләр белән тулды. Татар мәетләре өстендә — урыс, урыс өстендә — чирмеш, чирмеш өстендә татар мәетләре өелеп ята. Җәрәхәт алып егылган адәм, үлмәслек яра алган булса да, өстенә ауган ат гәүдәсе, аттан егылган җайдак гәүдәсе астында калып җан бирә. Атлар үлем ачысы белән кешни, ике яктан да туплар, мылтыклар гөрселди: тирә-як төтен, тузан белән капланган, кайда кайсы гаскәр икәнен дә аерып булмый.

## Кошчак углан

Бу вакыт урыс ыстанында хәрби киңәш бара иде. Киңәшмә башланырга торганда воевода Петр Туров, рөхсәт сорарга да онытып, чатыр эченә атылып керде. Кәрә-керешли, ут капкандай кычкырды:

— Тау ягы татарлары белән чирмеш укчылары Арча Кырына килеп җитте. Әмер көтәләр...

Воевода Алексей Ершов әйтеп куйды:

— Тау ягы куркыныч, сугышчан халык. Әмма алар, җай саклап капка ачылуга, капкага бәреп керсә, ягъни татар ягына качса, Сөембикә гаскәренә никадәр кылыч, җәя өстәләчәк. Кыенга туры киләчәк, Иван Васильевич.

— Сынап карарга туры килер, — диде Иван, — сынап карарга! Чирмеш укчыларын да, Тау ягы татарларын да Казан капкасыннан чыккан Сөембикә

гаскәренә каршы җибәрергә кирәк. Бер генә христиан да бу орышка катнашмасын! Катнашмасын!

Иван кул селтәде, бу ишарә Петр Туров белән Алексей Ершовка ишарә иде:

— Бу эш сезгә йөкләнә!—дигән әмер иде ул.

Ике воевода да, чатыр ишегеннән үк ияргә кунып, Арча Кырына таба чабып китте. Алар килеп җиткәндә Тау ягыныкылар сугышка әзерләнеп беткән иде. Ләкин Арча капкасыннан бер генә сугышчы да чыкмады. Бөтен көч Ханкапканы, Аталык капкасын, Түбән капкаларын, Нургали капкасын сакларга куелган иде. Арча капкасының теге ягында, кальга эчендә аз санлы атлы гаскәр, үсмер-оланнар гына тора иде. Диварлардагы, манарадагы сакчыларны санамаганда, капкага ныклы сак та куелмаган. Татарларны Арча капкасыннан кырга алдап чыгару хәйләсенә керештеләр. Бу яктан да, дивар-манарадан да татарчалап сүгенү сүзләре кычкыралар. Тышкы яктан:

— Чыгыгыз, куркаклар! Арча Кырында орышабыз!—диләр. Диварлары өстеннән:

— Килегез, йөрәгегез җитсә-ә!—дип үртиләр.

Берәрсе тозлырак сүз әйтсә, үз ягы акырып көлә; телчән кеше, аның саен канатланып, хәтәр сүзләр яудыра.

— Һәй!—дип кычкырды манара бактаны.—Ничә дуңгыз колагы өчен безне урыска саттыгыз, чучкалар?

Казан ягы, капка артындагылар көлде. Хәтәр сүз иде бу. Тау ягы тынып калды, тамакларына кылчык кадалды. Бер телчәне, алгарак чыгып, бугаз киереп янә җавап әйтте:

— Без сезне дуңгыз колагына саттык, дөрес! Без дуңгызның колагын да җыярбыз. Озакламый Иван сезнең барыгыздан да дуңгыз ясаячак! Без шул дуңгызның да башын бисмилла әйтеп ашарбыз!

Дошман явын табигыйдан артык көлү шаукымы тотты. Хәтәр көлү иде бу. Үчекләшә торгач, тау ягыныкылар, капкага хәтле чаптырып килеп, өстәгеләргә ук аттылар да кире чаптылар. Өстән дә ук яңгыры яуды. Беренче һөҗүмдә җан бирүче ике ат, алты чирмеш мәете калды. Җайдактан бушанган атлар чирмеш ыстанына кайтты. Атсыз калган ике чирмеш, калкан, сагадак белән башларын каплап, кире йөгерде.

Шулай өч тапкыр котырту һөҗүме ясалгач, бактан Кошчак угланга чапкын җибәрде. Кошчак углан, күп уйлап тормастан, биш йөз кешесе белән Арча капкасына күчте. Чирмешләр яңа һөҗүмгә ыргылгач кына, капкалар ачылып китте: Кошчак углан гаскәре ургылып чыкты да, Тау ягыныкыларның маңгаена бәреп керде. Тау ягы башлыклары моны көтмәгән иде, алар бүтән боерык биреп өлгермәде; хәтәр һөҗүмнән куркып, чирмешләр җәягә ук куяргамы, кылычка тотынаргамы белмәде—Кошчакныкылар, чирмеш гаскәрен биленнән өзеп, икегә бүлеп турый башлады. Тау ягыныкыларны шактый тураганнан соң, Кошчак углан быргы тавышына гаскәрен борды, үзенекеләрне сугыш кырыннан алып чыгып, капкага таба чабып китте. Чирмешләр, айнып, аларны куа китте. Куа-гаскәр төп яудан аерылгач, капкага килеп бәрелдем дигәндә генә, Кошчак гаскәрен янә артка борды, куа-гаскәрне кылычка алды. Куа килгәннәр кырылып бетте. Җайдаксыз калган дошман атлары килгән шәпкә капкага ыргылып керде. Алар артыннан Кошчакныкылар да калага кайтты. Капкалар ябылды. Арча капкасы белән Арча кырындагы мәйдан ат гәүдәләре, кеше мәетләре белән капланып калды... Ике як та, мәет җыярга шүрләп, әле генә яу узган мәйданны тын гына күзли. Җан бирә алмыйча, аяклары тартышып ятучы атлар; үлем җәрәхәте алса да, үлә алмыйча интегеп ятучы кешеләр икенче орышкача шулай кадерсез, ярдәмсез бичара булып яттылар.

Петр Туров белән Алексей Ершов, атларын калку җиргә туктатып, бу хәлләрне карап тора иде. Татарларга нәфрәтле бу ике башкисәр, Кошчакныкыларның каһарманлыгын күреп, тын калды. Кошчак угланның җендәй җитез, кыю сугышуына карап Туров үзе дә сизмәстән әйтте:

— Храбро! Храбро!—диде.

Ул арада капкалар киерелеп ачылды, аннан тагын Кошчак килеп чыкты; аның артыннан, тоташ ташкын булып, атлылар дошман явына ыргылды. Тау ягыныкылар үзләре һөҗүмгә тезелгән иде, курку белмәс егетләр ташкынын күргәч, аларны каушау шаукымы биләде: яуга каршы яу булыргамы, әллә кирегә чабаргамы, дип торганда төрле боерыклар бергә буталды:

— Ал-алга-а!

— Артка-а!

— Урыннан ат-ат!

Калкулыктан Петр Туров акыра:

— Алга-а! Алга-а!—дип кул изи.

Бер өлеш чирмешләр, бер өлеш Тау ягы татарлары Кошчакка таба йөри башлады, бер өлеше үз урынында таптана калды, бер өлеше качып китте. Ул арада Кошчак углан дошман уртасына бәреп керде, әллә каян гына икенче кылычын чыгарып, ике кылыч белән дошманнарын чаба-турый башлады. Аның аты өзәңге белән типкәнгә борылып йөрергә өйрәтелгән булып, сул ягына типсә — уңга, уң як өзәңге типсә — сулга борылып уйнаклый иде. Кошчак угланның кылычларына күз иярми. Аның уң ягын — Сатый мирза, сул ягын — Тәүбәк, арка ягын Хәтәр углан саклап сугыша; угланнар үзләре дошманга кылыч селти, үзләре күз кырые белән Кошчакны күзәтә.

Алгы гаскәр белән эшне бетергәч, каушап калганнарны туздырып, Кошчак углан качучыларны куа ыргылды. Куышу ераккарак китте, ахрысы, алар кире кайтканда Петр Туров белән Алексей Ершов арган сугышчыларның кайтыр юлына поскын гаскәрен чыгарды. Кошчак углан моны көтмәгән иде, кинәт туктады, якынындагы ике быргычысына нидер әйтте. Быргычылар ике төрле тавыш белән уйнарга тотынды. Кошчак угланны егерме егете белән калдырып, кайтып килүче гаскәр кинәт икегә аерылды да поскын гаскәрне урап, Арча капкасына керергә ниятләде. Дошманның поскын гаскәре, аптырап, тыела төште. Кошчак углан белән калган егермеләп егетне камаргамы, әллә, икегә аерылып, шәһәргә ыргучылар каршысына төшәргәме? Дошманнар нидер акыра, киңәшә. Калкулыктан воеводалар нидер кычкыра, ләкин һични аңлашылмый.

— Ку-ушча-ак!—диләр бугай.

Кошчакны әсир итәргәме, үтерергәме кушалар?Быргычылар тагын ике тавыш белән кычкыртырга тотынды. Кошчак углан, егерме егете белән кырт борылып, артка таба чабып китте. Поскын гаскәр тулаем алар артыннан ыргылды.

Икегә аерылган Казан атлылары, кинәт борылып, поскын артыннан томырылды. Кошчакны куучы дошман, дошманны куучы татарлар атларын бар көченә куалый, акыра-сызгыра. Кошчакныкылар, кинәт артка борылып, поскын белән орыша башлады. Бик тиз арада шактый дошманның башына чапкач, Кошчак янә кырт борылып чаба башлады, поскын аны янә куа китте. Төп гаскәрдән иллеләп дошман аерылгач, янә кырт артына борылып, Кошчак куа килүчеләрне кылычка алды. Шулчак дошман гаскәре эчендә:

— Камалышта-а!.. лышта-а!...—дигән иләмсез куркынган аваз яңгырады.

Поскыннар, артта ни бар, дигәндәй борылганнар иде, Кошчакныкылар кылычыннан башсыз калдылар.

Бу кырышта Кошчак угланныкылар, меңгә якын дошманны үтереп, йөз илле әсир алып, Арча капкасына кайтты. Исән калган чирмешләр, Тау ягы татарлары качып бетте. Иван янына кайткач, Петр белән Алексей әйтте:

— Таулылар яхшы орышты, алар безгә тугры хезмәт итәчәк!—диде.

Кошчак угланның зур җиңүе иде бу. Җиңүен җиңү дә, әмма Кошчакның җаны рәхәтлек кичермәде. Узган елгы орышта ул шушы кешеләр, чирмеш дуслары белән иңгә-иң, аркага-арка урыска каршы орышты, Казанны саклады. Бу юлы алар бер-берсенә кылыч чапты. Күпме көч-куәт үзара кырышка китте. Әгәр дә шул чирмеш батырлары белән берләшеп, уртак дошманга бәрсәң!

Арча ягы чуашлары да Иванга кушылды. Гомер буе Казан иленең иң яхшы урманчылары, игенчеләре булган, Казан өчен утка-суга кергән чуашлар

да иң авыр чакта, Казан эчендә сугышчылар азайганнан-азая барганда, Казаннан аерылып, Иванга буйсынды. Беренче сәгатьтә үк Иван боларга бик олы эш йөкләде. Чуаш укчылары, Казан капкасына якын барып, Кошчак углан белән турыдан-туры сөйләшергә тиеш иде. Иван кушканча, чуашлар, Аталык, Төмән капкаларына якын килеп, авызларына кушуч куеп кычкырды:

— Һәй! Кырымнан килмешәкләр! Нигә сез олы патшага буйсынмыйсыз? Капкаларны ачыгыз!

Кошчак углан капкаларны кинәт ачтырды, өч капкадан атлылар ургылып чыкты да чуашларны турап салды, бик сирәкләр генә качып котылды.

Казан эчендә ирләр кимегәннән-кими бара. Мәскәү гаскәре китәргә уйламый да. Шундый шомлы көннәрнең берендә Казан эчендә Кошчак угланга каршы бик зур фетнә купты. Сан ягыннан кырымлылар бик аз калганлыктан, Булат бәк үз эшен ачыктан-ачык эшли башлады. Аның:

— Кырымнар аркасында харап булабыз! Иван кырымнарга үч итеп сугыш башлады, кырымнарны суйсак, Иван безне ярлыкар!—дигән сүзе башсызларга бик нык тәэсир итте.

Кошчак угланга каршы ачык фирка барлыкка килде.

Булат бәкнең теләге бик гади иде. Кошчак бетсә, Сөембикә ялгыз башы һични эшли алмаячак, Казан идарәсе тагын Булат бәк кулында калачак. Шул вакытта, Иван җиңгәндә дә, Булат бәк өчен файда булачак. Гәүһәршад бикә дә арслан белән юлбарыс сугышканны тыныч ләззәт илә күзли, кем җиңә башлый, шул якка чыгарга форсат көтә иде. Бар да ачык: казанлылар белән кырымлылар никадәр генә батыр орышмасын—Казан җиңеләчәк. Иван илне басачак иде. Гәүһәршад бикә ире Булат бәккә әйтте:

— Кошчак углан белән егетләрен тотып, Иванга бир!

— Һи,—диде бәк.—Кошчакны тере килеш алу—булмас эш, бикәм.

— Алайса, бөтенесенең башын кисеп, Иванга төяп җибәрергә дә, солых төзергә!

Булат бәк шымчылары Кошчак белән аның тугры угланнарын таң алдыннан, өйләренә бәреп кереп үтермәкче булды. Бәк шымчылары арасында Сөембикәнең бер ышанычлы кешесе бар иде. Шул таң алдыннан суеш булачагын Сөембикәгә хәбәр итте. Хәл мөшкел иде. Кошчак углан Казанда калса, аңа каршы сугыш булачак, көчләр тигез түгел. Иван белән Булат бәк берләшсә, аларны кырып салачаклар. Казаннан качып, Нугай-Кырымга йөреп, гаскәр туплап, Мәскәү гаскәренең артына төшү иң мәгъкуле, дип хәл кылдылар һәм, суеш башланырга ике сәгать кала, җиде төн уртасында, Кошчак белән өч йөз углан, хатыннарын, балаларын калдырып, Алабуга капкасыннан шыпырт кына чыгып качтылар. Бик озак баргач, куучылар юклыгына инангач, гаскәр сулышка туктады.

Таң алдыннан Кошчак угланның качып киткәнлеге турындагы хәбәр тиз таралды. Шул сәгатьтә үк Иван да бу турыда белде. Доньял купты. Сугыш туктатылды. Казан карышмый иде инде. Булат бәк тә, Иван да Кошчакны куарга өч юлдан гаскәр юллады.

Кансыз Иван өчен бу хәбәр бер яктан сөенеч—Казан рәһбәрсез калган, икенче яктан ул Кошчакның качып котылуыннан, аның Нугай-Кырымнан куәтле гаскәр алып, хәтәр һөҗүм итүеннән курка иде.

— Тереләй алыгыз! Тереләй!—диде Иван.—Кошчак өчен саф алтын белән түлим, дәрәҗә бирәм, ун елга салымнан азат итәм.

Шулчак Иван чатырына Булат бәк чапкыны Җонай мирза ишелеп керде:

— Олуг бәк Булат... Ширин әйтте: Кошчак углан өч йөзләп кешесе белән Алабуга юлына төшкән,—диде.

— Дөрес!—диде Иван.—Кырым юлыннан китсә, ул Кошчак булмас иде... Ул кичүдә кем тора?—дип, Иван якыннарына дәште.

— Нократ кичүендә Бәхтияр Зюзин,—диде Алексей Ершов.

— Тиз!—диде Иван.—Суюрга башлык белән Федька Пахловны чакыр! Күп тә узмастан, ишектә чакырулы Суюрга башлык, Пахлов пәйда булды. Иван сәлам урынына сүз башлады:

— Сезгә бик олы эш йөклим, мин әйткәнчә, башкарып чыксагыз, олы бүләкләр алырсыз, кызганмам. Суюрга башлык—үзенең атлы укчылары

белән; син, Федор Пахлов, мылтыкларың, кылычларың белән Кошчактан алда — Нократ кичүенә, аңа өлгермәсәгез — Алабуга кичүенә барып җитәргә тиеш. Бөтенесен кырырга мөмкин, әмма Кошчак миңа тере килеш кирәк.

Кошчак углан алга да, арка якка да унар-унар каравыл куйды. Нократ кичүенә җитәрәк, алгы унлыкның бик каты чабып кире килгәне күренде. Бер-бер хәтәр хәл булганы ап-ачык иде. Кошчак углан гаскәрен туктатты. Иң алдан Барбулсын бәк килеп җитте. Аның йөзе каушаулы иде.

— Анда... кичүдә бик күп гаскәр...— диде бәк.— Татарлар да, урыслар да, чирмешләр дә тулган.

— Күпме? Биш йөз? Мең?— диде Кошчак.

— Шөкран булыр иде,— диде Барбулсын бәк.— Өч мең бар да бар. Күбесе кяфер, барында да — утчагар.

Ул арада арка унлык та чаптырып куып җитте. Бу унлыкта Ишмөхәммәт мирза башлык иде.

— Арттан урыслар килә,— диде мирза.

— Күпме?— диде Кошчак.

— Мең чамасы,— диде Ишмөхәммәт.

Кошчак әйтте:

— Вакыт тар,— диде.— Уңга кереп, Чулмангача барырга. Урманда саллар ясап, Чулманны кичәргә — башка юл юк. Йөзә белгән — үзе йөзеп чыгар. Өч йөзебездән өч кеше булса да исән котылырга тиеш...— Ул кинәт сүзен өзде, аның йөзе үзгәрде, үзе салмак-сабыр гына өстәде:— Бер кеше булса да, Чулманны чыгып, Кырымга җитәргә тиеш. Ул кеше җитә алмаса, менә бу хат җитәргә тиеш. Кем яхшы йөзә?

— Мин!— диде берәү. Бу Сулыш атлы яшь углан иде.

Кошчак су үтмәслек итеп тегелгән тире букчага салынган хатны бирде. Күп итеп алтын-көмеш акча салынган котыйчыгын угланга тапшырды.

— Атың үлсә — ат алырсың, үзең үләсе булсаң, кеше яллап, хатны Сәхип Гәрәй ханга җиткез!

Гаскәр уң кул якка, тар сукмактан урманга кереп китте. Качкыннар озак-ерак йөрде. Туктап-туктап хәл алдылар. Атлар яфрак, үлән ашый; адәмнәр ач, өйдәгеләре ашык-пошык кына салган ләвәш, салкын ит кисәкләре күптән бетте: бишенче көн йөриләр. Угланнарның җиләк тапканы — җиләк каба, сөтле чикләвек чәйни, кемдер учлап-учлап сәрдә, юкә яфрагы ашый... Алар Чулман ярына чыкканда таң аткан иде. Ярның сөзәк урынын эзләп табып, яр урманында бүрәнәләр кисеп, аска тәгәрәтә башладылар. Эш гаять авыр, бик әкрен бара, өч йөз угланга нибары ике балта алганнар. Кем уйлаган, дала-ялан егетләренә урман кисәргә туры килер дип. Нечкәрәк бүрәнәләрне алмашлап кисеп, сал бәйли башладылар. Сөембикә биргән аз-маз хәзинәне һәм йөзә белмәгәннәрне төяп, колга, ишкәк сыман нәрсәләр юнып, беренче салчыларга тоттырдылар. Атларның тезгеннәрен сал койрыгына тактылар; салга сыймаган йөзә белер-белмәсләр ат койрыгына тотынды. Ике сал ярдан аерылганда күке кычкырганы ишетелде. Кошчак углан сагайды. Күкедән соң ук сандугач сайрап алды һәм янә өч тапкыр күке кычкырды. Бу — каравылның афәт хәбәре иде. Ул арада сызгырып хәбәр бирүчеләр дә урманнан яр кырыена атылып чыкты.

— Ике яктан да гаскәр йөри!— диде яшь углан.— Безнең эздән... Яр буйлап та... Арттагысы меңләп булыр... Яр буйлап аннан да күбрәк...

Мәсьәлә ачык иде. Салдагылар яр буйлап килүче дошманны алдан күргән, эшне аңлаган иде. Сулыш углан сал уртасына басып, тамак киереп:

— Яр буйлап яу килә-ә!— дип кычкырды.

— Тизрәк, тизрәк!— дип кычкырды Кошчак углан.— Без орышабыз, сез тизрәк ишегез!

Колгалар, ишкәкләр тизрәк кыймылдый башлады. Эздән килүче дошманнар берәм-берәм сукмак авызында күренә башлады. Вакыт сузарга ярамый иде.

— Сугышып үләбез!— диде Кошчак, ике йөз сиксән кешесен икегә бүлеп:— Барбулсын белән Торгы бәкләр дошманны яр буенда каршы ала! Мин — урманнан чыкканнарны!

Яр буйлап килүче дошман йөзләп утчагар мылтыктан сал өстендәгеләргә ата башлады. Ядрәләр, чупырдап-чупырдап, суга борчак сипкәндәй, салның алдына да, ян-якларына да, арттан да коела.

Кошчакныкылар урманнан чабып чыккан һәр урысны кылычка ала торды.

Барбулсын белән Торгы кешеләре, яраланган арсланнардай, меңләгән мылтыкчыга ябырылды.

Сал ягындагы су баганачыклары кими төште. Салдагы берничә углан, яраланып, суга егылды, саллар уртасында да җансыз гәүдәләр бар иде.

Яр буенда сугыш кызганнан-кыза бара. Урыслар башта каушабрак калды, шулчакта угланнар аларны байтак кырды. Хәтта алгы мылтыкчылар урманга таба йөгерә башлады. Ләкин воевода Федька Пахлов белән Бәхтияр бөтен гаскәрне аларга каршы борды. Йөгерүчеләр кире борылды. Ике арада атыш башланды. Бәхтияр укчылары Барбулсынга таба болыт-болыт ук ата. Барбулсынныкылар да ук белән җавап кайтара. Барбулсын, ничәнче тапкыр инде, угланнарын кургаш ядрәләргә, укларга каршы әйдәде. Угланнар азайганнан-азая, исәннәре дә һәр һөҗүм саен җәрәхәт алып кайта, дисталәгән батыр угланнар ат югалтып, яра алып, әсир төште. Барбулсын батыр саллар ягына күз салды. Ишкәкчеләр бик аз калган, бер сал үз иркендә салмак кына агып бара: өсте тулы мәет. Икенче салда әле җанлылар бар, икәүмеөчәүме... Барбулсын соңгы һөҗүмгә унбишләп кенә егет белән китте. Барбулсынның уң кул башына кургаш ядрә тиде. Кулыннан сөяк саплы жандусты — кылычы төшеп китте. Уң кулы ихтыярсыз салынды. Шул мәлне үк ул дошман өере уртасында калды. Тере булсалар да, угланнар сугыша алмый иде инде: алар арасында җәрәхәтләнмәгән кеше юк иде. Боларга аркан-богау ыргытып, бәйләп ташладылар.

— Салга-а! — дип кычкырды Федька Пахлов.

— Салга-а! — диде Бәхтияр.

Яр буен төтен, сөрем каплады. Чулман өстенә ук болыты эленде. Уклар да, ядрәләр дә бер ноктага — салга төбәлгән иде. Сал өстендә хәрәкәт туктады. Бер углан, аягүрә басып, киерелеп, сыны катып торды да, аркасы белән суга ауды. Аның аркасына, биленә, артчүмеченә, кулларына илледән артык ук, йөзләгән ядрә тигән иде. Салда калган мәетләр дә, тегүче кулындагы мендәрчеккә кадалган йөз энә кебек, уклар белән чуарланган килеш хәрәкәтсез ята.

Барбулсын, телгәләнеп беткән иңбашыннан шаулап кан акса да, кашындагы кылыч ярасына тир кереп әчеттерсә дә, Чулман-суга, беренче сал ягына иңерәеп, чекерәеп карый. Кыймылдарга сәләтле, әмма богаулы сул кулының иңбашы белән уң күзенә агып кергән канлы, әче тирене сөртеп, янә су өстенә бага. Хәзинә төялгән беренче сал да ихтыярсыз гына бу як ярга якыная, түбән таба ага, хәзинә капчыгы өстендә аркылы-торкылы ике гәүдә ята... Чулманның теге як ярына таба өчәү йөзә, берсе бик тиз йөзә, арттагы икәвесе бер-бер артлы янәшә йөзә, акрын йөзәләр... Дошманнар укларын, ядрәләрен шул өчәүгә күчерде. Ләкин ядрәләр аларга барып җитми, суга төшеп чума. Беренче йөзүче ярга чыкты. Бу ат иде. Хайван, калтыранып-дерелдәп, суны койды да, шундук яр үләнен чемчи башлады. Икенче йөзүче белән өченче йөзүче дә ярда аякланды. Болары Сулыш углан белән аның Җирҗимер исемле аты иде. Сулыш Җирҗимер койрыгына ябышып йөзгән икән; димәк, ул да каты җәрәхәтле. Сулыш, сул кулын күкрәгенә куеп, беренче чыккан ат янына килде. Аның атлавы төз түгел, арган, җегәре киткәнме, әллә хәлкәйләре мөшкелме? Тезгенне чишеп, озынрак бауга бәйләде, бауның очын Җирҗимер ияренә такты; үзе, салмак кына, көчкә генә, Җирҗимергә атланды. Сул кулы һаман күкрәгенә кысулы. Сулыш углан, бу як ярга борылып карады да, атлары белән бергә чаукалыкка кереп югалды.

— Хуш, бәхил бул! — дип пышылдады Барбулсын. — Кырымыма сәлам күндер. Хуш, Сулышбәй батыр. Кайтып җитә күр. Сулышбай туган, Кырымбызга. Сөйлә туганнарыбызга: ничек орышты Кошчакныкылар, диң... Сөйлә: онытмасын безне халык, онытмасын...

Кошчак угланның да хәлләре мөшкелдән мөшкел иде. Алар башта эздән килүче дошманны бик күп кыра торды. Әмма, арттараклар урман эченә таралып, агачларга посып, күпләп мылтык ата башлагач, хәл үзгәрде, ялангачы атлылар еракка, ядрә җитмәс арага чигенде. Кошчак ярсып-ярсып сүгенде. Мылтыклылар атларына качып якыная, ата. Кошчакның чигенергә урыны калмады.

Кошчак атлар артына качып ата торганнарга бик күп ук аттырды да, кылыч һөҗүменә күчте.

Урысларның бик күп аты үлде, яраланды, мылтыкчылар урманга кереп качты. Татар атлылары, аларны куып җитеп, атсыз калганнарның күбесен кырып бетерде, ләкин урман эчендәге мылтыкчылар якын килгәннәрне мылтыкка ала башлады. Кошчак, бик күп атларны, угланнарын урман янында калдырып, кире чикте. Шулай тәбегә эләккән кебек орыша торгач, Кошчак янында корал тотарлык нибары егерме дүрт кеше калды. Аларының да җидесе атсыз, күбесе яралы иде. Кошчак угланның уң тез күмәче ядрә тиеп чәрдәкләнде. Урманнан бик күп кяферләр берьюлыҗ чыгып, аларга аркан ташлады. Ул арада яр буендагылар килеп, Кошчакның ярга сикерү юлын да каплады.

Кошчак углан Чулман өстенә каерылып бакты. Аның йөрәге жуылдап алды. Чулман гамьсез генә ага. Салларның берсе күренми, теге якта да юк, бу якта да юк, димәк, аны бу як яр каплый. Икенчесен бер өер урыс, тимер башлы аркан ыргытып, ярга чыгарырга тели: хәзинә дошман кулына кереп бара. Арканчылар, ниһаять, салны эләктереп ярга чыгарды. Аркылы-торкылы яткан мәетләрдән кылыч, хәнҗәр алып, кесәләрен актарып,ниләрдер алдылар; күн итек-читекләрен салдырдылар да, таланган мәетләрне суга этеп төшерделәр; мәетләр, бер бата, бер калка, ашыкмыйча гына йөзеп китте.

Шулчак яр буендагы богаулы угланнарын күрде Кошчак, алар унау иде, канга баткан Барбулсынны ул чак таныды. Аларның карашлары очрашты. Кошчак углан карашы белән тилмереп сорый: Сулышбәйне дә үтерделәрме, суга баттымы?

Барбулсын углан ишетелерлек итеп әйтте:

— Җирҗимер исән чыкты,— диде.

Кошчак угланның чырае яктырып китте. Шул мизгелдә үк аның йөзен каты әрнү каплады. Җиңелү әчесе дә, тезенең әрнүе дә берьюлы сызлану булып биткә чыкты. Чәрдәкләнгән аягы белән йөгереп-качып китәр, дипме, әллә Иванның боерыгын арттырып үтәр өченме, бичара Кошчакны селкенмәслек итеп бау белән урап куйганнар. Кырык алты кешене, авыр җәрәхәтле әсирләрне арбаларга төяп, Нократ кичүенә алып килделәр. Кичүдә Иваннан килгән чапкыннар аларны көтә иде. Алар боерык китергән, хәбәр алырга килгән: әсир төшкәннәрне, Кошчак угланны Казанга кайтарып тормаска, су юлы белән туры Мәскәүгә озатырга, Иван кайтканчы тере килеш, зинданда сакларга, диелгән иде боерыкта...

## Каргыш

Кошчак углан киткәч, Казан бичара хәлдә калды. Сөембикәне, углы Үтәмеш Гәрәй хан вә ахирәтләре белән үз йортына бикләп, капкаишекләргә сак куйдылар. Кошчак белән дустанә яшәгәннәрне, хәтта аның каһарманлыклары белән сокланган үсмерләрне дә зинданга яптылар. Карышканнарны шундук чаптылар, кистеләр. Кошчак углан белән киткән өч йөз баһадирның хатыннары, балалары, якыннары да үз йортларында тоткын сыйфатында яши башлады. Шәһәрне шом басты. Элек мыштым яшәп, астыртын эш корганнар өскә чыкты: аларга бәйрәм килде.

Кошчак углан китеп ике атна узгач, Сөембикәгә әче хәбәр килде: Нократ кичүеннән астарак, Чулман ярында Кошчакныкыларның барысын да кырып бетергәннәр, имеш. Бәхтияр-динсатар, урыска артык ялагайланып, җәрәхәтле Кошчакның башын чабып өзгән, иллеләп угланны әсир итеп, Мәскәүгә озаткан... Хәзинә белән Сәхип Гәрәй ханга аталган хатның язмы

шы турында бер сүз дә әйтүче булмады. Барысы да дошман кулына төшкән, дип уйлады Сөембикә... Кошчакның үлем хәбәре Сөембикәне аяктан екты. Җан Галинең фаҗигасе аның өчен иң беренче олы кайгы иде. Сафаны шымчылар агулагач, шуннан да олы кайгы юк сыман иде: Кошчак угланның үлүе, хатның дошман кулына төшүе алдагы фаҗигаләрдән дә хәтәррәк иде.

Сөембикәгә хәбәр итмичә генә, ханны чакырмаенча гына, Булат бәк дивани бәкләрне җыйнады. Нәтиҗәдә, Мәскәү белән Казан арасындагы бу сугышны вакытлыча гына булса да туктатырга кирәк табылды, солыхнамә язылды.

Мәскәү явы, су юлларын, кичүләрне үз кулында тоткан хәлдә Казанны камауны туктатты, Иван, гаскәрен алып, Казан каласына һәр кергәнне, шәһәрдән һәр чыкканны тикшереп-тентеп торыр өчен җитәрлек гаскәр-каравыл калдырып, Зөя каласына күчте.

Солыхтан соң бәкләр тагын диванга җыйналды. Карала торган мәсьәлә яңа хан сорау булып, Иван патшадан Казан тәхетенә Шаһ Галине җибәрүне үтенеп, Зөягә илчеләр күндерү иде. Төмән бәк, Бибарыс бәк бу йомышны үтәп кайтырга тиеш булды. Әлеге хатка өстәмә рәвештә яңа шарт, яман шарт язылып куелды: Сөембикәне, углы Үтәмеш Гәрәй ханны сиңа тоткын сыйфатында бирәчәкбез, син безгә, зинһар, Шаһ Галине генә җибәр, дип, Булат бәк үз кулы белән өстәде.

Бу илчелек артыннан ук икенчеләре — Нургали бәк белән Ходайкол углан Иванга яңа шартнамә алып китте:

— Казан йорты сиңа табына, бар ягыбызны үзеңчә кыйл! — дигән сүзләр дә Булат бәк кулы белән язылган иде. Углы Нургали бәк аны Иванга үз кулы белән тапшырды.

Егерме көнлек кыска вакытлы бу тынлыкта Казан язмышы хәл ителде. Чынлыкта исә Казан Мәскәүгә тез чүкте. Иван, мондагы эшләрнең үз файдасына хәл ителәчәген күрепме, Литва-Польша ягы кыймылдый башламагае дипме, Мәскәүдә аны сөймәгән баярлар фетнә ясап ятмыймы дипме, гаскәрен калдырып, тиз генә Мәскәүгә кайтып китте.

Казан илчеләрен озаткач, Шаһ Гали өенә кайтып егылды.

— Ни булды? — диде Фатыйма солтан. Шаһ Гали Казан эшләрен сөйләде:

— Ахшамнан соң ук воеводалар, баярлар олы киңәшкә җыйналасы. Киңәш рәһбәре итеп Иван мине калдырды. Мин нишләргә тиеш?

Фатыйма солтанның җавабы күптән әзер иде:

— Үтенәләр икән, тәхетне кабул кыйл! Баш тартмаң! Әмма үзең дә шарт куй. Әлбәттә, син куйган шартны урыс җә үтәр, җә үтәмәс, җә әз-мәз үтәр, әз-мәз үтәмәс. Шулай да... ятып каласыңмы, атып каласыңмы — син Тау ягын кайтаруны шарт ит!

Ахшамнан соң Шаһ Гали, хатыны ни әйтсә, шуны авыз эченнән кабатлый-кабатлый, калгай йортына киңәшкә китте. Воеводалар, баяр угыллары, кенәзләр аны көтә иде. Зөя калгае буларак та, элеккеге хан буларак та Шаһ Гали сүз башлады:

— Кенәзләр, баярлар, сугышчы-воеводалар! Минем Казан тәхетенә хан насыйп ителмешемә бөек кенәз, бөтенрусиянең олуг падишаһы Иван Васильевичның фатихасы бар... Әмма мин элеккеге Казан җире — Тау ягының Мәскәү тарафында булуына каршы. Тау ягы кайтарылса...

Аңа сөйләп бетерергә ирек куймадылар. Бөтен киңәшчеләр берьюлы гүелдәп ризасызлык белдерде.

— Бу була торган гамәл түгел! — диделәр. — Бу мәсьәләне кабат кузгатмаска! Кузгала калса, Иван Васильевич Казан тәхетенә бүтән хан насыйп итәр!

Бу сүзне ишеткәч, Шаһ Галинең ихтыяры ишелде дә төште. Киңәш шуның белән тәмам булды. Рөхсәт сорап тормыйча гына, воеводалар, баярлар чыгып китте. Әле киңәшәсе сүз бетмәгән иде, шулай да баярлар, юк йомышны бар итеп, бер җилләнеп керде. Бу эш: без бер сүзне ике сөйләшмибез, дигән мәгънәдә иде. Капка төбендә, күчә якта Казаннан килгән илчеләр

көтә. Шуларны чакырттылар... Касыйм мулла белән Бибарыс бәк, бик күп мирзалар, ишектән керүгә буй сындырып, сәлам тәгъзиме ясады.
— Аллаһ тәгалә бөек падишаһ, бөтенрусиянең олуг кенәзе Уасили углы Иванга сәламәтлек, озын гомер вә бөек җиңүләр китерсен!
— Амин!— диде баярлар.
— Гозеребез Ак падишадан шулдыр ки, камауны мотлак алып, Казанның азат яшәешенә юл куйсын иде. Олы гаскәр Мәскәүгә китсен иде. Әмма Казан Мәскәү химаясында калсын иде,— диде Касыйм мулла. Бәкләр аның сүзенә куәт биреп:
— Дөрест, дөрест! Вә һәм Тау ягыбызны падишаһ безгә кайтарса иде...— диде.
Воеводалар зык купты. Кызып китеп, татарлар да үзләренең хаклы икәнен исбатларга тотынды. Алар бәхәс шаукымында буталып, татарлар — урысча, урыслар — татарчага күчеп, эшне үз файдасына каерырга тырышты. Әйткәләшү озакка сузылып, татар илчеләре — тирләп, хәлсезләнеп, урыслар — тагын да катырак әйтү өчен, тын алырга туктады. Баярлар үзара, татарлар үзара киңәшә иде. Бары тик Шаһ Гали генә ялгыз башы түрдә утыра калды. Татарлар да, урыслар да аннан киңәш сорамый. Ниһаять, баярлар ягы сүз алды:
— Әгәр дә, Казан тулаем Иван патшага баш ормаса, шушы көзне Казанга тагын да зуррак яу белән йөриячәк. Бер казанга ике тәкә башы сыймый.
— Бәс,— диде сөйләүче баяр.— Сөембикәне, углы Үтәмеш Гәрәй хан белән, монда, Зөя каласына китерәсез. Рус тоткыннарын бөтенләе белән азат итәсез. Бу хакта кабат сүз булмаячак! Бетте!
Татарлар авыз ачканчы, воеводалар, баяр угыллары калгай өеннән чыгып китте... Казан илчеләре, әле — пошмас Шаһ Галигә, әле — бушаган урындыкларга карап көрсенде дә, сөмсерләре коелган килеш, боек кына Казанга кайтып китте. Атларны куаларга, дәртләнеп чабарга әчтә дә, тыштa да куаныч юк. Шартлар үтә дә кырыс иде: Казанга кайтып, Зөядә — калгай йортындагы киңәш хәлләрен алар дивани мәҗлестә сөйләп аңлатты.
— Нишлибез?— диде Булат бәк Ширин. Диван бәкләре телсез иде.
Булат бәк тагын да катырак итеп сорады:
— Нишлибез, ил агалары?— дип, Бәйгер тархан тамак кырды.
— Әйдә, әйдә, Мөхәммәт Бәйгер ага,— диде Булат Ширин.
Бәйгер тархан тагын тамак кырды, тәсбихын тарткалап алды, ул да кыюлык бирмәгәч, мендәр почмагындагы йонны ике бармагы белән тотып бөтергәннән соң, кыяр-кыймас әйтте:
— Без, кыхым, ие... болай сүзсез утырсак, таңгача таралмасбыз, ие... Ә урыс җавап көтә. Шарт белән килешсәк — без Аллаһ тәгалә каршында да... халык алдында да, дигәндәй... гөнаһ кылган булырмыз, ие...
Нургали бәк, түземсезләнеп, урынында кымырҗып алды да картны бүлде:
— Син, Бәйгер ага, сүзеңне әйт, сузма!— диде.— Шартны үтәмәсәк тә безгә фәтүә юк!
Олы Тархан, яшь бәкнең кайнарлануын сабыр гына тыңлап бетерде дә, форсат чыккач, тавышын һич үзгәртмәенчә, сүзен дәвам итте:
— Ие... бик зур гөнаһ кылган булырбыз... Шартлар белән килешмәсәк тә — дөрес әйтә Нургали карачы — килешсәк тә фәтүә булмас. Ләкин сез, карачылар — ил агалары, олы мәртәбәле бәкләр, гаскәр рәһбәрләре, сез уйлап бетердегезме соң, килешмәсәк — сугыш; сугышта, ягъни җиһад-газават юлында шәһит китәчәкбез. Килешсәк — ягъни мәшһүр Сөембикә ханшаны да, үзебезнең Казан ханын да, үз кулыбыз берлә тотып, кяфер кулына тапшырачакбыз. Киләчәк оныкларыбыз, туруннарыбыз безнең турыда ни уйлар? Тау ягын кайтарып алмасак, туфрагыбызга үз ихтыяры белән басып кергән һәм безгә әсир төшкән кяфер баскынчакларны да кайтарып җибәрсәк, Казан казнасына да, Казан халкына да һичбер файда кылмаган һәм кылмаячак мәнсез Шаһ Галине хан алсак, бу үзе әҗәлдән дә хәтәррәк түгелме соң, ил агалары? Фикерем шул, мөхтәрәм җәмәгать,— диде аксакал.— Истанбул, Кырым, Нугай безне бичаралыкта калдырмас, ихтимал.

өметләник әле, ие... Аңынчы шәһәрне бирмәскә, орышырга. Дары беткәч — ук атарбыз, ук беткәч — таш атарбыз; таш беткәч, бил хәнҗәре бар... Сүзем тәмам!

Мөхәммәт Бәйгер тарханны яклаучылар кыюланып сүз әйтте:

— Ярдәм килгәнче орышырга!

Булат бәк кул күтәрде:

— Беркайдан да ярдәм көтмәгез! — диде ул. — Бөтен Нугай мирзалары — Иванның дусты. Йә алар Иван ягыннан орышачак, йә бер якка да катнашмаячак. Кырымның үзендә суеш бара. Сәхип Гәрәй ханны тау арасында суйганнар!

— Ә?.. Ничек?! — дип беравыздан кычкырды бәкләр, болар бар да Сафа Гәрәй, Сәхип Гәрәй ханнарны олылаучылар иде.

Хәтәр хәбәр иде бу. Булат бәк соңгы өметне өзде дә ташлады. Булат бәк ике максатка ирешә: бу хәбәрне кинәт әйтеп, ул Кырым — Сөембикә яклыларның кем икәнен ачык белде һәм Кырымнан ярдәм килүенә өметләнгәннәрнең рухын, ихтыярын сындырды. Кемдер, йөрәгенә энә чәнчегәндәй, авыр сыкранып куйды. Булат бәк идарәне тулысы белән үз кулына алды. Ул янә әйтте:

— Сафа Гәрәй ханның уртанчы улы Бүләк Гәрәй — ханны үтерүче!

— Бүләк Гәрәй солтан? Ни өчен?

— Кем белә? — диде Булат бәк. — Анысын бер Алла beләдер!

Мөхәммәт Бәйгер тархан үз алдына әйтеп куйды:

— Сөләйман кануни... яки Иван котыртыгы... — диде.

Шартлар куелганның өченче көнендә Казанның Нургали капкасыннан бер алай атлылар чыкты. Бу — Казан илчеләре Нургали бәк, Ходайкол углан, Бәйгер тархан вә бәгъзе бәкләр, мирзалар иде. Аларның барыр юлы — Зөя каласы. Аларның максаты — Иван шартларына кул куеп, мөһер басу...

Килешү тәмамында Шаһ Гали канәгать баярлар исеменнән татар илчеләрен сыйханәгә чакырды. Табын-сый бик тә мул иде. Воеводалар, баяр егетләре, Казан илчеләрен артык үҗәтлек илә кыстап, сыйларга тотынды. Нургали бәк белән Ходайкол углан мәҗлес башында ук исереп бетте: аларга хәзер ике дөнья бер моржа, моржа саен бер маржа иде. Бәйгер тархан гына мәҗлескә бармады. Төнгә каршы, ялгызы гына, илчелекне саклый килгән угланнарга да әйтмичә, атына атланып, Казанга кайтып китте.

Шул төнне Бәйгер тарханның аты өенә буш ияр белән кайтты.

Аның мәетен урманнан таптылар. Ике-өч көн яткан мәетне танырлык түгел иде. Затлы хәнҗәре дә, алтынсулы кылычы да, кыйммәтле киемнәре дә юк, әллә юлда ташлап калдырган, әллә талаганнар — мәгълүм түгел. Бераз читтәрәк Бәйгер тарханның тамгалы тәсбихен тапмаган булсалар, мәетне танымаган да булырлар иде.

Сөембикәне, Үтәмеш Гәрәй ханны алыр өчен, Петр Серебряный бик күп баярлар, сакчы гаскәр илә Казанга килде: өч мең санындагы гаскәр Казан капкасыннан узды. Хан күчәсен тутырып, Сөембикә йортын камады. Булат бәк, җинүче гаскәр килгәч, үз каравылын Сөембикә йортыннан алды.

Ничә көн, ничә атналар буе, караңгы төшсә дә, Сөембикә ут кабызырга, чырак яндырырга кушмады. Хәтта көндезләрен дә ул тәрәзәләрдәге кояш каплавычларын ачтырмады. Яктылык та, җылылык та, һава да аңа кирәк түгел иде инде. Урамнан, күчәдән узучылар шомлы, караңгы тәрәзәләрне күреп сызлана, сызланмаганы сөенә.

Үзенә-үзе кул салмагае, дип Булат бәк ишекне ватарга кушты. Ике алып ишеккә иңнәре белән каты бәреп тә ача алмады. Бүрәнә-дөмбе белән бәрергә булдылар. Эчтән тавыш ишетелмәгәч, Булат бәкнең шиге калмады: Сөембикә ахирәтләре белән агу эчкәндер, дип уйлады ул. Дөмбе белән бәрә башлагач, эчтән аваз килде:

— Ишек ачык! — диде Нәргәтай. — Тартыгыз!

Ишек электән үк бикле булмаган икән. Бармак белән тартуга ачылды да китте. Булат бәк, каударланып, эчкәригә йөгерде: Сөембикә дә, ахирәтләре дә, Үтәмеш тә исән-сау, ләкин алар шәүләгә әверелгәндәй тавышсыз, хәрәкәтсез утыра. Җавап бирүче булмагач, Булат бәк чыгып китте: акылдан

язган болар дип уйлады ул. Булат бәк кешеләре ишекләрне яба чыгарга онытты. Шуннан соң ишекләр гел шулай ачык килеш калды. Әнчекләре белән Булат бәк чыгып киткәч, Сөембикә беренче сүзен әйтте:
— Кошчак углан Кырымга, Нугайга кеше җибәрә алмаган, мәрхүм,— диде.
— Җибәргәндер, бикәм,— диде Нәргәтай.— Кешесе барып җитә алмагандыр... Кырымга җитсә дә...
Нәргәтай сүзен өзде: «Барып җитсә дә, Кырым монда килмәс. Сәхип Гәрәй хан үтерелмеш, кем Казанны кайгыртсын?» — дип әйтсә, хуҗабикәгә авыр булыр иде.
— Димәк, корылтай мине бәйләп, урыска озатырга карар кылган? Рәхмәт! Сагъ улсыннар!— диде бикә.
Аның сүзләре салмак, күкрәктән чыга.
Нәргәтай аягүрә басты, бүлмәдән чыкты. Сөембикә һаман хәрәкәтсез утыра калды. Караңгыдан тагын бер шәүлә калыкты, бу — Үтәмеш хан иде.
— Анам,— диде сабый.— Карыным ачты... Тамагым кипте-е...
Сөембикә ишарәләде, эчкәридән шәүлә чыкты: бу — सауфия иде. Сауфия Үтәмешне алып китте. Аскы каттагы ризыкханәдә кашык-аяк шалтыраган ишетелде. Сөембикә үзалдына әйтте:
— Ихтимал, Колынчыгым, бу синең Казаныңда соңгы тапкыр тәгам җыюыңдыр...— диде. Бикә «Янмас кыз» бәетен көйли башлады.
Эчкәридән Нәргәтай чыкты. Ул, тавышсыз гына килеп, бикәсе янына тезләнде дә, пышылдап кына:
— Барысын да шулай эшләдек,— диде.— Сандыклар аскы юлдагы куышка куелды. Куышны кирпеч белән каплап, үзле балчык сылап каралталар.
— Алар кайткач, аскы юлны томалат!— диде бикә.
— Шулай булыр, диде Нәргәтай.— Әмма, бикәм-җаным, нигә боларын яшермисең?
Нәргатай сәке өстендәге, келәмдәге вак сандыкларга, затлы дирбияләргә, көмеш өзәңгеләргә, алтын тәңкәле йөгәннәргә, кием-салым, туннарга ым какты.
— Ярамый!— диде бикә.— Күзләрен буяу өчен, болары калсын. Юкса, боларын да әэли башлаячаклар. Дөньяны актарып, тегеләрен дә табачаклар. Шушы әйберләр бугазларына тыгылсын кара йөрәкләрнең!— Сөембикә өстә яткан нәрсәләрне максатсыз гына актарырга тотынды.— Бусы — мәрхүм Җан Гали ханның хәнҗәре... Монысы — Сафамның кылычы... Кылычны син аскы юлдагы беренче куышка куеп томала...
Нәргәтай, Сафа Гәрәй хан кылычын алып, бүлмәдән чыкты.
Таң атып, кояш чыкса да, Сөембикә йорты караңгы килеш калды. Эчкәридә хәзинә яшерүче ахирәтләр, бераздан соң Нәргәтай күренде.
— Җә!— диде бикә.
— Күзгә чалына торган түгел,— диделәр.— Казаяк тамгалары салып чыктык. Өч урында — хәзинә турындагы казаякларның урта сызыгы кыскарак.
— Аскы юл томаланды, беленмәсен өчен, бөтен диварларга да күп итеп су сиптек,— диде Нәргәтай.
— Хуш!— диде бикә.— Хәзер, ялган юлларга арзанрак нәрсәләр тутырып, һәр юлга берәр сандык куеп чыгыгыз... Киемнәрегезне, муенсаларыгызны... соңра ялган юлны күселәр күрердәй итеп яшерегез. Җимерсеннәр, алсыннар. Шуның белән нәфесләре тыгылсын.
Шушы эшләр белән әвәрә килеп тагын бер төн узды. Үтәмеш бичара җыен хатын-кыз арасында нишләргә белми иде. Башта аңа бик күп әкиятләр, дастаннар сөйләде кызлар. Уку-язу белән мәшгуль булдылар. Ләкин оланга иркенлек, уен, һава, ат кирәк иде. Ул ишегалдына чыга чыгуын, бакчадан да әйләнә, әмма урамга, күчәгә чыга алмый. Ат сыртына атланып, ыргый-ыргый чабасы килә ханның.
— Их, атам исән булса,— дип үзалдына сөйләнә Үтәмеш Гәрәй хан.— Атай исән булса, атай исән булсамы?.. Кирәгегезне бирер иде ул сезнең.

Үтәмеш ачык хәтерли.

...Сафа Гәрәй хан, иияргә менеп, улы Үтәмешне үз алдына утыртты. Ияр җәясенә ике куллап ябышып, Үтәмеш анасына карады. Сөембикә елмая иде. Елмаймаслыкмени?! Кечкенә башлы, нәзек муенлы, нечкә сыйраклы, чынаяк күзле, без колаклы, озын торыклы бу җен айгыры Уктай бер урында тик тора алмый: куәтенә, йөрәгенең кагуына чыдый алмыйча, таптана, чыгымлап чигенә, авызлыгын кимерә, алга ыргып куя. Уктайның йөгәненә көмеш тәңкәләр тагылган, тирлек урынында — зәңгәрсу келәм, келәм өстендә — көмеш өзәңгеле ияр. Ияр өстендә шәм кебек туры аркалы Сафа Гәрәй хан утыра. Өстендә — алтын ука-чикмән, билендә — алмаз ташлы хәнҗәр. Үтәмешнең беренче тапкыр ат менүе иде. Баланың йөзендә курку катыш соклану уйный.

— Курыкма, улым, курыкма, колыным! — диде анасы Сөембикә.

Сафа Гәрәй хан, улын кысыбрак тотты да, кап-кара мыегы астыннан ап-ак энҗе тешләрен күрсәтеп, иркен елмайды... Тезгенне чак кына бушатуга Уктай, арт аякларын җиргә каты терәп, гәүдәсен алга ыргытты. Сафа Гәрәй артындагы угланнар да, йөз тояк тавышы чыгарып, ханга иярде. Ике егет, кулларына ялангач кылыч тотып, ханны узып, алга чыкты, егерме адымлап ара калдырып, алдан китте.

...Яшь ханзадәнең беренче тапкыр елкы җилкәсенә менүен бәйрәм итәр өчен, хан үз якыннары, мәшһүр батырлар, сарай бәкләре белән Ханболынга китеп бара. Күчәдәге, урамнардагы халык хан малаен алкышлый:

— Йөз яшә, Сафа ха-ан! Йөз яшә, Үтәмеш ханза-дә-ә! — дип кычкыралар.

— Ат менешең котлы булсын, Үтәмеш Гәрәй! Йөз яшәгән гәүдәң туган туфрагында булсын! — диләр.

Сабые курыкмасын өчен, биеклеккә ияләшсенгә, Сафа Гәрәй хан атын тыеп бара.

— Бу туфракта яралдың, Үтәмеш ханзадә, шушы туфрак гәүдәнә юрган булсын!

— Адәмнәргә кул изә, улым, сәламлә! — диде Сафа Гәрәй хан.

Үтәмеш ханзадә, бер кулын ычкындырып, халыкка сәлам бирде.

Сөекле ирен, күз карасы-улын озатып кергәч, Сөембикә атменеш бәйрәменә ахирәтләрен чакырды. Аның ишарәсенә мотрибчылар дәртле көй башлады. Ахирәтләре дә, Сөембикә дә бик тынгысыз, йөрәкләрендә шатлыклы ярсу иде.

Ул чагында дүрт яшендә генә булса да, Үтәмеш ачык хәтерли. Ханболында аны аталык Рәхыш баба ат өстеннән алды. Шул көннән ханзадә аталык Рәхыш тәрбиясендә булды. Рәхыш баба көн саен аны җайдак йортә, иярсез ат менеп йөрергә, ирдә чабарга өйрәтә башлады. Кая китте ул Рәхыш баба? Кинәт юкка чыкты да, Үтәмешне анасы йортына кайтардылар. Каядыр, зиндангамы китте, диделәр. Тагын бер вакыйганы ачык хәтерли Үтәмеш Гәрәй хан. Бик күп агайлар, аксакаллар, муллалар, кылычбазлар җыйналып, Хансарайдагы бик олы матур келәмгә бастырып, дүрт почмагыннан дүрт иң олы бәк, ян-яклардан урта бәкләр тотып, аны югары күтәрделәр дә:

— Ризамы, аксакаллар? — дип кычкырдылар. — Ризамы, бәкләр, мирзалар, угланнар? — дип янә сорадылар.

Тәхетханә эчен тутырып берьюлы:

— Риза! — диделәр.

Шул чагында и кызык булган иде! Өстән, биектән озын-озын ягирләр, олы гәүдәле бәкләр тәп-тәбәнәк булып күренә... Өч тапкыр ризалык алгач, аны келәмнән тәхеткә иңдерделәр. Бик кызык уен иде ул. Аннан соң, озак итеп хөтбә укыды Колшәриф мулла: аннан соң, янә тәхеткә утыртып, Үтәмеш Гәрәй ханны Казан иленә тугры булырга ант иттерделәр. Шулардан котылгач, ул аталык Рәхыш баба белән, чабышкайларга атланып, Арча Кырына, кылыч уены өйрәнергә китте. Ну-у, кылыч уенын күтәп ала иде Үтәмеш хан. Аның иң сөйгән ике эше бар иде: атта йөрү, кылыч чәкештерү...

Сабый Үтәмеш Гәрәй хан, бакчада ямь тапмагач, янә өйгә керде.

Шулчак күчәнең тышкы Ханкапка ягыннан тояк тавышлары ишетелде. Ишектәге, капкадагы Булат бәк сакчыларының:

— Киләләр!— дигәне яңгырады.

Нәргәтай, пәрдәнең кырыен күтәреп, күчәгә бакты да, хәвефле тавыш белән әйтте:

— Хансарай ягыннан Булат бәк үзенекеләре белән...— диде.— Тыш капкадан — урыслар... Һу-у, бихисап, агылалар... Урыс явы калага кергән...

— Димәк, капканы ачканнар...— диде бикә.— Димәк, Казанның бетүе шушы икән...

Килешеп куйгандай, ахирәтләр берьюлы елый башлады: аларга карап, Үтәмеш тә еларга әзерләнде, бер — анасына, бер елаучыларга карап:

— Анакай, безне урыс нә кыйлыр?— дип кычкырды.

Шул мәлне Сөембикә, юату урынына, ачуланып әйтте ки:

— Җитте! Туктаң!

Бу әмер, Үтәмешкә генә түгел, ахирәтләргә дә аталган иде. Ахирәтләр мышкылдашып елаудан тыйлыгып туктады.

— Күз яше әрәм аларга!— диде бикә.— Төзәнегез, ясаныгыз. Нәрсә тага аласыз — тагыгыз! Үтәмеш колынны да яхшы киендерегез, ул әлегә — хан!

Ахирәтләр, җәһәт ясанып, Үтәмеш ханга тәхет киемнәрен кигезделәр.

— Хәзер барыгыз да дога кылыгыз!— диде бикә.

Баскынчы гаскәр, күчәдән килеп, урамнарга тулды, тыгылды, атлар кешни, баскынчылар акыра, сөйләшәләр, көләләр.

Ачык ишектә Булат бәк Ширин күренде, ишек ачыклыгында артка борылып ул:

— Узыңызлар!— диде.

Йорт эче ярым караңгы иде. Булат бәк әнчекләренә ымлады: тегеләре, түргә узып, тәрәзәләрдәге коруларны каерып ачты, йолкып та төшерде. Өй эче күз чагылдырырлык яктылык белән тулды. Әчкәригә урыс башлыгы Петр Серебряный керде. Ул бәйрәмчә киенгән иде. Сул ягында — затлылыгы еraktan күренә торган, бик кыйммәт кылыч,— аеруча яхшы хезмәт кылганы өчен Иван патша бүләк иткән алтынлы кылыч иде ул,— ап-ак төстәге бармакчалар кигән, иңендә — кызыл комач ябынча... Сөембикә — түрдә, урта сәкедә; ахирәтләре — астарак, идән келәмендәге намазлыкларда сәҗдәгә киткән. Үтәмеш Гәрәй хан атасының карышкысын — уң кулына, сулына гәрәбә тәсбих тотып, тәхеттәге кебек, мәгърур утыра. Өй эче тып-тын... Петр Серебряный, бу тамашаны күреп, ишек катында ук туктады. Хатыннарның сәҗдәгә китүен ул бөек падиша, олуг кенәз Иван Васильевичка баш ору, мәрхәбә, рәхим итегез, без сезнең колларыгыз, дигән мәгънәдә аңлады. Әмма, баш ору озакка сузылгач, Булат бәккә бакты. Тегесе:

— Намаз!— диде.

Ул арада сәҗдәгә киткәннәр, баш калкытып, аягүрә торып, күкрәкләрендә кул кушырды. Шунда Петр әйтте:

— Мин — Иван патша илчесе, бояр Петр Серебряный!— диде.— Шартнамәгә карый, син, Сөембикә ханша, вә угълың Үтәмеш Гәрәй хан, вә синең бөтен хезмәтчеләрең, вә бөтен ахирәтләрен, вә Кырымлы, Нугайлы вә Казанлы бәкләр, угланнарның Мәскәүгә нәфрәтлеләрен вә хатыннарын мин Мәскәүгә алып китәргә мәҗбүрмен!

Ахирәтләр тагын сәҗдәгә егылды. Петр бу эшне янә коллыкка ризалык галәмәте дип уйлады. Сәҗдәдән соң тагын пышылдап дога уку башлады. Дога озакка киткәч, кенәз тагын Булат бәккә әйтте:

— Нәрсә, алар әллә чукракмы? Айлар буе караңгыда утырып, шашканмы, сукрайганмы?

— Намаз,— диде Булат бәк.— Намазны өзәргә ярамый.

— Алайса, Үтәмеш хан сүз әйтсен!— диде Петр.

Булат бәк ханга таба борылды:

— Әйт!— диде.— Яңа хуҗаңа бер-ике кәлимә сүз әйт!

Намаз укылып бетте. Бөркәвеч астыннан Сөембикә өйгә басып кергән түрәгә бакты.

Хан каушау курку вә нәфрәт аша әйтә алды:

— Мин, каным Чыңгыздан килә торган, икенче ягым канын Идегәй әмирдән алган бөек Хаҗи Гәрәй токымы, Сафа Гәрәй хан углы Үтәмеш Гәрәй хан, сүзем — сабыйның тавышы әкренлә ныгый барды, әйтерсең лә, ул усал-катгый хакимгә әверелде.— Казан гаскәре әле корал ташламаган. Капка сатлыклар, хаиннар тарафыннан ачылган. Мәскәү илчесе воевода баяр Петр Серебряный кулында — канунга яраксыз шартнамә. Ул шартнамәдә Казан ханының кулы вә алтын нишанлы мөһере юк. Хан рәсми рәвештә тәхеттин алынмаган. Бәс, бу шартнамә куәткә ия түгел!

Хан әйткәннәрне өч ахирәт бирәр данә язып, теркәп бара иде. Үтәмеш Гәрәй хан анасы ятлаткан сүзләрне ялгышмаенча, ачык итеп әйтеп бетерде. Сөембикә дәвам итте:

— Укыгыз шартнамәне!— диде ул.— Шартнамәгә имза куйган, үз тамгасын салган карачы бәкләрнең исемнәрен кычкырып укыгыз! Бармы анда Бәйгер тарханның аты?

Бәләкәй ханның гаять оста вә үткәзерлек итеп әмер бирүе, Сөембикәнең таләпчән сүзе Булат бәкнең өнен алган иде. Әмерне үтәргә туры килде. Бу хан бәтчәсен тиз генә арбага салып китеп булмый икән әле. Бөтен нәрсәне рәсмиләштерергә туры килә икән. Баяр Серебряный, шартнамәне сүтеп, укый башлады:

— Казан ягыннан шартнамәгә кул куйган, мөһер баскан бәкләр: Нургали бәк Булат углы, Ходайкол углан вә мирзалар.

Сөембикә кабатлап сорады:

— Бармы анда Бәйгер тарханның аты вә тамгасы? Бармы анда ханның имзасы вә нишаны?

Петр әйтте:

— Юк!— диде.

— Юк!— дип кабатлады Сөембикә.— Ялган шартнамә! Ни өчен юк Бәйгер тарханның кулы вә тамгасы? Чөнки Бәйгер тарханны үтерделәр. Аның хәнҗәр белән актарылган мәете Зөя белән Казан арасындагы урманда табылды. Дүрт карачының берсе генә кул куймаса да, шартнамәнең куәте югала!..

Петр Серебряный, урынында таптанып, табан алмаштырды, ул нидер әйтергә теләде, ләкин хан карышкысын күтәрде.

— Торып торың, Мәскәү илчесе!— диде Үтәмеш Гәрәй хан.— Һәм, ниһаять, күрсәтең миңа шартнамәне!

Петр Серебряный тәмам хан ихтыярында иде: ул, ханга якын килеп, шартнамәне сузды; хан, кәгазьне укып тормыйча гына, Сөембикәгә бирде:

— Сөембикә ханбикә, укы!— диде ул.— Кәгазьдә ханның алтын нишанлы мөһере, ханның янә бадәм тамгалы билгесе вә янә ханның имзасы бармы?

Сөембикә, шартнамәне укып чыкты да:

— Юк, ханым-солтаным!— дип, янә ханга тоттырды.

Үтәмеш Гәрәй хан, шартнамәне ерткалап, Петр Серебряныйның итекләренә ташлады. Серебряный хан тарафына кискен омтылган иде, Үтәмеш Гәрәй янә карышкысын күтәрде. Илче киредән үз урынына басты. Алып гәүдәле воевода Петр Серебряныйга сабый кулындагы карышкыны тартып алу авыр эш түгел иде, әмма ханның әмиранә утыруы, үзенең хаклы икәненә нык инанган булуы илчеләрне бераз шөбһәгә салган иде. Чынлыкта, Серебряный — чит туфракка, чит хан йортына рөхсәтсез басып кергән кеше. Аның максаты бу яулап алуга ничек тә рәсми төс бирү иде.

Сөембикә үзенең кол ханша икәнен бераз онытты. Колынчыгы Үтәмеш Гәрәй ханның басып алучы гаскәр башлыгына әмер биреп утыруын күреп, үкереп еларлык шушы кызык уенга катнашып китте. Үтәмеш Гәрәй тәхет өчен яратылмыш хан икән ләса! Ул тумышыннан хаким икән лә. Түрәлек•куәсе аның канында ук бар икән бит. Илаһем, җай чыгарып, бераз үсә төшкәч, Аллаһ Тәгалә кодрәте илә тәхет насыйп булса, җиһанга шөһрәтле хан булачак аның колыны. Күрегез сез аның мәгъруранә утыры-

шын, тыңлагыз санә сөйләш аһәңен, багыгыз сез аның кыяфәтенә. Ул — хаким, гадел хаким...

Җарияләр кулыннан ярлыкларны алып, хан эчкәригә узды. Сөембикә дә аңа ияреде, бернична ахирәт тә эчкәригә китте. Хан белән Сөембикә, һәр ярлыкны укып, дөреслегенә инангач, алтын нишанлы кәгазьгә кучереп язгач, барысына да имза салып, мөһер сукты. Нәргәтай дүртенче ярлыкны Сөембикәгә сузды.

— Бусы каян? — диде Сөембикә.

— Мин, сиздермичә генә чыгып, бу якта сүзен-сүзгә алтын нишанлыга яздым. Алар өч данәсен дә яндырачак. Бу нөсхәсен ышанычлы кешегә калдырып, ышанычлы илнең хакименә тапшырырга боер. Бөтен илләр белсен хакыйкатьне!

Сөембикә, ярсып, ахирәтен кочты:

— Җаным син, Нәргәтай ахирәтем, — диде ул, аннан соң дүртенче ярлыкны Гөлдәрә ахирәтенә тоттырды. — Син яшер ярлыкны. Монда калырсың. Бикә мине сөймәде, гел җәбер-золымда тотты, мин аңа хезмәт итмәсмен, качып калдым, диярсең. Җае чыккач, ярлыкны Кырымга озат.

Гөлдәрә ахирәт әйтте:

— Баш өсте, бикәм, шулай булыр! — диде.

Әзер ярлыкларны, тантаналы рәвештә, Петр Серебряныйга тапшыру булды. Шуннан соң теге әйтте:

— Ярлыкны олуг патша Иван Васильевичка күндерермен! — диде. — Хәзер юлга әзерләнегез, Зөя каласына!

Берәү дә селкенмәде. Баскынчы янә кабатлады. Сөембикә дәшмәде. Аның шомырт кара күзләре яшь белән тулы иде. Серебряный, кәттә кыяфәтен ташлап, катырып куйган төз буынын сындырып иркен атлап, Сөембикәгә бераз якынайды да, ипле-йомшак кына сүз башлады:

— Мәшһүрә ханбикә, һич хафа күрмәссең! Иван Васильевич сине хөрмәткә куяр. Бөтен Мәскәү баярларының сиңа олы сөйгесе бар. Углыңа да, якыннарыңа да һични булмас! Зинһар, Аллаһыгыз хакына киен!

Сөембикә ике учы белән йөзен каплады: ахирәтләре дә, ханбикә дә тавышсыз гына елый иде. Булат бәк ишарәләде: бернична урыс вә Булат бәкнең бернична кешесе өй эчендәге нәрсәләрне сандыкларга, капчыкларга, киң җәймәләргә өя, төйи башлады. Берәү дә сөйләшми. Хәтта Петер Серебряный да нишләргә белми: бары тик Булат бәк Ширин гына әйбер җыючыларны ашыктыра. Үтәмеш Гәрәй хан, бичара, карышкысын яшерер җай эзли иде. Карышкыны ул җиңенә тыгып карады, сыймады: аннан соң артына качырды; ниһаять, кеше күрмәгәндә генә, карышкыны, камәрен чишеп, эчкә, култык астына тыгып, камәрен эләктерде дә, сул терсәге белән иң кадерле уенчыгын — хан карышкысын кысты. Бу карышкыны заманында Туктамыш хан кулында булган, әүвәлендә бу карышкыны Олы Мөхәммәт хан тоткан, бу карышкы Сафа Гәрәй хан учында булган: сакларга кирәк. Сөембикәнең, ахирәтләрнең үз әйберләре салынган кул-сандыкларны алып чыгып, ат арбасына салдылар. Өй җиһазларын, ганимәт малын, хәзинәне Мәскәүгә озатыр өчен, исемлек язып алдылар.

— Көймәләргә төягез! — диде Петр Серебряный. — Каравыл җитәрлек булсын! — Аннан соң әкрен генә Сөембикәгә эндәште:

— Кузгалырга вакыт! — диде.

Дошман кулына бирмәскә теләгәндәй, ахирәтләре хуҗабикәне урап, кочаклап, тагын да катырак еларга тотынды. Сөембикә ишарә белән аларны тыйды да, күз яшенә тыгылып:

— Ахирәтләрем! — диде. — Мин сезне азат итәм. Сез үз ихтыярыгызда. Кем минем белән Мәскәүгә йөреп, коллык изаларын татырга тели, кем монда калырга тели — һәрегезнең үз эше. Мин сезгә моннан ары ханбикә түгел...

Шулчак Гөлдәрә ахирәт, эчкәридән атылып чыкты да, яман тавыш илә кычкырды:

— Мин калам монда!.. Синдән күп золым күрдем, инде дә кан-яшь түгәргә эстәмәем! — дип, төенчеген тотып, буш сәкегә менеп, тәрәзә төбенә утырды.

Сөембикә әйтте:

— Ихтыярың, Гөлдәрә ахирәт!

Ул аягүрә басты, Үтәмеш Гәрәй хан көрсидән сикереп төште, анасына килеп сыенды, ахирәтләр дә аякланды.

Шуннан соң, Сөембикә чыгышка таба атлады. Петр Серебряный янында туктап, янә әйтте:

— Соңгы гозерем бар баскынчы түрәгә!—диде.

— Тыңлыйм сине, ханбикә!—диде Серебряный.

— Мәрхүм ирем Сафа Гәрәй хан кабере белән бәхилләшергә рөхсәт бир!

Караңгы төшкәнче, Зөягә кайтып өлгерергә кирәк иде: белмәссең, төн эченнән татар гаскәре чыгып, хан белән Сөембикәне коткарыр өчен сугыш башлар. Воевода ашыга иде. Ләкин Сөембикәнең гозерен үтәмичә дә ул моннан тыныч кына китә алмас кебек. Ул ханбикәне әсир алмас та иде, әмма бу эш аның ихтыярыннан тормый, мәҗбүрият аннан өстен. Мәскәү каты бәгырьле: кырыс холыклы баярлар белән Иван Кансыз тагын да рәхимсезрәк.

— Бәхилләш, ханбикә!—диде баскынчы кенәз.

Сөембикә, җәяүләп, эчке кирмәнгә—ханнар зиратына—Үтәмешне җитәкләп китте. Хан күчәсеннән эчке кальганың Ханкапкасына йөз алтмыш адым, капкадан кабер станга мең адым икәнен Сөембикә бик яхшы белә: ничәмә-ничә тапкыр адымлап санаганы бар. Жан Гали каберенә йөргәндә, авыр уйлардан арыныр өчен, ул шулай санап атлый иде. Соңгы юлны кяфер колы буларак узачагын һич тә уйламаган иде ул. Үзенең әллә нинди төшләр күрүе, юраучыларның әйткәне юш килүе турында уйлый иде ул җәяү барганда. Хумай кошы да, Хозыр Ильяс та аңа төшендә килде. Сөембикә ике тапкыр ханша булды. Ирәмбаг гелән төшкә кереп, ул, ниһаять язмыш вә Аллаһ Тәгалә кодрәте илә үзенең бакчасын төзеде: Казанда, Кабан күле буенда, табигатьнең гүзәл бер почмагында, Сөенбаг пәйда булды. Инде дә, төшенә кергәнчә, әүлияләр юравынча, аңа угыл олан бирәчәге әйтелде: юраганнары янә юш килде. Һәр юш килгән саен, Сөембикә гелән Каракошны күрер иде. Сафа Гәрәй ханны шымчылар үтерер алдыннан атна элек тә ул төшендә Каракошны күрде. Кошчак угланның тар-мар килүе вакытларында да төшендә дә, өнендә дә түбәндә генә очып йөрүче Каракошны күргәләде. Җиһанга туганнан бирле Сөембикәне бәхет кошы Хумай белән афәт бөркете Каракош сагалады һәм, ниһаять, ханбикә күчә буйлап Сафа Гәрәй хан каберенә таба барганда да күктә, Казан шәһәре өстендә очучы Каракошны тагын шәйләде.

Ханкапкага өерелеп килгән халыкны кертмәделәр. Сөембикә, Үтәмеш хан, ахирәтләр, Петер Серебряный, Булат бәк һәм мең сакчы эчкә узды. Калган ике мең урыс гаскәре, халыкны Сөембикәгә якын җибәрмәс өчен, капканы эчтән бикләтеп, үзләре тышта, капкага аркылы басып калды...

Хан мәсҗеде мөнбәрендә азан әйтәләр, аңа барча манаралар җавап бирә. Хан кальгасындагы унбиш мәсҗед мөәзине һәрберсе үз мәкаме илә азан әйтә: Бәкләр Бистәсендәге егерме биш манараның тавышы аларга кушылды. Тышкы шәһәр — Касабадагы, Арча Кырындагы, Кораеш Бистәсендәге ике дистә мәсҗед, Карабистәдәге дистә ярым мәсҗедтән мөәзиннәр халыкны намазга чакыра. Гаҗәеп моңлы, искиткеч матур аһәңле азан булса да, кайгылы азан иде бу. Ни өчен соң азан шулай бәгырь тураклагыч хәсрәт моңына манчылган? Сөембикәгә генәме ул шулай тоела? Әллә азанчылар, Сөембикә белән хушлашу билгесе итеп, авазларына шундый фаҗига аһәңе өстәгәнме? Казан өстендә азан тавышы йөри. Бөтен җан иясе азан тыңлый. Петер Серебряный да сиксән авазлы азанны тыңлый, хәтта баскынчылар да азан шаукымында өнсез калган иде.

Мөселманнар намазга керește. Сөембикә, Үтәмеш вә ахирәтләр, намазлык урынына кайсы—чапанын, кайсы ябанчасын җәеп, сәҗдәгә егылды.

Казан йорты ахшам намазы укый.

Күктә, Казан йорты өстендә, Каракош оча.

Намаздан соң, Сөембикә Ханзират капкасыннан узды. Мөселман хатыннарына зиратка керергә һич ярамый, диләр дә, әмма Сөембикә бу йоланы тотмады, ул инде йола-гадәт кануннарына буйсынмый: аның хәсрәтле, әмма әмиранә карашын күреп, мөҗавир агай капканы җәһәт кенә ачты. Сөембикә углы Үтәмеш вә ахирәтләре белән каберстанга керде. Мөҗавир капканы япты. Петер Серебряный белән сакчылар капкага терәлеп калды.

— Гаурәтләр кергән дә бик җиткән,—дип мыгырдады карт.—Кяфергә ни-намә калган анда, Ханзиратта?

Хансарай белән Диван сарай арасындагы бу зиратта нибарысы җиде кабер—җиде хан ята. Олы Мөхәммәттән башлап Казан мәмләкәтендә унөч хан булса да, җидесенең генә гүре шушында. Унөч ханның берсе Шаһ Гали—Зөя каласында, өченче тапкыр хан булып утырыр өчен, тәхет бушаганны көтә. Казанның хакыйкый ханы да исән-сау—Үтәмеш Гәрәй: ул, кол сыйфатында, Мәскәүгә китәчәк, гүре кайда булыр—билгесез. Мамык ханны Нугай сәфәрендә үтерделәр, каберенең кайда икәнлеге дә нәмәгълүмдер. Габдел Латыйф хан белән Илһам хан Мәскәү коллыгында үтерелмеш, каберләрен белгән адәм юктыр.

Сөембикә беренче кабер янына килде. Бу Олуг Мөхәммәт хан төрбәсе иде. Адәм биеклегендәге башташның дүрт ягы да язулы. Ян-якларында аятьләрдән кыйтгалар чокылган.

Сөембикә, якыннары белән чүгәләп, пышылдап, дога укый башлады. Догадан соң, Сөембикә әйтте:

— Казан ханнарының иң куәтлесе, иң батыры, бөек галәбәләр яулаганы, киң күңеллесе, олы җанлысы син булдың, Олуг Мөхәммәт хан... Олы җанлы, киң күңелле булганга, син Бөек Сарайның алтын тәхетендә озак утыра алмадың... Бичара Икенче Уасилий Иван углына син Мәскәү тәхетен үз кулың берлә бирдең. Уасилий сиңа мәңге тугры булырга ант эчте, аягыңа егылып куанды. Син бәлагә таргач, мәкерле, булдыксыз энең Кечек Мөхәммәт сине Сарайның алтын тәхетеннән китәргә мәҗбүр итте. Син үз дустың, Мәскәү кенәзе Уасилийга йөрдең. Ләкин ул, сиңа ярдәм күстәрмәк җирдә, сине кылыч белән Биләү каласыннан куарга алынды. Мең кылычлык гаскәрең берлә син Уасилийның утыз меңлек явын туздырдың. Янә килеп, Уасилий мәлгунь сиңа кылыч күтәрде, ук атты, анда да син дустан дошманга әйләнгән Уасилийны җиңдең, гарип кылдың, әсир иттең. Анда да син миһербанлык күрсәттең, Олуг Мөхәммәт хан. Мәскәүнең җиңелгән вә авыр җәрәхәтле кенәзенә дәва салып, ярасын бәйләп, Мәскәүгә җибәрдең. Уасилий, савыга төшкәч, күп гаскәр җыйнап, синең өстеңә яу булып килде. Анда да син түздең, рәнҗеш сакламадың: ниһаять, син яңа, үзбаш мәмләкәткә нигез салдың, күп җиңүләргә ирештең. Биләү һәм Морым калаларындагы җиңүләрең сине бөтен дөньяга мәшһүр итте. Мөслим вә төрки-татар өчен син кыйлган фидаилек, син исраф иткән гайрәтне бизмәнгә салсаң, синнән соң килгән ханнарның кылганын басар иде. Хак Тәгалә кодрәте илә килер бер көн: син кылганнарны торыннарың ядкәр итәр, сиңа алтын һәйкәл кояр! Амин! Туфрагың нур булсын! Урының җәннәттә булсын!

Матәм алае—Сөембикә, Үтәмеш Гәрәй хан, ахирәтләр—Мәхмүт хан төрбәсенә керде. Төрбә эчендә башташ, башташта шундый язу:

Ходаның рәхмәте улсын анларга.
Анлар лайыкъ ирде дога кыйлурга.
Сәккез йүз алтмыш туккызда улды фәнасы.
Энҗү-җәүһәрдин улсун яткан бәнасы.

Олы Мөхәммәт хан углы Мәхмүт хан рухына дога укыгач, Сөембикә:

— И Мәхмүт хан агабыз, син йортыбыз өчен җәсурәнә яулар чапкан, курку белмәй дошман илә орышкан адәмсең. Синең каһарманлыкларыңны санап, сүз төкәнмәс. Гали вә Рөстәмнәрдән һич ким түгелсең. Син атаңны астыртын дошманнардан саклый алмадың: куәтенә масаеп, гамьсезлегең сәбәбе илә үзеңне дә саклап калалмадың. Мәскәү кенәзе Уасилий шымчылары кулыннан дөнья күчтең. Куәтле, үзбаш дәүләт төзеп бетергәч кенә, син шәһит киттең. Гайбәт илә сине күп изделәр. Имеш, син атаң Олуг Мөхәммәт ханны үз кулың берлә үлтергәнсең. Дошманнарың, сине каралтыр

өчен өстеңә шундый пычрак чәчте. Син үз балаң кулыннан үттең. Туганны — туганга, диндәшне — диндәшкә, карындашны — карындашка өстерүче һаман шул — атаңның яман дусты Уасилий булды. Хакыйкатьне томалап була, әмма ул, таш астыннан үсеп чыккан үлән кеби, барыбер өскә калкачак. Бу хакыйкатьне мин яздым, өч нөсхәсен өч ышанычлыма тапшырдым. Хакыйкать оныкларга, торыннарга барып ирешер, иншаллаһ. Үзе тәрәт кылып та, башкага, гөнаһсызга сылтап, сәясәт ясау — Мәскәү кенәзләренең төп ысулы. Халык моны аңлар, Аллаһ боерса! Туфрагың мамык булсын, урының оҗмахта булсын! Амин!— диде.

Хәлил ханның кабер ташы шома-буш иде. Анда дога да юк, шигырь дә юк, бары тик исеме, туган һәм үлгән елы гына чокылган. Шомлы, төссез кабер. Сөембикә әйтте:

— Йа Илаһем! Син мине кичер, Илаһем, кичер мин гөнаһкярны, мәрхүмнәр турысында бары яхшы сүз генә сөйләү лазем. Әмма мин үз йортына зыян кылганнар хаккында ничек яхшы сүзләем? Ялган өчен син җәзаларсың: бәс, Ходаем, тугры сүзем өчен колыңны ни көтә?.. И Хәлилчәк хан! Каның Чыңгыз-Батыйлардан ирсә, җаның Олуг Мөхәммәтдин иңсә, тумышың ук сине кара бәхетле кылса, нә итәрсең? Атаң канын коймак илә, менеп тәхеткә ирештеңме син, бичара, бәхеткәме? Нугай, Кырым, Хаҗитархан һәм Казанда синдәй мәхлуклар үрчидер шул. Ни аяныч, һич булалмадың балигъ, буең үсеп, акылың калды зәгыйфь: дошман котыртыгы илә күңелендә йөрттең кинә һәм санечтең бер гөнаһсыз хан атаңны. Әлбәт, әлбәт, син акларсың кылмышыңны, диярсең: Мәхмүт атам бабамны үлтерде... ич дәлилсез, һич тәфсилсез ничек инандың дошман сүзенә вә олуг гөнаһ алдың үз өстеңә һәм гөнаһың сине харап итте, үз хәнҗәрең керде бәгыреңә. Синең өстән мин хөкемдар түгелмен. Аллаһ әйтер, ахыр җиткәч, ахыр сүзне!

Матәм алае Ибраһим хан каберенә килеп җитте. Башташтагы матур язу, яуларга язу үрнәгедер:

Имән агач иеләдүр, сынамын, диеп, һай-һай,
Үлмәс ханга ук тиебдүр, үләмен диде, һай-һай.
Хатыннары еглашадур, хур буламыз, дип, ходай.
Угланнары сүенешә, хан буламыз, дип, Ходай.

Сөембикә, ихлас дога кылып, Ибраһим хан рухына әйтте:

— И Мәхмүт углы Ибраһим хан, ханыбызның дүртенчесе. Җәсүрлектә син бабаң Олугъ Мөхәммәтдин ким түгелсең, усаллыкта атаңнан син өлге алыпсың. Казан өчен күп дошманның башын кабак кыйгандай кыюрсың. Бөек эшләр майтарып, син Идел өчен дастаннарга кердең. Ибраһим хан. Атаң үчен Аллаһ алды кулың белән. Хафа булма, онтылмассың. Син хәрами да, юлбасучы да түгелсең. Син хөкемдар ирдең атаң тәкъдиренә. Хөкемеңне сәет шәйхелислам вә муллалар хуплап әйтте. Син рәхимсез улдың, Ибраһим хан, илең-динең дошманына, ата булдың ятим-үксез вә юксылга. Астыртыннар, шымчы вә кандошманнар сиңа бөhтан яксалар, әйтәдер кем: җәүһәр нәҗестән дә тәмиз калур кем зыянкәр кешене үлтерсә, бел: җылан үлтергән тик улыр, аңлагыл. Гүрең якты булсын! Амин!

Укыдылар алар Мөхәммәт Әмин ханның башташында:

«Галимләргә тәрбият кыйлган, зәһидләрны сүгән, мәсҗедләрни гыймарәт кыйлган, үксүзләрни асраган, Ибраһим вә Нурсолтан углы Мөхәммәт Әмин хан зирате торур. Хак Тәгалә рәхмәт-мәсрүр кыйлуб кәүсәр шәрабе берлә кандурсын».

Сөембикә әйтте:

— Мөхәммәт Әмин хан, сиңа сүзем. Әйтер кемнәр сине дошман диеп. Әйтер сиңа кайберәүләр бөек шоңкар диеп. Һәресе дә мәгълүм дәрәҗәдә хаклы булыр. Син бутадың дөнья, дөнья сине бутады. Мәскәү белән Казан — ике ут арасы, син шул арада яндың. Һәм бервакыт син айныдың Мәскәү хәмереннән: үзбаш булып, мөстәкыйльлек син яуладың, шөкер. Әмма һаман Мәскәүгә син тез йөгәндең. Чындөресен әйтәмен ки: син шулай да бөек хансың, чирек гасыр бер тәхеттә утырмак һичкемгә дә насыйб

әйләмәде. Син орышсыз яшәттең үз халкыңны. Мәдәният, гыйлем, шигърият чәчәк атты син торганда. Үзең шагыйрь, Бабур солтан сыман, үзең маһир бөек Олуг бәктәй: аһ, дип әйтәм, чак иртәрәк айныш кирәк иде исерткечтән. Уйгандың да мәңгелек йокыга талдың. Соңгы сәясәтең ярамады Мәскәү түрәсенә һәм астыртын чакты сине елан, күкрәп торган ир чагыңда вафат кыйлдың, олуг Мөхәммәт Әмин. Булган гөнаһларың Аллаһ ярлыкасын Ахырзаман таңында! Амин!

Зиярәт кылучылар хозурында Җан Гали хан төрбәсе пәйда булды: баш-ташны Сөембикә үзе гамәл кылдырмыш иде. Бер сүрәдән башка һич сүз юк-тыр бу мәрмәрдә, төркичә дүрт юл калкытылган:

Үлем — ул киң капкадыр.
Юктыр аңа сыймаган.
Кемдер яман кулдан үтә,
Кемдер үз теләге белән китә дөньядан.

Сөембикә инде күптән елый иде: әмма аның елавы бәгырендә булып, күз яшьләре шунда, бәгыренә бөялеп ташкан иде. Кабер катына килеп, бикә башын иде, озак сүзсез торды. Аннан калтыравык тавыш белән әйтте:

— Гомерең озын булмады, Шәех Әүлияр углы Җан Гали хан. Ни аяныч ки, Хак Тәгалә сине бөек яратмаган... Сабый булып тудың, сабый булып яшәдең, сабый килеш вафат иттең. Ни гаҗәп ки, Казан ханнары елдан-елга зәгыйфьләнә, кечерәя, юашлана. Төрки-ислам дөньясында тәхет варислары, кырау суккан гөлләр кеби, шәлперәя, иртә һәлак була. Батыйлардан, Үзбәк ханнан, Туктамыштан соң алтын тәхетле Сарай Урдасында ханнар умыртка-сыз, ирлексез булып җаһилгә әверелеп бетте, борынгы ата-баба шөһрәтенә куанып, кымызга хәмер кушып эчә торгач, мәхлукка әверелдек. Борынгы ба-баларыбыз каршында тезгә төшеп ярлыкау сораган дәүләтләр хәзер үзләре безләргә хаким. Хәзер синдәй ханнар, Мәскәүгә барып, патша алдында гына түгел, гап-гади бер урыс кенәзенә баш ора. Кичер мине, Җан Гали хан, син шуларның берсе идең. Син, шуышып та бәхет тапмаган күк, үзбаш булырга омтылып та бәхет тапмадың. Кара язмыш илә яратылган бәндә булгансың икән лә. Аллаһ сиңа хөкемдар! Амин!

Сөембикәнең калтыравык тавышы кинәт өзелгәндәй булды, ул инде күз яшьләрен тыя алмый. Алар Сафа Гәрәй хан төрбәсенә килде. Бу төрбә бөтен ханнарныкына караганда да бай, мәһабәт иде. Сөембикәнең өзелеп сөйгән иренә куйган соңгы ядкәре шушы булды. Таштагы сүзләрне Сөембикә яшь аралаш кычкырып укый башлады:

Йегетләр күрке, күңелләр көзгүсе,
Һуваль-хаййль-ләдзи лә йамуту.
Үлем сәне алуб сөенде.
Үксез калуб җаным көенде.

Фатих углы Сафа Гәрәй хан баһадир зиярәте торур. Тарих туккыз йүз илле алтыда җасуслар кулындин вафат улды. Хак Тәгалә рәхмәт кыйлсын.

Соңгы сүзне әйткәндә бикә, олы хәсрәт авазы илә көйләп, тулгап сөйли башлады. Ахирәтләре бузларга кереште. Алар башта, ыңгырашкандай, күкрәк эченнән генә бузлау-кайгы җыруы башлады. Сөембикә ире мәрхүмнең туфрагына багып әйтте:

— Дөньяга мин тугдым кол булырга түгел...

Ахирәтләрнең күкрәк авазы бугазга менде, алар көчлерәк бузлый иде:

— Кол булырга түгел...

— Кол булырга түгел! — дип кабатлады ахирәтләре.

— Бу дөньяга мин карау хатын булырга түгел...

— Карау хатын түгел, — диде ахирәтләр.

— Бу дөньяга мин, сөймәгәнгә түгел, бу дөньяга мин баласыз, тол калырга түгел... бу дөньяга мин синең сөүгеле хатының булмак өчен тудым... Бу дөньяга мин хан булачак углан тапмак өчен килдем... Бу дөньяга мин гөлбакчалар үстермәккә килдем. Ханбикә дә мин булдым, варисыңа углан да

таптым. Казанны гөлбакчага күмдем. Мәдәният, гыйлем вә фән гамәлен менгердем мин иятгә... Бар да Аллаһ кушканча, мин ниятләгәнчә була килде... Сафа Гәрәй ханны, җаныкаемны-ханыкаемны һәлак иттеләр...

— Һәлак иттеләр...

Ахирәтләрнең көйләп елавы куәтләнә, Сөембикә кычкырып елый. Күзләре шашкын бер карашлы, үзе ике кулы белән кабер ташын тырнап илерә, тәкърарлый:

— Йа Ходаем, мин нишләрмен синнән башка, үзең булмасаң да, каберең юаныч иде, инде хәзер кабер туфрагыннан да аералар...

— Аерала-ар...— дип күтәреп алды ахирәтләр.— Аерала-ар: каерала-ар... Бикәбезнең канатларын каералар, кол итәләр ханбикәне...

— И Казаным, золым күргән кара тәкъдирле Казаным, дала кызы булып сиңа килдем, синнән мәртәбә вә назлар алдым... Җаныкаем, Сафа ханым, син булганда мин оҗмахта идем. Син булганда Казан мәгърур иде! Күрең, Сафа Гәрәй хан, бүгеннән соң бу каргалган йортта коелыр кан, кыелыр җаннар. Мөслим каны сугарыр бу туфракны.— Сөембикә елаудан тулгауга күчте, тулгау — бузлауга әверелде.— Ни сәбәпдин булдым инде гөнаһкяр? Гөнаһымны әйтеп биргел, җәлладлар! Золым илә килеп кулым багладың, пакь тәнемә нәҗес кулың ташладың. Гөлбакчамны хәтәр изеп башладың. Бай тәхетдин әйдәп мине һәйдәдең. Нинди гөнаһ кылдым, җәлладлар? Гөнаһымны әйтеп биргел, җәлладлар!.. Шәһре Казан манарасы, siксән алты дыр барчасы, монда калган бәндәләрнең күл күк агар күздин яше: гаҗәп ирер Казан юлы, ул юлларда дошман тулы, бу Казанда торганнарның күл күк агар кайнар каны. Әлвидаг, аһ, әлвидаг! Әлфирак, аһ, әлфирак! Бәхил бул, Сафам, бәхил бул! Бәхил бул, Казаным, бәхил бул!

Ахирәтләр иңрәп-иңрәп елый. Үтәмеш Гәрәй хан, атасының башташына багып, тораташтай катып калган. Ул — ир кеше, ул — хан, аңа елау төс түгел: ул, култык астына яшерелгән карышкысын катырак кысып, матәм эчендә гизә. Сөембикә, «а-аһ» тавышы илә калыкты да, тузанлы учлары белән битен каплады, ахирәтләр дә нәкъ бикә кебек эшләде. Ханзираттагы аһ тавышы, хәсрәт авазы, үзәк өзгеч фөрьяд Хансарайга бәрелеп, Дивансарайга тиде, аннан сигез манарага таралды, ул манаралар фөрьяд тавышын Казанның бөтен биек биналарына тапшырды: Казан елгасы, Кабан күлләре, Идел ярлары коллыкка төшкән Сөембикәнең елавын ишетә. Кара халык, эш ташлап, сәҗдәгә егылды: алар да елый иде. Баскынчылар да, шомлы бер халәттә булып, тын гына тора. Петр Серебряный кояшка карый, үзе һаман борчыла, төш куптән авышты, кояш салмак кына офыкка тәгәри. Ә фөрьяд йоласының бетәргә исәбе дә юк... Сөембикә ике яңагын тырнап-суеп бетерде, бөтен ахирәтләре дә куркыныч бер сурәткә керде: кан, күз яше, тузан-туфракка буялган чырайлы шашкын кыяфәтле бу хатыннарны зират капкасыннан чыкканда күргәч, баскынчылар, мылтык төбәп, артка чигенә башлады.

— Тимә!— диде Петр.— Төшер пищальләреңне!

Воеводаның тыныч икәнен күреп, сакчылар мылтык түтәләрен җиргә куйды. Ханзират капкасыннан чыккач, Үтәмешне җитәкләп, Сөембикә Кызыл манарага таба китте. Ни булганын да абайламый калдылар. Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәй хан манары ишегендә юк булды. Петр Серебряный тиз генә ишеккә атылып килде. Имән ишек эчтән бикле иде.

— Бүрәнә! Тарам!— дип кычкырды Петр Серебряный, ләкин аны бирәү дә аңламады.— Ишекне ватарга-а!— дип акыргач кына, гаскәриләр, төрлесе төрле якка йөгереп, ишекне ватар өчен бүрәнә эзли башлады.

Ул арада Сөембикә белән Үтәмеш манараның икенче катында — мөнбәрдә күренде. Алар шашкын тизлек илә икенче катка ыргылды. Петр әллә кайчан аңлаган иде инде: бүрәнә белән ваткалаганчы, Сөембикә белән сабый хан манарадан сикереп үлгерәчәк! Петрның зиһене житез иде. Ул ярдәмчесенә сабыр гына әйтте:

— Өстән сикерсәләр, чатырларны җәеп тотарга, дүрт якка да икешәр чатыр әзерлә!

Яшь воевода үзенекеләргә боерык бирде. Манараның дүрт ягына да тире белән киндер катнаш чатыр япкычлар әзерләп, һәр чатырга унар сугыш-

чы куеп өлгерделәр. Манара сигез буынлы иде, әмма каланы тупка тотканда очлымы белән өстәге ике каты җимерелгән булу сәбәпле, алтынчы каты гына исән иде. Сөембикә манарасы Сөембикәнең китек бәхете сыман тырпаеп калган. Сөембикә шул соңгы катта күренде. Дивар өстендә Үтәмеш Гәрәй хан пәйда булды. Сөембикәнең шашкан кыяфәтен күреп, халык, яугирләр аһ итте. Гүзәлләр гүзәле, газәлләр газәле бер ханым белән чәче-башы тузган, оешкан кан белән балчык каткан чырайлы, баш япкычсыз бер зат арасындагы уртаклыкны аңлатып булмас кебек иде. Сөембикә куәтле күкрәк тавышы белән аска таба кычкырды:

— Гәүһәршад бикә! Булат бәк Ширин! Колакларыгызны торгызыгыз! Сафа Гәрәй хан хәләле Сөембикә исеме илә, Сафа Гәрәйхан углы Үтәмеш Гәрәй хан гозере илә әйтәмен ки: Булат бәк Ширин кяферләр, мәҗүсиләр, дөньяның иң кабихләре Исламга зарар кылса — ул табигый ки, ул зарарны аңлап була, чөнки алар — кяферләр, мәҗүсиләр, тәһарәтсездер. Әмма Ислам йортына, Казан—Идел—Нугай—Кырымга Гәүһәршад бикә белән Булат бәк Ширин вә аларның өере салган зыян-зәхмәтне дөньяның бөтен кабахәтләре бергә җыйналса да эшли алмас иде...

Гәүһәршад бикә Сөембикә манарасыннан ерак түгел генә салынган карачы-йортыннан, чарлактан карап тора иде. Ханзираттагы бузлау-елауларны баядан бирле рәхәтләнеп күзәтте. Хәзер ул манарадан үзенә төбәп әйтелгәннәрне дә тыңларга дучар булды. Булат бәкнең тыны капланган, чарлакка, хатыны янына киңәш сорап менде. Бикә ирен мышнавыннан ук таныды, борылып бакмастан, зәһәрле итеп әйтте:

— Кая җәяң? Кая угың?

— Бикәм,— диде бәк,— янымда кылыч та хәнҗәр генә.

— Ишетәмсең, ни сөйли теге кара елан? Халык ишетә, бөтен илгә тарала. Бер ук белән бер җәя биргәннең колы булыр идем, кайда мәргәннәр? Нигә атмыйлар?— дип кычкырды бикә.

Сөембикәнең тавышы көрәя барып, бөтен Казан өстенә җәелә иде.

— Мондай вәхшилекне, мондай динсезлекне, мондай хаинлекне тарих әле хәтерләми. Әмма ишетсеннәр: Гәүһәршад бикә, Булат бәк Ширин вә бәгъзе хаиннәр, сезнең бу нәҗеслекне тарих-вакыт юмас, Хак Тәгалә ярлыкамас! Сөенмә, Гәүһәршад бикә, ахырзаман ерак түгел! Синең урын — җәһәннәмдә! Куанма, Булат бәк, синең урынның — тәмуг түрендә. Ахырзамангача, бу заманда ук җәзасын алырсыз, иншаллаһ! Каргышыма каршы, Гәүһәршад бикә, синең сихерең куәтсез калыр! Мин түгел, минем телем илә сине Аллаһ үзе каргый!

Гәүһәршад бикә елан чаккандай үрсәләнә, бармакларын тешли-тешли бәргәләнә. Булат бәк җәягәме китте, әллә хатыны янында торуга караганда башка бер җирдә булуың мең өлеш артык дидеме — юкка чыкты.

Сөембикәнең сүзе төкәнде: ул арада Үтәмеш үрмәләп диварга менде, аягүрә басты:

— Казан тәхетенең кануни ханы Үтәмеш Гәрәй хан — сүзем!— дип кычкырды һәм карышкысын өскә күтәрде.

Шулчак мылтык дөпелдәде, ук сызгырып очты, Үтәмеш хан аска егылды. Карышкысы, кулыннан аерылып, дошманнар аягы астына төште. Җыелган халык та, баскынчы яугирләр дә бердән аһ итте. Баласын тотарга үрелдеме, Сөембикә, башы белән чүмәлде дә, аска очты. Халык диңгезе үкереп куйды. Петрныкылар, чатыр каплавычын җәеп, каты тарттырып өлгерде. Үтәмеш белән Сөембикә бер-бер артлы тыгыз җәймәгә килеп төште. Үтәмешкә берни дә булмаган, Сөембикәнең иңбашында ук иде. Кем ук атты Сөембикәгә? Якын йортларның берәрсеннәнме, халык арасындагы хаин эшеме бу, әллә ерактан ялгыш очып килгән ук булдымы ул? Ялгыш аткан мылтыктан чыккан кургаш та, ялгыш очкан ук та Идел йорты — Казанның ханына, ханбикәсенә юнәлгән икән, димәк бу туфракны кара язмыш көтә. Атучыларны эзләргә, эзләтергә теләүче булмады. Урыс яугирләре, Сөембикә белән Үтәмеш ханны чатыр япмасына ураган килеш, арбага салды. Петр Серебряный, хан карышкысын алып, ярдәмчесенә бирде. Халыкның бер өлеше, үкереп, яугирләргә ташланды, ләкин Петр хәселен кургән иде инде, арбаны

урап алган гаскәр халыкка мең мылтык терәп атты. Янә канлы бәрелеш башланып, ул шактый озакка сузылды.

Эшләрнең мөшкелләнә барганын Петр Серебряный бик яхшы сизенә, тышкы кальга дивары артына татарлар корал белән җыелган булса, Гайса үзе дә ярдәм итә алмас. Әмма ул юкка хафаланган икән: эшнең кая барасын чамалап, Зөядән күп гаскәр килеп, Петр Серебряныйны котә булып чыкты.

Мәскәү воеводалары рәһбәрлегендә баскынчы гаскәр Сөембикә йортындагы малларны, идән астындагы, ялган юлдагы хәзинәләрне арбаларга төяп бетерде. Казан елгасында җилкәннәре төшерүле, ишкәкләре күтәртүле көймәләр Сөембикә малын котеп тора.

Ни өчен, ни сәбәпле Сөембикә углы Үтәмеш Гәрәй хан белән кызыл манарага менде икән? Казан халкына соңгы сүзен әйтергәме? Гәүһәршад бикә белән Булат бәк Ширинны фаш итәргәме? Әллә, әсир төшмәс өчен, углы белән үз манарасыннан сикереп үләр өченме?..

Казан елгасы күпере янында тоткыннарны, арбадан төшереп, көймәгә утырттылар. Бу көймә Сөембикәне алып китәр өчен махсус бизәлгән, матур җиһазландырылган иде. Көймә борынына да, ян-якларга да кенәзләрдән генә торган ныклы сак куелды. Алдан — ике зур көймә тулы баскынчылар, арттан — алты көймә тулы каравыл, яр буйлатып — атлы гаскәр камалышында, каеклар тезелешеп китте. Алар, җилкән киереп, ян-якларда унбишәр ишкәкче булып, берьюлы ишеп, Иделгә таба бик тиз йөзә иде. Бераз баргач, Сөембикә Казан ягына борылды. Хансарайның алтын гөмбәзе баеп баручы кояшның кызгылт нурларын кайтара, Хансарайга ут капкан кебек иде.

Казан елгасы буйлап Иделгә таба матур бизәлгән көймә бара. Матур көймәне сакчы каеклар камап алган. Матур көймәдә кара язмышлы ханбикә, кол хан вә якыннары бара. Яр буйлап халык йөгерә. Сөембикә елый, халык елый. Халык ханбикәгә тартыла, ләкин яхшы коралланган яр буе атлылары халыкны читкә куа. Сөембикә халыкка омтыла, каравылдагы кенәзләр аны көймә кырына җибәрми.

Караңгы төшеп төн үз хокукларына кереп беткән чакта, Петр Серебряный көймәләре Зөя каласына килеп җитте.

Мөхәммәдъяр белән Колшәриф мулла, бер-беренә белдермәстән, Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәй ханны коткару өчен аерым-аерым гаскәр әзерләде. Идел-йортка, Казанга җаны-тәне белән бирелгән батыр егетләр, Зөя каласына сиздермичә генә барып, каравылларга күренмәс өчен урман аша йөреп, Зөя капкасының сакчыларын кырып, калага керергә булды... Колшәриф мулла белән Мөхәммәдъяр остаз бер-бере белән киңәшеп эшләсәләр, ихтимал, морадларына ирешкән дә булырлар иде. Ике гаскәр түгел, бер гаскәр белән генә дә бу эшне майтарган булыр иде. Сөембикә белән Үтәмешнең тәкъдир-кыйсмәт дәфтәренә «коллыкта үләргә» диеп язылганмы, батыр егетләрнең берсе-агаракка, берсе тагаракка тартуы сәбәплеме, бу хәтәр эш бикяр-файдасыз булды. Казан өчен сөйләп бетергесез зыян булды... Сөембикә белән Үтәмешнең Зөя каласында кайсы йортка ябылуларын ышанычлы кешеләр аша белгәч, Мөхәммәдъяр остаз туплаган гаскәр башлыгы Өметбай мирза, үз егетләрен Гайшә кичүеннән алып чыгып, Тау ягыннан алып китте. Колшәрифнекеләр, Сәхран би рәһбәрлегендә Ослан кичүеннән чыгып, турыдан-туры урман аша юл ярырга булды. Ике гаскәр дә, каравылларга юлыкмаенча, Зөягә бәла-казасыз килеп җитте. Таң беленер-беленмәстә алар, капкага бәреп керергә тиеш иде. Ике гаскәр шунда, бер-берсен күреп, җиргә сеңде. Сәхран би егетләре, атларын яткызып, үзләре ат гәүдәләренә посып, ук атарга әзерләнде. Өметбай мирзанекылар, нишләргә белмичә, ат өстендә калды. Өметбай сак тавыш белән татарча әйтте:

— Кемнәр-әр?— диде.

Сәхран би дәшмәде. Шаһ Гали татарларыдыр, дип уйлады ул. Мирза тагын әйтте:

— Кемнә-әр? Тавыш бир! Юкса, турыйбыз!— диде.

Сәхран би чарасыз хәлдә иде. Ни әйтсә дә — эш харап. Өмет бай, нигә дәшеп тә җавап алмагач, болар Зөяне саклаучы урыслардыр, дип, һөҗүмгә

китте. Алар килгәнне шәйләп, Сәхран би атарга әмер бирде. Чабып килүчеләр иярдән очып-очып төшә башлады. Ул арада Сәхранныкылар, атларын торгызып, ияргә сикерде, кылыч орыш башланды. Ике якта да җәрәхәт алганнар.

— Алла! Алла!—дип кычкыра башлагач, Өметбай мирза аңлады, ул җир ярып акырды:—Туктагыз, бу үзебезнекеләр!

Ләкин соң иде инде, туганнар бер-берсен турый, атлар үлем-кан исеннән куркып-чинап кешни. Сугыш тавышына Зөя сакчылар күтәрелде, алар манара диварлардан карап күрде ки: капка алдында гына татарлар бер-берсен кыра. Сәхран би дә, Өметбайны танып:

— Мирза-а! Нишлисең?—дип үкерде.

Егетләр эшне аңлап туктаганда, ике гаскәр дә дошман гаскәр уртасында иде. Сөембикәне коткару инде мөмкин эш түгеллеген икесе дә аңлады. Хәзер—үлгәнче сугышырга гына кала. Үзара кырышканнары икесен дә шаштырган. Сәхран би, Өметбай мирзага әйтте:

— Урманга кереп өлгерә алабыз, тегеләр бөҗрага кушылганчы!—диде.

Өметбай мирза кычкырып көлде:

— Бу төнге оятыбызны йөзебезгә орсыннар өчен исән калыргамы?—диде. Үзе бугаз киереп кычкырды:—Мөселманна-ар! Орышып шәһит китик!

Сәхран би дә шашкан рәвештә сөрән салды:

— Кылыч сынса—хәнҗә-әр, хәнҗәр сынса—теш-тырнак бар! Сугышып үләрбез!—диде.

Исән калганнар, аркага-арка куеп, атларының койрыгын койрыкка борып, җан ачысы илә акырып, бихисап күп дошман гаскәренә ябырылды. Зөя кальгасының сак манараларыннан күзәтүче бактаннар бер-берсенә кычкыра:

— Карале, кара, иллеләп чеби филгә һөҗүм итә-ә!

Ләкин бактаннарның ерык авызлары тиз йомылды. Берничә бөртек татар егетләренең кара яуга каршы хәтәр орышын күреп, бактаннар телсез калды. Булса да булыр икән батыр йөрәкләр! Дәһшәтле орыш иде бу. Сәхран би Өметбай мирзага, мирза бүтәннәргә нидер кычкырды: егетләр кинәт, атларын бер тәртипкә борып, тегермән ташыдай түгәрәк ясап, бер генә якка чаба башлады. Шул түгәрәк буйлап ыргып чапкан уңайдан егетләр берьюлы:

— Аллаһ вә Аллаһ!—дип кылыч селти, баскын гаскәрнең беренче сафындагы яугирләрнең башлары тәгәрәп төшә.

Дошман атлары, түгәрәкне кисеп, бөҗра эченә керә алмый. Мылтыклылар мылтык атар иде—каршы якта үз кешеләре. Шулай итеп, дошман гаскәре «тегермән ташы»н урап баскан килеш, арттан килүчеләргә дә юл бирмичә, баш кистерер өчен чират торырга мәҗбүр иде. Алар татарларга кылыч чабарга өлгерми, тегеләре ажгырып узып китә. Атлы узган саен, бер баш тәгәрәп кала, җайдаксыз калган атлар кирегә ыргыла, һөҗүм итүче урысларга комачаулый. Тора-бара, түгәрәк тә тарайды, башлар, башсыз гәүдәләр, яралы атлар аяк астында өелеп, татарлар белән урыслар арасы кылыч җитмәс, ат үтмәс булды. Урыслар бер яктан китеп, икенче яктан йөзләгән мылтык атып, татарларның үзләрен дә, атларын да бер атуда кырып бетерә ала иде, ләкин бу уй воеводалар башына төшмәде.

— Урманга бә-әр!—диде Сәхран би.

Өметбай мирза үз атын урман ягындагы дошман гаскәре өстенә җибәрде: ярсу ат үлеменә таба ыргылды. Берьюлы әллә ничә мылтык ат күкрәгенә терәлеп диярлек атты. Ат, алган тизлеге белән, үзенә мылтык атучыларга күкрәге белән бәреп, бөҗраны өзде дә, каршы килгән кешеләрне сикереп, ал аяклары тотмаенча, яралы күкрәге белән җиргә егылды. Өметбай мирза атының баш очыннан тәкмәрләп китте, дүрт тапкыр әйләнеп, аягүрә басты. Аның кулы буш, кылычы ычкынган, атсыз-кылычсыз ул ялгызы басу уртасында тора. Аның артыннан, бөҗра өзегеннән бу якка чыгып, уңлап татар егете чаба. Мирза янынннан узганда Сәхран би атын тыйды, Өметбай мирза, сикереп, Сәхран би ияре артына атланды. Алар яныннан гына томырылып, каты мышнап, урман ягына татар егетләре узды. Ике ирне

күтәреп, Сәхран би аты да аларга иярде, ләкин йөк авыр иде шул: урман аша төне буе юл сабып та, «тегермән ташында»гы орышта чабып та җегәр качкан. Егетләр урманга кереп югалды. Сәхран би белән Өметбай мирзаны баскынчылар бик тиз куып җитте. Берьюлы йөзләп мылтык шартлады. Башта Өметбай мирза ат койрыгы аша тәгәрәп егылды, аннан соң ат сөрлекте, Сәхран би, башына күсәк органдай, артка чайкалды, кылычы төшеп җиргә кадалды. Аты белән алар икәүләп егылды. Сәхран би аты астында калды. Бастырып куучылар, Сәхран би, Өметбай мирза, ат гәүдәләре аша узып, урманга, ун татарны куарга китте. Алар узып киткәч, тигез туфрак кына караеп калды. Анда ат гәүдәләре дә, бөек каһарманнар Сәхран би белән Өметбай мирзаның мәете дә, сөякләре дә күренми иде.

Урман кочагына яшеренгән ун егетләрнең берсе исән калды. Калганнары дошман кулыннан шәһит китте... Колшәриф мулла белән Мөхәммәдъяр үз хаталарын аңлаган иде инде.

Атсыз калган, җәрәхәтле унбашы Яурын аларга хәлнең ничек булганын сөйләде. Колшәриф җибәргән йөз илле углан белән Мөхәммәдъяр остаз юллаган йөз егеттән берәү исән калды — Яурын унбашы. Ике хаҗи кяферләр кулыннан шәһит киткән батырлар рухына җеназа намазы укыды.

Бу вакыйгалардан соң, калгай Шаһ Гали сакны, каравылны икеләтә арттырды. Икенче төнне дә кемнәрдер Зөя каласына узарга азаплаганда, тотылып урыслар әлеге исемнәре билгесез унлап татарны кыйнап изделәр. Исәннәрен зинданга илтеп яптылар.

Һиҗрәтдин соң тукыз йөз дә илле туккыз (1551) тарихында Кабан Елында, Әүвәл Җомада аеның екерме алтынчы көнендә Үтәмеш хан белән Сөембикә вә ахирәтләрен, алар белән бергә әсир алынган Кырымлы, Нугайлы кешеләрен: Кошчак угланның хатынын, ике углын, кызларын, Сафа Гәрәй ханның вә Сөембикәсенең якыннарын һәм башка бик күп угланнар, мирзаларның хатыннарын, балаларын, көймәләргә төяп, Мәскәүгә алып киттеләр. Бу хәерсез сәфәрнең башында татарлар ягыннан Бибарыс бәк Костаров булды.

Сөембикә белән Үтәмеш ханны коллыкка озаткач, ятим калган Казан, мәет чыккан өй кебек, бушап, җансызланып, шомланып калды. Гәүһәршад бикә белән Булат бәк, аларның углы Нургали, иркен сулап, бер бәйрәм ясады. Бәйрәм кунакларын озаткач та, ата белән ана Нургалигә корылтай җыярга кушты. Корылтайда катнашучылар белән аерым-аерым сөйләшеп, ни әйтергә өйрәтеп куйдылар; Зөя каласына илче җибәреп, бу турыда, ягъни корылтай булачагын Шаһ Галигә вә баярларга бәян итеп киңәшкәч, Нургали бәк корылтайны Казан кырындагы Ханболында уздырырга булды; аны Сөембикә киткәннән соң ике тәүлек узгач, өйлә намазыннан соңга билгеләде. Корылтайда, диван бәкләреннән тыш, дин башлыклары чакырулы булып, аларның рәһбәре Мансур сәет углы Колшәриф имам иде. Корылтайга угланнар, яугирләр, бөтен олуг батырлар дәшүле булып, аларның башлыгы — Кошчак углан киткәч, аның урынына билгеләнгән Ходайкол иде. Корылтайга Казан олылары — бәкләре бәкләр, мирзалар килергә тиеш иде, аларның алдан сөйләүчесе Булат бәк углы Нургали карачы иде. Хан булмаганлыктан, корылтай түренә мәшһүр карачыларның берсе — бәкләре бәк Булат бәк Ширин үзе утырды.

Корылтай урыны һәрвакытта да Дивансарайда була торган иде, күп кеше чакырулы булмаганда, һич югында, Хансарайда җыйнала торган иде. Ни сәбәпледер, Булат бәк белән Нургали корылтайны ачык җирдә, Ханболында узгарырга булды. Бу эш күпләрне аптырашта калдырды. Әмма дә ләкин моның сәбәбе тиздән ачыкланды. Корылтай җыйналып беткәч, өйлә намазын шушында укып, намазлык өстендә тәһлил әйткәч, Булат бәк җыенны башлап җибәрде. Шулчак корылтайдагылар күрде ки, Казан елгасыннан да, Идел ягыннан да ярга таба, Ханболынга карап, бихисап күп көймәләр килә. Баскынчылар килә. Кораеш бистәсе ягыннан да тузан күтәрелә. Һич шик юк ки — монысы атлы гаскәр. Чыннан да, әрәмәлектән чыгып, Шаһ Галинең ат

лылары бер сәбәпсез ат уйната башлады. Мылтыкчылар көймәләрдән төшеп, ялга туктагандай, мылтыкларын чатыр сыман итеп бер-беренә сөяп өйделәр дә, учак кабызгандай итенә башладылар, янәсе, алар балык тотачак. Колшәриф имам белән Ирсай бәк Булат Ширинга бакты. Булат җинүче кыяфәтендә иде: ул Колшәриф белән Ирсай бәккә елмайды. Бу елмаю: кыймылдасы булсагыз, минем сүзгә каршы төшсәгез, шушында башыгыз киселәчәк, дигәнне аңлата иде.

Булат бәк сүз башлады:

— Аллаһ Тәгалә гыйнияте илә, сезнең хуплавыгызга күрә, Корылтай дәвам итәчәк, ил агалары, мөхтәрәм җәмагать, сөекле бәкләр, могтәбәр дин әһелләре, батыр угланнар — голамә, сарай агалары! Бүген ике мәсьәлә алдыгызда тора. Икесе дә бик тә мөһим. Сүз күп булыр, шәт. Әмма бу мөһим мәсьәләне хәзер хәл итмәк өчен, сезләрнең кыйбатлы сүзе кирәк. Әүвәлге мәсьәлә: буш тәхеткә Шаһ Гали калгайның утыруын үтенеп, Зөягә илчеләр багышларга. Икенчесе: Казан вилаятендәге барча урыс әсирләрен азат кылырга!

Олы бәкләрдән берәү, динчеләрдән берәү урында кыбырсып куйды: Ирсай бәк белән Колшәриф. Угланнар ягында Шәмун тамак кырды. Әлеге игълан бу кешеләрнең бәгыренә агулы ук булып кадалды. Өч карачы, уклау йоткан кебек, мәгърур утыра. Калган күпчелек, баш иеп, сүзсез каткан. Болары Булат бәк белән Нургали бәк һәм Ходайкол ни әйтсә, шуңа разый булырга күндерелгән иде инде.

Мәсьәлә кабыргасы белән куелган, хәзер фикер әйтү кирәк, фикер әйтү булмаса, ризалык билгесенә тәсбих күтәрергә кала. Бәхәс, көрәш булмас кебек. Арка якта Шаһ Гали атлылары кылыч уйната. Ал, ян-якларда — бихисап урыс мылтыкчылары. Шушы мохиттә мөстәкыйль дәүләтнең иң олы идарәчеләре үз теләген әйтә аламы?.. Карачыларның Ирсай бәктән калганнары өчесе дә тәсбих күтәрде.

— Шаһ Галинең хан булырына риза! — дигән сүз иде бу.

Угланнардан ике батыр селкенмәде.

— Хөсәен белән Хәсән углан ни әйтер? — диде Булат бәк.

Ике углан бердән әйтте:

— Шаһ Гали хан булсын да ди! Әмма әсирләрне азат кылуга каршы!

Муллалар ягыннан Колшәриф тәсбихен күтәрмәде, ул әйтте:

— Мәсьәләнең икенчесе корылтайга куелмаска тиеш иде. Куелса да, бу бик зур хата. Тагын бер мөһим шарт бар: Шаһ Гали хан булса, тышкы калага да, эчке калага да урыс гаскәрен кертмәскә ант эчсен.

Корылтайга җан инде. Халык бәхәсләшә башлады. Нургали бәк атасына ачулы бакты, янәсе, нигә юл куясың?

— Нинди шарт? — дип кычкырды Нургали бәк, атасы сүз бирмәсә дә. — Алар шарт куя, без түгел. Әнә, кара, без утрауда, чыкмас бөҗрада, камалышта.

— Каян белгән алар? — диде Ирсай бәк. — Ике ил арасында орыш барганда корылтай яшерен җыйналырга тиеш. Кем дошманга хәбәр салган?

Әшнең кызуга таба китәчәген чамалап, Булат бәк әйтте:

— Шарт куелган инде! Мәскәү гаскәренең калага керү-кермәү мәсьәләсен илчеләр хәл итәр!

## Килмешәк

Һиҗрәтдин соң туккыз йөз дә илле туккыз тарихында, Әүвәл Җомада аеның утызынчы көнендә (1551 елның 26 августы) Зөя шәһәренең калгае Шаһ Гали Казанга керде. Шаһ Галине саклап, ярым тантана, ярым курку илә, Мәскәү баярлары Юрий Галитский, Иван Хабаров, Иван Выродковлар, алар белән өч йөз урыс казагы, ике йөз мылтыкчы вә бик күп Касыйм татарлары, ягъни Шаһ Галинең атлы гаскәре эчке калага узды... Шаһ Галине шул көнне үк, ашык-пошык рәвештә, хан күтәрделәр. Борынгыча, озаклап, җегенә китереп хан күтәрү бәйрәме урыслар өчен һич кирәк нәрсә булмаганлыктан,

хәтта мәсҗедкә кереп хөтбә уку да үткәрелмәде. Беренче, икенче тапкыр бу бәндәне хан күтәргәндә катнашкан бәкләр дә күп иде. Алар да бу эшне теләр-теләмәс кенә, иңнәренә мәҗбүрият басканга гына башкарды кебек. Җитмәсә, моңарчы булмаган хәл — хан күтәрү мәҗлесендә урыс баскынчы-яугирләре. Хансарайга кереп, кайсылары хан күтәргәнне карап, бәгъзеләре хан баскан келәм кырыннан тотып, эшкә кул тыкты. Шуңа күрәдер, ахрысы, хан күтәрү төштәге саташу кебек тиз башкарылды. Аның каравы, Шаһ Гали ханны Мәскәүгә, бөек падиша вә олуг кенәз Дүртенче Иван Васильичка мәңге тугры кол булыр өчен телдән ант эчтерү, ул антны күп данәдә язып, мөһер суктыру, имза куйдыру, ягъни ярлык белән ныгытуны тәфсилләп эшләделәр. Бу эштә баярлар, кенәзләр, воеводалар бик үҗәт булды. Ханнан соң диван бәкләреннән аерым-аерым ант алып, шартнамә яздырдылар. Шартлар каты иде. Бу солыхтан соң Казан селкенә дә алмаячак, коллыкта калачак иде.

Ләкин, күп тә үтмәде, Шаһ Гали ханга каршы яңа фирка оешты. Кайчандыр Мәскәү кенәзләренең табанын ялаган, һәр воевода алдында бил сындырган, Булат бәк кулында хәнҗәр булып торган бәкләргә, мирзаларга аң кереп, алар Казанның мөстәкыйльлеген саклау өчен талпынып карарга булдылар. Бу фирканең башында йөрүчесе Сөембикәне бәйләп Мәскәүгә озатып җибәргән Бибарыс бәк иде. Аның янында куәтле шәхесләр — энесе Җанбарыс, Кадыш батыр, Карамыш угланнар терәк булып басты. Хәтта Колай бәк тә бу фиркага керде. Булат бәк Ширин, Нургали белән Гәүһәршад каушап калды: алар кая барырга белми иде. Шаһ Гали хан ягына күчсәләр, аларга Бибарыс фиркасы үчле булачак. Бибарыска аусалар, Шаһ Гали хан белән аны саклаучы урыс воеводалары куркыныч. Ике юл да һәлакәткә илтәчәк — йә тегеләре, йә болары көннәрнең берендә аларны акыртып суячак. Шуңа күрә бу өчәү, дәшмәү вә читтән карап тору сәясәтенә күчеп, күбесенчә өйдә бикләнеп утыруны яхшы күрде. Шулай итеп, Казанда өч фирка барлыкка килде. Башында Шаһ Гали хан һәм баскынчы гаскәр торган Мәскәү фиркасы; башында Бибарыс бәк торган, чынлыкта корылтайның куәтле бәкләрен туплаган, Казанны азат итәргә алынган көчле фирка; башында Гәүһәршад бикә белән Булат бәк торган, хәзергә бер якка да катнашмаучы өченче фирка... Өченче көн генә корылтайда Казанны баш-аягы белән саткан бу бәкләр ни өчен соң кинәт кенә үзгәрде дә, кинәт кенә ватанпәрвәргә әверелде? Оятларына көч килдеме, әллә халык, дин, дәүләт мәнфәгатьләре аларның вөҗданын уяттымы?

Шулай итеп, Казан янә болгана, кайный башлады. Бибарыс фиркасындагылар көн саен Шаһ Гали хан янына кереп, урыс баярлары югында гына, пышылдап кына булса да тукый торды:

— Тау ягын бирмә, хан! — диделәр. — Бирмә Тау ягын!

Бичара Шаһ Гали хан ике ут арасында калды. Кайнар куык эченә килеп эләккән күбәләктәй бәргәләнә иде. Янында Мәскәү баярлары басып торса, ул Казан бәкләренә каршы сөйли. Баярлар юкта бәкләр керсә, баш иеп, аларны тыңлап, аларның хаклы икәнен раслап утыра. Ханның сиртмә койрык-селкенчәктәй гел аумакай булуын сизеп, бәкләр катырак сөйли башлады:

— Тау ягын бирмә, хан!.. Тау ягын кайтармасаң, без, көмәч ашасы урында, борчак ашаячакбыз. Тау ягы китсә, җофар, кондыз урманнары китә. Базарларда Казанның җофары-кондызы алдан йөри. Җофар-кондыз, алтын-көмеш-тимер китерә. Хан, үз казнаңа алтын кайдан килер, ә?

Бик яхшы аңлый ла ул шулай икәнен, бик яхшы аңлый. Казанда эшләнгән малның Казанда калырга тиешлеген дә белә ул. Мәскәү кыса бит. Мәскәү кыса. Элек якадан гына кыса иде Мәскәү, хәзер бугазны буып сорый, таләп итә, таләп итми — талап ала. Шаһ Гали хан, сорап та, үтенеп тә, ялварып та, елап та карады бит инде — юк. Мәскәү ул елак татарның күз яшенә ышанмый. Мәскәү татарны кызганмый һәм кызганмаячак та. Бәкләр дә кыса, теңкәгә тиеп, колакка бавырга кереп утырдылар.

— Тау ягын бирмә, хан! — дип, өзмиләр дә, куймыйлар да.

Бәкләр кысуына чыдый алмагач, ул, Тау ягын кайтаруны сорап, Иванга илче җибәрде. Әгәр ана риза булмасаң, Тау ягыннан алган керемнең һич югында өчтән бер өлешен Казан файдасына күчерергә рөхсәт бирсәң иде, дип язды. Илчесе киткәч, бәкләр тынычлангач, Шаһ Гали хан иркен сулаган иде дә, алай гына котылып булмый икән әле: бәкләр таләбе белән ул икенче көнне үк дивани мәҗлес җыйнарга мәҗбүр булды. Мәҗлестә, әсир төшкән урыс баскынчыларын азат итмәскә, дигән мәсьәлә куеп, бәкләр янә Шаһ Гали ханны кысарга тотынды:

— Әсирләрне бирмә, хан! Мәскәүгә барып алган әсирләр түгел, үз аяклары белән илебезгә кергән баскынчылар. Аларның тәне дә, җаны да безнеке! Әсирләр бездә калырга тиеш!

Шаһ Гали хан пешеп бетте. Аның катгый җавабы әзер түгел иде, шул сәбәпле ул, авыз эченнән нидер мыгырдап алганнан соң, әйтә куйды:

— Бик бирмәс идем, олылар, бирмәс идем... Тау ягын да, әсирләрне дә бирмәс идем... Мәскәү кыса бит, кыса...

— Кысыласың килгәч, Мәскәү кыса инде! — диде Бибарыс бәк.

Кадыш батыр кычкырды:

— Әсирләрне биреп бетерсәк, Мәскәүгә түлисе ашлыкны кем үстерер, хан? Әсирләрне бирем юк, олылар! Авыз йомып утырмыйк!

Колай бәк сүз алды:

— Яз син бөек кенәз Иванга, — диде ул. — Без әсирләрне азат кылырбыз, диген, әгәренки син Мәскәүдәге вә башка шәһәрләрдәге тоткын татарларны кайтарсаң! Шундый шарт куй, хан! Башка баш алмашыйк, диң!

Хуш, дивани бәкләрнең кысуыннан соң, Шаһ Гали хан, әсирләрне өлешчә генә азат итәргә рөхсәт сорап, Иванга илче юллады:

«И бөек кенәз Иван Васильич! Казанда яшәү миңа бик кыен. Бәкләр көннән-көн аза, миңа-сиңа каршы сөйлиләр. Тау ягын өлешчә кайтармасаң да, әсирләрне сорама, сорасаң да, башка баш алмашырга фатихаң бир...»

Бөек кенәз вә бөтен Русиянең олуг падишасы Кансыз Дүртенче Иван Васильич, Казаннан килгән әлеге илчеләрне зинданга ташлады да, Шаһ Гали ханга тозлап-борычлап бик хәтәр хат язды, үзенең усал илчеләрен Казанга күндерде:

«Тау ягы вилаяте кеременнән татарларга сукыр тиен дә бирмәячәкмен! Кол торган йөз мең христиан кешесен азат итмәсәң, мин, бөтен куәтем илә өстегезгә йөреп, илегездән тузан-көл ясаячакмын!»

Бу хатны алып укыгач, илче баярларның каты сүзләрен тыңлагач, Шаһ Гали хан, гадәтенчә, мыгырдана башлады:

— Тузан-көл ясарга оста икәнеңне беләбез, — диде ул, үзе генә аңлардай итеп. — Асу, кисү, баш чабу, зиндан — синең яшәү хәятең...

Бу хатны ханга Дмитрий Палитский тапшырган иде. Шаһ Галинең сөйләнгәнен ишетеп, сорады:

— Хан җәнапләры ни әйтте? — диде.

Шаһ Гали хан, дерт итеп илчегә бакты да, ашыгып болай диде:

— Куркыныч! — диде. — Моннан соң бәкләр кузгалыр, дим. Алар Нугайга, Кырымга яшерен илче җибәргән. Аннан гаскәр килсә, һич шигем юк ки, Казан кузгалачак.

Кенәз Палитский, як-ягына карангалап алды да иелә төшеп, хан колагына гына әйтте:

— Син алдаш, — дип пышылдады. — Иван өлешчә риза булган, диң. Иң усал бәкләрнең барын да кунакка чакырт. Калганы — безнең эш. Бибарыс фиркасын таратсак, син дә котыласың, безгә дә тыныч булыр. Аннан соң, гомерең буена бу тәхет — синеке...

— Ул фирканы ничек таратасың?

— Фетнә башындагыларны багышлап...

— Ә ничек багышларсың?

— Кунакка чакырып...

— Тик торганда сый мәҗлесе!? Ни сәбәптән? Сизенерләр, килмәсләр, — диде хан.

— Сизенмәсләр!—диде кенәз.—Туган көнең, мөшәл туена чакы.э син аларны.

Шаh Гали хан, гаҗәпсенеп, кенәзгә бакты:

— Мөшәл туема ерак әле,—диде ул.

— Синең кайчан туганыңны кем белә?—диде кенәз.—Дүртенче мөшәлем, дин. Бу олуг бәйрәмгә кем килмәс? Ә?

Бибарыс фиркасының язмышын шушы сөйләшү хәл итте. Шаh Гали хан үз йортына иң гайрәтле йөз бәкне чакырды. Атаклы адәмнәр, угланнар килде. Бу мәҗлескә Колшәриф имам белән Мөхәммәдъяр остаз да чакырулы иде. Колшәриф имам кунакка җыенып беткән иде, Мөхәммәдъяр остазны үз бусагасында күреп, сәерсенде. Мөхәммәдъяр остазның мөшәл туена чакырулы икәнен имам белә иде: әмма остаз өстендә иске җөббә күргәч, тагын аптырады. Мөхәммәдъяр остаз аңа авыз ачарга ирек куймады, кабынган сулышы илә әйтте:

— Йөрмәң! — диде. — Йөрмәң анда! Суеш булачак!

— Нинди суеш? — диде имам.

— Шундый суеш,— диде остаз. — Күрәмсез, Зөядән ике бүләмле гаскәр килеп, берсе — Бишбалтада, икенчесе Ханболында чатыр корды. Палитский белән өч йөз мылтык Хансарай янында тора. Янәсе, илчеләрне саклый. Нугайга киткән хат Шаh Гали кулында... Иван Тау ягын бирмәячәк. Әсирләрне азат итү өчен Мәскәү кара яу җыйный... Мөшәл туе канлы туйга әйләнәчәк... Шаh Гали ханга кырык өч яшь тула, аның мөшәле җитмәгән әле. Ни өчен соң хан, туган елын яшереп, мәҗлес уздыра? Һич шик юк ки, ызгыш чыгарыр өчен... Хәйлә тап, авырган бул, хат җибәр. Үзең Арчага кач, мин Арьякка чыгып, гаскәр туплап карыйм. Син Арча даругасын күтәр. Юкса, Казан тагын башсыз калачак. Өлгерсәк ярый...

Мөхәммәдъяр хушлашмыйча чыгып китте.

— Әйтә алганнарга әйтеш кирәк! — диде Колшәриф. — Ихтимал, күбесе инде Шаh Гали хан өендәдер.

Мәҗлескә Кадыш батыр иң алдан килде. Кирә-керешли тамак кырып, сәлам биргәч, ул уенчак сүз әйтте:

— Алдан килгән — урын өчен, хан! — диде. — Дүртенче мөшәлең котлы булсын, Шәех Әүлияр углы Шаh Гали хан! Сигезенче мөшәлеңдә, ягъни туксан алты яшеңдә кәеф-сафа корыр булсаң ирде! Миннән алтын дирбияле айгыр — Киңтанау!

— Машаллаh! — диде хан, ул кочагын җәйде: — Бүген яңа йола башлыйм, бүген — кем алдан килә — шул иң түргә утырыр. Җайлаш!

Кадыш батыр хан күрсәткән урынга, түргә утырды. Бер-бер артлы Бибарыс бәк, Колай бәкләр килеп керде. Кадыш батыр уйлап куйды: hе, бу бүксәхан безнекеләрне генә чакырганмы соң?

Юк икән, мәҗлес башланыр алдыннан гына Булат бәк Ширин, Нургали бәк, тагын берничә мирза, углан килде. Алар Шаh Гали хан күрсәткән урынга, ишеккә якынрак, арт тәрәзәгә арка белән урнашты. Кадыш батыр hаман астыртын гына күзәтә, уйлый иде: hе, болар өере нигә соңга калган да, нигә алар түр урын өчен сатулашмый? Ә ни өчен алдан килгәннәрнең түрдәгеләрнең барысына да кызыл сөлгеләр бирелде дә, ни өчен Булатны кыларга ап-ак тастымал өләштеләр? Кадыш батыр, бу фикерен алга сөреп, төбенә төшәргә өлгермәде, мәҗлескә фатиха бирелде. Ләкин Кадыш бәкнең шиге зиhенен кычыттырудан туктамады. Шаh Гали ханның сул ягында—Кадыш, уң ягында илче-кенәз Палитский урнашкан. Кенәз ханга иелә төшеп:

— Колшәриф имам белән Мөхәммәдъяр остазны чакырмадыңмыни?—дип пышылдады.

— Чакырдым,—диде хан.—Имам сырхау икән—язуы бар. Хаҗи остаз хәзер килеп җитәр. Хаҗи Мөхәммәдъяр мәҗлескә сирәк йөри. Картның бер аягы гүрдә.

Ялган мөшәл туе бик җанлы башланып китте. Палитский кушуы белән кымызга аракы кушып болгатылган иде. Кайберәүләр беренче касәдән үк кызып сөйләшә, күп көлә башлады. Мәҗлестәшләр кымыздагы аракы исен сизмәде, тәмен тоймады, әмма кәефләр

— А-аһ, Шаһ Гали ха-ан, кымызың ла кымызың!— дип мактадылар, рәхәт кичерделәр.

Кадыш батыр да тәнендә рәхәт кызышу тойды. Әмма, рәхәтлек белән рәттән, аның күңеленә кереп оялаган шик тагын калыкты: кымызга нидер кушылган! Ул инде эшне аңлаган иде. Кунакка кылыч белән йөрмиләр. Кылыч тагып килгәннәр, алгы йортта салып калдырды. Ул-бу килеп чыкса, коралсызларны турап өячәкләр. Тышка чыгып керү хәйләсе белән ул калыкты. Ишек аша ишек, каравыл аша каравыл узып ишегалдына чыкты. Тәрәтханәгә керде: төннектән тышка бакты. Батырның йөрәген курку биләп алды: ханә арты тулы мылтыкчылар иде. Ул, җәт кенә чыгып, тәһарәт өенә керде, өйнең төнлегеннән кучәгә карады: кучә буйлап, тавыш чыгармаска тырышып, тагын бик күп баскын мылтыкчыларның хан йорты капкасына, диварларга, тәрәзә асларына сыенганын күрде. Кадыш батыр куырылып килде. Ул инде, уйламый-нитми, атылып, кунаклар элеп куйган кылыч өенә керде. Үз кылычын вә тагын бер-ике кылыч алып, мәҗлес йортының ишеген киереп ачты да, җир ярып кычкырды:

— Без камалышта-а! Без тозакта-а!

Тәрәзә янында утыручы Булат бәк, Нургали бәк тәрәзә аша чыгып качты, ак сөлгеләләрнең кайберәүләре аш өенә, эчкәрегә йөгерде, алар качуга ук, аш өеннән — эчкәридән, ялангач кылыч тотып, Шаһ Гали кешеләре атылып чыкты да табын янында утыручыларны турый башлады. Шаһ Гали хан үзе юкка чыкты. Палитский да Кадыш батыр кергәндә бүлмәдә юк иде. Кадыш кылычларны үзенекеләр ягына ыргытып, ике кулына ике кылыч тотып, берәүне дә янына җибәрмичә, ишектән керергә азапланучыларның башын чаба, эчләренә кылыч тыгып өлгерә. Эшне аңлаганнар, бил хәнҗәрләрен алып, кылычлыларга каршы орыша башлады. Идәндә, келәмдә аш, тәгам, җимеш, кымыз — кан аралаш измә; киселгән башлар... Кадыш өермә кебек бөтерелә. Бүлмәгә кергәннәрнең күбесе яраланып, байтагы үлеп беткәч, исән калган бәйләр кылыч бүлмәсенә ыргылды. Анда аларның чыккан беренә төбәп мылтык аталар. Өй эчен төтен каплады. Акырыш, сугенү, ыңгырашу, шартлау авазлары эчендә берни аңлап булмый. Тәрәзәдән сикергәннәрне ядрә, кылыч каршы ала. Исән чыгып өлгергәннәр ишегалдында җан өчен сугыша, бәргәләнә, өзгәләнә. Кадыш батыр, бик күпләрне кырып, аш йортына керде. Бавырчылар, кисмәкләр, казаннар арасына кереп посты.

— Сез салдыгызмы кымызга аракы? Алыгыз әҗәтегезне!— дип, Кадыш батыр аш өен мәет белән тутырды.

Ашханәнең арт ишегеннән ул урамга атылды, анда да кырыш бара иде. Кадышныкылар — бил хәнҗәре белән, дошманнар кылыч, мылтык тотып орыша. Кадышның аш йорты ишегеннән чыгуын көтмәгәннәр иде, мылтыкчылар аңа аркасы белән торып, караңгылык эченә, качып баручы кунакларга мылтык ата. Кадыш, арттан килеп, берьюлы ике баскынчының бөеренә ике кылыч тыкты, аннан тагын, тагын шулай ул дошманнарны кырды, шунда гына чайкалып китте, аңын җуя барганын тойды, табын өстендә ул каты җәрәхәт алган иде, ахрысы, аркасы буйлап кайнар кан акканын сизде: кылычлары берәм-берәм чалтырап ташка төште. Кылыч тавышына мылтыкчылар борылды, ике ядрә берьюлы аның күкрәгенә керде. Ул аңсыз килеш кылычлары өстенә ауды.

Кунакка килгән йөз бәкнең җитмеше сугышта үтерелгән иде.

Колшәриф имам белән Мөхәммәдъяр остаз хәбәр биргән гаскәрләр Казанга кырылыш беткәч кенә килеп җитте. Соң иде инде. Баскынчылар гаскәре, үз эшләрен эшләп, Зөягә киткән иде.

Мәетләрне җыеп, юып, җеназа намазы укылгач та исән калган яхшы бәкләр хан янына килде. Ләкин хан аларны кабул итмәде. Бәкләр, Шаһ Гали хан белән Палитскийны бу канлы мәҗлес оештыручы буларак фаш итеп, Мәскәүгә Иван исеменә илче юллады. Палитский да шул көнне үк Мәскәүгә китте. Ул китеп бераз вакыт узгач, Алексей Адашев, илче булып, Казанга килеп җитте. Ул Иванның фәрманы илә Шаһ Гали ханны тәхеттән төшереп, Мәскәүгә озатырга тиеш иде. Шаһ Гали хан үзе үк аңа:

— Казан миңа үчле! Казан гаскәр туплый. Нугайдан хан сорый. Мине үтерәчәкләр. Мин Зөягә китәм! — диде.

Шулай карар кылынды. Шаһ Гали Казаннан яшертен генә китәргә тиеш булды. Чөнки Колшәриф имам, Мөхәммәдъяр туплаган ике гаскәр Казан капкаларын сакта тота. Адашевка ярарга тырышып, Шаһ Гали хан Казанның бөтен дарысын арбаларга төятте. Арбалар җитмәгәч, баздагы дары мичкәләренә су сибәргә әмер бирде.

Хансыз калган Казанга калгай итеп кенәз Семен Микулинский билгеләнде. Микулинскийның үзеннән алда, аның шәхси әйберләрен, сандыкларын, коралларын төяп, бөтен байлыгын Казанга китерделәр. Бу кәрванның башында Чапкын, Борнаш бәкләр, урыс ягыннан мылтыкчылар воеводасы Иван Черемесинов иде. Болар, Казанның исән калган олыларын җыйнап, Микулинскийның хан урынын алып, Казан калгае булып утырачагын игълан итте... Алардан соң тоткын бәкләр арасында булган Ходайкол углан рәһбәрлегендәге илчелек Казанга кайтты. Алар белән бергә урысның дүрт баяры, җитмеш казак та Казанга килде. Казанның калдык-постык олылары белән Булат бәк Ширин Микулинскийны калгай итеп куярга ризалык бирде. Семен Микулинский, озак көттермичә, юлга чыкты. Аны каршы алырга Шамсә бәк, Ханкилде бәкләр җитәкләвендәге бер өер татар йөрде. Сөйләшенү буенча, Микулинский гаскәренә Казан капкаларын Шамсә бәк ачып куярга тиеш иде. Нәкъ шушы чакта, Зөя төрмәсенең сакчыларына кыйммәтле хәнҗәрләрен, алтын-көмеш нәрсәләрен биреп, Ислам бәк, Кәбәк би, Галикәй мирзалар качып, яшертен генә Казанга кайтты. Алар Алабуга капкасыннан шәһәргә узды. Һәр капкага ышанычлы кешеләр җибәреп, халыкны кисәтте:

— Капкаларны бикләргә! Микулинскийны Казанга кертмәскә! Шәһәрне сакларга! — дигән әмерне җайдаклар урамнар, күчәләр буйлап кычкырып йөрде.

Хансарай вә тышкы кальга мәйданнарына халыкны җыеп әйттеләр:

— Алданмагыз, каладашлар! — диделәр. — Баскынчы гаскәр, калага керсә, бер генә мөселман да исән калмаячак. Хәтта Иванга дус булганнар да суелачак, асылачак. Менә безгә багыгыз. Гомер буе Мәскәүгә хезмәт иттек. Шаһ Галине хан итүдә башлап йөрдек. Безне дә алар кол итмәк булды. Анда, Зөя каласында, җитмешләп олыларыбыз үлем көтә. Кем корал тота ала, ясаныгыз — яракларыгызны тагыгыз! Йоклаганда да киенгән килеш ятыгыз! Яу — сугыш игълан итәбез!

Халыкка шул өндәү җитә калды. Бөтен күчәләр, урамнар, манара-диварлар коралланган кешеләр белән тулды. Болардан куркып, төнлә Ходайкол углан, Борнаш бәкләр качып чыктылар да Микулинский янына чаптылар.

— Казанда чуалыш! Бөтен бәкләр корал алды! Халык кузгалганчы тиз һөҗүм итеп, Казанга керегез! Без капкаларны ачарбыз! — диделәр.

Микулинский әйтте:

— Капканы үзләре ачсыннар! Аларга бирни дә булмас!

— Юк, диде Ходайкол углан. — Алар суештан курка. Алар хәзер безне дә, Булат бәкне дә тыңламый. Алар каты ярсыган. Капка ачу түгел, алар сезгә һөҗүм хәзерли. Чапкын бу эштә башлап йөри.

Чыннан да, Чапкын бәк Казан эчендәге йөз сиксән урыс мылтыкчысын үтертеп, диван мәҗлесен җыйды. Шаһ Гали хан өендә суелган җитмеш бәк һәм дә Зөя зинданындагы сиксән бәктән соң исән калганнар алдында Чапкын үз сүзен әйтте:

— Ике мәсьәлә, — диде. — Тау ягын кайтару өчен гаскәр туплау. Казаныбызга яңа хан кирәк. Мин Касыйм хан углы Ядигәр бәкне сорарга, дим.

Бу мәҗлестә Булат бәк белән аның углы Нургали бәк юк иде. Имеш, Булат бәк сырхау икән дә, Нургали Арча ягына җофар сунарына киткән, ди.

Мәҗлестәшләр берьюлы тәсбихләрын өскә күтәрде:

— Хуплыйбыз! — диделәр. — Шулай булсын! Атлы гаскәр туплап, Чапкын бәк Тау ягына һөҗүм итте, ләкин бу сугыш татарлар өчен бик хәвефле булды. Мәшһүр баһадирлар Шаһчура, Шамай бәкләр һәлак булды. Бик күп угланнар, мирзалар әсир төште, Зөягә озатылды.

Казандагы бу хәтәр хәлләрдән Кансыз Иван бик тәфсилле хәбәрдар иде. Соңгы кузгалыш аның җенен чыгарды. Казан мәмләкәте инде бетте, Русиянең бер өлешенә әверелде, дигәндә генә, Казан янә кайный башлаган. Иван шушы хакта митрополит Макарий белән күзгә-күз сөйләшергә булды. Митрополитның сүзе берәгәйле һәм Иванга бик тә кирәкле иде:

— Христианнарны татарлар кулыннан коткарырга бару савап кына! Бар! Йөр! Кыр!—диде Макарий.

Шулай итеп, Кансыз Иван йөз илле меңлек гаскәр тәртип кылып, уң кул якка, сул кул якка, алга, арка якларга иң батыр баярларны куеп, йөз илле туп, бихисап күп дары, мылтыкларны көймәләргә төяп, кара яу сәфәренә чыкты. Ләкин, ерак китмәстән, Иванга шөбһәле хәбәр китерделәр: Кырым ханы Дәүләт Гәрәй Мәскәү өстенә яу чыккан. Имеш, Дәүләт Гәрәй хан үзе яу башы икән. Шушы хәбәр Казанга барасы яуны туктатты. Дәүләт Гәрәй ханны тоткарлау өчен Иван Тула каласына куәтле гаскәр күндерде. Бу вакытта Тула шәһәрен татарлар бәреп алган иде инде. Мәскәүдән хәтәр коралланган гаскәр якынлашканын ишеткәч, Дәүләт Гәрәй хан Туладан китте, артка чикте. Ашыгуданмы, булдыксызлыктанмы, ул Тула шәһәренең тирә-як авылларына мал җыярга таралган татар гаскәрләренә хәбәр бирмичә, шәһәрдән чыгып качты.

Шул рәвешчә, Кырым ханы Дәүләт Гәрәй, һич сугышмаенча, хур булып, җиңелеп, үз малларын да, үз яракларын да дошманга калдырып, Бакчасарайга кайтып егылды. Бу вакыйга хәрбиләр-яугирләр тарихында булдыксызлыкның иң әче вә иң көлке үрнәге булып калачак иде.

Кансыз Иван өчен бу көтелмәгәндә килгән куанычлы бәйрәм булды. Ул, яңа дәрт вә гайрәт илә гаскәрен кузгатып, Казан өстенә китте. Яу урыныннан купканда гына, Иванның Хаҗитархандагы илчеләре Семен Тутаев белән Сөендек Мошаев кайтып төште. Алар алып кайткан хәбәр Иван өчен куанычлы түгел иде:

— Нугай әмире Йосыф бәк Хаҗитархан шаһзадәсе Касыйм хан углы Ядигәрне Казанга хан сыйфатында юлларга җыена!—дигән яңалык Иванны хафага салды.

Казанга илтә торган бөтен юлларны, кичүләрне көчле каравыл гаскәрләре белән томалап, сак куярга боерып, Кансыз Иван алга чапкыннар, гаскәр җибәрде:

— Ядигәрне тереләй тоткан гаскәрдәге һәр кешегә меңәр алтын! Үтергәнгә — биш йөз көмеш. Шуның өстенә казна хисабыннан йорт салдырам!—диде Иван алга китүчеләргә.

Ул заманда Казан йортында хәлләр болайрак тора иде. Казан бәкләре азат иткән урыс әсирләре дә, Шаһ Галине хан итәргә килгән яу гаскәре дә Зөя каласында булып, эшсезлектән нишләргә белмичә, бал эчеп, хәмер чөмереп, махсус китертелгән хатыннар белән типтереп яши торгач, тәмам бәйдән, чыгырдан ычкынды. Шаһ Галинең үз хәлләре хәл: ул урысның бу кылмышларына катнашмый, катышса да аны һичкем тыңламас, санга сукмас иде... Ашый торгач, эчә торгач, типтерә торгач, Зөя каласында җыярга ризык, эчәргә хәмер бетте, кулдан-кулга, ятактан-ятакка йөрүче хатыннардан яман чир таралды. Шуңарга тагын эч китү, бизгәк хасталыгы да өстәлеп, сугышчылар, әсирлектән азат булганнар, вак сәүдәгәрләр, күпләп-күпләп кырыла торды. Воеводалар, кенәзләр бу типтерүләрне туктатасы урында үзләре типтерү башында йөреп, тәртип тәмам бетте. Азак — аракы вә хатын өчен үзара сугышып, күпләр үлде. Баскын гаскәр, әшәке юлбасар, йортбасар өеренә әверелеп, төркемләп-төркемләп каладан чыгып, тирә-як татар-чирмеш авылларын талау эшенә кереште. Зөя тирәсендәге урманнарда поскын булып ятучы татарлар, чирмешләр урыс казакларын кыра торды. Бу сугышларның берсендә җитмеш казак үтерелде, татарлар бик күп ганимәт мылтык-кылыч, ат кулга төшерделәр. Ачтан үлмәс өчен, Зөядәгеләр Нократ кичүендә торучы вә Мәскәүгә хезмәт итүче татар бәге Суюрга тарафыннан азык-эчемлек алырга сәфәр китте. Суюрга кырык казагы белән шәхсән үзе олау-олау икмәк, кисмәк-кисмәк әче бал төяп хәвефле юлга чыкты. Татарларның поскынына туры килеп, бу гаскәр дә кырылып бетте. Суюрга үзе те-

ре килеш бөтен малы белән әсир алынды. Суюрганы Казанга кайтарып, хөкем чыгардылар.

— Суюрга атлы бу бәндәнең Казан йортына тигән зыяны кайбер урыс түрәләренекенә караганда да күп. Кошчак углан гаскәрен суюда катнашкан, аны кырык батыры илә Мәскәүгә озаткан бу Суюрга хаинне асарга!

Һәм шулай иттеләр дә. «Чучкага чучка үлеме булыр!» — дип, баганасына язып та элделәр.

— Казанга хан булып Ядигәр Мөхәммәт киләчәк! — дигән хәбәр Казан халкына куәт бирде.

Чапкын мирза, баягы җиңелүеннән соң, янә атлы гаскәр туплап, Тау ягына яу чапты, һәм, ниһаять, Тау ягы куштаннарын һәм урыс гаскәрләрен җиңеп, Тау ягын тулаем кире кайтарды.

Колшәриф имам белән Мөхәммәдъяр остаз гаскәренә тирә-яктагы авыллар, даругалардан унарлы, йөзәрле-йөзәрле тупламнар килде. Халык яңа ханны түземсезлек белән көтә иде. Көч бар иде, карышу рухы янә уянды. Бу куәтне, бу рухны әйдәр өчен рәһбәр кирәк — хан кирәк!



## Кансыз Иван

Үзен белә башлаганнан бирле, Иван татарлар турында ниләр генә ишетмәде. Сабый чакта әнисе дә аларның батыр, серле халык икәнен инаныпсөйли торган иде. Татарларны якыннан белгән сәүдәгәр вә илчеләрнең гаҗәеп маҗараларын Иван сихерләнеп тыңлый, кат-кат сөйләтергә ярата. Татарлар яши торган илләр аның өчен әкият, хыял вә могҗизалар дөньясыдыр кеби тоела. Татарлар алтын тәхеттә утыра, алар алтын савыттан гына ашый, аларның өстендә дә алтын укалы чапаннар гына, ди. Хәтта коллары да бай киенә, дип сөйләделәр.

Иванның анасы Елена Глинская борынгы бабасы ягыннан татар. Иван Васильичның үз тамырларында да азмы-күмпе татар каны ага булып чыга... Тарих җиде йөз дә сиксән ике, Тавык Елында (1380) Кулик орышында татар гаскәрләренең башлыгы бәкләри бәк Мамай Кырымда үтерелгәннән соң, Мамайның улы Мәскәүгә хезмәткә күчкән. Ул, христиан динен кабул итеп, Елена Глинскаяның, ягъни бөек кенәз Иван нәселенең бер тармагы шуннан килә, ди...

Татарлар турында күп тапкырлар ишеткән, күңелдән белгән хикәятләрне тыңлау да, яңаларын ишетү дә Иван өчен рәхәтият дөньясында йөзү белән бер иде. Тора-бара Иван татарча өйрәнергә тотынды.

Тагын бер вакыйга Иванның хәтерендә уелып калган. Аңа биш-алты яшь чамасы булгандыр...

Аның өчен боярлар уйлап-киңәшә дә, бөек кенәз Иван исеменнән анасы Елена Глинская сүз әйтә торган иде. Иванга кызык. Ул игътибар белән тыңлап утыра, олы баярлар бәхәсләшә, кычкырыша да, бер фикергә килгәч, Еленага шул сүзне әйттерәләр. Шул көнне баярлар әйтте: Казанда Җан Гали ханны үтергәннәр, диделәр. Бушаган тәхеткә Мәскәү өчен кулай, тыңлаучан хан кирәк, диделәр. Баярлар, сөйләште-киңәштеләр дә, бу урынга иң кулай кеше Шаһ Гали, диделәр.

Әмма Шаһ Гали ул чакта Белозеро зинданында иде. Иванның атасы, бөек кенәз Василий Шаһ Галине гаиләсе, бөтен бәкләре, мирзалары белән төрмәгә ябып бетереп, үзе үлеп киткән иде. Имеш, Шаһ Гали Мәскәүгә һөҗүм итмәкче булган икән. Чынлыкта исә, бу эш сылтау гына булып, төп сәбәбе, киләчәктә шулай булмагае, дип шүрләгәннән генә иде. Василийның хөкеме каты, үтә рәхимсез булды. Шаһ Галине хатыны Фатыйма солтан белән Белозеро зинданына ябып, кыйнап, ач тотып, бик каты җәберләделәр. Сиксән биш олы бәкне хөкем көнне үк астылар. Псков каласындагы төрмәгә ябылган җитмеш өч олы бәк белән йөз егерме хатынны, яшь балаларны бер тәүлек эчендә җәзалап үтерделәр. Василий аларның мәетләрен күмәргә дә рөхсәт бирмәде. Җансыз гәүдәләрне төрмәдән алып чыгып, кырга, чүплеккә, этләргә, күселәргә ыргыттылар. Псков зинданында исән калган

сигез мирза ачтан үлде. Хәсән атлы мәшһүр бәкнең (Шаһ Галинең Мәскәү яклы иң якын киңәшчесе) үзен үтергәч, хатыны, балаларын ирексезләп чукындырдылар. Тол калган бикәләрнең бөтенесен, кызларны, сабый кызларның барчасын чукындырып, Василий яшь баярларга хатынлыкка өләшеп чыкты. Новгородта бик күп бәкләрне астылар, тол калган кырык алты хатын, утыз сигез тутайны, Псковтагы илле бикәч, Аришыктагы унике тол, Карилдагы утыз яшь кыз көчләп чукындырылганнан соң, баяр балаларына хатын булды. Шаһ Гали ике-өч якыны, хатыны белән берүзе генә исән калып, өч ел төрмәдә череп, үлем көтеп ята иде.

Менә хәзер, Шаһ Галинең кирәге чыгып, баярлар аны азат итәргә, дип сөйләште. Елена кенәзбикә улына әйтте:

— И, бөек кенәз Иван Васильевич! Белозеродагы зинданда, синең хөкемеңне көтеп, тилмереп ятучы татар ханы Шаһ Галине азат итеп, үз хозурыңа алып кайтырга фәрманың багышла!— диде.

«Татар ханы» дигәч тә Иван дерт итте. Матур әкиятләрдәге ханнар, шаһзадәләр, солтаннар аның хыялында кул җитмәс биеклектә, акыл үрелә алмаслык югарыда иде әле. Татар ханының төрмәдә утыруы бер гаҗәпсендерсә, аны азат итү аның үз ихтыярыннан торганын ишеткәч тагын гаҗәпләнде, турайды да:

— Татар ханы хозурымда булсын!— диде. Аннан соң:— Шаһ Гали ханга һәртөрле хөрмәт вә олылау булсын!— дип тә өстәде.

Иван хәтерли, Шаһ Галине Белозеро зинданыннан тантаналы төстә коткару өчен баярлар Иван исеменнән Никита Туранинны җибәргәннәр иде. Иван Шаһ Галинең кайтуын ашкынып көтте. Аның тере татар ханын үз күзләре белән күрәсе килә иде. Әкиятләр, дастаннар, маҗараларда гына түгел, хәзер аның каршысында кайчандыр Касыймда, Казанда хан булган, тагын хан булырга тиеш татар торачак. «Ха-ан» дигән сүз үзе генә дә дөнья бәһасе тора, «ке-нә-әз» түгел бит инде, «ха-ан». Чыңгыз ха-ан, Бату ха-ан, Туктамыш ха-ан, Олы Мөхәммәт ха-ан! Менә хәзер ишек ачылыр, мәһабәт Шаһ Гали хан килеп керер, мәгърур басып, бөек кенәз Иван Васильичка сәлам бирер...

Чыннан да, ишек ачылды. Никита Туранин күренде:

— Бөек кенәз Иван Васильич, боерыгың үтәлде!— диде Никита.— Шаһ Гали хан әмереңне көтә!

— Кертегез!— диде Иван.

Ишек яктылыгында бер шәүлә күренде.

— Каршыңда Шаһ Гали хан!— диде баяр Туранин.

Артыннан ишек ябылуга, шәүлә идәнгә егылды. Бөек татар ханы урынында таушалып беткән, буе юк бер түгәрәк чүмәлә ята иде. Шул чүмәлә тәхеткә таба тәгәри башлады, идән уртасына җиткәч, чикмәнгә төрелгән бу түмгәк үрмәләп китте, аннан шуыша башлады.

Иван бу затка җентекләбрәк бакты. Ханның аяклары, итекләре күренми, тезләнгәнлектән, җөббә итәге итекләрне каплаган. Куллары — әллә ачлыктан, әллә күпшәклектән — кабарынкы, кыска-юан бармаклары калтырый иде. Беренче карауга яшь Иван аны кызганды бугай, ләкин икенче мизгелдә үк аның күңелендә җирәнү уянды, җирәнү нәфрәткә әверелде. Аягы астында, сайгакта ауный-тәгәри ярлыкау теләнгән бу бәндә белән Иван хыялындагы мәгърур ханнар арасында бернинди бәйләныш-җеп тә юк иде. Их, шушы шешенке кабакчырайга тибәргә иде, яньчергә иде бу күпшәк чырайны, үз нәҗесен үзенә ашатырга иде. Ихтимал, ул чакта Иван алай уйламагандыр да, үскәч-олыгайгач, шул вакыйганы исенә төшергән саен, Иванның нәкъ шулай итәсе, Шаһ Галине салып изәсе килә башлый. Татар риваятьләренең бал тәпәненә иң беренче нәҗес тамызучы Шаһ Гали булды. Яшь Иван ул чакта әйтәсе сүзен алдан ук әзерләп куйган иде, артык тантанасыз гына, татарча сүз башлады:

— Шаһ Гали ханга талык сәлам!— диде.

Баярларга бу сүз нык тәэсир ясады. Сабый гына булса да, баярлар белән киңәшеп тормыйча, анасына да әйтмичә, бөек кенәз үз белдеклеге

белән ханга татарча эндәште: ике вак кына нәрсә митрополит Даниил игътибарына эләкте. Иван беренче тапкыр үз теләге белән фәрман әйтте. Аның тавышында беренче тапкыр хөкемдарлык рухы сизелде. Бөек кенәз беренче тапкыр, үзе ни теләсә шулай, Шаһ Гали белән татарча сөйләшә башлады. Зур сакаллы олы баярлар, әлбәттә, моңа риза түгел иде, әмма митрополит өчен бу бик шатлыклы хәл, хикмәт урыс кенәзенең татарча сөйләвендә түгел, аның үзбаш булырга омтылуында иде. Димәк, сабый кенәз эчендә үзбаш хаким утыра. Димәк, каты куллы баярларның азатлыгы тараячак. «Талык сәлам — җылы сәлам», диме?

— Әйтегез ханга, аягына бассын! — диде бөек кенәз.

Монысы да митрополит өчен тагын бер сөенеч булды. Иван турыдан-туры ханга дәшми, баярларны эшкә җигә. Никита Туранин, хан җилкәсенә орынып, бөек кенәз әмерен җиткезде.

Иван баярларга күз сирпеп алды. Шаһ Галинең әмергә буйсынмыйча, һаман идәндә аунавынамы, әллә баярларның мыскыллы елмаюын үзенә кабул итепме, Иван каты итеп кычкырды:

— Торып бас!

Шаһ Гали эшне аңлады: кабалана-сөртенә калкынды.

— Хәзер сүзең әйт! — диде Иван.

Куып чыгарганчы, яңадан зинданга илтеп тыкканчы сүземне әйтеп калыйм дигәндәй Шаһ Гали тиз-тиз сөйли башлады:

— Синең атаң — минем падишаһым — Василий Иванович — мине яшь көенчә алып, үзенең баласын багышлаганы кеби, Казанга падишаһ итте. Мине олуг ярлыкашлар илә ярлыкаган иде. Үземнең начар гаклым, яман уем илә аның алдында гөнаһка төштем. Шуңа күрә, синең атаң, минем падишаһым, шушы начарлыкларым өчен миңа ачуланып, мине каргады. Хәзерендә син минем падишаһым. Атаңның миңа булган яхшылыкларын уйлап, миңа мәрхәмәт күрсәттең. Моны синең күңелеңә Алла салды. Юкса, минем гөнаһыма күрә мондый ирек миңа тимәс иде.

Ханның сүзе бик озынга киткәч, кенәз Карпов әйтте:

— И хан Шаһ Гали! Узган эшләреңне сөйләмә! Кенәз сине гафу итте, моннан соң аңа раст хезмәт кылырга иҗтиһад ит! — диде. Карпов тагын нидер әйтмәкче булган иде, Иван аның омтылышын кисеп:

— Шаһ Гали хан! — диде. — Бүген синең гөнаһларың хакында лаф кирәкмәс... Синең Мәскәү тарафына кылган яхшылыкларыңны истә тотаек. Ал, Шаһ Гали хан, сиңа каюлы тун бүләк булсын!

Шулчак Иванның анасы кенәзбикә Елена Глинская ханга эндәште:

— Шаһ Гали падишаһ! Олуг кенәз Василий Иваныч, ачуланып, сине каргаган иде, ләкин углыбыз бөек кенәз Иван Васильич вә башкалар, ягъни баярлар, сине багышлап, үзебезнең ярлыкавыбызны күрсәттек, йөзебезне күрергә ирек куйдык. Инде хәзерендә син борынгы эшләреңне оныт. Вәгъдәңне җиренә җиткез. Без үзебезнең олуг ярлыкавыбызны вә санлавыбызны багышларбыз.

Менә шул вакыйгадан соң, бөек кенәз Иван Васильевич зиһенендәге татарлар турындагы матур риваятьләр җимерелә башлады.

Илнең бөек кенәзе булса да, сабый Иван олы гәүдәле, күркәм сакаллы, юан тавышлы баярлардан шүрли, митрополит Даниил, руханилар, поплар янында тынып кала иде. Чиркәү кешеләреннән әллә нинди куәт бәреп тора, алар янында Иванга куркыныч, серле бер көч тәэсир итә башлый. Бу куркыныч-серле көчнең тәэсирен Иван бигрәк тә чиркәүдә тоя. Поп сөйләгәндә дә, псалом укыганда да, хор җырлаганда да ул тетрәнә, курка һәм үзендә дә шундый бер куәтнең оеша башлаганын сизеп, эчтән генә куана иде. Олпат баярлар, куәтле воеводалар, поплар яныннан киткәч, әлеге серле куәт арта, күкрәк читлеген кага башлый, тышка, иреккә чыгарга тели иде шикелле. Яшьтәшләре белән уйнаганда Иван үзеннән көчлеләргә сокланып-куркып карый, үзе белән тиңнәр белән пәрмә-пәр сугыша, үзеннән көчсезрәкләрне рәхәтләнеп тукмый, екса, көндәшенең өстенә менеп атлана, торгызмый интектерә, шуннан ләззәт ала. Тигезләр белән сугышта җиңелсә, өзгәләнә, елый, үч алу турында гына уйлап йөри. Тиңдәшен җиңә алса, аңа ашау да,

уку да кирәкми: маңгаенда шеш булса да, җәрәхәтләнгән булса да, ул рәхәтлек тоя иде.

Ниһаять, митрополит Даниил ата бөек кенәз сабый Иванны дини китаплар укырга өйрәтә башлады. Даниилның тырышлыгы бушка китмәде, аның кечкенә шәкерте Иван үҗәтләнеп чиркәүгә йөри. Матур дастаннар бөтенләй онытылды, хәзер христиан дине тарихындагы изге атакайларның кургән мажаралары Иван күңеленең түренә менеп урнашты.

Иванның ни уйлаганын, ни теләгәнен анасы кенәзбикә Елена Глинская да белми иде. Митрополит Даниил атакай гына, яшьли ятим калып үскән, дөньяга ачулы бу үсмер кенәзнең эчендә нәфрәтле, үчле көч ялганын сизде. Аның уйнавы сабый беркатлылыгыннан түгел, ә бәлки, әнә шул, эчтәге билгесез бер кара гайрәтнең үзеннән килеп чыга кебек. Митрополит, аның үҗәт рәвештә чукынганын кара бәрхет чаршау тишегеннән карап, әнә шул хакта уйлады: христиан динен тарату тыныч юл белән генә булмаячак икән. Мөселманнарны христианлаштыру өчен иң башта аларны кылыч астына салырга кирәк. Аның өчен куәт кирәк. Ул куәтне әйдәү өчен рәһбәр кирәк. Ул рәһбәргә нык рух өрер өчен мәсих кирәк. Барысы да бар, шөкер. Мәсих — митрополит иде. Рәһбәр — бөек кенәз Иван Васильич. Туплар, мылтык, халык бар. Бер генә нәрсә кала — яу. Яуларга да, мөселман халыкларын кылыч астына салырга. Чукынган — исән кала, чукынырга теләмәгәне мөселман килеш шәһит китә. Мөселман халыкларының кайсысы Мәскәүгә иң якын яши? Татарлар. Кырым-Кавказ, Хаҗитарханны яулау өчен иң беренче чиратта Казанны сытарга кирәк. Аны кем сытар? Казанны бөек кенәз Дүртенче Иван сытар...

Ләкин Иванның бу максатка тугры барышын тәрбия кылырга, бүтәннәргә, анасы Елена кенәзбикәгә дә, Иванның үзенә дә сиздермәенчә, шушы сабыйдан яңа мәсих ясарга кирәк. Митрополит Даниил Иванның бөтен яшерен җепләрен, кайсы сеңерне кай якка тартасын бик яхшы өйрәнде...

Үзен белә башлаганнан бирле, Иван гайбәт арасында үсте. Мәскәү гайбәтләрен күбрәк яшь баярлар тарата. Кенәзләр, баярларның хәтәр маҗаралары турында тозлы, борычлы сүзләр Иван колагына да килеп ирешә. Иван кызык урында көлми, хәтәр урында аһ-ваһ килми. Шулай да ул тыңларга ярата. Ләкин беркайчан да вакыйга сөйләүне үзе сорамый. Аңа үзләре сөйлиләр... Иван үзенең ил патшасы икәнен бер генә мизгелгә дә оныта алмый. Көчлерәк баяр балалары, көрәштә Иванны җиңә алса да, үзе егыла, бөек кенәзгә юл куя. Көчсезләре Иваннан җиңелүне бәхет саный.

Бервакыт шулай булды. Бер өер олы баяр балалары белән уйнаганда Матвей Яузов атлы кенәз баласы Семен белән Харлампий исемле малай бәхәсләшеп китте. Бәхәс сугышка барып җитте. Иванга Семен хаксыз сыман тоелды, ахрысы, ул аны уеннан чыгарды. Семен, елый-елый, кайтып китте, бераз баргач, борылып кычкырды:

— Харлаша-параша! Бик масайма, Иван Васильичның дусты дигәч тә, борыныңны бик күтәрмә. Синең Иван Васильич турында ни сөйләгәнеңне әйтсәмме?!

Баяр баласы Семен сүзен әйтеп бетермәде, Иван, корт чаккан яшь үгездәй Семен ягына ыргылды, малайның якасыннан эләктерде, икенче кулы белән иягенә орды:

— Нәрсә сөйләде ул? — диде Иван чак ишетелерлек итеп. — Иван Васильич турында Харлаша ни сөйләде?

Семен Яузов агарып китте. Иван ярсып аны кыйный башлады, каты итеп тубык чәкәненә типте, йодрыгы белән башына сукты — Семен егылды. Үкчәсе белән авызына типте — авыз-борын тарафыннан кара кан бөркелде. Аннан сугып, изеп, типкәләп, мышнап, ярсып беткәч әйтте:

— Үтерәм, бабасыр! — диде. — Әйтәсеңме, юкмы?

— Ул... — диде Семен. — үзе Харлампий ягына карап алды. — Ул сине... анаң сине... Княгиня Елена атаңнан түгел... сине Василий Иванычныкы түгел икән, диде...

— Минем атам Василий булмагач, кем була инде?
— Ат караучы татар, баш конюшный Абяшевтан, диде...
Семен туктады, калганнарын сөйли алмыйм дигәндәй, хуҗасына ялварып караган эттәй төртелеп калды. Ләкин Иван рәхимсез иде, үзен дә, Семенны да кызганмастан таләп куйды:
— Сөйлә! Берсен дә калдырма!
— Ул әйтте, әллә ничә ел Василий Иваныч белән торып, княгиня Софияның бәбәе булмаган. Шуңа күрә, атаң аны аерган... Аннан соң анаңа, княгиня Еленага өйләнгән... Барыбер балалары булмаган, бик озактан соң гына син тугансың инде... Бөтен хатыннар, бөтен баярлар шунда әйткән: Софиянең һич гаебе булмаган, диде...
Алар сөйләшкәнен, Семенның ни әйткәнен үсмерләр ишетмәде, алар, куркышып-өелешеп бу кыйнашны читтән карап торалар, ни кылырга белмиләр иде. Иван йомшады, янаулы кыяфәте шиңде. Семенга кабат сукмады.
— Бар!— диде ул тыныч кына.— Чишмәдә юын. Өеңдә әйт, егылдым, диген... Бу сүзеңне тагын берәүгә әйтсәң — үтерәм!
— Әйтмим, әйтмим, Иван Васильич!— диде малай.
Семен буага юынырга китте. Бүтәннәр һаман түмәр кебек катып тора иде әле. Иван, алар янына килеп, йомшак тавыш белән әйтте:
— Бүгенгә җитәр!— диде.— Кайтыгыз!
Барысы да кайтып киткәч, Иван буа сукмагыннан менеп килүче Семенны көтеп алды:
— Кил,— диде.— Утыр!
Семен, тарсынып кына, җиргә чүмәште.
— Хәзер берсен дә калдырмыйча тез!— диде хуҗа.— Бу сүзне кемнәр ишетте?
Мәгълүм булды: бу төркемнән — Евстигней, тагын Семен үзе, баяр баласы Аркаша Иваныч ишеткән. Харлаша үзе исә анасы белән апасы сөйләгәндә тыңлап торган икән.
— Кайда, тагын кем шушы сүзне кемгә әйтә — ишетсәң, миңа чап! Син минем дустым булырсың!
— Колың булам, бөек кенәз Иван Васильич!— диде Семен.
Шул көннән соң Иван алышынган кебек булды. Үткен күзле карт төлке Даниил күзенә кечкенә үзгәреш тә күренмичә калмый иде. Иван тагын да төкселәнде, аңа олылар төсе иңде...
Шушы вакыйгадан соң байтак вакыт узгач, Иван бер өер баяр балалары белән Мәскәү елгасы буена ауга китте. Кенәзнең ат менеп ауга чыгасын белсә, Мәскәү халкы урамда булса — ишегалдына, ишегалдында булса — өенә кереп качарга тырыша башлады. Иванның гадәте шундыйга әйләнде: үзе кебек усал-дәһшәтле айгырын, камчы белән сугып, бар көченә куа. Урамда бала-чага уйный, тавык-мал йөриме, шәһәр кешеләре бармы — ул ак-кара күрми, дөньяны туздырып чаба. Мал тапталамы, кеше имгәнәме — аның эше юк. Качканы качып өлгерә, өлгерә алмаганы — ат тоягы астында кала.
Бу юлы ауга чыгар алдыннан Иван яшь баярларга мылтык янына ук-җәя дә алырга боерды. Мылтык тавышыннан җәнлекләр курка: кондыз белән урман тавыгына иң җайлысы — җәя белән ук. Тигезә алмасаң да, якындагы кош-корт курыкмый...
Ау азагында быргы тавышына бер урынга җыелырга килешенгән иде. Яшь сунарчылар берәм-берәм урманнан чыга башлады. Ау мул булды. Кем күпме тавык аткан, кемгә бәхет, кемгә кондыз эләккәне мәгълүм булды. Әмма яшь баяр Харлаша Задорнов күренмәде. Берничә тапкыр быргы уйнаттылар. Мылтык шартлаттылар. Җавап бирүче булмады. Кычкыра-кычкыра, Харлампийны эзләргә таралдылар. Ләкин яшь баяр табылмады. Икенче көнне дә ул кайтмады. Олылар, күпләп эзли чыгып, өч көн, өч төн урман сазлыкларны айкап та, югалган сунарчыны тапмадылар. Шул рәвешчә, яшь баяр Харлампий Задорнов эзсез югалды.
Харлашаның үле гәүдәсе сазлыкка батырылганын өч кенә кеше белә иде: Иван үзе, Харлампийны үтереп, сазга батыручы яшь баяр Семен Яузов

һәм митрополит Даниил. Ләкин Даниил атакайның бу яшерен маҗарадан хәбәрдар икәнен Иван да, Семен да белми иде...

Иван теге чакта, тәпәчле уйнаганда Семен Яузов авызыннан ялгыш ычкынган сүзнең таралып өлгергәнлегенә ышанды. Бу гайбәтне белгән, ишеткән һәр кеше үләргә тиеш иде. Ләкин бөтен Мәскәү халкын кырып бетереп булмый. Гайбәт таратучылар ун-унбиш булып, аларны үтереп бетерсә дә, гайбәтнең тамыры корыса да. Иван кирегә үзгәрә алмас иде, шат чырайлы кеше була алмас иде. Аның эченә поскан шом, дәһшәтле бер теләк, бу канлы вакыйгалардан соң, ана карынындагы яралгыга кинәт җан кергәндәй, искәрмәстән кыймылдый башлады. Семен аңа бөтенесен җиткезеп торды. Иван — үзе турында ни сөйләнә — барысын да тәфсилләп белә иде. Шуннан соң ул бәгырендәге нәфрәт яралгысын бик теләп, иркенгә куеп, ләззәтләнеп тәрбия кыла башлады. Иң беренче нәфрәт, зәһәрле нәфрәт анасы кенәзбикә Елена Глинскаяга аталып шытты. Кеше сүзе хакмы, юкмы? Хак булса? Димәк, бу ана эт, хәләл ире өстеннән йөреп, гөнаһлы мәхәббәт ләззәте татыган булып чыга. Шул зинадан Иван яралган булып чыга. Икенче нәфрәт угы мәрхүм бөек кенәз Василий Иванычка аталган иде. Димәк, бөек кенәз аның үз атасы түгел. Димәк, аның тамырларында Донскойлар, Өченче Иваннар каны акмый? Димәк, бөек кенәз Василий Иваныч хатыны Еленаның хыянәтен сизмәслек дәрәҗәдә мәхлук булган? Бәс, халык хак әйткән: Василий Иваныч ир рәвешендә кысыр булган... Өченче нәфрәт зәһәре Мәскәүнең атаклы атчысы — татар Абяшевка төбәлгән иде. Ул Абяшевны бик яхшы белә. Кечкенәдән ат янында кайнашканда Абяшев аны күп нәрсәгә өйрәтте. Кочаклап күтәреп, ияргә беренче ул утыртты — Иван бәхетле иде, атта йөреп кайткач та иярдән ул Абяшев кочагына егыла иде, кызык була иде, рәхәт иде. Бәлки, чыннан да, Иванны үз баласы булганга ул шулай яраткандыр?..

Митрополит Даниил вакыт җиткәнен бик яхшы аңлады. Ул Мәскәүнең бөек кенәзе Дүртенче Иван Кансызның рәһбәре булды.

## Колбикә

Сөембикәне углы Үтәмеш Гәрәй ханны вә бик күп Казан бәкләренең хатыннарын, балаларын төягән көймәләр Мәскәү елгасындагы бәрек-рыһтымга терәлеп туктады. Әсир төшкән ханны, Сөембикәне, затлы бикәләрне күрергә дип, яр буена бик күп халык төшкән, тамаша карарга дип, тагын бик күп кеше урамнар буйлап агыла. Көймәләрне сакларга китерелгән гаскәр башлыклары да, Сөембикәне озата китерүчеләр дә халыкны таратырга кирәклеген әйтте. Воеводалар, яшь баярлар халыкны ярдан урамнарга таба куа башлады. Юлда арыган бәкләрне дә, яшь ханны да күрсәтергә ярамый, янәсе. Әмма хикмәт бүтәндә иде. Сөембикәнең вә ахирәтләренең вә башка затлы бикәчләрнең, тутайларның йөзен халыкка күрсәтерлек түгел иде. Егерме өч көнлек юлда, юл буена елап, чәчләрен туздырып, тырнаклары белән чырайларын суеп, хатын-кызлар гүзәллекләрен ихтыярый бозып бетергән иде. Сөембикәнең йөзендә җәрәхәтләнмәгән урын юк. Нугай далаларыннан килгән борынгы йоланы үтәве идеме ханбикәнең? Якын кешең вафат булгач, шулай кылыш зарури. Дөрес, әмма Сөембикәнең максаты йола үтәү генә түгел иде. Мәгълүм ки, Кансыз Иван сәрхүш чагында бөтен баярлары вә Казан илчеләре алдында ант эчкән: мәшһүрә гүзәл хатын Сөембикәне үземә алып күкрәген түшәк ясамасам, урыным җәһәннәмдә булсын, дигән. Сөембикә ул кяфер Иванга булмас! Аның чыраендагы төзәлеп кутырлаган, төзәлеп бетмәгән җөйләрен һәм яңа җәрәхәтләрне күргәч, Сөембикәдән Иванның гайрәте чигәр.

Көймәләрдән тоткыннарны ике кат сак белән алып чыгып, таш кирмән — Кремль эчендәге ярым төрмә, ярым йорт кебек җиргә урнаштырдылар.

Икенче көнне үк Иван Сөембикәне күрергә теләде. Йомышлы татарлар да, баярлар да бөек кенәзгә нидер әйтергә теләгән иде. Иван аларның сулышын кисте:

— Хәзер үк!— диде.

Нишләмәк кирәк, Иван мәшһүрә Сөембикәне көтә-көтә тәкатьсез калган икән, боерыкны үтәргә туры килә. Озакламастан Сөембикәне бөек Иван хозурына бастырдылар. Сөембикәнең йөзе каплаулы иде.

— Талык сәлам, Ханбикә!— диде Иван.

Җавап булмады, иелеп, егылып тезләнү дә күренмәде.

— Курыкма, мәшһүрә гүзәл Сөембикә ханша!— диде Иван.— Сиңа монда олы хөрмәт булыр. Күп холоплар сиңа хезмәт кылыр. Углың Үтәмеш Гәрәй ханны да үз углымдай күрермен... Нишләмәк кирәк ки! Аллаһның гозере шулай булды. Синең әсирлегең коллык түгелдер. Син монда кунак, тантаналы бер шартларда яшәрсең...

Иван Сөембикәнең дәшмәвен хатын-кызның гадәти кирелеге, ялындыруы гына дип уйлады. Аннан соң, биредә Казан бәкләре дә, баярлар да күп. Ихтимал, бергә-бер калгач кына ханбикәнең теле ачылыр. Иван ишарәсеннән соң татар бәкләре дә, баярлар да, баш ия-ия, артка чигә-чигә чыгып юк булды.

Иванның һичкайчан да хатын-кызга ялынганы булмады. Бу юлы ул әсир хатын янында озак сөйләнде. Ләкин Сөембикә селкенмәде дә. Иванның эче кайный башлаган иде инде, бер җене чыкса, бу кире хатынны изеп, өзгәләп ташлый иде; ни гаҗәп, ул түзде, шулай да, кинәт усал хәрәкәт илә, Сөембикәнең баш тастарын йолкып алды. Бикә сизми калдымы, ничек торган шул рәвешле мәгърур басып калды, ике учы белән чыраен да капламады, тәкәббәр кыяфәттә бөек кенәзнең күзенә туры карады. Иван моны көтмәгән иде. Күзе, карашы... Карашы гына, күзләре генә яргаланмыйча калган Сөембикәнең.

Хыял чәлпәрәмә килде. Көйсез Иванның кулыннан тагын уенчыгын тартып алдылар. Сабый Иван зиһенендәге гүзәл Сөембикәне тагын урладылар. Иван карашындагы каушауны Сөембикә бик яхшы күрде. Бер мизгелгә генә булса да, ул рәхимсез Иванны җиңде. Җиңде Сөембикә Кансыз Иванны: ул гүзәлләр гүзәле Сөембикәне Иванга бирмәде, ул Иван ихтыярына каршы төште... Кулындагы тастарны ике йодрыгына йомарлап, бөек кенәз тәхетенә таба атлады. Ләкин ул калкулыкка менмәде, идәнгә утырып, тәхет күтәртмәсенә башын куеп ятты. Бөек Мәскәүнең бөек кенәзе елый иде. Егермене узган олы-ир булып, «Кансыз, Рәхимсез, Дәһшәтле» кушаматлары алган бу кенәзнең әсир хатын шаһитлегендә елавын Сөембикә аңламады...

Гүзәлләр гүзәле, шөһрәтле ханбикәнең йөзен воеводалармы шулай гарипләгән? Әллә бикәнең кан дошманы Булат бәк Ширин этләреме ергычлаган? Кем? Ниндидер билгесез бер кодрәт Иванның сабыйлык хыялларын җимерә килә? Бераздан Иван аякланды. Тастарны Сөембикәгә ыргытты, ләкин тастар аңа кадәр барып җитә алмады, юл уртасында идәнгә очып кунды. Сөембикә тастарга үрелмәде. Иван тынычлана төште, сабыр, әмма усал тавыш белән:

— Кем?— диде.

Сөембикә дәшмәде.

— Кем сине болай... Күз алдыңда суям шул кабихне! Нәселен бүген үк кырам! Татарлармы? Микулинскиймы, Петрмы? Кем?!

Әсир җавап кайтармады. Иван сәерсенеп куйды. Иванның авыр, төксе карашы кичерә алган кешенең булганы юк. Әллә нинди олы мәртәбә яулаган поплар да, гайрәтле баярлар да Иванга туры карый алмый иде. Караса, күзен шундук читкә ала. Сәерсенде Иван. Бу җәберләрдән Сөембикә шашканмы әллә? Әллә ул ишетми, күрмиме?

Ишетүен ишетә Сөембикә, күрүен дә күрә Сөембикә, әмма ул, күз кабагын ябып-ябып алырга онытып, хыялы белән Айдалада йөри. Табанлы күлдә ахирәтләре белән су коена, сөекле Казанында Баги Сафа бакчасында истирахәт кичә. Бичара тоткын бикә күзләрендә чагылган әнә шул бәхетне, ләззәтне күрде Иван; ул Сөембикәнең җәрәхәтле-ямьсез чыраеннан

гүзәллек эзли иде. Рәхимсез Иванның рәхимсез бәгырендә наз сеңере тартылып, зеңләп куйды. Булган ул матурлык, булган, ләкин ул матурлыкны изгәннәр, хәнҗәр илә яргалаганнар, әмма үтерә алмаганнар. Илаһи ул гүзәллек Сөембикәнең күз алмаларыннан чыгып, керфекләргә орынып, читкә тарала.

Иван ишек тарафына кычкырды:

— Кем бар анда? Керегез!— диде.

Сөембикәне Казаннан алып кайткан баярлар белән Казан бәкләре керде. Тәхеттәге Иванга, идән уртасындагы яланбашлы Сөембикәгә, аяк астындагы баш каплавычына карап, барысы да монда ни хәлләр булганын аңларга тырышты.

— Кем?— диде бөек кенәз.— Кем бикәне шулай рәнҗетте? Кем эше бу? Үзен, хатынын, балаларын бүген үк чаптырачакмын!

Баярлар да, татарлар да, шомланып, кенәзгә бакты:

— Үзе!— диде воеводалар.

— Үзе!— диде татарлар.— Үзе, Иван Васильич!

Бу катгый вә ышандырырлык җавап кенәзне беразга ихтыярсыз калдырды. Бер уйласаң, бу хәбәр ышанырлык түгел. Икенче уйласаң, Сөембикәнең холкына, мәгъруррлыгына, үҗәт-кирелегенә бу фәгалият тәңгәл килә кебек. Әмма Иванның катлаулы рухы бу җаваптан тынычлык алмады.

— Нигә сакламадыгыз?— диде Иван дәһшәт илә.— Нигә юл куйдыгыз? Аның үзен-үзе җәфалавын ярыктанмы карап тордыгыз?— Тәхет янында куркыныч шом урнашты.— Егерме биш көн буена аның ни кылганын нигә күзәтмәдегез? Нигә кулларын бәйләп, аның йөзен сакламадыгыз?

Иван, шундук тикшерү-хөкем ясап, карар чыгарды һәм юл буе Сөембикәнең ишеге төбендә алмашлап сакта торган берничә баярны, воеводаны һәм татар бәкләрен зинданга ябарга кушты. Бу хөкем барышында Сөембикә, ничек баскан, шул рәвештә торды. Сөембикә көймәсендәге баярлар белән татар бәкләрен алып киткәч, Иван калганнарга әйтте:

— Сөембикәне патша хатыны кебек тәрбия кылырга! Улын, Үтәмеш Гәрәйне, хан кыяфәтендә тотарга! Бикәне, өшкерүчеләр чакырып, бер ай эчендә элеккеге хәленә китерергә! Хәтта элеккесеннән дә сәламәт, чибәр булсын! Аның йөзендәге һәр сызык өчен башыгыз белән җавап тотачаксыз!

Бу сүзләрне Иван куркытыр өчен генә әйтмәде.

Сөембикәне якыннары белән Балчык Бистәсе дигән татарлар шәһәрчегендәге бик яхшы йортка куйдылар. Бу йорт үзе бер шәһәрчек кебек, коймакальга белән уратылган, эчендә берничә бина, мунчасы, бакчасы бар, хәтта чишмәсе-коесы да үзендә иде. Тоткыннар биредә үзләре белгәнчә яши ала. Әмма Сөембикә вә Үтәмеш Гәрәй хан янына нык сак куелды. Качу-качмау мәсьәләсеннән битәр, бикәнең үзен-үзе үтерүе һәм үзен-үзе тагын җәрәхәтләве бар иде. Әсирләр янына ашчылар, мич ягучылар, өйне-ишегалдын җыештыручылар һәм Сөембикәнең җәрәхәтләренә май сөртүче хатыннар гына керә-чыга ала. Аларның һәрберсе шымчы-әләкче, һәр сүзне җиткереп, һәр адымны күзәтеп торырга куелган җасуслар икәнен Сөембикә яхшы белә иде. Алар Кырым, Нугай, Казан ягыннан килгән кешеләрне Сөембикә белән очраштырмау өчен дә куелган иде. Әсирләргә ишегалдына, бакчага, чишмәгә чыгып йөрергә рөхсәт ителгән, әмма тышкы капкаларга, капка башларына, өй түбәләренә, арт ишекләргә өч сәгатьтән өч сәгатькә алмашынырга тиешле каравыл бастырылган.

Көннәр шулай гел бертөрле, әкрен уза иде. Үтәмеш аз-маз бәетләр тыңлый, ахирәтләрнең дала сагыну кичәләрендә катнаша, көндезләрен ишегалдында үзенә уен таба. Шулай, таяк атып, чүрәкәй сыман йомычкага бәреп, үзенә кызык табып йөргәндә ул ишегалдындагы юынтык су түгә торган баз янында, чүплектә иснәнүче бер көчекне күрде. Көчек тә Үтәмешкә карап алды.

— Маһ-маһ, маһмай!— диде Үтәмеш.

Көчекнең койрыгы зырлап әйләнә башлады. Үтәмеш, аш-су өенә йөгереп кереп, бер телем ипи белән бер кисәк сөякле ит алып чыкты. Сабый кулындагы ризыкны күргән көчек, атылып, Үтәмеш янына килде.

— Маһ-маһ, маһмай, аша, маһмай!— дип сөйләнә-сөйләнә, ул көчеккә ипи турап ташлады, алдына ит куйды.

Берәрсе тәмле ризыгымны тартып алмагае, дигәндәй алак-ялак каранга-лап, көчек кабаланып ашый башлады. Үтәмеш сак кына көчеккә үрелде, бәләкәй маэмай яңа хуҗасына сырпалана башлады. Ризык ашалып беткәч, Үтәмеш әйтте:

— Әйдә, маһмай, хәзер уйныйк инде! Син миңа иптәш булырсың!— ди-де.

Үтәмеш йөгергән булып китте, көчек уйнаклап аңа иярде. Үтәмеш абы-нып егылган булды, көчек тә мәтәлчек атарга тотынды. Бик озак уйнады алар.

— Үтәмеш!— диде Нәргәтай.— Өйгә керер вакыт. Сиңа чәй тәмләдем.

Аерылышуны сизептер, ахрысы, көчек чиный башлады. Үтәмешкә дә са-гыш төште.

— Китмә син, көчек!— диде сабый.— Мин сиңа оя ясап бирермен. Исем дә кушармын. Исемсез ат та, исемсез эт тә булмый! Табылдык булыр синең исемең. Ризамы?

Эт ризалык белдереп, өрә-өрә койрык болгады. Үтәмеш шундук утын-лыкта оя ясарга керешә. Оя әзер булгач, ул:

— Табылдык, менә синең йортың, кер,— диде.

Көчек түмәрләр арасындагы ояга кереп ятты.

Шул көннән соң Үтәмеш Гәрәй ханның әсирлектәге көннәре җанланып китте. Көчек белән сабый хан иртәдән кичкә чаклы уйный. Көчекнең тамагы тук. Үтәмешкә иптәш бар. Үтәмеш Табылдыкны лапта-чүрәкәй уйнарга да өйрәтте. Бәләкәй маэмай хуҗасы лапта белән бәреп җибәргән чүрәкәй ар-тыннан томырылып чаба да чүрәкәйне кабып хуҗасына китереп бирә. Ике-сенә дә кызык, сөенеч. Капка өстендә, түбәдә сакта торучыларга да кызык була, алар да көчек белән бала уйнаганны рәхәтләнеп карый. Бер көнне чүрәкәй койма өстеннән урамга очып чыкты. Табылдык капка астыннан урамга атылды, әһ иткәнче ишегалдына керде. Аның авызында чүрәкәй иде. Хәзер чүрәкәй койма-капка өстеннән гел урамга оча...

Үтәмеш Гәрәй ханга шундый дус табылганга өйдәгеләр сөенеп туя ал-мады. Сабый кич төшкәч кенә өйгә кереп егыла да йокыга китә. Хатын-кыз-лар төннәр буе бер нәрсә турында пышылдаша: ничек итеп Казан, Нугай яки Кырым белән бәйләнеш тотарга? Ничек итеп әмир Йосыфка хәбәр җибәрергә? Ничек итеп туганнарны берләштереп, Казанны сакларга, ничек итеп бу коллыктан котылырга? Атасы аны ташламас, абзыйлары да, агалары да бераз ярдәм итеп, илле мең, алтмыш мең елкыга алар Сөембикәне якын-нары вә углы белән сатып алырга тиешлеген ничек белгертергә? Күрәләтә болай әсирлектә калдырмаслар... Хәбәр бирү һич мөмкин түгел. Сак-каравыл кат-кат куелган. Урамның бу ягыннан үтеп-сүтеп йөрүче юк. Урамның аргы ягыннан гына йөрергә рөхсәт...

Ябылуда бер ай ятканда гадәттән тыш хәл булды. Ишегалдына Үтәмеш атылып керде.

— Анакаем!— диде.— Менә.

Үтәмеш анасына чүрәкәй сузды.

— Бу ни?— диде ана.

— Бу чүрәкәй?— диде бала.— Чүрәкәйдә язу бар.

Сөембикә чүрәкәйнең ике ягында да язу күрде.

— Каян алдың моны?— диде бикә.

— Табылдык урамнан алып керде,— диде сабый.

Сөембикә язуны сөртеп бетерде дә чүрәкәйгә нидер язды:

— Мә, улым, Табылдык белән тагын шулай уйнагыз!— диде ана.

Үтәмеш ишегалдына чыгып китте. Сөембикә белән Нәргәтай томаланган тәрәзәнең пәрдәсен чак кына ачты. Урамның теге ягында билгесез бер кеше арба төзәтә иде, ул янына килеп төшкән чүрәкәйне алып, аның урынына шундый ук бүтән чүрәкәй ташлады. Ул арада Табылдык, капка астыннан атылып чыкты да, чүрәкәйне эзли башлады. Ниһаять, ул, яңа чүрәкәйне та-бып, исnәп-иснәп карады да, тешләп, янә капка астыннан кереп юк булды.

Иван куйган бер ай вакыт бетте. Иртәгә Сөембикә сәламәт кыяфәттә бөек кенәз алдында басып торырга тиеш. Сөембикәнең кәефе әйбәт иде. Чүрәкәй аша язылган хатлар аның күңелен юаткан: әллә Иван белән көрәшүдәнме ул яхшы нәтиҗә көтә? Бу турыда Нәргәтәй да белмәде. Нәргәтәй болай уйлады: Сөембикә Иванга әсирлектән котылу шартларын әйтер. Илле мең елкыдан бер патша да баш тартмас. Башында акылы булса, Иван бу форсатны ычкындырмас. Ләкин Нәргәтәй бик нык ялгыша иде. Иван патша Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне илле — йөз мең баш елкыга гына түгел, йөз мең ат башы чаклы алтынга да алыштырмаячак иде.

— И ханбикә,— диде сакчылар башлыгы,— бөек кенәз сине көтә.

Сөембикәнең ай буена бик теләп дәваланганын Иван белеп торды. Ул бу эшне үзенчә юрады: ханбикә, кирелеген ташлап, язмышына буйсынды, янәсе. Шуңа күрә, ахрысы, Иван гадәттәгегә караганда кәефлерәк иде. Бу юлы сакчылар Сөембикәне тәхет янына түгел, Иванның аерым бер йортына алып килде. Бу йортта сәясәт, халыкара мөнәсәбәтләр турында сөйләшмәячәкләрен Сөембикә ишектән керүгә үк аңлады: бу — бөек кенәзнең күңел ача торган хоромы иде. Өстәл тулы сый-нигъмәт, шешәләр. Табыннан түрдәрәк — чаршаулы ятак. Ятак янында идәндә ләгән белән зур чүмеч, су белән тулы тәпән тора.

— Йөзен ачыгыз!— диде хаким.

Ике сакчы ике яктан Сөембикәнең йөз каплавычын алды. Сөембикәнең йөзе чистарган, җәрәхәтләре җөйләнеп, тимгел-тимгел булып торса да, элеккеге гүзәллекне каплый алмаган... Һич сүзсез, ишарәсез генә сакчылар юк булды. Хаким Иван белән әсир Сөембикә икәүдән-икәү генә калды.

— Яхшы!— диде кенәз.— Бик яхшы.— Ул ике көмеш савытка шәрап койды.

Ләкин аның тәкъдиме нәтиҗәсез калды. Иван кинәт Сөембикәгә таба борылды һәм аңлады: бу киребеткән хатын аңа буйсынмаячак. Кенәз савытындагы эчемлекне бер йотым белән эчеп бетерде дә, үзенчә мыгырданып, күз ачып йомганчы җиләнен салып идәнгә ыргытты. Сөембикәнең моңа бер дә исе китмәде. Иванның кыланмышы аңа тәэсир итмәде. Хуҗаның җене котыра башлаган иде инде. Ул:

— Барыбер сындырам бит мин сине,— дип, янаулы рәвештә корбанына таба атлады.

Шул мәлне үк Сөембикә, бер ыргым ясап, әллә каян хәнҗәр тартып чыгарды.

— Торып кал!— диде бикә.— Торып кал, Иван! Тагын бер атласаң, хәнҗәрем үз бәгыремә батар!

Әсир ханша күзләреннән Иван яхшы аңлады: бу хатын әйткәнен үтәячәк.

— Селкенсәң дә үз дигәнемне башкарам!— дип кабатлады Сөембикә.— Кяфердән нәҗесләнеп үлгәнче, үземне-үзем бетерәм. Мәетем белән теләсә ни кыла аласың!

Иванның сеңерләре бушанды, җиңелгән, ризалашкан кыяфәттә җиләнен алып киде дә, янә бер көрәгә аракы эчте. Үзалдына сөйләнә-сөйләнә, тәрәзә янына килде, калын пәрдәне ача төшеп, Сөембикә аңларлык итеп:

— Юкка уйныйсың син, колбикә!— диде.— Сине үз астыма салу миңа өч сукыр тиенгә дә тормый. Синең ризалыгың кирәк миңа.

Иван кемгәдер кул болгады шикелле.

— Үтәмеш углыңны кызган!— диде кенәз.

Углының исемен ишеткәч, Сөембикә тәрәзәгә ыргылды: сакчылар Үтәмешне каядыр алып китеп бара иде.

— Үтәмеш!— дип кычкырды бикә.

Ләкин сабый аны ишетмәде.

Ул арада Иван Сөембикәгә ташланды.

Сөембикә ычкынып китте, бар ишектән дә сакчылар керде. Колбикә хәнҗәрен күкрәгенә терәде, кемдер аның аягы астына егылды, кемдер кулын тотарга омтылды: ул арада бикә берничә мәртәбә кискен хәрәкәт яса-

ды; сакчылар, аның хәнҗәрен алып, кулларын каерды. Сөембикәнең күкрәгеннән, йөзеннән шаулап кан ага, үзе чекерәеп Иванга карый иде:

— Мәетемне нәҗесләрсең, Иван, мәетемне, дидем. Сиңа мәет өстендә яту төс!

Иван моңарчы түзде, әмма холоплар алдында бу сүзләрне тыңлау хурлык иде, кенәзнең миенә кан китереп орды: бөек кенәз бикә янына атылып килде дә эченә типте, бер типте, ике, өч типте, Сөембикәнең ихтыярсыз гәүдәсе ишелеп төште. Иван ысылдап кул изәде: сакчылар чыгып китте...

Сөембикәнең канлы гәүдәсен ике сакчы астагы тар зинданга төшереп яткызды. Хатыннар, табиплар чакырып, аның яраларын бәйләп, бераз су йоттырдылар. Димәк, Сөембикәне янә савыктырып, Иван җиңәргә өметләнә. Сөембикә үзен дәваларга кергән хатыннарга карышмады. Ул янә төзәлә башлады. Тыштан тыныч күренсә дә, ул эчтән яна иде: кая алып киттеләр Үтәмешне? Үтерергәме? Зинданга ташларгамы? Хәбәр алу өчен тизрәк савыгырга кирәк иде. Ихтимал, төзәлгәч, аны Иван тагын чакырыр. Шунда Үтәмешнең язмышы билгеле булыр.

Егерме көн узгач әйттеләр:

— Иртәгә Иван янына барасың, юмарт бул, тилебикә,— диделәр.

Ләкин икенче көнне дә, аннан соң да аны зинданнан алып чыкмадылар. Иван татарлар өстенә яуга китте, диделәр.

## Сөембикәнең соңгы көннәре

Мәскәүнең андый да олы бәйрәм күргәне юк иде әле. Татарларның җиңелүе, Казанның соңгы кирпеченә хәтле җимерелүе, татар ирләренең сигез яшьтән өстә булганнарының астырылуы, кистерелүе, Казанның соңгы ханы Ядигәр Мөхәммәтнең әсир төшүе, бәкләр, мирзаларның хатыннарын, кызларын, йөз меңләп ирне әсир итеп, Мәскәүгә алып кайтачакларын, Казан казнасындагы малны уналты олы көймәгә төяп алганнарын ишеткәч, Мәскәү халкы ай буе бәйрәм итте. Шатлык шулкадәр олы иде ки, Казан туфрагында күмелеп калган урысларның аналары, хатыннары, туганнары да сөенә-сөенә бии, ашый-эчә иде. Бу хәбәр Сөембикәгә дә килеп иреште: бүген ул төшендә Каракошның үз манарасы очына кунганын күргән иде.

Иван, Казан явыннан кайткач, өч көн, өч төн эчеп, ял итеп арганнан соң, җиңүчеләрне бүләкләү бәйрәме ясады.

Чапкыннар шәһәр буйлатып, ил буйлатып хәбәр салды: Мәскәүнең Мәркәзи мәйданында олы тамаша булачак. Бөек кенәз, бөтенрусиянең һәм Казан-Болгарның олуг патшасы Иван Васильевич мәйданга килгән һәр кешене бушлай ашатачак, бушлай эчертәчәк. Шунда Казанның соңгы ханнары һәм мәшһүр баһадир Кошчак углан һәм бәгъзе татарларның башы чабылачак. Тамашадан коры калмагыз! Мәскәүгә Мәркәзи мәйданга ашыгыгыз!

Патша белән якыннары, илчеләр, Казан сугышы батырлары, баярлар һәм дин әһелләре уртадагы калку урынга урнашты. Каршы якта — кара халык, һөнәрчеләр. Калкулыкта җәллад вә аның ярдәмчеләре янәшә баскан. Тамашачылар арасында пешкән кайнар ризыклар, кайнар эчемлекләр вә салкын исерткечләр таратып йөрүчеләр кайнаша. Беренче кар яуган көн итеп, һәркем җылырак киенгән. Патша Иван Васильевич бу тамашага Сөембикәне дә алып килергә боерган иде. Сөембикәне абруйлылар сафына, хатыннар арасына утыртып, арка ягына дүрт сакчы килеп басты. Сөембикәнең йөзендә бөркәвеч иде. Бикәне ташкирмәннән мәйданга алып чыгуга, халык арасында пышылдау башланды:

— Суембика! Царица басурманская!— дип телдән-телгә, колактан-колакка хәбәр китте.

Чит ил сәүдәгәрләре, илчеләр аягүрә басты. Аларга карап, тамашачылар да аякланды. Спасс манарасы янындагы күтәртмәгә урнашкан мотрибчылар Сөембикәгә чит-ят көй уйный. Шатлык көе. Сөембикә өчен бу кара кайгы көе иде.

Иван патша бөек җиңү бәйрәменә куанып килде, дип күп кеше бик каты ялгышты. Шатланмый патша, күптәнге хыялы — Казанны сытып, татарның тамырын корытып кайтса да, ул ни өчендер куанмады, хәтта елмаймады да. Ул үзенең уе белән мәшгуль. Татарның иң усал батырларының башын чабу да аңа кызык түгел. Кошчак батыр башы өчен ул ниләр генә вәгъдә итмәде. Әнә, Кошчак гарипнең башы хәзер чабылачак. Барыбер куаныч юк. Казанны алгач, ул канлы башчабышларны, адәм асуларны күп күрде. Татар ирләренең каны шулкадәр күп иде ки, оерга өлгермичә, татар каны Таҗик Ермагы буйлап Мунча урамына агып, Болакка, аннан Казан елгасына койды. Монда да нәкъ шул тамаша булачак. Хәзер татар каны Мәскәү елгасына агачак. Юк, ул түгел иде Иванның уе. Күпме әсир татар бүген чукынырга риза булыр? Чит ил сәүдәгәрләре, илчеләр алдында берсе дә чукынмаса, җир тишегенә кер дә кит! Бу эш башка илләрне дә аңа каршы котыртачак. Татар күпләп чукынса — менә шунда булыр бөек җиңү! Ике хан да үлемне сайлармы, әллә тәренеме? Кошчак углан мөселман килеш үлерме, әллә чукынырмы?

Бер баяр күтәртмәгә басып, куәтле аваз белән мәйданга кычкырды, мотрибчылар туктады.

— Бөек кенәз, бөтен Русиянең вә Казан-Болгарның олуг падишасы, татарларны җиңүче каһарман Иван Васильевич!

Мәйдан гөрләп ура кычкырды, озак кычкырдылар, һавага меңнәрчә бүрекләр очты.

Хәбәрче баяр дәвам итте:

— Мәскәүнең олы баярлары, Казан сугышы батырлары!

Мәйдан тагын алкыш кычкырды. Хәбәрче баяр, берәмләп, Казан сугышында аеруча батыр сугышкан воеводалар, баярлар, баскынчыларны санады. Спасс капкасыннан чыгып, исемнәре аталган батырлар патша каршысында йөри башлады. Иван алдан әзерләп куелган бүләкләрне һәр кешегә тапшыра, кочаклап өч тапкыр үбә, бүләкләр арасында Казаннан кайткан яхшы атлар, кыйммәтле кылычлар, хәнҗәрләр, алтын-көмеш балдаклар, туннар, матур итекләр — бар да бар иде. Бүләкләү тәмам булгач игълančы баяр тагын аваз салды:

— Өйләнмәгән баяр балалары, сугыш батырлары, воеводалар, мужиклар! Мәйдан буйлап сафка тезелегез! — диде.

Спасс капкасыннан чыгып, бихисап күп сугышчылар бүләкләнүчеләр белән бер сафка басты. Аларның саны сиксән мең чамасы булгандыр. Хәбәрче янә кычкырды:

— Казан бәкләренең, мирзаларның кызларын, хатыннарын чыгарыгыз!

Мәйданга әсир алынган бикәләр, тутайларны тезеп алып чыктылар.

— Бөек кенәз вә олуг патша Иван Васильевич һәр яшь баярга, һәр воеводага, һәр мужикка хатынлыкка татарның берәр затлы кызын бүләк итә! Алыгыз!

Мотрибчылар каты кычкыртып, дәртле көй уйный башлады. Яшь баярлар үзләренә тигән кызларны, яшь бикәчләрне мәйданнан алып чыгып китте. Сарай гүзәлләре тапшырылып беткәч, Арча, Кораеш бистәсе, Бишбалта, Әмәт бикәләрен, кызларын өләшү булды.

— Патшабыз Иван Васильевич әйтәдер: үрчегез! Татар хатыннарын чукындырып, өйләнегез. Һәр рус тамырында татар каны агарга тиеш. Ислам дөньясын татар канлы рус җиңәргә тиеш. Алла шулай куша!

Бу көнне, мәйданнан чыккач, әсир хатын-кызларны Мәскәү елгасына, бозлы суга куып керттеләр, бик күп кызлар кире чыкмады, батып үлде, чукындыра башлагач, бик күп кызлар акылдан язды.

Зыялы татар әсирләреннән, ике куллары артка каерып бәйләнгән сурәттә, җавап даулыйлар:

— Син үз теләгең белән чукынырга ризамы? — диләр. — Чукынасың икән — исән каласың, патшабыз сине азат итеп, баяр ясый, йорт бирә, хатын бирә. Чукынмасаң, башың чабыла!

Сөембикә куырылып килде. Сакчылар да сагайды. Иң беренче батыр күтәртмәгә калыкты, бу Барбулсын баһадир иде.

— Мин үз динемдә шәһит китәм!— диде гарип батыр.
Беренче баш җиргә тәгәрәде. Беренче кешенең каны шаулап ялгашка акты. Мәйдан тынып калды. Бу татарның батырлыгы, үз дененнән чыкмавына, үлемне сайлап алуына сокланамы халык? Әллә, шаулап аккан кан күргәч, мәйданның сулышы кысылдымы? Бик күп батыр үз дененнән язмаенча, саф мөселман килеш башын бүкәнгә салды. Сөембикә, төп-төз утырган килеш, һәр батырга карап, үзалдына кыска-кыска дога укый:
— Урының җәннәтә булсын, илаһым ярлыка тугры колларыңны! И тәңрем...
— Казанның соңгы ханы Ядигәр Мөхәммәт!— диде хәбәрче.
Мәйдан улап үкерде, сызгырды, ду купты.
— Әсир хан Ядигәр!— диде хәбәрче баяр.— Әйт соңгы сүзеңне. Чукынырга разый булсаң, бөек патшабыз Иван Васильевич сине исән калдырачак. Чукынганың соңында сиңа баяр дәрәҗәсе бирәчәк һәм сине Мәскәүнең иң атаклы кенәзенең иң чибәр кызы Мария Кутузовага өйләндерәчәк! Һәм үзеңә гаскәр вә бөтен керемнәре белән Серпухово каласын бүләк итәчәк! Чукынмасаң, чигәңне түмәргә сал!
Мәйдан тагын сулышсыз җавап көтә. Бөтен адәмнең күзе Ядигәр ханга төбәлгән. Ядигәр хан, патша ягына карап:
— Мин чукынам!— диде.
Һавага тагын бүрекләр очты. Мотрибчылар беренче булып чукынырга риза булган Ядигәр Мөхәммәт хан хөрмәтенә дәртле алкыш уйный башлады. Ядигәр хан Иван каршына килеп тезләнде. Иван аны үз янына утыртты.
Куй көтүе баш тәкәгә ияреп упкынга, ташкынга ташланып һәлак булганы кебек, Ядигәрдән соң берничә татар чукынырга ризалык әйтте.
— Баш тәкәнең мие әйләнчек булса, көтүнең эше харап!— дип уйлады Сөембикә.
Шуннан соң, яшәү бәрабәренә чукынырга ризалашучылар күбәя барып, чират Үтәмеш Гәрәй ханга җитте.
— Сафа Гәрәй хан углы Үтәмеш Гәрәй хан, соңгы сүзең!
Иван күз кырые белән генә Сөембикәгә бакты. Мәйдан сүз көтә. Сөембикә дә көтә. Үтәмеш Гәрәй хан тәгәрәгән башларга, башсыз гәүдәләргә карап дөньясын оныткан, әле яңа гына аның белән сөйләшеп торган батырларның башы кан эчендә ята, ярым ачык тонык күзләре куркыныч. Ике арбага, берсенә — башларны, икенчесенә гәүдәләрне төяп каядыр алып киттеләр. Арбага сыймаган ике мәет, өч баш аунап калды. Хәбәрче баяр Үтәмешкә җиңелчә генә, сак кына кагылып:
— Мәйдан көтә!— диде.
Үтәмеш Гәрәй хан чак ишетелерлек итеп:
— Мин риза!— диде.
— Мәйдан ишетмәде! Хан кычкырып әйтсен!— диде баяр.
— Мин чукынырга риза!— диде дә хан, кычкырып елый башлады.
Шулай елаган килеш, алкышлар тавышы астында Үтәмеш Гәрәй ханны алып килделәр дә Иван янына терәп үк утырттылар. Иван баланың аркасыннан сөйде. Мәйдан Кансыз, Рәхимсез, Дәһшәтле Иванның бу миһербанлыгын, бала җанлылыгын һаулап хуплады. Үтәмеш бичара, Сөембикәгә тартылып:
— Анакай!— дигән иде, Иван аның игътибарын алып, кесәсеннән сөяк саплы пәке чыгарып, сабыйга тоттырды.
Үтәмеш елаудан туктады, мышык-мышык сулкылдап, ят пәкене җентекләп карый башлады. Сөембикә селкенмәде дә, баласы тавышына да борылып карамады. Ул арада Калку урынга Алып гәүдәле бер батырны менгезделәр. Аның уң аягы йорми: ул, култык таякларына таянып, азапланып бүкән янына килде. Үтәмеш Гәрәй хан, пәкесеннән аерылып, түмәр ягына баккан иде, үзе дә сизмәстән кычкырды:
— Кошчак углан баты-ыр!— диде.
Хәбәрче баяр да бер очтан игълан итте:
— Сөембикә ханшаның җан сакчысы, гаскәр башлыгы баһадир Кошчак углан!— диде.

Кошчак углан артында үз чиратын көтеп торучы утызлап татар калган иде, ян-якларда ирекле әсирләр сыйфатында аларның хатыннары, балалары күренә. Сөембикә барысын да күрде, барысын да таныды. Үлем яки чукындыру көтеп торучы бу утыз тоткынның күбесе Кошчак углан егетләре иде. Ирекле әсирләр арасында аларның якыннары: хатыннары, балалары утыра. Алар бер-берсен күрми. Әсир, кутәртмәгә менгәч кенә, тамашачыга пәйда була. Сөембикә кебек, бу хатыннар да Кошчак белән киткән ирләрнең бөтенесе дә Алабуга кичүендә һәлак булган, дип уйлый иде. Өченче көнгә хәтле Сөембикә дә нәкъ шулай уйлады. Кичә зинданда утырганда, сакчылар йомыш белән чыккан арада тәрәзәдән ук очып кереп, имән ишеккә кадалды. Ук сабына юка кәгазь уралган иде. Ул кәгазьне тиз сүтеп, укны тәрәзә аша тышка ыргытты. Кәгазьдә Казанның харап булуы да, Кошчак угланның исән булуы да, берсекөнгә Мәркәзи мәйданда башы чабылачагы да, Үтәмешне шунда алып барачаклары да, Сөембикәнең энесе Әкрам Галинең үзен Казан ханы дип игълан кылып, тәхетне эстәп, яуга җыенганы да язылган иде. Язуы Нәргәтайныкы. Укны тәрәзәгә кем атканын Сөембикә белмәде. Бу хәбәрләрне Нәргәтай каян белгәндер? Ихтимал, Үтәмешнең көчеге Табылдык әле һаман чүрәкәй ташый торгандыр. Сөембикә, хатны чәйнәп, сагыз дәрәҗәсенә җиткезгәч, тәрәзә рәшәткәсе аша ыргытты. Хаттагы хәбәрләр аңа нык тәэсир итте. Ул, аптырап, сәкегә утырды, сакчылар кергәнне дә сизмәде. Кошчак угланның исән-сау булуы куаныч, Әкрам Галинең яу әзерләве олы юаныч, әмма Кошчакның исән булуыннан ни дә, Әкрам Галинең соңга калган явыннан ни? Кошчак белән Үтәмешнең җәза мәйданында чабылачаклары кара кайгы булып, аның йөрәгенә кереп утырды. Ул, ни кушсалар, шуны үтәргә әзер сыман, айнымаслык тирән кайгыда иде: бер өмет тә калмады. Мәйданга, тамаша карарга да аны шул килеш алып килделәр.

Сакчылар, як-яктагы ике хатын Сөембикәгә бакты. Иван дикъкатеннән Сөембикәнең утырышы читтә калмады. Сөембикә үзалдына сөйләнә иде:

— Мәһабәт батыр Кошчак углан Колынтай.

Хәбәрче баяр янә әйтте:

— Кошчак углан! Чукынсаң, Иван патша хатыныңны, балаларыңны үзеңә кайтара, алар Мәскәүдә!

Кошчак углан, хатыны, балалары Нугайга яки Кырымга качып өлгерә алмады микәнни?.. Түмәр куелган калкулык янына Кошчакның хатынын, берсеннән-берсе матур ике үсмер оланны китереп бастырдылар. Кошчак чак сизелерлек кенә хатыны ягына авышып куйды. Яшен мизгелендә Кошчак зиһенендә Кабан күлендәге бәке янында сыңар каз тотып басып торучы гүзәл кыз сурәте кабынды. Ул сурәт сүнде, алга — йончылган, ун елга картайган хатын басты:

— Атай! Атакай: син исәнме? — дип, ике олан таш диварга үрелде. — Атай, сине батып үлгән, диделәр.

— Атасы! Колынтай! — диде бикә.

— Анасы! Оланнарым! — диде Кошчак углан.

Ул, балаларын кочаргадыр, ахрысы, баскычка таба ыргылды, бер култык таягы төшеп китте, тыйтаклап килеп, ул кутәртмә кырына ябышкан дүрт кулны да учлары белән каплады. Аннан хатынына бакты. Бикәнең күз яшьләре ага иде.

— Син исәнсең икән, — диде хатын.

— Исән, — диде Кошчак углан. — Яңадан үләр өчен исән, бәгырьләрем.

— Атасы, — диде бикә. — Син исән калсаң да, калмасаң да — безне ирексезләп чукындырачаклар...

Кошчакның карашында усаллык балкыды, ул балаларына бакты; егет булып килүче оланнар да аңа ялварулы бага иде. Кошчак, кинәт кенә улларының кулларын этеп, таягын иелеп алды да, җәллад янына, түмәргә якын басты.

— Мин үз динемдә шәһит китәм! — диде.

Хәбәрче баяр җәлладка ишарә ясаган иде, бер мәлдә әллә ни булып алды, Кошчак углан әллә каян — җиңеннәнме, култык астыннанмы — сорнай

тартып чыгарды. Якын-тирәдәге мылтыкчылар, кылычлылар, балталылар — сорнайны табанча, хәнҗәр диптер — тиз генә коралларын тоткынга төбәде.

— Соңгы уйнавым! — диде Кошчак, сорнаен өскә күтәреп. Сакчылар ирексез кен сулап, үз хәлләренә кайтты. — Соңгы сүзем! Бөек кенәз Иванга минем сүзем юк! — дип башлады батыр. — Сезгә, чит ил сәүдәгәрләренә, илчеләргә ошбу лафым. Литуа, Төрек, Алмания вә башка Фрәнк мәмләкәтләренең мөхтәрәм вәкилләре! Ишетегез, хәтерегезгә салыгыз! Сез гөнаһсыз адәмнәрнең башын кисү тамашасын багып истирахәт кыласыз. Татарларның башы тәгәрәгәнгә куанып, үз башыгызны кашыйсыз. Инсан тарихында булмаган вәхшилек кылды Иван. Дәүләтле мәмләкәтне тамырыннан җимерде. Кол итәргә мөмкин, ясак салырга була, әмма телне, динне, дәүләтне корыту бер генә калыпка да сыймый. Килер заман, Мәскәү сезнең илләр белән дә шулай эш кылачак. Ул чагында, сезнең башлар очканда, минем рухым шаркылдап көләчәк. Кем бар арагызда, кемнәр исән кала, хәбәр бирегез илләргә, сөйләгез буыннан-буынга — татарлар арасында балта астында да денен сатмаганнар бар һәм булачак әле!

Шул мәлдә ул, озын тын алып, сорнаена өрде. «Янмас кыз» көе татар каны белән капланган мәйданга җәелде. Көйме әсәрләндерде мәйдан халкын? Әллә үлеме алдыннан бу татарга соңгы теләген үтәргә ирек куепмы, тамашачы сорнай тыңлый? Гаҗәеп имәнгеч тамаша иде бу. Матур, җылы киенеп, кызык карарга килгән христианнар да, үлем көтеп торучы әсирләр дә селкенми. Чиркәүләргә, каравыл манараларына, йортларга бәрелеп «Янмас кыз» үлем түмәреннән аска тәгәрәгән ачык күзле башларга, оеп өлгергән кан өстенә, Мәскәү елгасына таралды. Көй кинәт өзелде, сорнай каядыр тәгәрәде. Кошчак, бүкәнгә чабылган балтаны алып, баш җәлладның маңгаена орды, аннан җәллад ярдәмчеләренең берсен урталай өзде, ул арада әсирләр (кайчан богау-бауларын кисеп өлгергәннәр?!), сакчыларның хәнҗәр, кылыч, мылтыкларын тартып алып, хәтәр орыша башлады. Китте буталыш, китте акырыш, чыр-чу... Тамашачы берсен-берсе таптап кача. Хәбәрче баяр кемгәдер акырды, бик күп гаскәр өерелеш ягына таба йөгерде.

— Кошча-ак! — дип кычкырды Сөембикә.

Бераздан эш бетте. Кошчак углан да, соңгы батырлар да, бик күп җәрәхәт алып, ташка егылган иде.

Хәбәрче баяр канлы бәйрәмне тәмамлады. Халык таралып бетмәгән иде әле. Мәетләр өстендә козгыннар көтүе бөтерелә башлады. Сөембикә Спасс манарасы өстендәге хачка Каракош кунганын күрде.

Берничә атна узгач, колбикәне Балчык Бистәсендәге йортка китереп ташладылар. Бикә аңсыз иде. Аның кыяфәтенә карап, ахирәтләре калтыранып куйды. Бикәне танырлык түгел. Төзәлгән яралар янында чәйнәлепчиләнеп беткәннәре — теш эзләре. Тән җәрәхәтләренә ябышкан күлмәкне куптарып булмый, күгәрмәгән бер генә җире дә юк. Нәргәтәй бикәсен керфек төбеннән генә таныды, керфекләре генә исән иде. Кашларын ирексезләп йолыкканнармы, әллә пычак белән тунап алганнармы — каш урынында күнелҗем-коңгырт җәрәхәт кенә. Күкрәкләре чәйнәлгәнме, киселгәнме — аңлап булмый, бармак очлары яньчелгән иде...

Өч тәүлек буе Нәргәтәй җансыз гәүдәне су белән чылатып, әледән-әле юеш чүпрәкләрне алыштырып, бикәнең кутырлы коры иреннәренә су тигезә-тигезә саклады. Дүртенче тәүлектә Сөембикә ыңгырашты. Нәргәтәй сөт соратып, бикәнең һәр җәрәхәтенә сөт сөртә торды. Сөттә җебегән күлмәк кисәкләрен сак кына кубарды. Сөембикә күзен ачты. Үлем качты.

Нәргәтәй аңа барысын да сөйләде. Сөембикә белән Үтәмешне алып киткән көннән бирле, бу йорт ачык икән, сакчылар, беренче кичне үк, бөтен ахирәтләрне көчләп, ботарлап бетергән. Бу — Иванның кушуы булган икән.

Димәк, зинаханә икән бу. Сөембикә хәрам йортында ята икән.

Бераз аякланагач, ул Үтәмешкә хат язды. Ләкин хатны кире китерделәр, хат китергән йомышчы татар әйтте:

— Үтәмеш исемле кеше Кремльдә юк! Синең улың Александр атлы! Александр Савич!

Сөембикә ул исемне яза алмады. Хатны Нәргәтәй язды. Бер-ике атнадан соң, тантаналы бер вакыйга ясап, Балчык Бистәсенә атлы төркем килде. Төркем башында Үтәмеш Гәрәй иде. Үтәмешнең иптәшләре үзе кебек сигезтугыз яшьләрендәге баяр балалары иде.

Сөембикә углын танымады. Сабыйны алтын укалы киемгә төргәннәр, атынның дирбиясе дә патшаныкы кебек: Үтәмешнең сул янбашында — кыйммәтле кылыч, постау камәрендә — табанча. Бала да анасын танымады. Үтәмеш карашы белән эзләнә башлаган иде, Нәргәтәй әйтте:

— Анаң менә шул булыр, Үтәмеш!— диде.

— Улым, колыным!— диде бикә.

Үтәмеш аптырап торды, анасының тавышын, киемен таныдымы, әллә инде күз карашыннан төсмерләп, калтыравык тавыш илә әйтте:

— Анакай?— диде.

— Балакаем, колынкаем, Үтәмешем!— диде бикә, ул башта елмаерга теләде, иреннәре, битендәге җөйләре тартылып, елмаерга ирек бирмәде. Соңра бикәнең күңеле тулды, шул ук җөйләр, җәрәхәтләр еларга да ирек бирмәде; ул тавышы белән елый, йөзе белән елый алмый иде.

— Мин Үтәмеш түгел!— диде бәтчә.— Мин — Александр!

Үтәмеш муенындагы алтын тәрене анасына күрсәтте.

Сөембикә сабырлыгын җыйды, төз утырып калырга да көч тапты, хәтта каршысындагы кяфер малаена сөеп карарлык хәл алды.

— Минем өчен син — Үтәмеш!— диде.

— Синең янга кабат килмәм,— диде Александр.— Кенәз кушмый. Хәзер минем өч атам бар. Митрополит Макарий — чукындыручы атам. Ә болай атам — Савва Крутицкий — олы боярин. Бөек кенәз — минем өченче атам...

Сөембикә хәлсезлек сизде. Нәргәтәй аңа чәй бирде. Бераз тын алгач, ана тыныч-сабыр тавыш белән улына дәште:

— Синең атаң Сафа Гәрәй хан дөньяга мәшһүр баһадир иде... Аны синең бүгенге «атаң» Иван үтертте. Синең тәхетең — Аллаһ тәгалә кодрәте илә сиңа бирелгән Казан йорты! Иван аны харап кылды. Илең ирләрен ул суйды, балаларын көчләп чукындырды. Син — хан! Син үзең хаким кеше! Анакаеңны мәсхәрә кылган дәҗҗалнымы син үзеңә ата иттең? Кайт, балам, үз денеңә кайт! Юкса, син мәңге тәмугта яначаксың!

Сөембикә кыза барып сөйләде, аның сүзен куәтләп, Нәргәтәй да Сөембикәнең нинди җәза-золым күргәннәрен елый-елый тулгады.

— Юк исә,— диде Сөембикә.— Юк исә, мин сиңа ана түгел, син минем углым түгел. Мәрхүм Сафа Гәрәй ханның да, Сөембикә ханбикәнең дә Үтәмеш атлы углы юк! Син — кяфер, син — динеңнән язган мөртәт!

— Анам!— диде Үтәмеш, аның күзендә яшь күренде.— Анам! Ни кылаем хәзер. Мин бит инде — чукынмыш Александр!

Сөембикә пышылдауга күчте:

— Христианлыкны ташлап, янәдән мөселман булырга телисеңме, колыным?

— Мһм,— диде сабый.— Ә ничек?

— Юлы бар аның, колынчыгым. Хәнҗәрең белән кан тамырыңны ачып, кырык тамчы каныңны җиргә тамыз. Аннан соң, тамырыңны бәйләгәч йөз кабатла: әшһәду ән ля Иляһе илляллаһ вә әшһәду әннә Мөхәммәден абдуһү вә Рәсүлүһ, диген, соңра, Аллаһ тәгалә, мин сабый, өнсез баланны ярлыка, дип күп тапкыр кабатла. Көчләү, алдау аркасында гына мин денемнән яздым, ярлыка, Илаһем, дип ялын. Һичшиксез, хода сине ярлыкар, иншаллаһ!

Бакча түренә барып, баяр балалары күзеннән качып, шулай иттеләр, денгә кайтару йоласын майтардылар. Сөембикә белән Нәргәтәй, Үтәмешне кочаклап, елый-елый сөенделәр.

— Анакаем,— диде Үтәмеш.— Хәзер Иван мине үтерер бит.

— Син әйтмә! Белмәсләр. Аның алдында гына төртенгән бул. Озакламый сине дә, мине дә азат итәчәкләр. Бабаң Йосыф әмир, агаларың Юныс, Гали, Әкрам мирзалар безне күп мал биреп алыр, иншаллаһ...

Үтәмеш-Александр бакчадан бик боек чыкты, боек кына кайтты. Баяр балалары аны узышка чакырса да, табанчадан карачкыга атарга кызыктырса-

лар да, баш авырту сылтавы белән, йортына кайтып, чишенмичә генә ятагына сузынды.

Үтәмеш киткәч, Нәргәтай Сөембикә кулыннан нидер тартып алды. Бу — әкрен үтерә торган агу бөртеге иде.

— Бикәм! — диде Нәргәтай. — Бу ни кылмышың? Үзеңнеме харап итмәкче?

— Юк, — диде бикә. — Бу Үтәмешкә иде. Тәүбә кылмаса, чәенә сала идем.

— Сабыйның ни языгы? — диде ахирәт.

— Ул болай да үләчәк, тегеләй дә үләчәк... Тәүбә кылмаса, чәенә сала идем, ике-өч сәгатьтән вафат була иде...

Сөембикә бу сүзләрне бер ноктага карап, бер төрле тавыш белән серле итеп әйтте.

Сөембикәнең хәлләрен ишетеп, Иван патшага хатлар язып, Йосыф әмир кызын кайтаруны сорады. Ләкин Иван өчен хәзер Йосыф әмир дә, Әчтерхан да, хәтта Кырым да куркыныч түгел иде. Шуңа күрә, Йосыф әмирнең ялварулы хатлары да, янаулысы да җавапсыз калды. Җавап булганда — мыскыллы җавап, ялган-хәйлә җаваплары гына иде. Сөембикәнең хәле белән ныграк кызыксынучы илчеләргә Кансыз Иван:

— Сөембикә шөһрәттә, мәртәбәдә яши! Аны җәберлиләр, золымда тоталар дип сөйләүчеләр — дошман. Менә без ана бик яхшы кияү дә таптык. Сөембикәне Шаһ Гали ханга хатынлыкка бирәбез, — дип, юмалап, алдап җибәрә торган булып китте.

Тоткын ханбикәне Нугайга, атасы Йосыф әмир янына җибәрү Иван өчен артык борчулы мәшәкать булачак, аннан соң Сөембикәнең кыяфәтен читләргә күрсәтерлек түгел. Нугайга киткән очракта да, бикә анда тик ятмаячак, үч алу өчен бөтен мөселман илләрен Мәскәүгә каршы котыртачак; бәс, аны монда калдыру иң кулай эш, бикәне калдыру өчен хәйлә-сылтау кирәк, хәйләсе-сылтавы бер — тоткын бикәне Шаһ Галигә бирү. Сөембикәнең үзеннән сорап тормаенча гына, никах укыткан булып, аны Касыйм хан кирмәненә озаттылар: килгән-киткән күзеннән дә ераграк булыр...

Касыйм халкы мәшһүр Сөембикәне бик олылап каршы алды. Ләкин Сөембикәнең йөзен күрә-күрешкә үк йөзләр кара коелды, шатлык сүзләре тамактан чыкмас булды. Сөембикәнең гариплеге хакында бик күп имеш-мимешләр таралды. Мәскәүдән килгән баяр хатыннарының гайбәтен дә кушкач, Сөембикә белән күрешергә, котларга килүчеләр дә, мәҗлескә йөрергә теләүчеләр дә булмады...

Сөембикә, шулай итеп, өченче никахлы ирен каршылады. Каршылавы каршылау түгел иде. Ишек ачык. Бу йортка ул хуҗа — керсен, дигәндәй. Сөембикә кияү кертергә әзерләнмәде. Хәтта юл киемен дә алыштырмады. Шаһ Гали, тамак кыргалап, эчкәригә узды. Ул кергәч, Нәргәтай тавышсыз гына чыгып китте. Шаһ Гали бикәгә сәлам күндерде, ләкин җавап булмады. Сөембикә бу кешене беренче туенда беренче тапкыр күргәч тә зиһенендә беркетеп куйган иде: бу бәндәнең тәненә кулың тиеп китсә, исле сабын белән гомерең буе юсаң да, исе бетмәс. Бакага охшатты ул Шаһ Галине, ләүкә асты бакасына. Салкындыр, юешлер бу Шаһ Гали кайнаганың тәне... Ямьшәкайлар дигән, менә ул — Сөембикә — шул ләүкә астының гөберле бакасы Шаһ Гали никахында: бу никах шәргый шәрифчә булмады. Монда, Мәскәү җирендә шәригать кануннары да урыс итагатенә буйсына. Ни әйтсәң дә, ул инде — кандошманы, тәндошманы, җандошманы Шаһ Галинең хәләле.

Шаһ Гали Сөембикәнең җавапсыз утыруын ризасыз никах галәмәте дип фаразлады, әмма ул хаталана иде. Сөембикәгә хәзер ни булса да бер: Шаһ Гали хатынымы ул, Иван изәме аны, динсез, телсез аламан казаклар мәсхәрәгә саламы — барыбер. Сөембикә юк. Бу — Сөембикә түгел, бу — шәүлә. Касыйм кирмәненә китәр алдыннан аңа хәбәр китерделәр: энесе Әкрам Гали, урыс баскынчыларын Казан йортыннан куар өчен зур гаскәр туплап, Иделгә яу чапкан, яхшы җиңүләргә ирешкән: соңра, сатлыкҗаннар аркасында җиңелеп, үзе дә шул сугышта һәлак булган. Соңгы өмет кылы да

өзелде. Бөек кенәз Иванның дусты Исмәгыйль мирзаның, Сөембикәнең атасы Йосыф әмирне үтереп, бөтен нугайга иң олы түрә булганлыгын да белгәч, Сөембикә бөтенләй үлде. Аның үлемен рәсмиләштерергә генә кирәк иде. Көчләп христианлаштыру ташкынын Көнчыгышка, Шәрыкка җибәрми торучы төп субай баганасы — Казан ауды. Башка баганаларны бу ташкын сизмәячәк тә, сытып узачак.

— Бер кәлимәңне җәлләмә! — диде Шаһ Гали.

Сөембикә йөзен яшерми: ул хәзер бераүдән дә тарсынмый. Оятның качуымы бу, оятның бөтенләй бетүеме? Сөембикә Шаһ Галигә туры карады. Аның карашында җирәнү дә, нәфрәт тә юк иде. Казанны биргән, Үтәмеш Гәрәй ханны саткан, Сөембикәне шушы хәлгә төшергән кешеләрнең иң кабахәте: диндәшенә, телдәшенә дигән эштә — буынсыз-сыек бәдәнле бер бәндәчек. Мәскәүгә дигәндә — тиресеннән чыгардай булып эш йөртүче бу карахаингә ни әйтсен инде ул? Сөембикә үзе дә аптырады. Кая китте аның нәфрәте? Кая китте аның җирәнүе? Ул Шаһ Галине кызгана иде. Тугры эт кебек, ул Сөембикәгә карый, эчтән генә гафу сорый кебек. Сөембикә үз кәлимәсен әйтте:

— Чыңгыз токымыннан Шәех Әүлияр углы Шаһ Гали хан, син аклanma! — диде. — Син мәхлукка миннән ни кирәк? — Хуҗа дәшмәде. Ул мыскыллауларга күнеккән инде. — Ярый әле, Аллаһ тәгалә сине кысыр яраткан. Җир йөзендә синдәйләр үрчемәс, ичмасам. Синең балаларың булса да, алар гарип туар иде. Синең кебек үз халкын сатып, рәхәт яшәргә теләгән татар түрәләренең балалары гәүдәгә гарип туа, йә акылы зәгыйфь була. Куркактан куркак туа, нәҗестән нәҗес була!

Сөембикә туктады. Шаһ Гали башын иде. Аның сүзе дә, шөгыле дә юк иде, кулын кая куярга белмәгәч, тәсбих чыгарды — бармакларга эш табылды, әмма зиһенгә, телгә эш юк иде. Бәлки, аракы эчәргәдер? Аракыдан соң аның теле ачыла торган иде. Шаһ Гали сүзсез генә эчкәридән чыкты.

Бу йорт Шаһ Гали ханның хәләле Фатыйма солтанныкы булып, ул вафат иткәч, буш торган булса кирәк — почмакларда пәрәвезләр күренә. Сөйлиләр иде: имеш, Шаһ Гали хатыны Фатыйма йортына мәсҗедләре сыман манара кордырган икән. Дөресрәге, манараны Фатыйма солтан ясаттырган, дип сөйлиләр иде. Казаным белән Нугаем күренмәсме дип, Фатыйма солтан шул манарага көн дә таң алдыннан менә торган булган. Һәм шул манарага менеп үлгән дә. Сөембикә Фатыйма мәрхүмә көндәшеннән калган әйберләргә орынмады. Ул, тәһарәт алып, эчке киемнәрен алыштырды: урта ишекне ачты, урта ишекнең манарага ачылачагын ул чамалаган иде. Котыйчыгыннан нидер алып, авызына капты. Котыйчыкны сандык өстенә куйды да, тавыш чыгармаска тырышып, өскә менеп китте. Ачык калган ишектән җил бәрде: мөнбәр ишеге үзе ачылып китте. Үтәли җил Нәргәтәй йоклыйсы бүлмә ишеген дә ачты. Сизгер Нәргәтәй җәһәт кенә торды, ул Сөембикә бүлмәсенә узды, җил манара ишегеннән өрә иде. Нәргәтәй ишекне япты. Сөембикә йоклыйдыр, ахрысы дип, чаршау янына килде. Урынга кагылучы булмаган. Нәргәтәй эшне аңлады: ул җәһәт кенә манарага китә торган ишекне ачты, сандык өстендәге котыйчыкны күрде, котыйчыкта Үтәмеш чаена салынырга тиешле зәһәр борчагы юк иде. Нәргәтәй: «Бикә, бикәм, ахирәтем!» — дип эндәшә-эндәшә манарага менә башлады. Аның тавышына йорттагылар уянды.

— Кем йөри анда, манарада? — дигән тавыш ишетелде.

Нәргәтәй җавап бирмичә менде дә менде. Мөнбәр ишегеннән таң яктысы күренә. Сөембикә мөнбәрдә юк иде. Нәргәтәй аска бакты. Аста Сөембикә гәүдәсе ята иде.

— Сөембикә-әм! — дип җан әчесе белән кычкырды Нәргәтәй. — Ахирәте-ем!

Аның үзәк өзгеч тавышы Касыйм шәһәрен уятты.

Нәргәтәй, битен каплап, мөнбәр идәненә егылды:

— Саклый алмады-ым, саклый алмады-ым... Ханбикәчем, Сөембикә-әм, бәгырькәем, җаныкаем ла-а!..

Ул бәргәләнә-бәргәләнә елады да елады: кемнәрдер, манарага менеп, аны алып төште. Сөембикәнең җансыз гәүдәсен бүлмәгә алып кереп салганнар, күкрәгенә хәнҗәр куйганнар. Биканең-мәрхүмәнең мең яралы йөзе тыныч, әрнүле түгел; хәтәр рәнҗүдән — мәсхәрәдән котылганына сөенеп, рәхәт чигә иде сыман.

Шаһ Гали Сөембикәне җир куенына яхшылап тапшырырга кушты, ләкин үзе бу эшләргә катнашмады. Ханбикәнең өчесен, җидесен әйбәтләп уздырдылар. Кырыгына әзерләнгәндә Нәргәтай да җан бирде. Ул үзенең киселгән толымына асылынып үлгән иде. Ахирәтләрдән ул ялгызы гына иде. Кияүгә чыктылар, вафат булдылар, кимегәннән-кими бардылар; соңгыларын — чукындырып — баярларга өләштеләр, кайсылары Балчык Бистәсендәге яманатлы йортта торып калды. Бер Нәргәтай генә, Сөембикәгә ияреп, Касыйм каласына килде.

Нәргәтайның үлеменә Касыйм халкы аптырады. Чибәр, сәламәт хатынның кинәт үз-үзен үтерүен иң олы кайгы белән генә аңлатып була иде. Димәк, Сөембикә белән Нәргәтай гомергә бер җан булып яшәгән. Яртысы гарешкә очкач, яртысы монда, фани дөньяда кала алмаган. Урыннары җәннәттә булсын! Амин!

Сөембикә белән Нәргәтайны җирләгәннән соң күп тә узмады, Шаһ Гали ханга хасталык иңде. Күзгә күренеп, кычкырып торган чире дә юк, диде табиплар. Мәскәүгә чакыргаласалар да, йөрмәс булды. Башта ул Иванга: «Сырхаулыйм»,— дип хәйлә хатлары язды, тора-бара чынлап чирли башлады, тамактан калды, сөйләшмәс булды. Йомыш белән килгәннәргә җавап бирмәде, ул ятакта иде. Шул ястыгы өстендә ул үлеп тә китте.

Сөембикә дигән асыл затны татар халкы гомеренең бакыена да онытмас.

Шаһ Гали хан диндәшләре, телдәшләре тарафыннан һәрвакыт каргалыр, җаны зобанилар кисәве астыннан чыкмаса иде, диярләр.

Сөембикә җырларга, риваятьләргә, дастаннарга керер. Авыр туфрагы җиңел булсын! Урыны җәннәттә булсын, диярләр. Бирсен Ходай! Амин!

*1990*

# Фәрит Гыйльми

# ЗӘЙТҮНӘКӘЙ, АКЧАРЛАГЫМ

ХИКӘЯ

## 1



Беренче булып аны көтүче Гайни күрде.

Колхозның савым сыерларын люцерна басуына куу өчен олы юлны аркылы үтәргә кирәк. Иярenә кинодагы Чапайча төз, ипле утырган Гайни, һай-һайлап, тырыша-кабалана, сигездән үрелгән озын чыбыркысын һавада уйнатып, үшән малкайларны ашыктыра иде. Шул чакта, сызгыртып, кара «Волга» килеп туктады. Берничә мәртәбә сузып-сузып кычкыртып карады машина. Юл буенча сибелгән эре сөякле, зур имчәкле, бурадай ишелеп чыккан зур корсаклы колхоз сыерлары кояшта ялык-йолык килеп торган зиннәтле машинаны бар дип тә белмәделәр. Алай гына да түгел, машинага якынраклары, олы, дымлы күзләрен шардай түгәрәкләндереп, борын тишекләрен алагаем киереп, юлчыларга якынлашты. Силос, печән төягән йөк машиналарына, «Беларусь» тракторларына ияләнгән сыерларның мондый әкәмәт нәмәрсәне бөтенләй күргәннәре юк иде, шуңа күрә аны тансык иттеләр, иснәп, ялап карарга ымсындылар. Машина егерме, утыз метрлап артка чикте дә туктап калды. Ишектән ак күлмәгенең изүләрен ачып җибәргән, җиңнәрен сызганган озын буйлы, киң җилкәле, нык бәдәнле ир-ат чыкты. Аякларын киереп баскан, бөерләренә таянган, кып-кызыл булып кояшта балкып торучы симез битле мәһабәт ирне күргәч, Гайнине ток тоткандай булды. Тәне буенча, авырттырып, чәнчеп, сәер дулкыннар йөгерде, бер мәл башы миңгерәп торды. Аның каршында, һичшиксез, илнең дәрәҗәле кешесе — Хуҗа үзе басып тора иде!

Югалып калу, каушау гамәле Гайнидән атка да күчте, ахры. Менә әкәмәт, хайван һәйкәл-ат кебек каткан да калган! Хуҗа кул аркасы белән әллә күперәп торган чәчләрен сыпырып алды, әллә Гайнигә кул изәде. Хуҗа кеше тәккә генә маңгай сыпырмас. Юк, ул Гайнигә кул изәде: «Ни хәлләр, иптәш көтүче?!» Дулкынланудан Гайнинең йөрәге, күкрәк читлегенә сыеша алмас булып, шашына-шашына тибәргә тотынды. Башына, рәхәт биреп, кайнар кан йөгерде. «Хәлләр әйбәт, иптәш Баш Хуҗа! Һайт-һайт!»

Гайни, чыбыркысын гайрәт белән уйнатып, өч-дүрт сыерга бер кизәнүдә «тамызып» өлгерде. Иясенең холык-фигыленә тәмам күнегеп, өйрәнеп беткән ат та ук булып алга атылды, көтүнең икенче башына очты —һайт-һайт!! Гайни, давыл хәбәрчеседәй, бер очтан икенчесенә оча: һайт-һайт! Кушаяклап чапкан сыерларның тояк тавышыннан таш, ком түшәлгән олы юл дөбердәп тора.

Берничә минуттан юл бушап, ачылып калды. Хуҗа тагын бер кат кул аркасы белән әллә чәчен сыпырды, әллә Гайнигә кул изәде дә машинасына утырды. Әмма дулкынлануның иң югары ноктасына җиткән Гайни моны күрмәде. Кара «Волга»ны кыеклап узып, туры юлдан авылга томырылды.

Бәхете бар икән Гайнинең. Бригадир Сәлахның тарантасы ишек алдында иде. Димәк, Сәлах өйдә! Гайни, йөгәннең тезгенен тиз генә койма баганасына элде дә,

---

Фәрит ГЫЙЛЬМИ (1947) — *прозаик. «Урсай тау итәгендә», «Елганың борылган төшендә» кебек повестьлар һәм күп санлы хикәяләр авторы. Әлмәттә яши.*

өй эченә йөгерде. Тыны-көне беткән Гайнинең исе китте: өйдә берәү дә юк! Юк, бар икән. Бригадирның кече кызы мич каршында бәрәңге әрчеп утыра.

— Әтиең кая, үскәнем?

— Мунчада. Исәнмесез, абый!

— Нәрсә?

— Әти мунча керә. Әни дә...

Гайни гаҗәпләнүдән өнсез-телсез калды. Шушындый мөһим вакытта — колхоз җирендә Хуҗа басып торганда ничек итеп, ни җаның белән көпә-көндез хатының белән мунча кереп ятарга мөмкин?!

Гайни мунчага чапты. Ишек эчтән келәгә эленгән. Дөбердәтә башлады. Ниһаять, ачтылар. Бил тирәсен сөлге белән ураган Сәлах ачулы иде.

— Ни бар?

— Сәлах дим, ничек йөрәгең җитә? Ул басып торды... Безнең сыерларга карап... Хуҗа!

— Ни бар, минәйтәм!

— Иң олы министр иптәш Фарукшин олы юл белән безнең авыл эченә кереп китте. Миңа: «Ни хәлләр, иптәш Гайни!», — дип кул болгады!

— Фарукшин?! Бутамыйсыңмы?

— Эпекәем! Үзе иде! Кара «Волга». Ак күлмәктән. Кызыл йөз!

— Ахмак! Башта ук шулай диләр аны! Бар, көтүеңне кара.

Сәлах, сөлгесен чишеп, сөртенгәндәй итте дә, әһ дигәнче, киенеп тә куйды; хатынын гаҗәпләндереп, секунд эчендә атын җикте; кабаланудан, тарантас күчәрләрен капка баганасына ордыра-ордыра, урамга чапты.

Сәлахның да бәхете җиңде. Колхоз рәисе Хуҗа килүе хакында ишетмәгән икән. Бу хәбәрне аңа Сәлах ирештерде! Бригадир авылның баш мие генә түгел: ә күзе, колагы да булырга тиеш. Һәм шулай булып чыкты да! Сәлахның шатлыгы тулып түгелергә торса, Кушаев тирән хафага төште. Аны берсеннән-берсе авыр, шикле уйлар басып китте. Фарукшин ни өчен идарәгә кермәгән? Өлкә, район комитетлары ни өчен берни дә белгертмәделәр? Хуҗа булып Хуҗа үзе районга, колхозга килсен әле?! Уен эш түгел бу! Әлегрәк, ул район үзәгенә генә киләсе булса да, бөтен авыллар берәр атна алдан кисәтелә, җыештырыла, юллар, урамнар, ферма тирәләре рәткә кертелә, халыкка нәрсә сөйләргә кирәклеге өйрәтелә башлый иде. Ник Хуҗа идарәгә сугылмыйча китте? Ул кайдан килә, кая бара? Юк, чынлап, тирә-юньдәге иң хәлле колхоз «Уңыш»ка да тукталмагач, ул кая бара? Озатусызнисез. Бер үзе! Башка сыймый! Шунда авылның баш мие, күзе, колагы Сәлах (ул моның шулай икәненә хәзер ихлас күңелдән ышана, шуны эш белән раслады!) ничектер әйтеп куйды: «Ислам Гайнанович, теге өйгә китмәде микән ул, ә!» — диде. Киеренке уй, шик-шөбһәдән тирләп чыккан рәис шалт итеп өстәлгә сукты. Нәкъ үзе! Лач итеп өстенә басты Сәлах! «Ни баш минем, — дип уйлады рәис, — шуны да аңларлык булмагач, күтәреп йөрүе хәрәм!»

— Сәлах, партком секретаре белән икәүләп, белгечләрне, идарә членнарын җыя торыгыз. Мин теге йорт тирәсеннән әйләнәм, туктаганмы, конкрет белергә кирәк. Карагыз аны, миннән узып, райкомга чыгасы булмагыз!

Дөресен әйткәндә, рәис башта, разведка ясау өчен, машинасына утыртып Сәлахны гына җибәрмәкче булган иде. Шундук уеннан кире кайтты. Көтелмәгән хәл килеп чыкса? Хуҗа үзе очраса? Икеле-микелегә, очраклылыкка юл куймаска! Үзе бара! Моңа гына ушы җитә аның! Хуҗа районга гел килеп тормый. Елга — бер, күп булса — ике.

«Теге йорт» үзәк авылдан бер биш чакрым чамасы җирдә, төбәкнең иң матур, җәннәт урынына салынган иде. Ике яктан кырт почмак ясап килгән каен урманы, аннан соң — шомырт, миләш, кыргый алмагачлар китә. Уртада — чиллә уртасында да җылынмый торган, салкын, күз яшедәй чиста сулы, үтә күренмәле түгәрәк күл. Авыл ягына караган өлеше — ясалма болынлык. Егерме гектар чамасы җирне аерып, киртәләр белән бүлеп куйдылар. Затлы үлән орлыкларын да кулдан сиптеләр. Иген чәчәргә райком рөхсәт бирми. Чөнки Хуҗа анда ауга чыгарга ярата. Иртән, таң белән торып, бер-ике сәгать йөреп, җилләнеп кайта. Йортны да моннан оч ел элек, беренче кушуы буенча, Чаллыдагы Кызыл Ярдан кайтарылган, шомдәй топ-төз нараттан өйдерде ул. Беренче, көн дә килеп, тикшереп торды. Йорт Минзәләләрнекеннән әйбәтрәк булырга тиеш! Шулай булып чыкты да. Хәтта мунчага илтә торган сукмакны да ак кирпечтән тездерәр.

Рәис шоферының иңсәсенә кагылды. Тегесе, аны сүзсез аңлап, тормозга басты. Йортның тимер капкасы төбендә, кояшта җем-җем килеп, кара «Волга» тора иде. Яңа гына туктаганнар. Әле машинаны ихата эченә кертергә дә өлгермәгәннәр. Кирегә борылып маташканда, күктән иңдемени, урман авызында тагын бер «Волга» күренде. Беренче! Юл уртасына чыгып баскан рәискә терәлеп диярлек туктады.

— Тәртипме?

— Рәмил Габделхакович, сездән узып, сезнең рөхсәттән башка, йорт янына барырга җөрьәт итмәдем. Сезгә шалтыратканчы, шәхсән үзем тикшерим, дигән идем. Чынлап, Хуҗа үземе? Ә болай йорт эчендә полный тәртип. Сез кушканча.

— Ансы әйбәт. Дөрес эшлисең. Өченче белән элемтәдә тор. Культура бүлеге мөдирен җәһәннәм астыннан булса да тапсын. Кисәт, самодеятельность кызлары әзер торсыннар.

Беренче дөрес уйлый: Хуҗа, татарчаны ипи-тозлык кына белсә дә, борынгы көйләрне үлеп ярата. Болай булгач, аңлашыла: Хуҗа туп-туры монда килгән; берәүне дә кисәтмәгән икән, димәк, ул ял итәргә, бушанырга уйлаган. Анда хәзер эш кайгысы түгел.

— Алай-болай Хуҗаны эзләп шалтыратсалар, сорасалар?

— Белмәдең, күрмәдең. Урыныңда бул!

Колхозның активы җыелып өлгергән, чиксез кызыксыну, мөһим эшкә катнашу бәхете чыгу мөмкинлегеннән тәмам исергән, тәэсирләнгән авыл коммунистлары рәисне түземсезлек белән көтәләр иде. Аларны күргәч, рәис курка калды. Артык тырышып ташламадымы ул бу кадәр халыкны җыярга. Хуҗаның «теге йорт»ка килүен әйтергә кирәк идеме икән? Алай дисәң, авыл җирендә кеше түгел, җепсез энәне дә яшереп булмый. Әмма, әмма... Сәламәт булмаган сүзләр чыкмасмы халык арасында? Тфү, тфү, адашып, йорт, күл тирәсенә килеп чыгучылар табылмасын!

Үзеннән әмер сорап тилмерүче, газапланучы, бирелгән, күндәм берничә дистә күз карашы озатуында үзенең өстәл артына гына утырган иде, телефон шалтырады. Милиция начальнигы. Менә кайда ул телепатия! Әйтерсең, милиция начальнигы аның уйларын махсус укыган!

— Анда безнең егетләр куна китте. Тамак ягын кайгырт инде.

— Эшләрбез, иптәш майор, борчылма. Культура бүлеге мөдире югалган. Тапсаң, әйт әле, миңа шалтыратсын.

Трубканы куйганда, рәис күз очы белән генә эләктереп алды: мәктәп директоры, әле яшь егет, ничектер табигый булмаганча, урынында сикереп куйды. Әллә ул да аның уен укыймы?

Менә проблема. Активка нәрсә әйтергә?

— Иптәшләр, кыскача белдерү ясыйм. Иптәш Тимершин безнең районда Хуҗалыклар белән таныша. Кичкә, мөгаен, безгә килеп чыгар. Шуның өчен һәркем үз тармагында идеаль тәртип урнаштырсын. Тегенди-мондый түгел, ә идеаль тәртип! Сораулар бармы? Йомыш чыкса — телефоннан. Үземдә булам. Эшкә керештек!

Барсы да таралышты. Ә мәктәп директоры, ишек катына баскан да, бер урында таптана.

— Әйт, әйт, түбә калае җитмәдеме? Беләм. Хуҗа киткәч карарбыз.

— Ислам Гайнанович, Хуҗаны күргәч, безгә интернат бинасы кирәклеген дә әйтегезче, зинһар.

— Җитте! Ат абзары да кирәкмиме? Аның уенда синең мәктәбең генә иде! Менә монда башлар Себер китәрлек мәсьәлә чыкты, ә анда интернат кайгысы! — Кинәт ул, кыйммәтле ачыш ясагандай, яктырып китте, уң кулы белән өстәлгә сугып алды. — Бәлки, син ярдәм итәрсең?

— Боерыгыз гына, Ислам Гайнанович, хәзер эшлибез!

— Районның җырчы кызларын җыя алмыйбыз. Тимершинга кичке чәй тәкъдим итәргә кызлар кулы кирәк бит инде, ә?! Үзебезнең мәктәптә дә кешегә күрсәтерлек укытучы кызлар бар ич. Үзебезнең милли кадрлар, ә?! Шулардан иң мәслихәте, минемчә, Зәйтүнә булыр. Борынгы көйләрне дә шәп җырлый. Өздерә! Дөрес бит?

Яшь директор эсселе-суыклы булып китте. Каушавыннан җавап таба алмый интекте.

— Ислам Гайнанович, бу мөмкин түгел, мин рөхсәт итә алмыйм... Ул авырып тора...

— Терелт! Ничек рөхсәт итә алмыйсың? Ул синең хатыныңмы әллә? Түгел! Ул — авылныкы! Ә авыл — колхозныкы!

— Ислам Гайнанович, зинһар!..— егет тирләп чыккан иде, костюм җиңе белән маңгаен сыпырып алды.

— Мин үз гомеремдә бер генә сорыйм! Уйла! Син ахмак малай түгел!

## 2

Авылда хәбәр җил тизлеге белән йөри. Фарукшин «Уңыш» колхозында диген давыл-сүз, укытучылар белән бергә, Зәйтүнәгә дә санаулы минутлар эчендә иреште. Унынчыларның чыгарылыш кичәсенә дип, пионерлар белән, яңа җыр өйрәнәләр иде. Вакытны тиз тотты. Балаларны өйләренә озатып, канцеляриягә керсә, берәү дә юк. Укытучыларның һәркайсы агитатор, пропагандист санала. Мөгаен, бригада, терлекче, механизатор йортларына таралганнардыр, шушындый мөһим, әһәмиятле вакытта монда ятмаслар, дип уйлады кыз. Менә ул үзе соңга калмады микән? Партоешма, колхоз идарәсе йөзен дәрәҗәле кунак алдында кызартмасмы?

Әле яшь, шушы туган мәктәбен бетереп, икенче елын гына эшләве булса да, башлы бала бу дип, партком секретаре аны колхозның «Якты киләчәккә» диген

стена газетасына редактор итеп билгеләгән иде. Зәйтүнә сызым кәгазе, каләм, буяуларын өстәлгә таратып ташлады да, идарәгә социалистик ярышның күрсәткеч саннары артыннан йөгерде. Хисапчылар ишегә йозакта иде, кыз әрле-бирле сугылды, бәрәү дә аңа күтәрелеп карамады, һәркемнең үз кайгысы, мәшәкате баштан ашкан. Аптырап, ишек алдына чыкса, хәйран калды. Бәйрәмчә киенгән, ак эшләпәле ветераннар каралты-кура тирәсендәге әрем, кычытканны чаба, бер төркем халык сукмак-юлларга, пар казанына дип Чаллыдан махсус ташылган ак комны сибә, ә хисапчы апалар ялгыз гына моңаеп утыручы карт каенны ак буяуга буяп маташалар иде.

Баш хисапчы Зәйтүнәне күз чалымына да элмәде.

— Үскәнем, чәчемне агартма! Ә-ә, туктале, комсомол секретаре урам тактасына язып йөри ярыш нәтиҗәләрен, шуннан күчер — диде. Аннары ул кызны кызганды. Ул да уртак эш, күргәзмә агитация өчен янып йөри бит, комсомолга биргән киңәшен кабатлады: — Язгы чәчү әйбәт, былтырдан өч көнгә иртәрәк бетте, диген. Ит, сөт буенча саннарны да йөз дә биштән киметмә, йөз дә уннан арттырма — чат дөресе чыгар!

Төпченеп торырга вакыт гел беткән, Зәйтүнә идарәдән егерме адым да китәргә өлгермәде, аны таныш тавыш туктатты. Равил! Дулкынланудан кызның йөрәге, очып китәргә теләгәндәй, дөп-дөп типте, болай да алсу бит очлары кояштай яна башлады. Равил абыйсы!

— Зәйтүнә, акчарлагым, әле кая болай? — диде мәктәп директоры икеләнүен, кыюсызлыгын яшерергә тырышып.

— Стена газетасы чыгарам, Равил абый. Кичкә кадәр мәктәптә булам. Равил абый, ашыгам...

— Сүз бар иде, Зәйтүнә.

— Зинһар, хәзер түгел, Равил абый. Газетам яна! — диде кыз. Үзенең дә битләре яна иде. — Аннан соң Тимершин әйтер, газетагыз да юк, нинди политик томаналар сез, дияр.

— Ярар инде... Тик, зинһар, мин яки Ислам Гайнанович үзе дәшмичә, китми тор инде мәктәптән.

— Ә Ислам ага нигә? Аңламыйм, Равил абый?

— Мөһим эш бар. Зинһар, дим. Сөйләштек, Зәйтүнә, мине телефоннан райком көтә. Беренче үзе!

Кызга әллә ничек булып китте. Равил абыйсы бик борчылган, талчыккан кыяфәттә иде. Аның аяк атлауларына кадәр сәер, салынкы тоелды. Ходаем, авырып кына китмәсен тагы, дип кабатлады ул күңеленнән өзгәләнеп.

Зәйтүнә газета чыгарганда бөтенесен үзе эшли. Мәзәкләр уйлап таба, кайбер мәкаләләрне (бигрәк тә, унынчыны бетергәч, туган колхозында савымчы булып эшкә калган кызлар турында булса) шигырь белән генә яза. Әмма менә рәсемнәрен ясау... Булмый! Шул тота кулны! Гомер булмаганча, ялына-ялвара унынчы класс егетләрен күндерде. Тегеләр бизи, Зәйтүнә сүзләрне, караламага да язып тормыйча, турыдан-туры кәгазьгә төшерә. Дөресен әйткәндә, моның ул хәтле кыенлыгы да юк.

Унсигез яшьлек кыз күңеле — зәңгәр күл өстендә тибрәлгән йөгерек дулкын — бер урында гына, чуарланып беткән сызым кәгазенә генә ябышып торамы соң?! «Зәйтүнәкәй, акчарлагым!..» Аның бит очлары тагын кызыша башлады. «Акчарлагым...» Бер әр мөһим әйбер турында сөйли башласа, Равил абыйсы гел шушы сүзне кабатлый. Равил абый. Кызык, моңарчы бөтенләй уйлаганы булмады, нинә яшь аларның аралары? Мәктәпне бетерә — унҗиде, институт — биш, монда икенче ел. Димәк, аңа — егерме дүрт. Менә сиңа абый!

Зәйтүнә, мәктәпнең йөзек кашы, горурлыгы, уңны бетерүчеләр арасында бер үзе медальгә лаек булды. Химия олимпиадасында җиңүче, ә керү имтиханнарында дүрт фәннән унсигез бал җыя торып, Казан медицина институтының дәвалау факультетына конкурстан үтмәде.

Документларын алырга дип кабул итү комиссиясенә барса, әкәмәт хәл килеп чыкты. Ул кабул ителгәннәр арасында да, төшеп калганнар исемлегендә дә юк икән. Төне буе елап чыгып, шешенеп беткән, күз төпләренә кара сызыклар кунган иде, күтәрелеп карарга да оялып, башын аска игән хәлдә торды да торды. Өстәл артындагы бизәнгән, ясанган ханымнарның берсе түзмәде, каядыр чыгып китте.

— Шәмсетдиновамы? — диде ул әйләнеп кергәч.

— Әйе, апа.

— Безнең институтта укыйсың киләме?

— Килә-әә.

— Кайсы факультетка, сайла!

Зәйтүнә алдында күк капусы ачылдымыни! Ясанганга гына түгел, болай да бик матур икән ич бу апа. Бар ул гаделлек дөньяда! Бар! Әнә бу апа белгән: ике «дүртле»не, химия белән биологиядән юри киметеп куйдылар ич аңа. Ул «бишле»лек җавап биргән иде! Бу апа шуны сизгән!

— Дәвалау факультетына, апа.

— Шәмсетдинова, сез нәрсә?! Бу мөмкин түгел.— Ул бераз йомшара төште.— Сеңлем, ахмак булмагыз, тизрәк сайлагыз, ә дәвалау факультетын онытыгыз, аның группалары әллә кайчан расланган инде.

— Дәвалау факультетына...

— Юк дидем!!

— Алайса, киләсе елга килермен...

— Ихтыярыгыз. Киләсе елга да шушы булачак!

Зәйтүнә ишеккә таба иңге-миңге атлаганда, мәгънәләрен аңларлык хәлдә булмаса да, теге чибәр апаның сүзләрен ишетеп калды: «Шулкадәр чибәр кыз, һәм шулкадәр тискәрелек! Башка сыймый! Боже!»

Җуелмас кара мөһер кебек сугылган «чибәр» сүзен кыз үзен-үзе белә, таный алырлык яшькә җиткәннән бирле ишетеп үсте. Аның хәсрәтен, ачы күз яшен күп йотты. Бер үзе генә калган мизгелләрдә, шушы чибәрлегеннән кимсенеп, башын өстәл тактасына бәрердәй булып, үкси-үкси елады. Әле дә исендә, бик-бик бәләкәй вакытта, ерак әбисе белән мунчада юынганда, аны кочаклап, беренче булып шул әбисе елаган иде.

— Сөбханалла, бәбкәм, сөт тән икәнсең бит! Башкайларың бәхетсез булыр инде, күз нурым! Элгәрерәк заманда, безнең нәселдә булган шундый бер кыз, олылар сөйли иде, бала көенчә үк зобаныйлар калага апкиткән шул бәхетсезне. И бәбкәм, бәбкәм!..

Зәйтүнә, үсә төшкәч, авыл бала-чагасы белән ныклап аралаша башлагач кына, ачы хакыйкатьне аңлады. Бөтен авыл — баласы, малае, кызы булсын — төскә, кыяфәткә коңгырт яки кара иделәр. Әле мунча ташыдай чутыр каралары да очрый иде. Ә ул — ап-ак. Куллары, аяклары, бите — барсы да ап-ак. Һәм иң гаҗәбе, бөтен җәй буена аларга кояш нуры да кунмый иде. Әз генә алсуланса алсулана, әмма каралмый. Яз ничек булса, җәй азагына да шул төстә. Дөрес, яшьтәш кызларыныкыннан күпкә калын, мул чәчләре генә бераз сарырак, әмма алар да чын сары түгел, ә аксыл сары иделәр. Бераз соңрак, Зәйтүнә су коенудан да бизде. Барсы да чишенеп ташлый. Зәйтүнә дә. Шуннан соң, суга чумасы урынга, малае-кызы Зәйтүнәгә чекерәя.

Ак тәне өчен — иң аянычы, иң авыры, иң гарьлеге, иң хаксызы — аны әтисе гомере буена үги итте, җае чыккан саен гел кагып килде. Ул эчеп кайткан көннәрдә күп вакыт җил-давыл, җәһәннәм купты. Чем кара әнисе — юантыграк, әмма буынлы-буынлы, авылның чибәр хатыннарыннан саналган Маһибәдәр — бәхетсез кызын житәкләр иде дә, күршеләр канаты астына йөгерер иде.

Яшь укытучы, тарихчы Равил абыйсы белән алар бер елны эшли башладылар. Сентябрь, октябрьдә, гадәттәгечә, укучылар белән бәрәңге, чөгендер җыйдылар. Зәйтүнә аңлашылмас эчке тойгы белән сиземли иде: Равил абыйсы аны күзәтә, сыный сыман.Ара-тирә үтеп киткәндә шаян сүзләр дә әйткәли. Әмма, юк инде, кыз чатнатып җавап кайтара алмый. Югала да кала. Равил абыйсы хәтта аңа чөгендер басуыннан бергәләп җәяү генә кайтырга да тәкъдим ясады. Зәйтүнә, җир ярылса, оялуыннан җир тишегенә кереп китәр иде, кып-кызыл булды. Әмма шуны аңламады: бу минутларда ул үзе икенче кояшка — яз кояшына әверелгән иде, чөгендер басуы уртасында илаһи нур сибеп, күпләрнең күңелен яктыртып, балкытып тора иде. Оялчанлык соң ноктасына җитте: «Юк-юк, Равил абый, мин кызлардан аерылмыйм инде!..» — диде.

Кыр кәҗәсенекедәй сыгылмалы гәүдә йөк машинасына таба йөгерде.

Яңа ел кичәсе алдыннан Равил абыйсының тагын бер һөнәре «фаш булды». Ул ярыйсы гына баянчы да икән ич! Укытучыларга авыл яшьләре дә кушылгач, матур гына ансамбль барлыкка килде. Ә бер кичне, репетицияләр башланыр алдыннан, Равил абыйсы, тиктән генә, кызга бәйләнде дә куйды:

— Карале, акчарлагым, син ник үз җырыңны җырламыйсың?

— Нинди?

Билгеле инде, кыз шундук төшенде: «Акчарлагым» булгач, сүз — «Зәйтүнәкәй, акчарлагым...» җыры хакында.— Билләһи, дип сорыйм, әллә үз җырыңны белмисеңме? Нәкъ синең өчен дип, халык махсус чыгарган.

— Белмим, Равил абый.

— Әйтәм, көннәр һаман җылытмый, ходай тәгалә шушының өчен сиңа ачуланган икән. Тыңла, өйрәнәбез!

Тагын бер вакыйга кызның күңеленнән чыкмый йөдәтә. Вакыйга дип, вакыйга да түгел инде ул...

Күрше авылдан концерт куеп кайталар иде. Җәяүле буран уйный, әче җил теңкәгә тия. Түп-түгәрәк, тулган ай, күңелне шомландырып, әле болытлар арасына кереп, әле калка. Атлар да атлап кына кайталар, әледән-әле пошкыралар. Мондый вакытларда шаярышып, шау-гөр килеп, җырлашып кайта торган егетләр, кызлар да «сүнгән». Зәйтүнәгә урын читтән, чана урәчәсеннән калган булып чыкты. Язга таба барабыз дип, кыз җиңелчә киенгән иде. Туңды. Алсу иреннәре күгәреп чыкты, дердер килә башлады. Шунда Зәйтүнәне кемдер кешеләр өеменең үзәгенә табарак тартты. Кызның күшеккән иреннәре карышып бер генә сүз дә әйтерлек хәлдә түгел иде.

Ул чамалады. Равил абыйсының куллары! Аннары шул ук куллар аның муенына битенә йомшак шарф урады. Кеше арасында ышык иде, ә шарф шулкадәр жылы, кайнар иде, бу кѳтелмәгән үзгәрештән хәтта аның башы әйләнеп китте. Равил абыйсының тән жылысы аңа күчте! Үзе дә аңлата алмый, нәрсәдән, тулып ашкан бәхетеннәнме, әллә оятыннанмы, аның әкрен генә, беркемгә дә сиздермичә генә елыйсы килде. Куллар аны кочып алды. Ул карышмады. «Ходаем, ай гына, зинһар, болытлар арасына кереп китсен иде!» Күпмедер ара жир үткәч, кыз шушы халәтенә тәмам күнекте. Жылыдан тәне изрәгән, шарф эссесе күңелен кытыклый иде. «Эх, кайтасы иде шушы ике авыл арасын иртәнгә кадәр, юк, язга, жәйгә кадәр! Ай гына болытлар арасына керсен!..»

Шул айлы-болытлы, күпереп торган көпшәк кар көртләре белән авылны күмеп киткән жылы март кичләре кызның аңын томалады, ниндидер сәер көч йөрәген телгәләде. Табынга утырса — ашы үтми, эшкә тотынса — кулы тыңламый. Мал-туар, йорт мәшәкатьләрен иртәрәк бетереп, мәктәп эшләренә бирелергә, укырга, институтка әзерләнергә омтылып карый, аңы, башы буйсынмый. Сихерле яз жиле аны урамга тарта, бѳтереп алып, очыртып, клубка, яшьләр янына чакыра. Анда да Зәйтүнә жанына тынгылык тапмый. Ишек алдына чыга. Дымлы, тыгыз, шашкын жил иркенә бирелеп, колхоз идарәсе, мәктәп тирәләреннән әйләнә. Мәктәп белән колхоз идарәсе арасында гына аңа Равил абыйсы очрар кебек. Шушы беркатлы уеннан кыз ояла, кызыша башлый, мамык шәлен чишебрәк жибәрә. Болай гына йѳри ич ул, юк, һич болай түгел, ә эш белән йөри! Беткән мени мәктәп, идарә эше!

Чыннан да, шушы юлда аңа Равил абыйсы очрый!

— Хәерле кич, Зәйтүнәкәй, акчарлагым! Кая болай, кичке суык белән?

— Хәерле кич, Равил абый! Мәктәпкә. Планнарым каралмаган.

— Шулаймы? Минем дә каралмаган бит. Киттек, Зәйтүнәкәй, акчарлагым!

— Равил абый, гел шаяртасыз, миңа чиген ич. «Акчарлагым да акчарлагым!»

— Халык сүзе ул, Зәйтүнәм. Үлгәнче әйтермен!

Зәйтүнә тѳннәрне тәмле, ләззәтле газапта үткәрә. Иртәнге таң жиле кузгалгач, уяна да, күңеленнән мәктәп болдырына китә. Равил абыйсы белән сѳйләшә башлый. Юри генә, сүз ѳчен генә шаярта: «үртәмәссеңме!»

Мәктәп ишегенең шыгырдаганы, шапылдап ябылганы ишетелде. Равил абыйсы! Зәйтүнә аны аяк тавышыннан ук таный! Мең кеше шулай бергә атлап килсен, Зәйтүнә Равил абыйсының атлавын мең аяк тавышыннан аерып, танып алачак. Мәктәпнең яшь директоры, Равил абыйсы, бары тик ул гына шушылай ышанычлы итеп атлый ала. Менә ул, бер урында таптангандай итеп, озак кына торды, пионер бүлмәсе ишеге төбенә килде, әмма ачмады. Зәйтүнә янына кермәде, үз бүлмәсенә юнәлде. Гажәп! Зәйтүнә аны ферма йортына, кызлар-егетләр белән кич утырырга, уеннар уйнарга чакырган иде. Равил абыйсының коты очты:

— Син нәрсә, Зәйтүнәкәй, миңа ярамый! Әле генә партиягә кандидат итеп алдылар. Мәгариф бүлегендә дә нык кисәттеләр: мин андый жирләрдә күренә алмам ла инде. Әллә син шундый жиргә йѳрисеңме?!

— Юк ла, Равил абый. Бер үзем барырга оялам. Аннары, авыл яшьләре, үзебезнең укытучы кызлар да сине, һавалы, тәкәббер булып кыланмакчы, диләр. Бозылмасын иде, дип куркалар.

Равил абыйсы бѳтенләй кѳтелмәгән нәтиҗә чыгарып ташлады:

— Куркалар? Әйбәт! Менә күрдеңме? Минем райком, колхоз рәисе, мѳдир белән аралашып яшәвемнән укытучылар курка башлаган. Әйбәт! Куркалар — димәк, мине хѳрмәт итәләр!

Равил абыйсы шушы сѳйләшү ѳчен Зәйтүнәгә үпкәләмәгәндер бит?

Ниһаять, аяк тавышлары ишетелде! Равил абыйсы ишекне кыюсыз гына ачты. Аның күлмәгенең уң якасы бѳкләнеп муенына кергән, галстугы кыек иде. Каушавы йѳзенә чыккан.

— Газета әзер, Равил абый. Гадәттәгечә, идарәгә илтимме?

— Әлбәттә. Анда сине Ислам Гайнанович та кѳтә. Йомышы бар, ахры. Син карышма, зинһар. Мәктәп турында да уйла.

— Рәиснең миңа йомышы? Шаяртмачы, Равил абый. Мәктәп язмышы минем кулга гына калган булса, кѳне-тѳне эшлим мин, Равил абый. Мәктәптә кунып!

Кич тәмам якынлашып килә иде инде. Зәйтүнә, «Якты киләчәккә» газетасының яңа санын күтәреп, идарәгә йѳгерде.

## 3

Зәйтүнә, кояш нурларының, күзенә туры тѳшүеннән уянып, айнып китте. Ачык тәрәзәдән очынып-очынып сайраган кошлар тавышы ишетелә. Кайдадыр еракта-еракта эт ѳрә. Якында гына ниндидер жиңел машина «гѳрли». Ишек тупсасы дѳпелдәп алды. Кыз башта аңышмый ятты. Исенә килгәч, бѳрешге, калтыранды, ялангач тәнен бизгәк тота башлады. Йомшак, бәрхет юрганны күзенә кадәр тартты. Аңа карап жиңеллек килмәде, бизгәк тотуы дәвам итте. Үз-үзен, жанын кая куярга

белми изаланды, үз-үзеннән, тәненнән җирәнде. Әйтерсең, аның башыннан миен, күкрәгеннән барлык әгъзаларын суырып алганнар да, шулар урынына чүбек, тирес суы тутырганнар. Тышкы ишек тупсасында тагын нидер «гөрс» итеп куйды. Зәйтүнә, үрелеп кенә, затлы паласта таралып яткан эчке күлмәген, башка кирәк-яракларын җыйды. Кабаланып киенә башлады. Куллары дер-дер калтыранганлыктан, күлмәк сәдәфләрен каптыра алмый интекте. Хәсрәтле күңеленә ямьсез-күңелсез уйлар агылды. Шулардан котылырга теләгәндәй, кыз юрганга күмелде. Их, шулай итеп кенә үз-үзеңнән, шушы мәхшәрле төннән, кешеләр күзеннән, үткәнеңнән качып булсачы!

Пычрак, оятсыз хатирәләр монда да бәреп керде. «Үскәнем, синең кулны җиңел, тәмле диләр, кадерле кунагыбызга чәй ясап кына эчерт инде» — колхоз рәисе ничек килештереп, итагатьле, әдәпле итеп сөйләште! «Теге йортта» да башлап сүз катмады, тыңлап кына, Хуҗа белән райком секретаренең сүзләрен җөпләп, әледән-әле баш кагып кына утырды. Ә райком секретаре тәмам тугарылды, бәллүр рюмка күтәреп, Фарукшин каршысына тезләнде. «Шушындый иркен, шушындый бәхетле, шушындый муллык ташып торган республикабызны иптәш Фарукшин үз куллары, үз акыл җимеше белән ясады! Заманында Никита Сергеевич дөрес әйтте: «Шебутной Татарияне бары тик корыч куллы кешеләр генә җитәкли ала!» Мин Хуҗа исәнлегенә, Иптәш Фарукшин, бетмәс-төкәнмәс энергиясе, коммунизмга иң туры юлны күрсәтүе өчен эчәм!»

Исерүдән гәүдәсе шактый таралган Хуҗа райком секретаренең пеләш башыннан сыйпый:

— Ә сез, авыл өрәкләре, беләсезме, Кремльдә ат ите генә ашаганнарын? Академиклар, аннары галимнәр ат ите ашый! Исегездә тотыгыз: аракы барсын да җиңә, казылыкны җиңалмый. Казылык аша! Мин әйттем, аша!! Безгә бер-беребезне сакларга кирәк. Әнә, Африкада негрлар берләшә башлаган, ха-ха-ха! Безгә дә берләшергә вакыт! Аша! Мин негрларның нигә берләшкәнен беләм! Әмма без дә берләшәчәкбез! Шуның өчен тост тәкъдим итәм!

— Дөрес әйтә иптәш Фарукшин, ә гүзәл кыз ник эчми? Колхоз, аңлатма бирегез!

— Эчә ул, эчә. Иптәш Фарукшин хөрмәтенә әдәп кенә саклый. Аннары, иптәшләр, безнең гүзәлебез бик матур итеп җырлый. Үзенең исеме Зәйтүнә, иң яраткан җыры — «Зәйтүнәкәй». Сорыйк! — Райком сорый!

— Мин сорыйм!

Шундый зур кешенең, Хуҗаның үзенә атап дәшүеннән кыз тәмам югалып, каушап калган иде. Өч ир-ат аңа тын алырга да бирмиләр.

— Мин эчмим. Гомумән, минем эчкәнем юк. Зинһар, гафу итегез.

— Зәйтүнә, давай, алайса менә монысын эч. «Камю» диеп язылган. Бу аракы түгел, коньяк! Мәскәүдә студент кызлар гел шушыны эчә.

— Мин әйттем!

— Райком сорый!

— Зәйтүнә, туган колхоз турында уйла! — Монысын колхоз рәисе аның колагына пышылдый.

— Молодец! Ат ите, казылык кап!

— Иптәшләр, игътибар, «Зәйтүнәкәй» көе!

Пычрак хатирәләр, качыгыз! Их!! Кыз мендәрен рәтләде. Ул кап-кайнар, юпьюеш иде. Зәйтүнә үзе боз кебек сап-салкын, бизгәк тота, ә күз яшьләре кап-кайнар. Кыз төне буе җир белән йолдызлар арасында адашып чыкты. Иләмсез зур гәүдәдән ычкынып, йолдызлар арасына качуы була, көчле куллар келәшчәдәй эләктереп, аны кире җиргә төшерәләр. Ул карыша, чәбәләнә, тешли, тагын йолдызлар арасына кача. Куллар аны кабат җиргә төшерә, чытырдатып кысалар, кыз аңын югалта...

Ихата эченә үк үтеп, тагын бер машина килеп туктады. Йортны саклап, тәртиптә тотучы карчыкның нәрсәгәдер сукранганы ишетелде.

Зәйтүнә торып утырды. Зур көзге каршысына басып, таралып, чуалып беткән чәчләрен рәтләде, күлмәген төзәтте. Ишекләрне сак кына ачып, һавага чыкты. Күзләре камашты. Бер мәл ул аларны йомып торды. Бөтен табигать, агач яфраклары, ихата-кура, күл суы, аңа төшә торган такта басмалар иртәнге кояш нурында җем-җем килеп торалар иде. Кыз салкын суда озак итеп битен юды, текәлептекәлеп, күлне тикшерде. Күңеленнән генә күлнең төбен үлчәде. Авыр уйларыннан аны әлеге карчык бүлдерде. Аның кыяфәте усал, зәһәр иде. Буш чиләген басмага куйды да, күзләрен яман алартып, юка иреннәрен бөрештереп, кызга ысылдады: «Олтырак! Ыштыр бит! Уйнашчы! Син зиначы аркасында Хуҗа рәисне колхоздан куа! Тыңлап тордым, рәисне, маңгаена төртеп, кызың кыз түгел иде, дип сүкте, жирбит! Бер өстерәлчек аркасында менә дигән кеше харап булды! Югал күземнән!..»

Зәйтүнә сыгылып төште. Нахак сүзләргә җан ачысы белән күкрәк түреннән өзелеп чыккан «Аһ!» дигән ыңгырашу белән җавап кайтарды да капкага таба йөгерде. Кемдер «Зәйтүнә!» дип кычкырды, юл буйлап җыелган күгәрчен көтүләре пыр

тузып, һавага күтәрелде. Кыз берни дә күрмәде, берни дә ишетмәде, берни дә сизмәде, сулышына буыла-буыла, йөгерде дә йөгерде. Арттан сузып-сузып машина кычкыртты, ахры. Кыз юлдан читкә, басуга каерды. Уҗымга уралып, туфлиләре төшеп калды, әрфиядәй үтә күренмәле зәңгәр яулыгын җил алып китте. Кыз берни сизмәде, берни ишетмәде...

Каен урманының авызына җиткәч, абынып, яшел чирәмгә ауды. Учлары белән битен каплап, үксергә, сулкылдарга тотынды. Күз яшьләре чыкмады. Тамак төбенә каты булып төер утырды. Шул төер, кайгысын йөрәгенә җибәрмәскә тырышып, күңелендә тота кебек тоелды.

Аягы, тез капкачлары әрнүгә түзә алмыйча, торып утырды. Каршыда, бер чакрымнар ераклыкта гына авыл җәйрәп ята. Аны шушы пычрак дөньяга китергән, каһәрләнгән авыл!

Коры-сары өеменә абынып егылган икән. Бот төпләренә кадәр сыдырылып беткән. Кул сузымы арада, каен төбендә, бәрәңгеле чиләк, каен тузлары. Һәм әз генә арырак, кара еландай бөгәрләнеп, көтүче чыбыркысы ята иде. Кыз үләсләнгән күзләре белән аларга, тирә-юньгә карап торды.

Сары каештан сигезлегә үрелгән чыбыркы озын иде...

...Хуҗаның иртәдән бирле кәефе булмады. Ниндидер бер авыл мокыты аңа төне буе каршылык күрсәтте. Хатын-кыз өлкәсендә күпне күргән Хуҗа дөрес сиземләде. Кыз шәп иде, сирәк очрый торган нәселдән. Шуңа күрә ачуы отыры көчәйде. Бер авыл мокытын сындыра алмасын инде?! Әллә картаямы?! Табигатьнең бу явыз көче аңа буйсынмый иде, холыксызланудан күлмәгенә сыеша алмас дәрәҗәгә җитте.

Берничә сәгать буе, мылтык күтәреп, табигатьтә йөреп караса да, күңеле күтәрелмәде. Саубуллашып та тормыйча, шәһәренә китеп барды.

Көтүдән качып, каен урманына юл тоткан бер төркем азгын сыер каен ботагында чайкалган-җилфердәгән гәүдәне күреп, шашынып туктап калды. Яшь тана ал тояклары белән җирне казыды. Күзләре тонган, бу сәер күренештән тәмам илергән хайваннар башларын чайкый-чайкый мөгерәргә, үкерешергә тотындылар. Иртәнге аштан соң черем итеп алырга күнеккән көтүче Гайни малларының хәвефле тавышын ишетмәде...



# ШИГЪРИЯТ

*Күрше Башкортстанда яшәүче, татар телендә иҗат итүче каләмдәшләребез — танылган шагыйрьләр иҗаты белән журналыбыз даими таныштырып килде. Бу санда да без укучыларыбызга шушы төбәк шагыйрьләре иҗатыннан сәхифә тәкъдим итәргә булдык.*

## Фәрит Габдрәхим

### И горур зат!

Ошбу дөнья яралганнан бирле
Иң зур ихтыяҗдыр — бәхеткә.
Зиннәтле хан сараенда түгел —
Баш өстендә торган тәхетләр.

Һәр хәрефе чылбыр боҗрасыдай,
Язылганнар хәтәр законнар.
Шул законнар, шул зынҗырлар белән
Богауланган шагыйрь-акыннар.

Овидийлар һәм Җәлилләр шаһит,
Саный китсәң алар азмы соң?
Аерым башлар нәрсә! — Хөкемдарлар
Таптый хәтта халык язмышын.

Кибән башына да менә алмаган
Бисмәкче адәм башында
Тишеләдер башлар — шундыйларның
Куенында йөрткән ташыннан.

Авыз ачсаң, хаклык-мазар диеп,
Күрсәтәләр өскә, түшәмгә.
Күрсәтмәләр-фәрманнардан фәкать
Ул түшәмнәр, ахры, түшәлгән.

Йөрми бәла казык башларыннан,
Безнең баштан йөри бәлаләр.
Баш калкытсаң, буразнадан чыксаң,
Фәрман-күсәк белән бәрәләр.

И горур зат — Кешем!
Синең алда
Ул тәхетләр — бары чүп кенә.
Синнән югарырак беркем дә юк.
Синнән югарырак — күк кенә.

---

Башкортстанда яшәүче, татар телендә иҗат итүче шагыйрьләрдән — Ф. Габдрәхим — СССР Язучылар берлеге әгъзасы; Р. Идиятуллин, Н. Әминева, С. Рәхмәтулла — башкорт телендә басылган китаплар авторы; Рәшит Гатуллин, К. Шәфикова һ. б. вакытлы матбугатта актив катнашалар.

## Үз юлыннан аксын чишмәләр

*(Бер иптәшкә җавап урынына)*

Бабайларны язмыш куган — Казан
Ханлыгының көнчыгышына,
Нугай урдасына.
Ә без инде
Монда туып-үстек — шушында.

Кузгатмагыз Явыз Иван салган
Татарларның бәгырь ярасын.
Без дә төп халыкбыз: туган җирен
Сайлап аламыни нарасый?!

Гомер бакый арттан калмасмыни
Җиңелгәннең кара сакалы.
Төрле кыяфәткә керсә керде,
Татарлыгын татар сатмады.

Диннән кучкәннәр бар. Гаепләмик:
Үзе теләп кем соң чукынган.
Файда эзләп милләт үзгәрткәннәр...
Керми алар адәм чутына.

Элек «ялчы», хәзер «дуслар» диләр,
Күп тырыштык дуслык хакына.
Намуслылар инкарь итмәс: ихлас
Ярдәм иттек кардәш халыкка.

Төлке бүрек киеп алабыз да
Ташланабыз сәхнә түренә.
Сәнгатькә ник битлек кидерергә?
Татарлык бит барыбер күренә.

Җырлар чыгарабыз. Моң агыла.
Татар моңы. Шаклар катарлык.
Рәсем төшерәбез. Сурәтләрдән
Көлемсерәп тора татарлык.

Хәрефләргә койрык куябыз да
Шигырь бастырабыз — юл ачык.
Койрык куеп, койрык булган кына
Татарлыктан качып булсачы.

Татар рухы яши Кәкребашта
Миңештәдә, Балак, Келәштә...
Тана сөте һәрчак җиңеләчәк
Ана сөте белән көрәштә.

Милләттәшләр!
Каш чыгарабыз дип
Күз чыгарабыз без түгелме:
Татар рухы белән сугарабыз
Кан-кардәшләребез күңелен.

Күршеләрнең буасына түгел,
Үз юлыннан аксын чишмәләр.
Буаларны алар өстән түгел,
Сиздермичә, астан ишәләр.

«Сез бит татар түгел» диеп кенә,
Татарлардан булмый котылып.
Яшәүчеләр күрше исәбенә
Ахыр чиктә кала отылып...

# Рим Идиятуллин

❀

«...Ачлык баскан елда...» —
Дип әнкәем әл дә сөйләр.
Кулында көч калмаса да,
Ипине ул үзе теләр.

«...Сугыш чыккан елда...» —
Дип әнкәем һаман сөйләр.

Тыныч йоклый алмаса да,
Безгә тыныч йокы теләр.

Килеп-китеп тора афәт.
Кайлардадыр
Җир тетри, кояш тотыла...
...Аягына басмак булган улым
Аягында чак-чак басып торган
Әнкәм итәгенә тотына.

❀

Бу гомерем тәгәл бер көн кебек,—
Чыкты кояш, батты аннары;
Мин бит синең күңел күкләреңдә
Исемсез бер йолдыз нибары!

Өлешемә төшкән көмешемә
Күз күнсә дә, күңел күнмәде.

...Атылды да йолдыз көпә-көндез,
Көпә-көндез!— Беркем күрмәде.

[1] Башкортстанның күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре чыккан авыллар.

# Салават Рәхмәтулла

## Очрашулар

Таулар белән таулар очрашмый да...
Кеше белән кеше очраша.
«Хәлләр ничек?» «Ничек хәлләр?»
—диеп,
Әллә кемнәр туктап сораша.

Танышлар да кебек, түгелләр дә —
Кайда, кайчан күрдем үзләрен?
Үз хәлләрен сөйлиләр дә... миннән
Көтә алар җавап сүзләрен.

Һәм янадан сөйли башлый алар:
— Тулай торак!..
— Кызыл почмаклар!..
Шигырь кичәләре уздырганбыз —

Хәтердән дә чыккан ул чаклар...
Күпме кала, күпме авылларда
Күпме шигырь сөйләп кителгән!
Шагыйрьләргә охшап йөрелгән бит:
Автографлар бүләк ителгән...

Шагыйрь булып булмый, туган халкың
Шагыйрь итеп сине белмәсә.
Халык тудырмаса — шагыйрь тумый,
Шагыйрь үлми — халык үлмәсә...

...Хәлләремне, җанкисәккәйләрем,
Сез аңлагыз минем җыр аша:
Узып барабыз без кылдан нечкә,
Кылычлардан үткер чор аша!

## Өмет белән күңел тулышкан

Сорау белән күзләр мөлдерәмә,
Сорау белән күңел тулышкан:
«Бу җир шары берчак тынар микән,
Тынар микән берчак сугыштан?..»

Эче-тышы тулы — дары хәзер,
Орбитасы — юлы — гел дары...
Түп-түгәрәк алма сыман түгел,
Мина сыман хәзер Җир шары.

Бер метеор килеп бәрелсә дә,
Көлгә калыр төсле — таралып.
Һәм Кояш тирәли Җир урынына
«Кара бушлык» очар каралып...

Кеше яратылган чордан башлап,
Җир — ялкында, утта, күмердә...

Терекләкнең акыллысымы без,
Иң акылсызымы бу җирдә?!

Дөнья тулы корал: һәркайсыбыз
Әллә ничә тапкыр үләрлек.
Әйт, табигать, кешегә аң биреп,
Эшләдеңме әллә юләрлек?!

Өмет белән күзләр мөлдерәмә,
Өмет белән күңел тулышкан:
Бу Җир шары берчак тынар бит ул,
Тынар бит ул берчак сугыштан!

Кешелеккә аек акыл кирәк,
Җир-анага — җаннар тынгысы!
Соңгы сугыш үткән сугыш булсын!
Ах... булмасын алда соңгысы!..

# Рәшит Гатауллин

## Үз чорыңны ничек танырга

Һәр заманның була үз даһие,
Һәрбер чорның үз байракчысы.
Ияртүче, яраклашучысы,
Һәм, әлбәттә инде — җырчысы.

Һәлакәтләр, утлар эченә үтә,
Чоры белән атлый янәшә.

Кеше булып һәм җырчысы булып
Үз заманы белән сөйләшә.

Алышына дәвер, чор, мизгелләр,
Нәрсә генә бар соң мәңгелек!
Үткәнгә бак,
Бүгенгегә кара,
Күтәрелеп чыга җыр элек.

Җир өстендә бүген ниләр бара,
Нәрсә яна уйда, җанымда.
Үткәннәрем һәм бүгенгем өчен
Җавап тотам тарих алдында.

Үз дәверен кемнәр хурламаган,
Кем соң риза булган шул чорга?
Шулдыр инде язмыш.
Чорым мине
Бер утларга сала, бер суга.

Туры килгән икән шундый заман,
Кирәк булган икән янарга —
Үз чорымны ничек танырга соң,
Үз-үземне ничек табарга?!

## Каршы алам

Шыбыр-шыбыр көзге яңгыр ява,
Соңгы яфракларын коя каен.
Миңа гына шулай ямансумы,
Ямансумы — көзләр килгән саен?
Гомер буе мин ышанып килдем
Гел бер көе генә каламын, дип.
Үз-үземне генә алдадыммы:
Бөтенесе дә әле алдадыр, дип.
Менә бүген көзге яңгыр ява,
Соңгы яфракларын каен коя.
Язларымның инде үткәнлеген
Бөтен җаным-тәнем белән тоям.
Табигатьнең мизгелләре төгәл,
Көзе-язы кабатланып торыр.
Үзе генә белгән урыннарга
Кошлар тагын кайтып оя корыр.
Үз-үземне кабат алдасам да,
Язларыма кабат кайта алмам.
Кеше гомеренең мизгелләре
Үз вакытын белеп, торып калган.
Беләм, вакыт җиткәч кошлар килер...
Бар җиһанны каплар ап-ак карлар.
Минем өлешемә төшкән карлар
Хәзер инде эремәскә явар.
...Шыбыр-шыбыр көзге яңгыр ява:
Алдасам да һаман үз-үземне —
Үз вакытын белеп кенә хәзер
Каршы алам тагын бер көземне.

# Марис Нәзиров

Бу доньяда бар шул әле, һаман барлар:
Итәк белән ай-кояшны каплаганнар,
Кабарганнар — кызыл күргән күркә кебек,
Кинә тотып, талпан булып кадалганнар.

Бу доньяда бар бит әле, һаман барлар:
Комагайлык кочагына атылганнар,
Каерганнар атасының алтын тешен,
Халкын ташлап, дошманына сатылганнар.

Арабызда төрле затлар әле барлар.
Бил буылган. Кем — кемлеген бәйге барлар...

## Бары юатам гына

Әйтә торгач үз-үземә:
«Түзә белергә кирәк!»
Югалтулар җәзасына,
Кырыс язмыш ярасына
Өйрәнә бара йөрәк.

Ничә тапкыр янып көйдем,
Сөюдән исердем дә...
Җил түздыра хәтер көлен,
Учагымда көйри бүген
Бары бер исем генә.

Сердәш булыр дуслар таптым,
Шагыйрь күңелләрне.
Китәр алар... Теләр сүнә...
Үткән еллар көсләренә
Кем җаны күмелгәндер —
Җыр ята күмерләнеп.

Кочле шартлау тәмугында
Башлар очты тимергә.
Таш ярылды ут угыннан,
Әләм хәтле чүпрәк җитте
Адәм «тәнен» төрергә...

Өйрәнә бара йөрәгем
Югалту ярасына.
Юк, өйрәнми. Үз-үземне—
Барсына да, дип, түз инде...
Бары юатам гына.
Бары юатам гына...

# Нәҗибә Әминева

## Диңгездән түгел, йолдыздан...

Дөньяда юллар сузылган.
Юллар күп, урау-урау...
Дөньяның нәкъ уртасында
Туган ил — зәңгәр утрау.
Шул утрауга керәсең дә
Туган өйне күрәсен.
Ах, бу өйдә син — сандугач,
Ах, бу өйдә — күгәрчен.

Тиңләп сөелдең монда син
Йә аккош баласына...
Тәрәзәләре дә охшаш
Әнкәең карашына.
Исенә төшсә шул өйнең
Миһербанлы карашы,
Диңгездән түгел, йолдыздан
Кайта адәм баласы...

⁂

Гаебем булса, әйтегез,
Буямыйча ал төскә.
Дөреслекне аңлый алыр,—
Ышанам, күңелем нечкә,
Нахак гаеп кенә беркүк
Ташлый күрмәгез өскә.

Нахакларга түзә алмый,
Күтәрми, күңелем нечкә.
Тик танып гаебен кеше,
Үз-үзен җиңеп кочкә,
«Кичер!..» дия генә алсын,
Кичерәм — күңелем нечкә...

## Шөкер

Бәхетемне аңлый, уртаклаша,
Күңелемдә туа да шигырь...
Күңелендә шигырь яралмаган
Бәхетләрдә ничек яшидер?!
Һәм кайгылар — минем генә түгел,
Башканың да эчен өзәдер...

Йөрәгендә шигырь яралмаган
Кайгыларда ничек түзәдер?!
Тик яралу — әле язылу түгел —
Язылмаган чагың күп, шигырь...
Язылмаган чагың күп булса да,
Яралмаган чагың юк, шөкер!..

# Фәрит Суфияров

## Ир итте

Башны түбән игәнем юк,
Сер бирмәдем беркемгә.
Сагышларым, борчуларым
Бетми калган бу көнгә.

Яшьлектәге хыялларым
Артымнан һаман калмый.

Абынып егылган кеше
Үзенең хәлен аңлый...

Күп нәрсәләргә төшендем,
Беләм суның агышын.
Әкияттәге малай төсле,
Дөнья белән таныштым.

Кабул итеп алам барын,
Шатлыгын, кайгыларын.
Чайкалып җиргә түгелде
Эчкерсез тойгыларым.

Әзме өзгәләнде җаным,
Газабында тилмертте...
Сабырлатты тормыш мине,—
Ышаныгыз: ир итте.

# Вера Мусина

## Әй

Бар дөньяда бер елга,
Исемнәре аның Әй.
Тын гына җырлап ага,
Бик сагындым дигәндәй.

Бар дөньяда бер елга,
Ярларында көлә җәй.
«Мин яра-а-там!» — дип кычкырсаң,
«Мин дә!» диеп әйтә Әй.

*

Кинәт кысып ала йөрәк,
Тик әле түзәм, түзәм.
Шатлыгы, сагышы белән
Гомер көннәрен өзәм.

Юкка түгелдер эх! диеп
Алга ашкынуларым.
Тәнемдә чирләр күптер дә...
Җанымда — даруларым.

# Кәүсәрия Шәфикова

*

Тел бозылды, гарипләнде,
Чатанланды сүзебез.
Кем гаепле?
Үзебез!

Ярый әле, бүген килеп
Хатабызны таныйбыз.
Бер-беребезгә инде, якын
Килеп, бармак яныйбыз:
— Кара аны, сөйләр булсаң,

Телеңне бозмый сөйлә!
Моңыңны бозмый көйлә!

Татар татар булып калыр,
Юк, ул югалтмас үзен.
Үз телендә матур итеп
Сөйләр әле ул сүзен.
Манарадагы ай кебек,
Балкытып ашәр йөзен!

*

Матурлыктан ямьсезлеккә ерак түгел,
Барып җитеп була торган ара икән:
Кот очарлык хәлләр күрим әле дисәң,
Хыялыңнан аерылып кара икән!

## ПУБЛИЦИСТИКА

# Марсель Зарипов

# БАЛ НИГӘ БИК КЫЙММӘТ?

*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре язучы Марсель Зарипов татар әдипләре арасында иң җитди публицистлардан санала. Аның бинһая мөһим мәсьәләләрне күтәреп чыккан әсәрләре Татарстанда гына түгел, ил күләмендә киң таралган.*

*Бу жанрдагы уңышлар язучының катлаулы тормыш юлына барып тоташадыр, мөгаен. М. Зарипов, Сарман районының Петровка авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач та, шундагы спирт заводында эшли башлый. Аннары — Хәрби-диңгез флотындагы гаскәри хезмәт. Армиядән соң ул «Татнефть» берләшмәсенә килә, махсус әзерлек узып, электромонтер булып эшкә керешә.*

*Шушы елларда ул Әлмәтнең район газетасына хәбәрләр дә яза. Экстерн тәсендә — урта мәктәпне, читтән торып университетны тәмамлый. Башта — «Советская Татария», соңра «Советская Россия» газеталарында үз хәбәрче штатында эшли. Журналистикадагы күзәтүләре аңа әдәбиятка аяк басарга этәргеч була. Алтмышынчы елларда Татарстан һәм Мәскәү матбугаты аның беренче хикәяләрен басып чыгара. Аннары инде повестьлары да озак көттерми.*

*Марсель Зарипов Ә. Еники, Н. Фәттах, Г. Ахунов, В. Нуруллин кебек язучыларыбызның әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп тә татар әдәбиятына игелекле хезмәт күрсәтте.*

*Ул Татарстан дәүләтенең Г. Тукай исемендәге һәм Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге бүләкләренә ия.*

*Шушы елның октябрендә катлаулы һәм мактаулы хезмәттә чыныккан бу каләмдәшебезгә 60 яшь тула. Без аны шушы уңайдан ихлас котлыйбыз, киләчәктә тулы сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез.*

*Түбәндә язучының илебез хуҗалыкларында бал җитештерү мәсьәләләренә багышланган яңа мәкаләсен урнаштырабыз.*

Кыш нихәтле генә зәһәрләнмәсен, көннәр озая башлау белән, кар күмеп киткән умарта өйләрендә җанлану сизелә. Сау бул, кышкы тынлык! Яшәсен кызу хезмәт җәе! Умарта эчендә, ана корт тирәсендә тормыш кайный: коздән калдырылган корълагра язгы алмашны үстереп җиткерергә кирәк. Эшче кортлар кәрәз күзәнәкләрен чистарта, күкәй салырлык итеп шомарта, икенчеләре көзге азыкны ачып, ана кортка затлы ризык әзерлиләр. Зур кәрәзнең уч төбе хәтле урынында җылылык 30—35 градуска күтәрелә, ана корт кәрәз күзәнәгенә беренче күкәен сала. Зур кәрәзне тулаем җылыта алырлык көч юк әле, шуңа күрә кәрәз кишәрлекләп җылытыла.

Ана корт кәрәз күзәнәге төбенә ябыштырып киткән бала шундый да көчсез, хәлсез әле, шунлыктан булачак бал кортының апалары һәркайсы бишектәге сабыйны җылытыр өчен сулыш өрә, азык алып килә. Өлкән бал кортлары бәләкәйләре янына, егерме бер көн эчендә ун мең мәртәбә килеп китәләр. Кимендә — ун мең!

Умарталарны кышлау йортыннан чыгару 25 мартка туры килә. Әгәр ел килеше әйбәт булмаса, умартаны һавага чыгару 17 апрельгә тикле чигерелә. Бу вакытта инде кояш тәрәзәләргә туры карый башлаган була.

Умарта көчен тук яшәтү, бала үстерү, берничә буын эшче кортлар җитештерү өчен,— җәен бик тырышып бал ташыган кортлар 35—40 көн эчендә хәлдән таеп үләләр,— бер умартага йөз килограмм бал, утыз-кырык килограмм чәчәк серкәсе, ике чиләк су китерергә кирәк. Гаилә белән ана корт идарә итә. Умарта эчендә ул хуҗа. Ул үзе дә боерык бирел утыручы гына түгел, ул күкәй сала. Башта ул бер, ике, биш күкәй сала, ә җәй үзәгендә ана корт салган күкәйләр ике-өч меңгә җитә. Корт көче зур булырга тиеш, кышка җитәрлек азык хәзерләп калдырыр өчен эшче кортларның җәй үзәгендә бик күп булуы кирәк. Шуңа күрә ана корт кырык секунд саен күзәнәккә бер күкәй ябыштырып куя. Андый чорда ана корт салган күкәйләрнең авырлыгы аның үзенең авырлыгыннан да артып китә.

Ишле гаиләдәге кебек, умартадагы һәр бал корты үз вазифасын яхшы белә. Әле оякларга очып канат ныгытмаган яшь бал кортларына беренче өч көндә йортны чистарту, җыештыру эше йөкләтелә, алар кәрәзнең күзәнәкләрен чистарталар, бишекләренең төбен һәм стеналарын ялтыраталар. Дүртенче көнне яшь кортлар бәби караучыга әйләнәләр: бишеккә салган бәбиләрне сыйлыйлар.

Җиденче көнне яшь кортларга аеруча җаваплы эш йөкләнелә: умартаның хуҗабикәсен — ана кортны туендыралар алар. Ризыкның төренә карап, күкәйләрдән егерме бер көндә эшче кортлар, егерме дүрт көндә сорыкортлар чыга. Ә уналтынчы көндә, махсус сөтләгән салынган күзәнәктән, ана корт үсеп чыга. Кәрәз күзәнәкләр бала кортларны үстерү бишеге булып та, чәчәк серкәсен саклау урыны булып та, бал җыю савыты булып та хезмәт итә. Унсигезенче көнне бал кортлары кәрәз коярга керешәләр. Гомеренең иң балигъ булган чагында гына кортлар үзләренең төп эшләренә — бал һәм чәчәк серкәсе җыюга керешәләр. Чык тамчылары алып кайталар, үсемлекләрне серкәләндерәләр.

Кешеләр хуш исле кәрәзле балны кискән чагында, канатлы нечкәбилләрнең бу татлы ризыкны җыю өчен күпме «тир түккәннәрен» уйлыйлармы икән? Умартага бер килограмм татлы нектар кайтарыр өчен бал корты ун миллион чәчәккә куна. Бал алып кайта торган савыты бик бәләкәй умарта кортының, бер рейс ясаганда аның күтәреп кайткан йөге миллиграммнар белән генә исәпләнелә. Бер килограмм бал җыяр өчен бер йөз илле мең мәртәбә кайтырга тиеш ул умартага. Ярый ла баллы чәчәкләр умарталык янында гына булса, күп очракта безнең канатлы дусларыбызга әллә кайларга хәтле барып җитәргә туры килә. Йөк белән кайткан чакта, бик күп көч түгелә, бал кортының йөрәге минутына йөз илле мәртәбә тибеш ясый. Бер килограмм бал җыю өчен умарта корты узган җир шарын сигез-ун мәртәбә урап чыгарлык була. Бал кортының чәчәктән чәчәккә кунып, бал җыю рәвеше безгә мәгълүм, тик иң зур могҗиза бал корты умартага кайткач башлана.

Нектар — гади татлы су ул. Яңгырлы елларда дымлылык илле-алтмыш проценттан артып китә. Андый күп сулы ширбәт озак саклана алмый, күпчи, бозыла, яраксызга чыга. Шунлыктан умарта гаиләсе табышны артык суыннан арындыра. Бал җыючы эшче кортлар тырышып тапкан байлык бер «амбарга» гына салынмый, төрле күзәнәкләргә бүлеп салына. Меңләгән бал корты канат җилпеп тора, күзәнәкләрне җилләндерәләр. Меңләгән җилләзәләр берьюлы эшли башлагач, минутка 26 400 җилпү ясагач, умарта эчендә кайнар җил куба, алар инде сазлыкларны киптерә алырдай көчкә ия булалар.

Бал кортлары патшалыгының югары кануннары нигезендә Хуҗабикәне югарыдан билгеләмиләр, түбәннән сайлап куялар. Ана корт хәлсезләндеме, гаилә шундук яңа ана кортны үстереп чыгара, ә элекке Патшабикәне тәхеттән куып төшерә. Корт иленең законы әнә шундый.

Дөрес, оста умартачылар хәзер ике ана кортны бер умартада яшәтү ысулын да уйлап таптылар. Күзәнәкләрдә ана корт гадәти гаиләне — корт илен үстереп җиткерүгә умартаны урта бер җиреннән фанер белән бүлеп куялар. Җитәкчесез калган корт гаиләсе үзенә кирәкле ана кортны бик тиз үстереп чыгара да, шул рәвешле, бер умартада ике патша барлыкка килә. Ике ана корт эшче кортларны бик тиз ишәйтәләр, бал җыю бермә-бер арта, соңыннан бүлемне алалар, кортлар анда инде үзләренә кайсы ана корт ошый, шуны калдыралар.

* * *

Бал җыю илдә елдан-ел авырһаша, бал үзе исә елдан-ел кыйбатлана бара. Көмешкә кайнатучылар белән көрәш башланып, шикәргә һәркайда, хәтта ки Мәскәүдә дә талон кертелгәч, бер килограмм балга егерме биш-утыз сум сорый башладылар. Моннан ике йөз еллар элек үзебездә умартачылык белән шөгыльләнүнең энтузиасты Петр Иванович Прокопович, Чернигов якларында үз умарталыгында бер меңнән артык умарта асраган кеше, беренче карашка бик тә гади бер ачыш ясаган: әгәр кыргый кортлар ясаган кәрәзне агач рамнар белән әйләндереп алсаң, ул чагында кәрәзле рамнарны күчереп йөртеп, аларның умартадагы урыннарын алмаштырып була, артыгын ала аласың, җитмәгәнен өстисең. Шулай итеп, умарта асраучылар корт ояларын туздырып йөрүчеләрдән аларның дустына, хезмәттәшенә әверелләләр. Умартачылык кызыклы җитди эшкә әйләнә. Аны план белән, исәп-хисап нигезендә алып барырлык була. Про-

копович ачышыннан соң умартачылыкта безнең илдә һәм дөньяда яңа дәвер, канатлы дусларның серләрен өйрәнү чоры башлана.

Икенче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан безнең ил умарталыкларында ун миллион баш умарта асралган. Ватаныбызның бу милли хәзинәсе кадәр байлык башка бер генә илдә дә булмаган. 1975 елны Советлар Союзында XXIII Халыкара умартачылар конгрессы үткәрелде, шунда умартачылык җәмгыятенең өлкән эшлеклесе Жюль Рудольф Ридер: «Советлар Союзындагы умартачылык үзенең муп уңышы белән дөньяның барлык илләрен таң калдыра»,— дигән иде.

Мактау, әлбәттә, күңелле хәл, әмма игътибарлы кеше бөтендөнья умартачылыгының лидеры әйткән сүзләрнең котлау бупарак әйтелүен аңламыйй калмагандыр. Инде байтак еллар Ватаныбыз умартачылыгы илдә арткан халык саны артыннан куып җитә алмый. Сугышка кадәр безнең илдә 170 миллион кеше яши иде, инде менә 120 миллионга артты, ә умарталар саны кимеде.

Менә тагын берничә сан. ФРГда бал куллану кеше башына 1000 грамм, Австриядә, Канадада — 860, Франциядә — 407, Англия һәм Бельгиядә — 302, Румыниядә — 240... Алга таба бал турында ишетеп кенә белүче илләр исемлеге китә. Советлар Союзы бал куллану ягыннан иң соңгы исемлектә түгел түгелен, әмма беренчеләр рәтендә дә бармый. Безнең табыннарда бал ФРГдагыдан өч мәртәбә кимрәк,— барлыгы 310 грамм. Ә табиблар балны илле мәртәбә күбрәк ашарга кушалар.

Кемне гаепләргә: кешенеме, кортларнымы, әллә шартларнымы? Кортларның гаебе юк, билгеле. Ә менә бал кортлары үрчетү өчен кирәкле шартлар, дөресен әйткәндә, үзгәрде. Сугыш алдыннан булганны хәзерге белән чагыштырып карыйк. Урманнар кимеде, баллы чәчәк үсә торган аланнар һәм болыннар сукалап ташланды.

Тагын шунысын да истән чыгарырга ярамый: умартачылык — кешедән авыр хезмәт, фидакарьлек таләп итә. Тәлинкә тутырып кәрәзле алтын бал китерелп табынга куйганчы оста умартачының тозлы тир ачысыннан әлләничә күпмәге иеп төшә.

Бер ядза миңа Татарстанның Мамадыш районы «Таң» колхозы умарталыгында Василий Архипов белән танышырга туры килде. Җәйге челлә түгел. Умарталыкта язын эшләр ничек башлана икәнне үз күзем белән күреп кайтырга ниятләдем. Кортчыларның бал җыю сезонына кадәргe эшләре белән танышырга кирәк иде. Биш мең гектар җирдә 900 баш умарта.

Май. Архипов умарталарны аланга алып чыккан, әмма ояларны әле ачмаганнар иде. Кортлар кәрәзләрне чистарталар, чүп-чарны тышка чыгаралар, бала кортларны саклыйлар.

Василий Архипов товарлыксыз умарталыкка килгән. Беренче сезон эшләрне җайга салуга киткән. Ярдәмчесе Петр Якимов белән бергәләп йорт җиткезгәннәр, мунча салганнар. Умарталык Яковка авылының читендә генә икән, Вятка елгасы күренеп тора; тиз генә баганалар утыртып, умарталыкка ут керткәннәр, аланның читләренә слива, алма, чия агачлары утыртып чыкканнар, күлгә балык җибәргәннәр. Беренче елны ук корт илен аякка бастырганнар, әйбәт кенә бал да алганнар.

Майның беренче көннәрендә умартачылар ана кортлар үрчетү кебек бик тә четерекле кыен эшкә керешкәннәр. Башкалар мондый эшкә тотынмый. Ил буйлап зар ишетелә: урта Рәсәйдә ана кортларны каян алырга белми интегәләр, андый токым бетүгә йөз тоткан. Кавказда үсә торган ана кортларны почта аша җибәрәләр, әмма алар өметне акламый. Кавказ кортлары балны әйбәт җыялар. Тик алар бик иркә шул, суыкка бер дә чыдамыйлар.

Ана кортны, яки гаилә башлыгын умартачылар җәен үстереп чыгаралар, әмма алар бигрәк тә, сезон башланганда кирәк шул! Бу вакытта авырлыгы нибары 200 миллиграмм булган шул бөҗәкнең хакы бер сарыктан кыйммәтрәк, ник дигәндә, эшче кортларны ул үстерә бит.

Архипов умарталыгында мин корт аналары булмаудан интеккән умартачыларның зар елаулары никадәр хаклы икәнен белергә теләдем. Шулай ук авыр эш микәнни соң ул?

Кичтән бәрәңге пешереп ашадык, чәй эчтек, «Вакыт» программасын карадык. Телевизорлары әйбәт кенә күрсәтә иде, шуңа күңел булып, йокларга яттык. Иртән сәгать алтыда тордык. Һава торышын ачыклар өчен «120 минут» дигән иртәнге программаны да карадык. Бик зур җылылык вәгъдә итмәделәр: көндез плюс дүрт градус күтәелә, диделәр.

— Җылы көтеп утырып булмый, эш эшләргә кирәк,— диде Архипов, салкын җилгә битен куеп торгач.

Бал кортлары очмый, әмма умарталарда тормышның кайнап торганы сизелә иде. Умартачыларның эше — муеннан. «Голланка» миче кызды, өйдә эссе була башлады, зур алюмин чәйнекнең борыныннан пар бөркелде.

— Ташкенттагы төсле булсын, дымлы тропик джунгли,— дип аңлатты Архипов. Мичкә тагын берничә пулән ыргытты.— Салкын булса, ана корт салган күкәйләр өши, коры булса, кибеп, куырыла...

Өй эче тәмам җылынып, тәрәзәләр парлангач, бүлмәдә дым сизелә башлагач, өстәлгә гади генә бер җайланма куйдылар: ике рам, аларга дүрт катлы итеп дүрт дистә пластмасса тартмалар беркетелгән. Нечкә алюмин чыбыктан шпатель. Шырпы белән

мамык алдылар. Фанер тартма төбенә капчык киндере салдылар, чәйнектән аңа кайнар су агыздылар да умарталарга таба йөгерделәр.
Болар әле көзен үк иң яхшы үн корт көчен сайлап иң җаваплы операциягә әзерләгәннәр — язын корт аналары үрчетергә!
Архипов беренче умарта янында туктап:
— Төтен! — дип бер генә сүз әйтте.
Ярдәмчесе Якимов умарта авызына берничә мәртәбә төтен җибәргәч, Архипов умартаның капкачын ачып, мендәрне, чүпрәген алып, өстән дә төтен бөркеделәр. Умарта эченнән бүген салынган корт күкәйләре булган рамны алдылар. Күкәйләр күп. Архипов каз канаты белән кортларны оядарына сыпырып төшерде, ә рамны тартмага бик тиз тыгып, өстен капчык белән каплады.
Өйгә әйләнеп кайттык. Умартачыларның ыгы-зыгысыз, бик тиз һәм төгәл башкарган гамәлләреннән мин хәзер иң мөһим операция булачагын аңладым. Чәйнек паровоз кебек пар бөрки. Умартадан алынган бишекләрнең кайберләре коры иде, димәк, кортлар барысын да кабул итмәгәннәр, ә кайберләре ап-ак сөтлегән белән тутырылган, сөтлегәннең куәтле көче гади бер күкәйне эшче кортка яки соры кортка да әйләндерми, умартаның патшасына — корт анасына әверелдерә икән. Архиповның ярдәмчесе яңа рамның патроннарына шырпы белән яңа сөтлегән сөртеп чыкты, Архипов алюмин шпатель белән кәрәз ояларын ак күкәйләрне сак кына алып, аларны корт анасы яши торган иркенрәк бишеккә күчерде. Бирёдәге бала инде хәзер корт анасы булып үсәчәк. Дүрт планка, кырык бишек, димәк, кырык корт анасы, кырык яңа күч дигән сүз!..
Мин бу эшнең нәтиҗәсен исәпләп чыгардым да, кырык корт анасы кырык умарта бирәчәк, дип саксызрак сүз әйтеп ташладым.
— И-и-и, авызыңа — бал да май! — диде Архипов. — Анысы аның инде кортларның үз эше. Кичә суык иде, тапшырган кырык күкәйнең өчесен генә кабул иттеләр. Җылы кирәк, кояш! Ул чагында кортлар җанлана, куелган барлык күкәйләрне тәрбиягә алалар.
— Бәлки көннәр җылынганны көтәргә кирәктер? — дидем мин. — Вакыт җитәрлек, әле май башы гына бит.
— Умарталыкта вакыт акчадан да кыйммәтрәк. Егерменче майда корт аналары чыгачак, ул көнне өч ана чыга, аннары икенче көнне — тагын биш, аннары конвейердагы кебек чыгып торачак: умарта саен — унар, унбишәр. Һәрбер корт анасы — тагын бер умарта, тагын бер корт иле. Өч айдан бер корт күче 150—200 сум табыш бирәчәк. Ялкауланырга ярамый!
Башка умарталыкларда бу чорда әле тынлык. Умартачыларга язгы көндә артык эш юк, алар рамнар ясый, буш умарталарны тәзәтә. Ә Яковка чүннегендә ай буе корт аналары үстерәләр. Бу чорда бик уяу булу кирәк. Вакытны кулдан ычкындырырга ярамый. Бер корт анасына башкаларыннан алда «туу» җитә, анда ярышу дигән бөек закон гамәлгә керә. Бер тәхеттә ике патшабикә утыра алмый. Үтерешәләр. Үтереш-кырышларны булдырмас өчен пичәтләнгән бишекләрне тимерчыбык читлекләргә урнаштыралар.

* * *

Соңгы елларда умартачылыктан күңел кайту, зарланулар күбәя башлады. Умарта тоту чыгымнарны капламый, диләр. Нилектән соң болай?
Беренчедән, химикатлар бик күбәйде. Икенчедән, урманнар бетә, болыннарны сөреп ташлыйлар, бал җыяр өчен кортларга әллә ничә чакрымга очарга туры килә. Күмер әчелеге газының да зыяны, мөгаен, тия торгандыр, ул бит эппә булып, Җир шарын томалый, һава агымына, кояш нурлары үтеп керүгә комачаулый. Башкаларга килгән бәла-казалар «Таң» колхозындагы Архиповлар умарталыгын да читтә калдырмыйлар. Әмма аларның көн үтсенгә түгел, бупсынга эшләүләре әйбәт нәтиҗәләр бирә.
Май ахырында ана кортлар бишекләреннән чыга башлый. Бу инде табыш. Инде колхоз кассасына акча килә башлый. Суык чорда, әле бал җыелмый торган дәвердә. Бер йөз яшь ана корт, яки корт анасы Архиповларның үз умарталыгында калган. Бер йөз яңа умарта, яңа корт иле булачак дигән сүз! Бал җыясы көннәр килеп җиткәндә, ул корт күчләре инде буын ныгытып өлгерәләр, аларны йә бал җыйдыртырга, йә сатып җибәрергә була, колхоз моңардан табышын арттыра. Июнь башында Архиповлар умарталыгыннан колхоз кассасына 4080 сум акча кергән. Андый табышны алу өчен дәүләткә бер тонна бал тапшырырга кирәк. Бер тонна бал — бер умарталыкның уртача бер еллык табышы.
Корт аналарын үстерүдә ун-унбиш умарта эшләгән, калганнарын бал җыюга әзерләгәннәр. Икенче табыш — 6950 сумны Архиповлар умарталыгы бер йөз яшь күч сатудан алганнар, боларны инде яшь ана үстергән. Һәр яшь күч колхозга 70 сум табыш китергән. Көзгә кергәндә умарталардан 665 килограмм бал суыртканнар, 98 килограмм баланы эретеп куйганнар. Ел азагында бухгалтериядә Архипов белән Якимовның хезмәт хаклары 5763 сум 46 тиен чыга. Рәхим итеп алыгыз!
— Умартачы акчаны үзе таба, — диде миңа «Таң» колхозы рәисе Зәйнулла Һадиуллин. — Бал кортларын эшләтә белү кирәк!

Колхозда чәчүлек җирләре күп түгеллеген әйткән идем инде: биш мең гектарлап. Шөгыльләре — иген игү, ит, сөт җитештерү, бәрәңге, бал җыю. Сөреп ташланган җирләрдән тыш колхоз кырларында беркадәрле дәүләт урманы торып калган. Әнә шул урман кишәрлекләренең кояшлы аланнарында колхоз үзенең алты умарталыгын тота. 900 баш умарта!

Газета хәбәрчесе булып күп җиргә барып чыкканым бар. Барысыннан да бигрәк минем исемдә «Таң» колхозы умарталыгы торып калды. Урманнары — катнаш урман: каен, юкә, имән аралашып үсә. Әмма аеруча истә калганы — кешеләре. Эшне яратып, җаваплылык тоеп башкаручылар. Себер якларыннан бер мисал китерим. Красноярск краеның Балахтин районында «Кипрейный» дигән махсус умартачылык бар. Унберенче бишьеллыкта 3 мең баш умартадан 1063 яшь корт күче сатканнар. Ә бит безнең «Таң» колхозы умартачылары ике ел эчендә шуның хәтле корт күче сатып, 25 мең сум табыш алдылар. «Таң» колхозында бер умарта 50 сум табыш китерә, «Кипрейный»да — 2 сум 50 тиен. Ә күпме хуҗалыклар умартачылыктан бер тиен дә табыш ала алмыйча интегә. Димәк, тырышмыйлар, эшли белмиләр, эшләргә теләмиләр.

* * *

Һадиуллин белән бал җыю мәсьәләсендә әңгәмә корып, бәхәс ачып җибәрдек. Нык холыклы, тапкыр, уйлап эш итә торган бу җитәкче — дәүләттән алган бурычлар исәбенә яши торган кеше түгел. Хуҗалыкны ул эшнең үз исәбенә алып бара. Бал кортларын да ярата ул, дөресрәге — аңлый, аларга ихтирам белән карый. Бригадир чагында үзе дә берничә баш умарта тоткан, файдасын да күргән, җанына ләззәт тә алган.

Мамадыш корт карауччыларының даны бөтен илгә билгеле. «Пчеловодство» журналы да, Мамадыш умартачыларының хезмәтенә багышлап зур мәкалә бастырып чыгарды. Райондагы ун мең баш умартадан ел саен биш мең күч үстереп сатуларын да яздылар анда. Менә шуннан соң Вятка белән Кама суы кушылган якларга хатлар ява башлады. Эш тәҗрибәсе белән уртаклашуны, бал кортларының холыкларын өйрәтүне, салкын якларда яши торган эшче кортлар җибәрүне үтенеп сорыйлар.

Һадиуллин минем алга кочагы белән хат чыгарып салды. Без аларны икәүләп укырга тотындык. Дөресрәге мин укыдым, Һадиуллин аңлатма биреп барды. Менә Себердән килгән хат:

«Красноярск шәһәренең Умартачылар җәмгыяте Сездән үтенеп сорый: 10—15 данә яңа корт күче, шул ук күләмдә корт аналары җибәрә алмассызмы?»

— Карале син боларны! Себердә умартачылыкны нинди хәлгә калдырганнар. Берничә корт анасы, яки яңа күч алыр өчен җир читенә барырга әзерләр. Тайгада нинди генә чәчәк юк — берни майтара алмыйлар.

«Сездән корт аналарын 1988 елның июнендә сатып алырга мөмкинме? А. Попов, Оса шәһәре, Пермь өлкәсе».

— Мөмкин. Ай башында килсәләр, алырлар.

«Хөрмәтле колхоз рәисе! Базарда бездә бал бик начар, әллә нәрсәләр кушып саталар, кибетләрдә — юк. Сезгә 55 сум акча җибәрдек, мөмкин булса, бал озатыгыз әле!

Ю. Дрягина, пенсионер, Майкоп шәһәре, Краснодар крае».

— Көньякта бал булмасын инде, ә? Ышануы кыен. Сыйфаты хакында әйтелгән сүз дә сәер. Имеш-мимешләргә таянып язалар. Нинди генә бәлаләр якмыйлар умартачыларга? Әйтик, берсе шикәр сиробы өсти, шуңа кушып, барлык умартачыларны гаепліләр.

«Зинһар, сүземне тыңлап бер оя бал корты җибәрегез. 75 сум акчаны сезгә кайчан салыйм? В. Заяц, Мәскәү шәһәре».

— Бу кеше, мөгаен, дилетанттыр, төннәрен бал елгаларын төшендә күреп ята торгандыр. Беренчедән, бер оядан түгел, ике оядан башларга кирәк, алар бер-берсенә ярдәм итәләр, икенчедән, бер күчнең 75 сум торганына инде — ун ел».

«Минем биш баш умартам бар, бал ала алганым юк. Шунлыктан мин корт анасы алырга булдым, һич югы — 3 данә. Бәясен әйтеп, инструктаж биреп, хат язсагыз иде.

Д. Гаджиев, Дагестан».

— Сатарбыз. Ләкин ул Гаджиевның балы барыбер булмаячак, ник дисәң, бал умартачының үзенә бәйле...

...Хатларның кызыклы бер ягы бар: алар бал дөньясындагы проблемаларның, хәл ителмәгән мәсьәләләрнең күп булуын ачыклап тора.

Бал белән балавыз — Рәсәй экспортының күптәнге малы. Чит илләр белән бу өлкәдәге сәүдә безнең өчен һәркайчан файдалы, мәгънәле булган. Умартаны һәр гаилә асрый алмаган, чөнки җитди эш, акыл таләп итә торган авыр эш ул. Шулай да илдә булган барлык умарталарны бүлеп карасаң, һәр крестьян гаиләсенә бер умарта туры килгән.

Хәзер кимрәк, бал да кыйммәт, балга булган ихтыяҗ да нык артты. Бу урында Һадиуллинны тыңлап карыйк:

— Тормыш логикасыз була алмый, — ди ул. — Умарталар илдә азая төшсә дә, татлы ризык җитәрлек. Бал кортларын хәзер кырларда шикәр чөгендере алмаштыра. Россия Федерациясендә генә дә аны 30 миллион тонна үстерәләр: елга бер кешегә 50 кило-

грамм татлы азык туры килә. Әгәр кумешкә куучылар булмаса, илдә татлы азык җитәр иде...

Әмма шикәр белән бал — бер түгел, җир белән күк арасы. Шикәр бирән авыруына китерә, диабет бугаздан ала, аңардан илдә өч миллион кеше җәфа чигә, авырулар саны ел саен 8—10 процент үсәлә тора. Дөрес, бу, Америкага караганда, кимрәк, анда диабет белән 20 миллион кеше чирле. Ләкин ул статистика гына безгә тынычланырга ирек бирми.

Бал кирәк. Бал кими. Сугыштан соң кырык елдан артык вакыт узды, илебез әле сугышка кадәрге балны җыя алганы юк. Умарта кортларын кәрәз, агу, прополис, чәчәк серкәсе, сөтлегән алу өчен, барыннан да бигрәк бакчалар җимеш бирсен, болыннарда печән үссен өчен дә, димәк, илдә сөт һәм ит күп булсын өчен дә үрчетәләр. Менә сезгә бер сан: бер корт көче елына... 40 тонна сөт бирә. Әйе, әйе.

Латвиядә рәсми мәгълүматлар шуны әйтеп тора: бер умарта 40 тонна сөт бирә. Ничек?

Әгәр умарталар җәй буе урман аланында гына торсалар, ул чагында файда урманга гына килә. Әгәр умарталарны клеверга алып чыксаң, люцернага, башкаларга — бер умарта көче 70 килограмм орлык җитештерә. Ул орлык 10 гектарлы болынга чәчәргә җитә, ун гектар болын 10 сыерны туйдыра ала, ә Латвиядә бер сыер елына дүрт мең литр сөт бирә. Табигатьтә бар нәрсә дә бер-берсенә бәйле. Бал корты — ул орлык: орлык, болын — ул, болыннан терлек азыгы алына, ул сыердан сөт савыла.

Умартачылык — чын мәгънәсендәге дару фабригы да әле ул. Чәчәк серкәсе генә дә ни тора! Татарстанда, бик тырышсаң, ел саен 250 тонна чәчәк серкәсе җыярга, аны бал белән бергә кушарга, дару таблеткалары ясарга, кондитер фабригында шифалы ризыклар чыгарырга була. Миллион сумнар файда килечәк моннан, ләкин кондитерлар да, кооператорлар да, гомумән, Дәүләт агропромы да моның белән шөгыльләнергә теләмиләр, умарталыкларда чәчәк серкәсен ташлыйлар. Рамнарны гына боза ул, бал җыярга комачаулый, диләр.

«Таң» колхозы рәисе Һадиуллин:

— Безнең колхозның бал кортлары, бер умартага 25 килограммнан исәпләсәң, елына 20 тонна «корт икмәге» алып кайта. Әгәр шуның уннан бер өлешен генә сатсаң да, өстәмә 50 мең сум табыш алып булыр иде, ләкин аны алучы бармыни?— дип офтанып сөйли.

Умартачылыктагы мондый бәлаләрдән котылу өчен балга һәм чәчәк серкәсенә дәүләт заказы биру практикасын үзгәртү дә кирәктер. Умарта тоткан колхоз-совхозларга заказ бирәләр, тотмаганнарына — бирмиләр. Нәрсәгә нигезләнеп эшләнә бу — аңлау кыен. Башкортстан белән Татарстан — күршеләр, урман-кырлардагы нектар запасы да, умарталыклардагы кортлар көче дә бер ук түгел, заказ исә — икесенә бер — 600 тонна. Умарталыкларның түгел, бакчаларның, болыннарның, урманнарның, иген кырларының бал биру мөмкинлеген исәпләп чыгарырга кирәк. Әгәр кырда кара бодай бар икән, аның һәр гектары 70 килограмм бал бирә ала, юкә урманының һәр гектары бер тонна нектар бүлеп чыгара.

Инде махсус хуҗалыклар төзегән булып, бал кортларының башын әйләндерә башладылар. 350 махсус хуҗалык бал кортлары көчен арттырмады, ә бу эшкә зыянын салды. Соңгы ун елда Татарстанда умарталар саны 34 меңгә кимеде. Бал җитештерү буенча дан алган Башкортстанның да дәрәҗәсе төште, ә бит ул — нинди медальләр хуҗасы! Анда хәзер 200 дән артык колхоз һәм совхозның умарталыклары юк. Күңелсезрәк хәл шул: баллы Башкортстандагы колхозлар алдынгы механизаторларын, савымчыларын, сабый балаларын бал белән сыйлый алмый.

Һадиуллин әйтә:

— Колхозда умартачылык булмаса, колхозчылар да умарта асраудан туктый, алар бер-берсенә нык бәйләнгән,— ди.— Безнең колхоздагы 900 баш умартага нәреп, колхоз агайлары да бал корты асрый, йорт саен — бер ярым умарта.

Узган елны икмәк уңмады, бәрәңге дә әлләни кинәндермәде. Утыз биш ел колхозны җитәкләү дәверендә бик кыен хәлдә торып калдым. Банкка барырга микәнни инде, кул сузып, теләнеп барыргамы? Ояг, биллаһи! Менә шунда бөтен колхозны умартачылар коткарды: алты умарталык 111 мең сум табыш китерде!

«Таң» колхозының эш нәтиҗәләрен күршедәге «Яңалык» колхозы умартачыларының эш нәтиҗәләре белән чагыштырам. «Таң» колхозы умартачылары да тырышлар, әмма алар «Яңалык» колхозы умарталыгын алып баручы Татьяна Казаковадан калышалар. Анда узган елны Рәсәй семинары уздырдылар. Белгечләрне Татьяна Казакова умарталыгына алып киделәр. Ул 150 баш умарта карый. Бер җәйдә ул 250 яңа күч сата, бер тонна бал суыртa, 3 мең данә корт анасы үстерә. Колхозга шул 150 умартадан 25 мең сум саф табыш бирә, үзе айга 850 сум акча ала. Академик хәтле! «Яңалык» зур колхоз түгел, барлыгы бер миллион 200 мең сумлык продукция җитештерә, шуның 250 меңен 800 баш умарта бирә, һәр умартадан 236 сум.

А в т о р. Бал бик татлы ризык булса да, бездәге колхоз-совхозларның яртысы умарта асрамый, бәлки моның объектив сәбәпләре бардыр?

Һ а д и у л л и н. Барысы да эшне оештыра белүгә бәйле. Табигать никадәрле нектар бүлеп утыра! Ә умарталыкларны махсус хуҗалыкларга тапшыралар, варроатоздан зарла-

напар, иң ансаты — бал җыю планыннан азат итәләр. Ичмасам, аерым хуҗалыкларда үрчетсеннәр умарталарны?..

Автор. Крестьянга дәүләт заказы төшерә алмыйсың бит?!

Һадиуллин. Шәхси хуҗалыктагы умартачыларга бал тапшыруны мәҗбүри куймаска, аны кызыксындырырга кирәк. Корт асраучыларга мөнәсәбәтне үзгәртү мөһим. Аларга ихтирам белән карарга иде? Илдәге балның дүрттән өчен һәвәскәр умартачылар бирә.

Бакчачыларга, игенчеләргә, яшелчә үстерүчеләргә килгән табыш, бал җыючыларга караганда, 140 мәртәбә артыграк. Кушма Штатларда умартачыларның табышы 40 миллион доллар, ә фермерларныкы — 6 миллиард! Умартачыларның бал мичкәсенә көнләшеп караганчы, бу өлкәгә игътибар итмичә, нихәтле табышны югалтканыбызны санап карарга иде! Әйтик, берәү бал корты асрый икән, нигә аңа түләмәскә?! Агачларны, җиләк-җимеш түтәлләрен, кыярларны серкәләндерүче бал кортлары ничәмә-ничә чакрым җиргә хезмәт күрсәтәләр ич?!

Бал кортлары үрчетү хакында Дәүләт законы кабул итү кирәк. Бөтен дәүләт өчен бер көчле фәрман бу тармакны һәр яклап үстерү чараларын күздә тотарга, умартачылыктан алынган барлык байлыкны дөрес файдалану, һәвәскәрләргә түләү тәртипләрен булдыру, умартачылыкны бетергән өчен җәза бирү чараларын эшләргә кирәк. Шәһәр халкын да бу файдалы эшкә тартырга вакыт. Өстәмә түләүләр законлаштырылса, бухгалтерлар акчага ябышып ятмаса, һәвәскәр умартачылык бик тиз алга китәр.

* * *

1987 елны Красноярск краеның «Нагорновский» совхозында булдым. Зур хуҗалык икән бу! Фермаларында — 1250 баш сыер, 13 мең гектар чәчүлек җире бар. Моңардан тыш сөрелми яткан тагын җиде мең гектар — болыннар, көтүлекләр, тайга иркенлеге — рәхәтләнсен бал кортлары! Бер люцерна гына да биредә 500 гектар чәчелә. Үләнне яңарту өчен орлыгы кирәк, чәчкәне серкәләндермичә орлык алып булмый. Әмма совхоз директоры Николай Игнатенко безне таң калдырды:

— Умартачылыкны бетердек,— ди.

— Сатасызмыни?

— Алучы табылса, сатабыз.

— Ник?

— Аларны асраудан ни мәгънә? Бал бирмиләр, чүннеккә кисәң, чагалар.

Аңлашылды. «Нагорновский» совхозының элекке умартачысы Сергей Пастухов белән без күршедәге «Белоярский» совхозында очраштык. Пастухов яшь әле, армиядән күптән түгел генә кайткан, күрә — умартачылык беткән. Корт оялары кабат тергезергә мөмкин, әлбәттә, пакин җитәкчелек каршы килмәгән очракта гына. Бу юлы алай булып чыкмаган шул...

Әйтергә кирәк, «Белоярский» совхозында да бал кортлары әллә ни дәрәҗәле булмаган, бал сатуның җиде — нибары җиде! — центнер планын да үтәмәгәннәр. Бәхеткә, «Белоярский» совхозына яңа директор килә — Николай Михайлович Яушев. Элекке директордан аермалы буларак — хуҗалык эшендә моның үз принциплары. Яшь умартачы Пастуховны ул якты чырай белән каршылый, механизаторлар, терлекчеләр белән бер рәттән аңа яңа коттедж бирдертә, бердәнбер таләбе шул — умартачылыктагы тәртипсезлекләрне бетерергә, бал сату планын үтәп кенә калмаска, эшчеләргә дә өлеш чыгарып, аларны да куандырырга.

Пастухов җиң сызганып керешә эшкә. Бал корты асраучыларның кануннарына капма-каршы килеп диярлек, яз җиткәнне көтмәс борын ук корт иле сатып ала, байтак ала ул аны. Әйбәт китә эше Пастуховның. Совхоз бал тапшыру планын да үти, эшчеләргә дә бал кала.

Без Пастуховны тайга уртасындагы чүннектән эзләп таптык.

Ул бал кортларын кышлауга кую хәстәре белән йөри иде. Узган атнада умарталар күчмә урыннарыннан кайтканнар — күченеп йөрү тайга умарталыклары өчен сирәк хәл — кортлар ай буе донник үләнендә көн күргәннәр, балны, шөкер, әйбәт җыйганнар, совхоз икенче елын рәттән бал сату планын үтәп чыккан. Пастухов язга дип калдырган пичәтләнгән авыр рамнарны күрсәтте безгә:

— Умартада азык булса, корт көче булыр, корт көче булса, балы да булыр.

— Ә варроатоз? Ул зәхмәттән курыкмыйсызмы?

— Ә-ә-ә, Якобсон талпанын әйтәсездер? Дөнья гизеп йөри Һорган талпанны. Әгәр вакытын уздырып җибәрмәсәң, талпан куркыныч түгел.

Пастухов безне аллы-гөлле төсләргә бизәлгән умарталар арасыннан алып бара. Аннары ул безгә битлекләр кидерде, бер умартаның капкачын ачты. Киндер капчык астында без утыз тиенлек пластмасса сабын савыты күрдек, аның капкачына ике яктан тишек тишелгән иде.

— Кырык-илле грамм кырмыска кислотасы — явыз талпанга каршы көрәшнең чарасы менә шул гына,— дип аңлатты безгә Пастухов, сабын савытын ача-ача.— Бал җыйганнан соң, кәрәздәге күзәнәкләрдән бала кортлар чыгып беткәч, һәрбер ояга ике атнага шу-

шы кислотаны куеп чыгам. Бер мәртәбә күзен, икенчесендә язын... Менә шуның белән варроатозның, ягъни талпанның кәне бетә.

Красноярск краенда мин үзем өчен бер ачыш ясадым: бал кортларына мөнәсәбәт аркылы авыл хуҗалыгы алга киткәнме, әллә туктап калганмы икәнне билгеләп була. Әнә Нагорновский совхозында директор умартачылыкка каршы төшкән, башка тармакларны күтәргән дип уйлыйсызмы? Бал корты төгәллек, җаваплылык, белеп эшләүне таләп итә. Умартачылыкка кыек караган директорның башка тармакларында да тәртип юк, кешеләр эшкә эленке-салынкы йөриләр, ата ялкауга әйләнәләр.

Красноярский крае бик зур. Мин «Кипрейный» совхозын сайлап алдым. «Кипрейный» крайның төньяк-көнбатышында, Красноярский краеның Кемерово, Томск өлкәләре белән кисешкән урынында. Тюхтет, Енисей, Боготол, Пиров районнары...— болар төбәктәге балның биштән дүрт өлешен җыеп бирәләр.

«Кипрейный» бал совхозын 1965 елны оештырганнар. Зәңгәр дулкын булып җәелеп яткан үзәнлекләр кызыктырган җитәкчеләрне. «Концентрация», «специализация» дигән яңалыклар кертелгән заманда, тирә-юньдәге колхоз-совхозлардан умарталарны җыеп алып, гигант махсус хуҗалык оештырганнар. Вакыт күп узган, умартачылык эше барып чыкмаган, чөнки бал алу технологиясен оештыра алмаганнар, кырларда тулышып торган нектар шул килеш калган, люцерна, эспарцет, клевер һәм карабодай кырларына, шау чәчәкле басуларга умарталарны күчереп куярга кәчләреннән килмәгән, иренгәннәр, умартачылык алга китмәгән. Гигант хуҗалык кәч-хәл белән сулыш ала. Умарталарны күчереп йөртү үз җаена куелган, мең ярым умарта җәй буе бер урында тора. Кырларны серкәләндергән өчен, уңышны күтәргән өчен өстәмә түләү хакында колхоз-совхозлар белән килешү юк.

Красноярский крае илдә элек-электән бал җитештерүче иң күркәм як саналып килде. Беренче умартачы Социалистик Хезмәт Герое Дембо шушыннан чыккан кеше иң. Умартачылар җыенында бу якның осталары йөзләгән төрен күргәзмәгә куялар иде балның. Кая киткән соң алар? Базарда хәзер боларның үз балы юк. Мәсхәрә! Менә гамьсезлек, битарафлык, ялкаулык нинди хәлләргә китереп җиткерә!

Мин шундый ук диагнозны «Кипрейный» совхозы җитәкчеләренә һәм умарта караучыларына куяр идем. Умарта яратучылар Көнчыгыш Себердән Идел буйларына корт күче алырга барырга ниятләнеп йөриләр, ә белгечләре йоклый, белгечләрен уятасы бар. «Кипрейный» совхозында, мәсәлән, өч мең умарта, шундый зур умарталыктан читкә нибары 200 корт күче бүлеп саталар, унбиш умартадан бер күч дигән сүз иң уп. Аз шул, бик аз!

Архипов умарталыгында язын үткәргән көннәремне искә төшерәм, Вятка-Кама буйларын. Анда бит ел саен умарталарны икеләтә арттыралар, корт үрчетү өчен меңәр корт анасы үстерәләр. «Яңалык»тагы Татьяна Казакова 150 баш умартадан ел саен 300 корт күче үрчетә.

Ә мин йөргән Себер киңлекләрендә, табигатьнең муллыгы ташып торган урманнарда һәм болыннарда, бал кортлары өчен табигать әзерләп биргән оҗмахта гамьсезлек, битарафлык тамыр җибәргән.

* * *

Илнең төрле төбәкләрендә бал җитештерү буенча 350 махсус хуҗалык бар. Алар 1988 елны илгә 78 мең тонна бал бирде, аны 300 миллион кешегә бүлсәң, берәр стакан тия. Кенгә бер грамм!

1988 елны Казанда үткәрелгән РСФСР семинарында мондый саннар әйтелде: Россия авылларында умарталар нибарысы 3 миллион 700 мең оя калган. Воронеж, Башкортстан, Пенза, Ярославль, Брянск — менә кемнәр киметкән умарталарны. Блокнотымнан эзләп таптым: сиксәненче елларда Россия колхозларында һәм совхозларында 2 миллион 900 мең умарта калган. Вакыт бара тора, умарталар кими тора.

* * *

Бер мәлне мин бал корты кунган чәчәк өстенә иелдем. Зурайткыч пыяла аша караган идем, гаҗәеп бер күренешкә тап булдым. Бал корты чәчәктән нектар суырып алган чагында икенче бер эшне дә башкара икән: канатларын туктаусыз җилпеп тора, әнә шул канат җилпүдән чәчәк серкәләре очып һавага күтәрелә һәм аларны җил бакча буйлап алып китә икән. Бер чәчәк миллион, миллиард серкә бирә, ә бал корты, секундның күпмедер бер өлешендә, үзенең бал савытын тутырган арада, чәчәк тузаны эчендә кала. Бал кортын көчле канатлары алтмыш чакрым тизлектә очырткан чагында, серкә болыты тарала, җил белән тирә-юньгә очып китеп, бакча чәчәкләрен серкәләндерә. Серкәнең һәммәсе дә очып бетми, бал кортының йонтас тәненә ияреп кала, ә корт аларны арткы аякпары белән тәненнән алып, махсус кәрзиненә тутыра, татлы нектарны һәм серкәне умартага — балаларына азыкка да алып кайта.

Табигатьтә әнә шулай бал корты белән чәчәкнең берлеге барлыкка килә. Бал кортлары булган җирдә бакчалар 40—50 процентка артыграк уңыш бирәләр, чиянең уңышы бермә-бер арта, карабодай басуының һәр гектарыннан 2—3 центнер артыграк уңыш җыеп алына. Люцерна орлыгы бер центнерга арта, ә базарда аның бәясе 3 мең сум тора. Кыскасы, агрономнар белән умартачыларның мөнәсәбәтен тикшереп караганым булды, ә ул мөгамәлә чәчәк белән бал корты мөгамәләсеннән нык аерыла шул. Кызганыч! Табигатьтә ныклы берлек, бер-берсен аңлау; умартачылар белән агрономнарда — киресенчә. Бердәмлек тә, дуслык та юк. Алар, халыкча әйткәндә, этле-мәчеле яшиләр.

Бал кортларын акыллы җәмгыятьтә бал җыюдан бигрәк уңыш алу өчен үрчетәләр бит. Латвиянең умартачылык буенча зоотехнигы Лилия Бражинская миңа әйтте: бездә корт караучылар бал җыюда әлләни куандыра алмыйлар, ә менә сөтне, майны, иңдәге иң яхшы сырны, каймакны арттыруда аларның өлешләре зур,— диде ул.

— Ничек?— дидем мин гаҗәпләнеп.

— Балтик буенда кояшлы көннәргә караганда болытлы көннәр күбрәк. Бу исә бал җыюны кыенлаштыра... Әмма безнең бал кортлары һәр умартага... 40 тонна сөт бирә.

— Сөт савымчыларга, көтүчеләргә, зоотехникларга кирәк, ә умартачыларга аннан ни файда? Клеверның балы аз була, андый кырга умарталарны күчерүнең ни кызыгы бар?— дим.

— Умарталар бит бушлай күчерелми. Клеверны серкәләндергән өчен умарта башына — 60 сум. Аның чаклы акча алыр өчен дәүләткә 20 килограмм бал тапшырырга кирәк, ул хәтле балны бер умарта ике елда гына бирә ала. Балдан табыш биш йөз мең сум булса, серкәләндерүдән, чәчәк серкәсен сатудан, сөтлегәннән умартачылык өлкәсенә бер миллион ярым өстәмә табыш килә.

Серкәләндергән өчен түләү — умартачыларны япкаулыктан коткара, аларны чын мәгънәсендәге инициативалы, булдыклы корт караучыларга әйләндерә. Бу хәзер эксперимент түгел, агрономнар белән умартачыларның эшлекле мөнәсәбәтләре, үзара килешеп эшләүләре.

Умарта караучыга умартасын арендага алган өчен 60 сум түләү — ул инде акча, ә 70 килограмм клевер орлыгы (центнеры 3 мең сумнан), 40 тонна сөт — дотациядән тыш 15 мең сум, ә ул акча түгелмени?!

Болай эшләгәндә, ике як та ота. Клевердан тыш бал кортларын график белән бакчаларда, люцернада, көнбагышта, рапста эшләтергә мөмкин, серкәләндергән өчен аларның һәркайсына аерым түләү карапган, кычкыртып тапау түгел, махсус прейскурант белән. Эшне шулай оештырган сурәттә умартачылык үзен-үзе аклый, өстәвенә — бал да җыела бит әле.

Шундый ук аңлашып эшләүне, бик сирәк булса да, үзебезнең Татарстанда да күргәнем бар. Чүпрәле районының Бауман исемендәге колхозында. Бер як басуда ак күбеккә баткан карабодай кырлары, икенче якта зәңгәр дулкын кагып утырган люцерна басулары, урталыкта шахмат тәртибендә урнаштырылган йөз баш умарта, умарталар арасында дүрт умартачы йөри, һәвәскәрләр икән. Бу хәл мине кызыксындырып җибәрде. Бардым яннарына, белештем. Умарталар күрше Ульяновск өлкәсеннән күчкән булып чыктылар. Ничек? Колхоз рәисе Рәмил Хисматов, күрәсең, булдыклы, акыллы кеше, исәпли белә торган, Ульяновскига умартачы энтузиастлар янына барган, чакырган. Күченеп килгән умартачыларга торыр өчен вагон, газ плитәсе биргәннәр, азык белән тәэмин иткәннәр, колхоз ашханәсенә беркеткәннәр. Яши һәм эшли бирегез! 6 июньнән башлап канатлы агротехниклар басуларның уңышын күтәрәләр.

Икенче мисал да үзебезнең Татарстаннан, Буа районының «Искра» колхозыннан. Әлеге колхоз зур, ил һәм дөнья күләмендә атаклы. Аны атаклы иткән нәрсә — карабодай. Башка агрономнар карабодайны бик өнәп бетермиләр, мәшәкате күп, янәсе, файдасы әлләни түгел. «Искра» колхозы рәисе, СССР халык депутаты, Югары Совет әгъзасы Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов карабодай мәсьәләсендә башкачарак фикердә. Соңгы унбиш ел эчендә әлеге колхоз карабодайдан 17 шәр центнер уңыш ала. «Искра» колхозында мин еш булам, карабодай чәчәк аткан чакка туры килсәм, аеруча сөенәм. Без Мөхәммәтҗанов белән уй-фикерләребезне уртага салып сөйләшә алабыз. Бервакыт мин әйттем аңа: «Карале, Мөхәррәм туган, карабодай басуыңның бу башына да бер йөз умарта куясыңмы?» — дидем. Мөхәммәтҗановның минем сүзгә әлләни исе китмәде: карабодай басуының икенче башына кортлар авылдан киләләр, дип сүзен бетерде. Мин каршы төштем. «Авыл ерак, өч чакрымнан ары булса, бал корты анда бармый, ник дисәң, кире әйләнеп кайткан чакта ул алган нектар «яныпп» бетә».

Ләкин минем киңәш рәис күңелендә яклау тапмады. Шулай да көзен карабодайны ике алым белән суктырдылар. Ерак почмагыннан — 12 центнер (карабодай өчен бу табигый уңыш!), ә кортлар эшкәрткән ягыннан 32 центнер чыккан. Карабодайның бер центнерын дәүләт 90 сумга ала. Һәр гектардан күпме артык акча алына дигән сүз?! 800 сум. Бал корты әнә нәрсәләр булдыра!

Кайберәүләр арифметиканы саннар дип кенә карый, Мөхәммәтҗанов өчен арифметика — төгәл исәпләү чыганагы. Икенче бер килүемдә ул мине карабодай басуының аргы башына алып барды. Тәки китергән бит умарталарны, Ульяновск өлкәсеннән, аерым

хуҗалыклардагы умарталарны китергән. Умартачыларга — бал, умарта башына ун сум акчалата, ә колхозга мул уңыш!

Укучыда сорау туы мөмкин: колхоз кассасы шундый акча чыгымнарына ничек түзә икән соң? Умарта башына кырда чакта акчалата ун сум, өстәвенә әле кышларга калдыру да колхоз исәбенә эшләнелә. «Искра» моңардан бөлеп бетмәсме? Колхоз ел саен бер миллион чамасы табыш ала. Карабодайдан гына түгел — иттән, сөттән, икмәктән. Табигатьнең файдалы якларын күрә белгәнгә, аңардан хуҗаларча файдалана белгәнгә табыш ала «Искра» колхозы.

Уңышны мул итеп җыеп алуда бал кортларын кыш көне дә файдаланып була. Бу юлы мисалны Казан янындагы «Майский» совхозыннан алырбыз. 44 гектарлы яшелчә теплицасына өлеге совхоз 900 умарта һәм 12 умартачы тота. Гадәттә умарталарны урман аланында асрыйлар, теплица кызлары әйткәч, аларны бирегә китерәләр. Яшелчә үстерүчеләр корт караучыларның теплицага «ялкау» кортларны китермәүләрен таләп итәләр. Бал кортларының ялкау түгеллеге җыелган уңышка карап билгеләнә. Теплицага куелган һәр умарта өчен корт караучыларга 40 сум күчерелә. Шуның өстәвенә — күпме бал да, күпме балавыз! Умартачылар хәлсез умарта китермәсен, кортлар ялкауланмасын, бер генә чәчәк тә кысыр калмасын өчен кыярның центнеры саен умартачыларга янә дә 64 тиен акча каралган.

Умартачыларның көндәлек чыгымнары: эш коралы, эш киеме, шикәр, аксым азыгы,— барысы да бал кортлары «тапкан» шушы акчадан тотыла. Теплицаларда нектар аз, эшче кортлар бик тиз хәлсезләнә, шунлыктан умартачылар яңа корт күчләре сатып алырга да мәҗбүрләр, бер күч 250—300 сум тора. Шулай булгач, хуҗалык исәбе кызык өчен генә кертелми, аны тормыш үзе таләп итә. Әгәр умартачыларны эшләп алган табыш канәгатьләндерә икән, алар шуңа яши алалар икән,— бу эш алар өчен файдалы, чөнки кергән акча чыгымнарга тотылып бетмәсә, артыгы хезмәт хакы булып кала. Мәсәлән, сигезенче цех умартачылары Илдус Хөсәенов белән Мөнир Китаевка кортлары бал җыйган өчен 25 мең сум язганнар. Барлык чыгымнарны исәпләгәч, авансттан тыш, умартачылар 5807 сум акча алдылар.

— Кортлар ялкауланмасын өчен корт караучының ифрат тырыш булуы кирәк,— ди совхоз умартачыларының бригадир-арендаторы Анатолий Каменщиков.— Умартачы продукцияне күбрәк алырга, акчаны азрак туздырырга тиеш. Кышын эш шактый авыр: кортлар бик сизгер алар, кояш җылытмый, теплицаларда ясалма яктылык, өстәмә азык бирергә туры килә. Әгәр умарта күче хәлсезләнә икән, хәлсезләрен алып, көчлерәкләрен китерәбез. Яңа корт күче сатып алу — акча күбрәк шуңа китә, бер елга 50 мең сум акча тотыла аңа. Элеккерәк елларны читтән өчәр йөз корт күче алырга туры килә иде, хәзер үзебез үрчетәбез...

— 1989 елны 44 гектарлык теплицадан 12 мең 600 тонна яшелчә саттык,— ди «Майский» совхозы директоры Ипшат Ганиев.— Кыярны шундый күп үстердек, хәтта кибетләрдә алмый башладылар, хәзер помидор үстерүне арттырдык. Табышны 5 миллион сумлык итеп планлаштырдык, ә 2 миллионга артыграк алдык. Бюджет белән исәп-хисапны өздек, башка түләүләрне дә бетердек, 4 миллион сум үзебезгә калды. Теплицаларны зурайтабыз, кабак икрасы ясау буенча технология булдырабыз. 900 мең сум — торак төзелешенә, 200 мең сум мәктәп салырга тотылачак...

Нәтиҗә ясап карыйк: уңыш үстерүнең серләре химия белән генә бәйләнмәгән, агрономнар үсемлекләргә агулы нитрат тутыра торган ашламаларны бал кортлары бик әйбәт алыштыра ала.

* * *

Бал кортлары җыйган чәчәк серкәләре (халыкта аны «корт ипие» дип тә йөртәләр) кеше сәламәтлеген ныгытуда шулай ук бик файдалы. Латвиядә, мәсәлән, чәчәк серкәсен кабул итү өчен махсус кибетләр ачылган. Хакы нык.лы — килограммына 20 сум.

Кортлар андый серкәне язын ук җыя башлый. Аны кәрәз күзәнәкләренең төбенә сала да, өстен бал белән күмеп куя? Чәчәк серкәсе булмаса, корт күче үсми, бетә. Менә шул хәлләрне өйрәнеп, тикшереп яши торгач, чәчәк серкәсенең серләре ачыла башлаган. Бу бөртекләрдә менә нәрсәләр барлыгы билгеле: аскорбин кислотасы, аневрин, рибофлавин, пиридоксин, биотин, каротин, кальциферол, токоферол, рутин. Аннары азыкны эшкәртергә ярдәм итә торган ферментлар китә. Чәчәк серкәсендә галимнәр махсус матдәләр, мәсәлән, хатын-кызлар гормоны эстрон барлыгын ачтылар. Болардан тыш чәчәк серкәсендә магний, калий, бакыр, кремний, фосфор, күкерт, хлор, титан, марганец, барий, көмеш, алтын, палладий, вольфрам, кадмий, стронций бар. Медиклар әле шушы көнгә тикле бу серле серкәләрнең кеше организмына нинди йогынты ясавын ачыклап бетерә алмыйлар, әмма файдасының барлыгы инде исбат ителде.

Белгечләр бер умартадан биш кило чәчәк серкәсе алырга мөмкин дип исәплиләр. Латвиядә чәчәк серкәсен киптерәләр, ваклыйлар, уалар, банкаларга тутыралар, пакетларга, таблетка итәләр, брикет ясыйлар. Тартмаларда, капчыкларда күпләп сатып алучыларга — колхоз-совхозларга, кондитерларга, парфюмерларга, фармацевтика фабрикаларына озаталар.

Кызганыч ки, Латвиядәге хәлне башка республикаларда очратырга туры килмәде. Казанның атаклы «Заря» кондитер берләшмәсе генераль директоры Зураб Ильяс улы Хабулавадан сорадым: нишләп, мин әйтәм, татлы ризыкларыгызга шифалы нәрсәләр салмыйсыз? «Андый хәлләрне минем ишеткәнем юк, чәчәк серкәсен үз гомеремдә күргәнем дә булмады»,— дип җавап бирде Хабулава.

Тиргәнә-тиргәнә арып беткәч, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск, Алабуга кебек кыяр-помидор белән тәэмин итүче «Весенний» совхозын ягымлы сүзләр белән искә аласы килә. Бу совхозның утыз гектарлы теплицасында кыяр февраль аенда ук өлгерә, аннары помидор кызарып пешә, укроп, селдерей, салат яшелләнеп балкып утыра. Барлыгы утыз гектарлык биредәге теплица, ә уңышны ул шундый да күп бирә, кая куярга белми аптырый башлыйлар.

— Кышын үстергән яшелчәләр һәм витаминлы үләннәр бик күп көч таләп итә,— ди совхоз директоры Равил Нәҗметдинов.— Һәр квадрат метрдан без 32 кило азык алабыз, ә Диләрә Тимергалиева звеносы уңышны 50 килога җиткерә. Планнан тыш керем 6 миллион бупачак. Теплицалар өчен 600 баш умарта тотабыз. Аларны ашатырга татлы серкәне Латвиядән алып кайтабыз.

— Шул хәтлеерактанмы? Татарстанда бал кортлары Латвиягә караганда күбрәк бит?

— Безнең умартачылар япкау. Безнекеләр белән килешкәнче Балтик буеннан алып кайту җиңелрәк.

Баштарак мин «япкау» сүзен үзебезнең Татарстан умартачыларына гына кайтарып калдырмакчы идем, тикшерә-өйрәнә торгач, шундый ук япкаулык-битарафлыкның бөтен илгә хас булуын күрдем.

* * *

Безнең илебездә умартачылыкның үзенчәлеге шунда: һәвәскәр умартачылар җәмәгать умартачыларыннан алдарак эш йөртәләр.

Эчүчелеккә һәм алкоголизмга каршы көрәш кампаниясенә кадәр илдә барлыгы 8 миллион чамасы умарта бар иде. Шуның 5 миллионын шәхси хуҗалыклардагы умарталар тәшкил итте. Җәмәгать умарталыкларында бер умартадан 7—8 килограмм бал алып килделәр, шәхси хуҗалыкларда бу сан икеләтә-өчләтә артык.

Башкортстанның бәрәкәтле җире гомер-гомергә бал ягыннан дан тотып килде. Аларның абруен өч медаль тагын да ныгыта төште, соңгысы аларга 1971 елны Мәскәүдә Халыкара конгресста тапшырылды. Әйе, медальләре артты, әмма корт кучләре артмый, табигыйдер ки, шулай булгач бал җыю да артмый. Революциядән соңгы 17 ел эчендә колхоз һәм совхозларда 221 мең баш умарта була, бу сугыш алдыннан дигән сүз. Аннары тагын 50 ел, ярты гасыр вакыт узды. Җәмәгать секторында умарталарның саны икеләтә кимеде — 120 меңгә калды. Әгәр шәхси хуҗалыклардагы умарталарны алып карасак, аларның саны 103 меңнән 210 мең башка җитә. Инде җәмәгать секторындагы белән шәхси хуҗалыкларныкын бергә китереп кушсак, ул буладыр — 330 мең. Инде революциягә кадәрге 571 мең белән хәзерге 330 меңне янәшә куеп карасак, аерма шактый зур булып чыга бит. Моны аңлау мөмкин түгел. Башкортстан кибетләрендә үз балларын түгел, Урта Азиядән, Ерак Көнчыгыштан, Кавказдан һәм башка төбәкләрдән китергән балны саталар. Әгәр сезгә өч медаль һәм Салават батыр сурәте төшкән, бик матур савытка салынган бал тәкъдим итәләр икән, моның әле башкорт урманнарыннан җыелган бал булуына бигүк ышанырга ярамый. Урындагы кооператорлар конвейердан аның савытын гына чыгарганнар, эченә башка яклардан китергән балны тутыралар. Башка яклардан китерелгән бал начардыр дип әйтергә теләмим мин, башкорт дусларның дан тоткан һөнәрләренә игътибар бетә барганлыгын гына үкенү белән искәреп узам...

Авылда хәзер халыкның өчтән бере яши. Белгечләр әйтә, ике меңенче елга 15—20 процент калыр, диләр. Әгәр хәзерге кебек ун йортның берсе умарта асрый торган булса, шуларның егермедән берсе генә корт үрчетсә, бал җыюның киләчәге бик сөенечле түгел. Шикәр диабетының элмәге безне тагын да ныграк кысып алмагае...

* * *

Бал елдан ел кыйбатлана, мин бу очеркларны язган чакта, моннан бер ел элек кенә Казан базарында килосы ун сум иде, инде, карыйсың — егерме биш-утыз сумга менгән. Балның кадерен белүчеләр бал сатучылар янына киләләр дә, бәясен ишеткәч: «Адәм баласының ояты бөтенләй калмады!» — дип тиргәнеп китәләр. Мине бер нәрсә аптырауда калдыра: бензин кыйбатланган өчен нефтьчеләрне тиргәмиләр, бөрек кыйбат булган өчен бөрек тегүчеләргә дә ачуланмыйлар. Нилектән умартачыларны гына, бал кыйбатланган өчен, тиргәп китәләр? Чөнки бал хәзерләүче белән бал алучы күзгә-күз очраша, барлык нәрсәнең кыйбатлануына ачуы кабарып йөргән адәм баласы күңелендә җыелган зәһәр ачуын умартачы өстенә чыгарып аудара. Бал нилектән кыйбат? Бал сатучы шулай теләгәнгәме? Һич! Илдә, республикада, төбәктә, авылда елдан-ел кими барганга күрә кыйбатлана бал.

Бал кортлары турында күп язалар. Андый кәгазьләр, шигъри багышлаулар, фәлсәфи трактатлар санынча арта торган булса, без инде балны кая куярга белми интегер идек. Әмма яшь Советлар иленең башлыгы В. И. Ленин тарафыннан төзелгән, күп куелган документ минем өчен ачыш булды.

Илдә ачлык, сугыш афәте барган 1919 елны Ленин умартачылыкка карата ифрат дәрәҗәдә кайгыртучан документка кул куйган. Аңарда менә нинди күрсәтмәләр бар:

*«1. Умартачылыкка шәхси хезмәтеңне яки гаилә әгъзаларының хезмәтен салганда, нинди дә булса норма кую — умарталыкның күләме ягыннан да, умарталар саны ягыннан да — чикләү тыела.*

*2. Кортларны туйдыру өчен әзерләнә торган балга чик кую, нинди генә күрсәтмәләр булуга карамастан, һичшиксез, тыела.*

*3. Бу карарны бозуда гаепле кешеләр РСФСР законнары буенча җавапка тартылачаклар.*

*4. Урындагы властьлар бу карарга каршы килә торган карарлар чыгарсалар, алар туктатыла.*

*5. Умартачыны күчерү һәм аңа яңа участоклар бирү, яңа урыннарга күчеңү буенча һәр төрле чикләнүләр тыела».*

*Имза: Халык комиссарлары советы рәисе —*
*В. И. Ульянов-Ленин.*
*Мәскәү, Кремль, 1919 ел.*

Бүгенге башбаштаклыклар белән чагыштырып карар өчен дип китердем мин бу карарны.

* * *

Бер җайдә бер умарта йөз килограммга хәтле бал җыя ала. Кеше барлык кирәзне дә алып бетерми. Уртача исәп белән умартачы бер умартадан җиде-сигез-ун килограмм гына бал сыга. Әле аннан соң да кортларга өстәмә ризык кирәк.

Менә шундый хәлне күз алдына китерегез. Апрельдә, майда, июньдә кортларның үрчү инстинкты кузгалган чак. Корт күче ишәя, аларны туйдырырга, җылытырга кирәк. Берничә көнгә түзә әле умарта күче, запас азыгын ашый, шул берничә көндә генә дә аңа ун-унбиш килограмм бал кирәк була. Әгәр азык аз икән, корт анасы бала үрчетүдән туктый. Корт күче әзер күкәйләрне дә урамга чыгарып ташлый башлый. Тагын берничә көнгә генә сузылсын суыклар — корт күчендә ачлык башлана, гаиләгә һәлакәт килә.

Әнә шул чагында умартачылар бирәләр дә инде шикәрне. Шикәр бирүнең икенче вакыты — августта, сентябрьдә. Балны инде суыртып алган булалар, умартаның стеналары буенда азык запасы калдырылган, уртасында буш рамнар тезелеп тора. Аларын кортлар кышлыкка ризык белән тутырып куярга тиешләр. Әмма ул чакта инде нектар юк, җәй узып бара, көзен балны каян аласың. Акыллы умартачы әнә шул чагында буш рамнарны истә тотып, биш-алты килограмм шикәр бирә, корт гаиләсе шул шикәр белән кыш буе торып чыга ала.

Нигә әле без шикәр суы турында бик күп сөйлибез? Беренчедән, умартачыларны әшәке гайбәттән коткару өчен. Икенчедән, өстәмә азык кортларны һәлакәттән саклап кала бит. Әмма бүген шикәр юк, кортларга талон да бирелми. Нишләргә? Бу хакта бер кыйсса тыңлагыз!

Кабарда-Балкариядәге һәвәскәр умартачыларының җитәкчесе Павел Васильевич Лях, кечерәк түрәләрне йөреп чыкканнан соң, дәүләт агропром рәисе Бражниковка хат яза. Хатында ул 60 тонна шикәр сорап кына калмаган, үз ягыннан тәкъдимнәр дә әйткән. Һәвәскәр умартачылар кооперация аркылы 82—90 тонна бал, 3 мең корт күче сата. Алга таба бал сатуны 300 тоннага, корт күчен 8—10 меңгә җиткерергә мөмкинлеген аңлата. Соңыннан, кортларны туйдыру өчен, шикәр сорый ул.

Тик аның хаты көткән нәтиҗәне бирми. Павел Васильевич Лях картаймыш көнендә Мәскәүгә — илебезнең башкалясына юл тота. Аның максаты — хат калдырып китү генә түгел, СССР Министрлар Советы рәисе Н. И. Рыжковның үзе белән кара-каршы утырып сөйләшү.

Башта һәммәсе дә иппе генә килеп чыга. Җай гына сораша-сораша, умартачы агаебыз әчкерәк үтә бирә. Максатына җитәм дигәндә генә туктаталар аны. Кая? Ник? Кем чакырды? Аппаратчылар тавышларын күтәребрәк, кискенрәк итеп аңлатырга тотыналар. Әнә шул озаклап аңлату ярдәм итә дә инде аңа! Ляхны кайсы кабинетка кертергә, дип торганда, Николай Иванович Рыжков үзе килеп чыга.

— Ни булды? — дип сорый ул бәхәсләшүчеләрдән.

Лях каушамый, тәп-тәгәп һәм кып-кыска итеп йомышын аңлатып бирә. Ул да рәис лебаса! Тик ул Совмин рәисе түгел, һәвәскәр умартачылар җәмгыяте рәисе, хөкүмәт башлыгын ул бал кортлары өчен шикәр сорап борчырга мәҗбүр.

Н. Рыжков мәсьәләгә ачыклык кертүне кирәк таба:

— Нәрсә, үз республикагызда хәл итмиләрмени мәсьәләне?
— Хәл итсәләр, нигә мин шул хәтле ерак кузгалыйм, ди?
— Яхшы, барыгыз, өегезгә кайтыгыз, җавап алырсыз.
Нәкъ сигез көннән Ляхны Кабарда-Балкария автономияле республикасының Министрлар Советына чакырып алалар.
— Мәскәүгә шикәр турында яздыгызмы?
— Язмадым. Николай Иванович Рыжковка үзем бардым.
Умартачы карт алдына менә шушындый кәгазь чыгарып салалар.
«РСФСР дәүләт агропромы куллану өчен сезгә РСФСР Министрлар Советының 1988 елның 29 августында (№ 11129-2-42) һәвәскәр умартачыларга бал кортларын ашату өчен шикәр бирү турындагы хатын җибәрә.
Автономияле республикаларның Министрлар Советлары, крайларның, өлкәләрнең, шәһәрләрнең, районнарның башкарма комитетлары... умартачылар җәмгыяте тапәбе белән һәвәскәр умартачыларга умарта башына 10 килограмм исәбеннән... шикәр сатарга рөхсәт итә».
Хатны мин сөйләгән вакыйгамның дәреслеген әйтер өчен генә китермәдем, һәвәскәр умартачылар шикәргә интеккән чакта нәрсәгә таянып шикәр алырга икәнен дә, аның өчен кемгә рәхмәт әйтергә кирәк икәнен дә белеп торсыннар, дип күчереп яздым.
Тик, кызганыч, хөкүмәт башлыгының әмерен бөтен җирдә дә үтәргә җыенып тормыйлар икән.

* * *

1989 елның җәендә мин Татарстанның йөзәр, йөз иллешәр баш умарта тоткан колхоз-совхоз чүннекләрендә йөреп чыктым. Август ае. Нәкъ шул чагында кышкылыкка күпме бал калдырырга икәнен билгелиләр. Әмма умартачылар аптырашта иде. Апар сөүдә оешмаларының күпме шикәр бирәчәген аермачык кына белмиләр. Әгәр бирәләр икән, умарталарның һәркайсыннан әле тагын бишәр килограмм бал алып чыгарга була. Йөз мең умартадан бу — биш йөз тонна дигән сүз Республиканың еллык планы. Бирмиләр икән, балны кортларга калдырмый ярамый. Районнардан кайтуга Татпотребсоюз идарәсенең рәисе Рафкат Фәйзуллович Сафиуллинның котын алдым. Умарталыкларда Киров өлкәсе кооператорлары йөри, апар балны шикәргә алмашалар. Башмабаш: бер килограммга — бер килограмм!
Азактан белдем, мин әйткәннең тәэсире булган. Районнарга телеграмма сугып, умартачыларга шикәр бирергә кушылган. Ләкин соңга калганнар. Шикәр юк. Райпо кооператорлары колхоз-совхозларга шикәр бирмәгән, умартачылар балны умарталарында калдырганнар. Татарстан, ихтимал, беренче мәртәбәдер, бал җыю планын үтәмәде. Бар иде заманнар, безнең республика меңәр тонна бал әзерли торган иде. Соңгы елларда планны киметтеләр — 600 тоннага калды. Ә 1989 елны кооператорлар 533 тонна гына саттылар.

* * *

Илне бал белән тәэмин итәр өчен күпме умарта тотарга кирәк соң? Сергей Алексеевич Поправко «Үсемлекләр һәм бал кортлары» дигән кызыклы китабында (аны Казанда татарчага да тәрҗемә иттеләр), менә нинди мәгълүмат бирә:
— Уртача санны алып һәм кеше башына бер елга 10—20 килограмм (уртача 15 килограмм) китә дип исәпләсәк, тиздән безнең илдә 300 миллион кеше булачагын да истә тотсак, 60 миллион чамасы умарта асрарга кирәк булып чыга. Бер умарта — биш кешегә. Бу хәзергегә караганда алты мәртәбә артыграк.
Бал кортларын үрчетү ансат эш түгел, әмма монда бундырып булмастай нәрсә дә юк. Ул исәптән безгә, димәк, 60 мең умартачы кирәк булачак. Әгәр шул гаять зур санның бер өлешен энтузиастлар алса?! Ул хәтле умартага табигатьтә нектар җитәрме? Исәпләп карыйк әле. Умартачы кәрәздән балның яртысын гына ала: 8—10 килограмм. Ә корт күче бер умартага 100 килограмм нектар, 25—30 килограмм чәчәк серкәсе җыя. Шуны 60 мең умартага тапкырлыйк. 600 мең тонна бал! 150 мең тонна чәчәк серкәсе. Һай, бик күп була бит бу!
Ләкин төшенкелеккә бирелеп утыра торган заман түгел. Кортлар илебездәге нектарның бик аз өлешен генә җыеп өлгерәләр, күп өлеше шөпшәләргә, төкле туралапрга, күбәләкләргә, башка бөҗәкләргә кала. Россия Федерациясендә генә дә ике миллион гектар юкә урманлыгы бар, бер миллион 700 мең гектар чәчәкле аланнар җәйрәп ята. Бер гектар юкә урманыннан, табигать шартлары уңайлы килгән елны, кортлар бер тонна бал җыя алалар. Әмма юкә берүзе генә балга булган ихтыяҗны канәгатьләндерми. Юкә чоры унбиш көн. Табигатьтә аңардан башка да балны чәчәк җитәрлек.
Бал хәзинәсе — адәм баласының үз кулында. Бакчалар никадәрле күбрәк, карабодай басулары, тукранбаш, люцерна, донник, фацелия кырлары никадәрле иркенрәк, бал

шулкадәрле күбрәк булачак. Умарталар саны артачак. Тик аның да бер хикмәте бар. арткан умарталарны карарга кеше табылырмы? Хәзерге көндә парлап эшли торган ике умартачыга 100—150 умарта беркетелә. Артыгына көч җитми, чөнки барлык эш кулдан эшләнелә. Әгәр умарталыкларны техника белән кораллапдырсак, бал җыюга авыллардан һәвәскәр умартачы — энтузиастларны тарта алсак, ул чагында эшләр гөрләп китәр иде.

Хикмәт — теләктә, авырлыклардан куркып калмауда, эшкә йөрәксенеп тотынуда! Ул чагында 60 миллион баш умартаның кәгазьдә түгел, урман аланнарында, шау чәчәкле карабодай басуларында барлыкка килүе мөмкин.

Хыялдан чынбарлыкка әйләнеп кайтыйк. Баллы оҗмахка беренче адым нинди булырга тиеш? Укымышлы теоретикларны түгел, практикларны тыңлап карыйк. Татарстандагы «Яңалык» колхозының рәисе Ринат Сәләхетдинов бу хакта ниләр уйлый икән? Аның колхозындагы керемнең биштән бер өлешен умартачылык бирә бит. Авыл экономикасы өчен гадәти булмаган хәл!

— Эшне бал кортларына, умартачылыкка ихтирамнан башларга кирәк,— ди Сәләхетдинов.— Умартачыны рәнҗетмәү, кысмырланмау, аңа тиешлесен түләү зарур. Умартачының кесәсендәге акчаны — тир белән тапкан акчаны санап утырганчы, аның колхозга яки совхозга биргән табышын санау дөресрәк.

* * *

*Мин бу язмамны кайнарланып, ялкынланып иҗат иттем. Тизрәк, тизрәк! Вакыт көтми, вакыт уза! Теләгем шул: монда күтәрелгән мәсьәләләр укучыны уй-фикергә генә түгел, төгәл гамәлләргә дә кузгатып җибәрсен иде!*

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ЗАМАНГА ҖАВАП БИРӘБЕЗМЕ?..

*Бөтен кеше тыныч һәм затлы булса, һәркайда да мактаулар һәм әдәплелек яшәсә — намуссызлык, алдакчылык, томаналык өчен нинди киң мәйдан ачыла: беркем дә фаш итә, дәһшәтле гаделлек сүзен кистереп әйтә алмый бит!...*

В. БЕЛИНСКИЙ

Яңа туган һәр нәрсә — сабыймы ул, әллә яңа иҗтимагый-сәяси күренешме, алга бару омтылышы ясаганда, күпмедер вакытка артка китү гамәлен дә башкарырга мәҗбүр, ахры. Ягъни, ничек кенә парадокс тоелмасын, ниндидер бер вакыт аралыгында артка чигенү — алга баруның мөһим бер закончалыгы, аның әһәмиятле бер өлеше икән.

Без бүгенге көндә тормышыбызның бөтен тармакларында — икътисадта, сәясәттә, мәдәнияттә, мәгарифтә, рухиятта нәкъ менә шундый хәрәкәт кичерәбез. Алга бару өчен чигенү, артка китү гамәлен башкарабыз. Бу — даими рәвештә бер адым алга атлап, ике адым артка чигү генә түгел! Бәлки, тирән ышануымча, көч, җегәр, акыл, белем, тәҗрибә туплау өчен, вакыт оту өчен генә кирәк булган вакытлы бер чигенү, финишны яулау өчен мөһим булган ыргымга нык нигез, ышанычлы таяныч әзерләү генәдер.

Күпкырлы тормышыбызның үзенчәлекле көзгесе булган әдәбиятыбыз, бигрәк тә аның анализ һәм бәя сәнгате тармагы булган әдәби тәнкыйть әнә шулай инкыйлаби ислах кичергән яңа шартларга җавап эзләмәктә.

Шәхес культы һәм торгынлык чоры милли мәдәниятләрне әкренләп юкка чыгару максатында «формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик» булган, бәйнәлмиләл традицияләрен үстергән яңа бер мәдәниятне пропагандаларга, шул рәвешчә, адәм балаларының аңында дәһрилек, манкортлык карашлары тәрбияләргә омтылса, әдәбият исә хәленнән килгәнчә милли рух төсмерләрен якларга, үз мәсләгенә таба юл тотарга тырышты. Яңа чор өчен уңдырышлы һәм бәрәкәтле җирлек әзерләгән әдипләребездән Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Салих Батталның «Сигезенчесе кем?», Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган», Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» кебек кырыс тәнкыйди реализм рухында язылган күләмле чәчмә әсәрләре әдәби тәнкыйть игътибарыннан читтә калмады.

Әмма шунысын да искәртү кирәк: әдәби тәнкыйть табигый вазифасын — әдәбиятыбызда бөреләнә башлаган уңай хасиятләрне вакытында күреп алып, аларны үстерергә ярдәм итү бурычын тиешенчә үтәп бетерә алмады. Моның сәбәбе нидә соң?

Җәмгыятьтә һәм әдәбиятта регламентлар, аерым бер норматив кысалар хөкем сөргән торгынлык чорында, билгеле, хөр фикернең һәм гадел бәянең нинди шартларда яшәвен күз алдына китерүе кыен түгел. Нәкъ менә шундый заманда инде әдәби тәнкыйтьнең иң мөһим бер вазифасы — аның киң катлам укучыларны тәрбияләргә тырышкан төп функциясе җуела башлады. Рәсми идеология тарафыннан аңа әдәбиятка үгет-нәсихәт биреп тору, аның «хак юлдан» баруын күзәтү эше йөкләнде. Нәтиҗәдә, шундый идеология коралына әйләндерелгән тәнкыйть әле борынлый гына башлаган хөр фикерне буа барды, ә системага табынып, аңа мөритләрчә тугрылык күрсәткән калəм әһелләренең әсәрләре исә күккә чөелде, укучы аңына шул фикер сеңдерелә башлады. Ләкин андый әсәрләр, вакытның кырыс сынавын үтә алмыйча, әдәбият тарихында бер әдәби факт буларак кына калдылар. Ә норматив тәнкыйть тарафыннан каһәрләнгән әсәрләр исә, киресенчә, укучы күңеленә озакка кереп урнашты.

Ул чорда, дөресен әйтергә кирәк, әдәби тәнкыйть иҗтимагый фикернең дә вазифасын узурпацияләде. «Укучы һәм халык фикере» дигән булып, рәсми идеологиягә хезмәт итәргә теләмәгән рухи кыйммәтләр әдәби хәрәкәттән кысрыкланды. Ләкин әдәби тәнкыйтьнең бурычы аерым бер фикерләрне штамп хәленә китереп, аларны мәҗбүри рәвештә укучыларга тәкъдим итү түгел. Аның мөһим вазифасы — әдип иҗат иткән әсәрнең художество кыйммәтен бәяләүдә, шул әсәрнең әдәбиятны һәм тормышны нин-

ди яңа рухи хәзинәләр белән баета алуын ачыклауда. Әдәби тәнкыйть иң элек җәмгыятькә, кешеләргә, ягъни күңелләрен әдәби хәзинәләр белән баетырга омтылучыларга һәм шул рухи кыйммәтләрне тудыручы әдипләргә хезмәт итә. Образлы телдә әйткәндә, ул укучы белән әдипне тоташтырып торучы ышанычлы күпер булырга тиеш. Әмма, кызганычка каршы, безнең тәнкыйть һәммә очракта да ышанычлы күпер булып бетә алмады. Кай очракта, үзенчәлекле әсәр иҗат ителгәч, тәнкыйть аның әһәмиятен һәм кыйммәтен ачыклау урынына, рәсми идеология күзлеге аша бәя бирергә омтылды, аның укучылар арасында абруй казану сәбәпләрен өйрәнмәде. Төпле анализ һәм гадел бәя сәнгате булырга тиешле әдәби тәнкыйтьнең шулай төп маякларны бутавы, укучылар күңеле ятмаган фикерләрне димләве дә тәнкыйтьнең абруен төшермәде түгел.

Мондый хәлнең, тәнкыйтьнең кай очракта ялган ориентирлар белән укучыны юлдан яздыруның янә бер сәбәбе — тәнкыйди анализның төп принципларын урынлы куллана белмәүдә. Кайбер каләмдәшләребез эстетик төшенчәләр яки фәлсәфи категорияләр тирәсендә генә әвәрә килеп, гомумсәнгать терминнарының (образ, метод, стиль, жанр, сюжет, композиция һ. б.) әдәби текст тукымасындагы яшәү рәвешенә бөтенләй битараф калалар. Әсәрне бәяләгәндә комплекслы анализ ысулын урынлы куллана белмәү әнә шулай буталчыклыкларга китерә һәм тәнкыйтьнең сыйфат дәрәҗәсенә дә тәэсир итми калмый. Нигездә, тикшерү принциплары буенча бер булган, ләкин анализлау предметлары буенча гына әдәбият белеменнән аерылып торган әдәби тәнкыйть тормыш белән әдәбиятның үзара бәйләнешен — тормыш дөреслегенең сәнгать дөреслеге белән тәңгәллеге мәсьәләсен ачыкларга омтыла. Әгәр бүгенге тәнкыйтьтә тормыш дөреслеген «заман герое — замандаш образы — шәхес концепциясе» схемасында карарга омтылу сизелсә, нәфасәт дөреслеген аңлау процессы да үзенчәлекле һәм бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган өч төрле яссылыкта карала. Беренче яссылыкта сәнгать дөньяны танып белүнең бер калыбы буларак чагыла. Икенче яссылыкта исә укучыларның әдәби тасвирланган чынбарлыкка мөнәсәбәте ачыклана. Өченче яссылыкта нәфасәт дөньясын төзү принциплары төгәл билгеләнә. Иҗат процессында бары шушы мөһим элементлар искә алынганда гына әдәби тәнкыйть укучы белән әдипнең эчкерсез һәм ышанычлы дустына, киңәшчесенә әверелергә мөмкин.

Безнең тәнкыйть бүгенге көндә әдипкә дә, укучыга да йөз белән борыла башлады. Әле торгынлык елларында ук Ф. Мусин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Н. Юзиев, Ф. Миңнуллин кебек тәнкыйтьчеләребез тормышыбызда һәм әдәбиятыбызда барган катлаулы һәм каршылыклы процессларга гадел бәя бирергә омтыла иделәр. Билгеле, ул чорның сәяси шартлары аларны үз фикерләрен яшеребрәк белдерергә мәҗбүр итте. Ләкин шулай булса да, бу буын тәнкыйтьчеләре әдәби тәнкыйтьнең сәламәт нигезен бүлдырырга һәм аның әдәбиятта мөстәкыйль һәм сугышчан жанр булып җитлегүенә күп көч куйдылар. Әлеге тәнкыйтьчеләрнең иҗаты әдәби хәрәкәтне җанландырып, аның даирәсен киңәйтеп кенә калмады, бәлки иҗат мәйданына яңача фикерләргә һәм иҗат итәргә омтылучы бер төркем яшь тәнкыйтьчеләрне: Мансур Вәлиев, Равил Кукушкин, Салих Маннапов, Зиннур Мансуров, Фоат Галимуллин, Фәез Зөлкарнәев, Фаяз Дунай, Назыйм Ханзафаров кебек авторларны да мәйданга чыгарды. Боларның иҗат үзенчәлекләре нәрсәдә соң?

Салих Маннапов әдәби әсәрләрдә сурәтләнгән образларның табигый яшәвенә, димәк, рухи яшәүне тою аша чынбарлыкның тирән катламнарына үтеп керергә омтыла. Тәнкыйтьченең бу матур омтылышы «Сезгә ышанам» исемле китапта үзенчәлекле чагылыш тапты. Ул анда әдәбият өчен генә түгел, ә гомумән безнең каршылыклы тормыш өчен гаять мөһим булган проблеманы алып тикшерә. Китапны ачып җибәргән «Хәтер» исемле эссе «үзенең авылын эзләп йөрүче» сәер карчык турындагы хикәят белән ачыла. Һәм бу тикмәгә генә түгел: тәнкыйтьче безне өкренләп хәтернең — үз халкыңны, нәселнәсәбеңне, ата-баба васыятен онытмау мәсьәләләренә алып керә, тормыш һәм әдәбият күренешләре аша һәркайсыбызның күңел түрендә яткан уй-борчуларны, шатлык-кайгыларны ачарга омтыла.

Бу китапның геройлары — үзенчәлекле һәм гыйбрәтле затлар. Алар — безнең әйләнә-тирәбездә яшәүче гади һәм мөлаем кешеләр, күршеләребез, авылдашларыбыз да, яратып укый торган китапларыбызның каһарманнары һәм танылган әдипләр үзләре дә. Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, В. Нуруллин, А. Тимергалин кебек прозаиклар, С. Хәким, И. Юзиев, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Р. Харис, Р. Миңнуллин, Зөлфәт кебек шагыйрьләр иҗаты белән якыннанрак танышу, Бөек Ватан сугышы чоры һәм бүгенге татар әдәбияты панорамасын күздән кичерү, әдипләрнең иҗат серләре турында мәгълүмат бирү, тормыш бүген тудырган рухи мәсьәләләрне күтәрү җәһәтеннән дә китап тәнкыйтьтәге рухи анализ юнәлешенең дөрес юнәлеш, тирәнгә алып керә торган юнәлеш булуына кабат ышандыра.

Салих Маннапов үзе тасвирлаган күренешләрнең хикмәтен табып, укучыны уйлануга һәм бәхәскә җәлеп итеп, аңлаешлы шигъри тел белән яза. Шул уңайдан китаптагы «Хәйретдин агай чаң кага...» дигән бер язмадан түбәндәге юлларны искә төшерәсе килә: «Язучының фикер сереше җирдән — һәркайсыбызга якын, әсәрнең кайсыдыр бер өлешендә, көтмәгәндә генә укучыга үз-үзен искә төшереп, үз тормышына кайту мөмкинлеге бирелә: аһ, безнең инде рухыбыз җирдән күтәрелеп киткән, ул инде тыелгысыз тестә аяз күккә ашкына, дөнья, заман, көн агышына карау зарурияттен дауллый...»

Әнә шулай тәнкыйтьченең язу объекты җитдиләнә бара, әдәбиятның максаты, колачы милләт рухы белән булуын фәлсәфи-шигъри образлар аша ачуга якыная.

Бүгенге әдәбиятны агымдагы тормыш-көнкүреш контекстында гына түгел, бәлки мәдәният тарихы, халык тарихы, фикер тарихы җирлегендә дә аңларга омтылу Салих Маннаповның «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» исемле әдәбият турында уйланулар һәм эсселар китабында сизелә. «Тәллитут», «Исеңдәме?», «Чынлап та шулаймы соң», «Ачкыч эзләдем» һәм башка язмаларда әдәбиятның кайнар эзеннән атларга, әдәбият күренешләренә тормышыбызның катлаулы үсеш мантыйгы аша карарга тырышу бар. Ул әдәбиятның теләсә нинди жанрына караган әсәрдәге образларның эчке дөньясына, рухи үзәгенә төрле яссылыктан күз салу белән бергә, аларның әдәбияттагы һәм рухи тормыштагы роле, әһәмияте, мәдәният үсешенә ясаган тәэсире хакында да төптән, җитди итеп уйларга тырыша. Билгеле, әдәбиятны, бигрәк тә аның аерым тармакларына һәм жанрларына караган әсәрләрне шундый киң яссылыкта һәм катлаулы аспектта тикшерү, анализлау эше тигез бармаска да мөмкин. Тәнкыйть методологиясе аерым бер әдәби текстны әдәбият факты, тормыш күренеше, мәдәният һәм фикер үсеше тарихы, гомумкешелек проблемалары яктылыгында тикшерүне, нигездә, якласа да, мондый катлаулы синтетик анализны һәр очракта да тигез дәрәҗәдә куллана белү, дөресрәге, бу ысулны һәр тәнкыйтьченең төп иҗат принцибына әйләндерү мәсьәләсе бүген дә мөһимлеген югалтмаган, әле көн тәртибеннән төшмәгән. Тәнкыйтьче бары шундый күчле белем һәм интеллект коралына ия булганда гына уңышка ирешергә мөмкин дип раслый Салих Маннапов «Ачкыч эзләдем...» дигән язмасында һәм фикеренә таңгәл килгән кайбер дәлилләре белән дә бик теләп уртаклаша.

Шул принцибыннан читкә тайпылмый иҗат иткән Салих Маннапов, нигездә, яңа әсәрләрнең поэтикасын анализлауга, аларның әдәби хәрәкәттәге урынын ачыклауга күбрәк игътибар итсә, тәнкыйтьче Зиннур Мансуров публицистик үткенлек һәм шигъри кайнарлык белән мәдәният өлкәсендә яшәп килгән җитешсезлекләр турында фикер йөртә. Аның «Юлын белгән арымас» исемле тормыш, әдәбият һәм сәнгать турында уйланулар китабы үзенең замандаш каләмдәшләре һәм шигърият мәсьәләләре турындагы мәкаләләр белән бергә, «Ишетәсезме!..» исемле мәдәният эшенә җитәкчелек итүдә кадрлар әзерләү мәсьәләсенә багышланган җитди язмасын да үз эченә ала. Әлеге мәкалә хөрлек хөкем сөргән иҗат дөньясына хуҗа булып, милли мәдәният үсешен тоткарлаган надан номенклатура эшмәкәрләренең булдыксызлыгын, эшлексезлеген ачык күрсәтте, иҗат интеллигенциясенең кулына идеология богаулары кидерергә маташуның нинди күңелсез нәтиҗәләргә китерүен әтрафлы итеп, дәлилләп исбатлады.

Сәнгатьләрнең бик күбесен эченә алган синтетик иҗат үрнәге булган милли опера жанры үсеше турында язмы ул, әллә үз «кендегенә» үзе кисеп дөнья белән бик яшьли конфликтка кергән Габдулла Тукай иҗатына безнең заманнан күз саламы, яки иҗаты гына түгел, бәлки яшәү рәвеше дә чынлык, яхшылык, матурлык категорияләре белән бәяләнгән Рәшит Әхмәтҗанов шигърияте турында уйланамы — тәнкыйтьче барыбер милләт, мәдәният язмышы хакындагы мәсьәләләрне читләтеп узмый.

Шигъриятнең 1989 елдагы торышын бәяләүгә багышланган «Сиксәненче елларны озатканда...» дигән мәкалә дә инкыйлаби ислах чоры тудырган үткен мәсьәләләргә туктала. Бу мәкаләдә үзе дә талантлы шигырьләр язган тәнкыйтьче шигърият ташкынынннан үзенчәлекле шагыйрьләрне табып, танып, алар иҗатындагы матур төсмерләрне дөрес күрсәтә. Сәясәтләшү заманында бүгенге шигърияттә иҗтимагый якның тирәнәюенә, халкыбыз хакыйкатен ачыклау юнәлешенең көчәюенә игътибар итеп, тәнкыйтьче халык рухын исән килеш сакларга, татар шигъриятенең сугышчан рухын көрәштә янәдән расларга өнди. Зиннур Мансуров шигъри әсәрләрнең төзелеше, ритмы, рифмалаштыру кебек техник якларын да читкә тибәрмичә, аларның кайсы ягы белән катлаулы тормышка барып ялгануына, гомум шигърият фонында аның нинди яңгыраш алуына да битараф түгел. Ул шигырьләрне тарихи планда, дөнья әдәбияты җәүһәрләре югарылыгында тикшерергә, бәяләргә тырыша. Өлкән шагыйрь Нури ага Арсланов иҗаты, мәсәлән, нәкъ менә шушы яссылыкта калку күренде, аның икенче сулышы ачылып китүнең төп сәбәпләре шулай ачылды.

Гәрчә кайбер шагыйрьләр шигърият тәнкыйтенә дәгъва белдереп, вакытлы матбугат битләрендә кылыч уйнатып алсалар да, миңа калса, бу — тәнкыйтьнең иң җитди һәм җитлеккән тармагы шикелле. Һәрхәлдә, «Кешем, асылың кем?» һәм «Әверелеш» исемле китаплар авторы Фәез Зөлкарнәев иҗаты шулай дияргә ныклы нигез бирә.

Тәнкыйтьче булараk җитлегүнең, тагын да камилләшүнең матур мәгънәсендәге мисалы булган «Әверелеш» китабы хәзерге татар шигъриятендәге шәкли яңарыш, графикага нигезләнгән поэтик алымнар турында гына сөйләп калмый, бәлки поэтик эзләнүләрнең нәтиҗәлелеге белән бер-берсенә якын булган ике кызыклы дәверне — егерменче һәм алтмышынчы елларны да колачлый. Формасы буенча монографиягә тарткан бу китапта Х. Туфан, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Ш. Анак кебек шагыйрьләрнең иҗаты нигезендә шигъри әсәр табигате, аның формасы турында кызыклы фикерләр, мисаллар китерелә.

Әйтергә кирәк, Фәез Зөлкарнәев татар шигъриятен шаулаткан, аны ил аренасына чыгарган егерменче һәм алтмышынчы еллар чоры шагыйрьләре иҗатын милли җирлектә генә тикшерми, аны ил һәм дөнья шигърияте фонында анализлый, кешелек

дөньясы тупланган эстетик хәзинә янәшәсенә куеп чагыштыра. Сәяси формацияләр һәм иҗтимагый күренешләр алмашыну күренешенең шигърияткә йогынтысын күрсәтү белән бергә, әлеге факторларның шигырь төзелешенә, аһәңенә, ритмикасына тәэсирен дә төгәл ачыклый. Аерым алганда, ассоциатив фикерләү рәвешенең шигырьгә фикри һәм рухи богаулар кидерүгә каршы протест йөзеннән тууын искәртә. Бу нисбәттән, тәнкыйтьченең «Арын көн дә коллыгыңнан!» исемле мәкаләсе нәкъ менә шул мәсьәләне яктыртуы белән әһәмиятле. Кырыс регламентлар хөкем сөргәндә дә шигъриятнең көрәш рухыннан, милли рухтан читләшмәве аның яңа формасында, фикере катлаулы поэтик образлар киеменә төренгән үзенчәлекле эчтәлегендә яхшы чагылды. Кол Галиләрдән, Г. Кандалыйлардан, Г. Тукайлардан килгән бай традициягә таянган татар шигърияте мәгъриб белән мәшрикънең иң яхшы поэтик үрнәкләреннән өйрәнеп, дөнья әдәбияты хәзинәсе казанышларын үзләштереп үсте. Милли шигъриятебездә зур үзгәрешләр китереп чыгарган егерменче һәм алтмышынчы еллар шагыйрьләре иҗатындагы шәкли яңарыш турында күренекле галимнәребез Х. Госман, И. Нуруллин, Т. Галиуллин, Н. Юзиев, Р. Мостафин һ. б.лар үз вакытында язып чыкканнар иде. Ф. Зөлкарнәев шигырь парадокслары чагылган «Әверелеш» исемле монографиясендә шул фикерләрне ныклы мантыйкка нигезләп, бер фокуска туплый һәм фәнни система рәвешенә китереп, үз күзәтүләре белән дә баетып, тамырга үстерә. Ф. Зөлкарнәевның кызыклы үз фикерләре, оригиналь карашлары бар. Аерым алганда, ул Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Зөлфәт, М. Әгъләмов иҗатлары турында уйланганда ил һәм дөнья шигърияте тудырган эстетик һәм поэтик кыйммәтләр югарылыгында фикер йөртә, әлеге буын шагыйрьләренең шигърияткә алып килгән яңалыгын дөрес сизеп ала.

Үзе салган сукмактан кыю рәвештә алга атлаучы Мансур Вәлиев иҗаты исә нинди дә булса концепциягә бәйләнмәгән булуы һәм эмоциональ-экспрессив рухы белән каләмдәшләре арасында аерылып тора. Аның мәкаләләрендә әдәби әсәрнең рухы кабат яңара, анда күтәрелгән фикерләр әдип сүзенең дәвамы кебек кабул ителә. Мансур Вәлиевне теге яки бу әдәби әсәрнең нинди идеологиягә яки концепциягә хезмәт итүе түгел, бәлки аның әдәби-нәфис сыйфаты, эстетик тәэсир итү көче, куәте кызыксындыра, әсәрне саф килеш кабул итү, аның гүзәл хасиятләрен эзләү ләззәте ымсындыра, чын нәфасәт дөньясы белән шулай кавышу теләге дәртләндерә. Ул әдәби әсәрне төзүдә катнашкан сүзләрнең, тәгъбирләрнең, төшенчәләрнең, лексик берәмлекләрнең һәм конструкцияләрнең эчке куәтен тикшерә, хикәяләүнең үзенчәлекле һәм көтелмәгән яңа алымнарын, тасвирлауның үзенчәлекле калыпларын табу шатлыгы кичереп куана, шуңардан илһам ала. Ләкин шул ук вакытта, ул әдәби әсәрне аның табигый җирлегеннән — катлаулы һәм каршылыклы тормыш туфрагыннан да аерып алып анализламый, бәлки әсәрне әдәби хәрәкәтнең мөһим бер өлеше итеп саный һәм аны иҗтимагый процесс белән, яшәеш һәм рухият мәсьәләләре белән бергә тыгыз үреп бара, аларны бер бөтен итеп карый. Минем карашымча, Мансур Вәлиев иҗатының асыл сыйфаты, әгәр шулай әйтергә килешсә, аның кредосы — ул да булса, аның тормыш белән әдәбият арасындагы уртак күренешне — кеше күңеленең рухын тикшерүдә, яшәешнең серле һәм тылсымлы хасияте булган рухиятның тирән катламнарын анализларга омтылуда.

Әдәби әсәрләр җирлегендә чорыбызның рухи чынбарлыгын өйрәнү, рухи талпынышның яңа хасиятләрен ачарга омтылу тәнкыйтьченең «Яшьләр мәйданга чыга» исемле беренче китабында башланып, «Табарга һәм югалтмаска», «Күңелнең көткәне», «Учагың сүнмәсен», «Каһарманнар кирәк!» дигән күләмле җыентыкларда тамырга үстерелде. Әлеге китапларга тупланган мәкаләләрдә, диалогларда, ачык хатларда, репликаларда тынгысыз йөрәкнең ярсып тибүе сизелә.

Инкыйлаби ислах чоры өчен үтә мөһим булган рухи һәм әхлакый мәсьәләләр кузгатып, тәнкыйтьче аларның уңай чишелешенә ярдәм итә торган юллар эзли, шуңа бәгле уй-фикерләре белән уртаклаша. Әдәбият мәсьәләләре һәм әдәби хәрәкәт проблемалары яки тормышта бөреләнә башлаган яңа күренешләр турында фикер йөрткәндә Мансур Вәлиев укучылардан һәм әдипләрдән бер адым алга атлап барырга омтыла.

Әнә шулай кешеләрнең иң тирән рухи талпынышларын өйрәнү, рухи чынбарлыкны анализлау, халыкның, милләтнең иң үзәгенә үткән нәрсәләрне язу, алар турында халыкчан итеп, образлы һәм тәэсирле итеп язу рухы тәнкыйтьченең «Каһарманнар кирәк!» дигән яңа китабында тагын да көчәя төшкән. Мансур Вәлиев инкыйлаби ислах чорында тәнкыйтьнең яңа бурычын тагын бер кат искә төшерә: «Соңгы елларда татарның иң намуслы әдипләре бер дә юкка гына милләт өчен иң газиз булган милли азатлык идеясе турында язуга алынмадылар бит! Каһарманлык темасы да укучылар өчен һәрвакыт мөһим булып тора. Безнеке шикелле давыллы чорда, кискен үзгәрешләр вакытында — милләт өчен зур эшләр башкару һәрбер зыялы татар каршына намус бурычы итеп куелган заманда бу бигрәк тә шулай!

Димәк, әдәби тәнкыйть тә чын гражданлыкның мондый олы юлыннан баш тарта алмый. Киресенчә, тормышның иң үткен мәсьәләләренә алынырга кирәк».

Әмма, шул ук вакытта, Мансур Вәлиевның үз «казаныбыз»да гына кайнавы, хәзинәдә барын ил һәм дөнья күләмендә күрсәтергә теләмәве һич кенә дә аңлашылмый. Әдәби хәрәкәт мәсьәләләре һәм әдәбиятыбыз проблемалары турында фикер йөрткәндә дөнья әдәбияты ирешкән казанышларга таяна алган бу тәнкыйтьченең шулай «тыйнаклык» саклавы дөрес түгел. Чөнки, үзәк матбугат битләрендә яхшы әзерлекле

житлеккән тәнкыйтьчеләр ешрак чыгыш ясаганда, шул рәвешчә милли әдәбиятыбыз мәсьәләләренә ил һәм дөнья әдәбиятлары проблемалары аша күз салганда гына рухи байлыгыбызның артуы өчен уңдырышлы шартлар туарга мөмкин.

Гаделлек хакына танырга кирәк: бу кимчелек бер Мансур Вәлиевка гына хас түгел. Өлкән тәнкыйтьчеләребезнең дә күпчелеге, урта буынның да зур өлеше һәм «дәрте дә, дәрманы да булган» яшь тәнкыйтьчеләрнең дә шактые бу мәсьәләдә әле сүлпәнлек күрсәтәләр, житди язмалар белән үзәк матбугатка чыгарга бик атлыгып тормыйлар. Ф. Мусин, Р. Мостафин, Т. Галиуллин, Н. Юзиев, А. Әхмәдуллин, Ә. Мәхмүтов кебек галим-тәнкыйтьчеләр генә, нигездә, ил укучысын татар әдәбияты җәүһәрләре белән өлешчә таныштырып барырга тырышалар. Әмма алар гына бу зур бурычны башкарып бетерә алмый. Аны берничә кеше генә, гәрчә алар бик тырышсалар да, башкарып чыга алмый.

Бу мәкаләне язар алдыннан мин кечкенә генә бер социологик тикшерену уздырдым. 1988 елның 1 гыйнвареннан алып 1991 елның 1 гыйнварена кадәрге өч ел эчендә тәнкыйтьчеләребезнең үзәк матбугат битләрендә дөнья күргән язмалары белән танышып чыктым. Шул вакыт арасында 186 язма басылып чыккан. Әмма шуларның зур күпчелеген аннотация, кыска мәкалә, бәләкәй репортаж, блиц-интервью, китап күзәтү, нәни рецензия тәшкил итә. Үзәккә зур проблема куеп язылган житди мәкалә, әдәби хәрәкәтнең күп төрле тесмерләрен яктыртканнары берничә генә. Монография кебек фундаменталь хезмәтләр дә берничә генә басылган.

Әгәр без гел шулай пассивлык күрсәтеп, ил алдында әдәби хәзинәбезне күрсәтә алмасак, илебез укучысында, «боларның күрсәтә алырлык байлыгы юк икән» дигән фикер тумасмы соң? Әдәби хәзинәләре фәкыйрь, иҗат көчләре зәгыйфь дип уйламаслармы? Кыскасы, әлегә җавап көтеп торган шундый эчтәлектәге сорауларның саны бер дә кимүгә таба бармый.

Әлбәттә, бөтен милләт, әдәбият алдында торган мондый проблемаларның килеп чыгуына бер тәнкыйтьчеләрне генә җаваплы итеп калдыру дөрес булмас. Болай уйлау эчке механизмы ватылу сәбәпле йөрүдән туктаган сәгатьнең гаебен аның угыннан эзләү булыр иде. Ләкин кемдер, Данко кебек, барыр юлны яктыртып торырга, уңай үрнәк тә күрсәтергә тиеш ич... Бу очракта, билгеле, бөзнең күзләр мөмкинлеге һәм интеллекты, таланты һәм фидакарьлеге зур булган, әдәбият өчен җанын фида кылырга әзер торган иҗади шәхесләргә төбәлә. Көндәлек тормышыбызда да бит йөкнең зурысы яткан атларда түгел, бәлки тарткан атларда була...

Һәрхәлдә, безнең тәнкыйтьчеләр бу житди һәм әһәмиятле мәсьәләгә карата фикерләрен үзгәртерләр һәм аны уңай якка чишүнең төрле юлларын эзләрләр дип ышанасы килә.

Әйе, әдәби тәнкыйть чын мәгънәсендә анализ һәм бәя сәнгатенә әйләнергә тиеш! Ул милли әдәбиятыбызны дөнья әдәби хәрәкәтенең аерылгысыз мөһим өлеше дип расларга тиеш. Бу юнәлештә әдәби тәнкыйть алдында шактый зур бурычлар тора. Тоталитар системаның әдәбиятта хакимлек иткән бер принцибы — социалистик реализм методы богаулары өзелгәч, әдәби хәзинәбезне кабат барлау, аны яңа кыйммәтләр белән бәяләү мөмкинлеге ачылды. Шул сәбәпле, әдәбият тарихыбызны да гадел күз белән карап чыгу һәм аны кабат язу ихтыяҗы туды. Әлеге күренешнең тирән сәбәпләрен ачуда әдәби тәнкыйть тә үзеннән өлеш кертергә бурычлы.

Заманында тоталитар иләкнең стандарт кысаларына сыймау аркасында әдәби хәрәкәттән мәҗбүри рәвештә читләштерелгән бик күп яңа әсәрләр кире укучысына кайтарылды. Рәсми идеология күккә чөеп мактаган әсәрләр исә ул чорның бер әдәби факты булarak кына тарихта калды. Ислахның беренче карлыгачы — «Идегәй» дастаны басылды. Күренекле әдип Гаяз Исхакыйның бай мирасы әдәби хәзинәбезгә кушылды.

Илләрне, халыкларны гына түгел, бәлки мәдәниятләрне дә икегә аерган сыйнфый тәгълимат нәтиҗәсендә чит илләрдә «Сак белән Сок» хәлендә яшәгән Зыя Кадермәти, Йосыф Акчура, Зәки Вәлиди, Гали Акыш, Ләбиб Коран, Наилә Бинарк һ. б. милләттәшләребезнең мәдәни мирасын өйрәнү, аларны уртак милли мәдәниятебезгә кайтару эше көн тәртибенә килеп басты. Республикабыздан читтә, башка мәмләкәтләрдә яшәгән халкыбызның гасырлар агышындагы язмышын бердәм халык буларак яктырту да әдәби тәнкыйть алдында тора. Тәнкыйди реализм рухында иҗат иткән әдипләребезнең иҗаты белән дөнья укучысын таныштыру бурычы да әдәби тәнкыйть өстендә. Тыйнаклык саклап, үз казаныбызда гына кайнау заманы узды инде. 438 ел буена авыз каплап сөйләшү аркасында без болай да шактый мескен хәлгә төштек. Булган хәзинәбезне дөнья мәйданында күрсәтә башларга вакыт. Бабаларыбызның кайчандыр үз мөстәкыйль дәүләте булганда дөнья базарында теттереп сәүдә иткәне шикелле, без дә бүгенге мөмкинлекләрдән дөрес файдаланып, рухи байлыгыбызны дөнья әдәбияты хәрәкәтенә чыгарыйк! Каләмдәшләребез иҗатындагы кимчелекләрне эзләү белән мавыкмыйча, алар әсәрләрендә җемелдәгән рухият йолдызларын күреп алып, аларның балкып яңу мохитын киңәйтик! Бары шул вакытта гына әдәби тәнкыйть, «кәрванбаш» вазифасын үти алачак, шул очракта гына бай әдәби мирасыбызны дөнья әдәбияты җәүһәрләре янына алып киләчәк.

Әхмәт САХАПОВ.

**Китап күзәтү**

# ҖИЛГӘ КАРАП КЫЙБЛАНЫ ҮЗГӘРТМИК

## Ф. ӘМИРХАННЫҢ ДҮРТТОМЛЫГЫ ЧЫГУ УҢАЕННАН

Фатих Әмирхан... Татар мәдәниятенең тапсыз күгендә кабатланмас йолдыз булып балкыган бу гаярь каләм остасына шәхес буларак та, әдип буларак та нинди генә язмыш сынаулары үтәргә туры килмәде! Бер яктан, ул бәхетле иде: үзе исән вакытта ук гаҗәеп үзенчәлекле талант иясе буларак танылды, шөһрәт казанды, милли әдәбиятыбыз йөген төптән җигелеп тартучы фидакарь затлардан саналды. Мәгълүм ки, мондый сәгадәт фәрештәсе һәркемнең дә иңбашына кунмый. Икенче яктан, ул бәхетсез булды: Октябрь инкыйлабыннан соң очар канатлары каерылган тау бөркетенә охшап калды. Публицистикасында шактый гына үрләр яуласа да, «Татар кызы», «Хәят», «Кадерле минутлар» кебек сәнгать әсәрләренә торырлык яңа җәүһәрләр тудыру аның өчен вөҗүдкә ашмаслык хыялга әверелде. «Хәят»ның икенче кисәге дә, «Урталыкта» романының дәвамы да күренмәде. Аның 1917 елдан соңгы иҗат җимешләрен нинди генә бизмәннәргә салып үлчәсәк тә, әсәрләреннән, бигрәк тә көндәлек һәм хатларыннан, тыенкы рәвештә акланмаган өмет, яуланмаган ирек, җәрәхәте җуелмас фаҗига сулышы бөркелеп тора. Егерменче еллар уртасында бер кардәшенә язган хатында ул ниндидер гайре табигый күтәренкелек белән: «Ярый әле әти белән Нәҗип абый (әтисенең энесе.— Автор.) үз үлемнәре белән үлеп калдылар»,— дип язды. Яше яңа гына 30ның тегеягына чыккан әдип өчен бу чын мәгънәсендә трагедия иде. 35—36 яшьләрендә инде аның иҗаты бернинди ташламаларны белмәгән сыйнфый гобедә тугланып, вульгар социологизм дөмбесе белән дөмбәсләнә башлады.

Сүзне якты сәхифәләрдән башлыйк һәм рухи чордашлары авазына колак салыйк. Олуг шагыйребез Х. Туфан үзе шәхсән белгән әдипне «классиканың рухи әмир-ханы», «әдәбият ханы» «Әмирхан» дип атады. Аның өлкән замандашы рухына «Могикан» дигән махсус поэма багышлавы матур бер гражданлык акты булды. Ф. Әмирханның гаять куәтле сатира таланты алдында баш игән, аның аерым әсәрләрен үзе чыгарган «Көлке капчыгы»на керткән Ш. Бабич, сүзләренә традицион җор мәгънә салып, болай дип язды: «Бу Фатих «мыскыл» бабында һәм әмир, һәм хан хәзер». Инде сүзне Ж. Вәлидигә бирик: «Фатих Әмирханыбызны мин, рөхсәт итсәгез, мәшһүр немец шагыйре Генрих Гейне белән янәшә куяр идем». Аксакал рәссамыбыз Б. Урманче фикере: «Татар әдәби теле бинасын төзүче олуг мөһәндисләрнең иң күренеклесе Фатих Әмирхан булды...»

Әдип иҗатына объектив һәм югары бәя бирүчеләр арасында без Ф. Бурнаш, Г. Сәгъди, И. Биккулов, Г. Гобәйдуллин һ. б. күренекле шәхесләрнең исемнәрен очратабыз.

Әмма шул ук чорларда, әле әдип исән вакытта ук, элементар әхлак нормаларыннан йөз чөергән башка шәхесләр дә сәрән сала башладылар. 1923 елның 16 июлендә Ф. Әмирхан, үзара килешенү буенча Татарстан китап комбинатына «Беренче сөю», «Мәст озатканнан соң» (әнисе үлү уңае белән язылган), «Китерегез миңа чәчәкләр!» исемле әсәрләренең кульязмасын тапшырды. Ләкин кульязмалар Татнаркомпрос редакцион коллегиясенең 1924 елгы 9 май утырышы карары белән авторга кире кайтарылды. Карар Г. Толымбайскийның тискәре рецензиясенә таянып чыгарылды. Әдипнең әлеге әсәрләрендә «дини фикер белән кочаклашу, мистицизм тойгылары» табып, Толымбайский, «хәзерге көндә боларны басып тарату сәяси җинаять булачак» дип белдерде[1]. 1925 елда Х. Вәли дигән берәү «Безнең юл» журналында болай дип язып чыкты: «Фатих Әмирхан буржуазный язучы булу гына түгел, яңа буржуаның тормышы, идеологиясен кристаллаштырырга тырышучы булып мәйданга атыла... Фатих Әмирханга кадәр сәнгатьне буржуазный тенденциячелек өчен корбан иткән һичбер татар язучысы юктыр»[2].

Бүтән шәхесләр дә, йөгәнсез инстинкларына куәт биреп, «теге дәвер» вәкиленә каршы кискен һөҗүмгә күчтеләр. Бу өлкәдә бигрәк тә Г. Гали текә үрләр «яулады». Г. Ниргъмәти дә үзеннән «лаеклы өлеш» кертте. Г. Ибраһимов исә, әдипнең йөзенә бәреп, «син — контрреволюционер!» дип нәгърә орды...

---

[1] Безнең юл, 1926, № 5—6, 43—44 б.
[2] Безнең юл, 1925, № 9—10, 55 б.

Нәтиҗә буларак, татар театры репертуарыннан Ф. Әмирханның пьесалары чыгарып ташланды, матбугат идарәләре аңа аркан борылды.

Ә бит Ф. Әмирхан әле 1920 елда гына «Китерегез миңа чәчәкләр!» дип шагыйранә күңел самимилеге белән җырлаган иде. Аңа чәчәкләр алып киләсе урынга шайтан таягы, тигәнәк, кычыткан, әрем сабакларының саргайган көлтәсен ыргыттылар.

Болары әле «могикан» үзе исән вакытта. Ә әдипнең җаны фани дөнья белән видагълашкач?

«Ул безнең өчен үле иде инде!» (1926 ел. Һ. Такташ). «Пролетар» әдип Ф. Сәйфи-Казанлы 1929 елда «Ике татар классигы» исемендәге тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы бастырып чыгарды. «Фатих Әмирханның әсәрләре безнең заман өчен бөтенләй ят һәм зарарлы», дип өйрәтте ул һәм әдипне «марксизм иләге астыннан иләргә» чакырды. Ф. Сәйфи ясаган «ачыш» буенча, Ф. Әмирхан 1905 елгы шәкертләр хәрәкәтендә, реакция дәверендә ачыктан-ачык милләтче һәм социалистларга дошман булган, Февраль һәм Октябрь инкыйлабларында «саф милләтче» булып, «эшчеләргә каршы фронтта барган кеше»[1]. Димәк, революция һәм эшчеләр сыйныфы дошманы!

Бу инсаниятсез оранга «сыйнфый уяулык күрсәтүче» тагын әллә нинди «кызыл авызлар»ның какофониясе килеп кушылды. Әдипнең «Фәтхулла хәзрәт» дигән классик әсәренә «татар буржуазиясенең фантазиясе» дигән мөһер сугылды. «Тигезсезләр», «Яшьләр» исемле драмаларыннан буржуазия сыйныфын идеаллаштыру «таптылар». Февраль революциясеннән соң язылган «Богаулар өзелделәр», «Март каһарманы», «Куркыныч дошманнар» (1913, әмма 1918 елда яңадан басыла) һ. б. әсәрләреннән буржуаз инкыйлабны алкышлау, социалистлардан, советлардан көлү дигән нәтиҗәләр чыгарылды. Язучының кайчандыр әйткән «минем буржуаз тынычлыкны сөя торган табигатем» дигән гыйбарәсен күпертеп, тузга язмаган мәгънәләр салып, яшерен сыйнфый дошманлык эзләп маташтылар, 21 яшеннән аяксыз калып, гомер буена тәгәрмәчле креслога береккән кешенең канлы гарасатка мөкиббән китмәве бу «принципиаль» әһелләрдә аптыраш уяткан, күрәсең.

Ф. Әмирханны тәкыйрь кылу, аңардан чын мәгънәсендә «карачкы» ясау утызынчы еллар уртасыннан башлап зарури йола, ритуал төсен алды. Әдипне шәхес буларак бәяләү ачыктан-ачык «әмирхан-офобиягә» әверелде. Түбәндәге мисаллар моны ачык күрсәтә. Мәсәлән, М. Укмасый-Зәбиров үзенең 1940 елда язылган «Истәлекләре»ндә әдипнең сыйнфый яктан ят икәнен күрсәтеп, аның мөлкәтле дин әһеле баласы булуына басым ясады. Шуңа өстәп, «аристократ» язучыны эшче-крестьян язучысына әйләндерергә, бай гимназистка типлары урынына асрау кызлар образы иҗат итәргә өндәвен, ләкин каршылыкка юлыгуын ачынып «искә төшерде»[2]. Шул ук 1940 елда кодасы Ф. Әмирхан II классик әдипнең шаукымы, «карасы» йога күрмәгәе дип, аннан гамәлдә баш тарту йөзеннән, адашын буржуаз агым вәкиле буларак гаепләде, аның төрле «чит» социологик тәгълиматлар өйрәнүеннән, «мистикага бирелүеннән» акылга сыймас мордарлык тапты[3]. Хәтта Ф. Әмирхан тарафыннан бик яшьләй үк таланты күрелгән һәм иҗаты хуплаңган М. Җәлил дә, Татар Язучылар берлеге житәкчесе буларак, «буржуаз әдип»нең тетмәсен тетүгә үзеннән өлеш кертте[4].

Ләкин бу өлкәдә иң нык «мөгез чыгаручы» кеше мәгълүм Толымбайский булды. Аның «хезмәт»ләрендә Ф. Әмирханны хурлау психоз төсен алды. 1936 елда ул «буржуа ялчысы»н фаш итеп бөтен бер монография язды һәм шул җирлектә доктор-профессор дәрәҗәсен дәгъвалады[5]. Толымбайский Ф. Әмирханны «юкагач намус» (урысча «липовый» була торгандыр инде), «либерал», «совет властеның дошманы», «эчке эмигрант», «үзенә бер төрле сменовехчы» дип атады, ошбу китабының бер бүлегенә «Пролетариат диктатурасына каршы» дигән исем куйды. Тәнкыйтьче Ф. Әмирханда «пессимизм», «эротика», «акылдан башка яшәү», «теге дөнья тормышы белән тынычланырга чакыру» кебек галәмәтләр тапты, «татар эксплуататорларының чын йөзләрен пәрдәләргә» тырышу «күрде».

Ф. Әмирханның, үлгәч мөселман зиратына мулла белән күмегез, дигән васыятен «уяу» Толымбайский болай дип «бәяләде»: «Ул үзенең үләксәсе белән Совет властена каршы демонстрация оештырырга тырышкан. Әмирхан үлгәч, татар буржуазиясе чынлап та Әмирхан үләксәсен контрреволюцион көчләрнең демонстрациясе өчен файдаланырга маташтьı». Сталинның цитаталары белән чуарланган бу «хезмәт», әйткәнебезчә, «фәннилек»нең иң югары ноктасын гәүдәләндерде.

Мондый «хезмәтләр»гә ул чорда «ихтыяҗ» зур булганлыктан, аларның күбрәк «тире саклау» өчен «иҗат ителүенә» шик калмый. Ә ул дәвердә болардан кайтышрак «гөнаһлар» өчен дә җаннар кыелмалы, башлар Себер китмәле иде. Шик юк ки, гомер йомгагы 1937 елга кадәр сүтелгән тәкъдирдә, аяксыз инвалид булуына карамастан, Ф. Әмирхан репрессияләнергә «тиешле» төп кандидатларның берсе иде. Моңа өстәмә дәлилләр дә бар. Мәсәлән, «Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы 10 нчы санында (70 б.) Г. Халит язган мондый юллар бар: «СССРда калган буржуаз милләтче Ф. Әмирхан революция елларында большевиклардан көлде, «Дошманнар», «Март каһарманнары» һ. б. әсәрләрендә революцион элемент-

---

[1] Ф. Сәйфи-Казанлы. Ике татар классигы турында. Казан, 1929, 35—37 б.
[2] Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (ТӘҺТИ) архивы, 16 — ф., 2 — тасв., 46 эш.
[3] ТӘҺТИ архивы, 16 — ф., 2 тасв., 41 — эш.
[4] Аерым алганда, сугышка кадәр төзелгән, әмма төп тиражы юк ителгән «Татар поэзиясе антологияс»ендәге М. Җәлил язган «Кереш сүз» күздә тотыла.
[5] Толымбай Гомәр. Фатыйх Әмирхан. Казан, 1936.

ларны мәсхәрә итәргә теләде. Моннан соң ул совет матбугаты шартларына җайлашкан булып, матбугат битләрендә советка каршы дошманлыгын һәм икейөзлелеген күрсәткәләп килде». 1937 елда әдипнең бертуган энесе, күренекле дәүләт эшлеклесе, элекке дипломат Ибраһимның кулга алынып, 1938 елда атылуында, ихтимал, бу казынуларның да йогынтысы булгандыр. Җитмәсә Ф. Әмирханның туганнан туган энесе Гамәрнең дә шул чорларда ук ГУЛАГ төпкелендә гомере өзелә.

Язмышның каһкаһәсе үзен озак көттермәде. «Сыйнфый сизгерлек» күрсәтүчеләрнең бер ишесе үз-үзенә кул салды, икенчеләре сәрхүшлектән койма төбендә җан бирде, өченчеләре «азатлык дөньясы» төзегән «даһиның» гильотинасында башын салды... 37 яшьлек Г. Толымбайский исә, җәбер-золымга түзә алмыйча, төрмәдә сорау алганда акылыннан язды. Кем белә, бәлки НКВДның тынчу подвалларында, кандалалы топчаннарында ятканда алар «буржуазия ялчысы»ның кайбер карашлары белән килешә дә башлаганнардыр...

Әлбәттә, бу юллар әллә кайчан дөньядан кичкән шәхесләрнең рухларын рәнҗетү, исәннәреннән үч алу теләге белән язылмады. Шагыйрь сүзләре белән әйткәндә, «әрвахлары булсын шат». Әмма мондый афәт яшәвебездә яңадан килеп сармасын өчен язмыш кисәтүен искә алу бик мөһим. Чөнки табигатьнең «һәр нәрсә өчен түләргә туры килә» дигән язылмаган алтын кануны бар.

Кырыгынчы еллар башында, гомерен мәгълүм органнар элмәге кисмәгән булу сәбәпле, бик авырлык белән генә булса да, Ф. Әмирханның исеме әкрен-әкрен халыкка кайтарыла, җыентыкларда, дәреслекләрдә һәм хрестоматияләрдә беркадәр уңай сыйфатта урын ала башлады. «Могҗиза» 1941 елда башланды. Бу елны мәктәп сериясе шәкеленнән Казанда әдипнең «Сайланма әсәрләре» дөнья күрде. Төзүчесе А. Шамов, кереш сүз авторы Х. Хәйри булды. Әлбәттә, биредә дә әдипнең «татар либераль бурзуазиясе карашларын чагылдыруы», язу ысулының «бик чикле буржуа реализмы», әсәрләренә «төшенкелек, мистик рух» хас булуы нык искәртелде. Ләкин шул ук вакытта Ф. Әмирханның «зур художник, атаклы язучы» булуы икърар ителде, иҗат көче «бигрәк тә иске җәмгыятьнең тончыктыргыч шартларын, кара якларын ачы тәнкыйтьләп, фаш итеп язуында, фанатизмга каршы» көрәштә чагылды, дип күрсәтелде.

1947 елда М. Гайнуллин белән Җ. Вәҗиева «Татар әдәбияты хрестоматиясе» бастырып чыгардылар. Анда шактый гына урын Ф. Әмирхан иҗатына да бирелгән иде. Биредә дә әдип әле һаман да буржуаз язучы, иске катлаулар тормышын тасвир итүче каләм остасы дип искәртелсә дә, нигездә, иҗаты уңай бәя алды.

Аннары Ф. Әмирхан иҗатына карата илленче елларның азагына кадәр ниндидер торгынлык хөкем сөрде, хәтта ки иске бәяләрне тергезү шаукымы да үзен сиздергәләп алды. Бу урында беркадәр фәлсәфи фикер йөртү сорала булса кирәк. Әлеге чорда зыялыларыбыз Ф. Әмирхан кебек язучылар иҗатына «яңача» бәя биргәндә «сакланганны Алла саклый» принцибыннан чыгып, үзләрен шактый җыйнак тоттылар — язучының шәхесе дә, иҗаты да бик катлаулы, каршылыклы, җитди эзләнүләр сорый торган бәхәсле өлкә дигәнрәк искәрмә артына сыендылар. Оригиналь, бөек шәхесләрнең тормыш юлы һәм иҗаты (Л. Толстойны гына искә төшерик) катлаулы һәм каршылыклы булмаса, аларның мәшһүр булуына шик уяна түгелме соң? Бәлки ШӘХЕСне беренче чиратта нәкъ шул сыйфатлар билгели дә торгандыр. Миңа калса, вулкан гөрелтесен хәтерләткән чорда яшәгән күренекле шәхесләрнең тәрҗемәи хәле вә гуманистик иҗаты алтатар көпшәседәй төз булса, күпкә гаҗәбрәк булыр иде. Һәр каршылыкны, һәр катлаулыкны тыгыз бәйләнештә өйрәнү, гадел бәяләү тикшерүченең намус эше булырга тиештер. Шулай булмаганда, бөтен «каһарманлык» өстән җаваплылыкны төшерүгә генә кайтып калачак. Билгеле, каршылыкларны бөтен тулылыгы белән аңлата белү, проблемага мөкәммәл анализ ясау ифрат зур профессиональ хәзерлек, эрудиция һәм, шулай дип әйтергә ярасa, «гыйльми намус» таләп итә. Әмма әлеге сыйфатларның җитенкерәмәве әле фаҗига түгел. Бу очракта безне бик гадел бер принцип — тулылык принцибы коткара. Ягъни язучы иҗатының безнең күңелгә хуш килгән сөземтәсен, «сайланма әсәрләрен» генә бирмичә, укучыга бөтен продукциясен тәкъдим итәргә кирәк. Менә ул чагында барлык каршылыклар да, катлаулылыклар да падишаһ таҗындагы асылташлар кебек елкылдап торачак!

Әдипне ятимләнә башлаган мәдәниятебез мәйданына тулысынча кайтару эше илленче еллар азагында яңа сулыш алды. 1957—1958 елларда Ф. Әмирхан сайланма әсәрләренең калын-калын ике томы дөнья күрде. Беренче җилдне төзүче һәм текстларны хәзерләүче — А. Шамов, икенчесенеке Х. Хисмәтуллин булды. Бу зыялыларыбызны тулы мәгънәсендә беренче «әмирхановедлар» — «әмирхановчылар» дип атарга мөмкин. Шул уңайдан 1961 елда Ф. Әмирханның 75 еллыгына Хәй аганың бик күркәм китапчыгы басылып чыгуын да әйтеп үтәргә кирәк. Бу рисалә әдип иҗатына иң объектив бәя биргән хезмәтләрнең берсе булып тора.

Ике томлыкка кайтыйк. Язучы мирасына гадел бәя бирү, аны әтрафлы барлау ягыннан мондый җыентык чыгару үз чоры өчен зур казаныш булды. Н. Хрущевның «җепшеклек» дәвере җимеше буларак, аның күңелгә бик ятышлы яклары да, цензор кайчысы телгәләгән сәхифәләре дә аермачык күзгә ташлана. Бер генә мисал. Ф. Әмирханның «Сабан туенда» дигән хикәясендә (1914) мондый юллар бар: «Теләсә нинди зур рус галимен, зур мөхәррирен теләсә нинди татар ломовой ямщигы көрәшеп ега ала бит. Һәм, билгакес, татарның теләсә нинди Гаспринскиен, теләсә нинди Гаяз Исхаковын теләсә нинди бер йөк ташучы рус көрәшеп ега ала...» 1958 елның 2 нче томында исә соңгы җөмлә болай дип «төзәтелгән»: «һәм, билгакес, татарның теләсә нинди галимен, теләсә нинди язучысын теләсә нинди бер йөк ташучы рус көрәшеп ега ала...» Күргәнебезчә, татарның иң мәшһүр шәхесләрен цензура бернинди тәкәллефсез умырып аткан. Исемнәре

телгә алынмаса да, берсенең галим, икенчесенең язучы дип аталуына шөкерана итик. Ә мондый имгәтүләрне саный китсәң, үзенә бер мәкалә килеп чыгар иде.

Әмма, шулай булса да, Ф. Әмирхан утызынчы елларда чумдырылган вульгар социологизм баткагыннан бөтенләй диярлек тартып чыгарылды. Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури кебек әдипләр белән янәшә куелып, башта демократ, аннары революцион демократ дигән бәяләмә алуга иреште. Әдипнең 75, 80, 90 еллык юбилейлары торган саен киңрәк билгеләнеп үтелде, аңа багышлап фәнни докладлар сөйләнде, күп санлы мәкаләләр дөнья күрде.

Ф. Әмирхан иҗаты җитди фәнни җирлектә өйрәнелә башлады. А. Сайганов бу юнәлештә — докторлык, Н. Вәлиев һәм Э. Сибгатуллина (Г. Камал иҗаты белән уртак рәвештә) кандидатлык диссертациясе якладылар, беренче икесенең күләмле монографияләре басылып чыкты. Әдип мирасын фәнни юнәлештә шулай ук Р. Гайнанов, А. Хисамов, Тургенев иҗаты белән чагыштырма рәвештә профессор Й. Нигъмәтуллина һ. б. өйрәнде. Юбилейлар уңае белән әдип иҗаты турында Х. Хисмәтуллинның инде атап кителгән брошюрасы һәм М. Мәһдиевнең популяр китапчыгы дөнья күрде. Ф. Әмирханның 100 еллыгы уңае белән зур фәнни конференция үткәрелеп, аның материаллары соңрак аерым җыентык булып басылып чыкты. 1986 елда әдип турында шушы юлларның авторы һәм Ф. Ибраһимова тарафыннан истәлекләр китабы, 1988 елда өченче зур «әмирханчыбыз» И. Нуруллинның «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән «Фатих Әмирхан» дигән хезмәте дөнья күрде...

Ләкин, шундый уңышлар булуга да карамастан, әдипнең бик күп әсәрләре кабат барлауны, яңача өйрәнүне, бәя бирүне көтеп архив киштәләрендә һәм гарәп-латин графикасында басылган иске журнал, мәҗмуга битләрендә чәчелеп-таралып ятты. Үзгәртеп коруга йөз тоткан чорда «дәвернең иң күренекле зыялы заты» (Б. Урманче) әсәрләрен күп томлы итеп чыгару инде көн тәртибенә бөтен зарурлыгы белән килеп баскан иде.

Бу мәсьүлиятле бурычны күмәк рәвештә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (ТӘһТИ) фәнни хезмәткәрләре Фатыйма Ибраһимова, Нажия Садыйкова, Зөфәр Рәмиев һәм Марсель Әхмәтҗанов башкарып чыктылар. Әйтергә кирәк, эш шома гына бармады. Беренче том 1984 елда ук дөнья күрсә дә, төрле техник сәбәпләр аркасында, өченче том (4 нче том 1986 елда чыкты) укучыларга 1989 елда гына барып иреште. Ләкин ахыр чиктә әдипнең 100 еллыгы уңае белән төзелгән, гомуми күләме символик төстә 100 табакка җиткән зур хезмәт рухи мәдәниятебез тарихында үзенең лаеклы урынын алды. Әйе, тираж мәсьәләсендәге сәерлекләр дә булмады түгел: мәсьәлән, әгәр I һәм II томнарның тиражы 10,5 меңешәр булса, IV томныкы 7,5 меңгә, соңгы III томның исә 5,3 меңгә кадәр төште. Чагыштыру өчен: шул ук чорларда басылган Тукай биштомлыгының уртача тиражы 16 меңгә җитә. Моның серләрен нәшрият һәм сәүдә хезмәткәрләре намусында калдырыйк.

Инде сыйфат, тулылык, камиллек дәрәҗәсенә күчик. «Әсәрләр»не төзүче һәм искәрмә язучыларның барысын да яхшы белгәнлегемнән, аларның фигыле тулаем дип әйтерлек минем күз алдымда үтте. Шуның шаһиты буларак, мин әлеге фәнни хезмәткәрләрнең ифрат зур җаваплылык тоеп эзләнүләр алып баруына, әгъла җиддият белән эшләүләренә гуаһлык бирә алам. Моның ише җыентыкларның сыйфат дәрәҗәсен билгелисең килсә, беренче нәүбәттә аларның искәрмәләр һәм аңлатмалар өлешенә күз салу да җитә. Чөнки текстология фәненә хәзерге көндә гаять зур әһәмият бирелә һәм олуг таләпләр куела. Ә миңа бу очракта безнең алга текстологик эшнең югары дәрәҗәдә башкарылуның матур үрнәге килеп басар.

Моңарчы тупланган тәҗрибәгә бер мыскал да хилафлык кылмыйча, төзүчеләр классик әдип мирасын гаҗәеп төрле жанрларга бүлеп урнаштыруның отышлы принцибын тапканнар. Әгәр беренче өч томга традицион төстә хикәяләр, роман, повесть, драма әсәрләре, публицистикасы сыйдырылган булса, дүртенче томда әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте, көндәлекләр, хатлар, әдипнең тормышына һәм иҗатына бәйле документаль материаллар аерым бабны тәшкил итә.

Һәр дүрт томга гүзәл бер уртаклык хас. Төзүчеләр теге яки бу әсәрнең язылу тарихына күзәтү ясаганда аның кайчан, ни шартларда язылуына, кайсы органнарда басылуына, заманында нинди бәя алуына, әүвәлге җыентыкларга кертәндә нинди «профилактика»га дучар ителүенә әһәмият бирәләр, беренчел чыганакка, әдип үзе исән вакытта басылган нөсхәгә мөрәҗәгать итүне төп кагыйдә итеп алалар. Икенче мөһим һәм принципиаль момент итеп архив материалларына, әдипнең яшәгән даирәсенә, хатлар аша аралашу ысулына, замандашлары һәм кардәшләре истәлек-информацияләренә киң планда мөрәҗәгать итүне күрсәтергә кирәк. Төзүчеләр Ф. Әмирханның ТӘһТИ архивында саклаган күп кенә иҗат җимешләрен беренче мәртәбә әдәби вә фәнни әйләнешкә кертәннәр, аларга тиешле аңлатмалар биреп, бик күркәм эш башкарганнар. Бу җәһәттән Ф. Ибраһимова, З. Рәмиев һәм М. Әхмәтҗановның алымнары аеруча хуплауга лаек.

Дүрттомлык, әлбәттә, әдип иҗатын әтрафлы тикшерүне максат итеп куйган фәнни хезмәт түгел. Аның төп бурычы — классик әдип әсәрләрен барлап, аларны киң катлау укучыларга рухи азык рәвешендә тәкъдим итү. Бу җәһәттән караганда галимнәребез үз максатларына ирешкәннәрме соң? Томнар буенча күзәтеп китик. Беренчесе «Хикәяләр» томы дип атала. Аның белән танышкан укучы алдында үз эченә тойгылар нәфислеге һәм кырыс-реалистик чынбарлыкны органик төстә берләштергән язучы дөньясы ачылып китә. Бу тылсымлы дөньяга әдипнең 1907—1922 елларда язылган 47 хикәясе алып керә. 1957 елгы басма 23 хикәя белән генә чикләнгән иде. Әлеге жилдне басмага әзерләү дәверендә Ф. Әмирхан кульязма фондының моңарчы кул житмәгән әсәрләренә, документаль материалларга мөрәҗәгать ителгән. Аларның күбесе

әдип мирасына, аның аз өйрәнелгән сәхифәләренә шактый ачыклык кертә. Мондый әсәрләрдән томга беренче мәртәбә кертелгән «Куркыныч дошманнар», «Хәкимә әби», «Зәгыйфь карчыкның корбаны», «Мостафа», «Март каһарманы», «Канвалардан берсе...» һ. б. күрсәтергә кирәк. Болардан тыш төзүче әлеге томга матбугатта беркайчан да дөнья күрмәгән, әдипнең архивында гына сакланып калган 12 хикәясен керткән. Алар аерым бер бүлекне тәшкил итә. Ф. Әмирхан бу томда укучы алдына әүвәлге мәртәбә тәрҗемәче сыйфатында да килеп баса. Аерым алганда, ул мәшһүр Андерсен әкиятләренә мөрәҗәгать иткән.

Икенче том язучының төрле чорларда, башлыча революциягә кадәр иҗат ителгән повестьлар, роман һәм драма әсәрләрен («Фәтхулла хәзрәт», «Хәят», «Урталыкта», «Яшьләр», «Тигезсезләр» һ. б.) берләштерә. Аларның барысы да, 1922 елда пьеса рәвешендә эшләнгән «Фәтхулла хәзрәт»не исәпкә алмаганда, язучының элекке җыентыкларына кергән, яисә аерым китап булып чыккан әсәрләр. Ә менә «Фәтхулла хәзрәт» драмасына һәм «Икенче пәрдә», «Уенда мөшарәкәт итәләр», «Уенга катыша» кебек тәмамланган пьесалар язучының архивыннан алынып, җилдләренә беренче мәртәбә кертелгән. Бу — басманың әһәмиятен күтәрүче факторларның берсе.

Әдип әсәрләренең өченче томын публицистика тәшкил итә. Биредә беркадәр чагыштыру таләп ителә. Әгәр Ф. Әмирхан «Сайланма әсәрләр»енең 1958 елда дөнья күргән икенче томында 124 публицистик әсәр урын алган булса, без күзәтү ясый торган җилдтә исә боларның саны 141 гә җиткән. Ләкин механик чагыштыру гына әле күп нәрсәне аңлатмый. Әлеге томга беренчел чыганаклардан гайре бер җирдә дә басылмаган бихисап парчалар кергән («71 нче ел коммунасы», «Идарәдән», «Истанбул шәһәре», «Москва шәһәре», «Менделеев», «Зилзилә», «Петербург шәһәре», «Дума ачылды», «Татар мөхәррирләре союзы», «Кызганычлар», «Шәрык клубында», «Милли кызлар гимназиясе мөнәсәбәте илә» һ. б.). Аларның гомуми саны 74 кә җитә. Димәк, томга кергән публицистик әсәрләрнең яртысы диярлек бүгенге заман укучысына әүвәлге тапкыр тәкъдим ителә. Өченче том Г. Исхакый исеменең совет чоры әдәбиятына уңай сыйфатта кергән басмаларның беренчеләреннән. Биредә Ф. Әмирханның «Гаяз», «Гаяз әфәнде шәрәфенә», «Йолдыз» һәм «Гаяз Исхаков» исемле мәкаләләре генә түгел, Исхакыйның «Алдым-бирдем», «Солдат», «Мөгаллим», «Зөләйха» кебек драма әсәрләренә рецензияләре дә урын алган. Бу уңайдан Г. Е. Зиновьев, К. Б. Радек кебек дәүләт эшлеклеләренә бирелгән кыскача искәрмәләр дә, яңа карашның чагылышы буларак, хуплауга лаек.

Дүртенче томга Ф. Әмирханның матур әдәбият буенча тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре, истәлекләре, көндәлек һәм хатлары кергән. «Әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте» дигән беренче бүлектә язучының татар әдәбияты һәм сәнгате, гомумән, әдәбият хәрәкәте үсешенә турыдан-туры кагылышлы 66 мәкаләсе урнаштырылган. Әгәр барлык бу материалга комплекслы планда карасак, милли әдәбиятның күп гасырлы тарихына карата Ф. Әмирханның мөнәсәбәтен ачык билгеләргә мөмкин. Томның икенче бүлеген «Куен дәфтәрләре» алып тора. Укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителгән көндәлек Ф. Әмирханның тормышын һәм иҗат юлын өйрәнүгә бай материал бирә. Аны укыгач, төрле чорларда Ф. Әмирхан адресына әйтелгән тискәре фикерләрнең вульгар социологизм чире икәненә тулысынча ышанасың. Өченче бүлектә әдипнең 1902—1925 елларга караган 60 хаты урнаштырылган. Хатлар (аларның бик күбесе инде эзсез югалган) язучының сайланма әсәрләренә беренче тапкыр кертелә, ә 43-е, гомумән, беренче тапкыр басыла. XX йөз башында татар җәмгыяте, әдәбияты тарихы буенча Ф. Әмирхан хатлары бай чыганак буларак аеруча кыйммәтле: аларда беркайчан да теркәлмәгән мөһим фактлар бар. Материалларга бирелгән тулы һәм бай аңлатма-искәрмәләр бу җилднең сыйфатын яңа баскычка күтәрәләр.

Югарыда куелган соравыбызга кабат әйләнеп кайтыйк. Дүрт томлыкны төзегән галимнәребез үз максатларына ирешкәннәрме соң? Әчке бер сыкрау белән булса да, әйтим — әлегә мин бу нәтиҗәне ясый алмыйм. Әйе, әгәр сүзне беренче ике том турында гына алып барсак, бу сорауларга, беркадәр чыгармалар белән булса да, мотлака уңай җавап бирергә мөмкин булыр иде. Әмма өченче һәм дүртенче җилдләр турында моны әйтергә тел бармый. Ә бит бу җыентык инде традициябезгә әйләнгән «Сайланма әсәрләр» түгел, бәлки «әсәрләр» дип аталып, әдип иҗатының камил тулылыгын дәгъва итә. Менә монда инде без югарыда зикер кылынган «профилактика» мәсьәләсенә маңгаебыз белән килеп бәреләбез. Тагын сораулар туа. Кем гаепле? Төзүчеләрме? Ашыкмыйк. Чөнки миңа мәгълүм булганча, өч матбага — «Әлислах», «Аң», һәм «Кояш»ны гына күздә тотканда, Ф. Әмирханның публицистикасын тәшкил иткән, әмма өченче томга кермәгән җәүһәри әсәрләрдән кимендә янә бер том төзеп булыр иде. Тик ни аяныч! З. Рәмиев үзе туплап эшкәрткән материалларының күпмесен сыйдыра алмады. М. Әхмәтҗанов төзегән дүртенче томны кисү исә Ф. Әмирханның шәкерт вакытында һәм НЭП чорында язган «усал» көндәлекләрен, мәдрәсәдә уку чорында ук багышлап язылган мәдхияне, Г. Исхакый исемен телгә алган материалларны һ. б. шундый «шикле», «хәвефле» документларны кертмәү яисә гарипләү ысулы белән башкарылды. Ә бит 1921—26 елларда язылган көндәлекләрне (кара: «Идел», 1990, № 8, 26—27 б.) әдипнең гражданлык каһарманлыгы дип атарга мөмкин. Ф. Әмирхан Г. Толымбайский каһәрләгән «югагач намус» түгел, бәлки татар интеллигенциясенең шул гарасат чорында намус аклыгы булды. Әдип үз дәверенең җимергеч, кешелексез сәясәтенә, тоталитар хакимияткә, аның икейөзлелегенә, җинаятьчел гамалләренә үтергеч бәя бирүе белән Ю. Фучикның «Элмәккә башны тыккан килеш репортаж», М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н хәтерләтә. Ул гүяки «кешеләр, уяу булыгыз» дип кисәтә. Үз заманында шундый туры сүзле,

кыю көрәшчеләребезнең аз булуы соңыннан бик аяныч нәтиҗәләргә китерде: без дистәләгән еллар күзәтеп килгән мәсләксезлек, намуссызлык, миһербансызлык, ике катлы әхлак, манкортлык һәм икейөзлелек вирусы берничә буын кешеләренең күзәнәкләренә кадәр үтеп керде. Чагыштырмача аз кыркылган беренче том да афәттән имин калмаган: «әсәрләр»енә беренче тапкыр кертелә торган «Ай астендәге Зөһрә кыз» хикәясенә өч кисәктән торган «Халык кызлары» әсәренең ике өлешенә, «Сөембикә», «Картада оттырылган Зөлхәбирә»гә бисәбәп урын бирелмәгән. Хәер, сәбәбенә төшенергә була: Сөембикә образы татарның мөстәкыйль дәүләтчелеге булган дәверен искә төшерә... Мисалларга кытлык юк, аларны урысча әйткәндә, «до упора» дәвам итәргә мөмкин булыр иде.

Сизәм, мондый сорау да туарга мөмкин: бер томга 25 табактан да артык күләм бирелми, ә бу очракта томнарны дүрттән, ягъни 100 табактан арттыру «планда» каралмаган, бу мөмкинлеккә дә шөкерана кылырга кирәк, янәсе. Алайга китсә, монда да берничә каршы сорау бар. Без классик язучыларыбыз әсәрләренең тулы җыелмасы чыгаруны нинди «якты киләчәккә» калдырабыз соң? Аңарчы татарча язылган текстны ана телендә укырлык милләттәшләребез калырмы? Һич югында йолкынып төзелгән томнарның керешендә генә булса да, язучының бу әсәрләреннән кала тагын берничә йөз әсәре барын искәртеп, укучы күңеленә оптимистик «оеткы» салырга кирәк түгелме идеме икән?

Җае килгәндә шуны да искәртик әле: ТӘһТИдә икенче бер классигыбыз Г. Исхакыйның 8 томлык әсәрләрен чыгару күздә тотыла. Афәрин, әлбәттә. Ләкин бит бу әдәби дәрьяның публицистик әсәрләреннән генә дә ким дигәндә 8 том җыярга була. Ә болардан тыш Исхакый күпме романнар, повестьлар, хикәяләр, пьесалар иҗат иткән, рецензияләр, хатлар язган кеше! Димәк, әсәрләрне тагын инерция буенча тунаулар, йолкулар, телгәләүләр сыйфатындагы Газраил көтә.

Сүзебезне өзелгән җиреннән ялгап китик. Димәк, ничек кенә боргаласаң да, нәтиҗә бер: классикларыбызның әсәрләрен элек ни рәвешле имгәтеп килгән булсак, бүген дә кимен куймыйбыз. Бу «закончалык» Г. Тукай томнарына да, Г. Ибраһимов җилдләренә дә, Ф. Әмирхан әсәрләренә дә бердәй карый. Эш шуңа җитте ки, әсәрләр мәҗмугасын төзүче иптәшләр алдан ук «моны барыбер үткәрмиләр» дигән шиксыз диагноз куеп, шактый гына җәүһәрләрне игътибарларыннан мәхрүм итеп килаләр.

Тулы мирасны бирмәү — бик аяныч фал. Иртәме-соңмы, ул барыбер алама нәтиҗәләргә китерәчәк. Шуннан сорау туа: нәрсә — хәзер инде заман аршыны белән генә үлчәргә өйрәнеп җиткән зыялыларыбыз һ. Такташның «Солтангалиев кебек этләргә пуля саклап йөри башлавын» яңа җыентыкларына кертмәячәкләрме? Замана э үзгәрде бит! Ә хакыйкать исә шунда: җилнең юнәлеше үзгәргән саен мәсләк һәм кыйбла алыштырмасаң, яңа «төзәтмәләр» кертүгә бернинди дә ихтыяҗ калмас. Нәшрият мөхәррирләрен Алла урынына күргән галимнәребезгә үз карашларын яклау өлкәсендә кыюрак булу кирәк иде.

Гомумән алганда, «Дүрт томлык» — Ф. Әмирхан иҗатының төрле төстәге тылсымлы чәчәкләреннән үрелгән нәфис букет, гөлләр бәйләме. Шулай да өстә телгә алынган «китекләргә» тагын берничә «ярык» өстәмичә китеп булмый. Томнарның сәнгатьчә эшләнеше тонык, сирәк-мирәк урнаштырылган сурәт, документларның сәнгати сыйфаты җанга азык бирми. Сәяси мөхитнең туктаусыз демократлашуы шартларында «кичә» биргән бәяләр урынына яңа «берәмлек» кертү зарурияте дә үзен көннән-көн куәтлерәк сиздерә. Болар бигрәк тә «буржуаз», «ак эмигрант», «солтангалиевче» һ. б. шуның ише «йодрыклы» төшенчәләргә карый. Минем уемча, классик әдибебез булган Ф. Әмирхан әсәрләрен җиз иләктән иләүдән туктап, кечелеген һәм олуглыгын, катлаулылыгын һәм каршылыкларын тыгыз бердәмлектә чагылдырып, җете вә контраст буяуларга манчымыйча чыгару якын киләчәк эше булырга тиеш. Аның бай мирасы кимендә 6—7 том күләмендә дөнья күрергә лаек. Бәлки суверен Татарстан республикасының якын араларда төзелүе күздә тотылган үз фәннәр Академиясе бу мокатдәс эшкә яңа этәргеч бирер, «яшел ут» кабызыр.

**Равил ӘМИРХАН,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ИШАН ОНЫГЫ

Казан утлары» журналыннан күренекле язучыбыз Атилла Расихның «Ишан оныгы» романын зур кызыксыну белән укыдым. Әсәр аталышы белән дә күңелне үзенә җәлеп итә. «Ишан оныгына нинди бәхет эләкте икән, әллә ишаннан мирас булып бирәр төрле зур байлык калды микән?» — дип уйлыйсың... Ә оныгының язучы Атилла Расих булып китүенә нәрсәләр йогынты ясаган?

Безнең татар халкында кешене характерлаганда аның нәсел-ыруына күз салалар. Чыннан да, әдипнең бабасы Зәйнулла ишан ниндирәк кеше булган соң?

Зәйнулла хәзрәт турында төрле фикер язучылар бар. Риза Фәхретдинов 1917 елда «Вакыт» типографиясендә 105 битлек бер китап бастыра. Ул «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» дип атала. Риза Фәхретдинов аны бары уңай яктан гына искә ала, иткән изгелекләрен саный һәм «хакыйкать хәлдә Зәйнулла хәзрәт хакында язылган нәрсәләрнең иң дөресе Муса әфәнде язган нәрсәләр булыр, иншаа алла», — ди. Ә Муса хаҗи Зәйнулла ишанның якын туганы һәм дусты була. Ул ысул җәдитнең таралуына ишанның хезмәте гаять зур булганлыгын әйтә.

Мөхәммәт Нәҗип Түнтәри дә: «Егерме ел элек күргән нәрсәсен онытмас. Кирәкле китапларны һаман эзләп сорашып алып торадыр иде... Китап өчен акча кызганмады», — дип искә ала Зәйнулла ишан турында. («Әлдин вә әдәп» 6—7 саннар, 1917). Ул сөргендә дә вакытын бушка уздырмый, күп китаплар укый, шуның аркасында сөргеннән галим булып кайта. Бу турыда Рәхимҗан Атнабаев «Тормыш» газетасында яза (1917 ел, 600 сан).

Гади халык аның киң күңелле булуы, авыруларны (хәтта акылына зыян килгәннәрне) дәвалавы, Тибет медицинасын яхшы үзләштерүе, кешегә кулдан килгәнчә ярдәм итүе турында сөйли. Әнә шундый күп мәгълүматлар белән танышкач, Атилла Расих бабасының прогрессив карашлы, халыкка хезмәт итү юлыннан барган бер шәхес булуы ачыклана. Башкортстан галимнәре дә аның нәкъ шундый кеше булуын таныйлар. «Совет Башкортстаны» газетасы үзенең 1986 елгы бер санында нәкъ шул хакта язып чыкты.

А. Расихның тормышында әнисе — Зәйтүнә Мәүлүдова зур урын били. Әсәр аның көндәлек хатирәләре белән җанлана. Бу гади генә көндәлек түгел, ә шул чорның тарихи көзгесе дә. Әсәр турыдан ярып сөйләве белән үзенә җәлеп итә, шунлыктан геройлар белән бергә без дә кайгырабыз, чын күңелдән шатланабыз. Зәйтүнә Мәүлүдова, нинди генә авырлыклар булса да, курыкмыйча җиңә белә. Автор аны шулай сурәтли: «Ул — көчле, тормыш чыбыркылауларына каршы тора алган, буранга каршы барудан курыкмый торган кеше». Халык дошманы хатыны санап, мәктәптәге укытучылык эшеннән чыгарсалар да, ул коелып төшми, ничек кенә булса да авырлыктан чыгу юлын эзли. Авылга кайтып балалар укыта, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, күңелен төшерми.

Зәйтүнә Мәүлүдова яшьлегендә Буби мәдрәсәсендә белем ала. Соңыннан, Троицкида кызлар мәктәбендә укыту белән бергә, Гыйбад Алпаровтан дәресләр ала. Хаж сәяхәте вакытында да иң беренче максаты уку була. Акча җитмәүчелек тә комачауламый. Хаж сәяхәте вакытында әтисе, әнисе һәм туганнары да бушка вакыт уздырмыйлар: гарәп тормышы, Мәдинәдәге, башка шәһәр һәм авыллардагы тормыш белән танышалар.

Беренче Бөтендөнья сугышы башлануның хаж сәяхәте вакытына туры килүе алар өчен зур авырлыклар тудыра. Ашау-эчү яклары авырая, торак өчен дә түләргә кирәк, чит илдә булса да, әтисен солдатка алабыз, дип торалар.

Роман-истәлек буларак Зәйтүнә Мәүлүдованың Габдулла Тукай белән үзара мөнәсәбәтләре сурәтләнгән урыннарны аеруча күңел биреп укыйсың. Вакыйгалар Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев һәм башка тарихи шәхесләр белән бәйләнештә бирелә. Шушы әсәрне Тукай яратып йөргән кыз — Зәйтүнә Мәүлүдованың улы — Атилла Расихның язуы аңа булган игътибарны тагын да арттыра. «...Тукайның әниемә булган мәхәббәте кайнар, сәер һәм яшерен була», — диелә әсәрдә.

Зәйтүнә Мәүлүдова турында аерым әсәр язарга мөмкин түгел иде микән? Бу фикер «Казан утлары» журналын (1990 ел, 10 сан) укыгач, тагын да көчәйде. Билгеле булганча, анда Зәйтүнә Мәүлүдованың язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйга хаты, шул хатка Гаяз Исхакый җавабы басылган иде. А. Расих хатларны журналда чыгарып дөрес эшли. Бу хатлар бик тә кыйммәтле, чөнки алар тарихи вакыйгаларны тагын да тәгәлрәк күз алдына китерергә ярдәм итә.

Әйе, А. Расих гаиләсенең Тукайга игътибары, хөрмәте зур. Бу уңайдан Зәкия Рәсүлева-

ның (Зәйтүнә Мәүлүдованың килене) «Тукай эзләре буйлап» исемле китабын искә төшереп үтмичә булмый. Яраткан шагыйребезнең исемен мәңгеләштерү, үзенең каенанасы Зәйтүнә Мәүлүдовага олы ихтирам йөзеннән ул шундый зур мактаулы эшне башкарып чыккан. Бу китап — олы сәяхәт, күп кешеләр белән очрашу, аралашу, Г. Тукайның тормышын һәм иҗатын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсе. Татар халкының «килен — каенана туфрагыннан» дигән сүзләре Зәкия ханым Рәсүлевага бик тә тәңгәл килә. Киләчәккә шундый исталек калдырганы өчен аңа чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә.

Яңадан әсәргә әйләнеп кайтыйк.

«Гаиләбезнең укуга булган мөнәсәбәтен һәм шул юлдагы кичерешләрен күз алдымнан уздырам да, ирексездән үзебезне кыяларга үрмәләүче альпинистлар белән чагыштырасым килә. Мең төрле газап-җәфалар чигеп булса да, уку, белем алу иң олы максат итеп куелган. Күрәсең, ул кече яшьтән үк канга сеңгәндер». Әсәрдәге менә шушы юллар күп нәрсәне аңлау өчен ачкыч бирә.

«Ишан оныгы» романында автор тарихи шәхесләргә шактый урын биргән. Киләчәк буыннар өчен болар бик тә кирәк. А. Расих ул тарихи шәхесләрне үзе күреп белә, алар турында үз фикерен яза.

1924 елда Казанда җырчы Әлмөхәммәдев, композитор Солтан Габәши белән очрашуы аның аеруча исендә кала. Чөнки Атилла заманында үзе дә музыка белән мавыга.

Ә Абдулла Алиш авторның башлангыч иҗат чорында таянычы, рухландыручысы була. Әсәрдә аның гади һәм күңелле, ярдәмчел булуы турында сөйләнә.

Фатыйха Аитова турында әсәрдә күп язылмаган. Шулай да ул битләрне кызыксынып укыдым. Ф. Аитова үзенең көчен, энергиясен, байлыгын мәгариф өлкәсенә бирә. Ә бит кызлар өчен җәдит мәктәбен ачу җиңел булмый, бик күп каршылыклар аша үтәргә кирәк була. Ф. Аитова татар мәгарифен, мәдәниятен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Шундый батыр татар хатын-кызы, мәгърифәт йолдызы Фатыйха Аитова исеме алдында баш имичә мөмкин түгел.

Дин галиме Муса Бигиев турында да искә алына әсәрдә. Ул унынчы елларда Петербургта мулла булган кеше. «Муса Бигиевне мулла дип атаудан элегрәк, интеллигент дип әйтергә булыр иде», — дип йомгак ясый автор. Чөнки ул башка муллалардан үзенең эчке культурасы белән аерылып тора.

«Чаян» журналында эшләүче Һади Такташ белән очрашу, шул ук журналда беренче тапкыр «А. Расих» имзасы белән хикәя басылып чыгу шатлыгы да авторның исендә яхшы сакланган.

А. Расихның «Ишан оныгы» әсәрен укыгач аңладым: чыннан да, Зәйнулла бабасыннан оныгына бик күп байлык, зур мирас калган икән. Ул — гомер буе белемгә омтылу, халкыңа мәгърифәт өстәү. Шушы юлдагы каршылыклар белән көрәшә-көрәшә, автор тормышта үзенең чын урынын тапкан, күренекле әдип булган.

Равия ЗАРИПОВА,
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм тарих
институты аспиранты.

# КҮЗЛӘРЕМНЕ АЧТЫ

Тәүфикъ Әйдинең былтыр «Казан утлары»нда басылган «Елан угы» романын, актарып кына чыгыйм әле, диеп кулыма алган идем. Әмма әсәр мине беренче битеннән үк үзенә җәлеп итте. Әмударьяның кайнап торган чоңгыллары кебек, бөтереп алды да Урта Азиянең серле күренешләре дөньясына алып керде. Кардәш үзбәк халкының 1920 елгы үзара бәрелешләре, милли байсезлеге өчен кан коюлар, төрле төркемнәрнең хөрриятне яклауга мөнәсәбәте, уй-хыяллары һәм гамәлләре белән танышу мине гаҗәпсендерде дә, сокландырды да. Дөресен әйтим, якыннан белмәгәннәрдер инде, мин каләмдәшем Тәүфикъның мондый әсәр язуын көтмәгән идем.

Мин үзем 1947—1982 елларда Үзбәкстанда яшәдем, шул дәвердә Фирганә уйсулыгында кемнәр белән генә аралашмадым — күпме үзбәк кардәшләргә йортлар салышмадым да, өйләрен тәртипкә китерешмәдем. Бергә эшләү, бергә ял итү, күрше һәм хезмәттәш булу, мәҗлесләрдә бергә чүкердәшү, җырлашу безне дуслаштырды, мине аларның гореф-гадәтләре, йолалары белән якыннан таныштырды, телләрен үзләштерүгә этәрде. Т. Әйди анда минем шикелле утыз биш ел түгел, бер-ике ай да төпләнеп яшәмәгән иң. Менә шуны белгәнгә дә, аның Төркестан турында язуына югартын караганмын, ахры. Миңа нинди яңалык ача ала инде ул, янәсе! «Елан угы»н укый башлагач исә, гаҗәп ки, мин үзбәк халкын яңадан ачкандай булдым. Борынгы заман төрки шагыйре Йөгнәки, тарихи трактатлар язучы галим Даниш, гасырыбыз башындагы Бохара чәйханәләре, мәдрәсәләре, сәүдәгәр һәм дәрвишләр, укымышлылар һәм диһканнар, һөнәрчеләр һәм кәтүчеләр — кем генә юк бу әсәрдә! Үзтирәлеге, микроклиматы, йолаларымнары, риваятьләре белән сурәтләнә алар. Шундый итеп сурәтләнә — аннан төрле мәгълүмат алып кына калмыйсың, кискен бәрелешләргә кергән каһарманнарның кайсы өчен көенеп, кайсы өчен сөенеп укыйсың романны. Катлаулы төеннәр, күңелне билəп торган серләр әсәр тәмамланганчы сине киеренке халдә тота. Моңа геройларның җанлы гәүдәләндерелүе, вакыйгаларның тыгыз һәм

ышандыргыч сурәтләнүе сәбәп, билгеле Т. Әйди каһарманнарының тышкы кыяфәтләрен һәм эчке дөньяларын матур тасвирлый, табигать күренешләрен ачык итеп күз алдына китереп бастыра. «Юл буендагы биек, ерактан караганда жиргә кадап куелган каз каурыйларын хәтерләткән байтирәкләр, «мич төбедәй кызган саргылт-соры дуваллар», «кавын кабыгыдай сыек саргылт яктылык» — бу юллар хыялымда Урта Азияне жанландырмый калмады. «Тигәнәк чәчкән беркайчан да йөзем жыя алмаячак», «ике яхшы бер сәкегә сыя, ике яман бер шәһәргә сыймый», «өрекне күмер дип читкә тондыру көлке», «телең биктә тотгыл — тешең сынмас» — бу гыйбарәтләрдә образлылык, жирле буялар, борынгылык төсмере ярылып ята. «Елан угы»нда мондый сурәтле тасвирлау әз түгел. Романда үзбәк, казакъ, татар, урыс кешеләре чагылдырыла, 1920 ел яктыртыла. Төрле милләт вәкилләре кайнаган Бохара хәятен, андагы тел чуарлыгын гәүдәләндерү, шул ук вакытта әдәби телебез сафлыгын саклау язучы өчен ансат эш түгел. Тәүфикъ бу бурычны уңышлы хәл итә, туган әдәбиятыбызда Төркестанны сурәтләгән З. Бигиев, Ә. Айдар, Ш. Усманов традицияләрен истә тотып, үзбәк-казакъ сүзләрен чама хисен югалтмыйча гына куллана, шул ук вакытта кардәш халыклар вәкилләрен табигый хәлендә күз алдына китерергә дә мөмкинлек бирә.

«Елан угы» — мажаралы әсәр, бер үк вакытта ул — документаль сәяси роман. Шушы ике сыйфаты белән аны мәшһүр урыс язучысы, күпләр ябырылып укый торган Юлиан Семенов китапларына тиңләргә мөмкин. Әйтергә кирәк, Ю. Семенов миллионнарга яхшы билгеле тарихи шәхесләрне — фашизм юлбашчыларын, акгвардияче генералларны сурәтләп, ягъни укучыларны әллә кайчаннан кызыксындырган, серлелек пәрдәсе белән мавыктырган вакыйгаларны, шәхесләрне гәүдәләндереп уңыш казана. Татар язучысы бөтен дөньяны шаулатып Геринг, Канарис, Шелленберг һәм шундый бүтәннәр белән эш итми — ул үз милли эшлеклеләрен яки шулай ук әз билгеле Шәрекъ каһарманнарын әдәбият мәйданына алып керә, милләттәшләребезне дөньяга таныту максатын куя. Шуңа күрә, Т. Әйди романын алдан ук жилкенеп, комарланып көтеп торучы миллионлаган укучы юктыр. Аңа үз укучысын үзенә булдырырга туры килә. Моңа ул әсәрендә кызыклы каһарманнарны, кызыклы вакыйгаларны оста гәүдәләндерүе белән генә ирешә ала.

Шунысы күңелле, «Елан угы»нда Т. Әйди максатына тулысынча ирешкән. Мажара яратучыларга романда кискен бәрелешләр, яшьләргә — мәхәббәт кыйссалары, житди укучыларга сәяси бәхәсләр, акыл көрәше житәрлек. Мине исә, болардан тыш, Урта Азияне искиткеч тирән, күпкырлы, гыйбрәтле ачуы белән дә жәлеп итте бу роман. Шунда утыз биш ел яшәп тә белмәгән нәрсәләрне мин, «Елан угы»н укыгач, тагын да яхшырак белдем. Күзләремне ачуың өчен рәхмәт, Тәүфикъ, киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешүеңне телим!

Сафуан МУЛЛАГАЛИЕВ,
Казан.

# ЯЗМЫШЛАР ҺӘМ ЯЛГЫШЛАР

«Елан угы» романын сәләтле каләм иясе язуын укый башлагач ук тоясың. Анда комиссар Шиһабетдиновның үтерелүе белән башланган вакыйгалар безне бик тиз үзенең чоңгылына бөтереп алып кереп китә.

Романда күтәрелгән мәсьәләләр Урта Азиядә инкыйлап елларында яшәгән милләттәшләребезгә кагыла, ләкин ул безгә дә кызыклы. Чөнки ул замандагы хакыйкать безгә әлегәчә бозылган хәлдә генә килеп житә алды.

Мин шушы якларда туып үскәнлектән һәм мондагы тормыш шартларын шактый ук яхшы белгәнлектән, «Елан угы» Төркестандагы вакыйгаларны әйбәт һәм дөрес яктырткан татар романы дип исәплим. Бигрәк тә мондагы татарларның кайсы якта, жирлектә торырга тиешлеген Т. Әйди тәгәл чамалаган һәм әтрафлы чагылдырган, киләчәктә аларга нишләргә кирәклеген дә зирәк фараз иткән. Әсәр безнең өчен әнә шул ягы белән кыйммәтле дә.

Романда үзбәк милләтчеләре һәм контрлары тарафыннан татарларга атап әйтелгән бик әче фикерләр бар. Бу сүзләрнең укучы аңында төрле карашлар тудыруы ихтимал. Мәсәлән: «Автор үз халкына таш атарга юл ача, акыллы эшләми!» — диярга мөмкиннәр. Ләкин татарны гаепләү фикерләре шул заманда ук әйтелүе хак. Үзбәк контрлары, милләтчеләре тарафыннан гына да түгел! Без бүген егерменче елларда милләттәшләребез чәчкәнне урабыз — татарларга Урта Азиядә төксе караш әнә шул дәвердә тамыр жибәргән. Хәзер үткәндәге абыну-сөртенүләрне яшергәнче, киләчәк өчен шуннан гыйбрәт алу хәерлерәк. Узгандагы хаталарны ятлар төртеп күрсәткәнче, үз язучыбыз сурәтләве мең тапкыр яхшырак. Без капчыкта ятмыйк! Т. Әйди мәсьәләне романында кыюлык белән күтәреп чыккан һәм бик дөрес эшләгән. Гаепне моннан соң да яшереп яту хакыйкатькә дә, гаделлеккә дә хезмәт итми. Соң булса да, тәүбә итү уң булыр. Бу үзе үк кардәш халыкларда канәгатьлек хасил итәр һәм безгә карата хөрмәт, ышаныч хисләренең кайтуына булышыр.

Империя безне һәрвакыт үз максатында файдаланып килде. Аның барлык әшәке гамәлләрендә татарлар катнаштырылды. Хәзер инде безгә моны аңларга вакыт. Ятлар өчен утлы күмер чүпләү татарны яхшылыкка илтми. Болай ерак китеп булмый. Үз максатыбыз, үз юлыбыз алга чакырсын. Әйтик, бүгенгесе

көндә Татарстаныбыз мөстәкыйльлеген игълан итте. Ләкин аны гамәлгә ашыру бик кыен. Чөнки республикада татарлар андагы барлык халыкның яртысы чамасы гына. Шул шартларда Татарстанга бүтән милләт вәкилләрен эшкә чакырып китерү дәвам итә. Мондый көннәрдә яңадан-яңа Шиһабетдиновлар, Байкучатовларның теләсә кайда каңгырып йөреп, андагы жирле халыклар тормышына тыкшынуы, көчләрен генә түгел, газиз гомерләрен дә шунда бирүләре акланмый. Аларның үз тарихи ватаннарына кайтуы, шунда тупланып, милли тормышны тергезүләре кирәк. Тәүфикъ Әйди «Елан угы» романында бу мәсьәләне кабыргасы белән куя һәм шуның белән аеруча мәртәбәле бер бурычны исебезгә төшерә.

Әсәрнең тулы күләмдә аерым китап булып басылып чыгуын теләп калучы

Хәмит ТӨХФИ,
Ташкент.

# СӨЕНЕП УКЫДЫМ...

Батулла туган!

«Юл буенда зәңгәр чәчәк» — безнең татар әдәбиятының зур уңышы. Безнең әдәбиятта шундый төгәл такт, югары культура һәм искиткеч көчле ихласлык белән язылган әсәрләр сирәк. Милли гореф-гадәтләрне шундый төгәл итеп күрсәтә алгансың, геройларың шундый тере һәм тормышчан.

Сугыш елларындагы хәлләр, житәкче «явыз»ларны ачык һәм ышандырырлык итеп яза алгансың. Балалар, жәнлекләр дөньясын, чынбарлыктагыдан да реаль әкиятләр яза алуыңа сокланып туймый идем моңа кадәр, бу әсәрең сине татар әдәбиятының иң беренче сафында баручы язучылар рәтенә бастырды.

Аллаһ Тәгалә сиңа сәламәтлек һәм илһам бирсен.

Миргазиян ЮНЫС.
Мәскәү.

## Фәнис Яруллин

# АВЫЛНЫҢ ҖИДЕНЧЕ ЧИШМӘСЕ



Су буенда өзеп-өзеп сандугач сайрый. Аның жыры талгын гына аккан Шушма елгасына кушыла. Елгада кояш йөзеп йөри. Җир белән күк тоташкан. Җир белән күкне тоташтыручы сукмак буйлап бер кыз бала килә. Аның иңнәрендә көянтә-чиләк. Менә ул сандугач жырын ишетеп тынып калды, чиләкләр тавышы жырчы кошны куркытмасын өчен, аларны кулы белән тотты. Җырчы кош, кызны тагын да сокландырырга теләгәндәй, талның биегрәгенә кунып сайрарга тотынды. Үзе талпына, талпынган саен тавышы ераккарак китә. Әйтерсең, ул үз жырын бөтен дөньяга ишеттерергә тели.

— Их, синең кебек жырлап кына яшәсәң иде! — диде кыз көрсенеп. — Җырлап таңны аттырасың, жырлап кояш баетасың. Ә менә безнең — кешеләрнең жирдә эше күп. Минем бүген егерме көянтә су китерәсем бар. Миңа әти шулай кушты. Бакчага су сибәрсең, диде.

Бала күңелендә табигать һәм жыр бергә буталды. Кояш нурларын күктән, судан аерып алып булмаган кебек, жырны да кеше жаныннан аерып булмый. Җыр күңелнең төрле халәтләрендә төрлечә бәреп чыга. Әнә су буена төшкән кыз да сандугачка кушылгандай жырлап жибәрде:

Яши иде бу дөньяда
Нәни генә Нуржамал.
Келәм суга матур-матур,
Сере дөньяны аңлатыр —
Келәм серен белүе авыр.

Келәм серен ачкан кеше
Үлем китерә ханга.
Тик бик авыр аны белү,
Ханның сараена керү —
Үлем китерү ханга...

Бу жыр аның күңеленә кайда-ничек сеңгәндер, кыз аны белми. Бәлки берәр әкияттән укыгандыр? Алай дисәң, көен кем өйрәткән? Шушы жырны еш жырлагангамы — аны авылда нәни Нуржамал дип йөртәләр. Бу жырда ниндидер яшерен сер бар. Ул үзен серле келәм сугучы нәни Нуржамал итеп тоя. Җырлар да шундый ук матур, серле келәм түгелмени? Җыр да бит күңел нурларыннан тукыла.

...Келәм суга матур-матур,
Сере дөньяны аңлатыр...

— Гөлзада! Тагын шул жырың белән дөньяңны оныттыңмы? Нәрсә әйттем мин сиңа?!

Кызны әтисенең тавышы сискәндереп жибәрде. Гөлзада ашыга-ашыга чиләкләренә су ала башлады.

— Һы, тапкан юаныр нәрсә! Имеш, ул жырлый белә. Җырны аны юләр дә жырлый. Җыр жырлап тамак туймый...

Гөлзада әтисенең бу сүзләренә рәнжеми. Гомер буе жиргә ябышып яткан игенченең, әлбәттә инде, иң зур кайгысы — тамак туйдыру. Сигез баланың һәркөнне авызы ипи сорап ачыла. Әтисе гомер буе колхозда эшләсә дә, теләгән чакта ипине умырып ашый алганнары юк әле. Әниләре эшкә киткәндә ипине яшереп китә. Ә Гөлзада ипи исенә бик сизгер, шуңа күрә абыйлары аңа ялыналар: «Эзлә инде, сеңелкәй, тапсаң үзеңә дә ашатырбыз», — диләр.

Гөлзада яшерелгән ипине эзләргә тотына. Ис аны түр башындагы тотылмый торган мендәрләр янына алып килә. Мендәрләрне күтәреп карый, ә ипи юк. Нишләп соң әле мендәрләрдән ипи исе килә? Ә-ә, кичә әниләре ипине монда яшергән иде бит. Исе сеңеп калган, күрәсең. Димәк, бүген ипи ераккарак яшерелгән. Әмма никадәр ерак яшермә — Гөлзада аны барыбер таба... Гөлзада аннан абыйларына үпкәләп, әнисен кызганып утырып елый. Бераздан аның сулкылдап елавы җырга әверелә.

Сандугач баласы булсам
Бер агач сайлар идем;
Шул агачка оя ясап
Көн дә бер сайрар идем.

Җыр аны болынга, урманга алып китә. Урман аның күңеленә әллә нинди тавышлар, бизәкләр, хисләр өсти. Бу хис йөрәккә сыеша алмыйча тышка бәреп чыга, бәреп чыга да ботакта өздереп-өздереп сайраучы кошлар тавышына, урман шаулавына, чишмәләр агышына барып кушыла. Урманда меңнәрчә авазлар белән тулышкан кызның җаны каядыр биеккә-биеккә күтәрелә һәм бу мәшәкатьле, борчулы, газаплы дөньяны югарыдан күзәтә башлый. Югарыдан караганда кешеләр артык кечкенә, артык изелгән кебек булып күренә. «Әй сез, кешеләр,— дип кычкыра шашкын күңел,— башыгызны күтәреп югарыга карагыз әле. Дөнья шундый киң, күкләр шундый биек. Ә сез түбән иелгәнсез дә шушы киңлекләрне, шушы биеклекләрне күрми башлагансыз, гомер буе кырмыскалар кебек җирдә казынасыз, тамак туйдыру турында гына уйлыйсыз. Сез бит кешеләр. Дөньяга сез тамак туйдыру өчен генә килмәгән. Бер тураеп басыгыз да иксез-чиксез офыкларга карагыз, әз генә булса да тын калып урман шавына, җилләр сызгыруына, чишмәләр агышына, күкләр күкрәвенә колак салыгыз. Шулвакыт сез күңелегезнең баеганын күрерсез. Күз карашларыгыз ераграк офыкларны иңләр. Язгы күкрәүләргә кушылып сез тетрәнүләр кичерерсез. Ә бер тетрәнгән кеше яңадан шушы йокымсырау халәтенә кайтырга теләмәс. Урманнарга кереп кычкырыгыз — тавышыгыз нинди көчле икәнне ишетерсез. Биләрегезне турайтыгыз — үзегезнең нинди биек икәнлегегезне күрерсез. Күктәге кояшка күз салыгыз — кояш-көзгедә үзегезнең матурлыгыгыз чагылыр».

Шашкын Җан дөньяга әнә шулай аваз салып йөргәннән соң яңадан кызның күкрәгенә кайта. Куак төбендә хәрәкәтсез калган гәүдә җанлана. Аңга: «Тизрәк өйгә кайтырга кирәк, анда мине югалтканнардыр»,— дигән шом бәреп керә. Кыз өенә йөгерә. Ә өйдә гап-гади дөнья мәшәкатьләре, тавык чүпләп бетерә алмаслык вак эшләр көтә аны.

Гөлзада өчен дөнья күптән инде икегә аерылды. Берсе аның керләр юу, су ташу кебек ялыктыргыч эшләрдән торса, икенчесе — хыял дөньясы. Бу дөнья матур, бай, серле, ашкындыргыч. Бу дөньясына Гөлзада беркемне дә кертми. Кешеләр өчен бу дөнья бикле. Кешеләргә серенне ачсаң, алар синнән көлә башлый. Ә Гөлзада артист булырга хыяллана. Нинди артист? Җырчымы, драма артистымы — аның өчен әле барыбер. Тик аңа сәхнә кирәк. Ул шуны аңлый. Сәхнәдә тормыш шундый матур, шундый серле. Анда гел яхшылык җиңеп чыга. Казаннан артистлар килеп спектакль яки концерт куеп киткән саен кызның күңеле алгысып кала.

Җиденче классны бетергәч, Гөлзада беренче мәртәбә бу хыялына бик якын килә. Ул инде күңелендәге яшерен уйларын әнисенә дә чишә. Сизгер күңелле ана, тирән көрсенеп булса да, кызының омтылышын хуплый. Әмма башта әтисе белән киңәшергә куша.

— Әти, мин артистлыкка укырга китәм,— ди Гөлзада беркөнне кыюланып.— Казанга!

— Артистлыкка? Син нәрсә, әллә акылыңнан яздыңмы?— диде әтисе.— Артист, имеш. Бирермен мин сиңа артистлыгыңны. Артистлыгыңны түгел, исемеңне онытырсың. Урманга, су буйларына барып җүләр кешедәй авыз күтәреп җырлап йөрүләре балалыгы гынадыр дисәң — мәнә ул нәрсә уйлап йөри икән! Алай бик зур үскәнсең икән, әнә колхозда бүгеннән фермага сыер савучы кирәк. Ичмасам уч тутырып акча алырсың, кешеләр алдында йөзең якты булыр.

Бу тарткалаш шактый озак бара, әмма әтисенең һәр сүзен әмер дип кабул итеп үскән кыз җиңелә. Ул, хыялларын янган йөрәгенең көленә күмеп, колхозда эшли башлый. Язмышка рәнҗү, үпкәләү кайвакыт аның күзләренә яшь булып каплана. Мондый чакларда җанда әллә нинди җырлар актарылып чыга...

Нинди авыр хәлгә калганда да хыялын үтерми Гөлзада. Кичке мәктәпкә йөреп урта белем ала. Кулга өлгергәнлек аттестаты кергәч, хыялын янә бер тормышка ашырмакчы булып карый. Бәлки инде әтисенең күңеле йомшаргандыр? Әмма юк икән. Һаман шул сүз: артист булам дип авызыңны да ачма! Телисең икән агроном бул, игеннәр үстер. Әгәр инде һич тә җырсыз яши алмасаң — басуларда җырла. Анда иркен.

Әтисен җиңә алмагач, Гөлзада Казан дәүләт ветеринария институтына укырга кереп кайта. Шунда аны әтисе беренче тапкыр мактап куя: «Менә акыллы эш эшләгәнсең, кызым». Ләкин кызны әтисенең мактавы шатландырмый. Чөнки ул үзенең бу эше белән йөрәктәге шашкын омтылышларын тагын да тирәнгәрәк күмелүен аңлый. Көйрәп яткан күмерне озак вакыт көл белән күмеп яткырсаң — күмер сүнә. Чөнки аңа сүнеп бетмәс өчен әз булса да һава кирәк. Гөлзада Казанда укыган вакытта үзешчән түгәрәкләргә йөри. Шулай итеп, көлгә күмелгән күмерне калкытып-калкытып куя. Ә инде институтны бетереп Ташкентка эшкә җибәрелгәч, үзен тагын да иркенрәк сизә башлый. Ахунбабаев исемендәге мәдәният сараена йөри. Бераздан ул анда сәхнәгә гашыйк яшьләр арасында бөтенләй үз кешегә әйләнә. Драма

түгәрәген житәкли. Ташкент театр институтының режиссерлык бүлегенә укырга керә. Бер карaганда тормыш көйләнде, бер эзгә төште сыман. Кулда гомерлек һөнәр, күңел ашкынуын басар өчен сәхнә бар. Ләкин юк шул — жан канәгатьлек кичерми. Сирәк кешеләргә генә ходай бирә торган талант вакыт-вакыт баш күтәреп куя: «Мине читлектә үтермә, иркенгә жибәр»,— ди.

Гөлзада, Ташкентта өч елын тутыргач, ул өмет учакларына өр-яңадан ут тергезеп Казанга кайта. Хәзер инде ул — эти сүзенә карап торудан узган, жырдан башка яшәү алмаячагын аңлаган шәхес.

Ул филармониягә килә. Бу 1973 елның жәе. Филармониягә жырчылар кирәк икән. Берничә жырчы арасында конкурс уздыралар. Конкурс сайлауларын узган бәхетләр арасында Гөлзада да бар. Аны, көз көне килерсең, дип жибәрделәр. Ә көзен килсә, филармония житәкчеләрен алыштырганнар. Теге вакыт Гөлзадаларны сайлап алган кешеләрнең кайберләре юкка чыккан, кайберләре яңа житәкче килүгә фикерләрен үзгәртеп өлгергән.

— Кабат тыңлагыз! — дип үзенекен итә Гөлзада.— Мин жырларга тиеш. Аңлыйсызмы шуны? Жырларга!

— Ярар, тыңлап карыйк алайса,— диләр.— Әйдә, берәр халык жырын жырла.

Гөлзада «Рамай»ны жырларга тотына.

Төнгә каршы берәү моңлы итеп, Рамай,
Аерылышу көен жырлады.
Тынга калды урман буйлары да, Рамай,
Чишмәләр дә акмый тыңлады.

Жыр, бүлмәгә генә сыймыйча, ачык тәрәзәдән ургылып урамга чыга. Бүлмә эче сихри авазлар белән тула. Бу жырның тәэсиренә, жырлаучы тавышының көчлелегенә, жырдагы драматизмны оста бирә алуына сокланмый мөмкин түгел. Әмма туң йөрәкле түрәләрнең күңеленә ул үтеп керә алмый. Алар, Гөлзаданың ветеринария институтын бетергәнлеккә бирелгән дипломын кулларында әйләндереп карый-карый, бер-беренә күз кысыштылар. Ташкентта укып йөргән театр институтының өч курсын бетерү дә боларга әллә ни тәэсир итми.

— Юк,— диләр алар Гөлзадага,— безгә дипломсыз жырчылар кирәкми. Дөрес, тавышың бар. Ләкин...

— Бәлки нәфис сүз сөйләргә алырсыз. Мин шигырьләр дә сөйли беләм,— ди Гөлзада һаман бирешергә теләмичә.

— Юк, юк, нәфис сүз сөйләүче дә кирәкми,— диләр әлеге туң йөрәкләр. Кыз урамга атыла. Ә урам гөрли. Машиналар, үзләренең астына алып кереп китәрдәй булып, ажгырып өскә килә.

Менә бервакыт уннарча машинаның берьюлы кычкырту тавышына айнып киткәндәй була. Караса, юл уртасында басып тора икән. Урамда хәрәкәт туктап калган. Кемнәр сүгенеп аның каршына килә, кемнәрдер аның бу халәтеннән чыгарырга тырышып машинасын акырта.

Ниһаять, язмыш аңа бер елмаю бүләк итә. Татар дәүләт филармониясендә берничә ел эшләп, инде шактый конкурсларда катнашкан һәм жиңүләр яулаган Риф Сафиуллин өлкә филармониясенең татар группасында жырларга талантлы яшьләр эзли икән. Риф Сафиуллин Гөлзаданы тыңлап караганнан соң шатланып кулын кыса.

— Шәп, бик шәп. Менә шундый көче ташып торган яшьләр кирәк. Ике уйлап тормагыз, иртәгедән юлга жыеныгыз.

Профессиональ сәхнәгә юл менә шуннан башлана. Кешеләр күңеленә сукмак шушыннан салына.

Татар тамашачысы алдында гына түгел, Болгария, Югославия, Мисыр, Гарәбстан илләре тамашачылары каршында да жырлап «чиркәнчек» алган Риф Сафиуллин Куйбышев өлкә филармониясендә татар группасы ачып жибәрә. Аңа «Дуслык» дип исем кушалар. Гөлзада белән Риф менә шушы «Дуслык» ансамбленең җанына әверелә. Гөлзаданың шигърияткә яратуы, күп шагыйрьләрнең шигырьләрен яттан белүе монда бик ярап куя. Ул кирәк жирдә концертлар алып бара, кирәк жирдә солист булып сәхнәгә күтәрелә. 4—5 музыканттан, 2—3 жырчы һәм бер биючедән торган кечкенә генә бригада әле Урта Азия якларына, әле Урал төбәкләренә, әле Оренбург далаларына барып чыга. Кайда татар авыллары бар — алар шунда. Кайвакыт өйдән-өйгә йөреп билет таратырга, ачылмаган клубларны ачтырырга, ягылмаган мичләрне яктырырга туры килә. Менә шушында Гөлзада кеше күңеле өчен көрәшнең ничек авыр икәнен аңлый. Артистның эше сәхнәгә чыгып берничә жыр жырлау белән генә бетми икән. Брежнев чорының кәгазь кортына әйләнеп беткән түрәләренә синең татар жырларың нигә кирәк? Алар кыюрак әйтелгән һәр сүздән дер калтырап, сәхнәгә чыгасы жырларны мең иләк аша үткәрәләр. Аларга синең «Гөлжамал»ларың, «Уел»ларың, «Карурман»нарың чүп кенә. Артист икән, димәк, син интернационалист бул. Рус жырын да, казахныкын да, үзбәкнекен дә башкар. Гөлзада репертуарына рус, үзбәк, казах, һинд һәм башка халыкларның жырларын кертә. Советлар Союзында кайда татар авылы бар, алар шунда барып чыга. Чөнки башка халык жырын ничек әйбәт жырлама, үз халкыңның моңы якынрак. Әкренләп танылу килә. Ташкентта концерт куеп китәләрме, Пермь өлкәсендәге тамашачы алдында чыгыш ясыйлармы — алар китүгә, газеталарда матур-матур мәкаләләр чыга башлый.

«Гөлзада Сафиуллина чыгышлары кабатланмас матурлык, күңелдә якты хисләр уятты. Ул татар халкының жор күңелен, моңын, дәртен, тел байлыгын нәфис сүз һәм жыр-

лары белән йөрәктән алып йөрәккә салды» (Пермь өлкәсендә чыга торган «Таң» газетасы. 1978).

«Ансамбльнең солисткасы Гөлзада Сафиуллина тамашачы тарафыннан алкышлап каршыланды. Аның җырлары тамашачы күңелендә озак сакланыр. Гөлзаданың җырлавы зур профессиональ осталык һәм эмоциональлеге белән аерылып тора. Бу исә җырчының үз иҗатына таләпчән карауны күрсәтә» (Ташкент. «Ленин байрагы» газетасы. 1977).

Мондый юлларны бик күп китерергә булыр иде. Әйе, Гөлзаданы Татарстаннан читтә зур башкару осталыгына ия артист итеп, үзенчәлекле башкаручы итеп таныдылар, яраттылар. Ләкин читтә никадәр нык танылма, бу җиңү — ярты җиңү генә. Дөрес, «Дуслык» ансамбле белән Гөлзадалар Татарстан, Башкортстан чикләренә үтеп керергә тырышып карыйлар. Ләкин мылтыксыз чик сакчылары аларны татар мәккәсе — Казан якларына якын җибәрми. «Безнең үзебезнең филармониябез бар, әллә каян килгәннәрдән тамашачыбызның зәвыгын боздыра алмыйбыз,— диләр.— Сез инде безнең артистларыбыз икмәгенә сузылмагыз».

Әй бу артист икмәге! Күпме күз яшьләренең тозына манчылмый да, күпме юлларның тузаннарында аунамый ул.

«Дуслык» ансамбленең җитәкчесе, Гөлзаданың таянычы һәм ире Риф Сафиуллин кинәт кенә үлеп киткәч, Гөлзада бик кыен хәлгә кала. Кая барып сыенырга, баш тәртергә белми. Дөрес, Куйбышевта бер фатир кисәге бар барын, ләкин аңа ни җылы, ни су кертелмәгән. Гастрольләрдән кайткач, утын артыннан чабарга, ашау-эчү турында кайгыртырга кирәк. Өстәвенә әле бала бар. Менә шулай кая барып бәрелергә белми йөргән чагында Илһам Шакиров килеп чыгып ярдәм кулы сузмаган булса, Гөлзаданың язмышы бөтенләй икенче юнәлеш алып китүе дә мөмкин иде.

— Әйда, Казанга кайт,— ди Гөлзаданың җырлау мөмкинлеген яхшы белгән атаклы җырчы.— Мин анда филармония җитәкчеләре белән сөйләшеп карармын. Бәлки, күңелләренә миһербан килеп алып куярлар. Өметләндерергеч сүз әйтсәләр, мин әүвәл телеграмма җибәрермен.

Шушы сөйләшүдән соң Гөлзада Казаннан телеграмма көтеп яши башлый. Күңелендә өмет белән өметсезлек көрәшә. Менә беркөн аңа көтелгән телеграмма килә! Үзе телеграмманы укый, үзенең күзләреннән яшь ага. Аны сөртеп бетерә торган гына түгел. Кул аркасы белән күзләрне сыпырган саен бу якты чишмәнең агышы балачак хатирәләрен кузгатып көчәя генә бара.

Кечкенә вакытта Гөлзада чишмәләр казырга бик ярата иде. Бервакыт шулай, чүмеч белән ком актарып чишмә казып ятканда, чүмеч сабын сындырды. Өйгә кайтсам, чүмеч сабын сындырган өчен кирәкне бирәләр инде дип, мөлдер-мөлдер елап утырганда аңа укытучы апасы Нурания очрап: «Нәрсә булды, Гөлзада, нигә елыйсың?» — дип сорады. «Менә бит чүмеч сабы сынды,— диде Гөлзада сулкылдап.— Чишмә казый идем».

— Нигә кирәк булды соң сиңа чишмә? Безнең авылда болай да алты чишмә бар бит инде,— диде Нурания апасы.

— Җидәү булсын диген идем...

— Бер дә кайгырма,— диде Нурания апасы,— авылыбызның җиденче чишмәсе син буларсың. Синең тавышың чишмә тавышы кебек саф. Аннары хәтерләгәнең бар микән: чишмәләр бит алар нинди салкын кышларда да туңмыйлар. Нинди тирән елгалар туңа, калын боз белән каплана, ә кеп-кечкенә чишмә туңмый. Чөнки чишмә — җир җанының җыры. Синең җырың да туңып калырга тиеш түгел. Халык күңеленә барып кергәнче агарга тиеш ул.

Йә, рабби, халык күңеленә юл никадәр ерак, никадәр уравыч икән бит! Телеграмма белән чакырсалар да, Гөлзаданы Казанда колач җәеп каршы алмадылар. Нәфис сүз сөйләүче итеп кенә куйдылар. Ул Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова бригадаларында йөрде, оста итеп концертлар алып барды.

Һәр концерт бер спектакль кебек кабул ителсен өчен концертны алып баручыдан зур осталык, киң эрудиция, кеше күңеленә табигый агым булып килеп керә белү сәләте сорала. Ә Гөлзада нинди генә очракларда да югалып кала торганнардан түгел. Җырчы яки биюче ниндидер сәбәп аркасында сәхнәгә чыгып җитә алмый торса моннан котылу юлын тиз таба. Әлфия Афзалова үзенең бер язмасында: «Искиткеч кешелекле һәм кешеләр яратучы»,— дип язган иде Гөлзада турында. Илһам Шакиров та: «Тавышы көчле, дикциясе ачык, концертларны гөрләтеп алып бара»,— дип Гөлзададан канәгать булуын белдереп торды. Әмма Гөлзаданы болар гына канәгатьләндермәде, гастрольләргә барган саен ул җырламый калмады. Ә кайтуга аны сытык чырайлы түрәләр битәрләп каршы ала иде:

— Кем кушты сиңа җырларга?

— Җырладым һәм җырлаячакмын,— ди иде Гөлзада.— Мин бит Совет хөкүмәтенә каршы пропаганда алып бармыйм. Җырлаганым өчен сездән акча да сорамыйм.

Гөлзадага кайберәүләр мондый киңәш бирделәр:

— Син алар белән сүз көрәштермә, иелгән башны кылыч кисми. Башыңны ныграк и. Һәр түрәнең салпы ягына салам кыстыр. Начальствога күренер өчен йә Илһам Шакировлар кебек зур талант булырга, яки артыгын кечкенә булырга кирәк. Алар үзләренең табан астында туфрак булганны яраталар. Аларның бөтен психологиясе шул: менә син нинди талант, әмма минем кул астымда. Теләсәм сытам, теләсәм изәм. Алар таптаганда син рәхмәт әйтсәң, шул вакытта алар сине күтәреп алырлар, без сине кеше иттек, дип мактанып йөрерләр. Заманы шул бит, аларны мактамыйча макталып та, үсеп тә булмый.

Юк, Гөлзада мондый киңәшләрне тота алмады. Ул көрәшергә булды. Хәзер инде ул элекке хыялый Гөлзада түгел, бюрократлар корган калын стеналарга бәрелә-бәрелә, маңгайларын каната-каната шактый чыныкты ул. Язмыш яшь композитор Риф Гатауллин белән очраштыргач, Гөлзада тагын да канатланып, дәртләнеп эшкә тотынды. Чөнки Риф Гатауллинның үзенең дә кагылып-сугылып йөргән вакыты иде. Әлеге дә баягы — үзешчән композитор гына булуына карамастан, аны да профессионаллардан матуррак көйләр язуын, заман ритмын, көннең рухын өйдә утырып тынчып беткән профессиональ композиторлардан тизрәк тотып алуын кичерә алмыйлар иде. Нинди шәп әсәр язма — син үз урыныңны бел. Композиторлык белемең юк килеш әллә кая үрелмә, янәсе. Дөрес, Риф Гатауллин консерватория бетергән, ләкин вокаль бүлекне. Ә ул вакыттагы язылмаган законнар композиторлык бүлеген бетермәгән музыкантларга бик катгый иде. Ф. Әхмәдиев, С. Садыйкова кебек композиторлар да шушы язылмаган закон читлекләренә эләгеп әз тыпырчынмадылар бит.

Әйе, кайчагында ике бәхетсездән бер бәхет туа, диләр. Гөлзада белән Риф бергәләп тотындылар. Акча юклык, тормыш кысанлыклары аларны куркытмады. Эшләргә, эшләргә, бернигә карамыйча эшләргә дип җиң сызганып тотындылар. Риф белән бергәләп, «Үлемсез ил моңы» дигән зур концерт программасы әзерләп, Казан сәхнәләрендә бу концертларын бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышлап тамашачыларга күрсәтә башладылар. Программада иллегә якын җыр. Ул өч сәгатьтән артыграк бара.

Минем үземә дә бу концертны карарга туры килде. Башка җырчыларны да тыңлаган, караган бар иде, әмма бу кадәр очынып, бу кадәр ашкынып тамашачыга үзенең күңел байлыгын сибүчене күргән юк иде кебек. Әйтерсең, саркып кына агып яткан чишмәне авыр ташлардан арындырганнар, юлын чистарткannар да ирекка чыгарып җибәргәннәр. Ургылып-ургылып ага. Гөлзада бу җырларына кичкенәдән үк күкрәгенә җыелып килгән хыялларын, омтылышларын, өметләрен, тормышка мәхәббәтен, үзен аңларга теләмәүче таш бәгырьләргә булган нәфрәтен, үзенең кайчан да булса җиңәчәгенә ышанычын, кыскасы, йөрәге әрнүләрен, җанының бәргәләнүләрен салырга тырышты. Һәм сизгер күңелле тамашачы аны аңлады. Җыр саен алкышларга күмде. Бу — ике чишмәнең кушылуы, ике талантның танылуы иде. Аларның бу концертлары турында республика газеталарында зур-зур мәкаләләр басылып чыкты. Тамашачылардан рәхмәт хатлары яуды. Ишек төпләрендә автографлар сорап торучылар күбәйде. Алар районнан-районга йөреп куйган концерт акчаларын соңгы тиененә кадәр Тынычлык фондына күчерделәр. Көрәшсез бернинди җиңү яулап булмаганлыгын шушында аңладылар. Шушыннан соң тамашачы күңеле өчен көрәш, тормышта үз талантына лаеклы урын алу өчен көрәш тагын да кискенләште.

1985 елда яшьләр һәм студентларның Мәскәүдә узачак XII Бөтендөнья фестивале турында ишеткәч тә Гөлзада яңа концерт программасы әзерләргә керешә. Тырышлыгы бушка китмәде. Мәскәүдәге Бөтендөнья фестиваленә бару хокукын яулады. Мин Гөлзададан бу фестиваль турында тәэсирләрен сөйләвен сораган идем.

— Беренче тәэсир — шатлык, — диде ул. — Фестивальгә бару, дөнья яшьләре белән аралашу үзе бер шатлык булса, татар җырын, татар моңын дөньяга ишеттерү икенче шатлыгыбыз булды. Испан, итальян, француз җырларын бөтен дөнья җырлый. Ә безнең татар җыры аларныкыннан киммени? Без бит гомер буе изелеп яшәгәнгә генә мескенләнеп беткәнбез. Әгәр бастырып торган ташларны өстән алып ташласаң, безне дөнья күрәчәк әле. Мисалга мин шуны гына китерә алам. Фестивальнең соңгы көнендә дөнья яшьләренең очрашуы булды. Зур мәйданга бик күп ил вәкилләре җыелды. Китте бию, китте җыр. Башта без ирекка өйрәнгән дөнья яшьләре каршында бераз югалып калган идек. Бермәлне Риф, без кемнән ким соң әле дигәндәй, баянын уйнап җибәрде. Мин җыр суздым. Татар җыры Мәскәү мәйданында яңгырады. Бераздан безнең татар җырын башка ил вәкилләре дә күтәреп алды. Бермәлне карасам, безнең төркемдәге йөзләрчә кеше безгә кушылган, сүзләрен белмәсәләр дә безне дәртләндереп, көч биреп торалар. Шулвакыт шушындый җырлар иҗат итә алган халкым өчен горурландым, күзләрем яшьләнде. Их, дидем, нигә соң без гел-гел изелеп яшәргә тиеш? Кайчан соң без, шушы ирекле дөнья яшьләре кебек, теләгән җырыбызны теләгән җирдә җырлый алырбыз? Безгә дә бит тел авызга бикләп куяр өчен генә бирелмәгәндер. Кайчан чишәрбез соң без телләрне?!

Фестивальдән Гөлзада яңа дәрт, яңа планнар белән кайтты. Кешеләр күңеленә юлны балалар аша салырга кирәк, дигән ниятка килде ул. Һәм кая гына барса да мәктәпләргә сугылмый, балалар белән күзгә-күз очрашмый калмады. Өенә дә кочак-кочак балалар өчен язылган шигырь китаплары ташыды. Күңелгә ятышлы шигырьләрне сайлап композиторларга өләште. Риф Гатауллинны шигырь китаплары белән күмеп ташлады. «Кече Артек җыры», «Мушкетерлар» кебек җырлар шулай уртак тырышлык белән тудылар. Мәктәпләргә барганда да ул буш кул белән бармый. Кибеттән күп итеп татар китаплары ала. Татарча матур итеп сөйли, җырлый белгән балаларга шул китапларны бүләк итеп бирә. Бервакыт Казан шәһәренең 3 нче мәктәбенә очрашуга баруы турында Гөлзада болай сөйләгән иде: «Исәнмесез, балалар! — дип сүзне һәрвакыт татарча исәнләшүдән башлыйбыз. Бу юлы да шулай булды. Исәнләшкәч бер малайның янына килеп: «Ничәнче класста укыйсың, үскәнем?» — дип сорадым. Ул: «Эдик», — дип җавап бирде. Эдик белән без шул кичәдән соң дуслашып калдык, киләсе очрашуда бары тик татарча гына сөйләшергә сүз куештык. Эдик чынлап та үз сүзендә тора торган малай булып чыкты. Икенче елны баруымда без аның белән саф татарча сөйләштек. Хәзер инде ул татарча җырлар өйрәнеп йөри. Безнең телебез бик матур бит, бары тик шуның матурлыгын күрсәтә белергә, сокландыра белергә генә кирәк. Безнең күп кенә җырчыларыбыз

мәктәп балаларына жырлап йөрүне түбәнлек саный. Ә бит мәктәптә безнең иртәгеге тамашачыбыз утыра».

Яшьләр һәм балаларның ялын оештыру өлкәсендәге уңышлары өчен Гөлзада Сафиуллина белән Риф Гатауллинга 1988 елда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге бүләге бирелде.

Гөлзада жыр сюжетындагы кискен борылышларны, жыр героеның күңел халәтендәге үзгәрешләрне бөтен нечкәлекләре белән тамашачыга житкерергә тырыша.

Фикерем буш сүз булып калмасын өчен Татарстан һәм Үзәк телевидение аша күрсәтелгән бер концертка тукталып үтсәм урынлы булыр. Чөнки бу концертта Гөлзада башкару осталыгы белән дә, үз-үзен тотыштагы табигыйлеге белән дә, халкыбызның горефгадәтләренә, киенү-бизәнүдәге зәвыгына зур ихтирам белән дә тамашачы күңеленә кереп калды. Әйе, матур кием бит яхшы жыр кебек күңелне күтәрә. Һәркем күңел халәтенә карап кием кия, күңел халәтенә карап жыр жырлый. Бу ике нәрсә һәрвакыт янәшә, һәрвакыт бергә. Татар кызларының суга бару күренешен генә алыйк. Элек-электән суга бару кызлар өчен тантаналы вакыйга булган. Кызлар суга барганда матуррак күлмәкләрен киярга тырышканнар, чөнки су юлында сиңа күз атып йөргән егет очравы бар. Су юлы — мәхәббәт юлы, су юлы — кавышу-күрешүләр юлы. Гөлзаданың инәнә кәнтә-чиләк асып жырлый-жырлый судан кайтып килүче кызны тасвирлавы күңелдә әллә нинди тәэсирләр уята. Басма өстендә кызларның бәләкли-бәләкли кер юулары, каз өмәләрендә чәчәкле кәнтәләренә каз элеп тезелешеп елга буена барулар — болар бар да халкыбызның әшне матур итеп эшли, тормыштан тәм табып яши белүен күрсәтә. Гөлзада шушы күренешләрдә тормышыбызның шигърияген ача алды. Шул ук концертта, әйтик менә ак каеннар арасыннан ак күбәләк очып чыгуын хәтерләтеп, ак күлмәкле жырчы килеп чыга. Урманны яңгыратып «Сагыну» жыры яшетелә. Әйтерсең жырчы түгел, каен урманы үзе жырлый. Син үзеңне шушы гүзәл табигатьнең бер кисәге итеп сизә башлыйсың.

Безнең халык жырламый тора алмый бит ул. Без барыбыз да әниләребезнең авыз эченнән нидер көйләп жеп эрләүләрен, бәйләм бәйләүләрен күреп үскән кешеләр. Әмма шушы күренешләрне сәнгать дәрәжәсенә күтәреп халыкның үзенә күрсәтә алган жырчы юк иде әле. Гөлзада исә әлеге концертында халкыбыз күңеленең нинди бай, нинди хисле, нинди күп бизәкле икәнен күрсәтте.

Менә биш ел инде Гөлзада Татар дәүләт опера һәм балет театрының концерт бригадасында жырчы булып йөри. Репертуары баеганнан байый. Ул, халык жырлары белән бергә, композиторларның әсәрләрен дә яратып башкара. Гөлзада жыр турындагы мәкаләсендә болай дип язган иде: «Кешенең әхлагын чистарту, зәвыгын тәрбияләү, аның аңына сафлык-пакьлек, гаделлек, кешелеклек сыйфатлары салуда иң йогынтылы сәнгать чараларының берсе ул — жыр». Менә шушый хакыйкатьте нык белгән халдә, үзе әйткәнчә, «халыкның зәвыгын тәрбияләүдә» ул армый-талмый эшли.

Соңгы елларда үсеп киткән милли уянның көчәюе жырчыга яңа көч өстәде. Ул милләтнең, телнең киләчәге турында кайгыртудан, халкыбыз язмышы өчен борчылудан туган Татар ижтимагый үзәгенең актив әгъзасына әверелде. Ул митингларга чыкты. Трибунага менеп кыю сүзен әйтте. Татарстан үзенең суверенитеты өчен көрәшкән вакытта иң кайнар ораторларның берсе Гөлзада булгандыр мөгаен.

Әйе, халык аны яраткан жырчысы, ялкынлы сүзле көрәшчесе итеп таныды. Хәтта кызын артист итәргә теләмәгән әтисе дә үзенең хак түгеллеген танырга мәжбүр булды.

Бервакыт шулай үзләренең концерт бригадасы белән Гөлзада туган авылына килде. Концертка китәр алдыннан әнисенә ул: «Әни, концертка әти бармасын, яме,— диде.— Юкса мин жырлый алмам, оялырмын».

Менә авыл клубында концерт бара.

Жыр арты жыр агыла. Күзләрдә яшь. Күпләрнең күңел тетрәнүләре йөзләренә бәреп чыккан. Клубта шылт иткән тавыш та юк. Бары тик жыр гына. Ә жыр тар клубларны киңәйтеп жибәргән, гүя ки стеналар эреп юкка чыккан. Бу жыр сине үзенең йомшак канатларына утыртып каядыр биеккә, яктыга, хыял дөньясына алып китә. Арганлыгың, картлыгың, мәшәкатьләрең коелып кала. Син жыр дип аталган тылсым дөньясында яши башлыйсың. Барлык күңелләр сәхнәдәге жырлаучыга сихри жепләр белән тоташкан. Ул жепләр өзелсә табигый гармония юкка чыгар кебек. Шуңадыр, ахры, шым калып тыңлыйлар.

Менә концерт бетте. Меңнәрчә кош берьюлы канат кагып очып киткәндәй, кул чабулар яңгырады. Гөлзаданың дуслары, якыннары сәхнәгә күтәрелде. Котлау арты котлау яуды. Ә иң дулкынландырганы Гөлзаданың элекке укытучысы Нурания апаның сәхнәгә күтәрелүе булды.

— Авылыбызның жиденче чишмәсе булырсың дип әйткән идем, ялгышмаганмын икән, рәхмәт сиңа,— диде ул.

Әйе, концерт уңышлы узды, тик Гөлзада өенә курка-курка гына кайтты. Беркемгә сиздерми генә эчке якка үтмәкче иде, шулвакыт әтисенең мышык-мышык елаганын күреп тетрәнеп китте. «Нәрсә булды?— диде Гөлзада.— Ник елыйсың, әти?»

— Их,— диде ата өстәлгә йодрыгы белән сугып,— бөтенесенә мин гаепле. Күпме вакытлар синең талантыңны буып яткырдым бит. Булдыра алсаң, гафу ит мине, кызым.

— Минем сиңа үпкәм юк, әти,— диде Гөлзада.— Язмыштан узмыш юк, диләр бит. Ә мин язмышка ышанам. Язмыш миңа менә шушындый авыр бәхет бүләк иткән икән, нишлисең инде. Бәлки әле бәхетнең жиңеле булмыйдыр да. Ә сиңа зур рәхмәт, әтием. Күңелемдәге мәңгелек төерне алып ташлавың өчен рәхмәт...

Равил Фәхретдинов

# ТАТАР УГЛЫ ТАТАРМЫН

*Белегез, бу горур исем!*

Л. Гумилев

Алтай телләре гаиләсенең төрки телләр төркеменә керүче татар халкы үзенең саны ягыннан СССРда алтынчы урында тора. Рәсми мәгълүматлар, ягъни 1989 елгы бөтен Союз халык санын алу нәтиҗәләре буенча, Кырым татарларын да кертеп, илебездә 6920475 татар яши (шуның 271715 е — Кырым татары)[1]. Кырым татарлары милли хәрәкәте туплаган мәгълүматларга караганда, аларның бүгенге саны 450—500 меңгә җитә (кайбер хәбәрләр буенча, 800 мең тирәсе). Татар халкының башка этнографик төркемнәренең бөтен саны хакында, кызганыч ки, андый өстәмә мәгълүматлар тупланмаган. Әгәр дә ул материаллар бөтен Союз күләмендә бик җентекләп җыйналган булса, тарихчы буларак иманым камил, татар халкының гомуми саны күпкә артык булыр иде. Хөрмәтле укучыларыбызга уйланыр өчен берничә белешмә китерик. XVI йөзнең беренче яртысында, ягъни алты мөстәкыйль татар дәүләте — Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, Касим ханлыклары һәм Нугай урдасы — яшәгән чорда рус дәүләтендә алты миллион кеше була. Кызганыч ки, татар дәүләтләрендәге халыкның саны хакында мәгълүмат юк, әмма Нугай урдасының үзенең генә дә 300 мең атлы гаскәр куя алганлыгын һәм Кырым ханлыгы яшәеш чорының соңгы дәверендә, ягъни XVIII йөзнең яртысында аның халкының миллионнан артык булганлыгын искә алсак, бөтен татар дәүләтләрендәге барча халыкның гомуми саны күп булганлыгына шик калмас. Дөрес, бу дәүләтләр XVI—XVIII йөзләр дәвамында Россия тарафыннан басып алынып, татарларны көчләп чукындыру һәм урыслаштыру сәясәте үткәрү нәтиҗәсендә халыкның этник торышына һәм гомум санына башта шактый зыян килә. Әмма ислам диненең һәм татар халкының үз-үзен саклый алу сәләтенең көчле булуы (XVIII гасырда күпләп чукындырылган татарларның, мәсәлән, бөтенесенең дә диярлек мөселманлыкка кире кайтуы; башка күп кенә халыклардан үзгә буларак, татарларның инде үткән йөздә үк милләт булып оешуы; үзбилгеләнү аңының һәм милли хәрәкәтнең, гомумән, шактый үк югары дәрәҗәдә торуы; безнең гасырның 60 елларына кадәр илебездә татар мәктәпләренең әле күп булуы һ. б. мөһим факторлар) халкыбызның этник, милли йөзен саклый алганлыгы турында бик ачык сөйли. Менә шуларны искә алсак, бүгенге татар халкының җиде миллион тирәсе генә булмавы хакында уйланырга тулы хакыбыз бар. Ниһаять, уйландырырлык тагын бер сорау: рәсми мәгълүматлар буенча бүген 145 миллион тәшкил иткән урыс халкы татарлардан 27 тапкыр күп. Өч-дүрт гасыр эчендә генә элекке биш-алты дәүләтнең халкы бер дәүләт халкы белән чагыштырганда, гәрчә ул зур дәүләт булса да, шулкадәр фәкыйрь пропорция (27:1) тәшкил итә аламы? Мин бу сүзләремне ниндидер рәсми төстә гаепләр өчен язмыйм, минем аның өчен тулы мәгълүматым да, димәк, хакым да юк, тик күңелне борчыган һәм уйланырлык мәсьәләләрне күтәрергә җөрьәт итә алам.

Татар халкы берничә зур этнографик төркемнән тора: Казан татарлары, мишәр татарлары (бу ике төркем үзләре «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» дигән зур бер этник-мәйданый төркем тәшкил итәләр), шулай ук Себер, Әстерхан һәм Кырым та-

[1] Бу җан исәбе алу вакытында кырым татарларының саны беренче тапкыр башка татарлардан аерым бирелде. Бу хәл аларның милли үзаңнары бик нык үсеп китүе һәм туган җирләренә кайту хәрәкәтенең кискен көчәюе белән аңлатыла.

тарлары. Алар, нигездә, шул исемдәге татар дәүләтләре, ягъни Казан, Себер, Әстерхан һәм Кырым ханлыкларының төп халыклары булып саналалар һәм барысы да халык буларак бер тарихи чорда — XV йөзнең ахыры — XVI йөзнең беренче яртысында формалашканнар. Монда мишәр татарлары гына бераз аерылып тора, чөнки аларның ул вакытта үздәреп кенә әйтерлек үз милли дәүләтләре булмаган, ләкин мишәрләрнең халык буларак оешуы Казан һәм Касим ханлыклары белән янәшәдә, аларның төп халкы белән бик тә тыгыз этник һәм мәдәни мөнәсәбәттә барган. Хәер, кайбер тарихи чыганаклар мишәрләрне Казан ханлыгында итеп тә күрсәтәләр. Җитмәсә, аларның нигез бабалары булган кыпчаклар зур бер дәүләт — Алтын Урданың үзәк җирләре төп төрки халкын тәшкил иткән (Литва, Польша, Румыйн татарлары дип йөртелгән татарлар да шул ук XV—XVI йөзләрдә татар дәүләтләреннән бераз читтәрәк формалашканнар). Әйтеп үтелгән төп этнографик төркемнәр үзләре аерым төркем һәм төркемчәләргә бүленәләр, аларга кыскача тарихи-этник аңлатма бирү, хәтта санап китү генә дә шактый озакка сузылыр иде һәм бу эш кечкенә генә бер очеркның кысаларына сыймый.

Татар халкы берничә этник-мәйданый төркемнәргә бүленсә дә, аның төп, күп санлы үзәге — Казан татарлары. Аларның теле бөтен татар халкы әдәби теленең нигезен тәшкил итә, алар мишәрләрнең күпчелеге белән бергә Татарстан ССРның төп, җирле халкы санала. Союздагы һәм чит илләрдәге татарларның күбесе бу республиканың башкаласы булган Казан шәһәрен үзләренең мәдәни, этник һәм сәяси мәркәзе итеп саныйлар. Ниһаять, татар халкы берничә төркемнән торса да, алар һәммәсе бу халыкны берләштерүче бер үзатама — «татар» этнонимын йөртәләр. Бу төркемнәрнең формалашуы, кайбер мәйданый, тел һәм этник аермалыкларга карамастан, әйткәнебезчә, бер тарихи заман була. Мондый тарихи-этнографик бердәмлекнең нигезе, безнең уебызча, әлеге төркемнәрнең барысының да Алтын Урда дәверендә үк инде бик тә якынлыгы булган. Әгәр дә Алтын Урда дәүләте җимерелмәгән һәм төрле дәүләтләргә таркалмаган булса, аерым төркемнәргә бүленмәгән бер бөтен татар халкы оешкан булыр иде...

Татар халкының бабалары кем булганлыгы хакында фәндә өч төп караш бар. Революциягә кадәрге Россиядә, хәтта аннан читтә дә шактый киң таралган беренче карашның тарафдарлары татарларны монголларның токымнары дип санадылар һәм бу фикер әле дә яши. Әмма бүгенге татарларның XII—XIII йөзләрдәге чыңгызлы монголлар белән уртаклыгы юк. Антропологик, ягъни физик төзелеш ягыннан алар, нигездә, европеоидлар, ә монголлар исә — чын монголоидлар. Дөрес, Казан татарлары арасында монголоидлык 14—15 процент тәшкил итә, алардан башка европеоидлар белән монголоидлар кушылудан барлыкка килгән сублапоноидлар (безнең якның «мулатлары») да бар — аларның өлеше 24—25 процент. Әмма боларның берсе дә монгол этносының эзе түгел. Гомумән, монголоидлыкны турыдан-туры монгол дип аңламасыннар, монголоид ул — кеше расасының бер төре (европеоид, монголоид, негроид); аның классик билгеләре монголларда күбрәк һәм, шуңа күрә, аларга нисбәтле аталган гына (бу төр, гомумән, Азия халыкларында таралган). Татарлардагы өлешчә монголоидлыкны антропологлар нигездә кыпчаклар белән бәйле дип әйтәләр; ул Себер һәм Әстерхан татарларында хәтта күбрәк тә — аларның килеп чыгышында, кыпчаклардан тыш, башка төрки кабиләләрнең дә өлеше шактый. Сублапоноид тибы Көнчыгыш Европага безнең эраның башларында Себер кабиләләре үтеп кереп, аларның җирле европеоидлар белән кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Чыңгызлы монголлар белән бүгенге татарлар, беренче чиратта, Урта Идел һәм Урал буе татарлары арасында этнографик яктан да сиземле уртаклык юк. Ниһаять, Татарстан ССРда һәм аның тирә-юнендә монгол археологик истәлекләре очрамый. Дөрес, шәһре Болгарны казыганда Көньяк Себердә һәм Монголиядә очраштыра торган типтагы берничә йорт калдыгы табылды, әмма алар ул шәһәрнең һәм аның халкының этник тарихында роль уйнаган истәлекләр булып саналмый, ә XIII йөздәге монгол түрәләре (баскаклар h. б.) белән бәйле урыннар итеп кенә карала.

Шулай булса да, татар этногенезында (этногенез = этнос + генезис — «Халыкның килеп чыгышы», дигәнне аңлата) «монгол» теориясе яши. Аның барлыкка килүе һәм үсеш алуы бүгенге «татар» исеменең урта гасыр татарлары үзатамасы белән тәңгәллек нәтиҗәсе булып тора. Эш шунда ки, XII—XIII йөздәге монголлар «татар-монголлар», хәтта «татарлар» дип тә аталганнар. Ләкин каян килгән соң аларга ул исем һәм, гомумән, кемнәр алар борынгы татарлар?

VI—VIII гасырларда Көньяк Себер һәм Үзәк Азия җирләрен биләгән Көнчыгыш Төрки каганлыгының халкы арасында «татар» исемле төрки кабиләләр дә булган, алар турында шул дәүләтнең башлыклары, ягъни каганнар истәлегенә куелган язулы кабер ташларында хәбәрләр бар. Мәсәлән, Истәми каган һәм Бумын каганны искә алу мәҗлесенә җыелганнар арасында «Отуз татар» (утыз татар) вәкилләре дә булган. Бу татарлар Билге каганның әтисе Илтәрис каган җитәкчелегендәге тю-гю кабиләләренә каршы сугышканнар. Билге каган үзе «Токуз татар» (тугыз татар) кабиләләре белән орышкан. «Утыз» һәм «тугыз», шулай итеп, татар кабиләләренең санын аңлаткан булса кирәк. Борынгы татарлар IX-X йөзләрнең кытай чыганакларында да искә алыналар, кытайлар аларны «да-да», «та-тань» дип атаганнар. Ли-Дэюй дигән

кытайның 842 елда Урмуз атлы уйгырга язган хатында, мәсәлән, «Та-тань» исемле кабиләләр турында хәбәр ителә. Соңрак император Ванг-Иентинның илчесе ясаган бер докладта (981 ел) «Та-тань» кабиләләренең сигез булганлыгы әйтелә. Ә гомумән, кытай тарихи чыганаклары буенча, борынгы татарлар күбрәк «да-да» исеме белән мәгълүм.

Шул ук X йөзнең инде безгә таныш булган «Хөдүд әл-галәм» дигән фарсы язмасында татарлар Төрки каханлыгы җимерелгәннән соң төзелгән караханилар дәүләтендәге «Тугыз угыз» ыруының берсе диелә. XI гасырда яшәгән атаклы уйгыр филологы Мәхмүт Кашгари 20 төрки кабилә арасында татарларны да атый, ә шул ук йөзнең фарсы географы әл-Гардизи әсәрендә татар кабиләләре берлегеннән чыккан кешеләрнең Кимак каханлыгын төзүдә шактый зур роль уйнаулары турында риваять китерә (кимаклар VIII—X йөзләрдә Көнбатыш Себердә, Иртеш елгасы буйларында яшәгән төрки кабиләләр, аларның көнбатыш кавеме кыпчаклар исеме белән мәгълүм). Әлеге риваятьнең кыскача эчтәлеге болай: татарларның юлбашчысы үлеп, аның ике улы исән кала. Олысы патшалыкка хуҗа була, ә Шад исемле кече улы аңа көнләшә, үч тота башлый. Көннәрдән бер көнне ул абыйсына һөҗүм итә, әмма җиңелә һәм үзенең кәнизәге белән качып китә. Менә ул елгаларга, урман-далаларга һәм төрле мал-туарга бай җиргә килеп чатыр кора һәм гомер итә башлый. Озаклямый аның янына татарлардан җиде кардәше килеп кушыла, шулар арасында Татар, Кыпчак, Аҗлад. Кайбер чыганаклар, мәсәлән, урыс елъязмалары, XVII гасырның Хива ханы һәм тарихчысы Әбел Гази туплаган мәгълүматлар буенча, татарларның әле монгол яуларына кадәр үк Көнчыгыш Европада булганлыгы билгеле. Алар төрле тарихи заманнарда көнбатышка күченеп киткән татарларның бер өлеше булганнар һәм тора-бара башка төрки кабиләләр белән берлектә Алтын Урда дәүләтендә барган этник процесста катнашканнар.

Әмма борынгы татарларның тарихта шактый зур эз калдырган дәвере — аларның үз җирләрендә, ягъни Көньяк Себер һәм Үзәк Азиядә монголлар белән күрше булып яшәп, Монгол империясе төзүдә катнашу чоры. Бу вакыйгалар урта гасырның ифрат кыйммәтле берничә тарихи чыганагында яктыртыла: «Монгол ун-ниуча тобчаган» («Монголларның яшерен тарихы») дип аталган XIII йөз монгол язмасында («Күңел түрендәге риваять» исеме белән дә мәгълүм; кытайча атамасы — «Юань-чао-би-ши»); XIV гасырның бөек тарихчысы фарсылы Рәшидетдиннең «Җәмигъ әт-тәварих» («Елъязмалар җыентыгы») исемле атаклы хезмәтендә; XVII йөздә төзелгән «Алтан тобчи» («Алтын риваять») дигән монгол елъязмасында — аның авторы галим лама Лубсан Данзан; XIII гасырның «Мэн-да бэй-лу» («Монгол-татарларның тулы тасвирламасы») исемле кытай хроникасында. Бу чыганакларда монголларның һәм аларның көнчыгыш күршеләре булган төрки телле татарларның тарихы шактый киң яктыртылган. Ул тарих бигрәк тә беренче өч әсәрдә тулы күрсәтелә, ә менә «Мэн-да бэй-лу» да татарлар дип башлыча монголлар атала. Бу хезмәтнең авторы Чжао-Хун татарларны (аныңча, монголларны) өч ыруга бүлә: кара татарлар (хэй да-да), ак татарлар (бай да-да) һәм кыргый татарлар шэн-да-да). Аның замандашы Ли Синьчуань исә культуралы татарлар (шу да-да), һәм шулай ук кыргый татарлар турында яза («шэн»ның сүзгә-сүз кучермәсе — чи, пешмәгән) һәм соңгыларына, нишләптер, ак татарларны да кертә. Кытай әдәбиятында ак татарлар дип гадәттә онгутлар аталалар, ә алар исә чыгышлары белән төрки телле кабиләләр булганнар — бу хакта Рәшидетдин китабында ачык язылган XIX йөзнең күренекле шәрекъшонасы (көнчыгышны өйрәнүче), кытай тарихының зур белгече И. И. Кафаров (Палладий) да шундый ук фикердә тора һәм ул фикергә хәзерге заман галиме, «Мэн-да бэй-лу»ны нәшер иткән һәм шәрехләгән В. Н. Мункуев та кушыла. Чжао-Хун һәм Ли Синьчуань әсәрләрендә, шулай итеп, вакытлар үтү белән монголлар тарафыннан йотылып баручы элекке төрки кабиләләр ак татарлар, өлешчә, мәдәни татарлар дип аталганнар. Әлеге кытай авторларның төрки, монгол, фарсы чыганаклары (Орхон-Енисей язмалары, ягъни кабер ташларындагы язулар, «Монголларның яшерен тарихы», «Алтын тобчи» һәм Рәшидетдин китабы) буенча билгеле булган татарларны монголлар белән беркадәр бутаулары аларның ул татарлар хакындагы мәгълүматлар белән беренче тапкыр очрашуы нәтиҗәсендә туган. Соңыннан алар «татар» исемен барлык монгол-кабиләләренә дә таратканнар.

Әмма шуңа да карамастан, бу ике автор «кыргый», «кара» татарлардан, ягъни чын монголлардан үзгә буларак, югарыда әйтелгәнчә, чыгышлары белән төрки кабиләләр булган «ак» (беркадәр «культуралы») татарларны да атыйлар. «Ак татарлар дип аталучы татарларның буй-сыннары нәзек, үзләре әдәпле һәм ата-аналарын ихтирам итәләр», — диелә «Мэн-да бэй-лу»да. Кара һәм кыргый татарлар исә «җәлпәк битле, киң яңаклылар. Күзләренең өске керфекләре юк. Сакаллары бик сирәк. Тышкы кыяфәтләре шактый ямьсез». Кара татарларга «хәзерге император Чыңгыз, аның барлык әмирләре, министрлары һәм сановниклары да» керәләр, дип өсти Чжао-Хун. Шул ук вакытта ул Чыңгыз ханның башкалардан аерылып торып, зур һәм мәһабәт гәүдәле, киң маңгайлы, озын сакаллы булуын да әйтә («Мэн-да бэй-лу». М., 1975. 48 бит).

Татар халкының борынгы, урта гасырлар тарихын язганда моңарчы күбрәк Болгар дәүләте, өлешчә Алтын Урда һәм Казан ханлыгы заманнарына игътибар ителде.

Әмма халкыбызга исем биргән, аның килеп чыгышында аерым роль уйнаган. Үзәк Азиядән чыккан борынгы татарларның үткәне белән хөрмәтле укучыларыбызны бераз таныштырып үтмәсәк, бабаларыбыз тарихы шактый берьяклы булып калыр иде. Югарыда санап үтелгән чыганакларны җентекләп тикшергәннән соң, бу тарих кыскача болай булып күз алдына килә.

Хәзерге монголлар торган җирләрдә XII йөздә монголларның үзәк һәм башка кабиләләре, мәсәлән, кэрэитләр, меркитләр, ойротлар, найманнар яшәгәннәр. Алардан көнчыгыштарак булган җирләрне, Буир Нур һәм Колын Нур күлләре тирәләрен татар кабиләләре биләп торганнар. Кайбер монгол кабиләләре, шул ук кэрэитләр һәм найманнар, тора-бара шактый гына үсешкә ирешкәннәр, әлегә бик көчле үк булмаса да, беренче дәүләтләрен төзегәннәр. Мәсәлән, Хабул хан җитәкчелегендәге дәүләт булганлыгы мәгълүм. 1137 һәм 1147 елларда монголлар белән цзиннәр (кытайлар) арасында сугышлар булып ала, соңгыларына татарлар ярдәм итәләр. 1164 елда берләшкән цзин-татар гаскәре монголларны тар-мар итә һәм монгол дәүләтенә нык зыян килә. Шушы вакыйга соңыннан Чыңгыз ханга татарлар белән көрәшү өчен бер сәбәп була, ә монголлар белән татарлар арасындагы дошманлык әле 1137 елда ук башлана, ул вакытта татарлар Хабул ханның варисы Амбагай ханны цзиннәргә тотып биргән булалар.

Хабул хан төзегән дәүләт әллә ни нык була алмый. Социаль тигезсезлек үскәннән-үсә бара. Югары катлам арасында хакимлек өчен көрәш көчәя һәм ул озакламый бөтен монгол кабиләләрен берләштерү, бердәм монгол дәүләте төзү эшенә әверелә. Шундый зур эшне Чыңгыз хан үз кулына ала. «Чыңгыз хан» Бөек хан дигәнне аңлата, аның чын, үз исеме — Тимучин. Аңа татарларның юлбашчысы Тимучин әкә хөрмәтенә шул исемне куйшалар, ә Тимучин әкәне Чыңгызның әтисе Есүгәй багатыр улы туар алдыннан гына әсирлеккә алган була.

Есүгәй багатыр (ул — Хабул ханның оныгы) үлгәч, аның олысы таркала. Ләкин тиздән инде шактый буй-сынга җиткән Тимучин, ягъни, булачак Чыңгыз хан, таркалган монгол кабиләләрен берләштерү эшенә чын-чынлап тотына. Талантлы юлбашчы һәм оста дипломат буларак, ул зур уңышларга ирешә. 1198 елда элеккеге дуслар булган цзиннәр белән татарлар арасында низаг, ыгы-зыгы килеп чыккач, шуннан уңышлы файдалана. Җитмәсә, татарлар элегрәк аның әтисен үтерәләр, чөнки әтисе, ягъни Есүгәй багатыр, әйткәнемчә, татарларның юлбашчысын әсир иткән була. Шулай итеп, Тимучин (Чыңгыз) татарларга гомер буе үч тота, аларны үзенең кан дошманнары итеп игълан итә, алардан үч алырга чакыра: «Борын заманнан бирле татарлар безнең бабаларыбызны һәм аталарыбызны үтереп килгәннәр. Явыз һәм үч алучан халык! Без хәзер, мөмкинлектән файдаланып, аларны ике яктан китереп кысарбыз») Лубсан Данзан. Алтан тобчи. М., 1973, 107 бит). Татарлар шул сугышта җиңелсәләр дә, дүрт зур кабилә тәшкил итәләр; чаган татар, илче татар, дутаут татар һәм алухай татар. Чыңгыз хан аларны 1202 елгы сугышта тагын җиңә. Кайбер чыганакларда, ирләр кырып бетерелде, ә хатын-кызлар һәм балаларны башка кабиләләргә бүлеп бирделәр, дип язылса да, татарлар, әлбәттә, бөтенләй юк ителмиләр. Рәшидетдин, мәсәлән, Чыңгызның «татарларны кырып бетерергә» дигән әмере үтәлмәде, күп кенә татарлар көнбатышка киттеләр, дип яза. 1204 елда Чыңгыз хан: «Татарларны балаларына һәм хатын-кызларына кадәр юк итәргә», дип янәдән әмер бирә, тик анысы да ярты-йорты гына үтәлә. Чыңгызның ике хатыны — Ясү һәм Ясүкәй исемле татар хатыннары (ул аларны 1198 елда сугышта әсир төшереп, хатынлыкка алган була) балаларны саклап калалар, ә аның энесе Жучи Хазар үз хатынының үтенече буенча, — ул да татарлардан була, — мең татарның 500 ен коткара.

Чыңгыз хан татар кабиләләрен үзенең дошманы итеп санаса да, татарлар аның шәхси тормышында һәм дәүләт эшендә шактый гына урын тотканнар. Югарыда әйтелгән ике хатыны һәм туганының хатыныннан башка, әле ул татарлардан Котык атлы бер малайны да балалыкка ала. Бер татар кәнизәгеннән аның Чаган атлы улы туа, Чыңгыз аны бик ярата торган була. Ханның иң якын киңәшчеләреннән берсе, империянең баш судьясы Шиги Котык та татарлардан.

Менә шушы югарыда бәян ителгән татарлар һәм татар кабиләләре, әүвәл төрки кавемнар булсалар да, тора-бара, бигрәк тә Монгол империясе төзелгәч, монголлар белән шактый кушылалар. Һәрхәлдә, мәсәлән, Рәшидетдин буенча алар шулай булып күз алдына киләләр. Дөрес, моны бөтен төрки кабиләләр дә монголлар белән аралашып беткән, хәтта монголлашканнар дип уйларга ярамый. Рәшидетдин иң беренче чиратта монгол далаларында яшәгән, алар белән бик нык аралашкан татарлар турында яза. Ул үзе үк аларның әлек күп санлы булуы хакында әйтә. 14 төрки кабиләнең иң зурысы татарлар иде, алар 70 мең гаиләдән торды, ди. «Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм ихтирамга лаек булулары аркасында башка төрки кабиләләр, төрләренең һәм исемнәренең аермалыкларына карамастан, шул исем астына берләштеләр һәм татарлар дип атала башладылар», — дигән нәтиҗәгә килә.

Шуңа күрә, йотылу ике яклы булган, дип уйларга да урын бар. Ул заман монголларының телендә сизелгән төрки катлам, шөбһәсез, татарлар белән бәйле. Чыңгыз хан үзе дә татарча белгән. «Төркиләр шәҗәрәсе» исемле XV йөз фарсы язмасында мондый бер хәбәр китерелә. 1229 елда Чыңгызга читләтебрәк, шигырь белән генә

аның олы улы Жучиның үлемен җиткерәләр. Хан шунда ук аңлап ала һәм төркичә, ягъни, татарча болай дип җавап бирә:

*«Колын алган колындай колынымдин айрылдым.*
*Айрылышкан анкаудай зур улымдин айрылдым».*

(Тизенгаузен В. Г. Алтын Урда тарихы буенча материаллар. 2 нче том. М.—Л., 1941, 204 бит. Монда «анкау» — аңгыра, тинтәк, ә «эр» — беренче диган сүзләр).

Әмма шуңа да карамастан, үз токымын, монгол ханын саклауга, Монгол империясен төзүгә бөтен көчен биргән Чыңгыз хан чит кавем, чит кан кешеләре булган татарларга үзенең элекке дошманнары, көндәшләре итеп караган. Инде Евразияне яулап алу сугышлары башлагач, ул татарларны үз гаскәрләренең бәрелешкә алдан кертә торган, дошман явы белән беренче булып орыша торган чирүе итеп куя башлый. 1254 елда империянең башкаласы Каракорымда булган Фламандия сәяхәтчесе Гильом Рубрук болай дип яза: «Аннары Чыңгыз һәр җирдә татарларны алга җибәрде, шуннан бу исем тарала башлады, чөнки бөтен җирдә: «Менә татарлар килә», дип кычкыралар иде» (Плано Карпини һәм Рубрукның Көнчыгыш илләргә сәяхәте. М., 1957, 116 бит.) Бу уңайдан тагын бер европалы — венгр монахы Юлианның хәбәрләре дә кызыклы. Ул 1237—1238 елларда, ягъни монгол яулары вакытында миссионер сыйфатында Көнчыгыш Европага сәяхәт кылган була: «Яулап алган барлык җирләрдә алар үзләре өчен куркыныч саналган, каршы торырлык кенәзләр һәм башка җитәкчеләрне шунда ук үтереп бетерәләр. Сугышка яраклыларны коралландырып, үзләреннән алда көчләп сугышка кертәләр... һәм аларны татарлар дип аталырга мәҗбүр итәләр» (Аннинский С. А. XIII—XIX йөзләрдә венгр миссионерларының татарлар һәм Көнчыгыш Европа турындагы хәбәрләре. Тарих архивы. 3 том. М.—Л., 1940, 87 бит.) Шулай итеп, алдынгы гаскәрнең исеме белән бөтен монгол явы да татар явы итеп кабул ителә һәм бу исем киң таралыш ала.

Евразия дәүләте яулап алынып, Алтын Урда дәүләте төзелгәч, монголларның төп көчләре үз илләренә — Монголиягә кайтып китә, ә Чыңгыз ханның оныгы, дәүләтне төзегән Бату хан җитәкчелегендәге «татарлар» дип аталган монголлар ул җирнең төп төрки халкы булган кыпчаклар тарафыннан йотылалар. Бу хакта шул заманның атаклы гарәп энциклопедист-тарихчысы әл-Гомәри менә ничек яза: «Борын заманда бу дәүләт кыпчаклар иле иде, ләкин аны татарлар яулап алгач, кыпчаклар аларга буйсындылар. Аннары алар (татарлар) тегеләр (кыпчаклар) белән туганлаштылар, һәм ул җир аларның (татарларның) табигатен һәм төс-кыяфәтен җиңде һәм алар барысы да кыпчакларга охшап калдылар, әйтерсең, алар бер нәсел-ырудан иделәр, монголлар (һәм татарлар) кыпчак җирләренә күчеп утырдылар, алар белән туганлаштылар һәм аларның (кыпчакларның) җирләрендә калдылар. Шулай итеп, нинди дә булса илдә һәм җирдә озак яшәү кешенең табигатен шул мохитка яраклашырга, үзенең тумыштан килгән килеш-кыяфәтен шул илнеке кебек итәргә мәҗбүр кыла». (Тизенгаузен В. Г. Алтын Урда тарихы буенча материаллар. 1 том. СпБ. 1884. 235 бит.)

Әл-Гомәри бу сүзләрне XIV йөзнең беренче яртысында, ягъни Алтын Урданың иң көчле, иң куәтле чорында язган. Элегрәк, ягъни XIII йөзнең икенче яртысында — Урда дәүләтенең башлангыч дәверендә — аның рәсми теле булып монгол теле саналган. XIV йөздә бөтен Алтын Урдада кыпчак теле хакимлек иткән, бу хакта Шәрекънең һәм Көнбатыш Европаның тарихи чыганакларында бик ачык язылган. Берничә генә мисал китерик. 1333 елда Алтын Урданың үзәк җирләрендә, аның Сарай, Азак, Маҗар, Хаҗитархан һәм башка шәһәрләрендә булган гарәп сәяхәтчесе Ибн Баттута бу җирләрне аның әүвәлге исеме белән «Дәшти Кыпчак», ә аның халкын «кыпчаклар» дип атый. Франческо Пеголотти атлы итальян сәяхәтчесе үзенең 1340 елда язылган «Сәүдә эше» исемле китабында Алтын Урдага барырга теләгән сәүдәгәрләргә, тылмачтан башка, коман, ягъни кыпчак телен яхшы белгән бер-ике әйбәт хезмәтче дә алырга тәкъдим итә. Башлыча шул сәүдә эшендәге аралашуны җиңеләйтү максатында 1304 елда ук әле Италиядә «Кодекс куманикус» («Коман мәҗмугасы») исемле кыпчык сүзлеге төзелә. Гомумән, XIII—XV йөзләрнең атаклы гарәп-фарсы географиясенең күп кенә вәкилләре, мәсәлән, Жузҗани, Җүәйни, Ибн әл-Биби, Рәшидетдин, әл-Гомәри, Ибн Баттута, Ибн әл-Форат, Ибн Халдун, Хәмдулла Казвини, Низаметдин Казвини, әл-Гасади, әл-Гайни, Шәрәфетдин Йәзди һ. б. калдырган язмаларда «Дәште Кыпчак», «Кыпчак ханлыгы», «кыпчак далалары», «кыпчаклар» кебек атамалар тулып ята.

Ләкин бер үк вакытта яңа сүз, яңа исем — «татар» исеме киң тарала башлый. «Татар ханлыгы», «татар патшалары», «татар гаскәре», «татарлар», хәтта «татар дине» һ. б. шундый тәгъбирләр әкренләп «кыпчак»ны кысрыклап чыгаралар. 50—60 ел да үтми, Алтын Урда дәүләте инде бөтенләе белән татар дәүләтенә әверелә, татар җирләре дип атала башлый. Сүзебез дәлилләрәк булсын өчен, XV йөздә шул җирләрне үз күзләре белән күргән ике генә кешенең язмаларын китерик. 1436—1452 елларда Азак (хәзерге Азов) шәһәрендә яшәгән, Венециядән килгән дипломат һәм сәяхәтче Иосифат Барбаро: «Татар далаларында 1438 елда Олы Мөхәммәт хан идарә

итте, ул безнеңчә император Бөек Мөхәммәт дигәнне аңлата... Татарлар менә дигән ауычылар... Татарлар бик күп һәм кирәк вакытта алар өч меңнән алып дүрт меңгә кадәр гаскәр куя алалар (монда сүз Кырымдагы Кафа, хәзерге Феодосия шәһәре турында бара.— Р. Ф.)... Идел — күп сулы һәм гаҗәеп киң елга, ул Баку (Каспий.— Р. Ф.) диңгезенә коя... Әгәр дә шул елга белән... Мәскәүгә таба йөзсәң, унбиш көн буена елга яры буйлап Тартар җиренең бик күп санлы кабиләләре белән очрашасың». (Барбаро һәм Контарини Россия турында. Л., 1971. 140, 148, 154 битләр. Көнбатыш Европада «татар» сүзе уртасындагы «р» белән «тартар» рәвешендә дә йөргән). Яки менә икенче бер автор — монысы Шәрекъ кешесе, төрек солтаны Мөхәммәт 1 дә секретарь булып хезмәт иткән, соңыннан Аксак Тимернең биографы, Сарайда, Хаҗитарханда, Кырым һәм Хәрәземдә булган атаклы гарәп тарихчысы һәм язучысы Шиһабетдин ибн Гарәбша: «Бу — төрле җәнлекләр һәм төрки кабиләләр белән тулган, һәр яктан чикләнгән (сакланган.— Р. Ф.) һәм бар өлешләре дә эшкәртелә торган, бик киң, шифалы һавага һәм саф суга бай чын мәгънәсендә татар җире. Аның кешеләре — чын ирләр, сугышчылары — менә дигән укчылар. Телләре ягыннан алар оста сүзле, иң матур телдә сөйләүче төркиләр (В. Г. Тизенгаузен... Материаллар. 1 том, 459 бит).

Хөрмәтле укучыларда, ихтимал, мондый сорау туар: шулай да, диярләр алар, башта, ягъни Чыңгыз, соңра аның оныгы Бату хан гаскәре яу белән килгәндә анда монголлар белән бергә татарлар — төрки телле татарлар да булганмы, әллә алар ул вакытта инде монголлашып беткән булганнармы? Эш шунда ки, «татар-монгол» мәсьәләсе белән туган сорауларга җавап бирү өчен ничәмә-ничә буын тарихчылар баш вата. Берәүләр катнаш татар-монголлар (яки монгол-татарлар) булганлыгын дәгъвалап язалар; икенчеләр бары тик татарлар турында гына әйтергә яраталар, барлык монголларны да татарлар дип атыйлар, шулай итеп, бөтен Азияне һәм ярты Европаны яулап алуны безгә, ягъни, татарларга гына сылтамакчы булалар; өченчеләре исә анда бернинди татар да булмаган, «татар» исеме читтән алынып, бары тик монголларны атау өчен генә кулланылган, ә «монгол-татар» («татар-монгол») дигән тәгъбирне соңыннан тарихчы-галимнәр генә уйлап чыгарган ясалма исем, диләр.

Әлеге мәсьәләләрнең барысына да бәйнә-бәйнә аңлатма бирергә, тулы фәнни анализ ясарга җыенмыйм. «Татар-монгол» мәсьәләсендә тарих фәненең үзендә капма-каршы фикерләр булган кебек, укучылар да үзләренчә кабул итәләр: берәүләр монголлар арасында, хәтта Алтын Урданың үзендә дә татарлар булмаганлыгына ышаналар, бу дәүләтнең безнең тарихыбызга бер катнашы да юк, дип уйлыйлар, икенчеләр бөтен монгол явын татарлар, ягъни безнең бердәнбер бабаларыбыз һөҗүме итеп кабул итәләр, Бөек Чыңгыз һәм Батый исемнәре белән горурланалар.

Минем әлегә шуңа басым ясап үтәсем килә. Тарих ул теге яки бу галимнең аерым фикере, укучыларның шәхси уй-теләкләре, симпатия-антипатия, милли хисләре белән генә торгызыла торган әйбер түгел. Моңа бары тик объектив, барлык булган тарихи мәгълүматларга вә фәндә тупланган фикерләргә намуслы һәм профессиональ бәя бирү нигезендә генә ирешергә мөмкин. Моңарчы кемнәргәдер билгеле булмаган яки киресенчә — булып та күз йомып үтелгән кечкенә генә тарихи вакыйга да игътибардан читтә кала алмый. Кала икән, тарих тулы, дөрес булмый. Менә шушы уңайдан мин бер-ике мәсьәләгә генә кыскача тукталмакчы булам.

Иң мөһиме һәм без ул хакта югарыда төрле тарихи чыганаклардан ачык күреп үттек: Монгол империясе төзелгәнче дә, дәүләт составында да төрки телле татар кабиләләре булган. Басып алынган халыкларның монгол гаскәрен күреп, «Менә монголлар килә!» — дип кычкырулары хакында язган Гильом Рубрук, мәсәлән, монголлар белән беррәттән «татар исемле башка ярлы кабиләләр да бар», дип әсти. «Ярлы» сүзен монда, һичшиксез, үзләренең дәүләте, милке булмаган, башкаларга буйсынганнар итеп аңларга кирәк. Чыңгыз армиясе 1222 елда Грузия һәм Әзербайҗанны яулап алып, Гирван тарлавыгы аша Төньяк Кавказ киңлекләренә килеп чыга һәм берләшкән алан-кыпчак гаскәре белән очраша. Бу уңайдан XIII йөзнең атаклы гарәп тарихчысы Ибн әл-Әсир болай дип яза: «Шулчак татарлар кыпчакларга илчеләр җибәреп әйттеләр: «Без һәм сез бер ырудан, ә аланнар сезнекеләр түгел». Татарлар кыпчакларга акчалар һәм бүләкләр биреп, аланнарны калдырып китүләрен сорыйлар. Тегеләр ышанып, шулай итәләр, шуннан соң Чыңгыз армиясе аерым-аерым башта аланнарны, соңыннан кыпчакларның үзләрен дә тар-мар итә (шундый ук хәбәр Рәшидетдиндә дә бар). Ул сүзләрне нинди дер демагогия дип кенә карап булмый: максатларына ирешү өчен алар икенче хәйлә дә уйлап тапкан булырлар иде, ә монда татарлар үзләренең кыпчаклар белән кардәш булганлыгын яхшы белеп, шуннан оста файдаланганнар. Димәк, бу хәбәр дә монголлар арасында төрки телле татарларның булганлыгы хакында сөйли.

«Монгол-татар» (яки «татар-монгол») дигән кушма исем дә укучыларга гаҗәп тоелмасын. Бу сүз тарихи чыганакларда бар һәм аңа күз йомып кала алмыйбыз: югарыда телгә алынган «Мэн-да бэй-лу» дигән кытай хроникасы исеменең баштагы өлеше, ягъни «мэн-да» «монгол-татар» дигәнне аңлата («мэн» «мэнгу», ягъни «монгол» сүзеннән, ә «да» безгә мәгълүм булган «да-да» — «татар»дан). Ләкин бу һич кенә дә монгол белән татар бер халык булган дигәнне аңлатмый. Чагыштыру өчен бик үк төгәл булмаса да, бер мисал: күптән түгел безнең халык телендә кулланышта йөргән

«ар-чирмеш» сүзе дә бит «ар»лар (удмуртлар) белән «чирмеш»ләрне (мариларны) бер халык итеп исбатламый. Ике халыкны белдерүче кушма этнонимнар тагын да очрый, мәсәлән, татар-башкорт, кыргыз-кайсак һ. б.

Көнчыгыш Европага килеп, Алтын Урда төзегән монголлар һәм татарлар күпме булган соң? Рәшидетдиннең әйтүенчә, Чыңгыз хан үзенең олы улы Жучига көнбатыш җирләрне яулап алу өчен дүрт мең сугышчы бирә (монда монгол сугышчылары күз алдында тотыла). Бу гаскәр Жучиның олы улы Батуга кала, чөнки әтисе 1227 елда Чыңгыз хан белән бер елны үлеп китә, ә аның әмерен, ягъни көнбатышны яулауны һәм, шулай итеп, Алтын Урда дәүләтен төзүне Бату хан башкара. «Монгол унниуга тобчаган» да икенчерәк сан — тугыз мең гаилә, «йорт» күрсәтелгән (гомуми сан китереп чыгару өчен тугыз меңне бишкә тапкырларга туры килә, чөнки һәр йорт уртача биш кешедән торган дип исәпләнә).

Дүрт яки тугыз мең, әйткәнемчә, булачак Жучи олысы өчен Чыңгыз ханның үзе тарафыннан билгеләнә. Соңра, 1235 елдагы бөтен монгол корылтаеннан соң Европаны басып алу сугышы башлангач, Бату ханның гаскәрендә алар шактый күбәя. Юлиан, мәсәлән, 135 мең монгол булганлыгын әйтә, ә аның замандашы, икенче бер доминикан монахы Сентковский 160 мең иде, ди. Әмма бу саннар әлеге шул сугышларга, ягъни 1236—1240 елларга карыйлар, чөнки Көнчыгыш Европаны басып алгач, монголларның төп көчләре кире Монголиягә кайтып китә. Ә калганнарын шул дүрт яки тугыз мең тирәсендә дип уйларга кирәк. Болар — чын монголлар, югары катлам, гаскәр башлыклары (ун мең, мең кешелек гаскәрләр), башка төрле аксөякләр, араларында беркадәр татарлар да булмаган түгел. Төп масса исә — яулап алынып, Юлиан әйткәнчә, кулларына корал тоттырып сугышка кертелгәннәр: «ярлы» татарлар, Себер, Урта Азия, Кавказ халыклары, хәтта урыслар да бар. Шул ук Рәшидетдин, дүрт мең сугышчы турында әйткәч, аларга урыслар, чиркәсләр, кыпчаклар, мажарлар һәм башкалар кушылдылар, дип өсти (Тизенгаузен В. Г.... Материаллар.... 2 том. М.-Л., 1941. 33 бит). Шулай итеп, монгол яулары бер монголларныкы яки монгол-татарларныкы гына түгел, ә монгол армиясенә кертелгән башка күп кенә кабиләләрнең дә явы итеп күрсәтелергә тиеш.

Мәсьәләнең шул ягы бар бит әле. Гадәттә, тарихта булган — ерак гасырлардамы, күптән түгел булып узган вакыйгаларммы, барыбер,— басып алу сугышлары, кан коюлар турында сүз барса, аның өчен ул басып алучыларның бүгенге токымнары җавап бирми, дип әйтелә. Мәсәлән, Гитлер өчен немец халкы, Наполеон өчен французлар, явыз Иван өчен бүгенге урыслар җаваплы түгел, диләр. Соң шулай булгач, Чыңгыз яки Бату армиясендә сугышкан, җитмәсә, ул ханнарга кан-кардәшлек ягыннан бернинди катнашлары булмаган татарлар һәм башкалар җавап бирә аламы? Юк, әлбәттә. Явыз Иван өчен бүгенге урыс җавап бирмәгәнне, ни өчен монгол Чыңгыз өчен безнең татар җавап бирсен ди...

Югарыда без татар этногенезында монголларның роле булмаган, дидек. Әмма бу һич тә борынгы татарларга карата әйтелгән сүз түгел. Азмы, күпме,— анысы әлегә мәгълүм түгел,— борынгы татарлар бүгенге татар халкының килеп чыгышына, аның этник тарихына үзләренең өлешләрен кертканнәр. Ә инде халкыбыз исеме, гомумән, шул борынгы татарлардан килә һәм аның VIII гасырдан санала башлаган һәм 1200 елдан артыкка сузылган озын вә гыйбрәтле тарихы бар.

«Без шул татарларның гына токымнары, башка беркем дә түгел»,— дип әйтергә яратучылар исә бер бик тә мөһим әйберне онытмасыннар иде: бүгенге берәр халыкны аның урта гасырда яки аннан да элегрәк яшәгән бабаларыннан берсенең турыдан-туры токымы итеп карап булмый. Теге яки бу халыкның килеп чыгышы, аның нәкъ менә халык буларак формалашуы гәрчә ул тарихи исемне биргән борынгы кабилә бүгенгесенең этник үткәнендә теге яки бу дәрәҗәдә үз эзен калдырса да, исеменең, этнонимының килеп чыгышы белән вакыт ягыннан да, асыл мәгънәсе белән дә еш кына туры килми. Бу — дистәләгән, йөзләгән халыкларның озын һәм катлаулы, гыйбрәтле вә мактаулы тарихында дистәләрчә, йөзләрчә мәртәбә расланган хакыйкать!

Бу халәттән бер-ике генә мисал. Бүгенге славян болгарларга, ягъни Дунай болгарларына исемне борынгы төрки, Азов буе болгарлары («Аспарух болгарлары»), урысларга төньяктагы «рус» дигән варяг кабиләләре (варяглардан булган Рюриклар нәселе Рус дәүләте белән IX йөз ахырыннан XVI гасырдагы Федор патшага кадәр идарә иткән), французларга төньяк герман кабиләләре булган франклар калдырганнар. Борынгы болгарлар да, урыс-варяглар да, франклар да, гәрчә үзләре алар тарафыннан әкренләп йотылсалар да, шул заманның көньяк һәм көнчыгыш славяннар, ә Көнбатыш Европада галлар яшәгән җирләрдә беренче зур дәүләтләр (Болгар патшалыгы, Киев Русе, Франк дәүләте) төзегәннәр һәм җирле халыкларга үзләренең исемнәрен такканнар. Шул ук вакытта борынгы болгарлар, урыслар һәм франкларның эзләре бүгенгеләрнең телләрендә, матди һәм рухи культураларында нинди дер күләмдә сакланган.

Борынгы татарлар белән дә шундыйрак хәл. Дөрес, Алтын Урда дәүләтен башлыча монголлар, ягъни Чыңгыз хан нәселеннән чыккан кешеләр төзегәннәр, әмма алар ул вакытта татарлардан алган икенче, параллель, әмма күбрәк таралган «татар»

дигән исем йөрткәннәр һәм шул исемнәрен әлеге дәүләтнең төп җирле халкына — төрки кабиләләренә такканнар. Кыпчакларның ничек итеп татарларга әйләнделәре белән без югарыда танышып үттек.

Алтын Урда заманында ук инде андагы күпчелек халык шушы «татар» исеме белән йөри башлый, ә Урда таркалып, мөстәкыйль ханлыклар оешкач, бу исем аларда бөтенләйгә урнашып кала. Дөрес, аларның кайберләрендә, мәсәлән, Казан ханлыгында баштарак элекке этник исемнәр дә саклана. Урыс чыганаклары буенча, анда «болгар», «бисермән» («бусурман», ягъни «мөселман» сүзеннән), «казанлылар» атамаларының кулланылышта булуы билгеле. Әмма «татар» исеме дә керә бара. Казан дәүләтеннән аермалы буларак, башка төркемнәргә, мәсәлән, мишәрләргә, Себер, Әстерхан һәм Кырым татарларына бу исем тагын да иртәрәк, XIV гасырда ук керә.

Төрки телле халыклар арасында сан ягыннан иң күп булган һәм социаль-икътисагый үсеше ягыннан да шактый алга киткән татарлар XIX йөздә ук милләт буларак формалаша — берничә гасырлардан килүче «татар» дигән этнонимы, үзатамасы белән бергә оеша, берләшә.

Димәк, Үзәк Азиядә яшәүче борынгы төрки кабиләләрдән берсенең этнонимы баштарак аларны үзләренә буйсындырган чыңгызлы-монголларга да күчә, аларның XIII йөздә көнбатыш җирләргә яу белән килгәндә киң таралыш алган икенче, параллель исемнәре булып китә һәм алар аркылы Көнбатыш Себер белән Көнчыгыш Европаның төрки телле халыклары арасында тарала. Шулай итеп, «татар» исеменең килеп чыгыш һәм таралыш тарихы шактый катлаулы була, бердәм халык булып оешу дәвамында татарлар узган озын тарихи юлны бик ачык чагылдыра.

Татар халкының зур этник-мәйданый төркемнәреннән булган Идел һәм Урал буе татарлары этногенезының нигез бабалары, аерым компонент, өлешләре турында берничә сүз.

Урта Идел һәм Урал буе татарларының этногенезы турында тарих фәнендә берберсен тулыландыра, баета торган ике төп теория яши. Татарларның бабалары кыпчаклар булган, дигән фикер телгә, өлешчә тарихи материалларга һәм кыпчакларның инде XIV—XV йөзләрдә үк «татар» исемен йөртүләре турындагы бәхәссез тарихи фактка нигезләнгән. Бу теория өчен төп лингвистик чыганак булып XIV гасыр башында ук төзелгән һәм инде безгә таныш булган «Коман мәҗмүгасы» хезмәт итә. Аның теле хәзерге татар теленә, беренче чиратта, көнбатыш диалектына якын. Кыпчаклар хәзерге Пенза өлкәсенә һәм аның тирә-ягына XIV—XV йөзләрдә үк күченеп утырган булалар. Алар анда Урда кенәзләре, мәсәлән, Сикез би, Тагай, Бихан атлы биләр җитәкчелегендә киләләр, ул җирләрдә зур гына бер татар олысы оеша, аның сәяси үзәге Наручад (Мукшы) шәһәрендә була, шунда ук акча да сугыла. Бу хакта урыс елъязмалары да, нумизматика материаллары да ачык сөйли. Мордва АССРда табылган татар шәҗәрәсе буенча соңыннан Сәетәхмәтовлар, Адашевлар, Кудашевлар, Тенишевлар, Янгалычевлар дип аталган татар кенәзләре дә билгеле. Шәҗәрәдә әйтелгәнчә, алар Алтын Урда ханының ярлыгы нигезендә Мукшы (Мохша) елгасы буендагы шәһәрләр һәм күп кенә авыллар белән идарә иткәннәр.

Татар теленең мишәр диалектында кыпчак нигезе булуын Казан галимнәренең соңгы елларда үткәргән тикшеренүләре дә раслый. Тел галиме М. Зәкиев мишәр этногенезында, кыпчаклардан тыш, борынгырак халыкларның да катнашуын әйтә. Шулар арасында — гарәп-фарсы географиясе һәм Византия чыганаклары буенча билгеле булган, сөн кабиләләре берлегенә кергән акацирлар һәм соңгырак мажарлар.

Мажарлар турындагы фикерне куәтләгән хәлдә, мин мишәрләрнең этник тарихында беркадәр болгарлар да катнашкан дип уйлыйм. XII йөз ахырларында һәм XIII йөз башларында, бигрәк тә Алтын Урда дәверендә болгарларның беркадәр өлеше әлеге шул Мукшы елгасы буйларына күченеп утыралар, хәзерге Пенза өлкәсендә табылган археологик истәлекләр, мәсәлән, шәһәр һәм авыл калдыклары шул хакта сөйли. Әмма алар күп булмаганнар һәм әкренләп кыпчаклар белән кушылганнар. Болгар теленең кыпчак теле тарафыннан ассимиляцияләнүе иң әүвәл шул көнбатыш җирләрдә була.

Матди һәм рухи мәдәният буенча бүгенге көнгә тупланган мәгълүмат казан татарлары этногенезында болгарларның зур роль уйнаганлыклары хакында сөйли. Болгар дәүләтенең шәһәр һәм игенчелек культурасы Казан ханлыгы заманында яңа, зур үсеш ала. Казан мисалында болгарларның сәүдә традицияләре саклану да күренә. Болгарлар һәм Казан татарлары экономикасында һәм мәдәниятендәге дәвамлылыкны шәһәрләр төзүдә, архитектура һәм хәрби корылмалар эшләүдә дә күреп була. Бу уртаклык һөнәрчелекнең башка төрләрендә, халык сәнгате әсәрләрендә нык чагыла. Болгар, Бүләр, Суар, Җүкәтау һәм башка шәһәр калдыкларын, Иске Казанны, Казан кремлен, Тәберде Чаллысы шәһәрлеген казыганда табылган әйберләр бер-берсен кабатлыйлар. Бу җәһәттән авторның соңгы ел тикшеренүләренең төп объекты булган Иске Казанда тупланган бай материал бик тә игътибарга лаек. Ул — шушы ике җирле культураны берләштерә алучы мөһим буын — монда монголларга кадәрге чор, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверләренең матди калдыклары ята. Казан татарларының ювелир, гомумән, декоратив-гамәли сәнгате үзенең ясалу ысуллары, нәкыш-бизәкләре белән болгар сәнгатенә нигезләнгән дип әйтергә мәгълүмат җитәрлек.

Елъязмалардагы «Болгар-Казан», «хәзер казанлы дип аталучы болгарлар» (XVI йөз) дигән тәгъбирләр дә этник дәвамлылыкны дәлилли.

Ләкин Казан татарларының урта гасырлар тарихын, аның бөтен этник тормышын бары тик болгарлар белән генә бәйләү бик тә берьяклы адым, чөнки болгарлардан тыш, Казан татарларының этник тарихына кыпчакларның кергкән өлеше дә шактый. Мәгълүм ки, татар теле һәм, әлбәттә, Казан татарларыныкы да, кыпчак телләре төркеменең кыпчак-болгар төркемчәсенә керә. Казан татарлары этногенезындагы кыпчак компоненты турында сөйләгәндә мин иң беренче чиратта Түбән Иделдә яшәгән кыпчакларны — сәкъсиннәрне күз алдында тотам. Нәкъ менә аларның һәм көнбатыштарак яшәгән кыпчакларның монгол яулары алдыннан Болгар җиренә күченеп килүләре елъязмаларда теркәлгән. Бик күп булмаса да, кыпчакларның археологик истәлекләре дә Урта Иделдә, Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында очрый (аз булулары, бәлки, кыпчакларның башта күчмә тормышта булулары белән аңлатыладыр). Кыпчак этносының эзләре шулай ук фольклор әсәрләрендә, Казан карачыларының, ягъни бөек кенәзләренең кайбер нәселләрендә дә күренә.

Болгарлар һәм кыпчаклар хакында сөйләгәндә мин мөхтәрәм укучыларның игътибарын бер әйбергә җәлеп итәсем килә. Бу ике халыкның бер-беренә якынлыгы, ыруларының һәм телләренең бер тамырдан икәнлеге хакында әле XII йөзнең тарихи чыганакларында ук хәбәр бар. Фәкыйрегез аларны Идел буе төркиләренең ике зур этнографик төркеме, телләренең шул гомум төрки теленең ике шивәсе дип саный.

Казан татарларының халык буларак формалашуында нугайларның, ягъни XV—XVI йөзләрдә Җаек буйларында, Казан ханлыгы белән күрше булып яшәгән Нугай урдасының халкы — нугай татарлары да катнашкан. Бу — тарихи чыганаклар, Казан артының шивәләре һәм топонимнары, шулай ук татар халык дастаны «Идегәй»дә сөйләнгән вакыйгалар белән дә раслана. Әлбәттә, җирле фин-угыр халыкларының бер өлеше татарлар тарафыннан ассимиляцияләнүен онытырга ярамый. Моның шаһиты — антропология, топонимия, тел һәм этнография мәгълүматлары. Хәлбуки, угыр-фин элементы керәшеннәрдә күбрәк, әмма алар, диннәре аерым булса да, шул ук Казан татарлары.

Ниһаять... борынгы татарлар, ерактан, Орхан-Енисей якларыннан, тарих бабай бүләк иткән төрле заманнарда Көнбатыш Себергә, тагын да бирерәк, Идел буйларына күчеп килгән татар кабиләләре. Иң әүвәл «Утыз татар», «Тугыз татар»ларның көнбатышка китеп, соңгарак Мәхмүт Кашгари, «Хөдүд әл-галәм»дә һәм әл-Гардизида искә алынганнары — бусы бер чор, бер кавем. Икенчесе — XIII йөздә монголлар белән бергә килгән татарлар. Боларның һәммәсе бүгенге татар халкының — Себер һәм Әстерхан, Казан һәм Кырым татарларының бабаларының берсе. Үги баба түгел, ә үз бабасы. Исемен калдырган җисемен дә калдыргандыр инде...

Менә боларның барысын да искә алсак, хәтта Казан татарларының гына да,— башка этнографик төркемнәрне әйткән дә юк инде,— бер болгарның гына турыдан-туры токымы түгеллегенә ышану кыен булмас. Казан татарлары халык буларак Болгар чорында түгел, ә Казан ханлыгы дәверендә формалаша.

Татар халкының башка этнографик төркемнәрендә мәсәлән, мишәрләрдә, болгар компоненты булса да, зур түгел; кайберләрендә исә бик аз, әйтик Әстерхан татарларында, ә инде Себер һәм Кырымныкыларда бөтенләй юк.

Шөбһәсез, Болгар заманы Татарстан ССРның урта гасырлар тарихында данлы бер дәвер булып тора. Болгар дәүләтенең, гомумән, болгар цивилизациясенең тарихын өйрәнү нәкъ менә Көнчыгыш Европадагы иң беренче феодаль дәүләтләрнең берсе булган зур берләшмәнең тарихын, аның бай матди һәм рухи культурасын, Болгар дәүләтенең татар һәм башка халыкларның катлаулы тарихында тоткан ролен тикшерү һәм таныту рәвешендә алып барылды һәм шулай булырга тиеш тә.

Шулардан чыгып, болгарлар белән татарларның бөтенләй бер үк халык икәнлекләре турындагы фикерне артык беркатлы, фәнни яктан дөрес булмаган, дип бәяләргә кирәк. Бу идеяне филология фәненең кайбер вәкилләре һәм мәсьәләнең асылын аңлап җиткермәгән аерым җәмәгать оешмалары «татар» исемен «болгарга», «Татарстан»ны «Болгарстан»га алыштырырга кирәк дип дөньяга чыгардылар. Кызганыч ки, юк-бар сүзгә иңке-миңке килеп китә торганнар шуларга ышанып, алар оештырып язган һәм республиканың рәсми оешмаларына, гәзит-журнал редакцияләренә җибәргән хатларга кул да куйдылар. Моннан ике ел элек республикабызның һәм Казан шәһәренең хәбәр тарату чараларында шушы мәсьәлә буенча куерып киткән бәхәсләр вакытында җәмәгатьчелекнең күп өлеше бу ниятне кабул итмәде. Әлеге мәсьәләне ачыклап һәм күп санлы хатларга күзәтү ясап, мин гәзит битләрендә мәкаләләр бастырдым. Гомумән, шушы һәм борынгы тарихыбыз мәсьәләләрен күтәреп рәсми оешмаларга, газета-журнал редакцияләренә, телевидение-радиога, безнең институтка һәм үз исемемә килгән 700 гә якын хат белән таныштым. Бу хатларда — халык фикере, аларны олысы да кечесе дә, галимнәр һәм эшче-игенчеләр дә, республикабыз кешеләре дә, аннан читтә яшәүчеләр дә язганнар. Аларның чагыштыргысыз күпчелеге халкыбызның озын вә данлы тарихы, аның ерак гасырлардан килә торган «татар» дигән исеме белән чын мәгънәсендә горурланып язалар. «Татар

булып тудык, татар булып үстек, татар булып үләрбез дә!» — менә шундый һәм шуңа охшашлы сүзләрне хатларда күп очраттым мин.

Дөрес, «татар» исеменә каршы язганнарны да укыдым, аларның шактые газетләрдә басылып та чыкты (плюрализм заманы бит!), әмма алар азчылыкны (14—15%) тәшкил итә. Ул хатларны һәм реплика-мәкаләләрне язучыларның күбесе — әлеге кирәкмәгән эшне оештырып, вәсвәсәләнеп йөрүчеләргә сукырларча ияргән, тарихтан хәбәрдар булмаган кешеләр.

Минем аларны гаепләсем килми, сүз әйтергә теләгәне әйтсен, аны да хөрмәт итәргә, тыныч кына кабул итә белергә кирәк. Аянычы — бер яки берничә кешенең «татар» исеменә каршы оештырып язган хатларына башкаларның уйламыйча кул куюлары. Тагын да аянычы һәм кызганычы — «Болгар әл-Җәдид» исемле җәмгыятьнең бу өлкәдә әле бүген дә зыянлы эш алып баруы, тарихны күрә торып бозып сөйләгән һәм язган сүзләргә ышанучы фанатикларның Оренбург мәчете һәм нинди-дер билгесез оешма ярдәмендә «Болгар иле» дигән газит чыгарып, шунда «татар» исеменә каршы алып барган эше. Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, китап тарихчысы Ә. Кәримуллинның «Татарлар: исеме һәм җисеме» дигән хезмәте дә дөнья күрде, ул ике тапкыр моңарчы булмаган зур тиражлар белән урыс телендә басылып чыкты. «Татар» сүзеннән хурланып, татарлар турында дөньяда нинди начар сүз бар (кайсы халык турында гына төрле сүзләр сөйләмиләр икән!), шуларны туплап чыгарылган әлеге китапны укыган татарның аумакае, болай да милләте өчен хурланып йөрүче һәм иманын саткан бер манкорт тагын да бер хурланып куяр инде; берәү нәрсә язса, шуңа ышанып китүче, әле күп нәрсәне белеп тә, аңлап та бетермәгән яшь-җилбәзәк туган халкының исеменнән йөз чөерер, ә татарны гомере буе яратмаган икенче бер милләт агае (андыйлар да бар бит) шушы исемне әйтеп, рәхәтләнеп бер сүгенер. Әлеге китап 1989 елгы халык исәбен алу көннәре алдыннан чыгарылды һәм аны «Болгар әл-Җәдид» оешмасы юкка гына үзенең байрагы итеп күтәреп алмады, анысы да бит үзенең эшчәнлеген шул вакытларда җәелдереп җибәрде. Шушы эшләрнең нәтиҗәсе дә булмый калмады, җан исәбе алганда бер даирә кешеләр «болгар» дип язылдылар, димәк, рәсми кәгазьләр буенча болгарга, Болгария мәмләкәтенең СССРда яшәүче халкына әйләнделәр, ә татар халкы ничәмә-ничә кешегә кимеде. Шушы мәкаләмне укучыларга мин: «сак булыгыз, андый коткыларга бирелмәгез», дип мөрәҗәгать итәм.

Күп нәрсә татарны бүлгәләү, аның санын киметү максатында эшләнә. Халкыбыз данлы үткәне һәм, иншалла, матур киләчәге белән кемнәрнедер кыенсындыра да торгандыр, әмма ул кодрәтле, үзенчәлекле вә матур исеме белән яңадан-яңа гасырларга аяк басар.

Ерак бабаларыннан берсенең — Алтын Урда кенәзенең исемен, һичкемнән дә уңайсызланмыйча, үзенә фамилия итеп алган бөек шагыйрә Анна Ахматованың улы, төрки халыклар тарихы буенча бик кыйммәтле фәнни хезмәтләр бастырган атаклы урыс совет тарихчысы Л. Гумилев «татар» атамасы турында: «Белегез, бу горур исем!» дип язып чыкканда, үзебезнең үк голәмә туган халкының исеменнән гарьләнеп, аны алыштырырга өндәп китап-мәкаләләр яза, газитләр чыгарып ята. Тукай юк, тозлап-борычлап, шундыйларга бик «матурлап» бер шигырь багышлар иде... Кемгә үз исеме ошамый, теләгәнчә ямансасын, ашкына икән — алыштырсын. Әмма зур бер халыкның исеменә кагылырга, аңа яла ягарга бер генә «акыллы» затның да хакы юк!

Бу мәсьәләдә бөек Тукаебыздан үрнәк алып яшәү дөрес булыр:

*Җырлап торам, торган җирем тар булса да*
*Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да,*

— ди ул.

Шагыйребез Дәрдмәнд исә үз фикерен тагын да егәрлерәк, дәрманлырак итеп белдерә, мин мәкаләмне нәкъ менә аның сүзләре белән тәмамлыйм:

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше уз исемене инкяр итәрме.*
*Татарлыкта татар углы татармын,*
*Татар тугел дима — башың ватармын.*

# КОРЪӘННЕҢ УТЫЗЫНЧЫ ПАРӘСЕ

## «Фатиха» сүрәсе[1]
## Беренче сүрә, Мәккәдә иңгән җиде аять

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

الْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعٰلَمِينَ ۝ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۝
مٰلِكِ يَوْمِ الدِّينِ ۝ إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ ۝
اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ ۝ صِرَاطَ الَّذِينَ
أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ
وَلَا الضَّالِّينَ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).

Әлхәмдү лил-ләһи раббил-галәмин (2). Әр-рахмәнир-рахим (3). Мәлики йаумид-дин (4). Иййакә нәгъбүдү вә иййакә нәстәгыйн (5). Иһдинас-сыйраталь-мүстәкыйм (6). Сыйраталь-ләзинә әнгамтә галәйһим, гайрил-мәгъдуби галәйһим вә ләд-даллин (7).

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Һәрбер чын мактау — Аллаһы Тәгаләгә генә. Әмма Аллаһы Тәгаләдән башкаларга булган мактау — тыштан гына булган мактау. Ул — һәрбер бар булган нәрсәләрне — адәмнәрне, хайваннарны һәм үсемлекләрне тәрбия итүче, ике дөньяның да хужасы (2). Ул — изгелек һәм рәхмәт иясе булган кешегә изгелекле һәм мәрхәмәтле Зат (3). Ул — җәза (кыямәт) көненең хужасы (4). Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм эстибез (5). Син безне шундый адәмнәрнең тугры юлына күндерсәң иде (6). Син Үзең яхшылык һәм изгелек иткән адәмнәргә, пәйгамбәрләрнең күрсәткән юлына күндерсәң иде, ягъни яһүдләр кебек, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булган адәмнәр юлына күндермә! Һәм, тагын, азгын булмаган адәмнәрнең юлына күндер, ягъни христианнар кебек тугры юлдан азганнарның юлына күндермә (7)! Амин. Кабул кылсаң иде! Фатихадан соң «Амин» дию сөннәт, ягъни кирәк.

## «Нәбаэ» («Хәбәр») сүрәсе
## Җитмеш сигезенче сүрә, кырык аять

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

عَمَّ يَتَسَاءَلُونَ ۝ عَنِ النَّبَإِ الْعَظِيمِ ۝ الَّذِي هُمْ
فِيهِ مُخْتَلِفُونَ ۝ كَلَّا سَيَعْلَمُونَ ۝ ثُمَّ كَلَّا
سَيَعْلَمُونَ ۝ أَلَمْ نَجْعَلِ الْأَرْضَ مِهَادًا ۝ وَ

[1] «Фатиха» сүрәсе — ислам диненең нигезе булган өч олуг мәсьәләгә шарт. Берсе — Аллаһы Тәгалә бөтен галәмнең барлыкка китерүчесе һәм тәрбия итүчесе дип белү; икенчесе — кыямәт көненә һәм кыяматтә яхшылыкка — яхшылык, яманлыкка җәза булуына ышану; өченчесе — дөнья һәм ахирәттә сәгадәт иясе булу өчен һәм тугры юлны табу өчен Аллаһы Тәгаләгә ялваруның житәрлек булуы. Ислам диненең нигезе булган өч олуг мәсьәләнең кыскача бәяны — бу сүрәдән булганлыгы өчен бу сүрәне рәсүл әкрам, ягъни хөрмәтле пәйгамбәр «Өммел-Коръән» — «Коръән анасы» дип аталган. Бу сүрә Коръәннең башында булганы өчен «Фатихәтүл-китап» — «Коръән башы» дип аталган. Бу сүрә җиде аять булып, фарыз, ягъни үтәлергә тиеш намазда икешәр мәртәбә укылганлыгы өчен «сәбгыйлмәсани» — «икешәр укыла торган» дип аталган. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

الجبال أوتادا ۝ وخلقناكم أزواجا ۝ وجعلنا
نومكم سباتا ۝ وجعلنا الليل لباسا ۝ وجعلنا
النهار معاشا ۝ وبنينا فوقكم سبعا شدادا ۝
وجعلنا سراجا وهاجا ۝ وأنزلنا من المعصرات ماء
ثجاجا ۝ لنخرج به حبا ونباتا ۝ وجنات ألفافا ۝
إن يوم الفصل كان ميقاتا ۝ يوم ينفخ في الصور
فتأتون أفواجا ۝ وفتحت السماء فكانت أبوابا ۝ و
سيرت الجبال فكانت سرابا ۝ إن جهنم كانت
مرصادا ۝ للطاغين مآبا ۝ لابثين فيها أحقابا ۝
لا يذوقون فيها بردا ولا شرابا ۝ إلا حميما و
غساقا ۝ جزاء وفاقا ۝ إنهم كانوا لا يرجون
حسابا ۝ وكذبوا بآياتنا كذابا ۝ وكل شيء

أحصيناه كتابا ۝ فذوقوا فلن نزيدكم إلا
عذابا ۝ إن للمتقين مفازا ۝ حدائق
وأعنابا ۝ وكواعب أترابا ۝ وكأسا دهاقا ۝
لا يسمعون فيها لغوا ولا كذابا ۝ جزاء
من ربك عطاء حسابا ۝ رب السماوات
والأرض وما بينهما الرحمن لا يملكون
منه خطابا ۝ يوم يقوم الروح والملائكة
صفا لا يتكلمون إلا من أذن له الرحمن
وقال صوابا ۝ ذلك اليوم الحق فمن
شاء اتخذ إلى ربه مآبا ۝ إنا أنذرناكم
عذابا قريبا يوم ينظر المرء ما قدمت
يداه ويقول الكافر يا ليتني كنت ترابا ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

Гаммә йәтәсәәәлунә (2). Ганин-нәбәэил-газыйм (3). Әлләзи һум фиһи мухтәлифун (4). Кәллә сәйагъләмунә (5). Сүммә кәллә сәйагъләмунә (6). Ә ләм нәжгалил-арда миһадәв (7). Вәл-жибалә әутада (8). Вә халәкънакум әзважәв (9). Вә жәгалнә нәумәкум сүбатәв (10). Вә жәгалнәл-ләйлә либасәв (11). Вә жәгалнән-нәһара мәгаша (12). Вә бәнәйна фәукакум сәбган шидадәв (13). Вә жәгалнә сиражав-вәһһажа (14). Вә әнзәлнә минәл-мүгъсыйрати мәән сәжжажәл (15). Линухрижә биһи хаббәв-вә нәбатәв (16). Вә жәннәтин алфафа (17). Иннә йаумәл-фасли кәнә микатәй (18). Йаумә йүнфәху фис-сури фә-тәәтүнә әфважәв (19). Вә фүтихәтис-сәмаәү фә-кәнәт әбвабәв (20). Вә сүй иратил-жибалү фә-кәнәт сәраба (21). Иннә жәһәннәмә кәнәт мирсадәл 22). Лит-тагыйнә мәабаль (23). Ләбисинә фиһа әхкабаль (24). Лә йәзукунә фиһа бәрдәв-вә лә шәрабән (25). Иллә хамимәв вә гассакан (26). Жәзаәәв-вифакан (27). Иннәһум кәну лә йәржунә хисабәв (28). Вә кәззәбу би-айатина киззаба (29). Вә күллә шәйэин әхъсайнаһи китаба (30). Фә-зуку фә-лән нәзидәкум иллә газаба (31). Иннә лил-мүттәкыйнә мәфазән (32). Хадаэикә вә әгънабәв (33). Вә кәвагыйбә әтрабәв (34). Вә кәсән дихака (35). Лә йәсмәгунә фиһа лагъвәв-вә лә киззабар (36). Жәзаәәммир-раббикә гатаәән хисабар (37). Раббиссәмәвати вәл-арди вә мә бәйнәһүмар-рахмәни лә йәмликунә минһү хитабә (38). Йаумә йәкумур-руху вәл-мәләәикәтү саффәл-лә йәтәкәлләмунә ил-лә мән әзинә ләһур-рахмәну вә кәлә сауаба (39). Заликәл-йаумул-хакк, фә-мән шаәәт-тәхәзә илә раббиһи маба (40). Иннә әнзәрнакум газабән карибәй, йаумә йанзурулмәрьэу мә каддәмәт йәдаһү вә йәкулул-кәфиру йаләйтәни күнтү тураба (40).

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Мәккә кяферләре бер-берсеннән ни нәрсә хакында сорашалар? Алар үз араларында мөэмин-мөселманнар белән каршылыкта булган олуг хәбәр турында сорашалар (ягъни Коръәндә бәян ителгән үлекләрнең терелеп кабердән кубарылуы һәм кыямәт хәленнән сорашалар). Эш кяферләр әйткәнчә түгел, үлекләрнең терелеп кабердән кубарылуы булачак. Киләчәктә алар моның хаклыгын белерләр. Үлекләрнең терелеп кабердән кубарылуыннан соң газап булмавы да кяферләрчә түгел, ул кяферләр киләчәктә бу хакта да белерләр (2, 3, 4, 5)[1].

[1] Тулы һәм төгәл бер мәгънәне белдерү максатыннан Ш. Хәмиди кайбер урыннарда берничә аятьне бергә бирел аңлата — тәфсир ясый. Җая эчендәге саннарны әнә шул аятьләр саны дип аңларга кирәк. (Ә. Х.)

Уйлагыз, бәндәләрем! Минем үлгәннән соң сезне тергезеп җыярга ничек көчем житмәсен? Җирне йөрү өчен тигез һәм тору өчен бишек кебек уңайлы, җирдәге тауларны кадак кебек беркетүче кылмадыкмы? Һәм дә сезне җефет-җефет, ягъни парлы-парлы итеп яратмадыкмы? Сезнең йокыгызны рәхәтлек кылмадыкмы? Кичне кием кебек сезне яшерүче, көндезне көн үткәрер өчен кәсеп итәргә уңайлы кылмадыкмы? Әлбәттә, болардан һәрберсен дә сезгә файдалы итеп ясаган Зат — Минме?! (6, 7, 8, 9, 10, 11). Без сезнең өстегездә каты булган җиде Күкне төздек, һәм дә янып тора торган чыраг, ягъни Кояш ясадык. Һәм дә су белән тулган болытлардан агучы суны индердек. Бу суны индерүебез орлыкларны һәм дә үләннәрне, шулай ук берсе-берсенә әүмәләшкән агачлы бакчаларны үстерү өчендер. Бу ясаган нәрсәләребез барысы да сезнең файдагызга (12, 13, 14, 15, 16). Дөреслектә, һәртөрле халык арасында аеру хөкеме йөртелә торган кыямәт көне, дөньяның бетү вакыты булды. Ул кыямәт көнендә сур, ягъни быргы өрелер дә, сез барыгыз да груһ-груһ, ягъни төркем-төркем булып махшәр мәйданына килерсез. Күк ачылып ишек-ишек булыр, таулар һавада йөртелер, таралу һәм тетелүләреннән рәшә кебек булып әверелерләр (17, 18, 19, 20). Дөреслектә, азгыннар өчен тора торган урын булган җәһәннәм кяферләр өчен баглану урыны булды. Ул кяферләр анда чиксез еллар торырлар. Ул җәһәннәм әһле җәһәннәмдә йокыны да, тәмле эчемлекне дә татымаслар. Мәгәр эчемлектән эссе су һәм дә сары сулар гына татырлар. Кяферләрне болай җәза кылу — аларның дөньяда кылган гамәлләренә муафыйк җәзадыр, чөнки ул кяферләр ахирәт хисабыннан курыкмас булдылар һәм дә безнең аятьләребезне ялганга чыгардылар, шул эшләре бәрабәренә җәза бирелер. Без һәр нәрсәне ләүхыль-мәхфуздә, ягъни язмыш тактасында беркеттек. Ягъни аларның дөньяда кылган бозыклыкларын фәрештәләрдән яздырган идек. Кәгазьләрне газап тоткан вакытта Аллаһы Тәгалә тарафыннан әйтелер: «Инде сез татыгыз тиешле җәзагызны, без сезгә газаптан башка нәрсәне арттырмабыз. Ягъни сезгә газап өстенә газап булыр (21, 22, 23, 24, 25, 26, 27, 28, 29, 30). Инде ахирәт йортында җәннәт әһелләре өчен рәхәт урыны бар, җимешле агач бакчалары, йөземнәре бар. Яшьтәш булган кызлар бар. Савыты тулып житкән эчемлекләр бар. Ул җәннәттә буш һәм ялган сүзләр ишетмәсләр, бәлки һәрбер сүзләре хозур һәм кешенең күңелен ача торган булыр. Җәннәт әһелләренә мондый рәхәтләр жир, күк, һәм дә боларның арасында булган нәрсәләрнең Раббесе булган Раббеңнең гамәлләргә тәмам муафыйк булган җәза һәм мәрхәмәт өчендер. Ул Раббең сиңа мәрхәмәт ияседер. Хәзрәти Җәбраил һәм дә башка фәрештәләр саф-саф торган көндә халыкның куркуларыннан Аллаһы Тәгалә белән сөйләшергә, тартышырга көчләре булмас һәм сөйли алмаслар. Бары Аллаһы Тәгалә рөхсәт биргән кешеләре бәгъзе кешеләргә шәфагать иткәндә сөйләшә алырлар. Рух-җаннарга тапшырылган фәрештәләр кыяфәтендәдер (31, 32, 33, 34, 35, 36, 37, 38). Бу бәян ителгән кыямәт көне бер дә шиксез булачак көндер. Инде берәү бу көндә газапта булмауны теләсә, ул кеше Раббесе тарафына кайту ягын тотсын, ягъни иман китерсен, Аллаһыга гыйбадәттә булсын! Әй, Мәккә кяферләре! Без сезне якын булган ахирәт газабы белән куркытып хаклыкка өндәдек. Ул газап шул көндә булыр, ул көндә кеше үзенең дөньяда кылган нәрсәсен күрер. Һәм дә кяфер булган ир әйтер: «Их, әгәр дөньяга килмәгән булсам иде яки үлгәннән соң кубарылмаган булсам иде!» — дияр (39, 40).

## «Ән-Назигат» («Җан суыручы фәрештәләр») сүрәсе
## Җитмеш тугызынчы сүрә, кырык алты аять

بسم الله الرحمن الرحيم
والنزعت غرقا ۝ والنشطت نشطا ۝ والسبحت
سبحا ۝ فالسبقت سبقا ۝ فالمدبرت امرا ۝
يوم ترجف الراجفة ۝ تتبعها الرادفة ۝ قلوب
يومئذ واجفة ۝ ابصرها خشعة ۝ يقولون
ءانا لمردودون في الحافرة ۝ ءاذا كنا عظما
نخرة ۝ قالوا تلك اذا كرة خاسرة ۝ فانما
هي زجرة وحدة ۝ فاذا هم بالساهرة ۝ هل

اتىك حديث موسى ۝ اذ نادىه ربه بالواد
المقدس طوى ۝ اذهب الى فرعون انه
طغى ۝ فقل هل لك الى ان تزكى ۝ واهديك الى
ربك فتخشى ۝ فارىه الاية الكبرى ۝ فكذب
وعصى ۝ ثم ادبر يسعى ۝ فحشر فنادى ۝ فقال
انا ربكم الاعلى ۝ فاخذه الله نكال الاخرة والاولى ۝
ان في ذلك لعبرة لمن يخشى ۝ ءانتم اشد خلقا
ام السماء بنىها ۝ رفع سمكها فسوىها ۝ واغطش

ليلها وأخرج ضحاها ۝ والأرض بعد ذلك دحاها ۝
أخرج منها ماءها ومرعاها ۝ والجبال أرساها ۝
متاعا لكم ولأنعامكم ۝ فإذا جاءت الطامة الكبرى
يوم يتذكر الإنسان ما سعى ۝ وبرزت الجحيم
لمن يرى ۝ فأما من طغى ۝ وآثر الحياة الدنيا ۝
فإن الجحيم هي المأوى ۝ وأما من خاف مقام

ربه ونهى النفس عن الهوى ۝ فإن الجنة هي
المأوى ۝ يسألونك عن الساعة أيان مرساها ۝
فيم أنت من ذكراها ۝ إلى ربك منتهاها ۝ إنما
أنت منذر من يخشاها ۝ كأنهم يوم يرونها
لم يلبثوا إلا عشية أو ضحاها ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

Вән-назигати гаркав (2). Вән-нашитати нәштав (3). Вәс-сабихати сүбхан (4). Фәс-сабикати сәбкан (5). Фәл-мүдәббирати әмра (6). Йаумә тәрҗүфүр-раҗифәтү (7). Тәтбәгуһар-радифәһ (8). Кулүбүй-йаумәэизив важифәтүн (9). Әбсаруһа хашига (10). Йакулунә ә иннә лә-мәрдудунә фил-хафираһ (11). Ә иза күннә гыйзамән-нахираһ (12). Калү тилкә изан кәррәтүн хасираһ (13). Фә-иннәмә һийә зәҗрәтүв вахидәтүн (14). Фә-иза һүм бис-саһира (15). Һәл этакә хадису Муса (16). Из нәдәһү раббүһү бил-вадил-мукаддәси тува (17). Изһәб илә Фиргаунә иннәһү тага (18). Фәкуль һәл-ләкә илә ән-тәзәккә (19). Вә әһдийәкә илә раббикә фә-тахъша (20). Фә-әраһүл-айәтәл-күбра (21). Фә-кәззәбә вә гаса (22). Сүммә әдбәра йәсга (23). Фәхәшәра фә-нада (24). Фә-калә әна раббүкүмүл-әгълә (25). Фә-әхазәһүл-лаһү нәкәнәл-ахирати вәл-улә (26). Иннә фи заликә лә-гыйбратәл-ли-мәй-йахъша (27). Ә әнтүм әшәддү халкан әмиссәмаэү бәнаһа (28). Рафәгә сәмкәһа фә-сәвваһа (29). Вә әгъташа ләйләһа вә әхъраҗә духаһа (30). Вәл-арда бәгъдә заликә дәхаһа (31). Әхъраҗә минһа маәһа вә мәргаһа (32). Вәл-җибалә әрсаһа (33). Мәтагал-ләкүм вә ли-ән-гамикүм (34). Фә-иза җаәәтит-таммәтүл-күбра (35). Йаумә йәтәзәккәрүл-инсанү мә сәга (36). Вә бүррризәтил-җәхыймү ли-мәй-йәра (37). Фә-әммә мән тага (38). Вә әсәрәл-хайатәд-дуньйа (39). Фә-иннәл-җәхыймә һийәл-мәва (40). Вә әммә мән хафә мәкамә раббиһи вә нәһән-нәфсә ганил-һәва (41). Фә-иннәл-җәннәтә һийәл-мәва (42). Йәсьәәлүнәкә ганис-сагати әййанә мүрсаһа (43). Фимә әнтә мин зикраһа (44). Илә раббикә мүнтәһаһа (45). Иннәмә әнтә мүнзиру мәй-йахшаһа (46). Кә-әннәһүм йаумә йәраунәһа ләм йәлбәсу иллә гашиййәтән әү духаһа (47).

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кяферләрнең җаннарын каты суыру белән суыручы фәрештәләр белән ант итәмен, һәм дә мөэмин-мөселманнарның җаннарын шатлыклы сорау белән сораучы фәрештәләр белән ант итәмен, мөэминнәрнең җаннарын ашыгып, алдан җәннәткә илтүче фәрештәләр белән ант итәмен, һәм дә дөнья эшләрен башкаручы фәрештәләр белән ант итәмен, һәм дә Күктән Аллаһының әмерен иңдерүче фәрештәләр белән ант итәмен. Әй, Мәккә кяферләре! Үлгәннән соң бер дә шиксез кубарылачаксыз. Ул көннең башы булган әүвәлге сур, ягъни быргы вакытында селкенми торган нәрсәләр — һәрберсе дә селкенер һәм тетрәр, әүвәлге сурга икенче сур иярер. Әүвәлге сур вакытында таулар һәм җир тетрәр (2, 3, 4, 5, 6, 7). Ул көндә күңелләр куркуларыннан тетрәрләр. Күзләре куркудан хурлыкта булырлар. Шул курку хәлләрендә әйтерләр: «Кайчан эче куышланган сөяк булып үлгәнлегебездән соң тагын да әүвәлге кебек тереклеккә кайтарылган булырбызмы?» — дип, ягъни кубарылуга ышанмаган кешеләр шулай әйтерләр. Һәм әйтерләр: «әгәр дә бу икенче мәртәбә, үлгәннән соң терелү дөрес булса, без хәсрәттә булачакбыз», — дип. Кяферләр үлгәннән соң кубарылуны ерак күрсәләр дә, ул кубару Аллаһы Тәгалә өчен җиңелдер. Яңадан тергезүне теләп, икенче сурны, ягъни быргыны өрдерсәң, үлеп черегән сөякләр һәрберсе дә бик тизлектә яңадан Җир йөзендә булырлар (8, 9, 10, 11, 12, 13, 14). Әй, Мөхәммәд! Сиңа Мусаның сүзе килде, Мусаның «Туй» дигән чокырда Раббесе — Аллаһы белән сөйләшүе сиңа бәян ителәдер. Мусага Раббесе әндәште: «Әй, Муса! Фиргавен янына бар. Ул Фиргавен юлдан язды. Син аңа әйт: «Әй, Фиргавен! Сиңа мәҗүсилектән пакьләнергә ярамасмы? Һәм мин сине Раббең тарафына күндерәмен. Раббеңнән куркып, Аңа иман китерерсең!» — дип. Шул вакытта Муса Фиргавенгә олуг булган могҗиза күрсәтте. Шулай да Фиргавен Мусаны ялганга чыгарды, һәм дә аңа карышты. Шуннан соң Фиргавен Мусаның (Аңа Аллаһының сәламе булсын!) сүзен тыңлаудан баш тартты. Шуннан соң ук үзенең кавемен җыйды да әндәште: «Мин сезнең олуг булган Раббегезмен!» — дип. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә ул Фиргавенне дөньяда суга батыру газабы белән, ахирәттә ут газабы белән тотты. Инде Фиргавенне болай кылуда Аллаһыдан курыккан кешеләр өчен олуг гыйбрәт бардыр (15, 16, 17, 18, 19, 20, 21, 22, 23, 24, 25, 26). Әй, бәндәләр! Сезне ярату авырракмы, әллә Күкне ярату авырракмы? Әлбәттә, сезгә

караганда Күкне барлыкка китерү авыррак. Шул Раббегез Күкне тезде: Күкнең түбәсен тигез итеп күтәрде, һәм дә ул Күкнең кичен караңгы кылды. Кояш чыгарып, көндезен якты кылды. Күктән соң Жирне жәйде һәм ул Жирдә шулай ук хайваннар утлый торган болыннарны чыгарды һәм дә тауларны үстерде. Жир өстенә калкытты. Аллаһы Тәгаләнең Жирдә су һәм төрле үләннәр, жимешләр булдыруы сезгә һәм дә хайваннарыгызга файдалану өчендер (27, 28, 29, 30, 31, 32, 33). Адәм үзенең дөньяда кылган эшләрен искә төшерә торган олуг куркынычлы көн килсә, жәһәннәм тәмугысы караган кешегә ачык ителсә, инде бер кеше азгынлыкта булса, дөнья тереклеген ахирәттән артык күрсә, бу көндә ул кешегә жәһәннәм тәмугысы — урын булыр (34, 35, 36, 37, 38, 39). Инде бераү Раббесенең урыныннан курыкса, үзен бозыклыктан тыйса, бу кешегә жәннәт—тора торган урын булыр. Әй, Мөхәммәд! Синнән Кыямәт вакыты кайчан икәнен сорарлар, әмма Кыямәт вакытын бәян итү синең эшең түгел, бәлки аның вакытын белү Раббең каршындадыр. Әмма син Кыямәттән курыккан кешеләрне куркытучы гынасың. Ул кяферләр Кыямәт көнен күргәндә дөньяда көннең әүвәлге, яки соңгы өлешен генә күреп торган кебек булып калырлар (40, 41, 42, 43, 44, 45, 46).

## «Габәсә» («Чыраен сытты») сүрәсе
## Сиксәненче сүрә, кырык ике аять

بسم الله الرحمن الرحيم
عبس وتولى ۝ ان جاءه الاعمى ۝ وما يدريك
لعله يزكى ۝ او يذكر فتنفعه الذكرى ۝ اما من
استغنى ۝ فانت له تصدى ۝ وما عليك الا يزكى ۝
واما من جاءك يسعى ۝ وهو يخشى ۝ فانت
عنه تلهى ۝ كلا انها تذكرة ۝ فمن شاء ذكره ۝
في صحف مكرمة ۝ مرفوعة مطهرة ۝ بايدي
سفرة ۝ كرام بررة ۝ قتل الانسان ما اكفره ۝
من اي شيء خلقه ۝ من نطفة خلقه فقدره ۝
ثم السبيل يسره ۝ ثم اماته فاقبره ۝ ثم اذا شاء
انشره ۝ كلا لما يقض ما امره ۝ فلينظر الانسان
الى طعامه ۝ انا صببنا الماء صبا ۝ ثم شققنا
الارض شقا ۝ فانبتنا فيها حبا ۝ وعنبا وقضبا ۝
وزيتونا ونخلا ۝ وحدائق غلبا ۝ وفاكهة وابا ۝
متاعا لكم ولانعامكم ۝ فاذا جاءت الصاخة ۝
يوم يفر المرء من اخيه ۝ وامه وابيه ۝ و
صاحبته وبنيه ۝ لكل امرئ منهم يومئذ شان
يغنيه ۝ وجوه يومئذ مسفرة ۝ ضاحكة
مستبشرة ۝ ووجوه يومئذ عليها غبرة ۝ ترهقها
قترة ۝ اولئك هم الكفرة الفجرة ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).
Габәсә вә тәвәллә (2).Ән жаәәһүл-әгъмә (3). Вә мә йүдрикә лә-галләһү йәззәккә (4). Әү йәзәккәру фә-тәнфәгаһүз-зикрә (5). Әммә мәнис-тәгънә (6). Фә-әнтә ләһү тәсаддә (7). Вә мә галәйкә әллә йәззәккә (8). Вә әммә мән жаәәкә йәсгә (9). Вә һүвә йәхъшә (10). Фә-әнтә ганһү тәләһһә (11). Кәл-лә иннәһа тәзкиратүн (12). Фә-мән шаәә зәкәраһ (13). Фи сухуфим мүкәррамәтим (14). Мәрфугатим-мутаһһарәтин (15). Би-әйди сәфәрәтин (16). Кирамим-бәрараһ (17). Кутилә-л-инсанү мә әкфәраһ (18). Мин әййи шәйэин халәкаһү (19). Мин нутфәтин, халәкаһү фә-каддәраһү (20). Сүммәс-Сәбилә йәссәраһү (21). Сүммә әмәтәһү фә-әкъбараһү (22). Сүммә иза шаәә әншәраһ (23). Кәл-лә ләммә йакъди мә әмәраһ (24). Фәл-йәнзурил-инсанү илә тагамиһи (25). Әннә сабәбнәл-маәә саббән (26). Сүммә шәкакнәл арда шаккан (27). Фә-әмбәтна фиһа хаббәв (28). Вә гыйнабан вә кадбән (29). Вә зәйтүнән-вә нәслән (30). Вә хадәәика гулбән (31). Вә фәкиһәтан вә әббәм (32). Мәтагал-ләкүм вә ли-әнгамикүм (33). Фә-иза жаәәтис-саххатү (34). Йаумә йәфиррул-мәрьәү мин ахыйһи (35). Вә үммиһи вә әбиһи (36). Вә сахибәтиһи вә бәниһи (37). Ли-күллим-риэим-минһүм йаумәизин шәэнүй-йугънииһ (38). Вүжүһүй-йаумәизим-мүсфиратүн (39). Дахикәтүм-мүстәбширәһ (40). Вә вүжүһүй йаумәизин галәйһа габәратүн (41). Тәрһәкуһа катәраһ (42). Үләәикә һүмүл-кәфәратүл-фәжәрә (43).

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Бу сүрәнең иңүенә сәбәп — ошбу кыйссадыр: бер вакытта рәсүлебез курәйш олугларына дин өйрәтеп, аларны дингә өндәп торадыр иде. Шул вакытта Ибне Өмме Мәктүм, сукыр бер кеше булганлыгыннан, рәсүлулла янына килеп, рәсүлулланың сүз белән мәшгульлеген белмичә: «Әй, Аллаһының рәсүле, миңа дин өйрәт, Аллаһы Тәгалә бәян иткән хөкемнәрдән беразын өйрәт!» — диде. Аятьнең мәгънәсе: сукыр ир килгәне өчен, рәсүл йөз чытыкландырып, йөзен дүндерде. «Әй, Мөхәммәд! Сиңа ни нәрсә белдерде?» Өметтер ки: ул сукыр-мәҗүсилегеннән пакьләнер, яисә синнән ишеткән вәгазь аңа файда бирер» (2, 3, 4). Инде бер мәҗүси бай булып килсә, син аңа каршы булырсың, ягъни байларга мөрәҗәгать итешерсең, инде сукыр ир Аллаһыдан куркып, синең яныңа килсә, син аның белән сөйләшмисең. Инде сиңа ни булды? Курәйш олуглары исламга килмәгәнгә аларга кат-кат өндәү ясарга? Синең эшең исламны бәян кылу гына, башка түгел (5, 6, 7, 8, 9, 10). Әй, Мөхәммәд! Болай кылма, бу эш ярамый. Дәрәҗәле булган Коръән Шәриф хөрмәтле кәгазьләрдә пакь вә олуг хөрмәтле һәм дә гөнаһсыз булган хезмәтче фәрештәләрнең куллары белән язылды. Ул Коръән — теләгән кешеләргә вәгазьләнү өчен иңдерелде. Инде, син, әй, Мөхәммәд! Кемдер Коръән белән вәгазьләнүне теләсә аңа Коръәннән вәгазьләр кыл! Коръәнгә ышанмаган адәм ләгънәт кылынды, ягъни адәмнәрдән күбесе Аллаһы Тәгаләгә ышанмаганлыкларыннан көферләре сәбәпле мәлгунь ителәләр. Гаҗәп бу адәмнәрнең хәле. Ни гаҗәп эштер? Ник уйланмыйлар? Аларны Раббеләре булган Аллаһы Тәгалә ни нәрсәдән яратты? Әлбәттә, мәни суыннан яратып, аларны адәм итте. Шулай булып та, Раббеләренең сүзләренә һәм дә рәсүлләренә ышанмаулары бигрәк гаҗәп бер эш (11, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 18, 19). Адәмне барлыкка китергәндә, Аллаһы Тәгалә, бала булып туу өчен булган юлын җиңел кылды. Моннан соң аны үтерде һәм җиргә күмдерде. Шуннан соң кайчан теләсә, әлбәттә, шунда кубадыр. Адәмнең бу рәвештә яратылып та Раббесенә иман китермәве — яман эштер! Ул, адәм өстенә үтәлүе мәҗбүри булган эшне, ягъни Раббесенең фәрманын тәмам үтәмәде, Адәм затыннан (Аңа Аллаһының сәламе булсын!) бу көнгәчә һичберсе Аллаһының фәрманын бер дә кимчелексез итеп үти алмады. (20, 21, 22, 23). Инде адәм гыйбрәт күзе белән карасын! Үзенең ашый торган ашларыннан гыйбрәт алсын! Без аның ашый торган нигъмәтләренә (үсемлекләргә) Күктән су койдык. Соңрак Җирне ярып ул үсемлекләрдә орлык һәм йөзем, хөрмә чыгардык. Шулай ук зәйтүн агачы, хөрмә агачы еш булган бакчалар, төрле җимеш, һәм дә үләннәр үстердек. Боларны ашап, адәмнәр һәм дә хайваннар файдалансыннар өчен яраттык. Адәмгә гыйбрәтләнергә бик ерак барасы юк, бәлки үзенең ашамлыгы аның өчен бик олуг гыйбрәттер. Мәсәлән, ашар өчен бер кабасы икмәкне кулга тоткач, уйланып, шул кабымнан Аллаһы Тәгаләне танырга мөмкин, чөнки ул икмәк бер кечкенә орлыктан булган, ул орлыкны яратучы да Аллаһы Тәгалә Үзе. Шул орлык җир астына күмеләдер. Аллаһы Тәгалә вакытында яңгыр бирсә, ул орлык җирне тишеп чыга да үлән булып үсә. Үсә торгач башаклана, һәрбер башакта хәтта йөзгә кадәр орлык була. Инде бер кечкенә орлыктан йөз данә үзе кебек орлык, аның өстенә башак һәм салам булдыру кемнең кулыннан килер? (24, 25, 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32). Әгәр икенче сур, ягъни быргы өрелсә, ул көндә кеше үзенең кардәшеннән, һәм дә анасыннан, атасыннан, шулай ук хатыныннан һәм дә балаларыннан качар. Ул көндә һәммә кешенең кайгысы үзендә генә булыр. Бер дә кеше кайгысы уйланмас (33, 34, 35, 36, 37). Ул көндә мөэмин-мөселман булганнарның йөзләре якты һәм шатлыктан көлүче булыр. Дәхи дә ул көндә бәгъзе йөзләрнең өсләрендә караңгылык белән капланган каралык булыр. Бу йөзләр — көферләре өстенә бозыклыклар кылган кяферләрдер (38, 39, 40, 41, 42).

## «Тәквир» («Төрелү», «җыелу») сүрәсе. Сиксән беренче сүрә, егерме тугыз аять

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ ۝
إِذَا الشَّمْسُ كُوِّرَتْ ۝ وَإِذَا النُّجُومُ انكَدَرَتْ ۝ وَ
إِذَا الْجِبَالُ سُيِّرَتْ ۝ وَإِذَا الْعِشَارُ عُطِّلَتْ ۝ وَإِذَا
الْوُحُوشُ حُشِرَتْ ۝ وَإِذَا الْبِحَارُ سُجِّرَتْ ۝ وَإِذَا
النُّفُوسُ زُوِّجَتْ ۝ وَإِذَا الْمَوْءُودَةُ سُئِلَتْ ۝ بِأَيِّ
ذَنبٍ قُتِلَتْ ۝ وَإِذَا الصُّحُفُ نُشِرَتْ ۝ وَإِذَا السَّمَاءُ
كُشِطَتْ ۝ وَإِذَا الْجَحِيمُ سُعِّرَتْ ۝ وَإِذَا الْجَنَّةُ
أُزْلِفَتْ ۝ عَلِمَتْ نَفْسٌ مَّا أَحْضَرَتْ ۝ فَلَا أُقْسِمُ
بِالْخُنَّسِ الْجَوَارِ الْكُنَّسِ ۝ وَاللَّيْلِ إِذَا عَسْعَسَ ۝
وَالصُّبْحِ إِذَا تَنَفَّسَ ۝ إِنَّهُ لَقَوْلُ رَسُولٍ كَرِيمٍ ۝

ذِي قُوَّةٍ عِندَ ذِي الْعَرْشِ مَكِينٍ ۝ مُّطَاعٍ ثَمَّ أَمِينٍ ۝ وَمَا صَاحِبُكُم بِمَجْنُونٍ ۝ وَلَقَدْ رَآهُ بِالْأُفُقِ الْمُبِينِ ۝ وَمَا هُوَ عَلَى الْغَيْبِ بِضَنِينٍ ۝ وَمَا هُوَ بِقَوْلِ شَيْطَانٍ رَّجِيمٍ ۝ فَأَيْنَ تَذْهَبُونَ ۝ إِنْ هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ لِّلْعَالَمِينَ ۝ لِمَن شَاءَ مِنكُمْ أَن يَسْتَقِيمَ ۝ وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَن يَشَاءَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Изаш-шәмсү күввират (2). Вә изан-нүҗүмүн-кәдәрат (3). Вә изал-җибәлү суййират (4). Вә изал-гыйшару гуттыйләт (5). Вә изал-вухушу хушират (6). Вә изал-бихару сүҗҗират (7). Вә изан-нүфүс зүввиҗәт (8). Вә изал-мәуэүдәтү сүэиләт (9). Биәййи зәмбин кутиләт (10). Вә изас-сухуфу нүшират (11). Вә изас-сәмәэү күшитат (12). Вә изал-җәхыймү суггыйрат (13). Вә изал-җәннәтү үзлифәт (14). Галимәт нәфсүм-мә ахдарат (15). Фә-лә укъсимү бил-хуннәси (16). Әл-җәварил-күннәси (17). Вәлләйли иза гасгасә (18). Вәс-субхи иза тәнәффәс (19). Иннәһү лә-каулү расүлин кәримин (20). Зи куввәтин гыйндә зил-гарши мәкиним (21). Мутагыйн сәммә әмин (22). Вә мә сахибүкүм би-мәҗнүн (23). Вә ләкад рааһү бил-уфукыйль-мүбин (24). Вә мә һүвә галәл-гайби би-данин (25). Вә мә һүвә би-каули шәйтанир-раҗимин (26). Фә-әйнә тәзһәбун (27). Ин һүвә иллә зикрул-лил-галәминә (28). Ли-мән шаәә минкүм әй-йәстәкыйм (29). Вә мә тәшаәүнә иллә әй-йәшаәәл-лаһү раббүл-галәмин (30).

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кояшның яктылыгы бетерелсә, йолдызларның очкыннары таралса, таулар урыннарыннан кузгатылса, тәвәләр саклаучылардан башка җибәрелсә, вәхши хайваннар Җир йөзендә бер дә зарарсыз халык арасында йөри башласа, дәрья сулары тулып агызылса, һәрбер җан кушылса (2, 3, 4, 5, 6, 7), тере хәлендә күмелгән кыз балалар «ни гөнаһлары булды, ни сәбәптән үтерелделәр?» — дип соралса, һәм дә гамәл дәфтәрләре таратылса, һәм дә Күк ярылса, һәм дә җәһәннәм тәмугы кыздырылса, Җәннәт хәзерләнеп куелса (8, 9, 10, 11, 12, 13), шул эшләр барлыкка чыккан заманда һәрбер җан үзенең ни нәрсә хәзерләгәнен белер. Үзе нинди гамәл белән ихлас булачагын сизәдер. Эш кяферләр уйлаганча түгел, кыямәт булачак, бәян ителгән вакыйгалар — һәрберсе дә булачак. Кичегеп туып, кояш яктысында күренми торган (Зөхәл — Сатурн, Мөштәри — Юпитер, Мәрих — Марс, Зөһрә — Венера, Гутарид — Меркурий) йолдызлар белән ант итәмен, һәм дә кич белән ант итәмен, әгәр караңгыланса, һәм дә таң белән ант итәмен, әгәр яктырса; ошбу нәрсәләр белән ант итәмен (14, 15, 16, 17, 18). Дөреслектә, ул Коръән, Күкнең иң югары ноктасының хуҗасы булган Аллаһы Тәгалә каршындагы куәт иясе шул урында фәрештәләр арасында буйсынылган хөрмәтле илченең, ягъни Җәбраилнең (Аңа Аллаһының рәхмәте булсын!) Аллаһы Тәгалә тарафыннан китерелгән сүзедер. Инде сезнең вәхи иясе булган рәсүлегез Мөхәммәд гакылсыз кеше түгелдер. Бәлки Аллаһы Тәгалә тарафыннан әманәт иясе — илче китергән Аллаһының сүзләре белән вәхи таратучы кешедер. Чыннан да, ул Мөхәммәд Җәбраилне Кояш чыгышы тарафында күрде. (Ягъни, фәрештә вәхи китергәненә ышанмаган кяферләргә Аллаһы тәгалә рәсүлебезнең хәзрәти Җәбраилне күргән бәян итәдер (19, 20, 21, 22, 23). Ул, Мөхәммәд, үзенә Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңгән вәхине башкаларга ирештерүгә саранлык кылучы түгелдер, ягъни Аллаһы Тәгаләдән иңгән вәкилләрне һәрберсен дә халкына ирештерәдер. Гәрчә ул вәхидә үзенә шелтә булса да, яшереп калмыйдыр. Ул, Коръән, Аллаһы Тәгалә тарафыннан сөрелгән шайтан сүзе түгелдер, ягъни вәхи белән иңгән аятьләр Җәбраил фәрештә аркылы Аллаһы Тәгаләдән иңдерелгән сүздер. Шайтан алдавы түгелдер. Инде, Коръән Аллаһы Тәгаләнең сүзе булса, Аңа карышкан кешеләр кая барырсыз сез? Коръәннән башка тагын нинди юл белән йөрерсез? (24, 25, 26)? Ул, Коръән, сездән тугры юлда булуны теләгән адәм һәм җеннәр өчен вәгазьдер. Әй сез, мөэминнәр! Тугры юлда булуны теләмәссез сез. Мәгәр бөтен галәмне тәрбия итүче Аллаһы Тәгаләнең теләве белән генә теләрсез! Ягъни тугры юлда булуны теләсәгез дә, Аллаһы Тәгаләнең теләген юлы белән йөрми торып, тугры юлда була алмассыз (27, 28, 29).

## «Инфитар» («Ярылу») сүрәсе. Сиксән икенче сүрә, унтугыз аять

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ ۝ إِذَا السَّمَاءُ انفَطَرَتْ ۝ وَإِذَا الْكَوَاكِبُ انتَثَرَتْ ۝ وَإِذَا الْبِحَارُ فُجِّرَتْ ۝ وَإِذَا الْقُبُورُ بُعْثِرَتْ ۝ عَلِمَتْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ وَأَخَّرَتْ ۝ يَا أَيُّهَا الْإِنسَانُ

مَا غَرَّكَ بِرَبِّكَ الْكَرِيمِ ۝ الَّذِي خَلَقَكَ فَسَوَّىٰكَ
فَعَدَلَكَ ۝ فِي أَيِّ صُورَةٍ مَّا شَاءَ رَكَّبَكَ ۝ كَلَّا
بَلْ تُكَذِّبُونَ بِالدِّينِ ۝ وَإِنَّ عَلَيْكُمْ لَحَافِظِينَ ۝
كِرَامًا كَاتِبِينَ ۝ يَعْلَمُونَ مَا تَفْعَلُونَ ۝ إِنَّ الْأَبْرَارَ

لَفِي نَعِيمٍ ۝ وَإِنَّ الْفُجَّارَ لَفِي جَحِيمٍ ۝ يَصْلَوْنَهَا يَوْمَ
الدِّينِ ۝ وَمَا هُمْ عَنْهَا بِغَائِبِينَ ۝ وَمَا أَدْرَاكَ مَا يَوْمُ
الدِّينِ ۝ ثُمَّ مَا أَدْرَاكَ مَا يَوْمُ الدِّينِ ۝ يَوْمَ لَا
تَمْلِكُ نَفْسٌ لِّنَفْسٍ شَيْئًا ۖ وَالْأَمْرُ يَوْمَئِذٍ لِّلَّهِ ۝

#### ТРАНСКРИПЦИЯ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Изас-сәмәэүн-фәтарат (2). Вә изал-кәвакибүн-тәсәрат (3). Вә изал-бихару фәҗҗират (4). Вә изал-кубуру бугъсират (5). Галимәт нәфсүм-мә каддәмәт вә әххарат (6). Йа әййүһәл-инсану мә гарракә би-раббикәл-кәрим (7). Әлләзи халәкакә фә-сәүүәкә фә-гадәләкә (8). Фи әййи суратим-мә шаәә раккабәк (9). Кәллә бәл түкәззибунә бид-дини (10). Вә иннә галәйкүм лә-хафизыйн (11). Кирамән кәтибинә (12). Йагъләмүнә мә тәфгалүн (13). Иннәл-әбрарә лә-фи нәгыймин (14). Вә иннәл-фуҗҗарә лә-фи җәхыймий (15). Йасләүнәһа йаумәд-дин (16). Вә мә һүм ганьһа бигаэибин (17). Вә мә әдракә мә йаумүд-дин (18). Сүммә мә әдракә мә йәүмүд-дин (19). Йаумә лә тәмликү нәфсүл-линәфсин шәйәән, вәл-әмру йаумәэизин лил-ләһ (20).

#### СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әгәр күк ярылса, йолдызлар чәчелсә, дәрьялар тулып агыздырылса, каберләр кубарылса, шул вакытта нәфес, ягъни җан үзенең элек һәм соң кылган гамәлен белер. Ягъни һәркем дә үзенең ни күрәсен белер (2, 3, 4, 5). Әй, адәм! Үзеңне яратканнан соң тигез вә килешле итеп Үзенең теләгән сурәтләреннән бер сурәттә кылган хөрмәтле Раббеңә коллык итүдән ни нәрсә алдап тыйды сине? Ягъни шундый кодрәт иясе булган Раббеңә каршылык итүгә ни нәрсә тартты сине? Үзеңне яраткан Раббеңнән алдану — ярый торган эш түгел. Сез алдаган нәрсә, сезнең кыямәт көнен ялганга чыгаруыгыз, ягъни кыямәт көне булуга ышанмаганга Аллаһыга каршылык кылдыгыз! «Үләбез дә бетәбез»,— дип белдегез (6, 7, 8, 9). Сез, кяферләр «Кыямәт булмас, рәсүлләр юкны әйтә, безнең дөньяда яшәгән гамәлләребез ул көнгәчә онытыла»,— дип уйладыгыз, әмма бу уегыз мәгънәсез, чөнки сезнең эшләрегезне күзәтеп, һәрбер эшегезне белеп, язып торучы хөрмәтле фәрештәләребез бар, алар сезнең кылган эшләрегезне һәрберсен дә язып торалар (10, 11, 12). Дөреслектә изге гамәлләләр бер дә шиксез рәхәттә булырлар. Әмма бозыклар җәһәннәм тәмугында булырлар. Алар җәһәннәмгә кыямәт көнендә керерләр дә ул тәмугтан аерылмаслар, ягъни кяферләр анда мәңге булырлар. Җәза көне шундый яман көндер, аның чын сыйфатын һичкем дә сыйфатлый алмас, ул җәза көне шундый көндер, ул көндә һичбер җан икенчесе өчен һичбер файда бирә алмас. Ул көндә һәркемнең дә эше Аллаһы Тәгалә кулында булыр. Бәндәләрдә дөньядагы кебек ирек булмас (13, 14, 15, 16, 17, 18, 19).

## «Мутаффифин» («Киметеп үлчәп бирүчеләр») сүрәсе
## Сиксән өченче сүрә, утыз алты аять

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
وَيْلٌ لِّلْمُطَفِّفِينَ ۝ الَّذِينَ إِذَا اكْتَالُوا عَلَى النَّاسِ
يَسْتَوْفُونَ ۝ وَإِذَا كَالُوهُمْ أَو وَّزَنُوهُمْ يُخْسِرُونَ ۝
أَلَا يَظُنُّ أُولَٰئِكَ أَنَّهُم مَّبْعُوثُونَ ۝ لِيَوْمٍ عَظِيمٍ ۝
يَوْمَ يَقُومُ النَّاسُ لِرَبِّ الْعَالَمِينَ ۝ كَلَّا إِنَّ كِتَابَ

الْفُجَّارِ لَفِي سِجِّينٍ ۝ وَمَا أَدْرَاكَ مَا سِجِّينٌ ۝
كِتَابٌ مَّرْقُومٌ ۝ وَيْلٌ يَوْمَئِذٍ لِّلْمُكَذِّبِينَ ۝ الَّذِينَ
يُكَذِّبُونَ بِيَوْمِ الدِّينِ ۝ وَمَا يُكَذِّبُ بِهِ إِلَّا كُلُّ
مُعْتَدٍ أَثِيمٍ ۝ إِذَا تُتْلَىٰ عَلَيْهِ آيَاتُنَا قَالَ أَسَاطِيرُ
الْأَوَّلِينَ ۝ كَلَّا ۖ بَلْ ۜ رَانَ عَلَىٰ قُلُوبِهِم مَّا كَانُوا

يَكْسِبُونَ ۝ كَلَّآ إِنَّهُمْ عَن رَّبِّهِمْ يَوْمَئِذٍ لَّمَحْجُوبُونَ ۝
ثُمَّ إِنَّهُمْ لَصَالُوا الْجَحِيمِ ۝ ثُمَّ يُقَالُ هَٰذَا الَّذِي
كُنتُم بِهِ تُكَذِّبُونَ ۝ كَلَّآ إِنَّ كِتَٰبَ الْأَبْرَارِ لَفِي
عِلِّيِّينَ ۝ وَمَآ أَدْرَىٰكَ مَا عِلِّيُّونَ ۝ كِتَٰبٌ مَّرْقُومٌ
يَشْهَدُهُ الْمُقَرَّبُونَ ۝ إِنَّ الْأَبْرَارَ لَفِي نَعِيمٍ ۝ عَلَى
الْأَرَآئِكِ يَنظُرُونَ ۝ تَعْرِفُ فِي وُجُوهِهِمْ نَضْرَةَ
النَّعِيمِ ۝ يُسْقَوْنَ مِن رَّحِيقٍ مَّخْتُومٍ ۝ خِتَٰمُهُ
مِسْكٌ وَفِي ذَٰلِكَ فَلْيَتَنَافَسِ الْمُتَنَٰفِسُونَ ۝ وَ

مِزَاجُهُ مِن تَسْنِيمٍ ۝ عَيْنًا يَشْرَبُ بِهَا الْمُقَرَّبُونَ ۝
إِنَّ الَّذِينَ أَجْرَمُوا كَانُوا مِنَ الَّذِينَ ءَامَنُوا يَضْحَكُونَ
وَإِذَا مَرُّوا بِهِمْ يَتَغَامَزُونَ ۝ وَإِذَا انقَلَبُوٓا إِلَىٰٓ
أَهْلِهِمُ انقَلَبُوا فَكِهِينَ ۝ وَإِذَا رَأَوْهُمْ قَالُوٓا إِنَّ
هَٰٓؤُلَآءِ لَضَآلُّونَ ۝ وَمَآ أُرْسِلُوا عَلَيْهِمْ حَٰفِظِينَ ۝
فَالْيَوْمَ الَّذِينَ ءَامَنُوا مِنَ الْكُفَّارِ يَضْحَكُونَ ۝
عَلَى الْأَرَآئِكِ يَنظُرُونَ ۝ هَلْ ثُوِّبَ الْكُفَّارُ
مَا كَانُوا يَفْعَلُونَ ۝

## ТРАНСКРИПЦИЯ

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәйлүл лил-мутаффифин (2). Әлләзинә изәкталү галән-наси йәстәүфунә (3). Вә иза кәлүһүм әү вәзәнүһүм йухсирун (4). Ә лә йәзуннү үләәикә әннәһүм мәбгусунә (5). Лийаумин газыймий (6). Йаумә йәкумүн-насү ли-раббил-галәмин (7). Кәллә иннә китабәлфүжжару ләфи сижжин (8). Вә мә әдракә мә сижжин (9)7 Китабүм-мәркумүн (10). Вәйлүн йаумәәизил-лил-мүкәззибинә (11). Әлләзинә йүкәззибунә йаумид-дин (12). Вә мә йүкәззибү биһи илләә күллү мәгътәдин әсимин (13). Иза түтлә галәйһи айатүна калә әсатыйрульәүвәлин (14). Кәллә бәл ранә галә кулубиһиммә кәну йәксибун (15). Кәллә иннәһүм гар раббиһим йаумәәизил-лә-мәхжубун (16). Сүммә иннәһүм лә-салүл-жәхыйм (17). Сүммә йукалү һазәл-ләзи күнтүм биһи түкәззибун (18). Кәллә иннә китабәл-әбрари ләфи гыййлийин (19). Вә мә әдракә мә гыййллийун (20). Китабүм-мәркумүн (21). Йәшһәдүһүл-мүкаррабүн (22). Иннәл-әбрарә лә-фи нәгыймин (23). Галәл-әраәики йәнзурун (24). Тәгърифү фи вөжүһиһим надратән-нәгыйм (25). Йүскаунә мир-рахикыйм-мәхътүмин (26). Хыйтәмүһү миск, вә фи заликә фәл-йәтәнафәсил-мүтәнафисун (27). Вә мизажүһү мин Тәснимин (28). Гайнай-йәшрәбү биһәл-мүкаррабүн (39). Иннәл-ләзинә әжрамү кәнү минәл-ләзинә амәну йәдхакүн (30). Вә иза мәррубиһим йәтәгамәзун (31). Вә изан-каләбу илә әһлиһимүнкаләбу фәкиһин (32). Вә иза раәүһүм калү иннә һәәүләәи лә-даллунә (33). Вә мә үрсилү галәйһим хафизыйн (34). Фәл-йаумәл-ләзинә амәну минәл-күффари йәдхакүнә (35). Галәл-әраәики йәнзурун (36). Һәл сүввибәл-күффару мә кәнү йәфгалүн (37).**

## СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

**Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).**

**Үлчәүдә кимлек кылучыларга олуг үкенечләр! Алар кешегә үлчәп биргәндә ким үлчәп, кешедән үзләренә алганда артык үлчәп алырлар. Ул адәмнәр, әгәр савыт белән яки авырлык белән үлчәсәләр, киметеп үлчәрләр, ягъни кешегә биргәндә киметеп үлчәрләр. Кешедән алганда бер кадак аласы урында артыграк үлчәп, алдап алырлар (2, 3, 4, 5, 6). Эш алай түгел, ягъни үлчәүдә кимөтү — кешедән артык алу, үлгәннән соң үлекләрнең терелеп кабердән кубарылуы булмый дип уйлаган кешеләрдер. Хак булса иде, ни өчен кешедән артык алыр иде? Кимле булу шаять һәм дәлилсез хак түгел кимлек эшләр. Дөреслектә, кяферләрнең гамәлләре язылган дәфтәр әлбәттә сижжиндәдер. Сижжин ни нәрсә? Сижжин — явызларның гамәлләре язылган дәфтәрдер. Җәза көне булган кыямәт көнен ялганга чыгарган, ялганчыларга җәза көнендә олуг үкенечтер! Ул җәза көне чиктән тыш гөнаһка чумучы аятьләребез укылганда бу әүвәлгеләрдән калган үгетләр генә диюче кешеләргә үкенечтер (7, 8, 9, 10, 11, 12, 13, 14). Эш алай түгел, кыямәт көне — хак! Бәлки бу кяферләрнең эшләгән эшләре аларның күңелләрен каплады, ягъни бозыклыклары күңелләрен каралтканлыктан, кыямәт көненә иман китермиләр. Кылган эшләре тиешсез. Дөреслектә ул кяферләр кыямәт көнендә Раббеләрен күрүдән пәрдәләнерләр. Шуннан соң алар, әлбәттә, җәһәннәм тәмугына керәчәкләрдер. Моның соңында тәмугка кергәч әйтелер: «Менә инде бу ут — сез ялганга чыгарган нәрсәдер!» — дип. Эш алай кяферләр әйткәнчә түгел. Дөреслектә, изге кешеләрнең китабы, әлбәттә, гыйллиййундадыр, ягъни җиде кат күкнең дә иң югары урынындадыр. Гыйллиййун ни нәрсә? Гыйллиййун — язылган китаптыр; аны Аллаһыга якын булган фәрештәләр саклаклар (15, 16, 17, 18, 19, 20, 21). Дөреслектә, изгеләр җәннәттә диваннар өстендә нигъмәтләргә карап торырлар, аларны күрсәң — йөзләрендә**

ниГъмәттән шатланганлыкларын күрерсең. Алар җәннәттә башы мөһерләнгән саф хәмердән сугарылырлар. Аларның мөһере мисектән, ягъни хуш ис бөркеп торучы мускустан булыр. Инде бу ниГъмәттә булуны теләгәннәр, ошбу ниГъмәткә кызыгып, шунда булуга сәбәп булган гамәлләрне кылсыннар, ул хәмернең табигате — Тәсним, ягъни җәннәт чишмәсеннәндер. Ул чишмәдән Аллаһының якын коллары эчәрләр (22, 23, 24, 25, 26, 27, 28). Курәйш олугларыннан бозыклары мөэминнәрдән көлүче булдылар. Мөселманнардан үткәндә күзләрен йомып мөселманнарны хурлау булдылар. Әгәр дә өйләренә кайтсалар, шул хурлауларыннан кәефләнеп кайтыр булдылар. Әгәр мөэминнәрне күрсәләр, «Менә болар юлдан язганнар»,— дип әйтер булырлар. Ул Кяферләргә мөэминнәрнең гамәлләрен күзәтү эшләре бирелмәсен (29, 30, 31, 32, 33). Инде Кыямәт көнендә мөэминнәр диваннарга утырып карап торганда кяферләрдән көләрләр, ягъни кяферләр газап кылынган чакта мөэминнәр җәннәт эчләреннән: «Кяферләргә дөньяда кылган эшләренә күрә җәзалар бирелдеме икән?» — дип карап, кяферләрнең җәза һәм газапта булуларын күреп, алардан көләрләр (34, 35, 36).

## «Иншикакъ» («Ярылу») сүрәсе
## Сиксән дүртенче сүрә, егерме биш аять

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
إِذَا السَّمَاءُ انْشَقَّتْ ۝ وَأَذِنَتْ لِرَبِّهَا وَحُقَّتْ ۝ وَ
إِذَا الْأَرْضُ مُدَّتْ ۝ وَأَلْقَتْ مَا فِيهَا وَتَخَلَّتْ ۝
وَأَذِنَتْ لِرَبِّهَا وَحُقَّتْ ۝ يَا أَيُّهَا الْإِنْسَانُ إِنَّكَ كَادِحٌ
إِلَىٰ رَبِّكَ كَدْحًا فَمُلَاقِيهِ ۝ فَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ
بِيَمِينِهِ ۝ فَسَوْفَ يُحَاسَبُ حِسَابًا يَسِيرًا ۝ وَ
يَنْقَلِبُ إِلَىٰ أَهْلِهِ مَسْرُورًا ۝ وَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ
وَرَاءَ ظَهْرِهِ ۝ فَسَوْفَ يَدْعُو ثُبُورًا ۝ وَيَصْلَىٰ سَعِيرًا
إِنَّهُ كَانَ فِي أَهْلِهِ مَسْرُورًا ۝ إِنَّهُ ظَنَّ أَنْ لَنْ يَحُورَ ۝
بَلَىٰ إِنَّ رَبَّهُ كَانَ بِهِ بَصِيرًا ۝ فَلَا أُقْسِمُ بِالشَّفَقِ ۝
وَاللَّيْلِ وَمَا وَسَقَ ۝ وَالْقَمَرِ إِذَا اتَّسَقَ ۝ لَتَرْكَبُنَّ
طَبَقًا عَنْ طَبَقٍ ۝ فَمَا لَهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ ۝ وَإِذَا قُرِئَ
عَلَيْهِمُ الْقُرْآنُ لَا يَسْجُدُونَ ۝ بَلِ الَّذِينَ كَفَرُوا
يُكَذِّبُونَ ۝ وَاللَّهُ أَعْلَمُ بِمَا يُوعُونَ ۝ فَبَشِّرْهُمْ
بِعَذَابٍ أَلِيمٍ ۝ إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا
الصَّالِحَاتِ لَهُمْ أَجْرٌ غَيْرُ مَمْنُونٍ ۝

### ТРАНСКРИПЦИЯ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).

Изас сәмәәүн-шәккат (2). Вә әзинәт ли-раббиһа вә хуккат (3). Вә изаль-арду мүддәт (4). Вә әлкат мә фиһа вә тәхалләт (5). Вә әзинәт ли-раббиһа вә хуккат (6). Йа әййүһәл-инсану иннәкә кәдихун илә раббикә кәдһан фә-мүләкыйһ (7). Фә әммә мән утийә китабәһү би-йәминиһи (8). Фә-сәүфә йухасәбү хисабәй-йәсирав (9). Вә йәнкалибу илә әһлиһи мәсрура (10). Вә әммә мән үтийә китабәһү вәраәә заһриһи (11). Фә-сәүфә йәдгу сүбурав (12). Вә йәсла сәгыйра (13). Иннәһү кәнә фи әһлиһи мәсрура (14). Иннәһү заннә әл-ләй-йәхура (15). Бәлә иннә раббәһү кәнә биһи басыйра (16). Фә-лә укъсиму биш-шәфәкый (17). Вәл-ләйли вә мә вәсәка (18). Вәл-камәри изат-тәсәка (19). Лә-тәркәбүннә табакан ган табак (20). Фә-мә ләһүм лә йүэминунә (21). Вә иза куриза галәйһимул-Коръәнү лә йәсҗүдүн (22). Бәлил-ләзинә кәфәру йүкәззибунә (23). Вәл-лаһү әгъләмү би-ма йүгун (24). Фә-бәшширһүм би-газабин әлимин (25). Илләл-ләзинә амәну вә гамилүс-салихати ләһүм әҗрун гайру мәмнун (26).

### СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әгәр күк ярылса, үзенә буйсыну тиеш ителеп, Раббесенең фәрманын тотып ярылса, жир тигез ителсә (таулары бетерелсә), ул жир үзендә булган нәрсәләрне чыгарып бушанса, Раббесенең сүзен тыңлап, тыңлау тиеш ителгәнен белсә, шул вакытта адәм үзенең кылган гамәлләренә юлыгыр. Әй, адәм! Дөреслектә син үзең өчен тырышачаксың, Раббең тарафына тырышкан гамәлең белән барып Раббеңә юлыгачаксың (2, 3, 4, 5, 6)! Инде берәүнең гамәл

дәфтәре уңыннан бирелсә, ул кеше җиңел булган хисап белән хисап ителер һәм дә үзенең дус ишләренә шатланып кайтыр (7, 8, 9). Инде бәрәүнең гамәл дәфтәре арка тарафыннан бирелмеш булса, бу кеше үзенә һәлаклек белән кычкырыр: «Һәлак булдым!» — дип һәм дә җәһәннәмгә керер. Ул кеше дөньяда вакытында әһле эчендә шатланучы булды, үзен үлгәннән соң, үлгәч кире кайтарылып терелдем, дип уйлаган иде. Әмма үлгәннән соң терелачәк һәм җәза ителәчәк иде, чөнки аның Раббесе аны дөньяда вакытта күреп торган иде (10, 11, 12, 13, 14, 15). Эш кяферләрчә түгел. Шәфәкъ белән, һәм дә кич белән ант итәмен: шулай ук кичне җыйган һәм пәрдәләгән нәрсә белән ант итәмен. Һәм да Ай белән ант итәмен, әгәр ул Ай тулса, тәгалләнсә, ошбу нәрсәләр белән ант итәмен. Бер дә шиксез сез бер куркынычлы хәлдән икенчесенә алмашынырсыз. Ягъни әүвәл үлеп, үлгәннән соң кабергә куелып, кабердә сөәль ителеп, аннан кубарылып, аннан соң сөәль ителерсез һәм хисап ителерсез. Инде бу кяферләргә ни булды? Алар шундый куркулы көндә котылу өчен, үзләренең Раббеләренә иман китермиләр (16, 17, 18, 19, 20). Кайда ул, Коръән укыганны ишеткәч, Коръәнгә иелү?! Бәлки кяфер булганнар Коръәнне ялганга санарлар, ягъни Коръәнне ишетсәләр, илчеләреннән Коръәнне ялганга тоталар, ләкин Аллаһы Тәгалә аларның илчеләрендә булган серләрен бик беләдер. Инде, син, әй, Мөхәммәд! Ул кяферләргә каты газап белән сөенеч бир! Ягъни бу кяферләр шул хәлләрендә торсалар, шул кяферләрен яхшы дип санасалар, ул эшләре бәрабәренә бездән газап белән сөенеч бир! Мәгәр бу эшләреннән кайтып, иман китереп, изге гамәлләр кылсалар — алар газабыннан котылырлар һәм дә аларга бер дә бетми торган әҗер бирелер (21, 22, 23, 24, 25).

**Сүрәләрне Әнвәр ХӘЙРИ әзерләде.**

---

*Котлыйбыз!*

## Флера Гыйззәтуллинага 60 яшь




Флера Сабиржан кызы Гыйззәтуллина 1931 елның 6 сентябрендә Татарстанның Азнакай районы Әсәй авылында туган. Җиде класс тәмамлаганнан соң колхозда терлек карый, уналты яшеннән Кемерово якларына китеп, шахтада эшли. Омск—Томск тимер юлын салуда катнаша, аннары Донбасста «Калиновка» шахтасында хезмәттә була. 1952 елда кабат Татарстанга кайта һәм 1970 елга кадәр Лениногорск районы Карабаш поселогы ательесында тегүче булып эшли; кичке мәктәптә укып, урта белем ала. 1970—79 елларда ул Тольятти шәһәрендә яши, 1980 елдан исә Казанга күчеп кила, әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә.

Ф. Гыйззәтуллинаның беренче шигырьләре 1963 елдан башлап республика газеталарында, «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында, коллектив җыентыкларда басыла. 1974 елда шагыйрәнең беренче мөстәкыйль китабы — «Чишмә җыры» дөнья күрә. Хәзер ул — укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан җылы каршыланган күп кенә шигырь китаплары авторы. Шигырьләрендә аның бай хезмәт биографиясе, чорга бәйле кичерешләре, мәхәббәт хисләре һәм хатын-кыз язмышы аеруча калку сурәтләнүен С. Хәким, Ш. Маннур, Ә. Баянов кебек әдипләр язып чыкты. Бу сыйфатлар аның «Дүрт кыз», «Йөрәгемне эзлим» кебек поэмаларына да хас.

Ф. Гыйззәтуллинаның композиторлар тарафыннан көйгә салынган җырлары да бар. Ул — 1980 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**ФАТИХ ИБРАҺИМОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты

# ИЖ-БУБИ ШӘКЕРТЕ



Кол Галидән алып бүгенге көнгә кадәр саный башласаң, иҗатларын шәхси батырлык белән дә бизәгән, халык бәхете өчен башларын салган әдипләребез шактый күп. Акмулла, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәй, Шамун Фидаи — аларның кайберләре. Шундыйлар арасында тагын берәү бар. Ул да, әле генә саналган күренекле әдипләр белән рәттән, тарихыбызда азмы-күпме игелекле эш эшләп калдырган шәхес.

Ул үз заманында иген иккән, мал асраган, урман кискән, печән чапкан, балалар укыткан, шигырьләр язган, дәреслекләр иҗат иткән. Үзе укып үскән якларда торып, караңгылык патшасында яшәгән, якташларына мәгърифәт нурлары чәчкән. Аның исеме — Давыт, фамилиясе — Гобәйди.

Чыннан да, кем соң ул Давыт Гобәйди?

Без аны якыннан беләбезме? Аны гына түгел, кызганычка каршы, татар халкының тагын бик күп галимнәрен, рәссам-әдипләрен, артист-композиторларын, фән-культура эшлеклеләрен, педагог-методистларын белеп бетермибез. Аларның күбесен бездән Сталин чорында торгызылган кара стена каплап торды. Ә безгә, гомумән, халкыбызның тарихын бик нык белергә кирәк, бигрәк тә яшьләребез моңа мохтаҗ.

Мәгърифәтче, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Давыт Гобәйдулла улы Гобәйди Татарстанның хәзерге Әгерҗе районына кергән Кыдырлы авылында 1873 елда дөньяга килгән. Тик шунысы аянычлы: ата белән ана уллары Давыт һәм аның бертуганы Нәҗибне карап үстерү бәхетенә ирешә алмыйлар — бик иртә вафат булалар. Берсеннән-берсе кечкенә ике малай әби белән бабай кулына кала. Озакламый бабай кеше дә дөнья куя. Аңлашыла, патша армиясендә 25 ел хезмәт итеп кайткан солдат үз оныкларына әллә ни мөлкәт калдыра алмаган. Барлы-юклы крестьян хуҗалыгын тартып бару мәшәкате 12 яшьлек Давыт җилкәсенә әнә шулай бик иртә төшә.

Давыт кече яшьтән үк уку-язуга хирыс була. Әмма Кыдырлыда ул вакытларда кадимчә генә укытканнар. Бередә рәтле белем алып булмаячагына тиз төшенгән малай, энесен ияртеп, даны тирә-якларга таралган Иж-Буби җәдит мәдрәсәсенә юнәлә.

Иж-Буби мәдрәсәсендә хәтта кызлар мәктәбе дә була. Бередә сабак бирү, дөнья күтәргә өйрәнү белән генә чикләнмиләр; хәзергечә әйтсәк, класстан тыш чараларга да җитди әһәмият бирелә. Күңелле кичәләр уздыру, шигырьләр сөйләү, спектакльләр кую, җырлау-бию, төрле темаларга бәхәсләр оештыру гадәти күренешкә әйләнә. Кичәләрдә Давыт Гобәйди дә актив катнаша. Җор сүзле, яңгыравык тавышлы шәкерт матур итеп җырларга, оста итеп скрипкада уйнарга өйрәнә.

Ятим һәм ярлы булуга карамастан, Давыт күңелен төшерми, энесе Нәҗиб белән хәллерәк шәкертләргә самавыр кую, аш пешерү, мөгаллимнәрнең кулъязмаларын

күчереп язудан килгән кечкенә керем бәрабәренә укуын дәвам иттерә.

Давыт Гобәйди 1897 елда, элек мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, үзенең туган авылына кайтып, малайлар өчен җәдитчә мәктәп ачып җибәрә. Бубилар үрнәгендә, Кыдырлы авылы тарихында беренче буларак, кызлар мәктәбе дә эшли башлый.

Иске Кызылъяр авылы кешеләре 1905 елда алдынгы карашлы, укымышлы Давыт Гобәйдине үзләренә мулла һәм мөгаллим итеп чакыралар. Алар, имзалар җыеп, Уфа диния нәзарәтенә үтенеч җибәрәләр, аннан ризалык алуга ирешәләр. Шул елдан башлап Давыт мулла үзенең бөтен гомерен, белемен һәм сәләтен шушы авыл халкына хезмәт итүгә бирә.

Бирегә килгәч тә ул эшчәнлеген яңа мәктәп бинасы салудан башлап җибәрә. Элек татар авылларында мәдрәсәләрне, гадәттә, түбән җиргә, су буена сала торган булганнар. Давыт Гобәйди халыкны җыя да:

— Җәмәгать, урыс чиркәүләренә генә карагыз, авылның иң биек җирендә кукраеп утыралар, мәдрәсәне дә нигә шундый биек урынга салмаска?— ди.

Җыен ризалык бирә. Халыктан җыйналган акчага мәдрәсә бинасын авылның биек урынына салалар. Бик матур һәм иркен бинаның бер ягында малайлар, икенче ягында кызлар укый. Яңа ачылган мәктәпкә чит авыллардан, хәтта 30—40 чакрымнан килеп тә белем алалар.

Давыт Гобәйди, авылда муллалык вазифасын үтәсә дә, күбрәк вакытын иҗат һәм укытучылык эшенә сарыф итә. Өлкәннәрнең уку-язу һөнәрен үзләштерүләренә күп көч сала. Көндез балалар укытса, кичләрен зурлар белән шөгыльләнә.

Мөгаллим буларак исә, ул укучыларда матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли: үзенең шигырьләрен укый, үзе чыгарган көйләрне скрипкада уйный, Бубидагыча күңелле кичәләр үткәрә.

Давыт Гобәйди урыс телен һәм культурасын үзләштерүгә көчен кызганмый. Иж-Буби мәдрәсәсендә өйрәнгәннәрен авылга кайткач та дәвам иттерә. Күршедәге Мордыбай авылы укытучысы Арслан белән дуслашып, аңардан дәресләр ала. Олы кызы Һаҗәрне Иж-Буби мәдрәсәсеннән алып, күршедәге Быстряк авылындагы урыс мәктәбенә күчерә. Менә шуңа булса кирәк, дошманнары Давыт Гобәйдигә «урыс мулла» дигән кушамат тагалар.

Патша хакимияте 1912 елда Иж-Буби мәдрәсәсен тар-мар итә, аның җитәкчеләрен төрмәгә яба. Бу вәхшиятнең дәһшәтле җил-давылы Иске Кызылъяр авылына да килеп җитә. Һәм, Иж-Буби мәдрәсәсеннән чыккан күп кенә шәкертләр кебек, Давыт Гобәйди дә кулга алына. Әлеге күңелсез вакыйгаға шагыйрьнең олы кызы Һаҗәр менә ничек хәтерли:

— Әтине кулга алу болайрак булды. Без балалар идәндә, әтиләр исә караватта йоклый иде. Уянып китсәм, өй тулы кеше, шалтыр-шолтыр киләләр, аякларга да басып китәлиләр. Тышта 15-20 ләп җигүле ат. Урысча сөйләшәләр. Әткәй аларга китапларын, кәгазьләрен бирә. Өстәл тартмаларын, сандыкларны ачып күрсәтә. Хәтерлим: әтинең күп кенә китапларын һәм кулъязмаларын алып киттеләр ул чакта. Базларга да төштеләр, чардакларны да актардылар. Аннары стражниклар әтигә киенергә куштылар.

— Кая барасың?— дидем дә елый-елый аңа ташландым.

— Становой пристав янына, бер-ике сәгатьтән кайтырмын,— диде әткәй.

Көтәбез, көтәбез... Иртән дә юк, кичен дә. Аннары хәбәр килде: итекләрен, киемнәрен сораткан. Ике көннән Сарсык-Омгадан (волость үзәгеннән) Сарапулга алып киткәннәр.

Мулланы халык арасында панисламизм идеяләрен таратуда гаепләләр. Ләкин, исбат итәрлек дәлилләр тапмаганлыктан, дүрт айдан азат итәргә мәҗбүр булалар.

Буржуаз-демократик февраль революциясен Давыт Гобәйди зур өметләр белән каршы ала. Моны без аның һәр сүзе көчле эмоция белән сугарылган «Хөррият» шигыреннән ачык күрәбез.

*Алды бүген өстебездән йодрыгыны ил башы,*
*Чыкты бүген өстебезгә Хөрриятнең кояшы...*
*Урра! Урра! Шаула, халык, уйна, инде алга, алга!*
*Урра! Урра! Кара көчнең муены сынды — якты алда.*
*Ач күзеңне, тор, халык, алга бар, алга таба,*
*Алга таба, урра! Урра! Алдагы таңга таба!*

Гомумән, Д. Гобәйди киләчәккә өмет белән караучы шагыйрь. Ул бер шигырендә моны бик ачык итеп әйтеп бирә: «Әле, туган, безнең якты көннәр алда»,— ди. 1913 елда, Россиядә кара реакция хөкем сөргән елларда әйтелгән сүзләр бу.

Октябрь революциясеннән соң Давыт Гобәйдине якташлары волость Советына де-

легат итеп сайлыйлар. Ул Сарсык-Омга волость башкарма комитеты рәисе урынбасары һәм халык мәгарифе бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Бер үк вакытта ул мәктәптә мөгаллимлек эшен дә дәвам иттерә.

1919 елның язында Колчак яулары көнчыгыштан һөҗүм итеп киләләр. Сарсык-Омганың дошман бандалары кулына төшү куркынычы тугач, бер төркем партия-совет хезмәткәрләре һәм алдынгы фикерле укытучылар, Кызыл Армия частьлары белән бергә, Казанга таба чигенергә булалар. Җитмеш олауга төялеп юлга чыгалар. Алар арасында Давыт Гобәйди дә була. Узып барышлый, Давыт Гобәйди үзе яшәгән Иске Кызылъяр авылы кешеләренә васыять хатын язып калдыра. Бу минутларда аның нинди халәттә булуын чамалау кыен түгел. Хаттагы төгәлсезлекләр, килеп җитмәгән урыннар да әнә шул хакта сөйли. 1919 ел диясе урынга 1920 ел дип (числосы дөрес) язганын да сизми калган, күрәсең. Васыятьне кабат укырга да вакыты булмагандыр. Авторның башка кульязмалары белән чагыштырып карау хатның анык булуына шик-шөбһә калдырмый.

Менә ул хат-васыять. Авторның стиле, шул хәтәр заман ядкаре буларак, тулысынча сакланды.

*«Иске Кызылъяр авылы гражданнарына.*
*Туганнар, ибдәшләр!*

*Революциянең көчле дулкыннары, үз агымы белән мине дә алып китте. Мин инде бу көн үземнең кырык ел торган илемне (бу вакытта аңа 36 яшь — Ф. И.), унөч елдан бирле һавасын иснәп, суын эчеп яшәдегем Иске Кызылъярны, андагы бөтен дустишләрем белән бергә үземнең армый-талмый эшләп аякга бастыра алдыгым мөкатдәс мәктәбне, башларын күккә чыгарып, мөселманлыкның бердәнбер галәмәте булган мәһабәт мәсҗедне калдырып чыгып китәм. Мине революциянең көчле дулкыны үз агымына таба агызып, бик авырлык белән булса да сездән вә балаларымнан аерылып торырга мәҗбүр итте. Хәзергә хуш, сау булыңыз, ибдәшләр. Сез минем юлның нинди икәнен, дөньядагы партияләрнең берсенә булсын, катышмаганымны беләсез.*

*Минем бар тоткан юлым — халыкны укыту һәм агарту булып, мөнбәр башындагы сезгә чын белән ялган арасын аерып сөйләү, мөселманлыкның һәм Коръәнемезнең нәрсә икәнен аңлату, балаларыңызны вә гомумә яшь буынны адәб-тәрбиягә өйрәтү иде. Мин боларны булдырдым да инде ахры. Чөнки Иске Кызылъяр тәрбия ягыннан караганда башка һәрбер авылдан өстен тора.*

*Сез минем китүнең сәбәбе нәрсә икәнен сорарсыз инде. Кыскача гына шулай җавап бирәмен:*

*Мин һичбер партиягә каршы бер эш эшләмәдем. Беләсең мохтаҗлык дигән нәрсә мине укыту эшенә кыслып, ахырында мәктәпләрне һәм алардагы уку вә укыту эшләрен тикшерүче итеп куйды.*

*Янәшә-тирәнең надан кешеләре укытучыларга дошман күзе белән карыйлар. Аларны, укытучыларны, коммунист диеп беләләр. Шундан аңлашыла, алар икенче бер партиянең килеп керүе белән үк укытучыларга ябышып, кулларыннан килгән бөтен пычракларны эшләячәкләр. Аннары, мин сайланган көнемнән башлап, совет эшчесе булып танылганга, мин көчләнеп китәм. Китмәсәм — мылтык, китсәм, әллә нинди мәшәкатьләр куркыта. Менә шуның өчен дә мин көчләнәм, көчләнеп китәм. Ходай миңа шулай язгандыр инде. Сездән вә балаларымнан аерылу бик кыен булса да, Ходайдан тиз кайтуны өмед итеп, моңлы Кызылъярга сәламемне укып чыгып китәм. Хуш, сау булыңыз, ибдәшләр. Сез миннән файдадан башканы күрмәгәнсездер, инша алла. Кайберләреңезне рәнҗеткән булсам, гафу итеңез мине. Гаилә вә балаларымны Аллага тапшырып вә сезгә ышанып калдырам. Сезнең үзеңезнең тәмле тел, йомшак сүзләреңез белән аларның көенечле күңелләрен юатыңыз. Ходай сезгә вә сезнең балаларыңызга да рәхмәт күзе белән карасын. Ах, авыр миңа шушы ике юлны язу! Ышанам, ибдәшләр: сез аларны кеше капкасына тилмереп булдырмассыз, аларның усаллар тарафыннан сүгелеп кадерсезләнүләренә сезнең инсафлы вөжданнарыңыз разый булмас. Сүземнең шул төшләренә йеткәч, бик авыр миңа. Кулларым язарга бармый! Хуш, ибдәшләр, сау булыңыз! (Ул вакытта Давыт Гобәйдинең берсеннән-берсе кечкенә алтымы, җидеме баласы булган. Әнә шул балаларның язмышы турында аның тетрәнүе бик табигый.— Ф. И.). Мин сезгә нинди яхшы юл өйрәткән булсам, шуның буенча барып, мәктәбләр алдында тезләнеңез. Коръәнне тугры аңлап, аның эзеннән кыл кадәр дә аерылмаңыз. Коръәнгә хилаф, дин исемендән ялган сөйләүче, мөкаддәс динемезне карага буяучыларның сүзләренә ышанып дөнья, ахирәт-бәхетсез булмаңыз.*

*Элекке кебек тату, бер сүздә яшәп, береңез өстеннән береңез данус ясамаңыз, әләкләшмәңез. Күп мәртәбәләр әйткәнемчә, кулларыңызга агач кылыч алып, инкыйлабны тыныч кына уздырырга тырышыңыз.*

*Ходай тиз көннән күрешеп һәм шадланып яшәвемезне насыйб итсен иде. Амин. Кулларыңызны кысып, маңлайларыңыздан үбеп калам.*
*Апрель 8, сәнә 1920.*

*Габәйди».*

Качаклар Вятские Поляны шәһәренә килеп җиткәч, берничә көн шунда торалар. Планнары барып чыкмавына ышангач, күбесе кирегә борыла. Фаҗига шуннан башлана. Давыт Габәйди берничә юлдашы белән Туембаш авылына килеп җитә. Анда шагыйрьнең Уразбахтин фамилияле дусты була. Биредә берничә көн яшеренеп яткач, башка кеше исеменә яңа «обоз мужигы» дигән белешмә рәтлиләр. Давыт Габәйди ят фамилия белән туган ягына кайтырга чыга һәм Тәбәрле авылына килеп җитә.

Шушы авылда Колчак гаскәренең Акмолинск полкы штабы урнашкан була. Үзенең кыргыйлыгы белән яман аты таралган полкка килеп кабуын Давыт сизми дә кала, «обоз мужигы»н патрульләр штабка — авыл бае Латыйп Вахитов йортына китерәләр. Дежур офицер, документны карап, мужикны ирекке җибәрә. Әмма, бәхетсезлеккә күрә, ишектән атлап чыкканда Д. Габәйди хуҗа белән йөзгә-йөз очраша һәм Латыйп, ашыгып, кычкырып ук җибәрә:

— Нигә котылдырасыз бу кешене? — ди ул офицерга.— Чи коммунист бит ул! Революциягә кадәр үк бөтен дөньяны болгатучы иде, моны да җибәрсәгез, сезгә ышаныч юк!

Давыт Габәйдине шундук тотып алалар. Штабта ук чишендереп җәзалый башлыйлар. Ат койрыгына тагып каравыл йортына алып китәләр. Анда да җәзалау дәвам иттерелә. Палач аның кулын кылыч белән өзеп төшерә.

Җәзалау зират янында тагын да көчәя. Биредә Давыт Габәйдинең кылыч белән борынын, колакларын кисеп төшерәләр, күзен чыгарарлар һәм, муенын чабып, бөтенләй тураклап ташлыйлар. Шагыйрь әнә шулай утыз алты яшендә фаҗигале һәлак була. Аның мәетен хәтта күмәргә дә рөхсәт итмиләр, кискәләнгән гәүдә зират янындагы юл кырыенда аунап кала.

Шомлы көннәр кичергән авыл халкы, тәкате корып, аклар күрмәгәндә мәрхүмнең мәетен зират кырыена төнлә тиз генә күмеп куя.

Колчак бандалары куылгач, Давыт Габәйдинең гәүдәсен Тәбәрледән үзенең туган авылына алып кайтып, хөрмәтләп күмәләр. Аның кабере хәзер Кыдырлы зиратында. Әмма, Кыдырлы «перспективасыз» авыллар рәтенә кертелгәнлектән, анда хәзер нибары бер гаилә яшәп калган. Шунлыктан игелекле мәгърифәтченең кабере ташландык хәлдә. Күңелсез генә түгел, кызганыч, бик кызганыч хәл!

Давыт Габәйди үзенең утыз алты ел яшәү дәверендә халык өчен шактый эшләр эшләп калдырырга өлгерә. Ул ике-өч мәктәп салдырган, балалар укыткан, шигырьләр язган, тәрҗемә эше белән шөгыльләнгән, дәреслекләр төзегән, аларны бастырып чыгарган. Үзе ачкан җәдит мәктәбендә үзенең укыту методикасын булдырган. Бер үк вакытта ул имам да булып торган.

Менә шушы чандыр гәүдәле, уртача буйлы, шат күңелле, өстенә мамык тукымадан костюм, башына түбәтәй киеп йөри торган, гадидән дә гади авыл хәлфәсе, олы кызы Һаҗәр хәтерләвенчә, өйнең түр ягында язып утыра торган булган. Ул гомернең бер минутын да бушка уздырмаган. Уку-язудан бушаган араларда кул һөнәре белән шөгыльләнгән.

Давыт Габәйди кече күңелле, ярдәмчел, җыр-музыкага бик һәвәс кеше булуы белән дә мәгълүм. Матур, моңлы, яңгыравык тавышы белән татар көйләрен бик оста җырлаган. Халык арасында торып, аңа мәгърифәт идеяләрен турыдан-туры җиткерүче шәхес булуы белән безгә бик кадерле Давыт Габәйди.

Д. Габәйдинең халык арасында алып барган мәгърифәтчелек һәм җәмәгатьчелек эшчәнлеге, әдәби мирасы, педагоглык хезмәте — берсе дә тәфсилләп өйрәнелмәгән.

Аның 1904 елда «Татар кызы», 1905 елда «Күке» шигырьләрен язуы билгеле. Дөрес, ул үзе иҗат иткән әсәрләренең барысын да бастырып чыгарырга өлгерә алмаган. Кызганыч, аның архивын да, әсәрләрен дә саклап калучы булмаган. Мондый шартларда безгә аның иҗатының бер өлеше генә килеп җитүе ихтимал. Инде әйтелгәнчә, зинданга ябылу вакытында жандармнар аның китаплары белән бергә, бик күп кульязмаларын да алып китәләр һәм кире кайтармыйлар. «Җәһәннәм» дигән романының беренче китабын язып та, аның каядыр югалуы турында да хәбәрләр бар. Шунысын да әйтик, Казаннан еракта яшәгән әдипкә үзенең әсәрләрен китап итеп бастырып чыгару бик җиңелдән булмагандыр.

Д. Габәйдинең «Шүрәле каргаган авыл» исеме белән 1913 елда «Юл» китапханәсе нәшриятында шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Бу аның үзе исән чакта басылган беренче һәм соңгы җыентыгы.

Әлеге 182 юллык риваятьне автор 1913 елда иҗат иткән һәм, әйтергә кирәк, бу елларда аның иҗади активлыгы сизелерлек арткан булырга ошый. Әмма бер нәрсә ачык: риваять күп яктан Габдулла Тукайның «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» кебек әкиятләренә янәшә куярлык мавыктыргыч әсәр. Бигрәк тә аның сюжеты балалар өчен кызыклы. Аны хәзерге вакытта рәсемнәр белән бизәп, балалар өчен бастырып чыгару дөрес булыр иде. Бу әсәр халыкчан, аңлаешлы телдә язылуы белән дә игътибарга лаек.

Әлеге җыентыкта тагын «Тимерче», «Матур кызга», «Кыз», «Татар исереге ... ка», «Тормыш хәбәрләре», «Татар шагыйре ... га», «Таң алдыннан», «Дога», «Думбра», «Авыл» исемле үз шигырьләре һәм, болардан тыш, А. Кольцовтан тәрҗемә ителгән «Сукачы җыруы» тупланган.

Д. Гобәйдинең икенче җыентыгы 1959 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Китап, билгеле, яфрак калынлыгы гына. Беренче җыентыкка кергән шигырьләрдән тыш, икенчесенә нибары «Татар кызы», «Күке», «Сабанчы карт», «Шафкатьле әнкәй», «Хөррият» һәм «Татар улына» шигырьләре генә өстәлгән. Аны туплаучы Фоат Садыйков, әлеге җыентыкка авторның халык арасыннан тырышып язып алынган шигырьләренең өчтән бере дә кермәгәнлеген белдерә. Сәбәбе — кәгазь кытлыгы. Димәк, Д. Гобәйдинең җыентыкка керми калган шигырьләре Татарстан китап нәшрияты архивында сакланырга тиеш.

Д. Гобәйдинең рус әдәбияты һәм мәдәнияте белән даими кызыксынучы кеше булуы турында алда әйтелде инде. Ул рус һәм Көнбатыш Европа язучыларының әсәрләрен үзебезнең телгә тәрҗемә итү белән дә актив шөгыльләнә. Н. Гогольнең 1905 елда тәрҗемә ителгән «Өйләнү» һәм «Ревизор» пьесалары, 1912 елда Марк Твенның «Принц һәм теләнче»се, 1913 елда А. Кольцовның «Сукачы җыруы» әнә шундыйлардан. 1919 елның 4 февралендә Казанның «Новый клуб» дип йөртелгән тамаша залында Н. В. Гогольнең «Өйләнү» пьесасы Давыт Гобәйди тәрҗемәсендә сәхнәгә куела.

Д. Гобәйди дәреслекләр иҗат итү буенча да игелекле башлангыч күрсәтә. Аның ике кисәктән торган «Хифзы әс-сыйхәт дәресләре» дигән төрекчәдән тәрҗемә китапларының ике тапкыр басылып чыгуы мәгълүм. Китапларда һәр дәрескә эшкәртмә бирелгән, эшкәртмәләрдә гигиена мәсьәләләренә җитди игътибар ителгән. Анда, мәктәп балаларын чисталык-пөхтәлек күнегүләренә өйрәтү белән бергә, тәмәке тарту һәм аракы эчүнең зарары бик үтемле исбат ителә. Д. Гобәйдинең шигырьләрендә эчүчелеккә каршы әйтелгән фикерләрне шактый еш очратырга мөмкин.

Авторның «Мөгаллим әл-хәруф» дигән әлифбасына заманында җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәя бирелә. Аның өч тапкыр басылып чыгуы да шул хакта сөйли. Хәрефләрне өйрәнгәч, уку өчен күнегүләрне дә автор үзе язган. Әлифбадагы текстлар саф татарча, теле матур, фикере киң. Китап баланы тормыш көтәргә өйрәтүе белән дә кыйммәтле.

Д. Гобәйди — үз заманының күренекле мәгърифәтчеләреннән берсе. Аны тирә-як авылларда гына түгел, Казанда да яхшы белгәннәр. Октябрь революциясеннән соң халык аны хөрмәтләп искә алган, хәтта аның батырлыгын мактап авыл сәхнәләрендә спектакльләр уйналган. Ә соңрак ул бөтенләй диярлек онытылган. Кешенең кадере беткән шәхес культы елларында Д. Гобәйди генә түгел, башка бик күбәүләр дә әнә шулай онытылуга дучар ителде.

Әгерҗе якларында аны күреп белүче якташлары да исән түгел инде. Әнә шулай кайчандыр ихтирам ителүче шәхеснең тамыры өзелгән. Районда гына түгел, тәнкыйть әһелләре, язучылар җәмәгатьчелеге дә аны бөтенләй белми диярлек. Бик кызганыч, ләкин бу — чынбарлык.

Аның 1956 елда басылып чыккан «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелми калуы да әнә шул хакта сөйли түгелме соң? Соңрак чыккан әдәбиятка мөрәҗәгать итеп карадым. Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Татар әдипләре» (1979) дигән хезмәтендә дә Давыт Гобәйдинең исеме бөтенләй телгә алынмый. 1980 елда дөнья күргән «Татар балалар поэзиясе»нә ул «Шүрәле каргаган авыл» риваяте белән керергә хаклы иде. Һаман шул бер сүз: белмәгәннәр, күрәсең! Дөрес, «Татар әдәбияты тарихы»ның өченче (1986) һәм дүртенче (1989) томнарында Давыт Гобәйди фамилиясе бер-ике урында саналып кителә кителүен. Ул кем? Белмәгән кеше өчен бу исем һаман да табышмак булып кала бирә.

Казаннан еракта, эчкәрге татар авылларының берсендә торып мәгърифәт нурлары тараткан һәм халык бәхете өчен корәштә корбан булган Давыт Гобәйдинең бүгенге игътибардан читтә калуы бик аяныч.

Безнең белүебезчә, Әгерҗе районында данлыклы якташлары исемендә бер генә колхоз да, бер генә урам яисә мәктәп, пионер отряды яки дружинасы да юк. Ә кирәк иде, югыйсә.

Ә менә Колчак бандалары тарафыннан Давыт Гобәйди кебек үк үтерелгән мордва-

лы Молчановка Сарсык-Омга авылында авылдашлары музей ачканнар. Моның белән генә дә канәгатьләнеп калмаганнар, бәлки мәктәп каршындагы урамга обелиск та утыртып куйганнар. Ә без?!! Үзебез өчен үзебезгә кайгыртырга кирәк, юкса безнең өчен кайгыртучы табылмас.

Дөрес, кайчандыр Кырынды авылы мәктәбендә бик әйбәт музей булган булуын. Музей үз вакытында зур абруй казанган, укучыларны патриотизм рухында тәрбияләүдә ярдәм иткән.

Тик менә яңа килгән мәктәп директоры гына аның әһәмиятен аңлап җиткермәгән. Музей пионер бүлмәсенә әйләндерелгән. Аның әйберләре башта колхоз идарәсе бинасына күчерелгән. Бер елдан музейга анда да урын тарайган. Колхоз рәисе, музей өчен иң кулай урын автопарк, дигән фикергә килгән. Нәтиҗәдә, музей экспонатлары бүгенге көндә юкка чыгып бара.

Халык бәхете өчен көрәштә шәһит булган шәхесләрне без һәрвакыт тәкъдир итәргә бурычлыбыз. Давыт Гобәйди хөрмәтенә ачылган музейны туздырып, экспонатларын амбарга чыгарып ташлау, аларны кадерсезләү — вөҗданың алдында зур җинаять ясау һәм хәтерсезлек ул!

Әлбәттә, теләк булганда, район җитәкчеләре якташларының балаларга һәм яшүсмерләргә генә түгел, бәлки олы яшьтәге гражданнарга да патриотик тәрбия бирүдәге әһәмиятен аңласалар, һичшиксез, райондагы берәр колхозга яисә мәктәпкә Давыт Гобәйди исеме бирелер, дип ышанасы килә. Район үзәгендә музей да ачылыр, хәтта мәгърифәтчегә һәйкәл куярга да мөмкинлек табылыр. Минемчә, район хезмәт ияләре шундый якташларын хөрмәт итүдән читләшмәсләр.

Моннан ун ел элек үк шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов үзенең «Давыт Гобәйди» дигән шигырендә, барыбызның да бурычларын бергә берләштергән кебек, болай дигән иде:

...Син табигатьтә бер имән идең,
Илдән бары илең каршында.
Үлем алдыннан әйткән сүзләрең
Нник язылмаган кабер ташыңа?
Ник язылмаган?!
Ә бит аларны
Безнең йөрәкләр кабатлап бара:
— Иә, кулны артка каерып кара!
— Иә, безне илдән аерып кара!
— Иә, бөгеп кара безнең беләкне!
— Иә, җиңеп кара безнең йөрәкне!

Сүземнең ахырында кечкенә бер өстәмә бирүне дә кирәк табам: әлеге мәкаләне язуда һәм материаллар туплаудагы ярдәмнәре өчен Фоат Садыйков һәм Фәрит Шәрифуллин иптәшләргә зур рәхмәтемне белдерәм.

# ДУСЛЫК ТИГЕЗЛЕКТӘН БАШЛАНА

Айдар Хәлимнең «Казан утлары» журналының 1990 елгы 11 нче санында басылган «Иле барның теле бар» дигән әңгәмәсен өченче кат укып чыктым.

Башкортстандагы татар тормышының көзгесе булган ул әңгәмә.

Шул уңайдан минем дә бер-ике сүз әйтәсем килеп китте.

Шөкер, күп мәшәкатьләр, зур тырышлыклар белән Башкортстан Республикасы суверенлык алды. Ә анда яшәүче татарларга ни бирде бу суверенлык? Туймазыда «Уяну» исемле газета һәм татар театры ачу белән эш беттеме? Ә татарның төп проблемалары элеккечә хәл ителмичә калды. Шулай булгач, башкорт һәм татар дуслыгын ныгыта алырбызмы икән?

Заманны кызылга манып, барысына түзеп яшәп ятканда, башкортча укытырга дигән фәрман бирелде. Мәктәп директоры районнан кайта да чигенер урын юклыгын белдерә. Әти-әниләр җыелышы ясыйбыз — аларның балаларын башкортча укыта башларга ризалыгын алу өчен эшләнә бу. Күбесе эндәшми, сүзсез генә карышуны белдерә. Шунда дүрт баласы да мәктәпнең төрле классларында укыган, Нәҗибә Рәүпова дигән бер ана авылдашларына карата мондый сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

— Нишлисез сез, авылдашлар! Нигә бер сүз дә әйтмисез, балаларыбызны ни эшләтәчәкләрен әллә аңламыйсызмы? Уяныгыз, әйтегез үз сүзегезне! Ата-бабаларыбыз каршында ни диярбез? Бу гөнаһ безнең буынга төшә бит, ник онытгыгыз телебезне, диярләр. Ни дип җавап бирербез? Явыз Иван патшадан соң бу — икенче мәртәбә чукындыру кебек була бит...

Икенче көнне үк башкортча укыту башланды. Китаплар юк, укытучылар башкортча белмиләр. Башта башкорт китабыннан укырга гына өйрәндек. Менә шул дәрәҗәдә барды башкорт телен өйрәнү.

Ниһаять, яңадан татарча укытуга кайттык. Ләкин һәрьяклап каршылыкка очрадык. Тагын китаплар юк, имеш, тагын укытучыларны татарчага өйрәтергә кирәк, диләр. Кая карама, тоткарлау. Башкортстан ник бер татарча китап бастырып чыгарсын!

Минем энем — һөнәре буенча нефть чыгаручы. Ул паспорт алыштыру чорын (1978 ел) болай искә ала:

— Милләтеңне башкорт дип язабыз,— диләр.

— Ярый. Ә акчалата күпме бирәсез? — дидем, шаярып.

— Эштә күтәрелерсең, орден-медальләр булганда — өстенлек, укырга кергәндә шулай ук. Башкортстанда яшисең бит.

— Боларның берсе дә миңа кирәк түгел. Берүк минем милләтемә кагылмагыз! Мин җиде буын ата-бабамны беләм,— дип кистереп җавап бирдем.

Безнең Башкортстандагы ярты миллион татарны башкортлаштыруның бер гади мисалы бу.

Менә ничә еллар инде, демократия сүзен кабатлый-кабатлый, демагогия белән шөгыльләнәбез. Укытучыларның август киңәшмәләренең берсендә фәрманнарның берсе: «Бер генә башкорт үз телендә укырга теләсә дә, аерым класс ачабыз»,— дип сөрән салган иде. Ә ни өчен татарга да түгел?

Бүгенге көндә районыбызның күпчелек авылларында, икешәр һәм өчәр башлангыч класс балалары бергә утырып уку сәбәпле, тиешле белем ала алмыйлар. Шуңа күрә югары классларда да өлгереш күрсәткечләре түбән. Ә соң кыскартылган кечкенә авыл мәктәпләренең һәм бүгенге башлангыч класс укытучыларының санын киметкәннән чыккан «экономия» ни эш майтарырга ярады икән?

Иншаллла, Башкортстанга мөстәкыйльлек яулап алуга ирештек (кәгазьдә һәм сүздә). Ләкин бу әле башкортныкы гына. Сессия трибунасыннан торып ничек кенә көлмиләр. Имеш, татар белән башкорт — маңгайдагы ике күз. Ләкин аларның берсе — мәгърипкә, икенчесе мәшрикъкә караган. Нинди образлылык! Безгә — безнең мәнфәгатьләрне дә яклый торган суверенлык кирәк.

Әнвәр НИЗАМЕТДИНОВ,
Башкортстан республикасы,
Туймазы районы, Югары Бишенде авылы.

# СИБЕЛГӘНСЕҢ, ХАЛКЫМ...

Татар халкының милли бәйсезлеккә ирешү өчен көрәше һәрвакыт уңышсызлыкка очрады. Моның төп сәбәбе булып татар халкының күп өлеше үз туган төбәгеннән — Идел буеннан китәргә мәҗбүр ителү. Хәзерге заманда, ягъни колониаль системадан баш тартырга яки аны яңартырга мәҗбүр булган хәзерге чорда, безнең татар милли эшмәкәрләре, Татарстан җитәкчеләре татар халкын Идел-Урал төбәгенә кире кайтару өстендә эшләргә тиеш. Бүгенге Татарстанның «бәйсезлеге» әлегә мөшкел хәлдә. Чөнки республикада татарлар күпчелек тәшкил итми. Татарстан шартларында, ягъни Россия уртасында калган милли республикада төп халыкның күләме җитәрлек булмаганда, мөһим милли мәсьәләләрне хәл итү өчен референдум кулланып булмый. Рус хөкүмәтеннән бәйсезлек даулап булмый. Ул, бәйсезлек булса да, ясалма рәвештә генә булачак.

Татарстан республикасының халкы күпчелек татарлар булсын өчен иң элек түбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип уйлыйм:

— Күрше өлкәләрдә, республикаларда татар халкы күпчелек булып торган район һәм авылларны Татарстанга кайтарып бирү. Ул җирләр барысы да элеккеге Казан ханлыгы җирләре һәм бу дәгъва тарихи яктан урынлы.

— Татарстандагы барлык югары һәм урта белем бирү уку йортларында укып чыккан татар милләтеннән булган белгечләрне Татарстанда эшкә калдыру. Бу аларга үзләренең ата-аналарын да акрынлап Татарстанга кайтару мөмкинлеген бирәчәк. Алар өчен торак мәсьәләсен хәл итү.

Шулай иткәндә генә, әкренләп булса да, татар халкын Татарстанда тупларга мөмкин.

Х. ГАЛИН.
Уфа.

# ҖЫР ЮЛЫ

Безнең өй инеш буена урнашкан иде. Челтәр кәрнизле тәрәзәләре исә чыршы, нарат, усак, каен, өрәңге, миләш агачлары белән капланган яшел тауга карап тора. Без, тиктормас малайлар, җәй көннәрендә шул сай инешне ерып кына идек тә, тау башына менеп, каен җиләге җыярга керешәбез. Аннары, уртак табын ясап, җиләкләрне кура яфрагына төреп ашый башлыйбыз. Шул чакта күзләрем авылыбыздан егерме чакрым чамасы ераклыктагы мари урманына килеп төбәлә. Яшькелт-зәңгәр, гаҗәеп матур, сагышлы серле бер моң булып, дөньяның чиге булып тоела иде миңа бу киңлекләр. Малайлар, җиләкләрен ашап бетергәч, мәтәлчек ата-ата аска таба төшеп китәләр. Ә мин искиткеч күренештән аерыла алмыйча, уй-хисләр кочагында тирбәнеп, эңгер-меңгергә чаклы еш кына тау башында утырып кала идем.

Әле дә булса шул сихри урынны сагынам, авылыма кайткан саен иң әүвәл тау башына юл тотам...

Бу юлы таудан төшеп килгәнемне муенына зәңгәр гәрәбә таккан, чиккән алъяпкычлы күрше Зәйнәп тәтә инеш буенда көтеп тора икән.

— Исән-сау кайттыңмы, улым? Баядан бирле карап торам үзеңә, хәйран озак йөрдең. Әниең дә тау башына менеп йөрергә ярата иде, мәрхүмкәй. Нәкъ син утырган аланлыкта утыра иде ул да. Нинди сере бардыр шуның... Әниеңне әйтәм, кулына берәр савыт ала иде дә, тауга менеп югала иде. Бераздан: «Әйдәле Зәйнәп, каен җиләге белән чәй эчик әле»,— дип, өенә чакырыр иде.

— Әйдә, утыр әле чирәмгә...— Зәйнәп тәтә сүзен дәвам итте:— Минем сиңа күптәннән сөйлисем килеп йөргән сүзем бар, син аны бүтән беркемнән дә ишетмәссең, мин исән чакта белеп кал... Салкын март иде. Сугыш еллары бигрәк тә чыдый алмастай салкыннарга туры килде җитмәсә. Әниең урын өстендә ята, хәле яхшыдан түгел. Әтиең сугышта, ике абыең сабакта. Мин көненә берничә мәртәбә әниең янына хәл белергә кереп чыгам. Иртәгә тынасы дигән көнне әниең әйтә миңа: «Зәйнәп, мин дөнья куйсам, үләр бу бала ди,— ди.— Кем карасын аны, һәркемнең үз мәшәкате үзенә җиткән бит». Әниеңнең күзләре юешләнде, ул туп-туры түшәмгә карый, йөзләре тагын да алсулана төште. Иртәгесен чана белән салам тартып кайтып киләм. Өегез янына җиткәндә бала елавын ишетәм. Чанамны куйдым да йөгердем сезгә! Керсәм, анаң сине каты итеп куенына кыскан, тәпиләрең идәнгә тими, анаң кочагында килеш асылынып торасың. Әниең кулларын аерып җибәрүгә, «гөрс» итеп идәнгә төшеп утырдың да елавыңнан туктадың. Әниең җан биреп тә өлгергән иде

инде... Аның дөньядан бер дә китәсе килмәде. Әниеңнең соңгы йөрәк тибешен ишетеп калган бала син. Менә, улым, әйтәсе сүзем шул иде сиңа...

Җырчыбыз Искәндәр Биктаһиров башкаруында «Уйлану» җырын тыңладыммы, тау башындагы балачагым аерымачык булып күз алдына килә дә баса.

*Сандугачкай килеп, тауга кунып*
*Сайрар микән иртә таңнарда.*
*Газиз башым кая куйыйм,*
*Китәр идем әллә кайларга...*

Тирән мәгънәгә бай шушы җыр — халык җилкәсенә төшкән авырлыкны, тарихи авазларны күңелләргә сала да куя. Башкару өчен ул җыр шактый катлаулы, һәрхәлдә, бу әсәргә тотыныр өчен кыюлык, үзеңдә шундый көч барлыгына ышанырга кирәк. «Уйлану» җыры Искәндәр башкаруында беренче тапкыр үзебезнең Опера һәм балет театры сәхнәсендә яңгыраган иде. Тамашачы җырчыны көчле алкышларга, чәчәкләргә күмде. Бу — талантлы җырчыга бәя бирү белән беррәттән, халкыбызның борынгы җыр хәзинәсен олылау, аның белән горурлану, аңа соклану билгесе дә иде.

Искәндәр Биктаһиров Чирмешән районының Югары Чагадай авылында туып үсә. Анда сигез классны тәмамлагач, тугызынчы класска күрше авылга йөри башлый. Биш чакрым араны Әчеле елгасы буйлап көн саен җырлап бара, җырлап кайта торган булган. Бигрәк тә озын җырлар, халык җырлары ошый аңа.

Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Казан химия-технология институтын уңышлы гына тәмамлый, инженер-механик дипломы ала. Искәндәр, әлбәттә, яхшы инженер да булыр иде, ул төпле кеше, кулыннан килмәгән эше юк. Ләкин җырга булган мәхәббәте көчлерәк икән шул! Һәм бу мәхәббәт Искәндәрне профессиональ сәнгать юлына тарта.

1975 елда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбленә яшь талантлар сайлап алу конкурсы уза. Йөздән артык егет һәм кыз җыелган булса да, алар арасыннан нибары унлап кеше генә ансамбльгә кабул ителә. Бәхетлеләр арасында Искәндәр дә бар. Җырчы бертуктаусыз үз осталыгын арттыру өстендә эшли, күп тә үтми, ансамбльнең солисты дәрәҗәсенә күтәрелә һәм... җыр һәм бию ансамбле 1977 елның җәендә Туниста була. Борынгы рим театры Карфагенда җырлый Искәндәр. 1979 елның гыйнвар-февраль айларында исә ерак Африка илләре — Нигерия, Бенин, Сенегалга бару бәхетенә ирешә. Төрле милләт халкы белән очрашулар, аларның көнкүреше, мәдәнияте белән якыннан танышу, төрле музейларга йөрү, кайбер кабиләләр белән аңгәмәдә катнашу — болар барысы да җырчының рухи яктан баета, халыклар тормышына якынайта. Концерт залларында үзебезнең татар көйләре яңгыравы, дәртле биюләр, гарәп, негр, башка халыклар утырган тамашачы залын гына түгел, хәтта үзебезнекеләрнең күңелләрен дә рухландыра, дөньяга карашны киңәйтә, татар кешесе булу, татар сәнгате кешесе булу, бигрәк тә татар җырчысы булу горурлыгын арттыра.

Җыр сөючеләр беренче ишетүдән, беренче күрүдән ук Искәндәр Биктаһировны якын итте, үз итте. Аның башкаруында «Уел», «Сәфәр», «Дүртөйле», «Ядкарь», «Дусларыңны онытма», «Озата бармa», «Гармун, гармун», «Ак яулыклы әнием» кебек гаять табигый яңгыраган җырлар замандашларыбызның күңел юлдашына әверелде. Филармония классларында, җырчы үзе әйтмешли, бик тырышып, бик озак итеп фортепьянада уйный-уйный шөгыльләнә торгач, халкыбызның озын җырларыннан «Казан сөлгесе», «Зиләйлүк», «Уйлану»ны берминди аккомпанентсыз зур осталык белән башкару дәрәҗәсенә ирешә. Консерваториядә узган ике еллык стажировка да Искәндәргә җыр сәнгатен тиреннән үзләштерү, талантын камилләштерүдә зур ярдәм итте.

Ул илебезнең татарлар яшәгән төбәкләрендә еш була. Читтә яшәү бер дә җиңел түгел кешегә. Туган иленнән озакка яки бөтенләйгә аерылганнар моны яхшы белә. Җырчының сыктап, сагынып яшәүчеләрне еш очратканы бар. Кайда гына булмасын, йөрәгеннән чыккан җылы сүзләре белән дә, киләч йөзе белән дә, шат, моңсу җырлары белән дә кеше хәленә керә белә ул. Җыр илендә Искәндәр — үзе бер дөнья. Үзенчәлеге белән, җыр мирасына карата көчле мәхәббәте белән, башкару ихласлыгы белән, бәрхет тембрлы матур көчле табигый тавышы белән кабатланмас олы бер дөнья! Искәндәр үзе тотынган һәр әсәрнең фәлсәфи җһәцен ачып бирә ала торган җырчы, ул үткәннәр белән бүгенгене тоташтыра алу сәләтенә ия.

Иҗат лабораториясе белән якыннанрак танышып йөргәндә, җырчыга үземне күптән кызыксындырган бер сорау бирдем:

— Сәхнәгә чыккан саен җырлыйсың килеп чыгасыңмы яки тамашачы алдында үз бурычыңны үтәү теләге белән генәме?

Искәндәр ике дә уйлап тормыйча җавап бирде:

— Туйдырса, бетте диган сүз ул. Сәхнә артында киемнәрне алыштырып йөргәндә үк, көзге янына килеп пөхтәләнеп торганда ук дулкынлана башлыйсың, каяндыр көтмәгән көч, илһам иңә. Тизрәк чыгып җырлыйсың килә башлый, һәм һәрвакыт, хәтта көненә икешәр концерт бирергә туры килгәндә дә шулай.

— Ә репертуарны ничек баетасың?

— Монда эш болайрак тора. Җыр китапларыннан эзләнәсең, газета-журналларны актарасың, күңелгә ятышлы шигырьләр эзлисең, эчтәлегенә игътибар итәсең. Әгәр дә бөтен яктан да күңелгә хуш килгәнне тапсаң, уйланып йөри башлыйсың. Якынрак белгән композиторга барасың, киңәшәсең. Бераздан ул тулы бер әсәргә әйләнә. «Биек тауның башларында» дигән һәм башка җырлар белән дә шулайрак булды.

Бөек шагыйребез Хәсән Туфан сүзләренә язылган «Ромашкалар» җырын искә төшерик. Аны башка җырчылар башкаруында да күп тапкырлар тыңлаганым бар. Әмма Искәндәр, киң диапозонлы вокаль мөмкинлекләреннән файдаланып, бу җырга мелизмнар, бизәүләр өсти, шагыйрьнең рәнҗетелгән күңелендәге уй-серләрен ачып бирә.

Әйтерсең, җырчы үзе дә ерак далада шагыйрь белән тоткында бергә булган. Әйтерсең, шагыйрь башына төшкән авыр газапларны җырчы үзе дә кичергән.

Бүгенге көндә Искәндәр Биктаһиров — эстрада бригадасының җитәкчесе. Моннан ел ярым элек аңа Татарстан җөмһүриятенең атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелде. Артистның иҗат юлының уртасы гына әле, талантның киңәйгән, чәчәк аткан чагы гына. Аңа зур уңышлар юлдаш булсын. Юллары халык йөрәгенә илтсен. Иҗатының бөтен бәхете — шул юлда гына.

Хәниф ФӘЛӘХЕТДИНОВ.
Казан.

---

*Котлыйбыз*

## Хәниф Хәйруллинга 60 яшь



Язучы һәм журналист Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин 1931 елның 12 сентябрендә Татарстанның Сарман район үзәгендә туган.

1950 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул хезмәт юлын Азалак авылында укытучы буларак башлап җибәрә. Аннары Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң «Югары уңыш өчен» (Сарман) һәм «Байрак» (Буа) гәзитләрендә эшли. Хәзерге көндә Сарманда яши һәм эшли.

Х. Хәйруллинны язучы итеп таныткан әсәре — «Канатлар талмасын» повесте. 1971 елда язылып, башта «Казан утлары»нда, соңыннан аерым китап булып чыккан бу әсәрендә автор алтмышынчы еллар колхоз тормышында барган үзгәрешләр, яңалыклар җирлегендә хуҗалык белән идарә итүдәге уңыш вә кимчелекләр аша заман өчен характерлы каршылыкларны ача.

Х. Хәйруллин авыл тормышына багышланган һәм кеше холкын әхлакый яктан, фәлсәфи-психологик планда ачкан «Картлык... кемгә шатлык?» исемле повесть авторы буларак та укучыларга билгеле. Ул шулай ук, «Бакыр базының серләре», «Алмаз ихтыяр», «Канлы еллар, авыр еллар», «Хуҗида үскән батыр» кебек очеркларын һәм балалар өчен «Тылсымлы таяк табышы» исемле мажаралы повестен иҗат итте.

Хәниф Хәйруллин — 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Татарстан Язучылар берлеге һәм «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы юбилярларны ихлас күңелдән котлыйлар һәм аларга нык сәламәтлек, озын иҗат гомере телиләр.*

### ТАТАРСТАН ПАРЛАМЕНТЫНДА

Август ахырында ТССР Югары Советының чираттан тыш 6 сессиясе узды. Анда агымдагы хәл, республикабыз бәйсезлеген саклап калу һ. б. мәсьәләләр тикшерелде. Сессиядә чыгыш ясаган күпчелек депутатлар, шул исәптән, язучылар — Фәүзия Бәйрәмова, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллиннар Татарстан президенты Минтимер Шәймиевнең путч дәверендә законлылык нигезендә дөрес һәм сабыр эш итүен билгеләп, аңа тулысынча ышануларын белдерделәр. Депутатлар күпчелек тавыш белән Республикабыз житәкчелегенең хокукны бозуларга юл куймавын, Татарстанда путч дәверендә тыныч, эшлекле шартлар тәэмин ителүен раслап карар кабул итте.

Сессия «30 август — Татарстан ССР төзелү көне — бәйрәм көне», дип махсус закон чыгарды.

### ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КИЛЕШҮЕ

16 августта Уфа шәһәрендә Татарстан белән Башкортстан республикалары арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды. Аның 4 статьясында: «БССР да яшәүче татарларның мәдәни-тел һәм башка милли ихтыяжларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудырып, Башкортстан татар мәдәниятенең казанышларын пропагандалый», дигән юллар да бар.

### ХАЛЫКАРА АССАМБЛЕЯДА

БТИҮ президенты, ТССР халык депутаты Марат Мөлеков һәм БТИҮ эшлеклесе, КДПИ доценты Хәләф Гарданов август башында Голландиядә уздырылган Вәкаләтсез милләтләр һәм халыкларның 11 ассамблеясе эшендә катнаштылар. Алар монда татар халкының бәйсезлек өчен көрәше турында сөйләделәр. Ассамблея Татарстанның мөстәкыйльлеген танырга чакырып, СССР һәм РСФСР президентларына, барлык илләрнең парламентларына мөрәҗәгать кабул итте. Ассамблея утырышлары барган залда ТИҮ әләме эленүе, дөнья матбугаты, радио-телевидениесе хәбәрчеләренең Татарстан вәкилләреннән күп тапкыр интервьюлар алуы, аларның эфирда яңгыратылуы һәм матбугатта бастырып чыгарылуы жиһан җәмәгатьчелегенең безгә кызыксыну һәм теләктәшлек күрсәтүен дәлилләде.

### УФАДА СӘЯСИ КИЧӘ

Уфаның РТӘ заводы мәдәният сараенда Татарстан бәйсезлеген яклауга багышланган кичә үткәрелде. Аны БТИҮ, «Азатлык» татар яшьләре берлеге оештырды. Кичәдә БТИҮ җаваплы сәркатибе Кәрим Яушев, шагыйрь Фәрит Габдерәхим, журналист Фаягөл Фәткуллина һәм башкалар чыгыш ясады. Татарстан һәм Башкортстан сәнгать осталары зур концерт бирде.

### БЕЗНЕ ЯКЛАП

Гаделлекне яклавы белән бөтен дөньяга танылган Елена Боннер (ул мәрхүм академик А. Д. Сахаровның хатыны) 29 августта Үзәк телевидениедән чыгыш ясап, РСФСР президентына:

— Борис Николаевич, үзегез вәгъдәләгән мөстәкыйльлекне Татарстанга һәм башка республикаларга ни өчен бирмисез? Халыкларның иреккә булган изге омтылышын якларга кирәк! — дип мөрәҗәгать итте.

### ЯҢА НӘШРИЯТ

Быел КамАЗ акционерлык җәмгыятенең газета-китап нәшрияты барлыкка килде, аның матур әдәбият редакциясе мөдире итеп яшь язучы Вахит Имамов билгеләнде.

Күптән түгел яңа нәшриятның беренче китабы — «Әфган кызалаклары» дөнья күрде. Әфганстан сугышында һәлак булган Чаллы егетләре хакында очерклар һәм истәлекләр тупланган бу басма әлегә Татарстан китап нәшрияты белән берлектә чыгарылган. Тиздән КамАЗ нәшрияты мөстәкыйль эшли башлаячак, Чаллы төбәгендә яшәүче каләм ияләре Казанга гына исәп тотудан котылачак. Моңа шушы нәшриятта басылачак «Аргамак» әдәби журналы да житди ярдәм итәр.

### УФАДА ТАТАР ДӘҮЛӘТ ТЕАТРЫ

Уфада милләттәшләребез тырышлыгы белән берничә ел элек ярым профессиональ «Нур» татар театр-студиясе оештырылган иде. Кайбер спонсорларның ярдәмендә ул инде беренче спектакльләрен куярга өлгерде, тамашачылар алдында житди имтихан тотты. Башкортстан Министрлар Советы карары белән аңа хәзер Дәүләт театры статусы бирелде. Уфа сәнгать институтында аның өчен актерлар әзерләнә башлана, 1992—1993 елларда махсус бина да корылырга тиеш.

### ПОЛЬША ТАТАРЛАРЫ

Быел Польшаның Фән нәшриятында «1918—1939 елларда Польша татарлары: иҗтимагый-мәдәни һәм дини тормышлары» дигән китап басылып чыкты. Аның авторы — милләттәшләрен күптәннән бирле өйрә-

нел кила торган Али Мискевич. Ул шушы хезмәтендә XIX йөзнең икенче яртысыннан алып безнең көннәргәчә дәверне яктырта. Әлегә кадәр аз өйрәнелгән этнографик төркемне төрле яктан гәүдәләндерер өчен Али Мискевич сирәк очрый торган басма чыганакларга, шәхси архивларга, аерым кешеләрнең истәлекләренә таяна. Китапта бирелгән 45 фоторәсем һәм карталар Польшадагы милләттәшләребез тормышын тагын да ачыграк күзалларга булыша.

## БӨТЕНСОЮЗ ТАТАР РӘССАМНАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

28 августта Татарстан Рәссамнар берлеге күргәзмәләр залында ил күләмендәге беренче хәзерге заман татар сынлы сәнгате «ТАТАР—91» күргәзмәсе ачылды. Анда Казан, Санкт-Петербург, Минск, Омск, Пенза, Уфа, Хабаровск — барысы 25 шәһәрдә яшәүче 138 милләттәшебезнең хезмәте куелды. Бу күргәзмә әүвәл Санкт-Петербург шәһәрендә күрсәтелгән һәм күпләгән тамашачыларның ихтирамын казанган иде.

## ӘҺӘМИЯТЛЕ МӘСЬӘЛӘ

Республикабызда байтак музыка мәктәпләре, училищеләре һәм консерватория эшләп килсә дә, шушы тармакта милли белгечләр, иҗатчылар житешми. Чөнки бары урыс теленда гена укытыла торган әлеге белем учакларына татар яшьләре бик аз керә, кергәннәре дә туган теленнән, туган моңыннан аерылып тәрбияләнә. Музыка мәдәниятебезне чын мәгънәсендә тергезү, яңарту өчен Татарстанның суверенитетын ныгыту, дәүләт телен гамәлгә кертү нигезендә татарча белем бирә торган махсус Республика музыка училищесын ачарга кирәк. Музыка укытучылары Р. Ильясов, И. Алмазов, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре Т. Сөләйманов, Р. Халитова, Республикабызның атказанган сәнгать эшлеклесе Д. Айдаров, сәнгать фәннәре кандидаты А. Алмазовалар менә шушы мәсьәләне күтәреп республикабыз Президентына, Министрлар Советы рәисенә һәм ТИҮ житәкчелегенә мөрәҗәгать иттеләр.

## МИЛЛИ МӘКТӘБЕБЕЗ ТЕРНӘКЛӘНӘ

Торгынлык елларында хәтта милли башкалабыз Казан да туган мәктәбеннән коры кала язган иде. Былтыр, ниһаять, уңай якка үзгәреш башланды — берьюлы өч татар гимназиясе ачылды. Быел шулар сафына янә алты гимназия өстәлде. Шәһәрнең гомуми белем мәктәпләрендә исә татарча укыта торган 40 класс тергезелде.

## ЯҢА РЫЦАРЬЛАР

Халыклар арасында дуслык, тигезлек, гаделлек, жирдә тереклекне саклау өчен көрәшүче бөтен Дөнья Рыцарьлар Конфедерациясе өч меңгә якын әгъзаны берләштерә. Бу оешмада безнең ил вәкилләре әлегә санаулы гына. Күптән түгел алар сафына Татарстан парламенты депутатлары — шагыйрьләребез Равил Фәйзуллин, Рәзил Вәлиев, галимнәребез — фән докторлары Сәлам Алишев һәм Мирфатыйх Зәкиев тә кабул ителде. Рыцарьләр Конфедерациясе Баш Берлеге (Австралиянең Сидней шәһәрендә урнашкан) әгъзасы Әбрар Кәримуллин белдерүенчә, хәзер илебездәге уникe рыцарьның бишесе — татар милләтеннән. Бу дөнья җәмәгатьчелегенең халкыбыз тарихына, аның ирек өчен көрәшенә ихтирам һәм теләктәшлек күрсәтүе билгесе.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

ТССР Министрлар кабинеты карары белән Татарстан театр эшлеклеләре берләшмәсенең Актерлар йортына күренекле артист, режиссер, драматург Габдулла Кариев исеме бирелде.

## ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Август аенда күренекле композиторыбыз, СССР халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Яхинга 70 яшь тулды. Шушы уңайдан Казанда аның иҗатына багышланган тантаналы кичә уздырылды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР, БҮЛӘКЛӘР

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен журналыбызның бүлек редакторы, язучы Тәүфикъ Әйдигә «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Музыка сәнгатебезне үстерүдәге хезмәтләре өчен Казан консерваториясе укытучысы профессор Шамил Низаметдиновка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. Шушы ук уку йортының мөгаллиме Рафаэль Билалов исә Мактау билгесе ордены белән бүләкләнде.

* * *

Сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен КТИИ укытучысы, архитектор Закир Батраевка һәм кинорежиссер Эдмас Үтәгәневкә «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# УКА БЕЛӘН ЧИГЕЛГӘН

Ука белән күн әйберләрне чигү татар милли сәнгатендә аерым бер тармакны тәшкил итеп тора. Урыста бу шөгыльне алтын белән чигү дип йөртәләр. Сәнгатьнең бу төре чигү жебенең алтынга манчылганы өчен генә түгел, халык иҗатында бик сирәк очраганга күрә дә ифрат кыйммәт санала. Мондый чигеш белән һәрьяклап үскән, хезмәт житештерүчәнлеге алга киткән һәм мул тормышка ирешкән җәмгыятьтә генә шөгыльләнергә мөмкин. Үзеннән-үзе аңлашыла ки, алтын чигешле зиннәтле әйберләрне ясаганчы, аны кирәксенүче хөр күңелле, мул тормышлы асыл затларның булуы да шарт.

Татарларда мондый мөмкинлекләр бик борынгы заманнарда ук тудырылган. Бу төр сәнгатьнең тамырлары Болгар чорына ук барып тоташа. XVI гасырда, Казан ханлыгының җимерелүе, Казан каласындагы күп осталарның һәлак ителүе аркасында ука белән чигүчеләр ерак авылларга таралырга мәҗбүр була. Бу хәл исә аны гомумхалык сәнгатенә әйләндерә.

Журнал тышлыгында күрсәтелгән букчадагы укалы чигеш шулай ук бик ерак дәверләргә карый. Бу — Идел-Урал татарларының аеруча зиннәтле саналган әсәре. Мондыйны башка тарафларда табып та булмый. Булса да бары Касыйм татарларында гына очрарга мөмкин. Урысларда күренсә, сәнгать белгечләре раславынча, алар аны татар остасыннан чиктергәннәр яки күчереп кенә алганнар. Аларда очраган бу төр сәнгать әсәрләрендә бары татарлар гына ясый алган чалымнар ярылып ята.

Күнгә чигү төрки халыкларына гомумән хас. Таулы Алтай кабиләләрендәге бу сәнгати һөнәрне безнең эрага кадәрге бер меңенче елларда ук күзәтергә була. Ука белән чигү сәнгате тарихның әнә шул ераклыгына барып тоташа. Без, сәнгать фәннәре докторы Фоат Вәлиев тикшеренүләренә таянып, шуны әйтә алабыз: татарларның ука белән чигү сәнгате болгар чорына карый. Моны хәтта урыс елъязмалары да расլый: «...Болгар ханының (1236 ел) яшел күн путасы ука белән чигелгән иде...»

Казан ханлыгы чорында татарларның сәхтиян күн эшкәртү осталыклары тагын да югарырак дәрәҗәгә ирешә. Казанлылар ука белән чигелгән күн әйберләрне урыс патшасы сараена да, боярларга да озатып торалар (XVI—XVII гасырлар). Алай гына да түгел, татар эшкәрткән йомшак күн һәм ука белән чигелгән затлы күн әйберләренең даны бик еракларга тарала. Казах, кыргыз, үзбәк, уйгыр кешеләре «күн» төшенчәсен «болгар» сүзе белән тәңгәлләштереп йөртә башлыйлар.

Инде кабат журнал тышлыгындагы сурәткә — ука белән чигелгән күн букчага күз салыйк! Бу — һәрьяктан житеш тормышта яшәүче татар кызының милли киеменә өстәмә бизәк. Шушындый зиннәтле букчалар болгар-татар кызларының киң күн путаларына тагыла торган булган. Һәм алар стилендәге бу сыйфат XIX гасырга кадәр сакланып килгән.

Букчада хатын-кызга иң кирәкле вак-төяк әйберләр: кулъяулык, тарак, көзге, кечкенә кайчы, җан саклагыч бөти йөртелгән. Мондый букча татар кызының ука белән чигелгән бәрхет калфагына, чигүле камзулына төстәш булып, ифрат та килешеп торган.

Татарның ир-атлары да киң путаларга беркетелгән күн букча йөрткән. Алар аңа, кирәк чакта ут урләтер өчен, чакма ташлар салганнар, соңрак тәмәкеләрен дә шундый ук букчага сала башлаганнар. (XX гасыр).

Тышлыкта күрсәтелгән букчаның зурлыгы — 16X20 см. Аны «авызы» тирәсендәге тишекләр аша үткәрелгән нәфис күн бау белән бөреп-ябып куярга мөмкин. Букча кызгылт-көрән төстәге йомшак күннән тегелгән. (Ихтимал, «кызыл күн» төшенчәсе дә шуннан калгандыр әле...) Чигешкә чәчәк бәйләме үрнәк итеп алынган. Мондый чәчәкләр җан саклагыч көчләргә дә ишарә. Ука-җеп күпертелгән рәсем өстеннән йөртелгән.

Бу әсәр XIX йөзнең беренче яртысына карый.

Инде шунысын да әйтик: журнал тышлыгына төшерелгән укалы чигеш әсәре СССР халыкларының этнография музеенда (Санкт-Петербург) саклана.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА—СӨЛӘЙМАНОВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның дүртенче битендә: танылган язучы һәм драматург Шәриф Хөсәенов.**

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# Укучыларыбыз игътибарына!

Алдагы еллар тәҗрибәсен һәм күп санлы укучыларыбызның теләген искә алып, журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан, бу санда 1992 ел өчен әзер квитанция тәкъдим итәбез. «Казан утлары»н алдырырга теләүчеләр, квитанциягә үзенең тулы адресын язып, исем-фамилиясен күрсәтеп, аны өзек сызык буенча кисә һәм элемтә бүлегенә тапшыра ала.

Исегезгә төшерәбез: «Казан утлары» — унике томнан торган еллык китапханә ул. Анда хәзерге татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләре, заманыбызның үткен мәсьәләләрен күтәргән язмалар, аянычлы һәм бай үткәнебезне яктырткан мәкаләләр урнаштырыла. Журналга ярты елга да, өч айга да язылырга мөмкин. Ләкин, алда әйткәннәрне истә тотып, татар халкының рухи дөньясын эзлекле күзәтеп-танышып бару өчен, аңа алдан ук бер елга язылып кую хәерлерәк.

Сезгә уңышлар теләп —
редакция хезмәткәрләре.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов: I

на 1992 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов: | I |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1992 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

# «КАЗАН УТЛАРЫ» — ИҢ ЯХШЫ БҮЛӘК!

Иң якын дустыңа, туганыңа яңа елга нәрсә бүләк итәргә?
Киңәшебез бар: **«Казан утлары»на бер еллык подписка** бүләк итегез!
**Бер еллык подписка** — ул бүгенге татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләреннән төзелгән 12 томлык саллы китапханә дигән сүз.
**Бер еллык подписка** — кимендә дүрт-биш роман, алты-җиде повесть, хикәяләр, драма әсәрләре, шигырьләр һәм поэмалар, заманның үткен мәсьәләләрен күтәргән ялкынлы мәкаләләр.
**Бер еллык подписка** — күп акча туздырмыйча китапханә туплауның иң җиңел юлы.

Журналның бер саны нибары 1 сум 80 тиен. Китап бәясе исә кимендә 6—7 сум булачак. Оттырмагыз!

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки)

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

1988 г. Обл. тип., г. Кострома, зак. 983, тир. 141.150.000

*«Казан утлары» 1992 елда*

## Җәмит Рәхимов

# БАТЫРША

Соңгы елларда Шиһабетдин Мәрҗани, Газиз Гобәйдуллин кебек күренекле галимнәрнең һәм башка авторларның саллы-саллы тарихи хезмәтләре бүгенге графикабыз нигезендә басылып чыгуга карамастан, татарның чын тарихы әле язылмаган. Тарихыбызда «ак таплар» һәм без әле исемнәрен дә юньләп ишетмәгән бөек шәхесләребезнең исәбе-хисабы юк. Әнә шул хаксызга онытылган каһарманнарыбызның берсе — Абдулла Гали углы Мәзгытдин. Заманына күрә үтә белемле, гадел, чая һәм гаярь, бәхәс-тартышларда җиңелүне белмәс бу затны халык, үзенчә олылап, Батырша дип йөрткән.

Шушы мәгърур исеме элегрәк Идел-Урал төбәгендә яшәүче халыкларның теленнән төшмәгән бу азамат кем булган соң?

Абдулла Гали углы Мәзгытдинне — Казан, Оренбург һәм соңрак оешкан Уфа губерналарына даны таралган укымышлы татар мулласын — халык яратып һәм хөрмәтләп, «татар Пугачевы» дип атаган. Чөнки ул — 1755 елдагы атаклы татар-башкорт восстаниесенең, ягъни Россиядәге беренче милли-азатлык хәрәкәтенең идеологы һәм җитәкчесе. XVIII гасырда татар халкының чиксез һәм чамасыз изелүенә, рәнҗетелүенә каршы халыкларны яуга күтәргән Батыршаның тормыш һәм көрәш юлы безнең Татарстан җире белән турыдан-туры бәйле. Әйтик, ул Тайсуган (хәзерге Әлмәт районы) һәм Ташкичү (бүгенге Арча районы) мәдрәсәләрендә белем ала. Күренекле татар шагыйре, ахун Габделсәлам Урай углы белән гомерлек дус була. Әлеге восстаниене башлау өчен фатиханы да аңардан ала. Инде яу бастырылгач, патша җәлладларыннан качып, хәзерге Лениногорск районына кергән Сугышлы (элеккеге исеме Иске Нәдер) авылының мәчете базында кыш чыга. Аннары гына үз иреге белән язмышын байтүрәләр кулына тапшыра һәм ул замандагы иң кырыс, әшәке Шлиссельбург төрмәсенә озатыла. Әмма аның көрәш дәрте сүрелми. Җир астындагы шушы караңгы, дымлы һәм салкын казаматта алты ел газапланганнан соң, бу коточкыч зинданнан качмакчы була. Хәл сакчыларга мәгълүм булгач, хибесханәдә ыгы-зыгы, тартыш куба. Әлеге тарткалашу вакытында Батырша кулына очраклы гына эләккән балта белән «төрмә фәрештәләре»ннән дүртесенең башларын чабып яра, үзе исә тигезсез көрәштә йөрәк параличыннан аягүрә җан бирә. Ләкин каһарманның изге эше югалып калмый, тагы уналты елдан соң Россияне тетрәткән Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы башлангач, Батыршаның «кыздырмак вә үгетләмәк» хатларыннан, аның иманлы сүзеннән илһамланган татарлар бөек халык явына кушылып китәләр.

Язучы Җәмит Рәхимов күптән түгел аның хакында «Батырша» дигән тарихи роман язып тәмамлады. Бу әсәр Батырша каһарманлыгы турында гына түгел, Оренбург төбәгенә урыслар үтеп керүен, татар халкының ул чактагы тормыш-көнкүрешен дә гәүдәләндерә. Әсәрдә йолаларыбыз, бәйрәмнәребез, гореф-гадәтләребез дә киң сурәтләнә. Түрәләр һәм халык, шәкертләр һәм остазлар, вак җанлылык һәм олпатлык, намуслылык һәм хыянәтчелек, дуслык, дошманлык, мәхәббәт романда узәк урынны били. Кыскасы, укучы бу әсәрне укыганда үнсигезенче йөздә яшәгән ата-бабаларыбызның җанлы вәкилләре һәм көрәш тулы киеренке хәяте белән якыннан танышачак.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог